# 2019 елга Татарстан Республикасы  башкарма хакимият органнары эшчәнлеге турында ХИСАП


Казан 2020

**Эчтәлеге**


| | |
|---|---|
| I. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШЕ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ | 3 |
| II. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКАРМА ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ | 12 |
| КЕШЕ КАПИТАЛЫ | 12 |
| Демография | 12 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсе һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру | 18 |
| Хезмәт базары, эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү һәм социаль яклау | 26 |
| Үсеш нигезе буларак мәгариф | 31 |
| Яшьләр сәясәте | 42 |
| Мәдәният үсеше. Креатив индустрияләр | 45 |
| Граждан җәмгыяте үсеше | 53 |
| ТИРӘЛЕК, РЕАЛЬ КАПИТАЛ | 61 |
| Транспорт-логистика инфраструктурасы | 61 |
| Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык | 66 |
| Татарстан Республикасында агломерацияләрне үстерү | 77 |
| Туристлык-рекреация комплексын үстерү | 81 |
| САТУ БАЗАРЛАРЫ | 91 |
| Тышкы икътисадый элемтәләрне үстерү | 91 |
| Нефть-газ-химия комплексы | 98 |
| Энергетика комплексы | 101 |
| Машина төзү һәм башка эшкәртү производстволары комплексы | 105 |
| Агросәнәгать комплексы | 126 |
| Сәүдә комплексы | 130 |
| ИНСТИТУТЛАР. ЭШКУАРЛЫК | 133 |
| Стратегик планлаштыру | 133 |
| Илкүләм проектлар | 134 |
| Эшкуарлыкка ярдәм итү | 135 |
| Дәүләт идарәсе | 146 |
| ИННОВАЦИЯЛӘР | 162 |
| Инновацияле үсеш | 162 |
| Электрон рәвештә хезмәт күрсәтү | 191 |
| ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ | 195 |
| Җир һәм су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану | 195 |
| Әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметү | 200 |
| ФИНАНС КАПИТАЛЫ ҺӘМ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР | 207 |
| Финанс ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге | 207 |
| Инвестиция сәясәте | 213 |
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КОМИТЕТЛАРЫННАН ҺӘМ ДЕПУТАТ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕННӘН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКАРМА ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА СОРАУЛАР ИСЕМЛЕГЕ БУЕНЧА МӘГЪЛҮМАТ | 221 |

# I. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШЕ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ




Татарстан Республикасы төп макроикътисадый күрсәткечләр буенча элеккечә – Россия Федерациясенең алдынгы төбәкләре сафында. Республика Россия Федерациясе субъектлары арасында тулаем төбәк продукты күләме буенча – алтынчы, авыл хуҗалыгы буенча – дүртенче, сәнагать җитештерүе, төзелеш һәм торакны файдалануга тапшыру буенча – бишенче, төп капиталга инвестицияләр кертү буенча – алтынчы, ваклап сатудагы товар әйләнеше буенча җиденче урында тора.

### Россия Федерациясе субъектлары һәм Идел буе федераль округы төбәкләре арасында Татарстан Республикасы рейтингы

| Макроикътисадый күрсәткечләр | 2019 ел | |
|---|---|---|
| | Россия Федерация-се субъектла-ры арасында | Идел буе федераль округы төбәкләре арасында |
| Тулаем төбәк продукты күләме (2018 ел) | 6 | 1 |
| Сәнәгать җитештерүе күләме | 5 | 1 |
| Авыл хуҗалыгы җитештерүе күләме | 4 | 1 |
| Төп капиталга кертелгән инвестицияләр күләме | 6 | 1 |
| «Төзелеш» эшчәнлеге төре буенча башкарылган эшләр күләме | 5 | 1 |
| Торакны файдалануга тапшыру | 5 | 1 |
| Ваклап сатуда товар әйләнеше | 7 | 1 |
| Уртача номиналь айлык хезмәт хакы | 36 | 2 |
| 1000 кешегә карата исәпләгәндә халыкның табигый артуы | 19 | 1 |
| Эшсезлекнең теркәлгән дәрәҗәсе (декабрь ахырына)[1] | 8 | 2 |

[1] Урыннарга бүленеш күрсәткечнең артуы тәртибендә бүленешенә нигезләнеп исәпләнгән (беренче урын – иң түбән (иң яхшы), соңгы урын – иң югары (иң начар) күрсәткеч.

**Татарстан Республикасы тулаем төбәк продукты һәм Россия Федерациясе тулаем төбәк продукты динамикасы**




2019 ел йомгаклары буенча тулаем төбәк продукты күләме, бәяләүләр буенча, 2 584,3 млрдсум тәшкил иткән, ягъни 2018 ел дәрәҗәсенә карата – 101 процент. Икътисад үсешенә сәнәгать житештерүе һәм авыл хуҗалыгы төп өлешне кертте.

**2019 елда икътисадый эшчәнлек төрләре буенча Татарстан Республикасының ТТП житештерү структурасы (бәяләү)**




Икътисад структурасында иң зур өлешне, традиция буенча, сәнәгать алып тора һәм 48 процентны тәшкил итә (шул исәптән файдалы казылмалар чыгару – 29,1 процент, эшкәртү производстволары – 16,2 процент, электр энергиясе, газ, пар

белән тәэмин итү; һава әйләнешен булдыру – 2,3 процент, су белән тәэмин итү; су бүлү, калдыкларны җыюны һәм утильләштерүне оештыру, пычрату очракларын бетерү буенча эшчәнлек – 0,4 процент), күпләп һәм ваклап сату 11,6 процентны, төзелеш 8 процентны, авыл хуҗалыгы 6,1 процентны тәшкил итә.

**Сәнәгать**


Сәнәгать җитештерүе индексы 2018 ел дәрәҗәсенә карата 102,4 процент, төяп җибәрелгән продукция күләме 2 877 млрд сум[1] тәшкил итте.

Файдалы казылмалар чыгаруда җитештерү индексы 2018 ел дәрәҗәсенә карата – 101,1 процент, эшкәртү производстволарында – 103,5 процент, электр энергиясе, газ, пар белән тәэмин итүдә; һава әйләнешен булдыруда – 103 процент, су белән тәэмин итүдә; юынтык су агызуда, калдыкларны җыю һәм утильләштерүдә, пычрату очракларын бетерү буенча эшчәнлекне оештыруда 98 процент тәшкил итте.

Эшкәртү производстволарының түбәндәгеләрендә үсеш күзәтелде: кокс һәм нефть продуктлары (2018 ел дәрәҗәсенә карата 110 процент), резина һәм пластмасса әйберләр (100,1 процент), дәвалау максатларында кулланыла торган дарулар һәм материаллар (127,4 процент), машиналар һәм җиһазлардан тыш, әзер металл эшләнмәләр (110,3 процент), компьютерлар, электр җиһазлары (100,8 процент), металл булмаган башка минераль продукция (101,5 процент), кәгазь һәм кәгазь эшләнмәләр (111,4 процент), эчемлекләр (109,8 процент), азык-төлек продуктлары (103,2 процент), башка әзер эшләнмәләр (100,9 процент), машина һәм җиһазлар (100,9 процент), текстиль әйберләр җитештерү (104 процент).

Агач эшкәртү һәм агачтан һәм бөкедән эшләнмәләр җитештерүдә җитештерү индексы 100 процент тәшкил итте.

**Сәнәгать җитештерүе динамикасы**




[1]2020 елның гыйнварыннан 2018 һәм 2019 еллар өчен сәнәгать җитештерүе индексын исәпләү 2018 ел күрсәткечләренә нигезләнеп башкарыла.


2019 ел йомгаклары буенча түбәндәгеләрне җитештерү күләме артты: автомобиль бензины – 2,4 тапкырга, дару препаратлары – 28,2 процентка, дизель ягулыгы – 23,5 процентка, суыткычлар – 20,3 процентка, сыра – 16 процентка, ягулык мазуты – 3,2 процентка.

Химик матдәләр һәм химик продуктлар (2018 ел дәрәҗәсенә карата 96,4 процент), автотранспорт чаралары, прицеплар һәм ярымприцеплар (89,2 процент), башка транспорт чаралары һәм җиһазлары (79,6 процент), мебель (97,4 процент), кием-салым (92,4 процент), күн һәм күн эшләнмәләр (90,1 процент), электрон һәм оптик эшләнмәләр (86,7 процент) җитештерүдә тискәре динамика күзәтелә.

Йөк машиналары (2018 ел дәрәҗәсенә карата 94,3 процент), беренчел формадагы синтетик каучук (93,6 процент), техник углерод (83,8 процент), җиңел автомобильләр (40,4 процент) җитештерү күләмнәре кимеде.

Сәнәгать структурасында файдалы казылмалар чыгару өлеше – 24,1 процент, эшкәртү производстволары өлеше – 69,5 процент, электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава әйләнешен булдыру өлеше – 5,4 процент, су белән тәэмин итү; су бүлү, калдыкларны җыю һәм утильләштерү, пычрату очракларын бетерү эшчәнлеге өлеше 1 процент тәшкил итте.


**2019 елда Татарстан Республикасы сәнәгате структурасы**




**Авыл хуҗалыгы**

Авыл хуҗалыгында 2019 елда продукция күләме 250,9 млрд сум, ягъни 2018 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 103 процент тәшкил итте.

**Авыл хуҗалыгы җитештерүе динамикасы**



Үсемлекчелек продукциясен житештерү 2018 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 3,5 процентка артты һәм 124,4 млрд сум тәшкил итте.

Эшкәртүдән соң ашлыкның тулаем күләме 4,2 млн тонна тәшкил итте, бу исә 2018 елга караганда 14 процентка артыграк. Шикәр чөгендере тулаем алганда – 33 процентка (2 804,4 мең тонна), яшелчә (каплаулы җирдә үстерелгәненең исәпкә алып) – 4,9 процентка (343,9 мең тонна) артыграк җыеп алынды. Республикада 1 214,1 мең тонна бәрәңге җыеп алынды, бу 2018 елда җыелган уңышның 102,1 процентын тәшкил итә.

2019 елда терлекчелек продукциясе җитештерү 2018 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 2,4 процентка артты һәм 126,5 млрд сум тәшкил итте.

2019 елда, 2018 ел белән чагыштырганда, барлык категория хуҗалыкларда сугым терлеге һәм кош-корт җитештерү – 2,9 процентка, сөт җитештерү – 2,4 процентка, йомырка җитештерү 7,5 процентка артты.


2019 елда авыл хуҗалыгы оешмаларында бер сыерга уртача 5 842 килограмм сөт савылды, бу 2018 елга караганда 4,2 процентка күбрәк. Бер тавыкның йомырка салуы 2018 ел дәрәҗәсендә калды һәм 315 данә тәшкил итте.

**Төзелеш**

2019 ел йомгаклары буенча төзелеш эшләре күләме 363,1 млрд сум, ягъни 2018 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 98,6 процент тәшкил итте. Гомуми мәйданы 2 675,5 мең кв.метр[1] тәшкил иткән торак файдалануга тапшырылды, бу 2018 ел дәрәҗәсенә карата 111 процент тәшкил итте.

2019 елда социаль ипотека программасы буенча гомуми мәйданы 371,5 мең кв.метр булган 6 496 фатир төзелде.


**Төзелеш эшчәнлеге күрсәткечләре динамикасы**




[1]Гражданнар бакчачылык белән шөгыльләнә торган җир кишәрлекләрендә төзелгән торак йортларны исәпкә алып.


## Кулланучылар базары

### Ваклап сату динамикасы





2019 елда ваклап сатуда товар әйләнеше 952,7 млрд сум тәшкил итте (2018 ел дәрәҗәсенә карата 100 процент), шул исәптән азык-төлек булмаган товарлар буенча – 526 млрд сум (99,6 процент), азык-төлек продуктлары буенча, шул исәптән эчемлекләрне һәм тәмәкене дә кертеп – 426,7 млрд сум (100,5 процент).

### Кулланучылар бәяләре индексының динамикасы
(узган елның декабренә карата, процентларда)




Ел башына (2018 елның декабренә карата 2019 елның декабре) куллану бәяләре үсеше 102,9 процент, шул исәптән азык-төлек товарларына 102,5 процент, азык-төлек булмаган товарларга 102,5 процент, хезмәт күрсәтүләргә 103,8 процент тәшкил итте.

**2018 елның декабренә карата 2019 елның декабрендә Идел буе федераль округы төбәкләренең куллану бәяләре индекслары**




**Тормыш дәрәҗәсе**

2018 елдан башлап Татарстан Республикасы 2024 елга кадәр социаль-икътисадый үсешнең гражданнарның реаль керемнәрен арттыру, ярлылык дәрәҗәсен ике тапкыр киметү буенча илкүләм максатларга ирешүгә юнәлдерелгән сынау проектларын гамәлгә ашыручы төбәкләр сафына басты. Россия Федерациясе буенча ярлылык дәрәҗәсен – 6,6, Татарстан Республикасы буенча 4,3 процентка калдыру 2024 елга максат булып тора.

2018 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында ярлылыкның түбән дәрәҗәсе – 7 процент теркәлде. Гомумроссия дәрәҗәсендә әлеге күрсәткеч 12,6 процент булганда, Россия Федерациясе субъектлары арасында Татарстан Республикасы бу күрсәткеч буенча 4 нче урында тора.

Ярлылыкны киметүнең төп коралы – социаль контракт төзү. Республикада 2019 елда 3 500 социаль контракт төзелгән, шулардан 2 965 контракт аз керемле гаиләләр белән төзелгән, алар нигезендә 632 граждан эшкә урнаштырылган, 51 кеше яңадан һөнәри әзерлек узган, 638 кеше шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү белән шөгыльләнә башлаган, 895 кеше үзмәшгульләр сыйфатында теркәлгән. Башкарылган эш нәтиҗәсендә 44 процент, яки контракт төзегән 1 540 гаилә ярлылыктан чыккан.


Республика предприятиеләрендә һәм оешмаларында, кече эшмәкәрлек субъектларын да кертеп, **уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы** 2019 елда 37 422,3 сум тәшкил итте һәм 2018 ел белән чагыштырганда, 6,2 процентка артты. Товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә куллану бәяләре индексын исәпкә алып хисапланган реаль хезмәт хакы 102 процент тәшкил итте.

2019 елда уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы күләме буенча Идел буе федераль округы төбәкләре арасында рэнкингта Татарстан 2 нче урында тора (1 нче урында – Пермь крае).

2019 ел йомгаклары буенча республикада югары хезмәт хаклары икътисадый эшчәнлекнең түбәндәге төрләрендә күзәтелгән: файдалы казылмалар чыгару – 61,3 мең сум; финанс һәм иминиятләштерү эшчәнлеге – 53 мең сум; электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава әйләнешен булдыру – 48,5 мең сум;

һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек – 51,5 мең сум; мәгълүмат һәм элемтә өлкәсе – 48,2 мең сум; эшкәртү производстволары – 41,6 мең сум.

**Айлык уртача хезмәт хакы динамикасы**




2019 елда бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы түбәндәгечә: сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә –36,8 мең сум, мәгариф өлкәсендә – 30,4 мең сум, мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачуны оештыру өлкәсендә – 44 мең сум.

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасында социаль өлкә учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын этаплап арттыру буенча планлы эш алып барыла. Күрелгән чаралар нәтиҗәсендә 2019 ел өчен хезмәт хакы түбәндәгечә булды:

мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең педагогика хезмәткәрләре – 30 226,7 сум;

гомуми белем бирү учреждениеләренең педагогика хезмәткәрләре – 34 032,8 сум;

балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең педагогика хезмәткәрләре – 35 206,2 сум;

башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укытучылары һәм мастерлары – 35 445,4 сум;

югары һөнәри белем бирү учреждениеләре укытучылары – 79 423,5 сум;

медицина оешмаларының медицина хезмәтләре күрсәтүче, югары медицина (фармацевтика) яки башка югары белеме булган табиблары һәм хезмәткәрләре, – 67 129,5 сум;

урта медицина (фармацевтика) персоналы – 33 710,6 сум;

кече медицина персоналы – 33 429,1 сум;

социаль хезмәткәрләр – 33 862,3 сум;

мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре – 34 124,2 сум;

фәнни хезмәткәрләр – 74 728,9 сум;

белем бирү, медицина оешмаларының яки ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның педагогика хезмәткәрләре – 34 308,4 сум.

«Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә 2019 елның 1 гыйнварыннан хезмәткә түләүнең минималь күләме 2018 елның 1 гыйнвары белән чагыштырганда 18,9 процентка артты һәм аена 11 280 сум, 2020 елның 1 гыйнварыннан аена 12 130 сум тәшкил итте.

Федераль дәрәҗәдә хезмәткә түләүнең минималь күләме артуга бәйле рәвештә 2018 елның 29 декабрендә Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы эш бирүчеләр берләшмәләре координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында килешү кабул ителде. Аңа таянып 2019 елның 1 гыйнварыннан икътисадның бюджеттан тыш секторы оешмаларында һәм юридик зат оештырмыйча эшкуарлык белән шөгыльләнүче индивидуаль эшкуарлар тарафыннан үз акчалары, эш вакыты нормасын тутырган һәм хезмәт нормаларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәрнең минималь хезмәт хакы аена 12 000 сумнан да ким булмаган күләмдә билгеләү күздә тотыла. 2019 елның 25 декабрендәге килешү нигезендә 2020 елның 1 гыйнварыннан минималь хезмәт хакы аена 14 000 сум күләмендә билгеләнде, бу исә 2019 елның II кварталы өчен Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджеты бәяләр күләменең 88,8 процентын тәшкил итә.

Бурычлы предприятиеләр белән эшләү республикада Халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту, хезмәт, Татарстан Республикасында чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе, шулай ук Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы республика комиссиясе каршындагы Хезмәткә түләү, керемнәр һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе буенча координация советы эшчәнлеге кысаларында муниципаль берәмлекләрдәге территориаль комиссияләр, тармак министрлыклары, контроль күзәтчелек һәм салым органнары, республиканың һөнәри берлекләре һәм эш бирүчеләре берләшмәләре белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барыла.


# II. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКАРМА ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

## КЕШЕ КАПИТАЛЫ

### Демография

Кеше капиталы үсешенә демографик процессларның аерым йогынтысы бар.

2017 – 2019 елларда Татарстан Республикасында, тулаем Россиядәге кебек үк, туучыларның саны ел саен кимүе күзәтелә. 2019 ел нәтиҗәләре буенча республикада 42 871 кеше туды, туучылар коэффициенты 1000 кешегә 11 очрак тәшкил итте (тулаем Россия буенча – 10,1 очрак). 2017 – 2019 елларда туучылар санының кимүе кече яшь төркеменә керүче хатын-кызлар арасында (15 – 19 яшь) тудыру буенча яшь коэффициентларының кимүенә һәм бала табу яшендәге хатын-кызларның (15 – 49 яшь) яшь структурасы тискәре якка үзгәрүенә бәйле. Репродуктив яштәге хатын-кызлар арасында 20 – 29 яшьлек хатын-кызлар өлеше кимегән, кагыйдә буларак, барлык бала табучыларның яртысыннан артыгын шушы яштәге хатын-кызлар тәшкил итә.




2019 елда халык арасында үлүчеләр саны күрсәткече 1000 кешегә 11 очрак тәшкил итте (Россиядә – 1000 кешегә 12,3 очрак). 2019 елда үлүчеләр саны структурасында кан әйләнеше системасы авырулары – 100 мең кешегә 535,8 очрак (2018 елда – 603,2 очрак), шешләр барлыкка килү – 100 мең кешегә 186,1 очрак (2018 елда – 196,7 очрак), тән җәрәхәтләре, агулану һәм тышкы сәбәпләр йогынтысы – 100 мең кешегә 67 очрак (2018 елда – 70,2 очрак).

Соңгы елларда эшкә сәләтле кешеләр арасында үлем-китем күрсәткече кимүнең ачык динамикасы күзәтелә. 2019 елда эшкә сәләтле халык арасында үлем күрсәткече, 2018 ел белән чагыштырганда, 4,9 процентка кимеде һәм тиешле яштәге 100 мең кешегә 389,2 очрак тәшкил итте (2018 елда – 409,2 очрак).

2019 елда сабыйлар арасында үлем-китем очраклары коэффициенты тере туган 1 000 балага 4,9 очрак тәшкил итте.

Республикада халыкның табигый артуы 180 кеше тәшкил итте, ягъни

1000 кешегә 0 (тулаем Россия буенча табигый кимү – 1 000 кешегә (-)2,2).

Табигый үрчем коэффициенты буенча Россия Федерациясе төбәкләре арасында Татарстан Республикасы 19 урынны, ә Идел буе федераль округы төбәкләре арасында, туучылар санының күплеге һәм үлүчеләр санының азлыгы нәтиҗәсендә, 1 урынны алып тора.

Соңгы алты ел эчендә, 2019 елның якынча йомгаклары буенча, республика халкының фаразланган гомер озынлыгы 75 яшьтән артып китте.

***«Демография» илкүләм проекты***

*«Гаиләләргә бала туганда финанс ярдәме күрсәтү» төбәк проекты*

Татарстан Республикасында халыкның тотрыклы табигый үрчемен саклап калу өчен системалы нигездә балалы гаиләләр өчен социаль инфраструктура булдырыла, 40 социаль программа, шул исәптән балалар бакчалары, мәктәпләр, мәдәният йортлары, спорт объектлары, фельдшер-акушерлык пунктлары төзү һәм төзекләндерү, сәламәтлек саклау системасында поликлиникаларны, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен, балаларны савыктыру лагерьларын, яшүсмерләр клубларын капиталь төзекләндерү программалары гамәлгә ашырыла. Яшь гаиләләр өчен ипотека кредиты программалары гамәлдә, балалы гаиләләргә федераль һәм төбәк социаль ярдәм чараларының киң пакеты бирелә.

2019 елда республикада гаиләгә ярдәм итүгә, аны ныгытуга һәм яклауга, традицион гаилә кыйммәтләрен саклауга, гаиләдә һәм җәмгыятьтә ата-аналарның ролен һәм абруен күтәрүгә, гаиләдәге иминсезлекне профилактикалауга һәм бетерүгә, гаилә шартларын һәм тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар үткәрелде.

2018 елдан «Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында беренче бала тууга (уллыкка-кызлыкка алуга) бәйле рәвештә җан башына кереме хезмәткә сәләтле халыкның яшәү минимумы күләменнән 1,5 тапкырдан артып китмәгән гаиләләргә айлык түләүләр бирелә. 2020 елның 1 гыйнварына 13 780 кеше мондый түләүне алган.

Шулай ук 2018 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала тапкач бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирендә кимендә өч ел даими яшәүче хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган түләүләр каралган: 25 яше тулганчы беренче баласын тудыргач – 50 мең сум; 29 яше тулганчы өченче баласын тудыргач – 100 мең сум. 2020 елның 1 гыйнварына 2 487 хатын-кыз мондый түләүне алды.

Моннан тыш, 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге ярдәм чаралары кертелде:

биш һәм аннан да күбрәк балалы, җан башына кереме уртача яшәү минимумыннан азрак булган гаиләләрнең һәр әгъзасына гаиләнең җан башына исәпләнгән уртача кереме һәм яшәү минимумы арасындагы аерма күләмендә айлык пособие биреләчәк;

өч һәм аннан да күбрәк балалы, җан башына кереме уртача яшәү

минимумыннан азрак булган гаиләләргә балалар бакчасы өчен түләүгә компенсация күләме 100 процентка кадәр арттырылачак;

аз керемле гаиләләрдәге өч яше тулмаган балаларга ярты елга бер тапкыр дару сатып алу өчен 5 мең сум күләмендә акча биреләчәк;

җан башына уртача кереме халыкның җан башына исәпләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган, яңа туган балалары булган гаиләләргә балалар өчен кирәк-яракларның бүләк комплектлары биреләчәк.

*«Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү – өч яше тулмаган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын булдыру» төбәк проекты*

Мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасында ике айлыктан алып өч яше тулмаган балалар өчен мәктәпкәчә оешмаларда өстәмә урыннар булдыру буенча чаралар күрелде. 2019 елда моңа 855,6 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән 496,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 359,3 млн сум бүлеп бирелде. 2019 елда ике айлыктан алып җиде яше тулмаган балалар өчен 6 220 урынга исәпләнгән 30 мәктәпкәчә белем бирү объекты төзелде, аларның 3200е өч яше тулмаган балалар өчен каралаган. Казан шәһәренең балалар бакчаларында 4 төркем үзгәртеп корылды.

*«Өлкән яшьтәге гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм тормышка ашыру» төбәк проекты*

2019 елда Татарстан Республикасы озак вакыт дәвамында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны тәрбияләү системасын булдыру буенча 12 пилот төбәк арасына керде.

Республиканың өлкән яшьтәге гражданнарын һәм инвалидларны озак вакыт дәвамында карау системасын булдыру буенча сынау проектын гамәлгә ашыру чаралары төбәк планы («юл картасы») расланды, анда озак вакыт дәвамында тәрбияләү системасын кертүнең төп юнәлешләре билгеләнде. 2019 елда 1 638 кешегә, ягъни өйдә социаль хезмәтләр алучы өлкәннәр санының 8 процентына мондый ярдәм күрсәтелә.

Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт дәвамында карау системасын төзүгә 2019 елда 28,7 млн сум, шул исәптән 28 млн сум федераль бюджет акчалары һәм 0,7 млн сум Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан, тотылды.

Социаль хезмәтләрдән файдаланучы психик чирләрдән интегүчеләргә уңайлы һәм имин тормыш шартлары булдыру максатыннан, 2019 елда «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 97 урынга исәпләнгән өч катлы торак корпусын төзү эшләре башланды. Файдалануга тапшыру 2020 елга планлаштырылган.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре өчен Россия Федерациясе бюджеты акчалары исәбеннән 64,6 млн сумга 43 автомобиль сатып алынды, бу исә авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк 36,8 мең кешене

диспансерлаштыру һәм профилактик медицина тикшерүләре узу, планлы госпитализацияләү өчен үзәк район хастаханәләренә һәм табиблык амбулаторияләренә илтүне оештырырга мөмкинлек бирде.

Республикада 26 муниципаль берәмлектә 46 амбулатория-поликлиника учреждениеләре һәм үзәк район хастаханәләре поликлиникалары базасында 47 гериатрия кабинеты эшли, аларның 37 се 2019 елда ачылды.

13 медицина оешмасы базасында стационар гериатрик ярдәм күрсәтү өчен 12 муниципаль берәмлектә 168 койка тәүлек буе эшли, шулардан 143 койка 2019 елда ачылды, 1 530 кеше дәваланды.

Диспансерлаштыру һәм профилактик медицина тикшерүләре уздыру кысаларында, шул исәптән диспансер күзәтүе барышында, хезмәткә сәләтлелек яшендәге 610 285 кешенең сәламәтлеген тикшерү уздырылды (хезмәткә сәләтлелек яшендәге гражданнар санының 61,8 проценты).

2019 елда пенсия яше тулып килә торган гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү оештырылды, 4 747 кеше (план – 1 351 кеше) укытылды. Бу максатларга 92,4 млн сум, шул исәптән 87,8 млн сум федераль бюджет, 4,6 млн сум Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан, бүлеп бирелде.

*«Дөрес туклануны һәм начар гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын формалаштыру» төбәк проекты*

Гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын формалаштыру максатыннан чыгып 2019 елда «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасына «Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» ярдәмче программасы кабул ителде.

Ярдәмче программа чараларын үтәү кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан:

иҗтимагый сәламәтлек үзәкләренең моделе проекты эшләнде;

җәмәгать сәламәтлеген ныгыту буенча муниципаль программа проекты эшләнде һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына тиешле эшне оештыру өчен җибәрелде;

республика предприятиеләре («Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «С.П. Титов исемендәге Чаллы картон-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» ябык акционер җәмгыяте белән) һәм «Золотое сердце» Татарстан Республикасы төбәк мәгърифәтчелек иҗтимагый оешмасы арасында хезмәткәрләрнең сәламәтлеген ныгытуның корпоратив программаларын гамәлгә кертү турында өч өчьяклы килешү имзаланды.

*«Халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәренә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, шул исәптән спорт объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү, шулай ук спорт резервын формалаштыру» төбәк проекты*

Татарстан Республикасында 11 065 спорт корылмасы (авыл җирлегендә – 5 211 корылма) бар, болар: 46 стадион, мәйданчыклы 5 922 спорт корылмасы, 1 999 спорт залы, ясалма бозлы 48 ябык объект, 11 манеж, ябык һәм ачык 235 йөзү бассейны, 80 чаңгы базасы, спортның мылтыктан ату төрләре өчен 191 корылма, спортның ишкәкле төрләре өчен 2 корылма, башка төрдәге 2 531спорт корылмасы.

2019 елда республикада 215 спорт корылмасы файдалануга тапшырылган:

16 спорт залы (Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Әлмәт шәһәре, Саба һәм Питрәч муниципаль районнары);

физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен җайлаштырылган 10 бина (Казан, Чаллы, Әлмәт, Саба һәм Питрәч муниципаль районнары);

2 ябык йөзү бассейны (Әлмәт шәһәре, Чаллы шәһәре);

ясалма бозлы ябык 3 арена (Әлмәт шәһәре, Казан шәһәре);

4 футбол кыры (Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Апас муниципаль районы);

модульле 9 чаңгы базасы (Актаныш, Баулы, Биектау, Зеленодольск, Мамадыш, Менделеевск, Мөслим, Питрәч, Чистай муниципаль районнары);

170 универсаль-уен мәйданчыгы (баскетбол, волейбол, мини-футбол кыры, тренажерлы урам мәйданчыклары, төрле ел фасыллары өчен хоккей кортлары);

Казан шәһәрендә мылтыктан ату спорты төрләре өчен 1 корылма.

2024 елга Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт белән даими рәвештә шөгыльләнүче гражданнар өлешен 57 процентка җиткерү планлаштырыла (Россия Федерациясе буенча – 55 процент).

2019 елда Татарстан Республикасында түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелде:

физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче гражданнар (3 яшьтән 79 яшькәчә) саны 49,5 процент тәшкил итте (2018 елда – 45,7 процент);

физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр (3 яшьтән 29 яшькәчә) өлеше – 86,1 процент (2018 елда – 84 процент);

физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче урта яшьтәге гражданнар (30 – 54 яшьлек хатын-кызлар, 30 – 59 яшьлек ир-атлар) өлеше – 38,4 процент (2018 елда – 36,1 процент);

физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче өлкән яшьтәге гражданнар өлеше (55 – 79 яшьлек хатын-кызлар, 60 – 79 яшьлек ир- атлар) – 14 процент (2018 елда – 11,6 процент);

физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затлар өлеше – 28 процент (2018 елда – 18,3 процент).

Татарстан Республикасында 170 спорт мәктәбе эшли, шуларның 30ы Олимпия резервындагы махсус спорт мәктәбе, аларда 73 спорт төре үстерелә.

Спорт мәктәпләрендә укучылар белән тренеровка эшләрен 3 меңнән артык тренер башкара.

2019 елда Татарстан Республикасында түбәндәге чаралар үткәрелде:

Европа һәм халыкара дәрәҗәдәге 24 ярыш, шул исәптән нәфис гимнастика буенча дөнья Кубогы, йөзү, синхрон йөзү һәм суга сикерү буенча FINA дөнья сериясе этаплары, һавада ярышлар буенча Red Bull Air Race дөнья чемпионаты, хатын-кызлар командалары арасында регби-7 буенча Европа чемпионаты, тхэквондо һәм триатлон буенча Европа чемпионаты, көрәш буенча дөнья чемпионаты һәм беренчелеге, регби-7 буенча хатын-кызлар командалары арасында Европа Олимпия сайлап алу турниры, йөзү буенча Европа беренчелеге, суга сикерү буенча юниорлар арасында Европа беренчелеге, мотосерфинг буенча дөнья Кубогы этабы һәм башкалар;

98 чемпионат, Россия беренчелеге һәм Кубогы, шул исәптән синхрон йөзү, триатлон, тхэквондо, бию спорты, гер спорты, көрәш, самбо буенча Россия чемпионатлары һ. б.;

республикакүләм 800 чара.

Татарстан Республикасы спортчылары тарафыннан 2019 елда Россия һәм халыкара дәрәҗәдәге ярышларда 978 медаль яуланган, шуларның 286 сы – алтын, 313 е – көмеш, 379 ы – бронза.

***«Татарстан – Идел буена халыкны җәлеп итү үзәге» флагман проекты***

«Татарстан – Идел буена халыкны җәлеп итү үзәге» проекты Татарстан Республикасы халкының, барыннан да элек, Россиянең башка төбәкләреннән килгән мигрантлар хисабына артуын көчәйтүгә һәм мигрантлар агымында төбәк хезмәт базарында кирәкле квалификацияле һәм югары квалификацияле белгечләр санын арттыруга юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасы кысаларында ел саен мигрантларның социаль җайлашуына юнәлдерелгән кереш (юнәлеш бирү) курсларны үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирелә. 2019 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы үткәргән конкурс йомгаклары буенча әлеге максатларга «Яңа гасыр» автоном коммерцияле булмаган хәйрия оешмасы 2,32 млн сум күләмендә субсидия алды, кереш (юнәлеш бирү) курсларда 3 100 мигрантка белем бирелде.

Шулай ук «Яңа гасыр» автоном хәйрия оешмасы 2019 елда «Мигрантларны социаль җайлаштыру өлкәсендә секторара ресурс үзәге» проектын гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан 11,1 млн сум күләмендә Президент грантын алды.

2019 елда Татарстан Республикасында яшәү урыны буенча 324 163 чит ил гражданы (2018 елда – 335 097 кеше), шул исәптән беренчел буларак – 233 633 чит ил гражданы (247 405 кеше), озайту тәртибендә – 90 530 чит ил гражданы (87 692 кеше) миграция исәбенә куелды.

Республикага чит ил гражданнарының күпчелеге Үзбәкстан Республикасыннан, Таҗикстан Республикасыннан, Казахстан Республикасыннан, Азәрбайҗан Республикасыннан, Кыргызстан Республикасыннан, Украинадан,

Кытай Халык Республикасыннан, Төркия Республикасыннан һәм Германия Федератив Республикасыннан килә.

2019 елда чит ил гражданнарына эшкә 31,8 меңнән артык патент рәсмиләштерелде (2018 елда – 27,5 мең патент), алар өчен Татарстан Республикасы бюджетына 781,8 млн сум күчерелгән (2018 елда – 720 млн сум).

2019 елның гыйнвар – декабрь айларында Татарстан Республикасында халыкның миграцион үсеше 4 142 кеше тәшкил итте, бу 2018 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 1 405 кешегә артыграк. Миграцион үсеш республикадан башка төбәкләргә күченү очракларының кимүенә һәм Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләреннән килүчеләрнең артуына бәйле. Татарстан Республикасы чикләрендә күченүче мигрантлар саны 51 141 кеше тәшкил итте, бу 2018 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 4 процентка кимрәк.

**Сәламәтлек саклау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру**

2019 елда «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру дәвам иттерелде. Ул сәламәтлек саклау өлкәсендә профилактикалауны һәм беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне үстерүгә, махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен, диагноз кую өчен тикшеренүләрнең, профилактика һәм дәвалауның инновацион ысулларын үстерү һәм гамәлгә кертү, халыкны медицина ысуллары белән тернәкләндерүне үстерүгә, сәламәтлек саклау системасын югары квалификацияле һәм мотивацияле кадрлар белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән Таби б һөнәрнең абруен күтәрү максатында ел саен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Ел табибы – Ак чәчәкләр» республика конкурсы үткәрелә. 2019 елда конкурста җиңгән 18 кеше Германия Федератив Республикасының һәм Нидерландия Корольлегенең иң яхшы клиникаларында стажировка узды.

Республикада баш мие кан әйләнеше гадәттән тыш бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтү системасын камилләштерү буенча чараларны гамәлгә ашыру дәвам итә (алга таба – ОНМК). Республикада мондый авырулар өчен 18 районара неврология бүлеге эшли. 2019 елда аларда 17 874 кеше дәваланган (2018 елда – 16 918 кеше), ишемия инсульты белән чирләүчеләргә 1 057 тромболизис үткәрелгән (2018 елда – 788 тромболизис).

Йөрәк кан тамырлары чиренең көчәюе күзәтелгәндә, шул исәптән миокард инфаркты вакытында, халыкка ашыгыч медицина ярдәме, коронарография һәм йөрәк кан тамырларын стентлау технологияләрен кулланып, барлык муниципаль берәмлекләрдә 7 күппрофильле югары технологияле медицина учреждениесе базасында күрсәтелә. Алар түбәндәгеләр: «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина-санитария часте, «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Казан шәһәренең 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе»

дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Татнефть» ГАҖ һәм Әлмәт шәһәренең медицина-санитария часте, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.

2019 елда әлеге медицина учреждениеләренә «гаять көчле коронар синдром» диагнозы белән 11 484 пациент (2018 елда – 11 271 кеше), шул исәптән 5 495 кеше «миокард инфаркты» диагнозы белән (2018 елда – 5 043 кеше) салынды, ашыгыч рәвештә диагноз кую өчен 8 010 коронарография (2018 елда – 7 334), йөрәк кан тамырларына 4 692 ашыгыч ангиопластика (2018 елда – 4 289) уздырылды.

Татарстан Республикасында югары технологияле медицина ярдәмен 21 профиль буенча 15 медицина оешмасы күрсәтә, 2019 елда мондый ярдәм 24 284 кешегә күрсәтелде (2018 елда – 22 303 кеше).

2019 елда Татарстан Республикасында яман шеш авыруларының 16 507 очрагы беренчел ачыкланды (алга таба – ЗНО), бу 2018 елга караганда 1,2 процентка артыграк (16 305 очрак). 2019 елның 31 декабренә республикада яман шеш белән авыручылар саны 114 600 кеше тәшкил итте, бу 2018 ел белән чагыштырганда 3,9 процентка артыграк (106 306 кеше). 2019 елда авырулар структурасында түбәндәге шешләрне локальләштерү беренче урынга чыкты: калын эчәк – 13,2 процент, тире меланомасы – 13 процент, сөт бизе – 11,5 процент, үпкә – 9,7 процент, хатын-кыз җенес органнары – 9,2 процент, ашказаны – 6,4 процент, мәни бизе – 5,6 процент.

Татарстан Республикасында органнар күчереп утырту буенча ике үзәк эшли: «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында бөер һәм бавыр күчереп утырту, «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында – йөрәк күчереп утырту башкарыла. «Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә 2019 елда бөер күчереп утырту буенча 38, бавыр бөер күчереп утырту буенча 13 операция ясалды. «Төбәкара клиник-диагностик үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында йөрәк күчереп утырту буенча 4 операция ясалды (2018 елда – 1).

2019 елда республикада бала тудыра алмый торган авыруларны ярдәмче репродуктив технологияләр кулланып дәвалау шәхси милек формасындагы оешмаларда оештырылган: «АВА-ПЕТЕР» ҖЧҖ, «АВА-Казан» АҖ, «ВРТ» ҖЧҖ, «Гаилә медицинасы клиникасы» ҖЧҖ, «Нуриевлар Клиникасы – Чаллы» ҖЧҖ, «Корл» ҖЧҖ, «Ана һәм бала – Казан» ҖЧҖ. Экстракорпораль аталандыру буенча 1 887 процедура үткәрелгән, шуларның 430ы – яралгы күчереп утырту чаралары.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең яңа туган балалар патологиясе бүлегендә 2019 елда 1 341 яңа туган бала (2018 елда – 1 309 бала), шул исәптән 656 җитлекми туган бала (48,9 процент), экстремаль аз авырлыктагы 104 бала, бик аз авырлыктагы 142 бала дәваланды.

Республикада халыкка ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүче 59 структур бүлекчә эшли: 9 ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе һәм үзәк район хастаханәләре составындагы 50 бүлек.

Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү хезмәтенә 387 санитар транспорт бүлеп бирелде: «А» класслы 7 автомобиль, «В» класслы 359 автомобиль һәм «С» класслы 21 автомобиль. 2019 елда Татарстан Республикасының ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станцияләре һәм бүлекләренә «Форд Транзит» маркалы 237 санитар транспорт бирелде. Бу санитар автомобильләр паркын 60 процентка яңартырга мөмкинлек бирде.

2019 елда ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү һәм һәлакәтләр медицинасы бердәм диспетчерлык хезмәтен булдыру проекты уңышлы старт алды. Казан шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасында, Лаеш, Питрәч, Биектау, Югары Ослан муниципаль районнарының ашыгыч медицина ярдәме бүлекчәләрендә үзәк район хастаханәләре составында «Ашыгыч ярдәм» автоматлаштырылган идарә системасы программ тәэминаты кертелде.

2019 елда ашыгыч медицина ярдәме хезмәте көчләренең һәм чараларының гадәттән тыш хәлләрдә катнашырга һәм аларның медицина-санитария ягыннан тискәре нәтиҗәләрен бетерергә әзерлеген арттыру һәм Татарстан Республикасында үзара хезмәттәшлек дәрәҗәсен камилләштерү максатларында 800 дән артык оператив әзерлек чарасы, шул исәптән тактикага кагылышлы махсус 332 өйрәтү һәм күнекмә, 105 команда-штаб өйрәтүе, 349 штаб өйрәтүе, комплекслы ведомствоара 29 өйрәтү үткәрелде.

«Белем бирү сыйфатын мониторинглау республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе бригадалары 1 376 тапкыр, шулардан гадәттән тыш һәм штаттан тыш хәлләргә – 433 тапкыр, медицина эвакуациясенә – 195 тапкыр, шул исәптән санитар авиация линиясе буенча 105 тапкыр чыктылар.

2019 елда медицина хезмәтләре экспортын үстерү проекты кысаларында Россия Федерациясе төбәкләрендәге 3 628 балага, шул исәптән Идел буе федераль округындагы 2 346 балага, якын һәм ерак чит илләрдәге 1 147 балага медицина ярдәме күрсәтелде.

2019 елда массакүләм, шул исәптән спорт чаралары һәм акцияләр: WorldSkillsKazan-2019 һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты, Континенталь хоккей лигасы чемпионаты, «Казан марафоны-2019» бөтенроссия ярышлары, «ЗАБЕГ.РФ» бөтенроссия ярыммарафоны кысаларында узган «Идел буйлап йөгереп» ярыммарафоны, «Стоп ВИЧ/СПИД» бөтенроссия акцияләре, «Бөтенроссия тест көне», «Зеленодольск –Нурлат – Чистай – Казан» автойөреше вакытында ВИЧ-инфекциягә экспресс-тест үткәрү дәвам иттерелде. Әлеге чаралар кысаларында 8 400 дән артык кеше тикшерелде.

***«Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты***

*«Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты*

«Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыруга 2019 елда 397,4 млн сум, шул исәптән

федераль бюджет акчалары исәбеннән 121,9 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 275,5 млн сум бүлеп бирелде.

Проект кысаларында 2019 елда:

Лаеш муниципаль районында 1 фельдшерлык-акушерлык пункты төзелде;

санитар авиациянең 150 очышы башкарылды, санитар авиацияне кулланып өстәмә эвакуацияләнгән затлар (пациентлар) саны 146 кеше тәшкил итте (2018 елда – 120 санитар авиация очышы, 113 пациент эвакуацияләнде);

Казан шәһәренең 13 сәламәтлек саклау оешмасының 18 хастаханә бүлекчәсе «Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасының яңа моделе»н төзүдә һәм тиражлауда катнаша;

медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлеген арттыру максатларында 11 мобиль медицина комплексы, шул исәптән «Республика клиник туберкулезга каршы көрәшү диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе өчен 7 күчмә флюорограф, 100 кешедән ким булган торак пунктларда яшәүче республика гражданнарын диспансерлаштыруны уздыру өчен 4 «Мобиль поликлиника» медицина комплексы сатып алынды;

диспансерда тикшерү үткәрү тәртибе үзгәрде: 18 – 39 яшьлек затлар – өч елга бер тапкыр, 40 – 99 яшьлек затлар – ел саен (1,8 млн кешене карау планлаштырлган, чынлыкта 1,811 млн кеше каралган).

*«Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты*

Йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан үлүчеләр санын киметү һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары белән авыручыларга ярдәмнең сыйфатын яхшырту максатларында 2019 елда «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасына «Татарстан Республикасында йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» ярдәмче программасы кабул ителде.

Әлеге проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлүчеләр саны 100 мең кешегә 535,8 очракка кадәр кимегән (2018 елда – 603,2 очрак).

Проект кысаларында 2019 елда 1 төбәк үзәк («Төбәкара клиник-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) һәм 3 беренчел кан тамырлары бүлеге («Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Казан шәһәренең 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе яңадан җиһазландырылды. 73 берәмлек медицина җиһазлары сатып алынды һәм кайтарылды.

*«Онкология авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты*

Яңа шешләрдән, шул исәптән яман шешләрдән үлүчеләр санын киметү максатында, 2019 елда «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасының «Онкология авыруларына каршы көрәшү» ярдәмче программасы кабул ителде. 2019 елда проект чараларын гамәлгә ашыру өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән 491,5 млн сум бүлеп бирелде.

Әлеге проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә яңа шешләрдән үлүчеләр саны 100 мең кешегә 186,1 очракка кадәр кимегән (2018 елда – 196,7 очрак).

Проект кысаларында 2019 елда:

«21 номерлы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җирлегендә беренче амбулатор онкологик ярдәм үзәге ачылды (340 пациентка өенә барып ярдәм күрсәтү, 11 химиотерапия сеансы);

төбәк медицина оешмалары өчен 133 берәмлек җиһаз сатып алынды һәм кайтарылды.

*«Балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыруны да кертеп, балалар сәламәтлеген саклау өлкәсен үстерү» төбәк проекты*

Балалар сәламәтлеген һәм тормыш сыйфатын яхшырту, сабыйлар үлемен киметү максатларында 2019 елда «Ана һәм бала сәламәтлеген саклау» ярдәмче программасы («2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасының «Балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыруны да кертеп, балалар сәламәтлеген саклау өлкәсен үстерү» төбәк проект) кабул ителде. 2019 елда төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыруга 319,9 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән 185,6 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 134,3 млн сум бүлеп бирелде.

Проект кысаларында 2019 елда:

Симуляция үзәкләрендә 184 белгеч перинаталь, неонатология һәм педиатрия өлкәсендә әзерлек узды;

30 балалар поликлиникасы һәм поликлиника бүлекләре яңадан җиһазландырылды, 124 берәмлек җиһаз кайтартылды;

Казан шәһәренең 15 балалар хастаханәсендә балаларга уңайлы шартлар тәэмин ителде;

балалар табиб – уролог-андрологлары тарафыннан 42 397 малай (еллык планның 116,6 проценты), табиб – акушер- гинекологлар тарафыннан – 37 215 кыз (еллык планның 107,6 проценты) карап тикшерелде;

бала тудыру сертификатлары түләнде: 1 нче талон – 37 973 берәмлек, 2 нче талон – 40 794 берәмлек, бала тудырганда аналарга 41 320 тапкыр ярдәм күрсәтелгән.

*«Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты*

Проект кысаларында 2019 елда:

Татарстан Республикасы медицина оешмаларында табиблар белән тәэмин ителеш – 10 мең кешегә 35,0, урта медицина хезмәткәрләре белән тәэмин ителеш – 10 мең кешегә 91,4 тәшкил итте;

амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтү (алыштыру коэффициенты 1,2 булганда физик затлар тарафыннан) бүлекчәләрендә табиблар белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсе 83,4 процент тәшкил итте;

амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтү алыштыру коэффициенты 1,2 булганда физик затлар тарафыннан) бүлекчәләрендә урта медицина персоналы белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсе 99,8 процент тәшкил итте;

12 537 табиб югары медицина белемле белгечләргә өзлексез медицина белеме бирү системасына җәлеп ителгән;

15 639 урта медицина хезмәткәре урта һөнәри белемле белгечләргә өзлексез медицина белеме бирү системасына җәлеп ителгән.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан сәламәтлек саклау өлкәсендә кадрлар кытлыгын бетерү максатларында белгечләр җәлеп итү буенча актив эш алып барыла һәм түбәндәге чаралар һәм программалар гамәлгә ашырыла:

югары медицина белеме бирү оешмаларына керү өчен 223 максатчан юллама максатчан кабул итү квоталары буенча бирелде;

78 табибка һәм 22 фельдшерга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләнде;

19 кеше муниципаль берәмлекләр өчен табибларны адреслы әзерләү социаль программасы кысаларында белгечлек программалары буенча укырга җибәрелде;

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең медицина оешмаларына грантлар бирү программасы буенча 128 белгеч эшкә урнаштырылды;

2014 елдан «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина факультетында максатчан акча хисабыннан 60 кеше «дәвалау эше» белгечлеге буенча укый. Беренче чыгарылыш 2020 елда булачак. Белгеч аккредитация узганнан соң, уку йортын тәмамлаучылар Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсенең башлангыч звеносында биш ел эшләргә тиеш булачаклар.

*«Бердәм дәүләт мәгълүмати сәламәтлек саклау системасы (ЕГИСЗ) нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм цифрлы контур булдыру» төбәк проекты*

2019 елда төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыруга 156,7 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән 126,9 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 29,8 млн сум бүлеп бирелгән.

Татарстан Республикасында 104 медицина оешмасы «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсендә электрон хезмәт күрсәтү» (алга таба – ТР ЭСС БДМС) бердәм дәүләт мәгълүмат системасын һәм «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ТР ЭСМ БДМС системалары белән берләштерелгән автоматлаштырылган системасын кулланалар. 2019 елда Татарстан Республикасы медицина оешмаларында табибка кабул итүгә 18,1 млн электрон язылу очрагы теркәлгән (2018 елда – 16 млн).

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре порталында кара-каршы элемтә системасы гамәлгә ашырылды һәм кулланугa кертелде. Табиб килеп киткәннән соң икенче көнне һәр кешегә гади итеп төзелгән сораштыру кәгазе җибәрелә, анда 5 баллы шкала буенча медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын һәм шартларын

бәяләргә тәкъдим ителә. 2019 елда тавыш бирүчеләрнең гомуми саны 2 млн кешедән артып китте.

Татарстан Республикасы «Эшкә сәләтсезлек турында электрон язу» проектын гамәлгә ашыру буенча Россия рейтингында 1 нче урынны алды.

Татарстан Республикасының 89 медицина оешмасына 2 588 автоматлаштырылган эш урыны белән тәэмин итү өчен компьютер җиһазлары (компьютерлар, принтерлар һәм күпфункцияле җайланмалар) бирелде.

ТР ЭСС БДМС кысаларында пациентларны «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә медик-социаль экспертизага җибәрү рәсмиләштерелде, мәгълүматлар федераль медик-социаль экспертиза системасына тапшырылды.

*«Медицина хезмәтләре экспортын үстерү» төбәк проекты*

2019 елда дәваланган чит ил гражданнары саны 14 575 кеше тәшкил итте (план – 420 кеше), бу хезмәт өчен 46,7 млн сум акча алынды (план – 29 млн сум).

***«Актив озын гомер» флагман проекты***

Сәламәтлек саклау өлкәсенең өлкән яшьтәге гражданнарга кагылышлы төп бурычы – аларның актив яшәеш чорын озынайту һәм сәламәтлеген ныгыту.

Махсуслаштырылган гериатрия ярдәмен үстерү – өлкәннәргә медицина ярдәмен оештыруның мөһим өлеше булып тора, аның максаты – өлкән яшьтәге кешеләргә, аларның физиологик яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, медицина ярдәме күрсәтү.

Медицина оешмаларында иң актуаль мәсьәләләр буенча 800 сәламәтлек мәктәбе эшли.

Өлкән яшьтәге 350 111 граждан йогышлы булмаган авыруларны беренчел профилактикалау, шул исәптән актив озын гомерне пропагандалау буенча әзерлек узды.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан 2019 елда өлкән яшьтәге кешеләр өчен 20 дән артык акция үткәрелде, Халыкара инвалидлар көне, Бөтендөнья ишетү көне, Бөтендөнья сәламәтлек көне, Бөтендөнья артериаль гипертония көне, Бөтендөнья тәмәкесез көн уңаеннан уздырылган акцияләр шундыйлардан.

2019 ел дәвамында тематик матбугат конференцияләре үткәрелде, «Татарстан» ДТРКда максатчан тематик тапшырулар, телесюжетлар, радиода чыгышлар уздырылды, матбугатта басмалар, шулай ук төрле актуаль мәсьәләләр буенча, шул исәптән өлкән буын кешеләре өчен дә, мәгълүмати әдәбият дөнья күрде. Йогышлы булмаган хроник авыруларны профилактикалау буенча материаллар яңалыклар чыгарылышларында һәм мәгълүмати-аналитик программаларда, шул исәптән «Яңа Гасыр» ТРКда «7 көн» программасында, «Казан» ТРКда, «Столица» программасында, «Татарстан» ДТРКда «Вести-Татарстан» чыгарылышларында яктыртылды. «Эфир» телеканалында һәр якшәмбедә 30 минут дәвамында «Гадәти сәламәтлек рецептлары»тапшыруы трансляцияләнә.

2019 елда массакүләм мәгълүмат чараларында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм йогышлы булмаган авыруларны профилактикалау буенча

2 500 гә якын материал басылып чыкты, тематик матбугат конференцияләре, интервьюлар оештырылды. Республика һәм район массакүләм мәгълүмат чараларында «Наркотикларга «юк» дип әйт!», «Наркотиклар кулланучыларга түләүсез ярдәм күрсәтү» дип аталган роликлар күрсәтелә.

Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, диспансерлаштыру, инсульт һәм инфаркт кичергән авыруларга беренче ярдәм күрсәтү, яман шешне, суицидны, терәк-хәрәкәт аппараты авыруларын профилактикалау, хатын-кызларның ана булуга әзерлеге мәсьәләләре буенча видеороликлар һәм видеофильмнар республиканың медицина учреждениеләре холларында, гомуми белем бирү оешмалары экраннарында, шулай ук Казан шәһәре метрополитенының станцияләрендә һәм вагоннарында урнашкан экраннарда трансляцияләнә.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасы кешеләрнең актив озын гомергә омтылышында мөһим элемент булып тора. Республика халкына социаль хезмәт күрсәтү системасының хәзерге торышы өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты белән идарә итү өлкәсендәге уңай үзгәрешләр хас.

Республикада социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарга дәүләтнең хезмәт күрсәтү оешмасы, шул исәптән дәүләтнеке булмаган 24 оешма күппрофильле ярдәм күрсәтә. Ел саен әлеге учреждениеләр челтәре тарафыннан 204 меңгә якын гражданга хезмәт күрсәтелә.

Республикада ялгыз һәм ялгыз яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераннары, һава һөҗүменә каршы оборона объектларында эшләгән, «Камалыштагы Ленинградта яшәгән» билгесе белән бүләкләнгән, 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда тылда кимендә 6 ай эшләгән авыл кешеләренә өйләренә килеп социаль ярдәм күрсәтү хокукы бирелде.

Республикада авыл җирендә яшәүче 1 425 тыл хезмәтчәненә өйләренә килеп бушлай социаль хезмәт күрсәтелә.

2015 елдан муниципаль дәрәҗәдә 80 яшен тутырган һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз һәм ялгыз яшәүче кешеләрнең тормыш шартларын тикшерү буенча ведомствоара профилактика чарасы уздырыла. 2016 елдан бу эш 70 яше тулган кешеләргә, шулай ук I һәм II төркем инвалидларга карата да башкарыла. 2019 елда социаль хезмәткәрләр йорт саен (фатир саен) йөреп 112,6 мең кешенең хәлен белештеләр. Тикшерүләр барышында көнкүреш приборларын, газ җиһазларын, мичләрне, электр җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләү буенча, янгын вакытында саклану кагыйдәләре буенча, социаль мошенниклыклардан саклану ысуллары турында инструктажлар уздырыла, ашыгыч ярдәм күрсәтүче хезмәтләнең телефоннары теркәлгән белешмәлекләр таратыла, өйдә хезмәт күрсәтүгә мохтаҗлар исемлеккә теркәлә һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүнең индивидуаль программасы төзелә.

2019 елда Татарстан Республикасында Өлкән яштәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт дәвамында тәрбияләү системасын булдыру буенча сынау проектын гамәлгә ашыру башланды. Арча, Биектау, Зеленодольск, Кукмара, Түбән Кама, Балык Бистәсе муниципаль районнары һәм Чаллы шәһәре бу эштә беренчеләр буларак билгеләнгән. Озак вакыт дәвамында тәрбияләү системасына 1 638 кеше кертелгән (социаль хезмәт күрсәтелә торган затларның 8 проценты). Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсенә стационарларга алмашка технологияләр кертү һәм өлкән яштәге

гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту, аларны карау максатында Татарстан Республикасында Өлкән яшьтәге гражданнарны гаиләләргә тәрбиягә бирү (33 муниципаль районда 34 гаилә), «Өйдәге шифаханә» (51 кешегә хезмәт күрсәтелгән), «Тәрбияләү мәктәбе» (сәламәтлек саклау оешмаларының медицина хезмәткәрләрен җәлеп итеп, якыннарына өлкән яшьтәге кешеләрне карау күнекмәләре бирелә (234 кеше), «Сиделка» (193 кеше шөгыльләнә) проектлары тормышка ашырыла.

Инвалидлар файдалана алырлык даирә булдыру максатында 2019 елда 12 мәгариф оешмасы объекты җайлаштырылган (5 гомуми белем бирү, 5 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы һәм 2 балаларга өстәмә белем бирү оешмасы). 2019 елда программаны финанслауның гомуми күләме 21,5 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән 12,1 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 9,4 млн сум тәшкил итте.

2019 ел йомгаклары буенча «Инвалидлар файдалана ала торган социаль инфраструктураның өстенлекле объектлары» индикаторы күрсәткече 58 процент тәшкил итте (план – 55 процент).

«Уңайлы мохит» программасын гамәлгә ашыру кысаларында республикада мәгълүматлар банкын һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларыннан файдалану мөмкинлеге картасын формалаштыру һәм үстерү буенча программа продукты булдырылды һәм сәнәгатьтә файдалануга кертелде. Файдалану мөмкинлеге картасына 6 897 объект буенча мәгълүмат бирелә.

«Ачык Татарстан» проекты кысаларында Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында «Халык контроле» проектының «Һәркем файдалана ала торган мохит» бүлеге хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы кешегә теләсә кайсы объектның уңайлылыгы яисә киресенә уңайсызлыгы турында хәбәр итәргә һәм дәүләт органы яисә муниципаль орган кабул иткән карарның сыйфатын бәяләргә мөмкинлек бирә.

## Хезмәт базары, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм социаль яклау

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә үтемле дәүләт сәясәте уздыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы вазгыять чагыштырмача тотрыклы.

**Халыкны эш белән тәэмин итү күрсәткечләре динамикасы**




«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру республикада эшсезлекне киметүгә ярдәм итте. 2015 елдан башлап теркәлгән эшсезлек күләме өчтән бер өлешкә кимегән. 2019 елда халыкны эшкә урнаштыру хезмәте органнарына 194,7 мең кеше төрле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткән, шул исәптән 63,2 мең кеше эш эзләүчеләр сыйфатында исәпкә алынган. 37,2 мең кешегә эш бирелгән, шуларның 21,1 меңе – эшсез граждан.

2020 елның 1 гыйнварына халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшсезләр сыйфатында 10,9 мең кеше, ягъни эшче көчләр санының 0,54 проценты теркәлгән (2018 елның декабрь азагына – 0,5 процент).

2019 ел башы белән чагыштырганда, эшсезләр составында эштән киткән гражданнар өлеше – 67,5 процентка (2009 елның 1 гыйнварына – 66 процент), хатын-кызлар өлеше – 60,96 процентка (2009 елның 1 гыйнварына – 58,3 процент), пенсия яшенә җитеп килүче гражданнар өлеше – 23,9 процентка (2009 елның 1 гыйнварына – 9,8 процент) һәм эштән азат ителү сәбәпле эштән китүчеләр өлеше – 14,8 процентка (2009 елның 1 гыйнварына – 14,4 процент) арткан.

Эшсезләр составында инвалидлар өлеше 8,5 процентка (01.01.2009 – 11,3 процент), 16 – 29 яшьлек кешеләр өлеше 13,4 процентка (01.01.2009 – 15,1 процент) кимегән.

2020 елның 1 гыйнварына эш бирүчеләр тарафыннан 40,5 мең вакансия тәкъдим ителгән, хезмәт базарында киеренкелек коэффициенты 1 вакансиягә 0,27 кеше тәшкил иткән.

Республика буенча эшсезлекнең уртача дәвамлылыгы 4,04 ай тәшкил итте.

2016 елдан башлап инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре оештырган предприятиеләргә инвалидлар өчен гамәлдәге эш урыннарын саклап калуга субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтелә. 2019 елда программада Казан, Әлмәт, Алабуга, Чистай шәһәрләрендә эшчәнлек алып баручы 8 предприятие катнашты. 341 инвалидка хезмәт өчен түләүгә тотылган чыгымнар капланды.

«Инвалидларга һәм социаль ярдәмгә аеруча мохтаҗ булган гражданнарга эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган инвалидлар һәм гражданнар өчен эш

урыннары резервлау тәртибен раслау турында» 2007 елның 18 маендагы боерыгы нигезендә 2019 елда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен 16 эш урыны резервланды, аларга әлеге категориядәге 2 кеше эшкә урнаштырылды.

Әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эшкуарларда инвалидларны урнаштыру өчен эш урыннары квоталау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары нигезендә 2019 елда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен 979 эш урынына квота бирелде, аларга 489 инвалид эшкә урнаштырылды.

2019 елның 1 гыйнварына баласына өч яшь тулганчы бала карап өйдә утыручы 1 118 хатын-кыз укырга җибәрелде. Укыту хезмәт базарында ихтыяҗ булган һөнәр һәм белгечлекләр буенча уздырылды. Андыйларга маникюр ясаучы, парикмахер, бухгалтер, флорист, ландшафт дизайнеры, интерьер дизайнеры, компьютер дизайнеры, смета эше һәм башка шундыйлар кертелде.

Республикада социаль түләүләр системасы 84 төр түләүдән: 31 төр федераль һәм 53 төр республика чараларыннан тора. Социаль ярдәм чаралары 1,58 миллионнанн артык кешегә, ягъни республика халкының 41 процентына күрсәтелә. 2019 ел йомгаклары буенча төбәк дәрәҗәсендә социаль түләүләр 1,02 млн кешегә, шул исәптән адреслы чаралар 0,76 млн кешегә, ягъни төбәк дәрәҗәсендә социаль түләүләр  алучылар санының 74 процентына бирелгән. Адреслы чараларны финанслау күләме 7,1 млрд сум тәшкил итте.

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә күрсәтү турында» 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарын үтәү йөзеннән, аз керемле гаиләләргә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелә.

2019 елда 3 522 социаль контракт төзелде, дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә тотылган акча күләме 48,7 млн сум тәшкил итте.

2019 елда 11 939 граждан социаль контракт нигезендә дәүләттән социаль ярдәм алды, бу исә социаль ярдәм алган гражданнар гомуми санының 97,9 процентын тәшкил итә.

**Социаль хезмәтләр үсеше**

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасына социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары белән беррәттән дәүләтнеке булмаган оешмалар (коммерциячел һәм коммерциячел булмаган) да кертелә. Аларга, социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларга куелган таләпләргә туры килгәндә, социаль хезмәт күрсәтергә хокук бирелә.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 23 декабрендәге 1012 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрын

формалаштыру һәм алып бару тәртибе расланды. Реестрга кертелү оешмаларга шартнамә нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы кысаларында гражданнарга күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен хезмәт күрсәтүчеләрнең чыгымнарын раслаган документлары булган очракта гына компенсация алырга мөмкинлек бирә.

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына 24 дәүләтнеке булмаган оешма кертелгән, аларның 16сы өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны, 8 е сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләрне тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтә.

Дәүләтнеке булмаган оешмалар өлеше 16,9 процент тәшкил итте (2018 елда – 13,7 процент, 2017 елда – 9,7 процент, 2016 елда – 6,2 процент, 2015 елда – 2,3 процент). 2019 елда дәүләтнеке булмаган оешмалар 9 929 гражданга хезмәт күрсәтте, 185,5 млн сумлык компенсация түләнде.

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсен җайга салучы норматив хокукый документлар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы сайтында урнаштырылган һәм алар һәркемгә ачык.

Татарстан Республикасы халкына дәүләт хезмәте һәм социаль әһәмиятле хезмәтләр күрсәтү ачыклыгын һәм аның сыйфатын күтәрүне тәэмин итү өчен социаль өлкәгә мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланышка кертү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора.

Социаль яклауның сигез хезмәте тулысынча электрон төргә күчерелде:

мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-анадан алына торган түләүнең бер өлешенә компенсация билгеләү (төп компенсация);

мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-анадан алына торган түләүнең бер өлешенә гражданнарга аларның керемнәреннән чыгып бирелә торган өстәмә компенсация билгеләү ;

балага айлык пособие билгеләү;

пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү;

күп балалы гаиләләрдәге укучы балаларга транспортта йөрүгә айлык субсидия билгеләү;

18 яше тулмаган өч яисә аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә торак бина өчен һәм коммуналь түләүләргә субсидия-ташлама билгеләү;

18 яше тулмаган өч яисә аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә 6 яше тулмаган бала өчен дару алуга субсидия билгеләү;

инвалидларга торак өчен һәм коммуналь хезмәткәргә түләүләргә субсидия-ташлама билгеләү.

«Тулысынча электрон хезмәт» сүзтезмәсе гражданга Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (алга таба – Татарстан Республикасы хезмәтләр күрсәтү порталы) гариза бирергә генә кирәклеген аңлата. Социаль яклау хезмәткәрләре барлык мәгълүматны ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша ала. Гариза бирүче кабул ителгән карар

турында шулай ук Татарстан Республикасы хезмәтләр күрсәтү порталы аша белә һәм уңай карар кабул ителгәндә, акчалата социаль ярдәм гариза биргәндә күрсәтелгән счетка күчерелә.

Хезмәт күрсәтүнең бишесе буенча Татарстан Республикасы хезмәтләр күрсәтү порталы аша, сканирланган документлар теркәп, электрон рәвештә гариза бирү гамәлгә ашырыла. Алга таба граждан социаль яклау органнарына документларның оригиналларын алып, шәхсән мөрәҗәгать итәргә тиеш. Бу хезмәт күрсәтүләр түбәндәгеләр:

торак өчен түләүгә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр билгеләү;

гражданнарның аерым категорияләре өчен торакка түләүгә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташламалар билгеләү;

1,5 яше тулмаган бала карау өчен айлык пособие билгеләүгә заявка бирү;

бала тугач, бер тапкыр түләнә торган пособие билгеләүгә заявка бирү;

оешма ябылу сәбәпле эштән җибәрелгән хатын-кызларга йөклелек вакытында һәм бала тапкач түләнә торган пособие билгеләүгә заявка бирү.

Россия Федерациясе Президенты «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы кысаларында, аның нигезендә дәүләт хезмәте алу механизмын кулланучы гражданнар өлеше 70 проценттан ким булмаска тиеш.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең, өйдән чыкмыйча гына, социаль әһәмияткә ия хезмәтләр алу мөмкинлеге бар. Бу исә белгечләр эшенең нәтиҗәлелеген арттырырга, кирәкле белешмәләр бирү өчен территориаль социаль яклау органнарына кирәкмәгән йөрүдән арындырырга һәм, нәтиҗә буларак, социаль яклау бүлекчәләрендә чиратны киметергә мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Хезмәтләр күрсәтү порталында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә түбәндәге дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге гамәлгә ашырылды:

хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат;

гражданнарга аларга кирәкле эш табуда ярдәм итү;

эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда ярдәм итү;

Татарстан Республикасында эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

түләүле иҗтимагый эшләр оештыру;

шул исәптән башка җирдә белем бирүне дә кертеп, эшсез гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү;

эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә ярдәм итү.

2019 ел йомгаклары буенча социаль яклау органнарына тапшырылган 1,7 млн гаризаның 1,5 миллионы гражданның шәхси катнашыннан башка электрон рәвештә бирелгән.

**Үсеш нигезе буларак мәгариф**

*Мәктәпкәчә белем бирүнең үсеше*

Татарстан Республикасында балаларга мәктәпкәчә белем бирү төрле типтагы 2 013 мәгариф оешмасында бирелә, шуларның 1 747се мәктәпкәчә мәгариф оешмалары, 70е башлангыч мәктәпләр-балалар бакчалары, прогимназияләр, 196сы структурасында мәктәпкәчә төркемнәре булган мәктәпләр.

Халыкның туган телдә мәктәпкәчә белем алу ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында республикада татар телендә белем һәм тәрбия бирелә торган 759 балалар бакчасы, 9 – мари телендә белем һәм тәрбия бирелә торган, 45 – чуваш телендә белем һәм тәрбия бирелә торган, 15 – удмурт телендә белем һәм тәрбия бирелә торган балалар бакчасы эшләп килә.

Республиканың 492 мәктәпкәчә белем бирү оешмасында компенсация юнәлешендәге төркемнәр оештырылды, аларга физик мөмкинлекләре чикле 16 мең бала йөри. 4,3 мең бала тубинтоксикацияле, еш авыручы, аллергия, нефрология һәм башка авырулары булган балалар өчен сәламәтләндерү төркемнәренә йөри.

Мәктәпкәчә белем бирүнең вариатив рәвешләре дә үсештә. Күпбалалы гаиләләр базасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының структур бүлекчәләре буларак оештырылган 17 гаилә мәктәпкәчә белем бирү төркемнәре эшләп килә. 2,5 меңнән артык бала төрле юнәлештәге кыска вакытлы төркемнәргә йөри: иртә үсеш, мәктәпкә әзерлек, физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен.

Республикада мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча эшчәнлек алып баручы хосусый 29 мәгариф оешмасы һәм 8 шәхси эшмәкәр бар. Дәүләтнеке булмаган балалар бакчаларында 3,3 меңнән артык бала тәрбияләнә. 2019 елда субсидияләр 21 мәктәпкәчә белем бирү хосусый оешмасына, мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы 7 шәхси эшмәкәргә бирелде. Дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмаларына бирелә торган субсидияләрнең гомуми күләме 2019 елда 138,8 млн сумга җитте.

Гомумән алганда, 224 мең балага мәктәпкәчә белем бирелә, бу исә бер яшьтән алты яшькәчә барлык балалар гомуми санының 69 процентын тәшкил итә. Өч яшьтән сигез яшькәчә булган балаларның 97,5 процентына мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге тәэмин ителә.

*Гомуми белем бирүнең үсеше*

2019 елда Татарстан Республикасында 1 402 гомуми белем бирү оешмасы, шул исәптән 1 318 гомуми белем бирү мәктәпләре һәм мәктәп-интернатлар, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 53 мәктәп һәм мәктәп-интернатлар, 2 санаторий мәктәп-интернат, девиант тәртипле балалар өчен 1 мәктәп, 10 кечке мәктәп, 16 дәүләтнеке булмаган мәктәп, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 1 мәктәбе һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 1 мәктәбе эшли.

Белем алуга чыгымнарны субсидияләү рәвешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме гомуми башлангыч, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча эшләүче хосусый гомуми белем бирү оешмалары үсешенә этәргеч бирде. 2019 елда

субсидияләр 12 гомуми белем бирү хосусый оешмасына бирелде, аларда 1578 бала белем ала, субсидияләрнең гомуми күләме 99,4 млн сум тәшкил итте.

Мәгариф системасында педагогларның һөнәри үсешенә аерым зур роль бирелә. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан педагогларны аттестацияләүнең төбәк системасы укытучылар корпусы әзерлеген камилләштерү һәм Татарстан Республикасында уку-укыту сыйфатын яхшырту бурычлары белән бәйле рәвештә реформалаштырылды, эш бирүчеләрнең педагогик кадрларны эшкә алу, аттестациягә әзерләү, квалификацияләрен күтәрү вакытында билгеләнгән таләпләрне үтәү өчен җаваплылыгын арттыру чаралары күрелде.

2019 елда бердәм дәүләт имтиханын (алга таба – БДИ) тапшырган 15 975 чыгарылыш сыйныф укучысының 151е сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучылар иде.

Республикада дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру процедураларының ачыклыгын һәм аңлаешлылыгын тәэмин итү максатларында җәмәгать күзәтүе системасы оештырылды. 2019 елда җәмәгать күзәтүчеләре буларак Татарстан Республикасының югары уку йортлары һәм педагогика көллиятләрендә укучы 559 студентка аккредитация бирелде. БДИ буенча иң югары нәтиҗәләр күрсәткән (100 балл) укучылар саны узган ел белән чагыштырганда 5 кешегә артты. 100 балл алучылар саны профильле дәрәҗәдәге математика (5 тән 32 гә), физика (7 дән 13 кә) һәм әдәбият (5 тән 15 кә) фәннәре буенча күбәйде. Аларның саны бары рус теле буенча гына сизелерлек кимеде (99 дан 73 кә).

Урта гомуми белем турында аттестат бирелмәгән кешеләр өлеше 2018 ел белән чагыштырганда 0,03 процентка кадәр кимеде (6 кеше).

Татарстан Республикасы буенча БДИ нәтиҗәләре
(урта балл)

| Фән | 2018 ел | 2019 ел |
|---|---|---|
| Рус теле | 74,12 | 74,25 |
| Математика (профиль/ база) | 57,73/4,4 | 64,43/4,48 |
| Җәмгыять белеме | 61,96 | 61,25 |
| Физика | 57,01 | 60,32 |
| Биология | 57,62 | 58,53 |
| Химия | 63,3 | 64,95 |
| Тарих | 58,39 | 59,26 |
| Инглиз теле | 76,69 | 80,43 |
| Информатика һәм ИКТ | 66,36 | 69,6 |
| Әдәбият | 62,39 | 71,2 |
| География | 64,34 | 65,1 |
| Алман теле | 72,21 | 79,17 |
| Француз теле | 76,5 | 65,2 |
| Испан теле | 83 | - |

2019 елда Бөтенроссия һәм республика олимпиадаларының мәктәп этабында катнашучылар саны 180 меңнән артып китте, шуларның 40 меңнән артыгы – җиңүчеләр һәм призерлар; 68 233е – муниципаль этапта катнашучылар, шуларның 13 779ы – җиңүчеләр һәм призерлар.

Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы мәктәп укучылары командасы җиденче ел рәттән Мәскәү һәм Санкт-Петербург командаларыннан гына калышып, Россия Федерациясендә 3 урынны ала. Призер һәм җиңүче дип 148 кеше танылды.

2019 елда халыкара олимпиадалар йомгаклары буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләре яхшырды:

Венгриядә узган Биология буенча халыкара олимпиаданың көмеш медале;

Румыниядә узган Информатика буенча халыкара олимпиаданың алтын медале;

Санкт-Петербург шәһәрендә узган Халыкара Менделеев олимпиадасында көмеш медаль;

Кытай Халык Республикасында узган XVIII Кытай хатын-кызлар математика олимпиадасында алтын медаль;

Казахстан Республикасында узган Информатика, физика һәм математика буенча XV халыкара укучылар Жаутыков олимпиадасында ике көмеш һәм биш бронза медаль;

Болгария һәм Румыниядә узган Программалаштыру буенча халыкара турнирда дүрт алтын, бер көмеш һәм биш бронза медаль;

Болгариядә узган Информатика буенча халыкара турнирда дүрт алтын, дүрт көмеш һәм сигез бронза медаль.

2019/2020 уку елында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 12 838 баланың 4 918е муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә, 7 920е дәүләт бюджет гомуми белем бирү оешмаларында белем ала.

15 муниципаль район һәм Казан шәһәрендә 115 коррекция сыйныфы эшли, аларда 987 бала белем ала (ишетү, сөйләм, терәк-хәрәкәт органнары зарар күргән, психик үсеше тоткарланган, акылга зәгыйфь (интеллектуаль үсештә тайпылышлы) балалар).

525 гомуми белем бирү учреждениеләре базасында 2 016 сыйныфта сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 4 191 бала башка балалар белән бергә укый.

53 дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә кертү кысаларында педагогик тәҗрибәне өйрәнү буенча стажировка мәйданчыклары булып тора.

Тулаем алганда, гомуми белем бирү оешмаларында (коррекция мәктәпләрен дә кертеп) өйдә 1 982 бала укый, шуларның 70енә дистанцион технологияләрдән файдаланып белем бирелә.

2019 уку елы дәвамында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән һәм акылга зәгыйфь (интеллектуаль яктан тайпылышлары булган) балаларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә кертү 183 гомуми белем бирү мәктәбе базасында алып барыла. Башлангыч гомуми белем бирүнең адаптацияләнгән төп мәгариф программалары буенча сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 621 бала белем ала.

2019 елда Татарстан Республикасының мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм һөнәри яңадан әзерләү буенча өстәмә һөнәри белем бирү программалары (модульләре) республика реестрына кертелгән 14 программа

буенча 420 укытучы-дефектолог (тифлопедагог, олигофренопедагог, сурдопедагог), укытучы-логопед, шулай ук 265 педагог-психолог, социаль педагог укытып чыгарылды.

2019 елда электрон мәгарифтә компетенция үзәге булган 54 мәктәптә техника паркы яңартылды (заманча интерактив комплекслар сатып алынды).

Республикада «Яндекс.Лицей» мәгариф проектын тормышка ашыру дәвам итә. Ул 8 – 9 сыйныф укучыларын дөньяда иң популяр һәм еш кулланыла торган программалаштыру телендә (Питон) эшләргә өйрәтүгә юнәлдерелгән. 2019 елда проект 11 торак пункттагы 25 көндезге мәйданчык базасында гамәлгә ашырылды, аларда 30 укытучы укытты.

Татарстан Республикасында төрле мәгариф онлайн-платформаларын актив файдалануга кертү дәвам итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 августындагы 2132-р-к номерлы боерыгы нигезендә «Ачык мәктәп 2035» мәгариф платформасына (алга таба – платформа) Татарстан Республикасының 500 белем бирү оешмалары тоташтырылды, аның функционалы һәм контенты белем бирү процессында кулланыла. Платформада 1-11 сыйныфлар өчен мәктәп программасы нигезендә эшләнгән 10 меңнән артык видеоәсбаб, тренажерлар, тестлар һәм башка материаллар бар.

2019/2020 нче уку елыннан Татарстан Республикасы 20 белем бирү оешмасы базасында укытуның индивидуаль траекторийларын гамәлгә ашыруны һәм нәтиҗәләрне бәяләүне тәэмин итүче цифрлы платформаны сынау буенча Россия Федерациясенең пилот субъектларыннан берсе булып тора.

*Милли мәгарифне үстерү*

2019 елда телләрне үстерү буенча дәүләт программасы кысаларында республика дәүләт телләре буларак рус һәм татар телләре функцияләренең тигезлеген саклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру дәвам итә.

Программаның төп бурычларыннан берсе – республикада туган телләрне өйрәнүнең һәм республикада туган телләрдә укытуның тулаем системасын үстерү, Татарстан Республикасыннан читтә татар телен өйрәтүгә ярдәм итү.

Хәзерге вакытта республиканың мәгариф оешмаларында 5 телдә (рус, татар, чуваш, удмурт, мари) белем бирелә, 7 тел (рус, татар, чуваш, удмурт, мари, мордва, иврит) өйрәнү предметы булып тора. Якшәмбе мәктәпләрендә 23 милләтнең теле һәм мәдәнияте өйрәнелә. Укыту-методика ягыннан ярдәм итү өчен аларның эшчәнлеге дәреслекләр белән тәэмин ителә. 2016 – 2019 елларда туган телләр (чуваш, удмурт, мари, мордва) өйрәтелә торган мәктәпләргә барлыгы 2,2 млн сумлык 15 мең экземпляр дәреслек һәм матур әдәбият китаплары китертелде, Татарстанның якшәмбе мәктәпләре өчен дәреслек-методик комплектлары сатып алынды. Татар телен укытуның методикасын һәм технологияләрен камилләштерү һәм норматив базаны ныгыту максатында гомуми белем бирү оешмаларының 1 – 11 сыйныфлары өчен «Татарстан Республикасы дәүләт теле – татар теле», «Туган тел», «Әдәбият», «Туган телдә әдәбият уку» дигән предметлар буенча үрнәк төп мәгариф программалары эшләнде.

Федераль исемлеккә татар теле һәм әдәбияты буенча 89 дәреслек кертелде, 24 укыту-методик комплекты уку әсбабы буларак кулланыла.

Республика халыкларының телләрен саклап калуга һәм үстерүгә татар һәм рус телләре халыкара олимпиадаларын, туган телләр буенча республика олимпиадаларын, мәктәп театрлары һәм якшәмбе мәктәпләре театрлары фестивальләрен, мәктәп укучыларының этномәдәният компонентлы слетларын, тикшеренү эшләре конкурсларын уздыру зур этәргеч бирә.

2019 елның апрелендә Яшь шагыйрәләр һәм язучыларның «Илһам» бөтенроссия конкурсы уздырылды. Анда 1600 дән артык укучы катнашты, шул исәптән алар арасында Россия Федерациясенең 11 субъектыннан килүчеләр дә бар иде.

2019 елда татар теле һәм әдәбияты буенча VII халыкара олимпиадасы узды. Аның йомгаклау өлешенә 15 чит илдән һәм Россия Федерациясенең 26 субъектыннан 500 укучы һәм студент чакырылган иде.

2019 елның июнендә туган (рус булмаган) телдә белем бирә торган мәктәп укучылары өчен рус теле буенча Халыкара олимпиада үткәрелде. Анда 3 меңнән артык мәктәп укучысы катнашты, беренче турда Россиянең 22 субъектыннан һәм 4 чит илдән 129 укучы көч сынашты.

Татарстан Республикасында «Тоталь диктант» һәм «Татарча диктант» акцияләрендә катнашучылар саны елдан-ел арта бара. 2019 елда рус теле буенча тоталь диктантны 6 меңнән артык кеше, татар теленнән – Россия Федерациясенең 47 субъектыннан һәм 22 чит илдән 85 меңгә якын кеше язган.

Республикада яшәүче халыкларның дәүләт телләрен һәм телләрен популярлаштыру максатыннан 32 чара: иҗади конкурслар, фәнни-гамәли конференцияләр, олимпиадалар үткәрелде, аларда 40 меңнән артык кеше катнашты.

2019 елда укыту-методик ярдәм күрсәтү максатларында Россия Федерациясе субъектларының белем бирү оешмалары өчен 5 876 берәмлек уку әдәбияты сатып алынды һәм таратылды.

Татар телен электрон мәгълүмат киңлегенә таратуны гамәлгә ашыру буенча системалы чаралар күрелде. Балалар арасында да, өлкәннәр арасында да «Шаян ТВ» балалар телевизион каналы, «Бала» балалар мультимедиа китапханәсе һәм «Татар иле» электрон мәктәп энциклопедиясе популярлык казанды. Алар шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган һәм барлык төбәкләр өчен ачык.

Татар телендә интерактив проектлар: заманча операция системаларын туплау, татар теленең электрон корпусын, виртуаль клавиатурасын, шулай ук мобиль операция системалары өчен сүзлекләр булдыру программаның мөһим юнәлеше булды.

2019 елда «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе базасында Россия Федерациясенең 15 субъектыннан 40 татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләре квалификациясен күтәрде.

Милли мәктәпләр өчен педагогик кадрлар әзерләү кысаларында «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесе (алга таба – К(И)ФУ) базасында – 25 һәм «Чаллы дәүләт педагогика

университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү учреждениесе базасында 67 кеше белем алды.

К(И)ФУ базасында «Татар теле һәм әдәбияты», «Рус теле һәм әдәбияты» юнәлешләре буенча магистрлар һәм аспирантлар әзерләү дәвам иттерелә, рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча эшчәнлек алып баручы галимнәр һәм укытучылар өчен грантлар гамәлгә куелды.

Төбәкара профильле тел лагерьларында балаларның җәйге ялын оештыруга аерым игътибар бирелә. 2019 елда аларда Россия Федерациясенең 30 субъектыннан һәм 2 чит илдән 2 меңнән артык бала булып китте.

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең милләтара багланышларын саклап калу һәм ныгыту максатларында Туган тел укытучыларының осталык дәресләре бөтенроссия конкурсы «Туган тел», якшәмбе мәктәпләре һәм этномәдәни компонентлы белем бирү мәктәпләренең республикакүләм слеты, фәнни-тикшеренү конференцияләре һәм укучыларның Россия Федерациясе халыклары телләрендә әдәби әсәрләрне халык алдында укулары уздырылды.

Татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен «Ана теле» татар телен дистанцион өйрәнү буенча онлайн-мәктәбе гаять мөһим эш башкара. Аның эшчәнлеге системага керүгә чикләнмәгән рөхсәт биреп 2023 елның 1 июненә кадәр озайтылды.

«Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» бөтенроссия конкурсының йомгаклау өлешендә Татарстан Республикасыннан һәм Россия Федерациясе төбәкләреннән 32 иң яхшы укытучы катнашты. Фәннәрне татар телендә укытучыларга ярдәм итү өчен 50 укытучыга 71,5 мең сум күләмендә «Оста мөгаллим» гранты гамәлгә куелды, татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадаларында, татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиадада җиңүчеләрне әзерләгән өчен 13 укытучыга 115 мең сум күләмендә грант каралды.

Барлык муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары дәрәҗәсендә милли мәгарифне үстерү һәм туган телдә белем һәм тәрбия бирә торган мәгариф оешмалары челтәрен үстерү планнары расланды.

***«Мәгариф» илкүләм проекты***

2019 елда Татарстан Республикасы территориясендә «Заманча мәктәп», «Һәр баланың уңышы», «Цифрлы нигездә белем бирү мохите», «Яшь профессионаллар (һөнәри белемнең конкурентлык сәләтен арттыру)» төбәк проектлары буенча 8 чара гамәлгә ашырылды. Моңа 7,7 млрд сум акча тотылды, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 7 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 0,7 млрд сум.

2019 елда түбәндәге чаралар үткәрелде:

«Һәр баланың уңышы» проекты кысаларында барлыгы 8,8 млн сумга «Заманча мәктәп» төбәк проекты буенча 2 мәктәп төзелде, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында 6 спорт залы төзекләндерелде, шул исәптән федераль бюджет акчалары 5,1 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы 3,7 млн сум тәшкил итте;

«Заманча мәктәп», «Цифрлы нигездә белем бирү мохите» һәм «Яшь профессионаллар (һөнәри белемнең конкурентлык сәләтен арттыру)» проектлары

кысаларында республика мәктәпләренә 338,6 млн сумлык җиһазлар кайтартылды, шул исәптән федераль бюджет акчалары 274,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары 64,3 млн сум тәшкил итте;

федераль бюджет акчалары хисабына 6,1 млрд сумга WorldSkills чаралары үткәрелде.

«Заманча мәктәп» проекты кысаларында 2019 елда Татарстан Республикасының 97 авыл мәктәбендә «Үсеш ноктасы» цифрлы һәм гуманитар профильле белем бирү үзәкләре булдырылды. Белем бирү эшчәнлеген фәкать җайлаштырылган гомуми белем бирү программалары буенча гына башкаручы 17 оешмада хезмәт остаханәләренең, педагог-психолог, укытучы-дефектолог, укытучы-логопед, өстәмә белем бирү кабинетларының матди-техник базасы яңартылды.

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру чарасы кысаларында Казан шәһәренең Раис Гәрәев урамында 1 224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы («Перспектива» – 186 номерлы күппрофильле лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәренең Идел буе районы) ачылды.

Гомуми белем бирү инфраструктурасын модернизацияләү чаралары кысаларында 2019 елда Казан шәһәренең Бондаренко урамында 1 224 урынга исәпләнгән полилингваль гомуми белем бирү мәктәбен төзү эшләре башланды.

«Балалы гаиләләргә ярдәм итү» проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2019 елда Татарстан Республикасының 6 оешмасы консультация үзәкләре челтәрен булдыру буенча инновация проектларын гамәлгә ашырды («Тиктормас» мәгариф үзәге» автоном коммерциячел булмаган гомуми белем бирү оешмасы, Чаллы шәһәренең «Балалар тәрбиясен сәнгать-эстетик юнәлештә үстерү эшчәнлегенә өстенлек бирелә торган 95 номерлы «Балкыш» гомум үсеш төрендәге балалар бакчасы, «Гусельки» катнаш төрдәге 12 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, «Чаллы шәһәренең катнаш төрдәге 105 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, «Чаллы шәһәренең 105 номерлы «Дюймовочка» катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Мәскәү районының «403 номерлы татар телендә тәрбия һәм белем бирелә торган катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Яңа Савиново районының «Катнаш төрдәге 151 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе) . Әлеге балалар бакчаларында ата-аналар өчен балаларны тәрбияләү, үстерү һәм белем бирү мәсьәләләре буенча консультация үзәкләре булдырылды, шулай ук ерак торак пунктларда яшәүче ата-аналар өчен күчмә консультацияләр үткәрелде. 2019 елда чараларны гамәлгә ашыру өчен 26,2 млн сум бүлеп бирелде шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 21,2 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 5 млн сум. 2019 елда оешмалар 18 яшькә кадәрге балалар белән 120 200 консультация үткәрде.

Республиканың 32 мәгариф оешмасында «Цифрлы нигездә белем бирү мохите» проекты кысаларында цифрлы нигездә белем бирү мохитенең максатчан моделе кертелде. 15 мәктәп һәм 17 урта һөнәри белем бирү оешмасы өчен исәпләү

техникасы, укучыларга һәм педагогларга цифрлы нигездә белем бирү инфраструктурасына (федераль электрон платформаларны да кертеп) керү мөмкинлеге бирә торган программа һәм презентация җиһазлары сатып алынды.

2019 елның 23 декабрендә «Яшь һөнәр ияләре (һөнәри белемнең конкурентлык сәләтен арттыру)» проекты кысаларында «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында алдан һөнәри әзерлек үзәге (алга таба – үзәк) – гражданнарның барлык категорияләренә аеруча кирәкле, яңа һәм соралган һөнәрләр һәм компетенцияләр буенча һөнәри юнәлеш бирү, әзерлек, яңадан әзерлек, квалификация күтәрү өчен Татарстан Республикасы ресурслары агрегатор-мәйданчыгы һәм операторы ачылды. Үзәкнең максаты – кеше капиталын үстерү өчен уңайлы тирәлек булдыру, республикада ачылган 37 ресурс үзәгендә тупланган ресурслар интеграторы буларак, төбәктәге өстенлекле компетенцияләр буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен барлык төр белем бирү ресурсларыннан гражданнар (пенсия алды яшендәге гражданнарны да кертеп) файдалана алуны тәэмин итү. Үзәкнең төп партнерлары – эш бирүчеләр, югары белем бирү мәгариф оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары. Хезмәттәшлек механизмы төбәк һәм федераль дәрәҗәләрдәге мәгълүмати-коммуникация ресурслар белән кушылган цифрлы платформа аша тормышка ашырыла.

2019 елның 22 – 27 августында Казан шәһәрендә «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәге мәйданчыгында Worldskills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионаты узды, анда 56 компетенция буенча 63 илдән 1 354 яшь һөнәр иясе катнашты.

Чемпионат йомгаклары буенча Россия илкүләм җыелма командасы катнашучы илләр арасында икенче гомумкоманда урыны яулады. Россия Федерациясе ирешкән нәтиҗәгә Татарстан Республикасыннан конкурсантлар зур өлеш кертте, алар 11 төп компетенциядә һөнәри осталыклары өчен бер алтын, бер көмеш, ике бронза медаль һәм сигез медаль яуладылар. Моннан тыш, Junior Skills категориясендә Татарстан Республикасыннан конкурсантлар 3 компетенция буенча һөнәри осталыклары өчен бер алтын һәм ике медаль, FutureSkills категориясендә – 11 алтын һәм 3 бронза медаль яуладылар.

«Социаль активлык» проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2019 елда «Россия иреклеләр хәрәкәте» бердәм мәгълүмат системасында 13 996 волонтер һәм 316 оешма теркәлгән. ON RUSSIA кушымтасында 1 991 студент теркәлгән.

Татарстан Республикасының иреклеләр хәрәкәтенә (волонтерлыкка) ярдәм итү максатыннан Татарстан Республикасында иреклеләр хәрәкәтен (волонтерлыкны) үстерү өчен ведомствоара совет төзелде. Аның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының иреклеләр (волонтерлар) мәсьәләләре буенча иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлеген тәэмин итү;

- иреклеләр (волонтерлар) хәрәкәтенең өстенлекле юнәлешләренә булышлык итү һәм Татарстан Республикасында иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр формалаштыру;

- иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлегенә методик ярдәм күрсәтү (мәгариф, сәламәтлек саклау,

гражданлык-патриотлык тәрбиясе бирү, мәдәният, социаль яклау һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, әйләнә-тирә мохитне саклау, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен булдырмау һәм бетерү, эчке эшләр органнарына ярдәм итү, вакыйга, инклюзив, корпоратив ирекледәр хәрәкәте (волонтерлык), өлкән яшьтәге гражданнарның ирекледәр (волонтерлар) хәрәкәте – «көмеш волонтерлык»);

- Татарстан Республикасының ирекледәр хәрәкәте (волонтерлык) буенча норматив хокукый актлары проектлары буенча фикер алышу;

- ирекледәр (волонтерлар) хәрәкәтенә комплекслы анализ ясау һәм Татарстан Республикасында ирекледәр (волонтерлар) хәрәкәтенә ярдәм күрсәтү буенча гамәлләр турындагы мәгълүматны гомумиләштерү.

Ирекледәр хәрәкәтенә һәрьяклап ярдәм итү максатыннан «Татарстан Республикасы ирекледәр хәрәкәте үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы төзелде. Ресурс үзәге эшчәнлегенең төп юнәлешләре – волонтерлар, волонтерлык оешмалары һәм дәүләт хакимияте органнары вәкилләре арасында үзара хезмәттәшлекне оештыру, конкурс нигезендә волонтер берләшмәләренә һәм волонтерларга финанс һәм матди ярдәм күрсәтү, республикада ирекледәр хәрәкәтен пропагандалау.

2019 елда Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан яшьләр башлангычларын, шул исәптән ирекле проектларны яклауга юнәлдерелгән грант конкурсы үткәрелде. Конкурста катнашуга 126 гариза кабул ителде, 25 оешма (72 проект) җиңүче дип танылды, 18,4 млн сумлык грант бирелде.

Эшләнгән мәгариф программалары нигезендә «Шәфкать. Университет» сайтындагы Социаль фәннәр онлайн-университетында дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнарының ирекледәр хәрәкәтен үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы 170 белгече әзерлек (яңадан әзерлек) курслары узды, 33 кеше «Мәдәни башлангыч» белем бирү-акселерация программасында катнашты.

2019 елда студент яшьләр өчен үз мөмкинлекләрен тормышка ашыруга һәм һөнәри үсеш өчен сәләтләрен, шәхси компетенцияләрен формалаштыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән проектлар һәм чаралар комплексын гамәлгә ашыру эше дәвам иттерелде. «Тиңнәрчә кара-каршы сөйләшү» проекты кысаларында 22 очрашу үткәрелде.

Ел саен Татарстан Республикасы «Таврида» яшь мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре форумында катнаша. 2019 елда 67 кеше «Таврида»форумында катнашты. Фестиваль кысаларында грант конкурсын үткәрү йомгаклары буенча Татарстан вәкилләре 6 млн сумлык грантлар алды.

Ирекледәр хәрәкәтен (волонтерлыкны) популярлаштыру максатыннан мәгълүмати һәм реклама кампаниясе үткәрелде, шул исәптән телевидениедә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә реклама роликлары күрсәтелде. Теле- һәм радиорекламаның аудиториясен ел саен 10 миллионнан да ким булмаган кеше тәшкил итә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм социаль челтәрләрдә елына ким дигәндә 1000 мәгълүмати материал урнаштырыла.

***«Белем бирү төбәге: яңа икътисадка – яңа һөнәрләр һәм белемнәр» флагман проекты***

«ИнноКам» территориаль аерымланган инновация-җитештерү үзәген булдыру концепциясен гамәлгә ашыру кысаларында 2016 елдан Чаллы шәһәрендә Күпфункцияле гамәли квалификацияләр үзәге һәм Түбән Кама шәһәрендә Казан милли тикшеренү технология университетының Нефть химиясе инжиниринг үзәге эшли. Алар Татарстан Республикасының югары технологияле тармаклары белгечләренең квалификациясен күтәрү белән шөгыльләнәләр. Проект төбәктә машина төзү тармагында белем дәрәҗәсе төрле булган белгечләргә булган ихтыяҗ мәсьәләләрен хәл итәргә тиеш.

Күпфункцияле гамәли квалификацияләр үзәге – гамәли күнекмәләр һәм белем алу өчен һөнәри укыту һәм квалификация күтәрү буенча кыска вакытлы программаларны гамәлгә ашыручы уку үзәге. Анда түбәндәге эшчәнлек алып барыла:

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте персоналын өйрәтү, шул исәптән яңа һөнәр бирү өчен;

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте хезмәткәрләре квалификациясен, шул исәптән разрядын да, күтәрү өчен;

профильле мәгариф оешмаларында студентлар өчен уку-гамәли дәресләр уздыру өчен;

чит оешмалар хезмәткәрләрен һәм аерым затларны укыту өчен.

Чаллы шәһәрендә Күпфункцияле гамәли квалификацияләр үзәгендә машина төзү өлкәсендә 150 программа буенча төрле эшче һөнәрләр һәм белгечләр әзерләү каралаган. Үзәктә 18 уку кабинеты һәм лаборатория бар, алар заманча җиһазлар белән комплектланган. Болар: Mercedes-Benz двигательле КАМАЗ – 5 490 магистраль автопоездларын тарту машинасы, «Kremit» BSB буяу-киптерү камерасы, «Clark GTX16 электртөягеч, 6 «Wabeko» өйрәнгеч станоклары һәм «CORTINI» һәм башка лаборатор җиһазлар.

2019 елның 26 декабрендә Казан шәһәрендә һөнәри белем бирү оешмаларында «Мехатроника» юнәлеше буенча белем бирү дуаль системасын гамәлгә кертү проектының өченче этабына йомгак ясалды. Проектта һөнәри белем бирү оешмаларының 26 вәкиле һәм аларның җитештерүдәге партнерлары – Татарстан Республикасының машина төзелеше комплексы предприятиеләре катнашты. Тренинг нәтиҗәләре буенча «заманча автоматлаштырылган җитештерү эше принциплары», «Мехатроника һәм сәнәгать робототехника», «Заманча белем бирү технологияләре», «Предприятиеләрдә остазлык» юнәлешләре буенча белем бирү оешмалары вәкилләре үз партнерлары белән берлектә предприятиеләрдә алга таба гамәлгә кертү өчен җитештерү практикасы программаларын эшләделәр. Эшләнелгән программаларны бәяләүдә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Алдан-алы һөнәри әзерлек үзәге вәкилләре, Ford Motor Company һәм Sollers (Алабуга шәһәре) уртак предприятиесе заводының техник белгечләре катнашты.

2019 елда Россия Федерациясенең «Мәгарифне үстерү» дәүләт программасының «Яңа федераль стандартлар нигезендә конкрет өлкәләрнең модернизацияләү концепцияләрен эшләү, челтәр методик берләшмәләре булдыру

һәм аларга ярдәм итүне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү аша технологияләрне һәм укыту эчтәлеген яңарту» чарасы кысаларында метапредмет компетенцияләр буенча 3 996 мәгариф хезмәткәре квалификациясен күтәрде.

2013 елдан Казан (Идел буе) Федераль Университеты 5/100 федераль проектында катнаша (әйдәп баручы дөнья фәнни-мәгариф үзәкләре арасында конкурентлыкны үстерү максатында дәүләт ярдәме алу ачык конкурсында җиңүчеләрнең берсе). Проектта катнашуның стратегик максаты – дөнья университетларының ТОП-100 исемлегенә керү һәм шул рәвешчә Татарстан Республикасының имиджын күтәрү.

2019 елда Татарстанның югары уку йортлары дөнья югары уку йортларында уңай динамиканы саклап калды. Аерым алганда, QS World University Rankings халыкара академик рейтингында Казан (Идел буе) Федераль Университеты, проектта катнашуның тулаем чорында 258 позицияне узып, 392 позицияне биләде.

Times Higher Education «Мәгариф» юнәлеше буенча предмет рейтингында (анда 400дән артык югары уку йорты катнаша) Казан (Идел буе) Федераль Университеты 94 урынны алды һәм дөньяның иң яхшы йөз югары уку йорты исемлегенә керде.

«2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы кысаларында 2019 елда Яшьләрнең «Талантлар ачу» җәйге мәктәбе – укучылар, остазлар һәм экспертлар, Татарстанның алдынгы компанияләре һәм предприятиеләре, муниципаль идарә органнары вәкилләре, яшьләрне социаль-икътисадый проблемаларны хәл итүгә һәм аның Татарстан Республикасы икътисадына кушылуына җәлеп итү максатыннан, белем бирү мәйданчыгы уздырылды. Белем бирү программасы өч этаптан торды: «Карьера навигациясе», «Проект лабораторияләре» һәм «Сайлап алу өчен лабораторияләр».

2019 елда мәктәптә 13 яшьтән 17 яшькә кадәр 850 яшь кеше, 32 остаз һәм 35 остаз-модератор катнашты.

2019 елның февралендә 8 – 11 сыйныф укучылары өчен «Киләчәк һөнәрләре кампусы» дип аталган һөнәри пробалар күргәзмәсе оештырылды, анда республиканың 3 070 мәктәп укучысы катнашты.

2019 елның июлендә «Һөнәрләр кампусы» уздырылды, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе һәм якын һәм ерак чит илләрдәге 1000гә якын сәләтле укучы башлангыч һөнәри юнәлеш бирү буенча биш мәйданчыкта булып киттеләр:

| Т/с | Юнәлеш (мәйданчык) | Оешманың исеме |
|---|---|---|
| 1. | Нефть химиясе | «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ |
| 2. | Урбанистика | «Унистрой ИК» ААҖ |
| 3. | Кораблар төзелеше | «Зеленодольскиның А. М. Горький исемендәге заводы» ААҖ |
| 4. | Энергетика | «Казан дәүләт энергетика университеты» ЮБ ФДБМУ |
| 5. | Нейротехнологияләр | «Андромед» АКБО |

2019 елның 25 октябрендә «Мәгарифтә остазлык: заманча теория һәм инновация гамәле» бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе уздырылды, анда

талантлар белән идарә итү һәм яшьләрнең мөмкинлекләрен һәм компетенцияләрен үстерү өлкәсенең актуаль мәсьәләләре каралды.

*«Югары мәктәпләрнең конкурентлыкка сәләтен үстерү өчен партнерлык» флагман проекты*

2019 елда «Югары икътисад мәктәбе» илкүләм тикшеренү университеты ректоры Я.И. Кузьминов белән очрашу йомгаклары буенча Татарстан Республикасында урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан гамәли бакалавриат программаларын үтәү буенча «Юл картасы» эшләнде.

Гамәли бакалавриатның гамәли юнәлешле программалары кадрлар әзерләү системасыннан гыйбарәт, анда һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның югары белем бирү оешмаларында шундый ук әзерлек профильләрендә тизләтелгән укуларын дәвам итүе каралган. Белем бирү программасының структурасының 70 проценты кызыксынган предприятиеләр (оешмалар) базасында практик дәресләрдән һәм 30 проценты теоретик дәресләрдән тора. Проектның максаты – эш бирүчеләрнең соратулары нигезендә кирәкле компетенцияләргә һәм гамәли күнекмәләргә ия булган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләү.

Бердәм федераль норматив хокукый базаны формалаштыру йомгаклары буенча белем бирү процессына кертү планлаштырыла торган урта һөнәри белем – югары белем бирү моделе буенча гамәли бакалавриат программаларының алты концепциясе әзерләнде.

**«Инноваторларга социаль ярдәм» флагман проекты**

2019 елда «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында белем бирү буенча күрсәткечләре түбән булган мәктәпләрдә һәм начар социаль шартларда эшләп килүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын күтәрү чарасын гамәлгә ашыру буенча 5 528 кеше «Конкрет өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү һәм челтәр методик берләшмәләренә ярдәм итү буенча яңа федераль дәүләт белем бирү стандартына туры китереп белем бирү технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» чарасы буенча квалификацияләрен күтәрделәр.

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларын кызыксындыру, аларның һөнәри дәрәҗәсен күтәрү һәм иҗади потенциалын үстерү, иң яхшы педагогик тәҗрибәне тарату, педагогик хезмәтнең абруен күтәрү максатыннан 2019 елда «Өлкән укытучы» (4 000 сум), «Укытучы-мастер» (5 000 сум), «Укытучы-остаз» (8 000 сум) һәм «Укытучы-эксперт» (10 000 сум) номинацияләрендә грант ярдәме гамәлгә ашырылды. 2019 елда грант ярдәме 593 педагогка бирелде (100 – «өлкән укытучы», 155 – «Укытучы-мастер», 250 – «Укытучы-остаз», 88 – «Укытучы-эксперт» номинацияләрендә).

**Яшьләр сәясәте**

2019 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Россия төбәкләре арасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең федераль рейтингында 85,29 процент нәтиҗәлелек күрсәткече белән (2018 елда 2 урын –

72,81 процент) беренче урынны алды.

Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге оешмалар челтәрендә 313 учреждение исәпләнә: 11 республика учреждениесе, 29 муниципаль яшьләр үзәге, 223 муниципаль яшүсмерләр клубы, балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү буенча 9 муниципаль үзәк, балалар һәм яшьләр өчен телефон аша ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү үзәкләре, студентларның 2 муниципаль хезмәт отрядлары үзәге, җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләренең 37 муниципаль үзәге, хәрби-патриотик эш һәм яшьләрне әзерләү буенча 2 муниципаль үзәк.

Яшьләр сәясәте учреждениеләрен яңарту буенча эшнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен 2019 елда «Яшьләр мохите объектларын яңарту институты» автоном коммерциячел булмаган оешма төзелде. 2019 елда 13 сәламәтләндерү лагере, 27 яшүсмерләр клубы, 18 сәламәтләндерү учреждениесенә керү юллары ремонтланды, моңа барлыгы 1,3 млрд сум акча тотылды.

Республикада балалар һәм яшьләрнең җәйге ялын, аларны сәламәтләндерүне, аларның мәшгульлеген оештыру буенча нәтиҗәле система булдырылды. 2019 елда сәламәтләндерү кампаниясен үткәрүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 1 731 млн сум бүлеп бирелде, бу 2018 елга караганда 18,7 процентка артыграк. Татарстан Республикасында 218 672 кешегә карата ял һәм сәламәтләндерүнең төрле формалары кулланылган. Барлык төрдәге 1 815 лагерь, шул исәптән 115 стационар лагерь, 10 санатория-курорт учреждениесе, Краснодар крае һәм Кырым Республикасының Кара диңгез яры буенда 5 лагерь, палаткалы 65 лагерь, 944 көндезге лагерь, 676 хезмәт һәм ял лагере эшли.

Яшьләр проблемаларын нәтиҗәле хәл итү өчен 8 ярдәмче программадан торган «Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү» яңа тармак программасы расланды.

2019 елда Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтүне булдыру һәм үстерү концепциясе расланды, аның максаты – халыкка уңайлы һәм югары профессиональ психологик ярдәм күрсәтү өчен шартлар тудыру. Психологлар өчен 2 практик кулланма эшләнде: «Гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында эшләүче педагог-психологларның һөнәри эшчәнлеген оештыру буенча навигатор (гамәли җитәкчелек), «Психологик эшчәнлектә нәтиҗәле хезмәттәшлекнең клиентларга юнәлтелгән техникасы».

2019 елда Татарстан Республикасы яшьләрнең иреклеләр хәрәкәте 60 663 кешене берләштерде, шул исәптән 27 122 мәктәп яшендәге (7 – 17 яшь), 18 – 30 яшьләрдәге 27 915, 31 – 55 яшьләрдәге 2 811, 2 785 «көмеш» яшьтәге (55 яшьтән өлкәнрәкләр) иреклеләр хәрәкәтендә катнашучыны берләштерде.

2019 елда «Россия иреклеләр хәрәкәте» конкурсының төп призы «Э-моция» инклюзив иҗат студиясе проекты өчен Татарстан Республикасы вәкиле Инесса Клюкинага бирелде.

«Җиңү волонтерлары» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлеге Россиянең иң яхшы төбәк бүлекчәләре бишлегенә керә. 2019 елда ул 800 дән артык патриотик акция һәм чара үткәрде.

Халыкара яшьләр проектларын һәм чараларын үткәрү кысаларында Татарстанга 47 чит илдән яшьләр килде. 2019 елда Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең эшкуарлык эшчәнлегенә, талантлы яшьләргә, яшьләрнең рухи үсешенә, яшьләрнең халыкара мәйданда үзара алмашуына ярдәм итүгә юнәлдерелгән шартлар тудыру кебек юнәлешләр буенча 15 халыкара яшьләр проекты үткәрелде.

2019 елда яшьләр сәясәте өлкәсендә 828 халыкара, бөтенроссия һәм республика чаралары узды.

Республика яшьләре өчен социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыру дәвам итте:

«Татарстан Республикасы транспорт гранты». 2019 елда республика бюджетыннан конкурсны гамәлгә ашыру өчен субсидия күләме, бер кешегә уртача кереме 20 мең сумнан артмаган гаиләдән булган укучылар хисабына, шулай ук муниципаль берәмлеккә карап грант күләмен билгеләү белән, грант алучыларның категориясен киңәйтеп, 60 млн сумга кадәр арттырылды. 5 792 кеше транспорт гранты алды;

«Безнең Татарстан» республика яшьләр форумы (930 проект бирелгән, шуларның 137 проекты уңышлы тормышка ашырылган);

«Наше время – Безнең заман» эшче яшьләр иҗаты ачык республика телевизион фестивале (980 кеше катнашты);

«Созвездие-Йолдызлык» эстрада сәнгате ачык республика яшьләр фестивале (40 800 кеше катнашты);

студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәте (10 577 кеше);

эзләү отрядлары эшчәнлеге (63 эзләү отряды, аларда 1 080 кеше җәсәде табылган һәм күмелгән);

«Форпост» республика яшьләр хәрәкәтенең хокук саклау отрядлары 18 004 кеше катнашты);

авыл яшьләренә ярдәм итү (38 муниципаль берәмлектә «Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы бүлекләре эшли»);

эшләүче яшьләргә ярдәм итү (яшьләр иҗтимагый берләшмәләре Татарстан Республикасының 150 предприятиесе һәм оешмасы базасында эшли).

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан яңа проектлар башлап җибәрелде һәм тормышка ашырыла:

«МАРШ-архитектура воркшоп» (яшьләр учреждениеләренең архитектура концепцияләрен эшләү);

URAM урам культураларын үстерү проекты (яшьләр субкультурасының уңай юнәлешләренә ярдәм итү механизмнарын дәүләт дәрәҗәсендә эшләү һәм гамәлгә кертү);

«#Яшь министрлык» командасының «14–30» форматында Татарстан Республикасы яшьләре белән очрашуы (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хакимияте органнары җитәкчеләре катнашында яшьләр өчен актуаль темаларга мәсьәләләр, инициативалар, идеяләр һәм проблемалар турында фикер алышу буенча системалы дискуссия мәйданчыклары формалаштыру);

Deadline мәгариф платформасы (медиа өлкәсендә профессиональ кадрлар әзерләү һәм камилләштерү, яшь белгечләр белән тәҗрибә уртаклашу өчен мохит булдыру һәм чыгарылучы контентның сыйфатын яхшырту);

«Кайтам» медиапроекты (яшь ватандашлар белән эшләүдә уңай мәгълүмати юнәлеш формалаштыру);

«Таба» яшьләр этнопроектлары акселераторы (этнодаирәдәге актуаль стартапларны үстерү, аларга ярдәм итү һәм тиражлау өчен платформа булдыру; Татарстан Республикасы яшьләрендә ихтыяҗ булган этнопроектлар өчен үсеш шартларын тәэмин итү);

«Цифрлы министрлык» проекты. Система кысаларында инфраструктура объектларының торышы турында мәгълүматларны исәпкә алу һәм саклау процессын автоматлаштыру, яшьләр сәясәтенең барлык юнәлешләре буенча тулы картинаны аңлау өчен хисап һәм аналитик эш алып бару өчен сервислар эшләү гамәлгә ашырыла. 2019 елда җәйге ялны оештыру буенча халык тарафыннан хезмәт күрсәтү системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән «Ял һәм лагерьлар» сервисы прототибы файдалануга тапшырылды;

яшьләр сәясәте өлкәсендә «Корпоратив Университет» проекты («Сколково» фонды белән берлектә гамәлгә кертелгән яшьләр сәясәтен профессиональ кадрлар белән тәэмин итү системасы);

«Аналитик хаб» проекты (яшьләр сәясәте өлкәсен мәгълүмати-аналитик тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын булдыру максатларында гамәлгә ашырыла).

**Мәдәният үсеше. Креатив индустрияләр**

***«Мәдәният» илкүләм проекты***

Татарстан Республикасында «Мәдәният» илкүләм проекты максатларына ирешү өчен өч төбәк проекты булдырылган: «Мәдәни мохит», «Иҗади кешеләр» һәм «Цифрлы мәдәният». 2019 елда проектны гамәлгә ашыру өчен 74,2 млн сум бүлеп бирелгән, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан 37,6 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан 36,6 млн сум.

2019 елда «Мәдәни инфраструктураны үстерүнең яңа сыйфат дәрәҗәсенә ирешү («Мәдәни мохит»)» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында:

федераль финанслау нигезендә 3 объект төзелде: Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән авылында 200 урынга исәпләнгән күпфункцияле мәдәни үзәк, Алексеевск муниципаль районының Биләр авылында 300 урынга исәпләнгән авыл мәдәният йорты, Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авылында 200 урынга исәпләнгән күпфункцияле мәдәни үзәк ачылды;

«Т.Г. Миңнуллин исемендәге Түбән Кама дәүләт татар драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе, «Татарстан Республикасы милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең «Шәриф Камалның мемориаль фатиры белән бергә урнашкан татар әдәбияты тарихы музее» бүлеге, «А.С. Пушкин исемендәге мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе кебек төбәк мәдәният объектларын төзү, төзекләндерү һәм реконструкцияләү эшләре төгәлләнде»;

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре «Балалар сәнгать мәктәбе», «Н.М. Кудашев исемендәге Лениногорск балалар музыка мәктәбе», «Нурлат балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениеләре төзекләндерелде.

«Зеленодольск муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 12 номерлы филиалы – Белобезводнено китапханәсе һәм «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 3 номерлы филиалы – Әсән-Елга авыл китапханәсе базасында модельле ике муниципаль китапханә булдырылды;

Алабуга һәм Яңа Чишмә муниципаль районнарында муниципаль ике кинозал, Зеенодольск муниципаль районының Осиново авылында 4 шәхси кинозал җиһазландырылды;

Арча, Спас, Мамадыш, Баулы һәм Алабуга муниципаль районнарында «Алабуга муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең үзәк китапханәсе, Баулы муниципаль районының «Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе, Спас муниципаль районының Авылара үзәк китапханәсе, «Мамадыш шәһәренең композитор Яруллиннар  исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениясе, «Арча үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе базасында Арча, Спас, Мамадыш, Баулы, Алабуга районнарында булдырылган 5 виртуаль концерт залы өчен җиһазлар сатып алынды;

мәдәният өлкәсенең белем бирү оешмаларына үзебезнең илдә җитештерелгән 63 пианино, 100 «Тальян» гармуны сатып алынды.

2019 елда мәдәният оешмаларына 28 392,7 мең кеше (максатчан күрсәткеч – 27 008,72 мең кеше) килде.

2019 елда «Милләтнең иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру» («Иҗади кешеләр») төбәк проекты кысаларында:

373 белгеч өзлексез белем бирү үзәкләре базасында квалификациясен күтәрде, шул исәптән 62 кеше көндезге уку формасында, 311 кеше дистанцион рәвештә белем алды;

үзешчән 10 коллектив грантка лаек булды, алар арасында фольклор коллективлары, балалар инструменталь оркестрлары һәм ансамбльләр, халык театрлары да бар;

372 волонтер «Мәдәният волонтерлары» программасында катнаша, бу максат итеп куелган күрсәткечтән 39,8 процентка артып китә (максат күрсәткече – 266 кеше);

коммерциячел булмаган ике оешманың 5,3 млн сумлык проектлары хупланды: «Алабуга шәһәренең һөнәрчеләр мәйданы» проекты (2,4 млн сум) һәм «Татарстан республика «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фондының «Игелек планетасы» яшьләр һәм инвалид балалар төбәк иҗтимагый оешмасының ARTS BILER FORUM музыкаль, хореография, театр сәнгате төбәкара фестиваль-конкурсы» (2,9 млн сум) проекты;

2019 елның 17 июлендә «Татарстан Республикасы милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – Е.А. Баратынский музеенда

А.С. Пушкинның тууына 220 ел тулуга багышланган «Я числюсь по России...»: Петербург – Царское село – Казан» күргәзмәсе ачылды;

шагыйрь Мөхәммәд Садрига, җырчы Әлфия Авзаловага, режиссер, композитор һәм педагог Илгиз Мәҗитовка, җырчы һәм педагог Мөнирә Булатовага, Россия армиясенең А.В. Александров исемендәге җыр һәм бию ансамбле артисты Владислав Голиковка мемориаль такталар тантаналы рәвештә ачылды.

Шулай ук 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгы алдыннан Казан шәһәренең Җиңү Паркында тыл хезмәтчәннәренә һәйкәл куелды.

2019 елда «Хезмәтләрне цифрлаштыру һәм мәдәният өлкәсендә мәгълүмат киңлеген формалаштыру» («Цифрлы мәдәният») төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында:

республиканың биш муниципаль районында (Арча, Спас, Мамадыш, Баулы һәм Алабуга) 5 виртуаль концерт залы булдырылды;

250 китап-ядкәрләр цифралаштырылган;

цифрлы гид белән тәэмин ителгән бер күргәзмә проекты («Татарстан Республикасы милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең «Тарихи-мәдәни мирас» экспозициясе булган мультимедиа гиды) ачылды.

*«Креатив индустрия» флагман проекты*

2019 елда мәдәният учреждениеләре челтәрендә 3 808 учреждение исәпләнде: 39 театр-тамаша учреждениесе (23 дәүләт һәм 16 муниципаль), 1 512 китапханә (4 дәүләт, 1 508 муниципаль, шуларның 1 301е – авыл җирендәге китапханәләр), 173 музей челтәре берәмлеге (68 дәүләт, 105 муниципаль музей), 1 933 мәдәни-ял итү учреждениесе (шуларның 845 е – авыл җирлегендә), 117 мәгариф оешмасы (11 дәүләт, 104 муниципаль, 2 федераль), 14 киноучреждение (1 дәүләт, 13 муниципаль), 12 халыклар дуслыгы йортлары (1 дәүләт, 11 муниципаль), 7 дәүләт мәдәният учреждениесе, 1 зоопарк (муниципаль).

*Театр-тамаша учреждениеләре*

2019 елда республика районнары, Россия төбәкләре һәм чит илләр буенча дәүләт театр-тамаша учреждениеләренең 1 156 гастроле булды, шуларның 918 е – Татарстан Республикасы буенча; 191 е – Россия төбәкләре буенча; 47 се – чит илләрдә.

Республиканың дәүләт һәм муниципаль театрлары тарафыннан 87 премьера спектакле (шул исәптән дәүләт театрлары тарафыннан – 78) куелды, шуларның 32 се – балалар һәм яшүсмерләр аудиториясе өчен. Театрлар спектакльләрен 1 027,9 мең, шул исәптән дәүләт театрларында 958,9 мең тамашачы карады, 4 869 чара үткәрелде, шул исәптән дәүләт театрларында – 4 470 чара. Татарстан Республикасы театрлары тарафыннан 13 фестиваль үткәрелде, алар үзләре 63 фестивальдә катнашты.

Татарстан театрлары өченче ел «Кече шәһәрләр театрлары» федераль партия проектларында катнашты (8 театр, шуларның 2 се муниципаль – «Түбән Кама шәһәренең яшь тамашачы театры» һәм «Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениеләре һәм «Театрлар – балаларга» (4 дәүләт балалар театры). 2019 елда әлеге проектлар кысаларында 34 яңа спектакль куелган, финанслауның

гомуми күләме 75,7 млн сум тәшкил иткән, шул исәптән 31,8 млн сум Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, 43,9 млн сум федераль бюджет акчалары исәбеннән тотылган.

2019 елда Россиядә Театр елына багышланган чараларны гамәлгә ашыру кысаларында 607 чара (фестивальләр, дәүләт театрлары гастрольләре, белем бирү, социаль, яшьләр проектлары, Татарстан Республикасының юбилей һәм мәдәни-агарту чаралары) үткәрелде.

Дәүләт һәм муниципаль концерт оешмалары тарафыннан 417 яңа концерт программасы (шул исәптән дәүләт оешмалары тарафыннан – 224), 1 818 концерт (шул исәптән дәүләт оешмалары тарафыннан – 683) куелды, шуларның 425 е – балалар өчен; 44 абонемент концертлары куелды, оешмалар 676 хәйрия чарасында катнашты.

2019 елда Татарстан Республикасы концерт оешмалары 23 фестиваль үткәрде, 119 фестивальдә катнашты.

2019 елда Татарстан Республикасы Идел буе федераль округының «Театраль Идел буе» фестивалендә катнашты. Төбәк этабы йомгаклары буенча җиңүчеләр арасында – «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе һәм Чаллы шәһәренең «61 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең «РИФ» театр студиясе коллективы. Финал этабы йомгаклары буенча «Иң яхшы актриса» номинациясендә «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе студенты Ләйсән Гатауллина җиңде.

«Алтын битлек – 2019» илкүләм театр премиясенең музыкаль театр жюрие тарафыннан «Терек шәһәр» заманча сәнгатькә ярдәм фондының һәм Татарстан Республикасының башкару сәнгатен үстерү «Сфорцандо» фондының «Иаковның төшләре яки куркыныч урын» спектакле тарихи материалны заманча композиция һәм режиссура чаралары белән үзләштергән өчен махсус премиягә лаек дип табылды.

2019 елда иҗат берлекләре тарафыннан мәктәп театрларының «Өченче кыңгырау» фестивале, «Ирекле сәхнә» IX иҗат лабораториясе, яшь язучыларның республика семинары, «Композиторлар укулары» халыкара яшьләр семинары, «Кырымны кушуның 5 еллыгына» күргәзмәсе, Кито шәһәрендә (Эквадор), Лима шәһәрендә (Перу), Винья-дель-Мар шәһәрендә (Чили) «Татар музыкасы җәүһәрләре» концерты һ. б. уздырылды.

Мәктәп яны лагерьларында ял итүче балалар өчен «Театруля» дип аталган 13 интерактив танып-белү–күңел ачу программасы әзерләнде һәм үткәрелде.

2019 елда Казан циркы мәйданчыгында 7 программа уздырылды, 121 предприятие, 151 399 тамашачыга хезмәт күрсәтелде. Чаллы циркы тарафыннан 81 ачык чыгыш һәм күңел ачу программалары күрсәтелде.

*Китапханә эшчәнлеге*

Татарстан Республикасында һәркем файдалана ала торган 1 512 китапханә, шул исәптән 4 республика китапханәсе («Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Татарстан Республикасының «Республика яшүсмерләр китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе,

Татарстан Республикасының «Республика балалар китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе) һәм 1 508 муниципаль китапханә ( шуларның 1 301е – авыл җирендә) эшли. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль китапханәләре фондына 23,3 млн берәмлек китап саклана, шул исәптән дәүләт китапханәләре фондына – 3,9 млн данә, муниципаль китапханәләрдә – 19,4 млн данә.

2019 елда китапханәләрдә 15,5 млн кеше булды, 1,45 млн китап укучы китапханә хезмәтләреннән файдаланды, 32 миллионнан артык басма укучыларга кулга бирелде, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә 1 365 китапханә тоташтырылды.

*Музей эше*

Татарстан Республикасы музей челтәренә 173 дәүләт һәм муниципаль музей челтәре берәмлеге керә, шул исәптән – 14 дәүләт һәм 50 муниципаль музей. 2019 елда дәүләт һәм муниципаль музейларга 7,2 млн кеше килде. Республика музейларында 103 843 экскурсия, 3 702 массакүләм һәм 9 718 мәдәни-белем бирү чарасы, 2 567 күргәзмә узды.

Татарстан Республикасы дәүләт музейлары һәм музей-тыюлыклары тарафыннан Россия Федерациясенең башка төбәкләре музейлары белән берлектә 67 күргәзмә проекты оештырылды.

Музейара хезмәттәшлек кысаларында республикада әйдәп баручы Россия музейлары күргәзмәләре оештырылды: «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында (8 күргәзмә), Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында (15 күргәзмә), Татарстан Республикасы милли музеенда (1 күргәзмә), сынлы сәнгать дәүләт музеенда (11 күргәзмә), Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында (3 күргәзмә).

16 музейның (12 дәүләт һәм 4 муниципаль) рәсми сайты бар, социаль челтәрләрдә 39 музей (14 дәүләт һәм 25 муниципаль) теркәлгән.

Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогында 2 309 Россия музее, шул исәптән Татарстан Республикасының 75 музее тәкъдим ителгән.

Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогына 309 760 саклау берәмлеге (дәүләт музейларыннан – 232 605, муниципаль музейлардан 77 155 берәмлек), комплекслы автоматлаштырылган музей мәгълүмат системасының махсус системасына 1,1 млн предмет кертелгән. «Татарстан Республикасы музейлары» электрон каталогында 62 музей һәм музей берләшмәсе тәкъдим ителгән, алар әлеге ресурста 202 061 саклау берәмлеген, шул исәптән 188 028 төп фонд предметын, 14 033 фәнни-ярдәмче фонд предметын урнаштырган.

Музей эшчәнлеге өлкәсендә 2019 елгы казанышлар:

«Зөя утрау-шәһәрчеге» музей-тыюлыгы территориясендә урнашкан «Татар бистәсе» агач археология музее ICOM Халыкара музейлар берлегенең аудиовизуаль, яңа технологияләр һәм социаль медиа (AVICOM) халыкара комитетының профессиональ бүләген алды;

Татарстаннан 7 проект Вакыйгалы туризм өлкәсендә Russian Event Awards – 2019 илкүләм премиясенең җиңүчеләре булды. Алабуга дәүләт тарих-архитектура

һәм сәнгать музей-тыюлыгының «Спас ярминкәсе» «Халык традицияләрен һәм кәсепләрен популярлаштыру буенча иң яхшы туристик вакыйга» номинациясендә Гран-прига лаек булды;

«Татарстан Республикасы милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең «Шәриф Камал мемориаль фатиры белән бергә урнашкан татар әдәбияты тарихы музее»н ачу тантанасы»;

2019 елның 14 июнендә Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында яңартылган Декоратив-гамәли сәнгать музей-остаханәсе ачылды;

2019 елның 28 августында Башкортстан Республикасының Бишбүләк районы Ает авылында Фатих Кәрим музее ачылды. Яңа экспозиция Татарстан Республикасы милли музееның иҗат төркеме тарафыннан эшләнгән концепция һәм дизайн-проект нигезендә төзелгән, анда шагыйрьнең төп мемориаль коллекциясе саклана;

2019 елның 30 ноябрендә Актаныш муниципаль районының Актаныш авылында «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе бинасында Әлфия Авзалова музее ачылды.

*Мәдәни-күңел ачу учреждениеләре*

Татарстан Республикасында 1 933 мәдәни-ял итү тибындагы учреждение исәпләнә, аларда 16 015 клуб оешмасы эшли, шул исәптән 13 879ы – авыл җирлегендә (86,7 процент).

Мәдәни-ял итү учреждениеләре бурычларының берсе – инвалидлар ялын оештыруда методик һәм оештыру ярдәме күрсәтү. Сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән гражданнарны мәдәни-массакүләм чараларда катнашуга җәлеп итү максатыннан, мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрдә 19 254 кеше катнашында 1 581 инклюзив клуб оешмасы эшли. Инвалидлар катнашында 57,4 мең чара үткәрелде. Бу – концертлар һәм әдәби программалар, күргәзмәләр, аралашу кичәләре, хәйрия акцияләре һәм мәдәни-массакүләм эшчәнлекнең башка формалары.

*Мәдәният өлкәсендә белем бирү*

Хәзерге вакытта республикада мәдәният һәм сәнгать өлкәсе өчен кадрлар әзерли торган 105 өстәмә белем бирү, 9 һөнәри белем бирү, 2 югары белем бирү оешмасы эшли. 2019 елда мәдәният өлкәсе мәгариф оешмаларында 43 172 кеше белем алды, шулардан 38 552 кеше өстәмә белем бирү оешмаларында, шул исәптән 420 кеше «Бәхетле балачак» балалар үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә укыды; 2 212 кеше һөнәри белем бирү оешмаларында (көллиятләрдә); 2 408 кеше югары уку йортларында белем алды.

2019 елда 7 кеше «Россиянең яшь талантлары» бөтенроссия конкурсында җиңүче булды.

*Кинематография*

2019 елда Татарстан Республикасы кино челтәрен 148 кинозал, шул исәптән 1 дәүләт кинотеатры («Мир» кинотеатры), Татарстан Республикасы «Татаркино» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең 3 кинозалы (алга таба – «Татаркино» ТР ДБМУ ), 7 муниципаль кинотеатрдагы 9 кинозал, 23 шәхси кинотеатрдагы 106

кинозал, муниципаль мәдәни-ял итү учреждениеләре составындагы 36 кинозал тәшкил итте. Шулай ук халыкка даими рәвештә кино һәм видео күрсәтүче 25 күчмә кинозал бар.

2019 елда республиканың киноучреждениеләрендә 15 мең картина, шул исәптән балалар өчен – 8,5 мең картина күрсәтелде, 284 мең тамашачы, шуларның 190 меңе – балалар, кино карады, 10 млн сум акча җыелды.

2019 елда төрле жанрдагы 11 фильм төшерелде: 6 – документаль фильм, 4 уен, 1 анимация фильмы.

Мөһим вакыйгалар:

Казанда «Алтын тәлинкә» төбәкара кинопремиясе гамәлгә куелды;

«Кино вакыты» VII бөтенроссия мәгърифәти форумы кысаларында тулы метражлы уен фильмы төшерү өчен приз фонды 2,5 млн сум булган Кинопроектлар питчингы узды. «Мин килермен» дигән фильм сценарие өчен А. Шутов җиңүче дип танылды;

KazanSummit кысаларында Казан халыкара мөселман киносы фестивале узды, халыкара Кинопроектлар питчингы уздырылды. Нәтиҗәдә Үзбәкстан Республикасы һәм Казахстан Республикасы белән уртак фильмнар төшерү турында килешүгә ирешелде;

«Кино 7 көндә» XI халыкара проекты гамәлгә куелды, аңа дөньяның 31 иленнән 100дән артык кинопроект килде. Проект нәтиҗәсендә 10 фильмнан торган киноальманах дөньяга килде, ул халыкара фестивальләрдә, кинофорумнарда һәм социаль челтәрләр аша күрсәтеләчәк;

Татарстан кинорежиссеры Алексей Барыкинның «Су Анасы» балалар өчен уен фильмы Россиянең 54 шәһәренең 260 кинотеатрында, Казахстан Республикасында, Вьетнам Социалистик Республикасында, Кытай Халык Республикасында, барлык электрон мәйданчыкларда һәм онлайн-кинотеатрларда: iTunes, Google Play, Ivi, Okko, Tvzavr, МТС, Билайн һәм Мегафон прокатка чыкты.

*Мәдәният өлкәсендә грант ярдәме*

2019 елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан мәдәният өлкәсендә грантлар һәм акчалата бүләкләр бирү буенча түбәндәге конкурслар үткәрелде:

иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (6 җиңүче, гомуми суммасы 4 млн сум);

муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (65 җиңүче, гомуми суммасы 11,5 млн сум);

халык сәнгать һөнәрчелеге өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (17 җиңүче, гомуми суммасы 4,97 млн сум);

мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (53 җиңүче, гомуми суммасы 3 млн сум);

мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты гранты (Татарстан Республикасының 8 әйдәп баручы иҗат коллективы, 339,4 млн сум);

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан муниципаль мәдәният учреждениеләренең иң яхшыларына һәм аларның хезмәткәрләренә (63 җиңүче-хезмәткәр, гомуми суммасы 3,2 млн сум һәм 85 җиңүче-учреждение, гомуми суммасы 8,5 млн сум) акчалата бүләк;

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (91 җиңүче, гомуми суммасы 15 млн сум).

*Вакыйгалар туризмы*

2019 елның 1 апреленнән 7 апреленә кадәр «Татарстанда музейлар язы – 2019» республика музейара акциясе узды, анда 14 дәүләт һәм 48 муниципаль музей катнашты.

2019 елның 18 маенда узган «Музейлар төне» бөтенроссия акциясендә 13 дәүләт һәм 45 муниципаль музей катнашты.

2019 елның 21 – 22 июнендә 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы башлану һәм Брест крепостен саклау вакыйгалары истәлегенә «Әлбәдән» хәрби уены» вакыйгалар фестивале уздырылды.

Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгы MITT-2019 халыкара туристлык күргәзмәсендә (12 – 14 март, Мәскәү шәһәре), шулай ук «Туристлык һәм спорт» халыкара махсуслаштырылган күргәзмәсендә (11 – 13 апрель, Казан шәһәре) катнашты.

2019 елның 17 апрелендә Мәскәү шәһәрендә Россия мәдәният фондының «Даһилык. Туган якны яңача өйрәнү» музей проектлары конкурсында «Казан Кремле музей-тыюлыгы» «Вакыйга» номинациясендә җиңү яулады.

*Халыкара һәм төбәкара мәдәни хезмәттәшлек*

2019 елда Татарстанның иң яхшы театр, хореография, вокал коллективлары 16 илгә (Австралия, Канада, Кытай Халык Республикасы, Япония, Һиндстан Республикасы, Нидерландия Корольлеге, Бельгия Корольлеге, Австрия Республикасы, Швейцария Конфедерациясе, Германия Федератив Республикасы, Чехия Республикасы, Франция Республикасы, Румыния, Финляндия Республикасы, Казахстан Республикасы, Үзбәкстан Республикасы) гастрольләр һәм концертлар белән бардылар.

Татар халкының традицияләрен, гореф-гадәтләрен һәм телен саклап калу һәм татар милли мәдәниятен пропагандалау максатыннан чыгып, Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәрен үткәрү эше алып барыла. 2019 елда Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре Башкортостан Республикасында, Үзбәкстан Республикасында, Кытай Халык Республикасының Хэйлунцзян провинциясендә уздырылды.

Ватандашларыбызны җәлеп итеп «Түгәрәк уен» бөтенроссия татар фольклоры фестивале, «Идел-йорт» төбәкара театр коллективлары фестивале, Р.Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале, «Татар халкының этнографик

мозаикасы» фотоконкурсы, «Сөйкемле Шүрәле» бөтенроссия иҗади эшләр бәйгесе һ. б. чаралар дәвам иттерелә.

2019 елда 361 «Сабантуй» бәйрәме, шул исәптән 282се – Россия Федерациясенең 57 төбәгендә, 79ы – якын һәм ерак чит илләрнең 28ендә үткәрелде.

Самара өлкәсенең Камышлы авылында XIX Федераль Сабан туе (15 меңгә якын кеше катнашты) һәм X Бөтенроссия авыл Сабан туе (30 меңнән артык кеше катнашты) оештыру дәрәҗәсенең югары булуы белән истә калды.

**Граждан җәмгыяте үсеше**

Татарстанда граждан җәмгыяте институтлары белән актив хезмәттәшлек алып барыла. Идел буе федераль округында теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар саны ягыннан Татарстан Республикасы алдынгы урыннарның берсен алып тора. 2020 елның 1 гыйнварына республикада 5 847 коммерциячел булмаган оешма, шул исәптән 1 754 иҗтимагый оешма, 1 987 дини берләшмә, 2 062 коммерциячел булмаган башка оешмалар, шулай ук сәяси партияләрнең 44 төбәк бүлекчәсе теркәлгән.

Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасының 2014 – 2020 елларга икътисадый үсеше һәм инновация икътисады» дәүләт программасының 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм буенча ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлдә. Аның максаты – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешендә катнашуга социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга этәргеч бирү, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм милләтләр арасындагы татулыкны саклау, социаль сәясәтнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрнең балансланган булуы нигезендә иҗтимагый иминлеккә ирешү. Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3,3 млрд сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 2,7 млрд сум, федераль бюджет акчалары исәбеннән – 42,2 млн сум, җирле бюджетлардан – 10,2 млн сум һәм бюджеттан тыш чыганаклардан – 587,8 млн сум. 2019 елда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме, бюджеттан тыш чыганаклардан тыш, 315,4 млн сум тәшкил итте (2018 елга карата 8,8 процентка үсеш).

Шулай ук барлык муниципаль берәмлекләрдә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итүгә юнәлтелгән программалар кабул ителде һәм гамәлгә ашырыла.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга төрлечә ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасында 2000 еллардан алып барыла. Дәүләт һәм муниципаль дәрәҗәдә дәүләт ярдәме алган коммерциячел булмаган оешмалар саны арта бара. Грант ярдәме, максатчан финанслау, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан тормышка ашырылучы социаль әһәмиятле проектларга конкурс нигезендә субсидияләр бирүгә кагылышлы норматив хокукый актлар кабул ителде.

Татарстан Республикасы иҗтимагый хәрәкәте үзәгендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тора. Аның эшендә 60 палата әгъзасы һәм

эксперт берлегенең 150 вәкиле катнаша. Иҗтимагый үсешнең актуаль мәсьәләләре буенча 8 комиссия төзелде. Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары каршында 32 иҗтимагый совет, муниципаль берәмлекләрдә 44 иҗтимагый совет эшли.

2012 елдан башлап Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстанда ярдәмнән файдаланган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар республика реестры алып барыла. Аны тутыру өчен социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итүче башкарма хакимият органнары төрле формада мәгълүмат бирә. Моннан тыш, республиканың муниципаль берәмлекләрендә шундый ук реестрлар алып барыла. 2020 елның 1 гыйнварына Республика реестрында муниципаль һәм республика дәрәҗәсендә ярдәм алучы 789 оешма турында мәгълүмат теркәлде, аларга 2012 – 2019 еллар дәвамында 9,3 млрд сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелгән. Реестр мәгълүматларына караганда, 2019 елда социаль юнәлешле 359 коммерциячел булмаган оешмага барлыгы 1,6 млрд сумлык ярдәм күрсәтелгән.

Реестр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга инфраструктура ягыннан ярдәм итү кысаларында 2017 елдан Татарстан Республикасында коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәкләре эшли, алар Ярдәмче программа акчалары ярдәмендә укыту, консалтинг һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүне тормышка ашыралар. 2019 елда муниципальара үзәкләр Казан, Әлмәт шәһәрләрендә эшләде, 2020 елда мондый үзәкләр Чаллы, Буа, Чистай һәм Кукмара шәһәрләрендә ачылачак.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы башлангычында 2019 елда «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы төзелде, аны республиканың әйдәүче социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалары («Дөнья чишмәләре» хәйрия фонды, «Ретт синдромлы авыруларга ярдәм итү ассоциациясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы, «Тиктормас» мәгариф үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы) гамәлгә куйды.

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган оешмаларга ярдәм итү, муниципальара ресурс үзәге хезмәткәрләренең компетентлылык дәрәҗәсен арттыру өчен Казан шәһәренең муниципальара ресурс үзәге «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә һөнәри яктан яңадан әзерләү буенча белем бирү программасы һәм «Социаль проектлау һәм социаль проектлар белән идарә итү» курсы буенча методик рекомендацияләр эшләнде (260 сәгать; 2,5 ай). Ул «юл картасы» эшләүгә һәм коммерциячел булмаган оешмаларны социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертү өчен документлар пакетын әзерләүгә, шул исәптән халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бирелә торган бюджет акчаларын алуны тәэмин итүгә дә юнәлтелә. «Юл картасы»на социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына керү өчен кирәкле документлар пакетын әзерләү, социаль хезмәтләр күрсәтү, бюджеттан компенсация алу, хисап бирү, электрон мохиттә эшләү һәм бюджеттан

тыш өстәмә акчалар куллану механизмнары кирә. Әлеге Программа нигезендә 2017 – 2019 елларда социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның 53 вәкиле белем алды. Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән 22 дәүләт (муниципаль булмаган) оешмасыннан 11 оешма вәкилләре әлеге программа нигезендә укытылды.

СЮКБО вәкилләренең һәм социаль проектларны гамәлгә ашыручы һәм СЮКБО рәсмиләштерергә планлаштыручы гражданнарның белемнәрен арттыру өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесе белән берлектә даими рәвештә белем бирү чаралары уздырыла. 2019 елда гына да 22 муниципаль районда «Коммерциячел булмаган оешмалар көне», «Коммерциячел булмаган оешмаларны ничек төзергә», «Коммерциячел булмаган оешмаларның грант отчеты» семинарлары, «Татарстан Республикасы грантлары» мәгълүмати-белем бирү курслары кебек белем бирү интенсивлары һәм башка чаралар узды.

Гражданлык инициативаларын хуплау һәм республикада граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы гамәлгә ашырыла.

2019 елда Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен дәгъвалауга үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча (гомуми приз фонды – 2,75 млн сум) премияләр түбәндәгеләргә бирелде: Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы генераль директоры Г.Р. Руденкога; Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе А.А. Фоминга; «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар ассамблеясы» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасары, Казан шәһәренең «Сиони» грузин милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе М.М. Хухнашвилига, ««Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасына, «ДЦП авырулы балалар» хәйриячелек фондына, «Татарстан Республикасы удмурт милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасына, Татарстан Республикасының «Гаилә канаты астында» төбәк иҗтимагый оешмасына; Татарстан Республикасының «Без бергә!» тәрбиягә бала алган гаиләләрнең төбәк иҗтимагый оешмасына (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 11 октябрендәге ПУ-615 номерлы Указы).

Социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы СЮКБОларның Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасарының 2016 елның 23 маендагы 3468п – П44 номерлы йөкләмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 28 июлендәге 524 номерлы карары белән расланган 2016–2020 елларга халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү өчен бүлеп бирелә торган бюджет чараларыннан этаплап файдалана алуын тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар комплексын үтәүне оештыру максатларында Татарстанда социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы СЮКБОларның халыкка социаль хезмәт күрсәтү өчен бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан

файдалана алуын оештыру буенча Координация советы (алга таба – Координация советы) төзелде.

Социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы СЮКБОларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү өчен бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан этаплап файдалана алуын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының комплекслы чаралар планы нигезендә социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган оешмаларның, шул исәптән СЮБКО эшчәнлегенә ярдәм итүнең төрле рәвешләрен куллану, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүгә, социаль өлкәдә хезмәт күрсәтүче дәүләтнеке булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү механизмнарын эшләү буенча даими нигездә системалы эш алып барыла.

Татарстан Республикасының комплекслы чаралар планын гамәлгә ашыру максатларында «юл картасы» эшләнде, анда дәүләтнеке булмаган оешмаларга ярдәм итүнең төп бурычлары, этаплары, механизмнары, гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү эшчәнлегенә дәүләтнеке булмаган оешмаларны җәлеп итү чаралары билгеләнгән.

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль хезмәт күрсәтү системасына дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмалары белән берлектә, алар социаль хезмәт күрсәтүчеләр таләпләренә туры килгән очракта социаль хезмәт күрсәтү хокукына ия булган дәүләтнеке булмаган (коммерциячел һәм коммерциячел булмаган) оешмалар да кертелгән.

2019 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының тиешле өлкәдә хезмәт күрсәтүләргә бүлеп бирелә торган акчаларның гомуми күләмендә СЮКБОларга социаль хезмәт күрсәтүләр өчен бүлеп бирелүче өлеше түбәндәгеләрне тәшкил итте:

социаль хезмәт күрсәтү һәм социаль ярдәм – 4,6 процент;

балаларга өстәмә белем бирү – 8 процент;

гражданнарның сәламәтлеген саклау – 1,7 процент;

мәдәният – 10 процент;

физик культура һәм массакүләм спорт – 3,2 процент.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрын һәм социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар регистрын формалаштыру һәм алып бару турында» 2014 елның 23 декабрендәге 1012 номерлы карары белән социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестры (алга таба – Реестр) формалаштырылды, ул Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылды.

Реестрга кертелү ирекле нигездә гамәлгә ашырыла һәм оешмаларга хезмәт күрсәтүләрнең хосусый программасы кысаларында гражданнарга күрсәтелә торган социаль хезмәтләр өчен, хезмәт күрсәтүче тарафыннан документаль расланган очракта, компенсация алырга мөмкинлек бирә.

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрында 24 дәүләтнеке булмаган оешма (2018 елда – 19 оешма, 2017 елда – 13 оешма, 2016 елда – 8 оешма, 2015 елда – 3 оешма) кертелде, шул исәптән:

16 дәүләтнеке булмаган оешма (шул исәптән 12 СЮКБО), алар өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтә;

8 дәүләтнеке булмаган оешма (шул исәптән 6 СЮКБО) мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләргә тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтә.

СЮКБОларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында коммерциячел булмаган оешмалар йорты эшләп килә (Казан шәһәре, 8 Март ур., 18 йорт). Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан СЮКБОларга түләүсез нигездә мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча республика конкурсы үткәрелә. Конкурста СЮКБОларга ике елга түләүсез нигездә эш урыннары бирү уйнатыла. Күрсәтелгән эш урыннары тулысынча мебель, компьютер һәм башка оештыру техникасы белән җиһазландырылган.

Гражданнарны граждан җәмгыяте үсешендә катнашуга җәлеп итү эше коммерциячел булмаган оешмаларның Татарстан Республикасы ведомство һәм муниципаль иҗтимагый советларындагы, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарындагы вәкиллеге аша алып барыла.

Территориаль иҗтимагый үзидарә, гражданнарны территориядәге проблемаларны чишүгә җәлеп итү ресурсы буларак, Татарстан Республикасының күп кенә муниципаль районнарында актив кулланыла.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы муниципаль берәмлекләр территорияләрендә СЮКБОларга ярдәм итү чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтү максатларында СЮКБО белән хезмәттәшлекне көчәйтү, шулай ук СЮКБО эшчәнлегенең нәтиҗәле технологияләрен һәм методларын куллану буенча методик тәкъдимнәр әзерләде.

Республикада СЮКБО эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү мәсьәләсенә зур роль бирелә, ул социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруны республика массакүләм мәгълүмат чараларында (алга таба – массакүләм мәгълүмат чараларында) киң яктыртудан тора. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Татмедиа), шулай ук СЮКБОларга ярдәм итү буенча ресурс үзәкләре тарафыннан СЮКБОлар эшчәнлеген пропагандалау һәм популярлаштыру буенча зур эш алып барыла.

Татмедиа тарафыннан СЮКБОлар эшчәнлеген, хәйриячелек, ирекleләр хәрәкәтен һәм социаль эшкуарлыкны мәгълүмати тәэмин итү буенча республика чаралар планы эшләнде. Татмедиа коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан социаль-гуманитар проектларны гамәлгә ашыруны мәгълүмати тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасында ирекleләр хәрәкәтен һәм хәйриячелек идеяләрен формалаштыру буенча даими эш алып барыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырткан иң яхшы массакүләм мәгълүмат чаралары билгеләү буенча конкурс үткәрү турында» 2016 елның 2 декабрендәге 885 номерлы карары нигезендә

республикада СЮКБО эшчәнлеген яктыртуга игътибарны җәлеп итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы ярдәме белән 2016 елдан СЮКБО эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрелә. Конкурста ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, авторлар коллективлары һәм төркемнәре, шулай ук башка юридик затлар, шул исәптән СЮКБОлар да катнаша ала. Конкурсның максаты – Татарстан Республикасы СЮКБО эшчәнлегенә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү. 2019 елда конкурста 12 массакүләм мәгълүмат чаралары авторы җиңүче булды. Конкурсның гомуми приз фонды – 400 мең сум, беренче урыннар саны – 4, икенче урыннар саны – 4, өченче урыннар саны – 4.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциячел булмаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 елның 8 июнендәге 373 номерлы карары нигезендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы коммерциячел булмаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы үткәрелде. Республика конкурс комиссиясе карары буенча 2019 елда конкурста 79 СЮКБО җиңүче булды, аларның проектларын тормышка ашыру өчен 19,9 млн сум бүлеп бирелде.

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының актуаль социаль әһәмияткә ия мәсьәләләрен хәл итү максатларында 2019 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 20 маендагы 1070-б номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциячел булмаган оешмаларның социаль әһәмияткә ия проектларын гамәлгә ашыруга 35 млн сум бүлеп бирелгән. Татарстан Республикасы бюджетыннан социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы билгеләнде. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 8 августындагы 565 номерлы карары нигезендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча конкурс үткәрелде. Конкурс нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының 36 муниципаль берәмлегеннән 130 коммерциячел булмаган оешма җиңүче дип танылды.

Моннан тыш, ел саен республиканың коммерциячел булмаган оешмалары Россия Федерациясе Президенты грантларын алу буенча конкурсларда катнаша. 2017 елдан башлап конкурслар үткәрү һәм Россия Федерациясе Президенты грантларын бирү эше Президент грантлары фондына – граждан җәмгыятен үстерү буенча президент грантлары операторына йөкләнде.

2019 елда Президент грантлары фонды конкурсында Татарстан Республикасының 85 коммерциячел булмаган проекты җиңүче булды, грантларның гомуми суммасы 155 млн сум тәшкил итте.

Татар телен саклап калу, Россия Федерациясендә татар милли мәдәниятен үстерү һәм популярлаштыру, гражданнар инициативаларына ярдәм итү максатыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм итүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү буенча конкурс үткәрелә. 2019 елда әлеге конкурс нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе субъектларыннан 23 коммерциячел булмаган оешма җиңүче дип танылды, субсидиянең гомуми суммасы 10 млн сум тәшкил итте.

2019 елда шулай ук 5 СЮКБО Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау, үстерү һәм популярлаштыру буенча иҗтимагый һәм шәхси инициативаларга ярдәм итүгә 1 млн сум, 5 СЮКБО галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклап калу һәм үстерү буенча башлангычларына ярдәм итү грантларын алды, гомуми суммасы 500 мең сум.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлтелгән иҗтимагый әһәмияткә ия (социаль) проектларны тормышка ашыру белән бәйле финанс чыгымнарны тәэмин итүгә конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бүлеп бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 27 февралендәге 122 номерлы карары нигезендә республикада экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендәге СЮКБОларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүгә конкурс уздырылды. Конкурс комиссиясе карары белән 2019 елда 6 СЮБКО җиңүче дип табылды, проектларны гамәлгә ашыруга 11,5 млн сум акча бүлеп бирелде.

Коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү максатында республикада махсус портал булдырылды, анда коммерциячел булмаган оешмалар интернетта бушлай үз сәхифәләрен булдыра ала (http://www.nkort.ru/), ул СЮКБОларның Порталда коммерциячел булмаган оешмалар өчен кирәкле барлык мәгълүмат: норматив хокукый база, республика һәм федераль конкурслар, социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре һ. б. урнаштырыла.

Ресурс үзәге форматында 2019 елда республикада «Татарстан – мөмкинлекләр территориясе» платформасы булдырылды, аның төп максаты – яшьләргә гамәлдәге Федераль грантлар турында мәгълүмат бирү, гаризаларны һәм проектларны дөрес әзерләү.

2019 елның 7 декабрендә «Казан» халыкара ат-спорт комплексында «Социаль ярминкә» I Республика хәйрия фестивале узды. Социаль ярминкә – җәмәгатьчелек башлангычы белән оештырылган инновацион практика, ул халык өчен социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыруда СЮКБО һәм бизнесның нәтиҗәле хезмәттәшлеген үстерүгә юнәлдерелгән.

Фестивальне оештыручылар булып Татарстан Республикасы Хөкүмәте булышлыгы белән Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, «Наше дело» региональ иҗтимагый хәрәкәте, «СЮКБОларга ярдәм итү буенча Республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма тора.

Эшкуарларның белемнәрен арттыру, коммерциячел булмаган оешмаларның потенциаль заказчылары һәм бизнес-партнерлары өчен тәкъдимнәр һәм тәкъдим итү

материаллары әзерләү максатыннан «Коммерциячел булмаган оешманың эшлекле активлыгын арттыру механизмнары» программасы буенча укулар узды.

Фестивальне үткәрү алдыннан зона этаплары уздырылды – Чаллы, Әлмәт, Кама аръягы, Кама алды, Идел алды зоналарында, Казан агломерациясендә, аларда 3 муниципальара ресурс үзәге җаваплы башкаручылар, ә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы координация үзәге булды.

Гомумән алганда, Татарстан Республикасы бюджетыннан фестивальнең зона этапларын, СЮКБО өчен укыту семинарларын һәм «Социаль ярминкә» I Республика хәйрия фестивален уздыруга 2019 елда 5 790 мең сум акча бүлеп бирелгән.

Фестивальгә онлайн-теркәлү ачылды, анда 677 кеше – СЮКБО, республиканың 37 районы һәм шәһәренең ведомство һәм муниципаль иҗтимагый советлары вәкилләре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары, экспертлар, кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе әгъзалары катнашты.

## ТИРӘЛЕК, РЕАЛЬ КАПИТАЛ

### Транспорт-логистика инфраструктурасы

***«Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» милли проекты***

Проектның төп максаты – нормага туры килүче автомобиль юллары өлешен арттыру һәм юл-транспорт һәлакәтләре (алга таба – юл-транспорт һәлакәтләре) күп булган урыннар санын киметү. Татарстан Республикасында проект составына өч шәһәр агломерациясе – Казан, Чаллы һәм Түбән Кама агломерацияләре, шулай ук төбәк автомобиль юллары челтәре кергән.

2019 елда финанслауның гомуми күләме 6,1 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән:

төбәк юллар челтәренә – 1,2 млрд сум, шулардан 0,6 млрд сум федераль бюджет акчалары хисабына;

Казан агломерациясе – 3 млрд сум, шулардан 2 млрд сум федераль бюджет акчалары хисабына;

Чаллы агломерациясе – 1,4 млрд сум, шулардан 0,7 млрд сум федераль бюджет акчалары хисабына;

Түбән Кама агломерациясе – 0,5 млрд сум, шулардан 0,4 млрд сум федераль бюджет акчалары хисабына.

Милли проект кысаларында түбәндәге эшләр башкарылды:

205,8 км юлларны төзекләндерү (шул исәптән 97,5 км шәһәр юл-урам челтәрләрен һәм 108,3 км төбәк юлларын төзекләндерү);

юл-транспорт һәлакәтләре булган 235 һәлакәт куркынычы урыннарын да юл хәрәкәте иминлеген арттыру чаралары (юл-транспорт һәлакәтләре күп булган 113 урын, юл-транспорт һәлакәтләре күп булырга мөмкин булган 58 урын, юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар булган 64 урын) юл хәрәкәте иминлеген арттыру чаралары.

2019 елда Казан шәһәрендә (Казан агломерациясе) 47,3 км юл-урам челтәре төзекләндерелде, бу нормага туры килгән юлларның 83,3%. 21 светофор, юлларда 77 ясалма тигезсезлек, 46,9 км җәяүлеләр йөри торган юлларга коймалар һәм 542 юл билгесе урнаштырылган.

Моннан тыш, «Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» милли проекты кысаларында Казан шәһәрендә «Зур Казан боҗрасы. Мидхәт Булатов урамыннан Техник урамына кадәр (1 этап – Мидхәт Булатов урамыннан Борисковская урамына кадәр)» объекты төзелеше башланды, аның гомуми бәясе 2,3 млрд сум тәшкил итә. 2020 елда файдалануга тапшыру планлаштырыла.

Чаллы агломерациясендә 40,9 км юл-урам челтәре төзекләндерелде, бу юлларның нормага туры килгән өлешен 78,7% ка җиткерергә мөмкинлек бирде.

Түбән Кама агломерациясендә Түбән Кама шәһәренең 9,3 км юл-урам челтәре төзекләндерелде , бу юлларның нормага туры килгән өлешен 67,2% ка җиткерергә мөмкинлек бирде.

***Һава транспорты предприятиеләре эшчәнлеге***

Татарстан Республикасының һава транспортын биш авиакомпания тәшкил итә: Татарстан Республикасы аэропортларыннан төбәкләргә авиаочышлар ясый

торган «ЮВТ АЭРО» акционер җәмгыяте, «Тулпар Эйр» авиакомпаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Тулпар Экспресс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Казан авиапредприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Авиасервис» авиакомпанияләре, алар «Бизнес авиация» сегментында эшчәнлек алып бара.

Татарстан Республикасында формалаштырылган өч агломерациянең (Казан, Кама, Әлмәт) һәркайсы үзенең аэропорт комплексы бар.

2019 елда Татарстан Республикасы аэропортларына 4 301,8 мең кешегә хезмәт күрсәтелгән (очып килү һәм очып китү), бу 2018 ел белән чагыштырганда 8,6 процентка күбрәк (3 961,9 мең кеше).

Тармакның үсешенә этәргеч бирүче тагын бер өстәмә фактор – республиканың төбәкләр дәрәҗәсендә очышларга субсидияләр бирү федераль программаларын гамәлгә ашыруда катнашуы. 2019 елда Татарстан Республикасы Россия Федерациясе территориясендә (Казаннан Барнаул, Калининград, Махачкала, Түбән Новгород, Нижневартовск, Яңа Уренгой, Омск, Пермь, Самара, Сургут, Чиләбе, Ярославль, Әстерхан, Волгоград, Оренбург, Калуга шәһәрләренә; Түбән Камадан Ростов-на-Дону, Краснодар, Екатеринбург һәм Минеральные Воды шәһәрләренә; Бөгелмә шәһәреннән Түбән Новгород, Яңа Уренгой, Яңа Уренгой шәһәрләреннән; Түбән Кама шәһәреннән, Ростов-на-Дону, Краснодар, Екатеринбург һәм Минераль Сулардан; Бөгелмә шәһәреннән Нижневартовск, Яңа Уренгой, Ноябрьск, Сургут һәм Усинск шәһәрләренә).

Махсус тарифлар буенча регуляр рейслар төбәк очышларыннан халыкның файдалану мөмкинлеген арттырды, Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм Россиянең башка төбәкләре арасында багланышларны киңәйтергә, үсеш һәм аралашу өчен яңа юллар ачарга мөмкинлек бирде.

*Халыкара авиаочышлар*

2019 елда «Казан» халыкара аэропорты» акционер җәмгыятенең маршрут челтәре 85 юнәлешне үз эченә алды, шулардан 45 халыкара (Астана, Ашхабад, Баку, Бишкәк, Дүшәнбе, Ереван, Минск, Ош, Сәмәрканд, Ташкент, Фирганә, Худжанд, Анталья, Барселона, Бангкок, Батуми, Бодрум, Будапешт, Бургас, Гоа, Даламан, Дубай, Джидда, Ираклион, Камрань, Караби, Ларнак, Ла Роман, Монастир, Прага, Пхукет, Рига, Чана, Салоники, Стамбул, Тбилиси, Тәһран, Франкфурт, Харбин, Хельсинки, Шарджа, Джерба, Әл Мактаум, Энфида).

Халыкара рейслар арасында иң күп пассажирлар саны Анталья шәһәренә рейсларда булды – 588 742 пассажир (2018 ел белән чагыштырганда 129,5 процент). Башка халыкара юнәлешләр буенча да уңай динамика күзәтелә – Даламан (107,3 процент), Камран (110,6 процент), Бургас (121,4 процент), Стамбул (129,9 процент), Прага (132,2 процент) һәм Джерба утравына (111,7 процент).

***Тимер юл транспорты эшчәнлеге***

Татарстан Республикасының тимер юл пассажир транспорты дигәндә, «Содружество» ачык акционер җәмгыяте шәһәр яны компаниясе эшчәнлеген күз алдында тотабыз.

2019 елда тимер юл транспорты өлкәсенә төбәк әһәмиятендәге тарифларны дәүләт җайга салу һәм гражданнарны ташламаларга ия категорияләрен йөртү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы бюджетыннан 348,4 млн сум бүлеп бирелгән.

2019 елгы эш йомгаклары буенча шәһәр яны тимер юл транспортында 6,65 млн пассажирга хезмәт күрсәтелгән, бу 2018 ел белән чагыштырганда 103,4 процент тәшкил итә (6,43 млн пассажир), шул исәптән 305,6 мең ташламага хокукы булган гражданнар, 647,5 мең студент һәм мәктәп укучысы.

2019 елда пассажирларга уңайлы булсын өчен аэропортка бару һәм кайту өчен өстәмә төнге поезд кертелде. Арча-Васильево һәм Васильево-Бирюли поездлары маршруты Паратск станциясенә кадәр озайтылды.

2019 елның 1 августында Свияжск утрау-шәһәренә кадәр интермодаль туристик маршрут ачылды: «Казан-1» тимер юл вокзалыннан Свияжск станциясенә кадәр шәһәр яны электр поездлары, аннары автобуста Свияжск утрау-шәһәренә кадәр.

Татарстан Республикасы буенча тимер юл транспортында 15,6 млн тонна йөк ташылган (2018 ел белән чагыштырганда 98 процент).

***Эчке су транспорты предприятиеләре эшчәнлеге***

Республика территориясендә шәһәр яны су транспортында пассажирлар йөртү эше белән 2019 елда «Татфлот» суднолар компаниясе» АҖ һәм «Чаллы» мәгъдән булмаган материаллар производство берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте шөгыльләнде.

2019 ел йомгаклары буенча шәһәр яны су транспортында 289 мең пассажирга хезмәт күрсәтелгән, шул исәптән 58,6 мең кеше – пассажирларның ташламага хокуклы категориясенә керә.

Татарстан Республикасы бюджетыннан ел саен җайга салына торган тарифлар куллану һәм гражданнарның аерым категорияләренә ташламалар бирү белән бәйле алынмый калган керемнәрне каплау, шулай ук җирле әһәмияттәге суднолар йөрү трассаларында юл эшләре башкаруга, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә гомуми кулланыштагы причалларга килү юллары ясау һәм аларны карап тоту өчен субсидия бүлеп бирелә.

Болгар һәм Свияжск яр буйларында елга төбен тирәнәйтү, шулай ук 2019 елда 4 – 6,5 км участогында Болгар шәһәренә су юлы буйлап килүнең уң як читен кисү кирәклеге белән бәйле рәвештә, әлеге яр буйларында елга төбен тирәнәйтү буенча эшләр башкарылды. Казып алынган грунтның гомуми күләме 423,1 мең куб метр тәшкил иткән. Проект өлешләп финанслау шартларында гамәлгә ашырылды: федераль бюджеттан – 36,2 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 36,2 млн сум.

2019 елда круиз судноларын причалга бәйләп кую операцияләрен куркынычсыз рәвештә уздыруга таләпләрне үтәү өчен Свияжск һәм Болгар причалларына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан Свияжск һәм Болгар причалларын модернизацияләү буенча проект-тикшеренү эшләре башкарылды.

***Автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы предприятиеләр эшчәнлеге***

Татарстан Республикасының автомобиль транспортын төрле милек рәвешендәге эшчәнлек алып баручы 41 пассажир йөртүче, шул исәптән Татарстан Республикасының 15 эре автотранспорт предприятиесе тәшкил итә.

Регуляр муниципальара пассажирлар ташучы күчмә составларның барысы да ГЛОНАСС яисә ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе системасына тоташтырылган һәм «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат тапшыра.

2019 елда республиканың автотранспорт предприятиеләре тарафыннан даими маршрутларда 225 млн пассажирга хезмәт күрсәтелгән, бу 2018 ел белән чагыштырганда 4 процентка күбрәк, даими маршрутларда гомуми кулланылыштагы автобусларда пассажирлар әйләнеше 1 386,1 млн пассажир тәшкил иткән (2018 ел белән чагыштырганда 100,5 процент).

2019 елда Татарстан Республикасының зур автотранспорт предприятиеләренең күчмә составы саны 2 778 берәмлек автобусны тәшкил итә, алар 772 маршрутка хезмәт күрсәтә.

2019 елда барлык эшчәнлек төрендәге кече эшкуарлык субъектларына кермәгән оешмаларның автомобильләр белән йөк ташуы күләме (коммерция йөк ташулары белән шөгыльләнүче эшкуарларны исәпкә алып) 49,9 млн тонна йөк (2018 ел белән чагыштырганда 93,3 процент) тәшкил иткән. Йөк әйләнеше 4 107,2 млн тонна (2018 ел белән чагыштырганда 112,6 процент) тәшкил итте.

***Шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы предприятиеләр эшчәнлеге***

Татарстан Республикасының шәһәр электр транспорты 3 муниципаль предприятие – «Метроэлектротранс» МУП, «Электротранспорт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте , «Горэлектротранспорт» МУП, «Әлмәт троллейбус идарәсе» МУП эшчәнлеге белән бәйле.

2019 елда шәһәр электр транспорты предприятиеләренең хәрәкәт составы 481 берәмлек тәшкил иткән, шул исәптән 263 трамвай, 204 троллейбус, 47 метрополитен вагоны.

Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә 51 маршрут буенча пассажирлар йөртү гамәлгә ашырыла. Казан шәһәрендә метрополитен белән пассажирлар йөртү гамәлгә ашырыла.

2019 елда шәһәр электр транспортында 103,5 млн пассажир йөрде (2018 ел белән чагыштырганда 100,3 процент). 2019 елда шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртүдә әйләнеш 453,9 млн пассажир тәшкил иткән (2018 ел белән чагыштырганда 99,5 процент).

***Казанда WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатына транспорт хезмәте күрсәтү***

WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионаты чараларына хезмәт күрсәтү кысаларында 135 төп һәм резерв маршрут буенча клиент төркемнәре – катнашучыларны транспортта йөртү гамәлгә ашырылды. WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча чемпионат

уздыру чорында 668 мең пассажирга хезмәт күрсәтелгән, 23 меңнән артык рейс башкарылган. 10 меңгә якын кеше түләүсез йөрү хокукыннан файдаланган, волонтерлар һәм аккредитацияләнгән затлар Казан шәһәренең шәһәр пассажир транспортында (автобус, трамвай, троллейбус, метро), шулай ук «Казан-1» тимер юл вокзалы – «Казан»халыкара аэропорты маршруты буенча шәһәр яны электр поездларында 95 023 тапкыр йөргән.

***Юл инфраструктурасын үстерү***

Татарстан Республикасының федераль һәм төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы 14 687,7 км тәшкил итә, шул исәптән федераль юллар – 1 075,4 км, төбәктәге юллар – 13 612,3 км.

Камилләштерелгән каты катлаулы федераль һәм төбәк әһәмиятендәге гомум файдаланудагы автомобиль юлларының озынлыгы – 12 751,3 км (87 процент), күчү тибындагы катламлы – 1 353 км (9,2 процент), грунт юллары – 583,4 км (4 процент).

Гомуми файдаланудагы юллар челтәренең тыгызлыгы 1 000 кв км территориядә 216,5 км тәшкил итә.

Төбәк автомобиль юлларының күп өлеше түбән (IV һәм V) категориядәге юлларны тәшкил итә – 11 853,4 км (яисә 87,1%).

Моннан тыш, республика шәһәрләрендәге урам юллары  һәм торак пунктлары юллары челтәре (муниципаль милектәге) озынлыгы – 24 675,6 км.

2019 елда бүлеп бирелгән акчалар хисабына Төбәк автомобиль юлларында юл эшләре программасы нигезендә түбәндәгеләр эшләнде:

93,9 км төбәк автомобиль юллары төзелде һәм реконструкцияләнде;

11 күпер төзелде;

196,8 км гамәлдәге төбәк челтәр төзекләндерелде ;

7 күпер төзекләндерелде;

22 авыл торак пункты 70 км озынлыктагы каты өслекле юллар белән тоташтырылды;

авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә ярдәм итү өчен 31,2 км озынлыкта 49 гаилә фермаларына һәм терлекчелек комплексына керү юллары төзекләндерелде;

63 мәктәп маршрутында транспорт-эксплуатация шартлары яхшыртылды.

Татарстан Республикасы бакча ширкәтләренә гомуми озынлыгы 26,1 километр булган 33 керү юлы төзелде.

«Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында 11 торак пункт гомуми озынлыгы 41,3 км булган каты өслекле керү юллары белән төзелде.

*Муниципаль юлларда юл эшләре*

Республиканың торак пунктларында муниципаль юл-урам челтәре торышын яхшырту максатыннан түбәндәге эшләр башкарылды:

200 км озынлыктагы торак пунктларда (вак таш-ком катнашмасы) юл-урам челтәрен нормага туры китерү. Әлеге программа ярдәмендә 43 муниципаль берәмлектә 457 урам яңартылды;

торак пунктларның гомуми озынлыгы 350,9 км булган гамәлдәге асфальт-бетон катламын төзекләндерү . 2019 елда муниципаль районнарда 440 урам төзекләндерелде;

юлларны төзекләндерү муниципаль юл фондлары хисабына гомуми озынлыгы 130 км (390 урам).

*Татарстан Республикасы шәһәрләрендә ишегалды территорияләрен, квартал эчендәге юлларны төзекләндерү*

2019 елда гомуми мәйданы 1,3 млн кв метр булган 716 объектка (республика шәһәрләрендә ишегаллары территорияләренә һәм квартал эчендәге юлларга) ремонт ясалган.

*Федераль автомобиль юллары*

2019 елда Татарстан Республикасында федераль әһәмияттәге автомобиль юлларын һәм ясалма корылмаларны карап тоту, төзекләндерү, капиталь төзекләндерү, төзү һәм реконструкцияләү өчен федераль бюджеттан юл эшләрен финанслау күләме 10 270,1 млн сум тәшкил итте.

«Идел» М-7 автомобиль юлының сул якка борылып төшү мөмкинлеге булган 1 014 км участогында һәм 1 017 км участогында бер дәрәҗәдә транспорт чишелешләре төзү эшләре алып барылды. «Идел» М-7 автомобиль юлының 1 048+300 км, 1 052+600 км участокларында төрле дәрәҗәләрдә транспорт чишелешләре проектлау эшләре алып барылды.

***«Каршылыкларсыз юл» флагман проекты***

«Каршылыкларсыз юл» проекты Татарстан Республикасында зур тизлектә хәрәкәт итү өчен өстәмә юл, ул Казан шәһәрен, «Казан» халыкара аэропортын, Алексеевск штп, Чистай шәһәрен, Кама Аланы штп, Түбән Кама шәһәрен, «Бигеш» аэропортын, Чаллы шәһәрен, Менделеевск шәһәрен тоташтырачак.

2019 елда юл эшләре программасы кысаларында Түбән Кама муниципаль районында 92,9 млн сумга Чистай – Түбән Кама (48+610 – 49+390 км, 73+735 – 74+735 км, 40+860 – км 43+556 км, 44+373 – 45+129 км); Чистай муниципаль районында 15,1 млн сумга Чистай – Түбән Кама (0+741 – км 2+133 км) автомобиль юллары, Чистай – Түбән Кама автомобиль юлында (15+890 км) 14,7 млн сумга Талкыш елгасы аша күпер төзекләндерелде.

**Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык**

«Торак» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә 2019 елда 2 675,5 мең кв метр торак файдалануга тапшырылды, шул исәптән:

күпфатирлы инвестицион торак – 1 211,7 мең кв метр;

социаль ипотека – 358,1 мең кв метр;

шәхси торак төзелеше – 1 105,7 мең кв метр.

2019 ел йомгаклары буенча бәяләүләр буенча бер кешегә гомуми торак мәйданы 27,4 кв метр тәшкил итә.

2020 елга 2 979 мең кв метр торак булыр дип планлаштырыла.

Моннан тыш, «Торак» төбәк проекты чараларын үтәү кысаларында торак төзелешен үстерү программаларына ярдәм итү максатыннан гомуми күләме 1 425,1 млн сум финанслар бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 997,6 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 427,5 млн сум.

«Весна» торак комплексында 1 501 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү мәктәбе файдалануга тапшырылды;

«Салават Күпере» торак районында кварталлар арасындагы юллар файдалануга тапшырылды;

«Царево утары» торак комплексында 1 224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү мәктәбе төзелеше башланды.

Торак төзелеше программасын үтәүне тәэмин итү максатларында, даими режимда түбәндәге ярдәмче программалар буенча торак йортлар төзелеше барышын тикшереп тору һәм күзәтү алып барыла:

*Күпфатирлы инвестицион торак.* 2019 елда гомуми мәйданы 1 211,7 мең кв метр булган 253 күпфатирлы йорт файдалануга тапшырылды. Күпфатирлы инвестицион торак программасы 12 муниципаль берәмлектә – Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә, Әлмәт, Арча, Баулы, Буа, Биектау, Алабуга, Зеленодольск, Лаеш, Лениногорск, Питрәч муниципаль районнарында кертелгән.

*Азкатлы йортлар төзү программасы (шул исәптән, шәхси торак төзелеше).* 2019 елда республикада гомуми мәйданы 1 105,7 мең кв метр булган 8 442 шәхси торак йорт төзелгән һәм файдалануга тапшырылган.

*Социаль ипотека.* Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 15 февралендәге 104 номерлы карары белән расланган «2019 елга Татарстан Республикасы гражданнарын торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме» программасы нигезендә 2019 елда гомуми мәйданы 358,1 мең кв метр булган 6 214 фатирлы 119 торак йорт файдалануга тапшырылган. 2020 елда гомуми мәйданы 273,6 мең кв метр булган 4 970 фатирлы 130 торак йортны файдалануга тапшыру планлаштырыла.

Республикада социаль ипотека программасына яшь гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан үзләренең теркәлгән торaклары булмаган затларны, радиацион аварияләр һәм һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны, Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән территорияләрне, күченеп килергә мәҗбүр булган затларны, 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү, запастагы хәрби хезмәткәрләр һәм аларга тиңләштерелгән затлар өчен торак төзү буенча федераль механизмнар кертелгән.

*Бөек Ватан сугышы ветераннарының торак шартларын яхшырту программасы.* Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү турында» 2008 елның 7 маендагы 714 номерлы Указын тормышка ашыру буенча эш алып барыла. 2019 елда 98 ветеран торак белән тәэмин ителгән, финанслау күләме 171,7 млн сум тәшкил итә.

Бер үк вакытта 2005 елның 1 гыйнварына кадәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә баскан инвалидларның, инвалид балалары булган гаиләләрнең, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, һәлак (вафат) булган хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзаларының торак шартларын яхшырту буенча эш алып барыла.

2019 елда Татарстанда сугыш хәрәкәтләре ветераннарын торак белән тәэмин итү өчен 113,2 млн сум, инвалидларны торак белән тәэмин итү өчен 111,1 млн сум каралган. Әлеге акчалар тиешенчә 134 ветеранга һәм 131 инвалидка субсидия бирү мөмкинлек бирде.

*Ятим балалар өчен торак.* «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак белән тәэмин итү» программасы буенча бүлеп бирелгән финанслауның гомуми күләме 2013 елдан 2018 елга кадәр 1 960,8 млн сум тәшкил итте, 1 818 ятим бала торак белән тәэмин ителде. 2019 елда 309 ятим бала торак белән тәэмин ителде, финанслау күләме 373,2 млн сум тәшкил итте, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 328,5 млн сум, федераль бюджет акчалары исәбеннән – 44,7 млн сум.

2020 елда ятим балаларны торак белән тәэмин итүгә 840,7 млн сум бүлеп бирелде. Бүлеп бирелгән акчалар кысаларында 600 ятим баланы торак белән тәэмин итү планлаштырыла.

*5 һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү.* Чаралар торак сатып алу өчен субсидияләр бүлеп бирүгә яисә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне шәхси торак белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән. 2007–2018 елларда республика буенча җыелма исемлеккә кертелгән 411 күпбалалы гаилә торак белән тәэмин ителде, финанслау күләме 1 166,4 млн сум тәшкил итте. 2019 елда 33 гаилә (267 кеше) торак белән тәэмин ителде, финанслау күләме 153,7 млн сум, гомуми мәйданы – 2 243,4 кв метр. 2020 елда 46 күпбалалы гаиләне торак белән тәэмин итү планлаштырыла, финанслауның гомуми күләме 211,9 млн сум тәшкил итәчәк.

*«Гражданнарның федераль законнар белән билгеләнгән категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» өстенлекле милли проекты кысаларында гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү.* 2006–2018 елларда ярдәмче программа кысаларында 1 732,3 млн сумга 1 178 субсидия рәсмиләштерелде. 2019 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән барлыгы 100,1 млн сумга 51 субсидия рәсмиләштерелде, шул исәптән:

Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәсендә радиация нурланышы алган гражданнарга 44 млн сумга 25 дәүләт торак сертификаты;

билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри күчеп килүче гражданнар дип танылучыларга 52,9 млн сумга 25 дәүләт торак сертификаты;

Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән күчеп кайтучы гражданнарга 3,2 млн сумга 1 дәүләт торак сертификаты.

2020 елда 73,99 млн сумга 28 субсидия рәсмиләштерү планлаштырыла.

*Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү.* «Россия Федерациясе гражданнарын уртача бәядән уңайлы торак белән тәэмин итү һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү» Россия Федерациясе федераль дәүләт программасы кысаларында «2014–2021

елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» республика ярдәмче программасы нигезендә 2019 елда 57,9 млн сум финанслау күләмендә 54 яшь гаиләгә субсидияләр бүлеп бирелде. 2006–2018 елларда барлыгы 7 840 яшь гаилә социаль түләүләр алды һәм торак шартларын яхшыртты (финанслауның гомуми күләме – 4 229,3 млн сум).

2020 елда 47 яшь гаиләне торак белән тәэмин итү планлаштырыла (финанслау күләме – 62,8 млн сум).

«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру кысаларында 2019 елда 70 яшь гаилә дәүләт ярдәменә ия булды. 1999–2019 елларда барлыгы 4 315 яшь гаиләгә ярдәм күрсәтелде.

*Аренда торагы.* «Аренда торагы» программасы Татарстан Республикасы шәһәр һәм районнарын үстерүгә юнәлтелгән. Аренда торагын төзү өчен яңа җитештерү мәйданчыклары, махсус икътисадый зоналар, сәнәгать парклары булдыру, IT – өлкәне, нефть химиясе сәнәгатен үстерү, шулай ук бюджет өлкәсе белгечләренә (табиблар, укытучылар, мәдәният өлкәсе, спорт, көч структуралары хезмәткәрләре һ.б.) кискен кытлык булган урыннар өстенлекле булып тора.

Аренда торагы предприятие хезмәткәрләренә дә, чакырылган белгечләргә дә – бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә бирелә.

2010 елдан 2019 елга кадәр республикада гомуми мәйданы 177,7 мең кв метр булган 3 124 фатирлы 297 аренда торагы файдалануга тапшырылды, шул исәптән 2019 елда – гомуми мәйданы 25,3 мең кв метр булган 486 фатирлы 73 торак йорт.

2020 елда аренда торагы программасы кысаларында гомуми мәйданы 8,5 мең кв метр булган 138 фатирлы 71 торак йорт төзү планлаштырылган.

*Җәмәгать инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь төзекләндерү. Халыкка беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү эшен камилләштерү.* 2012 елдан башлап фельдшер-акушерлык пунктларын (алга таба – ФАП), патологоанатомия бүлекләрен төзү һәм сәламәтлек саклау объектларын капиталь төзекләндерү буенча чаралар тормышка ашырыла.

2019 елда 54 сәламәтлек саклау объекты төзелде, 9 сәламәтлек саклау объекты капиталь төзекләндерелде һәм җиһазландырылды, гомуми финанслау күләме 330 млн сум тәшкил итә, шул исәптән:

1 ФАП һәм 9 табиблык амбулаториясе төзелде;

9 объект медицина җиһазлары һәм мебель белән җиһазландырылып, капиталь төзекләндерелде.

2020 елда 51 сәламәтлек саклау объекты төзү, гомуми финанслау күләме 330 млн сум булган 8 сәламәтлек саклау объектын капиталь төзекләндерү һәм җиһазландыру планлаштырыла (төзелеш-монтажлау эшләре – 321,9 млн сумга, проект-тикшеренү эшләре – 8,1 млн сумга), шул исәптән:

гомуми финанслау күләме 147,4 млн сум булган 43 ФАП төзү;

гомуми финанслау күләме 77,4 млн сумга 7 табиб амбулаториясен төзү;

1 сәламәтлек саклау объекты төзү («Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми практика табибы офисы, Бөреле җәнлек совхозы поселогы) гомуми финанслау күләме – 28 млн сум;

8 объектны медицина җиһазлары һәм мебель белән җиһазландырылып, капиталь төзекләндерү, гомуми финанслау күләме – 69,2 млн сум.

*Мәгариф объектларын капиталь төзекләндерү һәм төзү.* 2019 елда 150 мәгариф объекты төзекләндерелде, шул исәптән 38 мәктәп һәм 112 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы. 115 объектта функциональ зоналар (төрле максатчан билгеләнештәге участоклар) булдырылды. Гомуми финанслау күләме 3 101,1 млн сум тәшкил итте. Гомуми күләме 6 370 урынга исәпләнгән 30 мәктәпкәчә белем бирү объекты һәм 6 521 урынга исәпләнгән 8 гомуми белем бирү объекты төзелде.

*Ресурс үзәкләрен капиталь төзекләндерү*. Татарстан Республикасында 2014 елдан башлап һөнәри белем бирү ресурс үзәкләрен капиталь төзекләндерү программасы гамәлгә ашырыла. 2019 елда 681,4 млн сумга 17 объект капиталь төзекләндерелде.

2020 елда 17 һөнәри белем бирү оешмасын төзекләндерү планлаштырыла. Финанслауның гомуми күләме 681,4 млн. сум тәшкил итәчәк.

*Яшүсмерләр клублары челтәрен капиталь төзекләндерү*. 2015–2018 елларда 114 объект төзекләндерелде, финанслау күләме 395 млн сум тәшкил итте.

2019 елда 27 объект төзекләндерелде, финанслау күләме 100 млн сум тәшкил итте.

2020 елда 100 млн сумга 17 объектны төзекләндерү планлаштырыла.

*Балаларны сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү*. Программа 2014 елдан бирле тормышка ашырыла. 2019 елда 12 объект капиталь төзекләндерелде, 3 объект төзелде, 2 объект реконструкцияләнде. Финанслауның гомуми күләме 885,9 млн сум тәшкил итте.

*«Универсаль спорт мәйданчыклары төзү» программасы.* 2019 елда 105 спорт мәйданчыгы һәм 427,4 млн сумга мебель, инвентарь һәм җиһазлар белән 8 блоклы модульле чаңгы базасы төзелде.

2020 елда 91 объект төзү планлаштырыла, шул исәптән 84 универсаль спорт мәйданчыгы, 6 блоклы модульле чаңгы базасы, мебель, инвентарь һәм җиһазлар, 20х40 метрлы каркас-тент капламы булган 1 ябык футбол манежы һәм административ бина. Финанслау күләме 427,4 млн сум тәшкил итәчәк.

*Спорт инфраструктурасын үстерү.* 2019 елда 215 спорт корылмасы файдалануга тапшырылган.

«Спорт – тормыш нормасы» федераль проекты кысаларында түбәндәге эшләр башкарылды:

«Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормаларын үтәү өчен 18 мәйданчыкка тренажерлар кую һәм аларны монтажлау;

Буа һәм Лениногорск шәһәрләренең боз сарайларына хоккей җиһазлары, шул исәптән ике боз катыру машинасы китерү;

Лаеш, Минзәлә һәм Сарман муниципаль районнарында 3 универсаль спорт мәйданчыгы төзелде;

Апас муниципаль районында ясалма өслекле 2 футбол кыры һәм Чаллы шәһәрендә йөгерү юллары төзелде;

Чаллы шәһәрендә йөзү бассейны төзелә башлады.

2019 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән:

Байлар Сабасында бадминтон, өстәл теннисы, фехтование, шахмат, мини-футбол һәм волейбол белән шөгыльләнү өчен универсаль спорт залы файдалануга тапшырылды;

Питрәч авылында универсаль спорт залы төзелеше тәмамланды;

Казан шәһәренең Юдино бистәсендә Боз сарае ачылды.

Яңа объектларны гамәлгә кертү нәтиҗәсендә бүгенге көндә республика спорт объектларында бер үк вакытта спорт белән шөгыльләнүчеләрне кабул итү мөмкинлеге 67,1 процентка (2018 елда– 66,8 процент) җитте.

2019 ел йомгаклары буенча Татарстанда 11 065 спорт корылмасы бар.

*Мәдәни билгеләнештәге объектлар төзү һәм төзекләндерү*. Муниципаль берәмлекләрдә тормыш сыйфатының дәрәҗәсен күтәрү, халыкның мәдәни хәзинәләребездән файдалана алуын һәм үзенең иҗади мөмкинлекләрен күрсәтә алуын тәэмин итү максатларында мәдәни билгеләнештәге объектларны төзү һәм төзекләндеү программалары тормышка ашырыла.

2019 елда гомуми суммасы 227,6 млн сумга 21 мәдәни объект төзелде һәм 412,2 млн сумга 40 мәдәни объект төзекләндерелде.

2020 елда 12 мәдәни билгеләнештәге объект төзү һәм республиканың муниципаль берәмлекләре торак пунктларында 37 мәдәни объектка капиталь ремонт ясау каралган.

*Сыер абзарларын, яшелчә саклау урыннарын, машина-трактор паркларын, ындыр табакларын капиталь төзекләндеү һәм силос-сенаж траншеяларын төзү.* 2019 елда түбәндәге объектларда капиталь ремонт эшләре тәмамланды:

155 сыер абзары (финанслауның гомуми суммасы 660,4 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 200 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 460,4 млн сум);

68 машина-трактор паркы (финанслауның гомуми суммасы 164,9 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 50 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 114,9 млн сум);

129 ындыр табагы хуҗалыгы (финанслауның гомуми суммасы 369,8 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 112 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 257,8 млн сум);

түбәндәге объектлар төзелде:

94 силос-сенаж траншеясы (финанслауның гомуми суммасы 200 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 60 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 140 млн сум.);

14 сыер абзары һәм 1 сарык фермасы (финанслауның гомуми суммасы 391,3 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 120 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 271,3 млн сум).

2020 елда төзү планлаштырыла:

90 силос-сенаж траншеясы (финанслауның гомуми суммасы 200 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 60 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 140 млн сум.);

6 сыер абзары һәм 1 сарык фермасы (финанслауның гомуми суммасы 333,3 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 100 млн сум, бюджеттан тыш акчалар – 233,3 млн сум).

*Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен капиталь төзекләндерү*. 2019 елда барлыгы 121,3 млн сумга 34 объектка капиталь ремонт ясалды:

6 интернат-йорт;

6 психоневрологик интернат;

балалар һәм яшүсмерләр өчен 5 социаль приют;

8 комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге;

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен 4 тернәкләндерү үзәге;

3 инвалидларны тернәкләндерү үзәге;

1 республика инвалидларны социаль тернәкләндерү үзәге;

1 билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәге.

2020 елда 121,3 млн сумга 37 объектны төзекләндерү планлаштырыла.

*Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирлекләре советлары биналарын төзү һәм капиталь төзекләндерү*. 2016–2018 елларда 158 объект төзекләндерелде һәм 300 млн сумга 21 объект төзелде.

2019 елда 11 объект төзелде, гомуми суммасы 100 млн сумга 31 объект төзекләндерелде.

2020 елда 11 объект төзү һәм гомуми суммасы 100 млн сумга 21 объектны төзекләндерү планлаштырыла (шул исәптән 2,6 млн сумга проект-эзләнү эшләре).

*Татарстан Республикасы муниципаль архивлары биналарын капиталь төзекләндерү*. 2019 елда 50 млн сумга 13 объект төзекләндерелгән. 2020 елда гомуми суммасы 50 млн сумга 7 объектны төзекләндерү планлаштырыла.

*Ветеринария берләшмәләренә һәм авыл хуҗалыгы идарәләренә капиталь ремонт.* 2019 елда гомуми суммасы 50 млн сумга 33 объектка, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе карамагындагы 22 учреждение бинасына һәм Татарстан Республикасының 11 авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә капиталь ремонт ясалды. 2020 елда гомуми суммасы 60 млн сумга 41 объектны капиталь төзекләндерү планлаштырыла, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе карамагындагы 22 учреждение һәм Татарстан Республикасының 15 авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе бинасы.

*«Уңайлы мохит» программасы.* 2019 елда 12 мәгариф өлкәсе объекты адаптацияләнде (8 муниципаль берәмлектә), шул исәптән 5 гомуми белем бирү, 5 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы һәм 2 балаларга өстәмә белем бирү объекты. 2019 елда программаны финанслауның гомуми күләме 21,5 млн сум тәшкил итте, шуның 12,1 млн сумы – федераль бюджет акчалары, 9,4 млн сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә.

### ***Торак-коммуналь хуҗалык***

*Күпфатирлы йортларга идарә*

Татарстан Республикасы торак фонды мәйданы 104,1 млн кв метр торак тәшкил итә, шулардан 93,2 проценты хосусый милектә (97,1 млн кв.метр),

5 проценты – муниципаль (5,2 млн кв метр), 1,8 проценты – дәүләт милкендә (1,8 млн кв. метр).

Республикада гомуми мәйданы 77,6 млн кв метр булган 46 126 күпфатирлы йорт (алга таба – КФЙ), шул исәптән гомуми мәйданы 72,6 млн кв метр булган блоклы төзелгән 17 332 КФЙ исәпкә алмыйча, шулардан:

14 631 йортка (84 процент) идарәче компанияләр идарә итә;

2 588 йортка (15 процент) торак милекчеләре ширкәтләре һәм торак-төзелеш кооперативлары идарә итә;

113 йортка (1 процент) – турыдан-туры милекчеләр үзләре идарә итә.

Идарәче компанияләр эшчәнлеген дәүләт җайга салуы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларга идарә эшчәнлеге лицензия нигезендә башкарыла. 302 идарәче компаниянең күпфатирлы йортларга идарә итүгә лицензиясе бар.

«Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә җәмәгать контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы тарафыннан «Бердәм Россия» партиясе проекты кысаларында Белемле кулланучы мәктәбе» дигән программа нигезендә халыкның торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләре буенча мәгълүматын арттыруга юнәлтелгән эш алып барыла. Халыкның төрле төркемнәрен максатчан укытуның мультиформат алымнары эшләнде. Күпфатирлы йортлардагы фатир милекчеләре өчен бушлай укыту һәм аларга консультацияләр бирү, шул исәптән дистанцион рәвештә дә оештырылды. «Белемле кулланучы мәктәбе» дигән программа буенча 1 411 күпфатирлы йортлар советлары рәисләре һәм әгъзалары, шулай ук актив фатир милекчеләре уку узды.

Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кадрларны яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 14 декабрендәге 2941-б номерлы боерыгы белән расланган 2017-2021 елларга кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү чаралары планы кысаларында башкарылды.

*Күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү*

Тармакның төп проблемаларыннан берсе – торак фондының нык дәрәҗәдә тузган булуы.

2019 елда Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлары уртак милегенә капиталь ремонт уздыруга финанслауның гомуми күләме 5,4 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 1 млрд сум, муниципаль берәмлекләр бюджеты акчалары – 1,1 млрд сум, гражданнар акчасы – 3,3 млрд сум. Гомуми мәйданы 5,5 млн кв метр булган 935 күпфатирлы йортта капиталь ремонт үткәрелде, аларда 209 меңнән артык граждан яши.

*«Яшәү өчен яраксыз торак фондын эзлекле рәвештә киметүне тәэмин итү» федераль (төбәк) проекты*

Дәүләт торак сәясәтенең гражданнар өчен торак алу мөмкинлеген, анда яшәү өчен куркынычсыз һәм уңайлы шартлар тәэмин итә алырлык торак өлкәсенең тотрыклы эшләве һәм үсеше мәсьәләләрен комплекслы хәл итүгә юнәлдерелгән бурычларыннан берсе – ул авария хәлендәге торак фондында яшәүче

гражданнарның торак шартларын яхшырту хокукын тормышка ашыруны тәэмин итү.

Татарстан Республикасы территориясендә «Яшәү өчен яраксыз торак фондын эзлекле рәвештә киметүне тәэмин итү» федераль проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 29 мартындагы 242 номерлы карары белән 2019–2025 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасы расланды.

2019 елда 90 кеше күчерелде, 1 087,2 кв метр авария хәлендәге торак бетерелде. Чараларны финанслау күләме 129,9 млн сум тәшкил итте, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды акчалары исәбеннән – 64,5 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 65,4 млн сум.

*ТКХ объектларын модернизацияләү*

*Блок-модульле пар казаннары урнаштыру, газ белән тәэмин итү инженер челтәрләрен төзү һәм хосусый җылылык системасына күчү*

Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарында һәр фатирны аерым җылыту системасына һәм блоклы пар казаннары урнаштыруга күчү программасы 2005 елдан бирле ягулык-энергетика ресурсларын рациональ куллану, югары чыгымнар таләп итүче икътисадый яктан отышлы булмаган пар казаннарын бетерү, челтәрләрдә югалтуларны киметү, республика шәһәрләре һәм районнары җылылык белән тәэмин итү системаларының нәтиҗәлелеген арттыру, алдынгы энергиясаклагыч технологияләр кертү, халыкның яшәү шартларын яхшырту, шулай ук кайнар су белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтү максатларында тормышка ашырыла.

2019 елда әлеге максатларга 161,6 млн сум акча тотылды, 973 фатир хосусый җылыту системасына күчерелде, 13 блок-модульле пар казаннары урнаштырылды, 14 км тоташтыргыч, боҗралы һәм фасад газүткәргечләре төзелде.

2020 елда программаны финанслауга 162,2 млн сум каралган.

*Бюджет өлкәсе объектларын җылылык белән тәэмин итүче пар казаннары биналарында казаннарны алыштыру*

Социаль өлкә объектларын җылылык белән тәэмин итә торган пар казаннарының ышанычлы һәм нәтиҗәле эшләвен арттыру, электр энергиясе ресурсларын куллануны киметү максатларында социаль-мәдәни өлкә объектларындагы пар казаннары биналарында казаннарны алыштыру программасы тормышка ашырыла. 2019 елда финанслау күләме 70,5 млн сум тәшкил итте, 64 объектта пар казаннары җиһазлары монтажланды, 42 муниципаль берәмлектә 119 казан алмаштырылды. Программаны тормышка ашыру өчен 2020 елда 69,9 млн сум бүлеп бирелгән.

*Авыл җирлекләрендә су белән тәэмин итү*

Татарстан Республикасы торак пунктларында хуҗалык һәм эчәр су белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итүнең сыйфатын арттыру максатларында «Халыкны эчә торган су белән тәэмин итү» программасы тормышка ашырыла.

2019 елда әлеге чыгымнарга 685,3 млн сум күләмендә финанслар бүлеп бирелде, 213,6 км суүткәргеч челтәре, 42 су башнясы, 33 артезиан скважинасы төзелде (реконструкцияләнде). 2020 елда Программа чараларын тормышка ашыру өчен 650 млн сум бүлеп бирелде.

***Чистарту корылмаларын модернизацияләү һәм канализация челтәрләрен капиталь төзекләндерү***

2019 елда «Чистарту корылмаларын модернизацияләү һәм канализация челтәрләрен капиталь төзекләндерү» программасы чараларына 421,5 млн сум күләмендә финанслар бүлеп бирелде, 40 объектның проекты эшләнде һәм төзелде, шул исәптән 15 объектның проект-тикшеренү эшләренә 12,6 млн сум акча бүлеп бирелде, 25 объект төзелешенә (капиталь төзекләндерүгә) – 408,9 млн сум. 2020 елда 317,1 млн сумга 26 юынтык суларны агызу объекты һәм канализация челтәрләрен төзекләндерү планлаштырыла.

*Коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтләрендә каты көнкүреш калдыклары өчен мәйданчыклар булдыру һәм су белән тәэмин итү*

2019 елга программаны тормышка ашыру өчен 150 млн сум бүлеп бирелде.

58 су җыю савытларын алмаштыру, 34 артезиан скважинасын бораулау, 37 насосны монтажлау, 82 коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтендә 9,541 км суүткәргеч салу, контейнерлар кую өчен 58 мәйданчык әзерләү, 256 контейнерны урнаштыру, 56 мәйданчыкны бункерлар кую өчен әзерләү һәм 22 муниципаль районда 100 коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтендә 81 бункер урнаштыру буенча эшләр башкарылды.

2020 елда Программа чараларын үтәүгә 100 млн сум бүлеп биреләчәк.

*Җәмәгать урыннарын үстерү*

«Шәһәрдә уңайлы мохит формалаштыру» өстенлекле проекты кысаларында җәмәгать урыннарын үстерү программасын гамәлгә ашыруга 2019 елда 2 767,5 млн сум бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 1 402,8 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 1 364,7 млн сум, 54 җәмәгать урыны объекты төзекләндерелде.

Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр арасында уңайлы шәһәр тирәлеген булдыру буенча иң яхшы проектларның бөтенроссия конкурсы кысаларында 2018 елда конкурста җиңүче 14 муниципаль берәмлекнең проектлары тормышка ашырылды. Проектларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан 905 млн сум (грант) бүлеп бирелде. Проектларны гамәлгә ашыру буенча барлык чаралар 2019 елда конкурс шартлары нигезендә тәмамланды.

2019 елгы конкурс кысаларында Мамадыш шәһәре «Табигать-спорт комплексы» проекты белән конкурста җиңүче булды. Федераль бюджеттан грант суммасы 60 млн сум тәшкил итте. 2019 елда объектта, асфальт җәюдән һәм агач-үсемлекләр утыртудан (газон, чәчәкләр утырту, агачлар утырту) тыш, барлык эшләр дә тәмамланды. Төзелгән килешү нигезендә объектны тапшыру срогы – 2020 ел.

*Авыл торак пунктларында яктырту җиһазларын төзекләндерү программасы*

Электр энергиясеннән сакчыл һәм нәтиҗәле файдалану җиһазларын кулланышка кертү хисабыннан электр энергиясен куллануны киметү, халыкка яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру һәм республикада урамнарны яктыртуны нормада билгеләнгән таләпләргә китерү максатларында 2014 елда яктырту җиһазларын төзекләндерү программасы эшли башлады.

2019 елда программаны финанслауга 225 млн сум бүлеп бирелде. 237 км электр белән тәэмин итү линиясе төзелде, 171 электр энергиясен исәпкә алу приборы, 10 429 яктырткыч урнаштырылды, 45 муниципаль берәмлектә (534 торак пункт) 12 309 яктырткыч алмаштырылды.

*Хосусый инвестицияләр җәлеп итү*

Торак-коммуналь хуҗалыкка хосусый инвестицияләр җәлеп итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы түбәндәге юнәлешләрне үз эченә ала:

коммуналь инфраструктура системаларын, шәһәр җирлекләрен һәм шәһәр округларын җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу схемаларын комплекслы үстерү программаларын системалы актуальләштерү;

торак-коммуналь хуҗалык объектларын җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вакытында теркәү һәм хуҗасыз объектларга хокукларны рәсмиләштерү;

җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә тарифларны җайга салуның озак вакытка исәпләнгән чараларын гамәлгә ашыру;

унитар предприятиеләр нәтиҗәлелегенең расланган критерийлары нигезендә аларга идарә нәтиҗәсез дип танылган дәүләт һәм муниципаль предприятиеләр милкен концессиягә тапшыру.

Җирле үзидарә органнарының торак-коммуналь хуҗалык объектларын тапшыру буенча эшчәнлеге Россия Федерациясе Төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы линиясе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 22 августындагы 1493-б номерлы боерыгы белән расланган Торак-коммуналь хуҗалыкка хосусый инвестицияләрне җәлеп итү буенча гамәлләр планын үтәүгә концессия килешүләре нигезендә алып барыла.

Хәзерге вакытта республиканың су белән тәэмин итү, юынтык суларны агызу һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә 151 концессия килешүе гамәлдә.

Моннан тыш, муниципаль милектә булган һәм биш елдан артык арендада булган коммуналь милеккә концессия килешүләре төзү буенча эш алып барыла.

2020 елның 1 гыйнварына коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү буенча 826 программа расланган (100 процент үтәлеш).

2019 елда Татарстан Республикасында су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә 4 оешманың инвестицион программалары расланды.

Башлангыч мәгълүматларга караганда, 2019 елда су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә инвестицион программалар буенча үтәлеш 932,3 млн сум тәшкил итә, шулардан су белән тәэмин итү буенча – 203,6 млн сум, юынтык суларны агызу буенча – 728,8 млн сум.

**Татарстан Республикасында агломерацияләрне үстерү**

*Казан агломерациясе*

Казан агломерациясендә төп үзгәрешләр тотрыклы структура булдыручы транспорт каркасын төзүгә кагылышлы алып барылачак. Моңа тизлекне сакларга мөмкинлек бирүче автомобиль юллары, Казан янында әйләнгеч яңа автомобиль һәм тимер юллары төзү, шулай ук Гребени авылы янында Идел аша стратегик күпер салу кирә. Казан шәһәреннән көньяктарак Идел аша күпер салу Лаеш районын үстерүгә мөмкинлекләр ачачак. Иделнең уң ярында урнашкан Югары Ослан муниципаль районы агломерация процессларында актив катнаша. Экосистеманы саклап калу – «яшел» технологияләр, аз катлы йортлар төзү, рекреация һәм ял оештыру функцияләрен файдалану бу территорияне үзләштерүнең төп шарты булып тора.

Үзгәртеп корулар түбәндәге проектлар кысаларында алып барыла:

*«Казан шәһәрендә тимер юл боҗра хәрәкәтен оештыру».* Проектны гамәлгә ашыруның якынча бәясе 22,4 млрд. сум тәшкил итә. Түбән Новгородның «Росжелдорпроект» ачык акционер җәмгыяте филиалы «Нижегороджелдорпроект» проект институты тарафыннан 15 млн сумга проектка техник-икътисадый бәяләү эшләнде.

Башлангыч этапта Юдино ст. – Дәрвишләр ст. һәм Яңа Аракчино ст. районындагы съезд участогында өченче юл төзү планлаштырыла, бу «Казан» халыкара аэропорты – Казан 1 ст. – Казан 2 ст. бару һәм кайту маршруты буенча шәһәр яны поездларының хәрәкәтен тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

«Казан Гипронииавиапром» АҖ тарафыннан расланган техник задание нигезендә Яңа Аракчино станциясеннән Восстание-Пассажир станциясенә кадәр участокта «Казан шәһәрендә боҗра тимер юл элемтәсен оештыру» проектының беренче этабының проект-смета документациясе эшләнде.

*«Территорияләрне оештыруны яңартып тору».*

Планлаштыру структуралары элементларын аерым алу, планлаштыру структуралары элементларының планлаштырылган үсеш параметрларын, федераль әһәмияткә ия, төбәк әһәмиятенә ия, җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру планлаштырылган зоналарны билгеләү максатларында территорияләрне планлаштыру проектлары әзерләнә.

Алар халык яшәеше өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлтелгән, социаль, мәдәни, көнкүреш, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары урнаштыруны һәм төзүне күз алдында тота.

Татарстан Республикасында бүгенге көндә территорияләрне планлаштыру буенча 1 025 проект эшләнде. Алга таба тагын 313 территорияләрне планлаштыру проекты әзерләү һәм раслау планлаштырыла.

*«Казан шәһәр яны зонасы».* Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан бирелгән мәгълүмат буенча:

Зеленодольск муниципаль районында 23 территорияләрне планлаштыру проекты (алга таба – ТПП), тагын 15 ТПП әзерләү планлаштырыла;

Биектау муниципаль районында 2 ТПП проекты, тагын 5 ТПП әзерләү һәм раслау планлаштырыла;

Питрәч муниципаль районында 3 ТПП, тагын 10 ТПП әзерләү планлаштырыла;

Лаеш муниципаль районында 43 ТПП, тагын 9 ТПП әзерләү планлаштырыла;

Югары Ослан муниципаль районында 15 ТПП, тагын 11 ТПП әзерләү планлаштырыла.

*«Казан агломерациясе инженерлык инфраструктурасын үстерү һәм яңарту».*

Казан, Зеленодольск, Биектау, Питрәч, Лаеш, Югары Ослан муниципаль районнарында торак пунктларда су белән тәэмин итү системалары куелу, ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалану, электр энергиясе челтәрләрендә көчәнешне саклап калу, ягулык казаннары эшенең ышанычлылыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру, чыгарыла торган юынтык суларның норма күрсәткечләренә туры килүенә ирешү, каты коммуналь калдыкларын җыю контейнерлар һәм бункерлар урнаштырылган контейнер мәйданчыклары булдыруга юнәлдерелгән программалар гамәлгә ашырыла:

авылда су белән тәэмин итү («Чиста су» программасы);

хосусый җылылык системаларына һәм блоклы-модульле казаннар күчү программасы;

бюджет учреждениеләрендә казаннарны алмаштыру программасы;

республика торак пунктларында юынтык суларны агызу системаларын яңартып кору программасы;

республиканың бакчачылык ширкәтләрендә хуҗалык суы белән тәэмин итү һәм каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар һәм бункерлар куелган мәйданчыклар төзү.

Казан шәһәрендә коммуналь хуҗалыкка өстәмә инвестицияләр җәлеп итү, торак фондын төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру, коммуналь инфраструктураның тузуын киметү максатларында 2014–2028 елларга Казан шәһәре «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең коммуналь инфраструктура объектларын үстерү, модернизацияләү һәм реконструкцияләү буенча инвестиция программасы тормышка ашырыла. Программа гамәлдәге су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу объектларын төзү һәм реконструкцияләүгә, эчә торган суны бүлгәндә һәм юынтык суларны агызганда эксплуатация чыгымнарын киметүгә, юынтык суларны чистартуның сыйфатын тәэмин итү буенча чараларны үтәүгә юнәлдерелгән.

Программаны финанслауның гомуми күләме 43 562,3 млн сум тәшкил итә, шулардан су белән тәэмин итүгә – 25 133,2 млн сум, юынтык суларны агызуга – 18 429,1 млн сум.

2019 елда программаны финанслау күләме 1 647,3 млн сум тәшкил итте, шулардан су белән тәэмин итүгә – 549,8 мең сум, юынтык суларны агызуга – 1 097,5 млн сум.

*«Сәнәгать зоналарын күчерү».* Файдаланылмый торган сәнәгать һәм коммуналь территорияләрен билгеләнешен үзгәртү мәсьәләләре аларны актуальләштерү эшләре башкарылганда территориаль планлаштыру документларында карала. 2019 елда агломерациягә керүче муниципаль районнарның территориаль планлаштыру схемалары актуальләштерелде.

2020 елда Казан шәһәренең яңа генераль планын раслау планлаштырыла.

*«Казанның елга ярлары».* 2019 елда «Шәһәрдә уңайлы мохит формалаштыру» программасы кысаларында Комсомол һәм Аккош күлләре пляж зонасын төзекләндерү эшләре башкарылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 28 декабрендәге 1083 номерлы карары белән расланган «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын яңадан торгызу һәм куллану» дәүләт программасы кысаларында 2019 елда түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

«Казан шәһәрендә «Бишбалта» буасының су балансын торгызу» объекты буенча 8 млн сумга проект-эзләнү эшләре;

113,9 млн сумга Казан шәһәрендә «Бишбалта» буасының су балансын торгызу;

«Казан шәһәрендә «Бишбалта» буасына агып җыелган суларны чистарту корылмаларын төзү» объекты буенча эшләрне тәмамлау;

12 млн.сумга Казан шәһәренең Казансу елгасының «Һәлак булган сугышчыларга һәйкәл, архитекторы Н.Ф. Алферов» федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты урнашкан территориядә яр буен ныгыту.

*Кама агломерациясе*

Кама агломерациясен үзгәртеп коруның төп юнәлешләре – Кама агломерациясе муниципаль районнарында торакларның сыйфатын арттыруга, халыкның үзәкләштерелгән су белән тәэмин ителүен арттыру, алыштырылырга тиешле канализация челтәрен киметү, юынтык суларны чистартуны тәэмин итү, су объектларын артык күп файдалануны киметү, яр буе территорияләрен төзекләндерү; уңайлыклар булдырылган иҗтимагый мәйданнар белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсен арттыру; экологик хәлне агломерациянең тотрыклы структура булдыручы транспорт каркасын төзү.

Куелган бурычларны тормышка ашыру түбәндәге проектлар кысаларында тормышка ашырыла:

*«Реновация/объектларны урнаштыруның акылга ярашлы рәвештә тыгызлыгы».* Территорияләрне планлаштыру проектларын әзерләү планлаштыру структурасы элементларын билгеләү, капиталь төзелеш объектларының, шул исәптән федераль әһәмияттәге объектларның, төбәк әһәмиятендәге объектларның, җирле әһәмияттәге объектларның урнаштырылу зоналарын билгеләү өчен территорияләрне планлаштыру проектлары эшләнә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан бирелгән мәгълүмат буенча:

Чаллы шәһәрендә 25 территория планлаштыру проекты эшләнде, тагын 3 ТПП эшләү һәм раслау планлаштырыла;

Түбән Кама муниципаль районында 24 ТПП эшләнде, тагын 8 ТПП эшләү һәм раслау планлаштырыла;

Алабуга муниципаль районында 19 ТПП эшләнде, тагын 3 ТПП эшләү һәм раслау планлаштырыла;

Тукай муниципаль районында 24 ТПП эшләнде, тагын 13 ТПП эшләү һәм раслау планлаштырыла;

Менделеевск муниципаль районында 8 ТПП эшләнде, тагын 3 ТПП эшләү һәм раслау планлаштырыла.

*«Шәһәр һәм ландшафтлар».* Чаллы шәһәрендә, Түбән Кама, Алабуга, Тукай, Менделеевск муниципаль районнарында су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу схемалары расланган.

2017–2019 елларга Чаллы шәһәрендә «Челныводоканал» ҖЧҖ тарафыннан су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә инвестиция программасы гамәлгә ашырылды. 2019 елда финанслау күләме 321,5 млн сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан 2020–2024 елларга «ЧаллыВодоканал» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең инвестиция программасы расланды. Инвестиция программасын финанслауның гомуми күләме 500,2 млн сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 2020 елга – 156,1 млн сум.

«Иделне чистарту» федераль проекты кысаларында 2019 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасында һәм Алабуга шәһәрендә көнкүреш һәм сәнәгать юынтык суларын чистарту корылмаларын реконструкцияләү» объектында эшләр башкарылды. I этап финанслауның гомуми лимиты – 795,5 млн сум.

2019 елда 12 җәмәгать урыны төзекләндерелде, шул исәптән Чаллы шәһәрендә – 3, Түбән Кама муниципаль районында – 4, Алабуга муниципаль районында – 3, Тукай муниципаль районында – 1, Менделеевск муниципаль районында – 1.

*«АлаБег» проекты.*

«Бигеш аэропорты – «Алабуга» махсус икътисадый зонасы» Алабуга шәһәре янында Кама елгасы аша күпер белән» югары тизлектәге автомобиль юлы төзү проектын эшләгәннән соң һәм расланганнан соң шәһәр төзелеше документларына төзәтмәләр кертеләчәк.

*Әлмәт агломерациясе*

Үзгәртеп коруларның төп юнәлешләре:

Әлмәт, Бөгелмә һәм Лениногорск шәһәрләренең территорияләрне үстерүне үз эченә алган спутник – торакларында селитеб корылмалар төзүне үстерү;

Әлмәт агломерациясенең бердәм транспорт системасын автобус хәрәкәте нигезендә булдыру: агломерация үзәген тәшкил итүче шәһәрләргә, спутник – торакларга һәм авыл торак пунктларына хезмәт күрсәтүче җәмәгать транспорты челтәре эшен интенсификацияләү һәм үзәкләштерү;

агломерациянең төп шәһәрләрендә һәм муниципальара мәйданчыкларда коммуникация үзәкләрен формалаштыру һәм үстерү;

спорт һәм туристлык комплекслы инфраструктурасын үстерү.

*«Реновация», «Әлмәт агломерациясе җәмәгать урыннары».* 2019 елда агломерациягә кергән муниципаль берәмлекләр түбәндәге социаль-мәдәни объектлар белән тәэмин ителгән:

Әлмәт муниципаль районы – 1 фельдшер-акушерлык пункты (Новотроицкое авылы), 1 табиблык амбулаториясе (Кәләй ст.) төзелде; 1 объект (Кузайкино авылы)

медицина җиһазлары һәм мебель белән җиһазландырылып, капиталь төзекләндерелде;

Бөгелмә муниципаль районы – 1 фельдшер-акушерлык пункты (Ключи авылы); 100 урынга исәпләнгән 1 күпфункцияле үзәк (алга таба-КФҮ) (Яңа Сумароково авылы) төзелде;

Лениногорск муниципаль районы – 1 фельдшер-акушерлык пункты (Иске Иштирәк авылы) төзелде.

Территорияләрне планлаштыру проектларын әзерләү планлаштыру структурасы элементларын билгеләү, планлаштыру структурасы элементларын, капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән федераль әһәмияттәге объектлар, төбәк әһәмиятендәге объектлар, җирле әһәмияттәге объектларның да, планлаштырылган урнаштыру зоналарын үстерү параметрларын билгеләү өчен ТПП эшләнә:

Әлмәт муниципаль районында 136 ТПП расланды, тагын 30 ТПП әзерләү һәм раслау планлаштырыла;

Лениногорск муниципаль районында 40 ТПП расланды, тагын 2 ТПП әзерләү һәм раслау планлаштырыла;

Бөгелмә муниципаль районында 32 ТПП расланды, тагын 25 ТПП әзерләү һәм раслау планлаштырыла.

*«Татарстан Республикасының Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә һәм Азнакай муниципаль районнарында логистик инфраструктура объектларының бердәм челтәрен булдыру».* Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә, Азнакай муниципаль районнары территорияләрендә йөк ташучылар һәм йөк хуҗалары белән логистика объектларының бердәм челтәрен булдыру максатларында хезмәттәшлек планы эшләнде.

*«Әлмәт – Чаллы автомобиль юлын реконструкцияләү».* 2019 елгы юл эшләре программасы буенча түбәндәге участокларда Чаллы – Зәй – Әлмәт автомобиль юлын төзекләндерү буенча эшләр башкарылды: 83+327 – 89+655 (уң як), 89+654 – км 92+254 Әлмәт муниципаль районында 99,578 млн сумлык, 23+840-26+910 км, 41+007-41+400 км, 41+527-43+247 Зәй муниципаль районында 67,982 млн сумга.

**Туристлык-рекреация комплексын үстерү**

Татарстан Республикасы Россия Федерациясе төбәкләре арасында туристлык өлкәсендә беренче урынны алып тора. 2019 елда Татарстан Республикасы «Россиянең гастрономия туризмы» категориясендә National Geographic Traveler Awards 2019 конкурсында икенче тапкыр рәттән җиңүче булды. Премиянең җиңүчеләре ачык онлайн-тавыш бирү барышында билгеләнде.

Республикага туристлар агымының еллык үсеш темпы уртача 8 процент тәшкил итә. Татарстан Республикасына 335 576 чит ил гражданы килгән. 2019 елда туризм өлкәсендә түләүле хезмәтләр 13,9 млрд сум тәшкил иткән.

2019 ел ахырына Татарстан Республикасы территориясендә 101 туроператор теркәлгән, шулардан эчке туризм өлкәсендә 99 туроператор, 65 туроператор – халыкара эчке туризм өлкәсендә, 8 – халыкара тышкы туризм өлкәсендә.

Ел дәвамында Россия төбәге эчендә дә һәм шулай ук өстенлекле чит ил базарларында да Татарстан Республикасының туристлык өлкәсендә мөмкинлекләрен күрсәтү һәм популярлаштыру буенча актив эш алып барылды:

Финляндия Республикасында, Россия Федерациясендә, Иран Ислам Республикасында һәм Кытай Халык Республикасында 8 халыкара туристлык күргәзмәләрендә катнашу: Matka Nordic Travel Fair – 2019 (17 – 20 гыйнвар, Хельсинки шәһ., Финляндия), Tehran International Tourism Exhibition (12 – 15 февраль, Тәһран шәһәре, Иран), «Интурмаркет» (9 – 11 март, Мәскәү шәһәре, Россия), «MITT/ Сәяхәтләр һәм туризм» (12 – 14 март, Мәскәү шәһәре, Россия), «Җәй» (5 – 6 апрель), «Екатеринбург, Россия), BITE/Beijing International Tourism Expo (18 – 20 июнь, Пекин, Кытай),«Ял» (10 – 12 сентябрь, Мәскәү, Россия), Saint Petersburg Travel Hub (11 – 12 сентябрь, Санкт – Петербург шәһәре, Россия). Күргәзмәләрдә республиканың туристлык мөмкинлекләрен, шул исәптән Свияжск утрау-шәһәрен һәм Бөек Болгарны күрсәтүче материалны тәкъдир итү оештырылды, полиграфия материаллары таратылды, виртуаль чынбарлык форматында видеороликлар күрсәтелде, шулай ук Татарстан Республикасының мәдәни-тарихи мирасы һәм туристлык инфраструктурасы турында доклад оештырылды;

Россия Федерациясендә, Иран Ислам Республикасында, Чехия Республикасында, Испания Корольлегендә, Финляндия Республикасында, Кытай Халык Республикасында, Казахстан Республикасында, Үзбәкстан Республикасында, Япониядә, Корея Республикасында һәм Һиндстанда туроператорлар һәм журналистлар өчен 16 тәкъдир итү чарасы һәм роуд-шоу. Татарстан Республикасының төп туристлык үзәкләре, аларның инфраструктурасы һәм транспорт логистикасы презентацияләре узды;

Россия Федерациясе, Япония, Германия Федератив Республикасы, Австрия Республикасы, Финляндия Республикасы, Испания Корольлеге, Америка, Канада, Кытай Халык Республикасы, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Казахстан һәм Венгриядән 222 туроператор һәм журналистлар өчен 16 реклама-мәгълүмат турлары;

Татарстан Республикасының Иран Ислам Республикасында, Төркия Республикасында, Россия Федерациясендә һәм Казахстан Республикасында 6 реклама кампаниясе.

Шулай ук төбәкара маршрутларны таныту буенча эш дәвам ителде.

«Россиянең мәдәни брендлары» чарасы кысаларында Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән берлектә, 2019 елның 7–8 ноябрендә Казан шәһәрендә милли мәдәни-белем бирү проектларын («Алтын балдак», «Император маршруты», «Бөек Идел юлы» һ.б.) тәкъдир итте.

Чарада Туристлык буенча федераль агентлык җитәкчесе урынбасары С.Е. Корнеев, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының Музейлар департаменты директоры урынбасары Н.В. Чечель, Россия Федерациясе субъектларының мәдәният һәм туристлык өлкәсендә башкарма хакимият органнары җитәкчеләре, Россиянең зур музей һәм музей-тыюлыклары директорлары, шулай ук Россия Федерациясенең 13 төбәгеннән 130 артык делегат катнашты.

«Россияне танытучы маршрутларда музейлар» пленар сессиясендә «Бөек Идел юлы» төбәкара туристлык маршрутын тәкъдир итү булды.

Чара барышында экспертлар милли музей маршрутларын гамәлгә ашыру юнәлешләре һәм перспективалары, аларны төрле дәрәҗәдәге музейлар белән кушу мөмкинлекләре, шулай ук потенциаль партнерлар белән хезмәттәшлек нәтиҗәсендә таныту турында фикер алыштылар.

«Бөек Идел юлы» төбәкара туристлык маршруты шулай ук Екатеринбург һәм Мәскәү шәһәрләрендә «Россиянең мәдәни брендлары» проекты кысаларында тәкъдим ителде.

«Татарстан Республикасы туристлыкны үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма «Ак Барс» Банк гавами акционер җәмгыяте белән берлектә Tatarstan Tourist Pass мобиль кушымтасы булдырылды. Кушымтаны Google Play һәм AppStore аша күчерергә була. Шулай ук бушлай виртуаль банк картасын эшләп чыгару ярдәмендә кулланучылар туристлык инфраструктурасы объектларына ташламалар яки бонуслар алырга мөмкин.

2019 елда Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты республика территориясендә үткәрелә торган һәм Татарстаннан читтә күпсанлы туристларны җәлеп итә торган вакыйга-чараларны бергәләп финанслау механизмын сынап карады. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм тышкы туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия эшчәнлекне тормышка ашыручы оешмаларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 724 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм тышкы туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия эшчәнлекне тормышка ашыручы оешмаларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча конкурс үткәрелде. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына Казан шәһәреннән һәм республиканың 8 муниципаль районыннан барлыгы 28 млн сумга 26 гариза керде. Конкурс комиссиясе тарафыннан 9 проектка 5 млн сумлык ярдәм күрсәтелде.

***Туристлык өлкәсендә эшлекле чаралар***

2019 елның 11 – 13 апрелендә «Туристлык һәм спорт» дип аталган 24 нче халыкара махсуслаштырылган күргәзмә узды, анда гомуми мәйданы 2000 кв метр булган 155 экспонент катнашты, Россиянең 20 төбәге һәм курорты, шулай ук Беларусь Республикасы, Казахстан Республикасы, Төркия Республикасы, Кытай Халык Республикасы тәкъдим ителде.

2019 елның 23 – 25 октябрендә Казан шәһәрендә кунакханә һәм ресторан бизнесы Horeca by Kazan 2019 IV Халыкара күргәзмәсе узды. Күргәзмәгә килүчеләр һәм катнашучылар арасында рестораторлар, отельерлар, менеджерлар һәм идарәчеләр, шеф-поварлар, кондитерлар, барменнар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре һәм блогерлар, Россия һәм халыкара экспертлар, товар сатучылар һәм җитештерүчеләр бар иде. Күргәзмәдә Кырым Республикасыннан, Самара өлкәсеннән, Марий Эл Республикасыннан, Алтай краеннан, Тыва

Республикасыннан, Санкт – Петербург шәһәрләреннән, Мәскәү шәһәреннән, Екатеринбургтан, Чиләбе шәһәреннән, Новосибирск шәһәреннән, Мурманск шәһәреннән, Казахстан Республикасыннан, Кыргызстан Республикасыннан, Монголия, Төркия Республикасыннан, Төньяк Кипрдан 5 меңнән артык кеше катнашты.

2019 елның 11 октябрендә Казанда WHERETOEAT TATASTAN 2019 милли ресторан премиясен тапшыру тантанасы узды. Оештыру комитеты составына Татарстан Республикасының ресторан бизнесы буенча 100 эксперт керде. Җиңүчеләр «Татар кухнясының иң яхшы рестораны», «Ел шеф-повары», «Казанның иң яхшы 10 рестораны», «Ел сомельесы», «Елның иң яхшы ресторан күзәтүчесе», «Массакүләм мәгълүмат чаралары тәкъдиме» номинацияләрендә билгеләнде.

2019 елның 4 октябрендә Казан шәһәрендә Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле каршындагы советның эчке һәм тышкы туризмны үстерү мәсьәләләренә багышланган утырышы узды. Совет әгъзалары һәм чакырылган кунаклар туристлык тармагының хәзерге торышы, аны федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә үстерү буенча тәкъдимнәр һәм чаралар турында фикер алышты. Утырыш нәтиҗәләре буенча туристлык өлкәсендә законнарны камилләштерү һәм стратегик документларны гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр эшләнде.

2019 елның 23 – 25 октябрендә «Киләчәк юнәлешләре» халыкара туристлык форумы оештырылды, ул Туристлык буенча федераль агентлык һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәмендә узды. Эшлекле өлешне оештыручылардан берсе булып Яңа проектларны таныту буенча стратегик инициативалар агентлыгы һәм Profi.Travel медиахолдингы тора. Форумда табигать территорияләрендә экологик туризмны үстерү һәм туризмда цифрлаштыру һәм маркетингның иң яхшы практикалары каралды. Форумда 30 дан артык Россия һәм халыкара спикерлары, Россиянең 46 төбәгеннән һәм 8 якын һәм ерак чит илдән 1000нән артык делегат катнашты.

***«WorldSkills» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионаты***

2019 елның 22 – 27 август көннәрендә Казанда WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын уздыру кысаларында чемпионат кунаклары өчен экскурсия хезмәте күрсәтү оештырылды. Чемпионатның рәсми лицензиаты – «Казан шәһәренең туристлык-мәгълүмат үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.

«Клиентлар төркемнәре» категориясе өчен экскурсия хезмәте 2019 елның 18 һәм 20 августында оештырылды. Катнашучыларның гомуми саны 4 400 кеше тәшкил итте, автобусларның һәм экскурсоводларның саны һәр көнгә 55әр берәмлек иде. Ул Казан шәһәре тарихында иң зур экскурсияләрнең берсе булды, Казан шәһәренең тарихи үзәге белән танышу, шулай ук Казан Кремленә һәм Иске Татар бистәсенә экскурсияне үз эченә алды.

Чемпионат кысаларында шулай ук «Кунак» категориясендәге 6 800 кеше өчен экскурсия хезмәте дә оештырылды.

WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын уздыру чорында Казанның тарихи үзәгендә: Петербург, Бауман һәм К. Нәҗми урамнары, 1 Май мәйданы, Г. Камал исемендәге театр мәйданы, «Казан-1» тимер юл вокзалында мәгълүмати ярдәм күрсәтү шатерлары оештырылды. Биредә туристлар өчен волонтерлар эшләде, алар һәм Россия һәм чит ил туристларына шәһәр һәм аның истәлекле урыннары турында тулы мәгълүмат бирде.

Кунакларны мәгълүмати яктан тәэмин итү өчен биш телдә (рус, инглиз, алман, испан, француз) карталар чыгарылды, аларның гомуми тиражы 154 мең данә тәшкил итте. Шатерда шәһәрнең һәр кунагы бушлай Казан шәһәренең картасын, Татарстан Республикасының төп истәлекле урыннары турында буклет һәм башка кирәкле мәгълүматны ала алды.

**Мәдәни мирас**

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәгеләр урнашкан:

1) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестрына кертелгән 663 мәдәни мирас объекты, шул исәптән:

447 федераль әһәмияттәге объект, шул исәптән 281 – археологик мирас объекты;

876 – төбәк әһәмиятендәге;

340 – җирле (муниципаль) әһәмияттәге;

2) 3 522 элек билгеле булмаган мәдәни мирас объекты, шул исәптән:

795 архитектура һәм шәһәр төзелеше объекты, мемориаль объектлар һәм тарих объектлары;

2 727 археологик мирас объекты;

3) тарихи әһәмияткә ия һәм шәһәр территориясен формалаштыручы 424 объект;

4) 13 тарихи җирлек, аларның:

2 – федераль әһәмияттәге;

11 – төбәк әһәмиятендәге;

5) ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектлары:

Казан Кремле тарих-архитектура комплексы;

Болгар тарих-археология комплексы;

Успение соборы һәм Свияжск утрау-шәһәрчеге монастыре.

2019 елда тармакны инвентаризацияләү эше дәвам итте: 372 объект тикшерелде, техник хәл актлары төзелде, 68 дәүләт саклавына алу йөкләмәсе әзерләнде һәм расланды, 28 объект төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары буларак дәүләт саклавына куелды, 47 объект буенча территорияләрдән файдалану чикләре һәм режимнары расланды, 344 объект буенча расланган чикләр турында мәгълүмат файдалануга билгеле бер чикләүләр кертеп, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертелде.

Археология һәйкәлләрен саклау мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә. 2019 елда 4 964 күчемсез милек объектына (җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары), аларның мәдәни мирас объектлары булып тору-тормавына тикшерү уздырылды. Хуҗалык кулланылышына тапшырыла торган җир

кишәрлекләрендә мәдәни мирас объектларын саклау шартлары буенча чикләүләр булу турында 1 386 бәяләмә әзерләнде.

2019 елда Болгар шәһәрендә казу эшләре башланып китте. Нәтиҗәдә, Болгар дәүләтенең төзелә башлаган чорына, монголлар яулап алганга кадәрге чор һәм Алтын Урда чорына караган объектлар табылды.

Җир кишәрлекләренә тарихи-мәдәни экспертизалар уздыру һәм фәнни археологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә элек билгеле булмаган 14 археологик мирас объекты ачыкланды һәм дәүләт саклавына алынды. Бу исемлеккә Идел (Бакалда) пристаньларына бара торган 700 метрга якын озынлыктагы таш түшәлгән юл керде, биредә Идел елгасының саегуы нәтиҗәсендә фәнни-архитектура тикшеренүләре алып бару мөмкинлеге туды.

Аксубай муниципаль районында нефтьүткәргеч уздыру планлаштырыла торган участокларны тикшерү барышында археологлар тарафыннан элек билгеле булмаган «X–XIV гасырлар Иске Кыязлы каберлеге» дип аталган объектны табылды.

Тарихи мохиттә һәйкәлләрне саклауны тәэмин итүнең мөһим шарты булып, саклау зоналарын билгеләү һәм алар турында мәгълүматларны кадастр исәбенә алу органына кертү тора.

2019 елда түбәндәгеләр оештырылды:

Казан шәһәрендә урнашкан объектларны саклау берләштерелгән зонасына төзәтмәләр кертү;

«Казан кремле ансамбле, XVI–XVIII гасырлар» федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектын саклау зоналарының яңа проектын эшләү;

Болгар шәһәре территориясендә объектларны саклау зоналарын эшләү.

Моннан тыш, «Казан Кремле тарих-архитектура комплексы» бөтендөнья мирасы объектының буфер зонасы картасын һәм чикләрен актуальләштерү эше башланды.

Шулай ук 2019 елда дистәләрчә мәдәни мирас объекты буенча төзекләндерү-реставрация эшләрен документаль һәм методик яктан тәэмин итү буенча эш дәвам иттерелде. Казан Кремле территориясендә масштаблы эшләр дәвам итте. Аварияне кисәтү буенча эшләр комплексы, шулай ук «Административ биналар һәм консистория, XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башы» объектындагы фасадларны реставрацияләү эшләре башкарылды.

10 ел дәвамында барган реставрация эшләре тәмамланганнан соң быел Свияжск утрау-шәһәрчегендәге Успение соборы ачылды. 2019 елның августында Казан һәм Татарстан митрополиты Феофан катнашында Бөек изгеләндерү тантанасы узды.

2019 елда Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә булышлык итү фонды ярдәме белән Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авылында 1769 елда республикадагы беренче таш мәчеттә реставрация эшләре башланды.

Казан шәһәренең Юдино бистәсендәге Тимерьюлчылар мәдәният сараенда, Сәетгалиев исемендәге Мәдәният сараенда, Алафузов театры бинасында һәм Сандецкий утарында төзекләндерү-реставрация эшләре актив рәвештә дәвам итә. Петропавловск соборында һәм Әҗем мәчетендә реставрация эшләре дәвам итә.

Узган ел М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасы интерьерларын һәм инженерлык системаларын төзекләндерү-реставрация эшләре башкарылды. «Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе биналарында (1900 – 1904 елларда төзелгән) аварияне кисәтү эшләре башкарылды. күргәзмәсе, Казан укытучылар семинариясе бинасында (1873 елда төзелгән) авариягә каршы беренче чираттагы эшләр башкарылды.

2019 елда язучы Шәриф Камал музее-фатирында урнашкан Татар әдәбияты тарихы музеенда төзекләндерү-реставрация эшләре тәмамланды.

2019 елда хосусый инвестицияләр ярдәмендә яңадан торгызылган «Торак йорт, 19 гасыр башы» мәдәни мирас объектында Казан иконасы музее ачылды.

Татарстан Республикасында агач архитектура сәнгате объектларына аерым игътибар бирелә. 2019 елның гыйнварында «Мәчет, XIX гасыр» (Балык Бистәсе муниципаль районы) һәм «Михаил-Архангельск чиркәве, 1757 ел» (Кама Тамагы муниципаль районы) кебек агач архитектурасы уникаль һәйкәлләрендә төзекләндерү-реставрация эшләре башланды. Эшләр Вологда шәһәреннән агач эшләре остасы, архитектор, югары категорияле реставратор Александр Попов җитәкчелегендә алып барыла, ул «Реставрация үзәге – архитектура, җитештерү, укыту» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җитәкли. Реставрация эшләре борынгы технологияләр буенча алып барыла, осталар максималь рәвештә барлык элементларның төп нөсхәсен саклап калырга тырыша.

Республикада агач архитектура сәнгатен үстерү темасы, шул исәптән Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан 2019 елның июнендә оештырылган агач архитектура һәйкәлләрен саклау буенча ведомство проектын исәпкә алып, комплекслы рәвештә карала.

2019 елда «Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектлары» геомәгълүмат системасын тормышка ашыру буенча эш дәвам итә. 2019 елда геопорталга 246 археология мирасы объекты, 798 мәдәни мирас объекты (тарихи һәм шәһәр төзелеше һәйкәлләре), 577 мәдәни мирас объекты территориясе һәм Казан шәһәренең тарихи җирлеге чикләре турында белешмәләр кертелде.

Мәдәни мирас объектларының торышына, аларны карап тотуга, саклауга һәм кулланылышына дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү барышында 148 объектка, шул исәптән 32 объектка прокуратура органнары белән бергә урынга барып тикшерү уздырылды, мәдәни мирас объектларының торышын контрольдә тоту буенча 59 чара һәм аларны системалы рәвештә күзәтеп тору буенча 81 чара үткәрелде.

Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү, аларга мәгълүмат бирү һәм хокукый белемнәрен арттыру, мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә хокукый практика үзенчәлекләрен аңлату максатында квартал саен мәдәни мирас объектлары милекчеләре һәм арендаторлары белән тармакның иң мөһим мәсьәләләре буенча ачык фикер алышулар үткәрелә.

2019 ел республика өчен фәнни һәм гамәли эчтәлекле вакыйгаларга бай булды. 2019 елның маенда Казанда «Архитектура мирасы – 2019» II Бөтенроссия фестивале узды. Фестивальнең эшлекле программасы 60 тан артык чараны үз эченә

алды, аларда Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән 200ләп спикер катнашты. «Архитектура мирасы – 2019» фестивале кысаларында Россия һәм Греция арасында гомуми мәдәни мирасны саклау, арттыру һәм үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек турында меморандумга кул куелды.

Узган елның шулай ук «Астрономия һәм дөнья мирасы» халыкара форумы да республика өчен әһәмиятле вакыйга булды, ул Германия Федератив Республикасы, Греция Республикасы, Болгария Республикасы һәм Италия Республикасы, Пакистан һәм Монголия Республикасы, шулай ук Беларусь, Украина, Молдова Республикасы, Үзбәкстан Республикасы, Таҗикстан Республикасы, Кыргызстан Республикасы, Әрмәнстан Республикасы һәм башка илләрдән дөньякүләм танылган галимнәр катнашында узды.

***Экологик зонада урнашкан торак пунктларның көнкүреш һәм яңгыр сулары агынтылары чистарту корылмаларын һәм су чыгару челтәрләрен реконструкцияләү һәм төзү***

2019 елда республиканың муниципаль берәмлекләрендә көнкүреш юынтык суларын агызу һәм чистарту корылмалары челтәрен һәм яңгыр сулары агу урыннарын реконструкцияләү һәм төзүне тәэмин итү кысаларында чаралар башкарылды: Зеленодольск муниципаль районында – 2 объект һәм 1 проект-тикшеренү эше (алга таба – ПТЭ), Югары Осланда – 1 ПТЭ, Лаешта – 1 объект, Спас районында – 3 объект, Тәтеш районында – 1 объект һәм 1 ПТЭ, Кама Тамагында – 2 объект һәм 1 ПТЭ, Балык Бистәсе районында – 1 объект, Мамадыш районында – 1 объект һәм 1 ПТЭ.

***«Яшел стандартлар» ны куллану һәм үстерү***

Төзелеш объектларының экологик яктан иминлеген тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүдә төп юнәлешләрнең берсе - «яшел стандартлар»ны популярлаштыру. «Яшел» төзелешнең максаты – кеше һәм икътисад өчен уңайлы әйләнә-тирә мохит булдыру, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны минимальләштерү һәм тулаем алганда тотрыклы үсеш.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында «яшел» төзелеш алгарышлы үсеш стадиясендә.

«Яшел» төзелешнең үсеш юнәлешләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 930-б номерлы боерыгы нигезендә билгеләнгән. 2014 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2014 елның 1 мартындагы 402-б номерлы боерык кабул ителде, аның нигезендә Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына күчемсез милек объектларын төзү, аларны реконструкцияләү, капиталь төзекләндерү һәм эксплуатацияләү эшчәнлеген башкаручы коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар, шәхси эшкуарлар белән аңлату эшләре алып бару, күчемсез милек объектларын проектлауны оештырганда «яшел стандартлар»ны куллануның максатка ярашлы булуы һәм гамәлдәге ирекле экологик сертификацияләү системалары турында аңлату эшләре алып бару эше йөкләнде.

Әлеге боерыкларны үтәү йөзеннән «Татарстан Республикасының Экологик картасы» геомәгълүмат системасында (алга таба – «Татарстан Республикасының

Экологик картасы» ГМС) «яшел» күчемсез милек объектларын үстерү һәм популярлаштыруга юнәлтелгән «Яшел стандартлар һәм технологияләр» системасын тулыландыру эше тормышка ашырыла. Әлеге форматта картадан файдаланучылар түбәндәгеләр турында мәгълүмат ала:

Татарстан Республикасы территориясендә «яшел стандартлар» кулланылган эксперименталь объектлар турында, шул исәптән әлеге стандартларга туры килү сертификатлары бар;

әлеге өлкәдә эшләр башкаручы үзәкләр турында.

«Татарстан Республикасының Экологик картасы» ГМСда «яшел стандартлар» принцибын куллана торган объектлар: Иннополис шәһәре, «Химград» технополисы территориясендә энергияне сакчыл куллану йорты, «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыятенең фәнни-техник үзәге, «Сувар Плаза» сәүдә-офис үзәге, Казан зоопаркы, Чаллы шәһәрендәге энергияне сакчыл куллану йорты, «Красное яблоко» торак комплексы, «ГоркиПарк» сәүдә үзәге, «Современник» торак комплексында 0010 нчы йорт, «Казан Арена» футбол стадионы, «А1» бизнес үзәге, Зәй шәһәрендәге «Акыллы йорты», «Казан» халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте, «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәге. Шулай ук «Свияжск утрау-шәһәре» музей-тыюлыгы территориясендә урнашкан «Татар бистәсе» агач археологиясе музее турында мәгълүматларны кертү планлаштырыла.

«Яшел» төзелеш икътисадый үсешкә ярдәм итә, киң күләмле һәм шулай ук төбәк күләмендәге проблемаларны да хәл итә, әйләнә-тирә мохит ресурсларын рациональ кулланырга мөмкинлек бирә, халыкның тормыш сыйфатын яхшырта.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 1 мартындагы 402-б номерлы боерыгы нигезендә «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (алга таба – КДАТУ) базасында Татарстан Республикасы территориясендә «яшел стандартлар» кертүгә фәнни-методик ярдәм күрсәтү, шулай ук күчемсез милек объектларына экологик сертификацияләр бирүнең халыкара системаларын адаптацияләү буенча эшләрне координацияләү өчен «Яшел стандартлар» буенча компетенцияләр үзәге» структур бүлекчәсе төзелде. Эшләнгән концепция кысаларында «яшел стандартлар» буенча компетенцияләр проекты биш юнәлеш буенча тормышка ашырыла: белем бирү үзәге, фәнни үзәк, сертификацияләр бирү органы, демонстрация үзәге һәм «яшел стандартлар»ны популярлаштыру үзәге.

Аның кысаларында «Биналарда электр энергиясен сакчыл куллану һәм электр энергиясенең нәтиҗәлелеге» магистр программасы (2015 ел) эшли башлады, «Яшел стандартлар»ны сертификацияләү һәм популярлаштыру үзәге (2015 ел), «Төзелештә инженерлык системалары үзәге» фәнни-белем бирү үзәге («Systems/системалар» фәнни үзәге) (2018–2019 еллар) ачылды.

«Яшел стандартлар» буенча компетенцияләр үзәге халыкара һәм Россиядәге «яшел» стандартлар буенча күчемсез милек объектларын сертификатлаштыру мөмкинлегенә ия.

Проект кысаларында 2019 елның 17 гыйнварында «Systems/системалар» төзелешендә яңа инженер системалары үзәге (алга таба – үзәк) ачылды. Үзәк «Җылылык-газ белән тәэмин итү, вентиляция, биналарны, корылмаларны һәм торак пунктларны су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу», «Торак хуҗалыгы

һәм коммуналь инфраструктура» юнәлешләре, шулай ук төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кадрларны һөнәри яктан яңадан әзерләү өчен белем бирү һәм фәнни компетенцияләрне берләштерә. Үзәктә электр энергиясен нәтиҗәле файдаланучы инженер системалары төзү буенча яңа эшләнмәләр һәм проектларны фәнни-техник яктан тәэмин итү инфраструктурасы булдырылды.

Үзәкнең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасында төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә компетенцияләрне формалаштыру, кадрлар потенциалын үстерү;

ресурсларны саклауның яңа технологияләрен һәм материалларын тикшерү, сынау һәм анализлау;

биналарның инженерлык системаларында ресурсларны саклау өлкәсендә яңа чишелешләрне һәм техник яңалыкларны күрсәтү.

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты каршындагы үзәк базасында 2019 елда Татарстан Республикасы, Ульяновск шәһәре, Ижевск шәһәрләренең проект һәм монтажлау оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен төзелешне проектлаштырганда ресурсларны саклау һәм энергияне сакчыл тоту мәсьәләләре буенча түбәндәге темаларга 4 уртак семинар оештырылды һәм үткәрелде:

«Бассейннар һәм боз сарайлары өчен климатик җиһазларда заманча эшләнмәләр» («ТехВент4 ҖП ҖЧҖ фирмасы белән берлектә);

«Federica Bugatti маркалы җылылык техникасы җиһазлары» («Федерика Бугатти» ҖЧҖ фирмасы белән берлектә);

«Federica Bugatti маркалы электр энергиясеннән нәтиҗәле файдалану эшләнмәләре» («Федерика Бугатти» ҖЧҖ фирмасы белән берлектә);

«Airway махсус җиһазларының төп үзенчәлекләре һәм компаниянең яңа эшләнмәләре» («ТехВент» ҖП ҖЧҖ фирмасы белән берлектә).

***«Идел-Кама агымы» экозонасы флагман проекты***

Республикада килүче туристлар агымы уңай динамикада һәм биредә ел саен уртача 8 процент үсеш күзәтелә. 2019 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасына Россиядән һәм башка дәүләтләрдән 3,6 миллионнан артык турист килде (2013 елда – 2,2 млн кеше). Татарстанга килүче туристлар агымының күпчелеге Россия гражданнарыннан тора – 90 процентка якын, 10 процентка якыны – чит ил туристлары.

Татарстан Республикасы территориясендә конкурентлыкка сәләтле туристлык продукты булган дөнья дәрәҗәсендә үсеш алган туристлык дестинациясен булдыру максатларында «Идел буе Болгарстаны» комплекслы инвестицион проекты тормышка ашырыла.

2019 елның ноябрендә әлеге проект Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 316 номерлы карары белән расланган «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» дәүләт программасының «Туристлык» ярдәмче программасы чаралары составына керде.

Федераль бюджеттан чыгымны каплау срогы озак вакытка исәпләнгән тәэмин итү инфраструктурасы объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә) уртак финанслауга субсидияләр якынча 481,5 млн сум тәшкил итте (2020 ел – 96,3 млн сум, 2021 ел – 244,2 млн сум, 2022 ел – 141 млн сум).

# САТУ БАЗАРЛАРЫ

## Тышкы икътисадый элемтәләрне үстерү

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең тышкы икътисадый эшчәнлегендә актив катнаша, тышкы сәүдә әйләнеше күләме буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында 6 нчы урынны һәм Идел буе федераль округында 1 нче урынны алып тора.

2019 елда Татарстан Республикасының тышкы сәүдә әйләнеше, башлангыч мәгълүматлар буенча, 15 720,1 млн АКШ доллары тәшкил итте һәм 2018 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 3 611,5 млн АКШ долларына яки 18,7 процентка кимегән.

Товарлар экспорты 18,9 процентка кимеде һәм 12 555,3 млн АКШ доллары тәшкил итте. Товарлар импорты 17,9 процентка кимеде, 3 164,8 млн АКШ доллары тәшкил итте.

Татарстан Республикасының тышкы сәүдә балансында уңай сальдо күзәтелде – 9 390,5 млн АКШ доллары, ул 2018 ел белән чагыштырганда 2 230,9 млн АКШ долларына кимеде.

**Татарстан Республикасының тышкы сәүдә динамикасы, процентларда**




Татарстан Республикасының сәүдә партнерлары булып 163 ил, шулардан 139 ил белән экспорт сәүдә операциясе, 122 ил белән импорт сәүдә операцияләре башкарылды.

2019 елда республиканың иң эре сәүдә партнерлары булып түбәндәгеләр тора:


экспорт операцияләре буенча: Польша Республикасы (15,9 процент), Нидерланд Корольлеге (13,5 процент), Беларусь Республикасы (6,5 процент), Германия Федератив Республикасы (6,2 процент), Бөекбритания һәм Төньяк Ирландия Берләштерелгән Корольлеге (5,2 процент), Казахстан Республикасы (4,3 процент), Венгрия (4 процент), Словакия Республикасы (4 процент), Чехия Республикасы (3,4 процент), Финляндия Республикасы (3 процент), Болгария Республикасы (2,9 процент), Төркия Республикасы (2,2 процент);

импорт буенча: Германия Федератив Республикасы (22 процент), Кытай

Халык Республикасы (13,3 процент), Америка Кушма Штатлары (8,5 процент), Беларусь Республикасы (7,1 процент), Төркия Республикасы (6,6 процент), Италия Республикасы (5,2 процент), Франция Республикасы (2,5 процент), Бельгия Корольлеге (1,9 процент), Испания Корольлеге (1,9 процент).


2019 ел йомгаклары буенча экспортның товар структурасында нефть – 41,3 процентны, нефть продуктлары – 33,1 процентны, химия сәнәгате продукциясе – 16 процентны, машина төзелеше продукциясе 4,4 процентны алып тора.

**2019 елда Татарстан Республикасы экспортының товар структурасы**




2019 елда, 2018 ел белән чагыштырганда, циклик углеводородлар экспорты 1,8 тапкырга, пластмасса һәм аның эшләнмәләре – 4,1 процентка, төсле металл – 11,1 процентка, йөк автомобильләре – 17,9 процентка (1925 тән 2269 данәгә) артты. Шул ук вакытта нефть экспорты – 11,1 процентка, нефть продуктлары – 20,5 процентка, минераль ашламалар экспорты – 2,8 процентка (680,6 дан 661,3 мең тоннага кадәр), шиннар – 13,5 процентка, агач һәм агач эшләнмәләр – 10,4 процентка (275 дән 246,3 мең тоннага кадәр), синтетик каучук – 2,3 процентка, җиңел автомобильләр – 89,1 процентка (790 данәдән 86 данәгә кадәр) кимеде.

**2019 елда Татарстан Республикасы импортының товар структурасы**



Импортның товар структурасында машина төзелеше продукциясе (64,8 процент) һәм химия сәнәгате продукциясе (19,5 процент) әйдәп баручы урында тора.

2019 елда, 2018 ел белән чагыштырганда, органик химик кушылмалар импорты 1,6 процентка, башка химик продуктларны – 6,3 процентка, пластмасса һәм аның эшләнмәләре – 34,9 процентка, натураль каучук – 11,3 процентка, төсле металл – 14,7 процентка, йөк машиналары – 28 процентка (407дән 521 данәгә) артты. Шул ук вакытта минераль ягулык импорты 13 процентка, җиңел автомобильләр 68,5 процентка (445 данәдән 140 данәгә кадәр) кимеде.

***Халыкара эшчәнлек***

Татарстан Республикасы халыкара дәрәҗәдәге вакыйгаларда актив катнаша.

2019 елда 200 дән артык халыкара чара, шул исәптән халыкара кооперацияне үстерүгә юнәлдерелгән рәсми визитлар һәм эшлекле сәфәрләр, бизнес-форумнар оештырылды.

2019 елда Татарстан Республикасына 125 чит ил делегациясе килде, шул исәптән: Төрекмәнстан Президенты Г.М. Бердымөхәммәдов, Словакия Республикасы Парламенты (Милли Совет) рәисе А.Данко, Беларусь Республикасы Сәнәгать министры П.В. Утюпин, КХР Дәүләт Советы әгъзасы Ван Юн, Хунань провинциясе Губернаторы Сюй Дачжэ, Төркия Палаталар һәм биржалар берлеге президенты Р. Хисарджиклыоглы, Швейцариянең Икътисад буенча статс-секретаре М.Г. Инайхен-Фляйш, Франциянең Хезмәт министры Мюриель Пенико, Белоруссия Республикасының Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле вәкиле В.И. Семашко, Латвия Республикасының Россия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле Илчесе М.Риекстиньш, Төркиянең Сәнәгать һәм технологияләр министры М.Варанк, Вьетнам Социалистик Республикасының Милли Җыелышы рәисе Нгуен Тхи Ким Нган, Тюрингиянең (Германия) Икътисад, фән һәм цифрлы технологияләр министры Вольфган Тифензее, Баварияның (Германия) Икътисад, төбәк үсеше һәм энергетика министры Х.Айвангера визиты булды.

Татарстан Республикасы делегацияләренең, шул исәптән Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, Германия Федератив Республикасына (Саксония, Бавария һәм Тюрингия җирләре), Чехия Республикасына, Таҗикстан Республикасына, Француз Республикасына, Нидерландия Корольлегенә, Дания Корольлегенә, Төркмәнстанга, Төркия Республикасына, Финляндия Республикасына, Кытай Халык Республикасына, Үзбәкстан Республикасына, Словакия Республикасына, Беларуссия Республикасына 30дан артык күчмә визиты оештырылды.

2019 елда даими эшләүче биш эшче төркем утырышы уздырылды: икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек буенча Төрекмәнстан-Татарстан эш төркеме, Татарстан – Тюрингия эш төркеме, сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне җайга салу буенча Татарстан-Чехия уртак эш төркеме, Татарстан Республикасы һәм Үзбәкстан Республикасы арасында хезмәттәшлекне үстерү буенча эшче төркем, Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе) һәм Беларуссия Республикасы хезмәттәшлеге буенча эшче төркем.

*Татарстан Республикасының чит илләрдәге вәкиллекләре эшчәнлеге*

Татарстан Республикасының вәкаләтле, даими һәм сәүдә-икътисадый вәкиллекләре эшчәнлеге Татарстан Республикасының тышкы икътисадый мәнфәгатьләрен тәэмин итүдә нәтиҗәле инструмент булып тора.

2020 елның 1 гыйнварына якын һәм ерак чит илдә Татарстан Республикасының 15 вәкиллеге (4 – вәкаләтле, 1 – даими, 10 – сәүдә-икътисадый) эшли.

Татарстан Республикасының чит илләрдәге вәкиллекләре системасы әлеге илләрдәге ватандашлар белән хезмәттәшлекнең төп механизмы булып тора. Вәкиллек урнашкан илдәге татар диаспорасына даими ярдәм күрсәтелә. Татар милли мәдәниятен пропагандалау максатыннан милли бәйрәмнәр үткәрелә.

*Хезмәттәшлекнең килешү базасы*

Чит илләр белән шартнамә базасын яңарту өчен 2019 елда түбәндәге килешүләргә кул куелды, шул исәптән:

Татарстан Республикасы һәм Саксония арасында хезмәттәшлек турында килешү (2019 елның 19 феврале);

Татарстан Республикасының Лейпциг шәһәрендә (Германия Федератив Республикасы) вәкиллеген ачу турында килешү (2019 елның 13 мае );

Татарстан Республикасы Хөкүмәте (Россия Федерациясе) һәм Чунцин шәһәре Халык Хөкүмәте (Кытай Халык Республикасы) арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни-гуманитар хезмәттәшлек турында килешү (2019 елның 23 мае);

Чехия Республикасы һәм Татарстан Республикасы арасында сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне җайга салу буенча уртак эш төркеменең җиденче утырышы беркетмәсе (2019 елның 20 июне);

Россия Федерациясе һәм Беларуссия Республикасы хезмәттәшлеге буенча эш төркеменең җиденче утырышы беркетмәсе (2019 елның 1 октябре);

Татарстан Республикасы Хөкүмәте (Россия Федерациясе) һәм Минск өлкә башкарма комитеты (Беларусь Республикасы) арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль-мәдәни һәм гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлек турында килешү (2019 елның 12 декабре).

***Төбәкара эшчәнлек***

Төбәкара эшчәнлекнең төп юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасының төбәкара эшчәнлеген дәүләт җайга салуы инструменты буларак хөкүмәтара килешүләр;

республика предприятиеләре вәкиллекләрен, филиалларын оештыру;

татар милли-мәдәни автономияләре һәм татар җәмгыятьләре белән үзара хезмәттәшлек;

күргәзмә-тәкъдим итү чараларын үткәрү.

Төбәкара багланышлар өлкәсендә 2019 елда 80ләп чара үткәрелгән. Алар арасында Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы делегацияләренең Краснодар краена, Санкт-Петербург шәһәренә, Башкортостан Республикасына, Әстерхан, Төмән, Ростов өлкәләренә, Ненец

автоном округына визитларын билгеләп үтәргә кирәк, алар барышында берничә хөкүмәтара документка кул куелды.

Татарстан Республикасына Карелия, Ингушетия, Калмыкия, Кырым, Төмән, Ростов, Омск, Чиләбе, Әстерхан, Томск, Липецк өлкәләре, Алтай крае, Еврей автономияле өлкәсе һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләре вәкилләре визитлары булды.

*Россия Федерациясе субъектлары белән хезмәттәшлекнең шартнамә базасы*

2020 елның 1 гыйнварына Республика Россия Федерациясенең 76 субъекты белән шартнамәләргә нигезләнгән мөнәсәбәтләр урнаштырды. Килешүләр текстлары һәм аларга теркәлгән беркетмәләр Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтындагы http://mpt.tatar.ru// «Эшчәнлек/Хезмәттәшлек/Россия Федерациясе төбәкләре белән хезмәттәшлек/Хезмәттәшлек турында килешүләр» бүлегендә урнаштырылган.

2019 елда Россия Федерациясе субъектлары белән 20 килешү һәм чаралар планына кул куелды (Пенза, Түбән Новгород, Калуга, Новосибирск, Төмән, Самара, Омск һәм Белгород өлкәләре һәм Башкортостан Республикасы, Ненец автоном округы һәм Еврей автономияле өлкәсе белән килешүләр, Түбән Новгород, Әстерхан, Новосибирск, Ростов, Кемерово һәм Архангельск өлкәләре, Красноярск крае, Карелия һәм Башкортостан республикалары белән чаралар планы).

*Татарстан Республикасы вәкиллекләренең Россия Федерациясе төбәкләрендә эшчәнлеге*

2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының Россия Федерациясе төбәкләрендә 8 вәкиллеге эшли. Аларның төп бурычлары: Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый мәнфәгатьләрен яклау һәм эшчәнлек алып барган төбәкләрендә үзара файдалы хезмәттәшлек алып бару, шулай ук Татарстан Республикасы икътисадының өстенлекле юнәлешләрен саклап калу өчен потенциаль партнерлар һәм инвесторлар табу.

*Күргәзмәләр уздыру эшчәнлеге*

2019 елда 25 конгресс-күргәзмә чарасы уздырылды.

Шулардан иң мөһим чаралар булып түбәндәгеләр тора:

Башкортстан Республикасында Татарстан Республикасы көннәрен үткәрү кысаларында техника күргәзмәсе һәм демонстрациясе (17–18 апрель);

чит ил хәрби атташелары делегациясе визиты кысаларында сәнәгать предприятиеләре күргәзмәсе һәм техникасы демонстрациясе (Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казан Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү учреждениесе, 29 май);

Төрекмәнстан Президенты Г.М. Бердымөхәммәтов визиты кысаларында предприятиеләр күргәзмәсе һәм техника демонстрациясе (Казан шәһәре, Халыкара аэропорт, 23 июнь);

«ИННОПРОМ» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә Татарстан Республикасы экспозицияләре (Екатеринбург шәһәре, 8–11 июль);

I Каспий икътисадый форумында Татарстан Республикасының бердәм

экспозициясе һәм техника демонстрациясе (Төрекмәнстан, «Аваза» туристик зонасы, 11–12 август);

«МАКС-2019» халыкара авиация-космос салоны кысаларында Татарстан Республикасының берләштерелгән экспозициясе (Жуковский шәһәре, 27 августтан 1 сентябрьгә кадәр).

Шулай ук тармак күләмендә зур чаралар үткәрелде: TIAF халыкара автомобиль төзелеше форумы, Татарстан нефть, газ, химия форумы, Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы, «Машина төзелеше. Металл эшкәртү» күргәзмәсе ачылды.

***«Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проекты***

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм милли проектлар Советы президиумы тарафыннан расланган «Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проектын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасында түбәндәге төбәк проектлары гамәлгә ашырыла:

1) «Татарстан Республикасында халыкара кооперацияне һәм экспортны үстерүнең системалы чаралары»;

2) «Татарстан Республикасында хезмәт күрсәтүләр экспортын үстерү»;

3) «Татарстан Республикасында сәнәгать экспортын үстерү»;

4) «Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексы продукциясе экспортын үстерү».

Максатчан күрсәткечләргә ирешү өчен республикада «Татарстан Республикасы экспортын үстерү» дәүләт программасы проекты эшләнде.

Сәнәгать продукциясе экспортына этәргеч бирү максатларында «Сәнәгать экспорты» федераль проекты кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан түбәндәге ярдәм чаралары гамәлгә ашырыла:

экспорт юнәлешле производстволар төзүгә экспорт кредитлары һәм кредитлар буенча процент ставкаларын субсидияләү (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Конкуренциягә сәләтлелекне арттыруның корпоратив программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларга дәүләт ярдәме турында» 2019 елның 23 февралендәге 191 номерлы карары) һәм «Үсеш һәм тышкы икътисадый эшчәнлек банкы (Внешэкономбанк)» дәүләт корпорациясенә югары технологияле продуктлар җитештерүгә булышлык итү белән бәйле рәвештә федераль бюджеттан Россия Федерациясенең мөлкәти кертеме рәвешендә субсидияләр бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү). Конкурентлык сәләтен арттыру корпоратив программаларын тормышка ашыручы компанияләрнең бердәй исемлегенә (алга таба – КҮКП) Татарстанның 14 предприятиесе керде, шулардан 3се – федераль («ПОЗиС» АЖ, «Түбән Кама нефть химиясе» ГАЖ, «КАМАЗ» ГАЖ), 11е – төбәк («ТЭМ-ПО» «Чаллы торба заводы» АЖ, «Зеленодольск фанера заводы» ГАЖ, «Инженерлык-җитештерү үзәге» ҖЧҖ, «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ, «ВОЛМА-Әбсәләмово» ҖЧҖ, «Кама полимер материаллар заводы» ҖЧҖ, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе, «Түбән Кама шин заводы» ҖЧҖ, «Алабуга базальт технологияләр үзәге» ҖЧҖ, "П-Д Татнефть-Алабуга Пыяла җепселләр» ҖЧҖ, «ТатХимПласт» ҖЧҖ);

транспортлауны субсидияләү (экспортка җибәрелә торган продукцияне

транспортлауга чыгымнарны киметү).

Субсидияләр алу өчен (2018 елның 1 октябреннән 2019 елның 31 августына кадәр) 14 компаниядән («Зеленодольск фанера заводы» ҖАҖ, «Идел буе фанер-мебель комбинаты» ҖЧҖ, «Аутоматив Глас Альянс Рус» АҖ, «Тракья Гласс Рус» АҖ, «ПОЗиС» АҖ, «АгроИдея» ҖЧҖ, «Сәүдә йорты «Кама» ҖЧҖ, «Нәфис Косметикс» АҖ, «ТЭМ «сәүдә йорты» ҖЧҖ, «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ, «ТК Казансельмаш» ҖЧҖ, «ТК Казаньсельмаш» ҖЧҖ, Данафлекс-Нано» ҖЧҖ, «КАМАЗ» ҖАҖ, «Алнас» ҖЧҖ) гаризалар кабул ителде, 9 предприятиедән килгән 11 гариза хупланды.

2020 елда субсидия алу өчен 17 компаниядән («ПОЗиС» АҖ, «ТЭМ «Сәүдә йорты» ҖЧҖ, «Тракья Гласс Рус» АҖ, «АгроИдея» ҖЧҖ, «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ, «Идел буе фанер-мебель комбинаты» ҖЧҖ, «Нәфис Косметикс» АҖ, «ДАНАФЛЕКС-НАНО» ҖЧҖ, «Данафлекс-Алабуга» ҖЧҖ, «ДАНАФЛЕКС» ЯАҖ, «АЛНАС» ҖЧҖ, «Аутомотив Гласс Альянс Рус» АҖ, «Аутомотив Гласс Альянс Рус» АҖ, Кама «ТД» ҖЧҖ, «Цилиндерсрус» ҖЧҖ, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе, «КАМАЗ «ҖАҖ,» ТЭМПО «Кама металлоконструкцияләр заводы» ЯАҖ) 8 гариза хупланды, аларның 2 се буенча килешү төзелде, 6 сы буенча җавап көтелә.

Республика предприятиеләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыяте аша экспортка күрсәтелә торган ярдәм чараларыннан актив рәвештә куллана.

Моннан тыш, республика предприятиеләре «Россия экспорт үзәге» АҖ тарафыннан үткәрелә торган «Ел экспорчысы» халыкара кооперация һәм экспорт өлкәсендә бөтенроссия премиясенә катнаша.

Татарстан Республикасының 6 предприятиесе 4 номинация буенча «Ел экспортчысы» бөтенроссия премиясенең төбәк этабы бүләкләнүчеләре булды («КАМАЗ» ГАҖ, «Кама» сәүдә йорты, «Татспиртпром» АҖ, «Арсенал» ҖЧҖ, «Татэкспорт» ҖЧҖ, «Камагро Сәүдә Йорты» ҖЧҖ). «КАМАЗ» ГАҖ «Ел экспортчысы» конкурсында берничә тапкыр җиңүче булды.

«Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проекты кысаларында «Хезмәтләр экспорты» федераль проекты кысаларында чит ил туристларын кабул итү белән шөгыльләнүче туроператорларга финанс ярдәме механизмы эшләнде. Россия Федерациясенә килүче чит ил туристлары саны артуны тәэмин итүче оешмаларга федераль бюджеттан субсидияләр бирү кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 апрелендәге 534 номерлы карары белән расланды. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән 6 туроператор әлеге субсидияне алу өчен документлар тапшырды. Бүлеп бирелгән акчаларның гомуми суммасы 1 342,5 мең сум тәшкил итте.

***Кластерлар үсеше***

Татарстан Республикасының дөньякүләм һәм төбәкара конкурентлыкта алдынгы урын өчен көрәштә катнашуының нигезе булып конкурентлыкка сәләтле икътисадый комплекслар һәм кластерларны үстерү тора.

Россиянең иң зур икътисадый үсештә булган төбәкләреннән берсе буларак Татарстан Республикасында эзлекле рәвештә халыкның тормыш сыйфатын

арттыруга һәм икътисадның тотрыклы инновация үсешен, конкурентлыкка сәләтлелекне арттыруны тәэмин итүгә юнәлтелгән сәясәт алып барыла.

**Нефть-газ химиясе комплексы**

2019 ел йомгаклары буенча нефть-газ-химия комплексы предприятиеләре тарафыннан 1 759,2 млн сумлык продукция сатуга чыгарылган, бу тулаем республика буенча сатуга чыгарылган продукциянең 61,1 процентын тәшкил итә.

«Татнефть» ГАҖ, «ТАИФ-НК» АҖ, «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, «Казан Органик синтез» ГАҖ, «Нәфис Косметикс» АҖ, «Түбән Кама шин» ГАҖ, «Түбән Кама шин заводы ЦМК» ҖЧҖ нефть - газ химиясе комплексы компанияләре продуктларын сатуның 90 процентын тәэмин итәләр, Татарстан Республикасының бюджет һәм шәһәр төзүче предприятиеләре булып торалар. Әлеге предприятиеләр Россиянең иң зур компанияләре, ә продукциянең аерым төрләре буенча – иң зур Европа компанияләре булып тора.

2019 елда 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын үстерү стратегиясе актуальләштерелде (2019 елның 6 августындагы 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы). Стратегия республиканың ягулык-энергетика комплексын үстерү перспективаларын һәм минераль чимал базасын, нефть эшкәртүне, газ тармагын һәм энергетика комплексын яңарту мәсьәләләрен дә кертеп, нефть чыгаруны үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен билгели.

2019 елда Татарстан Республикасының 2020–2024 елларга нефт-газ-химия комплексын үстерү программасы эшләнде, аның төп максаты булып функциональ материаллар (яңа һәм композицион материаллар, суперконструкцион пластмасса, функциональ өстәмәләр) һәм урта һәм кече тоннажлы химия продукциясенең башка төрләрен үстерү өчен чимал һәм фәнни база булдыру тора.

*Нефть чыгару сәнәгате*

Нефть компанияләренең стратегик максатлары ресурс базасын ныгытуга, нефть һәм газ чыгаруны арттыруга юнәлдерелгән. Куелган максатларга ирешүдә җитештерүне оештыруда принципиаль яңа һәм технологик яктан яңа алымнар куллану мөһим фактор булып тора.

2019 елда 36,6 млн тонна нефть чыгарылды (2018 ел белән чагыштырганда 100,6 процент), шул исәптән республиканың иң зур компаниясе «Татнефть» ГАҖ тарафыннан 29,5 млн тонна, кече компанияләр тарафыннан 7,1 млн тонна).

*Нефть эшкәртү сәнәгате*

2019 елда Татарстан Республикасының нефть эшкәртү заводларында 18,6 млн тонна углеводород чималы эшкәртелде, 637,9 млрд сумга продукция сатуга чыгарылды, сәнәгать җитештерүе индексы 110 процент тәшкил итә.

Эшкәртү тирәнлеген арттыру һәм чиста нефть продуктларын чыгаруны арттыру өчен «ТАИФ-НК» ачык акционер җәмгыяте һәм «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте компанияләре инвестиция проектлары гамәлгә ашыра.

«ТАИФ-НК» АҖ нефть эшкәртү заводының авыр калдыкларын тирәнтен эшкәртү комплексы төзелешен тәмамлый.

«Татнефть» гавами акционер җәмгыяте планлы төстә Түбән Камада нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексын («ТАНЕКО» АҖ), чыгарыла

торган нефть продуктлары төрләрен арттырып һәм сыйфат дәрәҗәсен яхшыртып, төзүне дәвам итә.

2019 елның 12 февралендә «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте нефть эшкәртү комплексында (АИ-92, АИ-95, АИ-98, АИ-100, АИ-100 маркалы) югары сыйфатлы бензин җитештерүгә старт бирелде. Автомобильләр өчен бензин җитештерүнең проектларда билгеләнгән куәте – елына 1,1 млн тоннадан артык.

2019 елның 22 августында «ТАНЕКО» акционер җәмгыятендә ЭЛОУ-АВТ-6 нефтьне беренчел эшкәртү буенча икенче җайланма файдалануга тапшырылды. ЭЛОУ-АВТ-6 җайланмасының исәпләнгән егәрлеге – елына 6 млн тонна эшкәртелмәгән нефть. Аны эшләтеп җибәрү белән «ТАНЕКО» акционер җәмгыятенең нефтьне беренчел эшкәртү буенча гомуми проект егәрлеге елына 15,3 млн тоннага арта.

*Химия производствосы, резин һәм пластмасса эшләнмәләр җитештерү*

2019 ел йомгаклары буенча республиканың химия предприятиеләре тарафыннан 329,4 млрд сумга продукция җитештерелеп, сатуга чыгарылган. Сәнәгать җитештерүе индексы – 96,4 процент.

2018 ел белән чагыштырганда бензол (23,4 процентка), синтетик юыну әйберләре (11,1 процентка), беренчел формада пластмасса (1,9 процентка), лак-буяу материаллары (3,9 процентка) җитештерү күләмнәре арткан.

Шул ук вакытта глицерин (23,1 процентка), техник углерод (16,2 процентка), синтетик каучук (6,4 процентка) җитештерү кимегән.

«Резина һәм пластмасса эшләнмәләр җитештерү» эшчәнлеге төре буенча 2019 елда предприятиеләр тарафыннан 96,6 млрд сумга продукция җитештерелеп, сатуга чыгарылган. Сәнәгать җитештерүе индексы – 100,1 процент.

Тармакта пластмасса торбалар, шланглар, фитинглар (9,5 процентка), тәрәзә пластмасса блоклары (17,8 процентка) һәм резин шиннар, покрышкалар һәм резин камералар җитештерү күләмнәре (29,8 процентка) кимегән.

2019 елда нефть химиясендә берничә мөһим вакыйга булды.

«Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыятендә:

2019 елның февралендә олигомерлар һәм гликольләр заводында елына 3 мең тонна егәрлекле КДИ-М катализаторы производствосы файдалануга тапшырылды. КДИ-М катализаторының яңа производствосы елына 2 мең тонна җитештерү куәте булган гамәлдәге производство белән бергәлектә «Түбән Кама нефтехим» ГАҖ бүлекчәләрен дегидратлау катализаторлары белән тәэмин итәчәк, әлеге продуктны башка җитештерүчеләрдән сатып алу ихтыяҗы бетәчәк;

март аенда этилен җитештерү заводында 18 нче миллион тонна (эшләтеп җибәрелгән вакыттан) этилен эшләп чыгарылган;

август аенда киң колачлы реконструкциядән соң биологик чистарту корылмалары ачылды, биредә заманча технологияләр һәм яңа җиһазлар кулланышка кертелде;

октябрьдә олигомерлар һәм гликольләр заводында каты полиэтиленгликоль (алга таба – КПЭГ) эшләп чыгарыла башлады. КПЭГ үзлелекне көйләүдә, статикага каршы, йомшарткыч, желатин, гранула һәм таблетка ясауда ярдәмче матдә буларак керамика, резин-техника сәнәгатендә кулланыла. КПЭГ ясау өчен яңа уникаль җиһаз

– кристаллаштыру узелы, шулай ук продукцияне робот ярдәмендә төрү линиясе файдалануга тапшырылды.

Полимер эшкәртүче предприятиеләр җитештерү күләмнәрен арттырып, Россия Федерациясенең башка төбәкләре белән һәм Россия Федерациясеннән читтә үз компетенцияләре белән уртаклаша.

Шулай итеп, 2019 елның августында «Ай-Пласт» ҖЧҖ Ростов өлкәсендә полимер зур габаритлы контейнерлар җитештерү заводы эшли башлады.

5 март көнне Простеев шәһәрендә (Чехия Республикасы) «Данафлекс» компаниясенең сыгылмалы пластик төрү материаллары җитештерү заводы эшли башлады.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы территориясендә түбәндәгеләр ачылды:

«Август-Алабуга» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үсемлекләрне саклау өчен химик чаралар җитештерү заводы. Проектта билгеләнгән җитештерү куәте елына 50 млн литрдан артык әзер продукция эшләп чыгару;

«ТН-Алабуга» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бер компонентлы полиуретан монтажлау күбеге җитештерү буенча завод;

«Транснефть – Синтез» нефть транспортлау тармагы ихтыяҗлары өчен турбулентка каршы матдәләр җитештерү заводы. Производствоның җитештерү куәте 3 мең тоннага кадәр продукция җитештерү, аны 10 мең тоннага кадәр җиткерү мөмкинлеге каралган.

«Казан Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте предприятиене алга таба үстерү өчен үз энергетика куәтләрен булдыру, әзер продукция җитештерүгә чыгымнарны киметү, әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны киметү максатларында 250 МВт егәрлекле (ПГУ-250) пар-газ җайланмасын төзү проектын гамәлгә ашыра. Бу максатларда 2019 елның 2 октябрендә Мәскәү шәһәрендә Россиянең энергетика атнасы – 2019 мәйданчыгында «Казан Органик синтез» ГАҖ һәм «Сименс» ҖЧҖ (Siemens AG) арасында 250 МВт (ПГУ-250) егәрлекле пар-газ җайланмасын төзү буенча шартнамәгә кул куелды. Шулай ук «ТАИФ» компанияләр төркеме һәм «Сименс» ҖЧҖ арасында «Казан Органик синтез» ГАҖ һәм «Түбән Кама нефтехим»ГАҖ өчен газ турбинасы җайланмаларына хезмәт күрсәтү буенча ике шартнамәгә кул куелды.

«Түбән Кама нефтехим» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятендә яңа ЭП-600 олефин комплексын һәм аның ярдәмче производстволары төзү буенча, шулай ук метанол производствосы (җитештерү куәте – елына 500 мең тонна) төзү буенча эре проектларны, «Казан Органик синтез» гавами акционер җәмгыятендә этилен һәм полимерлар производствосын үстерү буенча проектларны гамәлгә ашыру эше дәвам ителәә.

2019 елда өч «полимер көне» узды, анда полимерлар җитештерүне һәм эшкәртүне үстерү юнәлешләре, тармакның чималга бәяләр, җитештерелә торган продукциянең сыйфатын саклау һәм дәүләт ярдәме чаралары белән бәйле актуаль мәсьәләләре, шулай ук предприятиеләрнең «Халыкара кооперация һәм экспорт» һәм «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык итү» милли проектларында катнашу мәсьәләсе каралды.

*Дарулар һәм медицина максатларында кулланылучы материаллар җитештерү*

«Дарулар һәм медицина максатларында кулланылучы материаллар җитештерү» эшчәнлеге төре буенча 2019 елда 3,9 млрд сумга продукция җитештерелеп, сатуга чыгарылды. Сәнәгать җитештерүе индексы – 127,4 процент.

2018 ел белән чагыштырганда күз авыруларын дәвалау (16,6 процентка), йөрәк-кан тамырларын дәвалау (11,7 процентка) өчен препаратлар җитештерү күләме арту күзәтелә. Тире авыруларын дәвалау өчен препаратлар эшләп чыгару (41,1 процентка) кимегән.

Татарстан Республикасының фармацевтика тармагын үстерү максатларында Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Татарстан Республикасында проект офисы форматында фармацевтика сәнәгатен үстерү институтын төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 16 апрелендәге 251 номерлы карары кабул ителде, фармацевтика сәнәгате резидентларын адреслы рәвештә Татарстанга җәлеп итү өчен «Татарстан Республикасының фармацевтика медицинасы полисы» ҖЧҖ төзелде. Бүгенге көндә оешма портфелендә 20дән артык проект бар, аларның иң зурлары – Татарстан Республикасының халыкара медицина кластеры һәм медицина сәнәгать паркы.

**Энергетика комплексы**

Татарстан Республикасы энергетика комплексының төп предприятиеләре булып тора:

бергә эшләү режимында электр энергиясе һәм җылылык энергиясе җитештерүче өч оешма («Татэнерго» акционер җәмгыяте, «ТГК-16» ачык акционер җәмгыяте, «Түбән Кама җылылык-электр станциясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте);

электр челтәрләре предприятиеләре, алар арасында электр челтәрләренең озынлыгы һәм төп җиһазларының составы буенча да, шулай ук җитештерелә торган электр энергиясе күләме (куәте) буенча «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте иң зур предприятие булып тора;

республика территориясендә гарантияләнгән электр энергиясе белән тәэмин итүче оешма – «Татэнергосбыт» акционер җәмгыяте.

2008 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы территориясендә «РДУ Татэнерго» ябык акционер җәмгыяте базасында «Система операторы – Үзәк диспетчерлык идарәсе» (алга таба – Татарстанның ТДИ) филиалы оештырылды, аның функцияләре булып Татарстан Республикасының электр энергиясе системасы эше режимнарына оператив-диспетчерлык идарәсе тора.

2019 елда республиканың электр энергиясе системасы кулланучыларны электр энергиясе белән ышанычлы тәэмин итте.

Татарстанның ТДИ мәгълүматлары буенча, электр энергиясе бүлү генерациясе объектларын исәпкә алып, 2019 елда электр энергиясе җитештерү 2018 ел белән чагыштырганда 6 процентка арткан һәм 28,9 млрд кВтч тәшкил итә.

Электр станцияләре тарафыннан 27,4 млрд кВтч электр энергиясе җитештерелде, бу 2018 ел белән чагыштырганда 6,9 процентка күбрәк.

2019 елда Татарстан Республикасы энергосистемасында электр энергиясен куллану 30,59 млрд кВтч тәшкил итте, бу 2018 ел белән чагыштырганда (30,19 млрд кВтч) 1,3 процентка күбрәк.

Электр станцияләре тарафыннан 34,2 млн Гкал җылылык энергиясе җитештерелгән, бу 2018 ел белән чагыштырганда 0,6 процентка күбрәк.

*Татарстан Республикасы энергосистемасының проектлары һәм үсеш мөмкинлекләре*

Соңгы алты елда Татарстанда 4 зур энергетика станциясе яңартылды, бу энергосистеманың куәтен 1,2 ГВт *(Казанның 2 номерлы җылылык-электр станциясен – 220 МВт, «Түбән Кама җылылык-электр станциясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен – 350 МВт; Казанның 3 номерлы җылылык-электр станциясен – 394,4 МВт; Казанның 1 номерлы җылылык-электр станциясен – 246 МВт)* арттырырга мөмкинлек бирде.

2019 елда «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыятендә 495 МВт көчәнешле пар-газ җайланмасы төзү проектын гамәлгә ашыру эше дәвам итте. Проект Siemens *(Германия)* компаниясе белән генераль подряд килешүе буенча төзелешне тулысынча үзләре башкару *(EPC-контракт)* шартларында гамәлгә ашырыла.

Уздырылган җылылык электр станцияләрен модернизацияләү буенча проектларны сайлап алу йомгаклары буенча «Татэнерго» акционер җәмгыятенең Зәй ГРЭСында 850 МВт егәрлекле пар-газ җайланмасын төзү планлаштырыла (2025 елга).

Егәрлекне бүлү шартнамәләре кысаларында шулай ук түбәндәге проектларны гамәлгә ашыру планлаштырыла:

Түбән Кама җылылык-электр станциясендә «Түбән Кама җылылык-электр станциясе» ҖЧҖ 155 МВт егәрлекле газ турбинасы җайланмасын төзү (ПТК-2) (2024 елга);

«Татэнерго» акционер җәмгыятенең Казан 2 номерлы җылылык-электр станциясендә энергетика пар казаннарын модернизацияләү (65 МВт, 2025 елга);

гомуми егәрлеге 267 МВт булган пар турбиналарын модернизацияләү (Түбән Каманың 1 номерлы җылылык-электр станциясендә) һәм 50 МВт Казанның 3 номерлы җылылык-электр станциясендә (2025 елга).

2019 елда шулай ук челтәр хуҗалыгында да электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыруга, шулай ук энергетика инфраструктурасын Казан шәһәрендә WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатына әзерләүгә юнәлдерелгән эшләр дәвам итте.

Чаралар комплексын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы энергосистемасының ышанычлы эшләвен һәм WorldSkills KAZAN 2019 чемпионаты инфраструктурасы объектларын өзлексез рәвештә электр белән тәэмин итүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирде. Ярышлар уздыру чорында Татарстан Республикасы энергосистемасы тотрыклы эшләде, 110–500 кВ челтәрендә электр энергиясе режимының рөхсәт ителгән чикләреннән чыгу, шулай ук WorldSkills KAZAN 2019 объектларын ышанычлы рәвештә электр энергиясе белән тәэмин итүгә йогынты

ясаучы челтәр һәм генерацияләү җиһазларының эше туктатылу очраклары теркәлмәде.

2019 елда «Челтәр компаниясе» ААҖ тарафыннан Зеленодольск ПС 220 кВ ярдәмче станциясендә тулы масштаблы реконструкцияләү эшләре тәмамланды, бу шәһәр һәм районның эре сәнәгать предприятиеләрен («Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» АҖ, Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» АҖ, «Зеленодольск машина төзү заводы» АҖ, «Идел буе фанера-мебель комбинаты» ҖЧҖ һәм башкалар) электр энергиясе белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттырырга мөмкинлек бирде.

2019 елның июнендә 110 кВ Портовая ярдәмче станциясе (Казан шәһәре) файдалануга тапшырылды. Ул Татарстан Республикасы энергетиклары өчен цифрлы ярдәмче станция төзүнең беренче тәҗрибәсе. Якын киләчәктә Казан шәһәре территориясендә тагын бер цифрлы электр энергиясе җитештерү объекты – 110 кВ Азино ПС төзү планлаштырыла.

Моннан тыш, 2019 елда «Челтәр компаниясе» ААҖ тарафыннан 110 кВ Азнакай – Якей һава линиясе һәм 110 кВ Ямбакты – Кама Тамагы һава линиясе реконструкцияләнде. 110 кВ Кама – Октябрьнең 25 еллыгы һава линиясе төзелде һәм файдалануга тапшырылды, ул Татарстан Республикасының өч муниципаль районын – Лаеш, Питрәч һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарында кулланучыларны ышанычлы рәвештә электр энергиясе белән тәэмин итү мөмкинлеге бирде.

2020 елга компаниянең өстенлекле бурычлары булып кулланучыларны электр энергиясе белән өзлексез рәвештә тәэмин итү, электр энергиясе белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыру һәм төп җайланмаларны һәм электр бүлү челтәрләрен яңа заманча технологияләргә күчерү тора.

Республикада энергиянең яңартыла торган чыганакларын, аерым алганда җил энергиясен файдалану нигезендә альтернатив энергетиканы файдалануга зур игътибар бирелә.

2019 елда республиканың өч муниципаль районында – Кама Тамагы (Красновидово авылы), Балык Бистәсе (Сорочьи Горы авылы) һәм Спас (Измери авылы) җил көчен үлчәүнең махсуслаштырылган комплекслары биеклеге – 100 м) ярдәмендә җил үзгәрү белән бәйле шартларны тикшерү өчен җил көчен үлчәү эше алып барыла. Нәтиҗәләр буенча җил көче турында хисаплар һәм bankable статусы белән электр энергиясен җитештерү турында хисаплар әзерләнде. Хәзерге вакытта потенциаль инвесторлар – Россиянең җил энергиясен файдалану базары вәкилләре (Энел, Новавинд, ФРВ җил парклары) белән берлектә республикада җил парклары төзү өчен мәйданчыклар әзерләү эше алып барыла.

*Газ белән тәэмин итү*

Республиканың газ тармагында иң күренекле предприятиеләр «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте төбәк газ бүлү оешмасы һәм газ сату буенча «Газпром төбәкарагаз Казан» ябык акционер җәмгыяте махсуслаштырылган төбәк оешмасы.

Хәзерге вакытта газ тармагының мөһим максаты булып ресурслар ягыннан икътисадтагы төп структур үзгәртеп коруларга ярдәм итү тора. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге төп бурычларны хәл итү күздә тотыла:

сатып алына торган газны сәнәгатьтә, энергетикада, коммуналь-көнкүреш ихтыяҗларын өчен рациональ куллану;

газ-транспорт инфраструктурасын үстерү.

2019 ел йомгаклары буенча республикада тотылган газ 17,7 млрд куб метр тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 30 декабрендәге 1265 номерлы карары белән 2019–2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча төбәк программасы расланды. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 31 гыйнварындагы 147-р номерлы боерыгын үтәү кысаларында «Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру)» максатчан моделен гамәлгә кертү буенча чаралар планы («юл картасы») расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 июнендәге 405 номерлы карары). Әлеге максатчан модель күрсәткечләре үтәлде.

Әлеге эшнең өстенлекле һәм перспективалы юнәлешләренең берсе булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 26 апрелендәге 283 номерлы карары белән расланган «2013–2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру тора. Программа кысаларында республикада транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерү һәм газ-мотор ягулыгы кулланыла торган техниканы сатып алу гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 15 июнендәге ПР-1298 номерлы йөкләмәсе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ-мотор ягулыгыннан куллану өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 767-р номерлы боерыгы нигезендә план буенча эш алып бара.

2019 елның 7 июнендә Петербург халыкара икътисадый форумы – 2019 кысаларында Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Газпром» ГАҖ арасында «Татарстан Республикасында табигый газны сыеклату комплексын төзү» һәм «Татарстан Республикасында криоген автомобильләргә ягулык салу станцияләре челтәрен төзү» инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында килешүгә кул куелды.

2019 ел йомгаклары буенча республика программасы буенча 1 221 транспорт метанга күчерелде һәм газ-мотор ягулыгы ярдәмендә эшләүче 357 транспорт сатып алынды. Программаны тормышка ашыру башланган чордан алып газ-мотор ягулыгы ярдәмендә эшләүче 2 684 транспорт сатып алынды һәм 4 123 транспорт метанга күчерелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 18 сентябрендәге 789 номерлы карары белән «2019–2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ ягулыгы салу компрессор станцияләре төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы расланды. Программа кысаларында барлыгы 30 аның кысаларында 30 автомобильләргә газ

ягулыгы салу компрессор станциясе (алга таба – АГСКС) һәм 21 автомобильләргә газ ягулыгы салу күчмә станциясе төзү һәм файдалануга тапшыру планлаштырыла. Татарстан Республикасы АГСКС саны буенча Россия Федерациясе төбәкләре арасында алдынгы урында тора. Бүгенге көндә республика территориясендә 21 АГСКС һәм 1 автомобильләргә газ ягулыгы салу күчмә станциясе эшли.

## Машина төзү һәм башка эшкәртү производстволары комплексы

### *Машина төзелеше һәм металл эшкәртү*

2019 ел йомгаклары буенча машина төзелеше комплексы предприятиеләре тарафыннан 549,9 млрд сумга товар продукциясе җитештерелеп, сатуга чыгарылган.

2019 елда «ТЭМПО «Холдинг компаниясе» АҖ, «Казанкомпрессормаш» ААҖ, «Ремдизель» АҖ, «ТАТПРОФ» АҖ, «Алабуга автомобиль заводы җитештерү берләшмәсе» АҖ, «КАММИНЗ КАМА» ЯАҖ, «Инкомсистем» фәнни-җитештерү үзәге ЯАҖ, «Аккурайд Уилз Руссиа» ҖЧҖ, «Казан медицина инструментлары заводы» АҖ, «Теплоконтроль» АҖ һәм башка предприятиеләр җитештерү күләмен шактый арттыруга иреште.

Тармак эше йомгаклары, беренче чиратта, «КАМАЗ» ГАҖ күрсәткечләре белән билгеләнә. 2019 елда предприятие тарафыннан 35 меңгә якын йөк автомобиле эшләп чыгарылган.

«КАМАЗ» ГАҖ инвестицион үсеш программасын гамәлгә ашыруны дәвам итә. Инвестицион программаны тормышка ашыруның иң яхшы нәтиҗәләреннән берсе булып К5 буын йөк автомобильләрен базарга чыгару тора. Двигательләр заводында К5 өчен гомумән яңа типтагы көч агрегаты – Р6 двигателе җыела башлады.

Стратегик партнер «ДАЙМЛЕР КАМАЗ РУС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән берлектә кабиналар каркасы җитештерү буенча яңа завод төзелеше тәмамланды, биредә К5 КАМАЗ йөк машиналары һәм Mercedes-Benz йөк автомобильләре җыю производствосы өчен кабиналар каркаслары җыелачак. Заводны ачу тантанасы 2019 елның 27 маенда булды.

2019 елның июнендә 800 литр сыйдырышлы алюминий ягулык баклары җитештерү буенча яңа линия эшли башлады.

«КАМАЗ» ГАҖ һәм «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе арасында хезмәттәшлек һәм университет базасында йөк машиналары өчен уникаль автопилот системасын бергәләп эшләү һәм кулланышка кертүне күздә тоткан КАМАЗ-КФУ интеллектуаль транспорт системаларын өйрәнү һәм эшләү үзәге төзү турында килешүгә кул куелды.

«КАМАЗ» ГАҖ тарафыннан транспортның экологик төрен үстерү өлкәсендә эш алып барыла. 2019 елда предприятие 100 электробусны һәм 36 заряд станциясен Мәскәүгә җибәрде. 2019 елның 15 апрелендә «КАМАЗ» ГАҖ һәм «РОСНАНО» АҖ литий-ион аккумуляторлар нигезендә электр транспорты һәм төягеч техника өчен перспективалы батареялар эшләп чыгарганда һәм җитештергәндә стратегик партнерлык турында килешүгә кул куелды. Документ Россиядә электр транспортын үстерү буенча уртак проектларны һәм литий-ион аккумуляторлар нигезендә энергия

туплау системаларын гамәлгә ашыру өчен нигез булып тора, шулай ук ике компания арасында хезмәттәшлекне яңа глобаль дәрәҗәгә күтәрә.

«КАМАЗ» ГАҖ газ-мотор автотехникасын эшләү һәм җитештерү буенча тармак лидеры булып тора:

елына 8 000 автомобиль һәм 1 500 автобус эшләп чыгаруга исәпләнгән массакүләм производство оештырылган;

хәзерге вакытта компримацияләнгән газда 100дән артык модель эшләп чыгарыла, шул исәптән газ-дизель магистраль тягачларын да кертеп, сыекландырылган табигый газ ярдәмендә эшләүче автомобильләр серияле рәвештә җитештерелә башлады, алар инде «Газпром» ГАҖнең ярдәмче җәмгыятьләренә җибәрелде, алар анда уңышлы кулланылып килә;

Россиянең бөтен территориясендә КАМАЗ газ-баллон техникасына хезмәт күрсәтү челтәре киң җәелдерелгән.

«КАМАЗ» ГАҖ газ-мотор техникасын алга таба үстерү буенча төгәл программа бар, ул инде К4 һәм К5 буын модельләре җитештерүгә юнәлтелгән. Сыекландырылган табигый газ ярдәмендә эшләүче автотехниканы куллануны арттыру буенча заман тенденцияләрен исәпкә алып, седель тягачлар, үзбушаткычлар, тулы приводлы автомобильләр һәм хәтта автобуслар эшләнде.

2019 елның 29 апрелендә Казахстан Республикасы территориясендә КАМАЗ автомобиль техникасы һәм аның өчен компонентлар җитештерүне үстерү буенча хезмәттәшлек турында бишъяклы килешүгә кул куелды. Яклар Казахстан Республикасында «Tobolkz» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «КАМАЗ» ГАҖ яисә «КАМАЗ-Инжиниринг» АҖ («КАМАЗ» ГАҖ һәм «Казахстан Инжиниринг «Милли Компаниясе»АҖ уртак предприятиесе) катнашында теркәлгән уртак предприятие төзү мөмкинлеген карарга ниятли.

«КАМАЗ» ГАҖ КАМАЗ CONTINENT дип аталган К6 КАМАЗ-54907 йөк автомобиле прототибын тәкъдим итте. «Кабина 2020» проектын тормышка ашыру кысаларында энергияне нәтиҗәле файдаланучы гибрид магистраль тягач эшләп чыгарылды. Электр двигателе ябык территорияләрдә хәрәкәт иткәндә, тауга күтәрелгәндә яки көпчәк бер урында әйләнеп торганда автоном хәрәкәт итүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Йөк машинасына шулай ук 100 кмга 25 литрдан да кимрәк ягулык куллану мөмкинлеге бирүче Р6 дизель двигателе куелган.

2019 елның декабрендә пилотсыз хәрәкәт итүче транспортны үстерү юнәлеше буенча «КАМАЗ» ГАҖнең җитештерү мәйданчыгында КАМАЗ-4308 пилотсыз автомобильнең беренче тест узышлары башланды. Комплектлау детальләрен автомобиль-роботлар ярдәмендә китерү проекты «Одиссей» дип атала. Әлегә сүз «КАМАЗ» ГАҖ сәнәгать мәйданчыгы периметрында юллардагы логистик операцияләр турында бара. Мондый машиналар кыска арага йөк ташу таләп ителгән теләсә-кайсы производстволарда кулланыла ала.

«Цифрлы тау предприятиесе» инновацион проектын гамәлгә ашыру кысаларында Кузбассның «Листвяжная» шахтасында 2019 елның декабрендә – 2020 елның гыйнварында «КАМАЗ-43118» пилотсыз автомобиле сыналды. Аның нәтиҗәсе буларак Кузбасста 2020 елның декабренә күмерне пилотсыз ташу буенча тулы бер система эшләнергә тиеш.

Конкурс нәтиҗәләре буенча «КАМАЗ» ГАҖ һәм иң эре пассажир ташучы «Мосгортранс» дәүләт унитар предприятиесе 511 дизель НЕФАЗ-5299-40-52 автобусы сатып алу турында килешүгә кул куйды. Гомуми суммасы – 6,5 млрд сум. Барлык техника этап буенча 2020 елның 1 июленнән 30 ноябренә кадәр китерeләчәк. Контракт шартлары буенча, «КАМАЗ» ГАҖ башкалага пассажирлар саны күбрәк булган 462 түбән идәнле автобус, инструктор өчен кабинасы булган 25 автобус, пассажирлар агымын автоматик күзәтү системасы булган 24 автобус тапшырачак. Шулай ук килешүдә машина йөртүчеләрне һәм ремонт персоналын күчмә составка хезмәт күрсәтү һәм аны куллану үзенчәлекләренә өйрәтү дә каралган.

«ДАЙМЛЕР КАМАЗ РУС» ҖЧҖ (Daimler AG немец автомобиль төзелеше концернының һәм Россиянең йөк машиналары җитештерүче «КАМАЗ» ГАҖ белән уртак предприятиесе) Mercedes-Benz һәм FUSO йөк автомобильләре җитештерү һәм сату белән шөгыльләнә. 2019 елда компания инновацион опцияләр белән яңартылган Mercedes-Benz Actrosны Россия базарына сатуга чыгарды. Яңа релизда ягулык куллануны һәм эксплуатацияләү ягыннан нәтиҗәлелекне, шулай ук йөк машиналарыннан файдалануның куркынычсызлыгын арттыру өчен булдырылган 7 инновацион система пакеты бар.

2019 елның мартында Ford Sollers уртак предприятиесе Россиядә бизнесны реструктуризацияләү турында карар кабул итте, аның нәтиҗәсендә җиңел автомобильләр һәм двигательләр производствосы туктатылды. Хәзер уртак предприятие яңартылган версиядә Форд Транзит коммерция автомобильләре җитештерүгә өстенлек бирә. Автомобиль барлык өстенлекле якларны саклап калып, анда яңартылган утыргычлар, экстерьер детальләрендә һәм салон эчендә бизәлештә яңа төсләр өстәлде. Шулай ук кузов, ишек йозаклары яңартылды, бу кузовның тагын ныгуына китерде.

Предприятие эшчәнлегендә локальләштерү мәсьәләләренә җитди игътибар бирелә. Бүген Россия Федерациясе территориясендә предприятие 34 товар җитештерүче белән эшли. 2019 елның февралендә «Татхимпласт» ҖЧҖ локаль материалыннан Ford Transit автомобильләре өчен бампер кайтартуга рөхсәт кәгазенә кул куелды. Товар җитештерүчеләр чылбырын түбәндәге предприятиеләр тәшкил итә: «Татнефть» ГАҖ – нефть чыгару, «Түбән Кама нефтехим» ГАҖ – база полимерлары, «Татхимпласт» ҖЧҖ – компаундлар, «Хитон Пласт 2» ҖЧҖ – бампер, «Форд Соллерс Алабуга» ҖЧҖ – җыю буенча.

2019 елда локаль материаллардан алты деталь кайтартуга рөхсәт бирелде, шулай ук Ford Transit автомобильләренә штамповканың тагын биш детале (штамповка «Джошкуноз Алабуга» ҖЧҖ заводында эшләнә) уңышлы локальләштерелде. Шулай ук «Форд Соллерс Алабуга» ҖЧҖ продукциясенең бөтен линейкасы буенча локаль штампларның 100 процентына «ММК» ҖАҖ җитештергән локаль металл хупланды.

2019 елда Ford Sollers уртак предприятиесе автомобиль сәнәгате өчен югары квалификацияле белгечләр әзерләү өлкәсендә уку йортлары белән актив хезмәттәшлекне дәвам итте, Worldskills хәрәкәтенең «алтын иганәчесе» булып, халыкара чемпионатны уздыруга ярдәм күрсәтте.

«Ремдизель» АҖ «Тайфун», «Выстрел» һәм «Торнадо» бронеавтомобильләрен эшләп чыгара һәм чыгара. Предприятиедә 2023 елга кадәр стратегик үсеш планы

эшләнгән. Аерым алганда, аңа «Махсус ныгытылган автомобильләр производствосын үстерү» һәм «Запас частьләр һәм алар өчен комплектлау детальләрен җитештерүне модернизацияләү» инвестиция проектлары керә.

«Махсус ныгытылган автомобильләр җитештерүне үстерү» проектын гамәлгә ашыру барышында заманча югары технологияле производство булдырылачак, ул махсус билгеләнештәге автомобильләрнең яңа төрләрен (елына 200 дән артык автомобиль) чыгарырга мөмкинлек бирәчәк.

«Алабуга автомобиль заводы җитештерү берләшмәсе» АҖ Россия Федерациясе нефть чыгару тармагының махсус техника белән тәэмин итүчеләр арасында алдынгы позицияләргә чыкты һәм күп еллар дәвамында уңышлы рәвештә үз урынын саклап кала. «ЕлАЗ» маркалы җиһазлар һәм машиналар Россиянең һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеген әйдәүче компанияләрен тарафыннан танылу һәм ышаныч яулады. Предприятиенең заказ бирүчеләре арасына эре нефть-газ, нефть сервисы һәм бораулау компанияләре керә.

Предприятиедә үзе җитештергән ярымприцеп базасында АПРС-32/40 скважиналарын төзекләндерү өчен югары технологияле күтәрткеч агрегатларын эшләп чыгарыла башлады. 2019 елда «Татнефть» ГАҖ заказы буенча шушындый 25 берәмлек техника эшләп чыгарылды. «Алабуга автомобиль заводы җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятендә элек кулланыла торган «УРАЛ», «КАМАЗ» 3 күчәрле шасси урынына АПРС-40 һәм АПРС-50 йөк күтәрү агрегатларының транспорт-монтажлау базасы буларак куллану өчен тәгәрмәче 8×8 формулалы ППС үзйөрешле шассилары (күчмә үзйөрешле платформа) җитештерелә башлады. Шулай ук 780 модель Bobcat йөк төягеч экскаватор җитештерү үзләштерелде.

«РариТЭК» компаниясе газ-мотор техникасын, газ салу җиһазларын һәм күчмә автомобильләргә газ салу станцияләре эшләп чыгару (үзләштерелгән техниканың 130 дан артык моделе) һәм җитештерүче (lotos үз бренды астында автобус җитештерү) тармагында әйдәүчеләрдән булып тора, сыекландырылган табигый газны газ-мотор ягулыгы буларак куллану базарын үстерүдә актив катнаша.

Бөтенроссия газ-мотор форумы кысаларында «РариТЭК» компанияләр төркеме Россиянең газ-мотор тармагы үсешенә аеруча зур өлеш керткән компанияләрнең берсе буларак махсус билгегә ия булды.

«РариТЭК» компаниясе тарафыннан «МТЗ-Татарстан Сәүдә-җитештерү компаниясе» ҖЧҖ белән берлектә Россиядә сыекландырылган табигый газда эшләүче беренче авыл хуҗалыгы тракторы җитештерелде.

«ЦФ КАМА» ҖЧҖ, «КАМАЗ» ГАҖ һәм ZF Friedrichshafen AG уртак предприятиесе тарафыннан 2019 елда яңа төр КАМАЗ автомобильләре өчен асылмалы кабина производствосы эшли башлады. Компаниянең төп игътибары яңа инновацион Trakson автоматлаштырылган тизлекне күчерү тартмаларын җыю һәм алар өчен детальләр җитештерүгә юнәлдерелгән.

Россиядә машина тәгәрмәчләре җитештерүче иң зур компания – «Аккорайд Уилз Руссиа» ҖЧҖ. Әлеге продукциясене төп кулланучылар булып «КАМАЗ» ГАҖ, «АВТОВАЗ» ГАҖ тора. «Йөк автомобильләре һәм җиңел автомобильләр өчен тәгәрмәчләр производствосын булдыру һәм модернизацияләү» проектын гамәлгә ашыру предприятиегә җиңел машиналар өчен тәгәрмәчләр номенклатурасын

киңәйтергә һәм FORD, «Лада Ижевск автомобиль заводы» ҖЧҖ, «УАЗ» ҖЧҖ җыю конвейерларын продукция белән тәэмин итү мөмкинлеге бирде.

«КАММИНЗ КАМА» ЯАҖ – «КАМАЗ ГАҖ һәм Cummins Inc корпорацияләре тарафыннан төзелгән уртак предприятие. Чаллы шәһәрендә двигательләрнең, ягулык аппаратурасының база узелларын локальләштерү өстендә эшли. Локальләштерү дәрәҗәсе 60 процентка җитте.

2019 елның мартында «КНОРР-БРЕМЗЕ КАМА» ҖЧҖдә, «КАМАЗ» ГАҖ һәм Knorr-Bremse AG немец компаниясенең уртак предприятиесендә, ике миллионынчы барабан тормозы эшләп чыгарылды. Компания дискны сыеклык белән каплау, механик эшкәртү линияләрен эшләтеп җибәрде, йөк автомобильләре өчен күчәрләр җыю эше башланды, тормоз камералары, дым-майны бүлү җайланмалары җитештерү буенча линияләр эшли башлады, Р6 двигателе өчен конструкторлык документациясе килештерелде.

«РИАТ» ачык акционер җәмгыяте тарафыннан белорус техникасының күпчелек модельләренә утыргычлар җитештерү үзләштерелде, «РТЮ» ачык акционер җәмгыятенә китерү өчен локомотив машинисты утыргычын һәм пассажир утыргычларын булдыру буенча эш алып барыла, шартлаудан якланган утыргычларны үзләштерү буенча эш дәвам итә.

«ТЭМПО» холдинг компаниясе – зур сәнәгать концернналарыннан берсе. Холдингның төп предприятиеләре түбәндәгеләр:

«Транспорт электр җиһазлары заводы» җитештерү сәүдә-финанс компаниясе» ябык акционер җәмгыяте БелАз автомобильләренең модель рәтләрен тулыландыру максатларында 90 тонна йөк күтәрүчәнлеге булган үзбушаткыч өчен Б-90 комплект электроприводы төзелде, бу дөнья базарында карьер техникасының конкуренциягә сәләтен арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Компания тарафыннан моңарчы Россиядә җитештерелми торган маневрлы тепловозлар өчен ТАМ880 агрегаты төзелгән;

«Технотрон» җитештерү сәүдә-финанс компаниясе» ябык акционер җәмгыяте автокомпонентлар, кран һәм электр җиһазлары өчен компонентлар җитештерүче, җитештерүне модернизацияли – роботлаштырылган комплексларны гамәлгә кертә, процессларны автоматлаштыра;

«Технотрон-Метиз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җитештерелә торган продукциянең сыйфатын күтәрү һәм производствога яңа төр продукция кертү өстендә эшли. Заманча цинкаль катламнарны төшерү линиясе эшли башлады, ул традицион катламга караганда дистәләрчә тапкыр күбрәк коррозиягә чыдам булырга мөмкинлек бирә; «КАМАЗ», «АВТОВАЗ», «УАЗ», «ГАЗ» автомобиль заводлары конвейерлары өчен ныгытма җитештерүне үзләштерү буенча чаралар тормышка ашырыла;

«ТЭМ-ПО» НТЗ» ябык акционер җәмгыяте, «Северсталь» гавами акционер җәмгыяте һәм «Мәскәү корыч һәм эретмәләр институты» милли тикшеренү технология университеты белән берлектә нефть-газ тармагы өчен кирәкле булган коррозиягә чыдам һәм салкынга чыдам үзлекләргә ия «Северкор» проекты инновацион маркалы корычтан торган торба продукциясен эксперименталь прокатка алу эше үткәрелде.

Үзенең проект идарәсе ярдәмендә «ТЭМПО» Кама металлоконструкцияләр заводы» ябык акционер җәмгыяте катлаулы проектларны гамәлгә ашыра, аларның

заказчылары – «Газпром» гавами акционер җәмгыяте, «Роснефть» нефть компаниясе» гавами акционер җәмгыяте, «Сибур Холдинг» гавами акционер җәмгыяте һәм башка эре предприятиеләр.

«ТЭМПО» Кама металлургия комбинаты» акционер җәмгыяте сортлы прокат һәм арматура җитештерә.

2019 елда рәшәткәле эретеп ябыштыру япмасы һәм электр машиналары өчен электрографит щеткалар җитештерү буенча предприятиеләр («Камский настил» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Графит Плюс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – Яр Чаллы шәһәре ТОСЭР резидентлары) эшләтеп җибәрелде.

«Казанкомпрессормаш» ачык акционер җәмгыяте «В.Б. Шнепп исемендәге НИИтурбокомпрессор (ГМС төркеме)» акционер җәмгыяте белән берлектә Россия һәм Бәйсез Дәүләтләр Берлеге сәнәгатенең төрле тармаклары өчен югары технологияле компрессор җайланмаларын һәм җиһазларны проектлау, әзерләү һәм китерү проектларын гамәлгә ашыра. «Казанькомпрессормаш» ачык акционер җәмгыятенең ТАКАТ 78.2-7 МЗа ХЛ1 модульле винт компрессор җайланмасы «Россиянең иң яхшы 100 товары» федераль конкурсы һәм «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре» республика конкурсының «җитештерү-техник билгеләнештәге продукция» номинациясендә лауреат дип танылды. Конкурслар дипломанты булган 32ГЦ-20/30-106 К.У1 компрессор җайланмасы да югары бәягә лаек булды.

«Әлмәт торба заводы» ачык акционер җәмгыяте (Берләштерелгән металлургия компаниясенә керә) – Россиядә югары сыйфатлы тышкы капламалы корыч электр белән эретеп ябыштыру торбалары җитештерүче иң эре компания. 2019 елда предприятиенең продукция чыгару күләме 5,7 млрд сумнан артык тәшкил итте.

«Татпроф» акционер җәмгыяте алюминий профильләр җитештерүче, хәзерге вакытта Россия алюминий экструзиясе базарының 22 процентын алып тора. Предприятие «Green Al» алюминийдан әзер продуктларның яңа юнәлешен үстерүне дәвам итә: шампиньоннар үстерү өчен җиһазлар, сәнәгать теплица комплекслары. Әлеге юнәлеш Россиядә алюминий продуктлары импортын алмаштыруга тренд бирә.

«Римера» компанияләр төркеме составына керүче «АЛНАС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте нефть чыгару өчен электр белән үзәктән эшләүче насослар җайланмалары (алга таба – УЭЦН), югары көчәнешле чумдырма электр двигательләре, газосепараторлар, гидросаклану җайланмалары чыгара. «АЛНАС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең тулы комплектлы УЭЦН Россиянең һәм ерак чит илләрнең иң эре компанияләренең нефть промыселларында уңышлы эшли. Завод продукциясен төп кулланучылар булып Россиянең эре нефть чыгару компанияләре – «Роснефть», «Лукойл», «Газпром нефть», «Славнефть», «Юганскнефтегаз», шулай ук Һиндстан, Венесуэла, Казахстан, Украина, Белоруссиянең нефть компанияләре торалар.

«Инкомсистем» фәнни-инженер үзәге» ябык акционер җәмгыяте дүрт чиктәш юнәлештә эшли: автоматлаштыру һәм процесслар белән идарә итү, газ һәм сыек мохитне коммерция исәбенә алу, инновацион җиһазлар һәм технологияләр, программа-исәпләү комплекслары. Предприятие җитештерә торган ягулык газын әзерләү блогы «Россиянең иң яхшы 100 товары» федераль конкурсының

«Җитештерү-техник билгеләнештәге продукция» номинациясендә лауреат дип танылды. Хәзерге вакытта «Инкомсистем» фәнни-җитештерү үзәге» ябык акционер җәмгыяте ике инвестиция проектын гамәлгә ашыра: гомуми мәйданы 9 927 кв.метр булган нефть-газ тармагы өчен өзлексез газоанализаторлар, блок-модульле җиһазлар җитештерү буенча завод төзелеше һәм «ХИМГРАД» технопаркы территориясендә универсаль климатик үтәлгән шартлаудан сакланган өзлексез газоанализаторларның коррозиягә каршы капламасын эшләү өчен кремний капламнарының химик парофазлы утыруын тикшерү.

«БЕТАР» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 2019 елда СХВЭ/СГВЭ 15 электрон су исәплəгечләрен серияле җитештерү эшен башлап җибәрде. «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятендә кисә торган инструмент әзерләү үзләштерелде һәм беренче тәэмин итүләр ясалды.

«БЕТАР» ПКФ җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте көче белән республикада станок төзелеше торгызыла: предприятие тарафыннан трансфер/агрегат станоклары җитештерелә һәм китерелә. BORCHE компаниясе белән берлектә BORCHE-BAYAR техник компетенцияләр үзәген ачу проекты гамәлгә ашырыла, аның эшчәнлеге басым астында кою җитештерүен оештыру буенча хезмәтләр комплексын күрсәтүгә юнәлдерелгән.

«Бөгелмә электр насослары заводы» ачык акционер җәмгыяте – нефть чыгару өчен 3 600 метр тирәнлектән катлам сыеклыгын суырып алырга мөмкинлек бирә торган чумдырма электр белән үзәктән эшләүче насослар җайланмалары җитештерүче. Завод шулай ук УЭЦН һәм аларга запас өлешләрне капиталь һәм агымдагы ремонтлау буенча да хезмәт күрсәтә. Предприятие «Роснефть» нефть компаниясе» гавами акционер җәмгыяте, «Русснефть» нефть-газ компаниясе» ААҖ, «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, «Лукойл» нефть компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, шулай ук Украина, Казахстан, Әзербайҗан, Судан компанияләре белән күп еллар хезмәттәшлек итә.

«Вакууммаш» акционер җәмгыяте Россия Федерациясендә һәм Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләрендә вакуум җиһазлары җитештерү буенча эре предприятие булып тора. 2019 елда предприятие тарафыннан Leybold GmbH (Германия) компаниясе өчен диффузион вакуум насосларының яңа линиясе эшли башлады.

«Түбән Кама механика заводы» акционер җәмгыяте («Татнефть» КАМА TYRES» төркеме Шина бизнесы составына керә) машина төзелеше продукциясе һәм стандарт булмаган җиһазлар җитештерә, шулай ук «Татнефть» төркеме Шина бизнесы предприятиеләре җиһазларын ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнә. Бу Россиядә бердәнбер завод – «Татнефть» КАМА TYRES Шина бизнесының җитештерү куәтләрендә кулланыла торган резин катнаштыру камераларын, шулай ук аларга запас өлешләрне җитештерүче завод.

«Казан медицина инструментлары заводы» акционер җәмгыяте тарафыннан бер тапкыр кулланыла торган стериль медицина әйберләрен заманча җитештерү оештырылган. Бу Идел буеның бердәнбер стерилизация үзәге. Россиянең газ стерильләштерүенең 50 проценты аның өлешенә туры килә.

«Эйдос-Робототехника» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – Россиядә сәнәгать роботлары һәм автоматлаштырылган карарлар җитештерүче. Компания Россия заводларында пэт-савытларга эчемлекләр салу өчен роботлаштырылган

линияләр кертелде; «ЕВРОПЛАСТ» заводында (Казан шәһәре) заводта пластиктан эшләнмәләрне автоматлаштырылган җыю линиясе булдырылды; эзлекле кинематикалы сәнәгый робот-манипуляторның серия алды үрнәкләрен сынау тәмамланды.

«Кориб» компанияләр төркеме предприятиеләре:

«Алабуга аккумулятор заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте заводның икенче чиратын эшләтеп җибәрү өстендә эшли, ул автоматлаштырылган рәвештә 1 млн берәмлек яңа төр аккумулятор батареяларын җыюны оештыра;

«Кориб Металл» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте экологик куркынычсыз ысул белән елына 18 мең тонна кургаш-кислоталы аккумулятор батареяларын эшкәртү юлы белән 10 мең тонна икенчел кургаш җитештерү буенча завод төзи;

«Кориб» авторемонт заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте йөк техникасының ремонт комплектларын җитештерү проектын тормышка ашыра.

Haier компаниясе Россиядә Haier суыткычларын җитештерүне оештыру буенча проектны гамәлгә ашыруны дәвам итә. Хәзерге вакытта суыткычлар өчен ярымфабрикатлар җитештерү буенча икенче автоматлаштырылган линия төзелә.

2019 елның августында барабан тибындагы кер юу машиналарын җитештерү буенча завод эшли башлады. Шулай ук компания тарафыннан көнкүреш техникасы (суыту һәм туңдыру җиһазлары һәм башкалар) җитештерү заводлары төзеләчәк.

***Оборона-сәнәгать комплексы***

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе оборона-сәнәгать комплексы составына керүче һәм сугыш кирәк-яраклары, махсус химия, авиация төзелеше, суднолар төзү, идарә системалары һәм гадәти кораллар җитештерү өлкәсендә эшләүче 27 зур һәм урта предприятие бар.

2019 ел эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре буенча продукция эшләп чыгару 96,5 процент сәнәгать җитештерү индексына карата 105 млрд сум тәшкил итә.

«Туполев» гавами акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы, »Казан «Электр җиһазлары» заводы» ачык акционер җәмгыяте, «Казан төгәл машиналар төзү заводы» ФКП, «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте (алга таба – «КМПО» акционер җәмгыяте), «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте (алга таба – «ПОЗиС» акционер җәмгыяте) һәм башка предприятиеләр җитештерү күләмен шактый арттыруга иреште.

Оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең техник кораллану, җитештерүне модернизацияләү, фәнгә нигезләнгән продукциянең яңа төрләрен җитештерү, җитештерүнең күләмен арттыруга федераль бюджеттан акчалар җәлеп итүне тәэмин итү буенча дәүләт программаларында актив катнашуы республика дәүләт хакимияте органнары, директорлар корпусының федераль структуралар белән тыгыз хезмәттәшлеге нәтиҗәсе булып тора.

2019 елда республиканың 13 оборона-сәнәгать комплексы предприятиесе Россия Федерациясенең «Оборона-сәнәгать комплексын үстерү» һәм «2013 – 2025 елларга авиация сәнәгатен үстерү» дәүләт программаларында катнашты.

«ПОЗиС» акционер җәмгыяте 2019 елның декабрендә беренче «МИР» суыткычын чыгаруга 60 ел һәм заводка нигез салынуга 121 ел тулуны билгеләп үтте.

2019 елда «ПОЗиС» акционер җәмгыяте һәм Үзбәкстан Республикасының медицина техникасы җитештерүчеләр һәм тәэмин итүчеләр ассоциациясе «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыятенең Үзбәкстан Республикасындагы вәкиллеге ярдәмендә хезмәттәшлек турында меморандум имзаладылар. Документнып топ пунктларыннан берсе Узбәкстан Республикасында POZIS медицина техникасын алга этәрүне күз алдында тота.

Төп җитештерүне техник яңадан коралландыруны, хезмәт шартларын яхшыртуны дәвам итеп, 2019 елда предприятие «Оборона-сәнәгать комплексын үстерү» дәүләт программасы кысаларында 1,5 млрд сумлык яңа инвестицион проектны гамәлгә ашыруга кереште, аның максаты – төп билгеләнештәге продукция номенклатурасын тәэмин итү һәм яңа, перспективалы эшләнмәләрне үзләштерү өчен бердәм җиңел җайга салына торган җыю производствосын булдыру. Проектны тормышка ашыру вакыты: 2019 – 2027 еллар.

Яңа сату базарлары: Балтыйк буе илләре, Италия, Германия актив үзләштерелә. Нәтиҗәдә, экспортка гражданлык продукциясе җибәрү күләме 15 процент тәшкил итте.

«КМПО» акционер җәмгыятенең стратегик максаты – яңа продуктлар белән сату базарларына чыгу.

Берләшмәдә компрессор станцияләренең пэкиджы хезмәтләрен күрсәтүне диверсификацияләү һәм үзләштерү стратегиясе кысаларында кулланучыларның үсеп килүче таләпләренә җавап бирә торган продукциянең яңа модификацияләрен эшләү һәм тикшерү буенча эш алып барыла, шулай ук «Газпром» гавами акционер җәмгыяте, «НОВАТЭК» гавами акционер җәмгыяте, «Сургутнефтегаз» акционер җәмгыяте, «Роснефть» нефть компаниясе» гавами акционер җәмгыяте кебек эре нефть-газ компанияләре һәм аларның бүлендек җәмгыятьләре белән үзара файдалы һәм озак вакытлы хезмәттәшлекне җайга салу буенча чаралар күрелә.

Нефть-газ чыгару компанияләренең аналитик мәгълүматлары буенча, 20 – 25 ел озак вакытлы эксплуатация срогы булган разведка ятмаларын файдалануга тапшыру кими һәм аларга алмашка 8 – 10 еллык «кыска» эксплуатация циклы булган ятмалар килә. Моңа бәйле рәвештә, күп тапкыр кулланыла торган модульле типтагы газ суырту агрегатларын куллану икътисади максатка ярашлы була, кирәк булганда, аларны минималь ресурслардан файдаланып, тиз арада яңа урында урнаштырырга мөмкин. Хәзерге вакытта «Новатэк» гавами акционер җәмгыяте һәм «Роснефть» нефть компаниясе» гавами акционер җәмгыяте мондый агрегатларга карата кызыксыну белдерде.

Кулланучы өчен күрсәтелгән бурычның актуальлеген аңлап, «КМПО» акционер җәмгыяте күп тапкыр кулланыла торган агрегатның төп техник чишелешләрен эшләүгә кереште.

Күп тапкыр кулланыла торган модульле газ чыгару агрегатлары концепциясе түбәндәге принципны күздә тота: агрегат төрле ятмаларда күп тапкырлар җыю/сүтү (кимендә 5 тапкыр) тәэмин итә торган тулы завод әзерлекле блокларының минималь саныннан торырга тиеш.

Электр энергиясенә тарифларның алга китеп үсеше шартларында бизнес өчен

беренче чираттагы бурычларның берсе – җитештерүнең энергия нәтиҗәлелеген арттыру.

Яңа ятмаларны үзләштерү өчен эре нефть-газ компанияләре электр энергиясе һәм җылылыкның үз генерациясен булдыру буенча инвестиция программаларын гамәлгә ашыралар.

Газ чыгару җиһазларын «ачкыч астында» комплекслы тәэмин итү буенча проектларны тормышка ашыруның уңышлы тәҗрибәсен исәпкә алып, «Новатэк» гавами акционер җәмгыяте, «Сургутнефтегаз» гавами акционер җәмгыяте, «КМПО» акционер җәмгыяте кече куәтле энергоблоклар төзү буенча үзара файдалы хезмәттәшлек тәкъдим итә.

Әлеге эш кысаларында 2019 елда «КМПО» акционер җәмгыяте җитәкчелеге тарафыннан унификацияләнгән карарлар (НК-16-18СТ һәм НК-38СТ приводы белән), үзебезнең комплектлау җайланмаларын (генератор, утильләштерү казаны) кулланып, үз җитештерү мәйданчыгында ГТЭУ-18 төзи башлау турында карар кабул ителде. «Юл картасы» нигезендә ГТЭУ-18 эксплуатациягә 2020 елның апрелендә тапшыру планлаштырыла. «Ачкыч астында» проектын предприятие белгечләре көче белән гамәлгә ашыру алга таба Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясендә потенциаль заказчылар өчен тикшерелгән карарларны тиражлау мөмкинлеген бирәчәк.

«Химия продуктларының дәүләт фәнни-тикшеренү институты» федераль казна предприятиесе «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте нефть чыгару объектында юлдаш нефть газын күкертле чистарту җайланмасының тәҗрибә-сәнәгать сынауларын уңышлы үткәрде. Күкерт чистарту җайланмасын серияле чыгаруга «Машиналарның һәм җайланмаларның иминлеге турында» Таможня берлегенең Техник регламенты ТР ТС 010/2011 таләпләренә туры килү-килмәве турында декларация һәм Евразия икътисадый берлеге продукциясе тибына күкерт чистарту җайланмасын урнаштыруга сертификат алынды.

Таможня берлегенең кинология хезмәтләренең хезмәт этләрен тренировкалау өчен шартлаткыч һәм наркотик матдәләр исе имитаторлары чыгара торган номенклатура киңәйтелде. Наркотик матдәләр исе имитаторларына патент алынган.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 23 февралендәге 191 номерлы карары кысаларында «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе:

СТ-1 товарының (граждан билгеләнешендәге дары һәм нитроцеллюлоза) килеп чыгуы турында сертификат алынды;

Россия Федерациясе территориясендә әлеге сәнәгать продукциясен җитештерүне раслау турында Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының бәяләмәсе алынды;

конкурентлылык сәләтен арттыруның корпоратив программасы эшләнде;

предприятие конкурентлылык сәләтен арттыруның корпоратив программасын гамәлгә ашыручы оешмаларның бердәм исемлегенә кертелгән.

*Авиация төзелеше*

«Туполев» гавами акционер җәмгыяте һәм С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы төп бурычларының берсе – Ту-160 җитештерүен яңарту. Ту-160М

стратегик ракета йөртүчеләрне серияле җитештерү җәелдерелде, алар якын елларда ерак авиацияне коралландыруга керә башлаячак.

2018 елда Россия Федерациясе Оборона министрлыгы «Туполев» гавами акционер җәмгыяте белән 2027 елга кадәр Казан шәһәрендә Ту-160М яңа бомбардировщик төзүне күздә тоткан контрактка кул куйды. Россия Федерациясе Оборона министрлыгы 2021 елда өр-яңадан төзелгән беренче ракета йөртүче-бомбардировщик алачак. Ту-160М берсе инде сынауларга тапшырылды.

Моннан тыш, предприятиедә Ту-22М3 бомбардировщигын модернизацияләү эшләре бара. Дәүләт сынаулары тәмамлангач, Ту-22М3 строй самолетлары Ту-22М3М вариантына кадәр эшләп бетереләчәк.

Предприятиедә Ту-160 һәм Ту-22М3 самолетларын ремонтлау һәм модернизацияләү, шулай ук махсус билгеләнештәге Ту-214 самолетларын төзү дәвам итә. «Казан Гипронииавиапром» акционер җәмгыяте С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводының җитештерү мәйданнарын реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан җиһазлау эшен башкара.

«Казан вертолет заводы» гавами акционер җәмгыяте 2019 елның февралендә Милли санитар авиация хезмәте өчен дүрт «Ансат» вертолетын тапшырды. Винт канатлы машиналар илнең төрле төбәкләрендә билгеләнгән бурычларны үти инде.

2019 елның июнендә ике «Ансат» вертолеты (медицина һәм VIP-комплектацияләрдә) беренче тапкыр Ле-Буржада Paris Air Show 2019 Халыкара аэрокосмик салонында тәкъдим ителде. Моңа кадәр Россиянең граждан билгеләнешендәге вертолет техникасы Париж автосалонында 30 ел элек куелган иде.

2019 елның августында югары комфортлы салонлы беренче серияле Ми-38 граждан вертолеты очты, август аенда аны «МАКС-2019» халыкара авиация-космос салонында тәкъдим иттеләр.

«Казан вертолет заводы» гавами акционер җәмгыяте җитештергән беренче Ми-38Т заказ бирүчегә (Россия Федерациясе Оборона министрлыгы) 2019 елның ноябрендә тапшырылды. 2019 елның декабрендә Россия Оборона министрлыгы заказы буенча эшләнгән икенче Ми-38Т вертолеты тапшырылды.

2019 елның 10 декабрендә «Казан вертолет заводы» гавами акционер җәмгыяте «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм» милли проектын гамәлгә ашыру кысаларында Ми-38 тибындагы калаклар әзерләү» пилот проекты старт алды.

2019 елда «МВЕН» фирмасы» акционер җәмгыяте тарафыннан эшләнгән һәм сертификацияләнгән МВ-500 авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җиңел моторлы самолет һәм аның аның ике урынлы һәм пилотсыз вариантлардагы модификацияләрен чыгару өчен яңа җыю авиация производствосын һәм эксперименталь авиация аэродромын проектлауга һәм төзүгә старт бирелде. Җитештерү куәте елына 60тан 100гә кадәр һава судносы тәшкил итәчәк.

2019 елның февралендә «МВЕН» фирмасы» акционер җәмгыяте Лаеш муниципаль районының авиация кластеры күргәзмәсендә катнашты, анда МВ-500 самолеты һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында «Державино» тулы циклы авиация-сәнәгать мәйданчыгы проектын тәкъдим итте.

2019 елның маенда Иннополис шәһәрендә статэкспозициядә 10 МВ-500 самолеты презентациясе узды.

Июнь аенда «Казан» халыкара аэропортында МВЕН-2 «Фермер» һәм МВ-500 самолетлары Төркмәнстан Президенты Г.М.Бердымухамедовка тантаналы рәвештә тәкъдим ителде, ә 2019 елның августында МВ-500 самолеты Төрекмәнстанда Каспий икътисади форумы кысаларында сәнәгать күргәзмәсендә катнашты.

2019 елның августында «МВЕН» фирмасы» акционер җәмгыяте традицион рәвештә «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен оештыруда һәм үткәрүдә катнашты, анда ике МВЕН-2 «Фермер» самолеты очу программасында һәм бер самолет җир өсте экспозициясендә тәкъдим ителде. Шулай ук август аенда предприятие Татарстан Республикасының берләштерелгән стенды кысаларында «МАКС-2019» халыкара авиация-космос салонында катнашты, анда билгеле продукциядән тыш, яңа эшләнмә тәкъдим итте: 6 – 10 урынлы бизнес-класстагы турбореактив самолет.

2019 елның көзендә «МВЕН» фирмасы» акционер җәмгыяте эшләгән һәм җитештергән 10 МВ-500 самолеты сынауларга чыкты. Җир өсте һәм очу сынаулары башланыр алдыннан самолетлар Россия Оборона министрлыгының 264 хәрби вәкиллеге аша бәйсез инспекциядә гомуми техник тикшерү уңышлы уздылар.

«Эникс» акционер җәмгыяте 2019 елның сентябрендә Югары Ослан муниципаль районының Каинки авылында Авиамоделизм һәм пилотсыз очу аппаратларының тышкы пилотларын әзерләү үзәгендә модельләр классында (F-3J, F-3K, F5J, F3A) Идел буе федераль округы беренчелеген оештырды һәм үткәрде.

«Элерон – 3СВ» – «Элерон – 7» пилотсыз очу аппаратының яңа модификациясе яхшыртылган характеристикалар белән дәүләт сынауларын үтте, серияле җитештерүгә старт бирелде һәм заказчыларга куелды. «Элерон – 3СВ» пилотсыз очу аппаратларына файдалы йөкләнеш яңартылды.

Заводта «ВЕЕР»мультиротор тибындагы квадрокоптер яңа эшләнмә сынаулар уза.

«Урал гражданлык авиациясе заводы» акционер җәмгыятенең 2 нче аерымланган бүлекчәсе көче белән 2019 елның 16 августында Казан шәһәрендә 881 борт номерлы пилотсыз очу аппаратының (алга таба – ЭО БЛА) эксперименталь үрнәге беренче очыш башкарган. Очышны әзерләү һәм үтәү «Туполев» ҖАҖ филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводының Казан шәһәре эксперименталь авиация аэродромында (Борисоглебское) тулысынча очышларны башкару регламенты нигезендә башкарылды. ЭО БЛА һәм җир өсте идарәсе пунктының барлык системалары штатлы эшләде.

«Альтиус» БЛА өстендәге эшләрнең киләсе этабы 2020 – 2022 елларга планлаштырылган һәм аның максаты – әлеге очу аппаратының функциональ мөмкинлекләрен үстерү. 2023 елдан «Альтиус» тибындагы пилотсыз очу аппаратлары булган комплексларны серияле җитештерүне оештыру планлаштырыла.

«Казан авиация технологияләре фәнни-тикшеренү институты» акционер җәмгыяте детальләрне электролитик формалаштыру технологиясен үстерә, тирән сузылган пресслар, тавыштан саклау, тавыш йоту һәм тавыш изоляцияләү панельләрен эшли һәм җитештерә, электр үткәргеч пластик эшли һәм 3D-басма өчен

филамент җитештерә, шулай ук заказ бирүче бурычлары өчен 3D-принтер эшли һәм әзерли.

«КАПО-Композит» акционер җәмгыяте Sukhoi Superjet 100 самолетын модернизацияләү программасында катнаша.

Шулай ук МС-21 һәм Sukhoi Superjet 100 кысаларында серияле җитештерү башлану сәбәпле, егерме самолет комплекты җитештерү мөмкинлеге өчен җитештерү куәтләрен модернизацияләү планлаштырыла.

*Суднолар төзү*

Республикада тармакны үстерү максатларында «Ак Барс» Холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте инициативасы буенча «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясе төзелде, ул 10 меңнән артык кеше эшли торган сәнәгать предприятиеләрен һәм оешмаларын берләштерде. «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясе» акционер җәмгыяте составына 9 оешма керә.

«Төньяк проект-конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте тарафыннан проектланган заманча 22160 проекты корабльләре территориаль суларны саклау, ачык һәм ябык диңгезләрдә икътисади зонаны патрульләү, контрабанда һәм пират эшчәнлеген булдырмау, диңгез һәлакәтләрендә зыян күрүчеләрне эзләү һәм аларга ярдәм күрсәтү, әйләнә-тирәне мониторинглау, диңгез кичүендә корабларны һәм судноларны, шулай ук сугыш вакытында дошманның төрле көч һәм чаралары һөҗүме турында кисәтү максатында хәрби-диңгез базаларын һәм су районнарын саклау өчен билгеләнгән.

Хәзерге вакытта Кара диңгез флоты составында 22160 «Василий Быков» проектының баш корабы эшли, ә әлеге проектның Россия Хәрби-Диңгез Флотының корабель егәрлеген ныгыту өчен билгеләнгән тагын дүрт патруль корабы төзелештә. Бу заманча корабльләр кораллануның модульле концепциясен кулланып проектланган.

22 августта Махачкала шәһәренең тапшыру базасында дәүләт сынаулары нәтиҗәләре буенча тантаналы шартларда «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционер җәмгыяте тарафыннан төзелгән 21980 проектының махсус билгеләнештәге катер сериясеннән унынчы катерны кабул итү актына кул куелды.

Предприятиедә 21980 проектының махсус билгеләнештәге катерлары 2008 елдан бирле төзелә. Заманча җиһазлар һәм югары диңгез характеристикалары аларга бурычларның киң спектрын хәл итәргә мөмкинлек бирә. Әлеге проект катерлары заманча радиоэлектрон кораллар һәм су асты объектларын ачыклау чаралары белән җиһазландырыла, бортта водолаз кирәк-яраклары бар.

2019 елның 1 декабрендә Кронштадт шәһәренең тапшыру базасында «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционер җәмгыяте тарафыннан төзелгән 22100 «Петропавловск-Камчатский» проектының 1 рангтагы чик сакчылары корабле сериясеннән икенче кабул итү актына кул куелды. «Океан» проектының яңа буын корабле («Алмаз» ҮМКХ» акционер җәмгыяте, Санкт-Петербург шәһәре) – Россиянең иң яңа тарихында диңгез чик сакчылары таләпләре буенча тулысынча проектланган беренче кораб. Кораб күп функцияле, югары хәрби потенциалга ия һәм тулы масштаблы коткару операцияләрендә катнашырга сәләтле. Техник характеристикалар җыелмасы буенча «Океан»ның аналоглары юк.

Хәзерге вакытта 22100 «Полярная звезда» проектының төп корабы Көнбатыш арктика районы буенча чик буе идарәсе составында уңышлы хезмәт итә, ә сериянең өченче корабы – «Анадырь» сынаулар уза.

*Радиоэлектроника кластеры*

Стратегик үсеш программаларын үтәү кысаларында радиоэлектроника кластеры предприятиеләре махсус һәм гражданнарга аталган продукцияләрнең яңа төрләрен чыгаруны үзләштерде, алар радиоэлектроника приборлары белән җиһазлау өлкәсендә төрле модификациядәге очкычларны төзү һәм яңарту программаларында актив катнаша.

Хәзерге вакытта җитештерү базасына эре предприятиеләр («Казан «Электр җиһазлары» заводы» ААҖ, «Элекон заводы» акционер җәмгыяте, «Радиоприбор» акционер җәмгыяте, «Әлмәт «Радиоприбор» заводы» акционер җәмгыяте, «Казан электр техникасы заводы» акционер җәмгыяте, «Казан оптика-механика заводы» акционер җәмгыяте һ.б.), шулай ук фәнни үзәкләр һәм конструкторлык бюролары («В.И.Шимко ис. Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте, «ГИПО фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте, «Швабе – Технологик лаборатория» акционер җәмгыяте, «КПКБ» акционер җәмгыяте һәм башкалар) керә.

«Казан электротехника заводы» акционер җәмгыяте 2019 елда СИДИАНТ-0909-0140 КДЗ автоматлаштырылган үлчәү-исәпләү комплексын файдалануга тапшыру буенча эшләр комплексын тәгәлләде. Комплекс төрле типтагы антенналарның параметрларын үлчәү нәтиҗәләрен кулдан һәм автомат режимда эшкәртү һәм югары төгәл үлчәүләр башкару өчен билгеләнгән.

Комплексны сынауларның уңай нәтиҗәләре һәм аны 2019 елда Дәүләт үлчәүләр реестрына кертү аны FH01Э эшләнмәләрен чыгару буенча килешү йөкләмәләрен үтәгәндә үлчәү өчен кулланырга мөмкинлек бирде. Шул ук вакытта комплексны куллану, антен параметрларны үлчәү белән заказ бирүчегә барлык антенна блокларын җитештерүнең, сынауларның ябык циклын оештырырга һәм аны кулдан үлчәгәндә 4 – 5 тапкыр тизрәк тапшырырга мөмкинлек бирә.

Дәүләт тану системасын һәм аңа керүче самолет, җир өсте, корабль чараларын һәм криптографик кодлаштыру аппаратурасын эшләү, сынаулар һәм серияле җитештерү буенча Россия Федерациясендә төп предприятие булып «В.И.Шимко ис. Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте тора. Предприятие модернизацияләнгән «Пароль» системасының радиолокацион танып белү һәм криптографик кодлаштыру аппаратурасының иң яңа чараларын эшләүче, җитештерүче һәм тәэмин итүче булып тора.

«Радиоприбор» акционер җәмгыяте очу аппаратлары өчен актив каршылыклар станциясенең серияле производствосын эшли һәм оештыра.

«Әлмәт «Радиоприбор» заводы» акционер җәмгыяте радиоэлектрон көрәш һәм авиация өчен антенна-фидер системалары өчен аппаратураның состав өлешләрен җитештерүчеләрнең берсе булып тора.

Казан «Электр җиһазлары» заводы ачык акционер җәмгыяте авиациягә эшләвен дәвам итә: үлчәү, җайга салу, температураны үзгәртү һәм контрольдә тоту датчиклары һәм системалары, авиация двигательләре әйләнеше, янгын

сигнализациясе датчиклары һәм системалары, Россиядә җитештерелә торган самолет һәм вертолетларның барлык төрләренә китерелә торган башка эшләнмәләр чыгара.

«Казан приборлар төзү конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте алдынгы авиация проектлары: перспективалы фронт авиациясе комплексы һәм МС-21 магистраль граждан самолетлары өчен эшләрне тәмамлады.

«Швабе – Технологик лаборатория» акционер җәмгыяте – Россиянең оптик-электрон приборлар һәм комплекслар эшләп чыгаручы алдынгы компанияләренең берсе. Предприятиедә проектлауның турыдан-туры автоматлаштырылган мохите булдырылган: концепцияне эшләүдән башлап конструкторлык документларын чыгаруга һәм җитештерүне әзерләүгә кадәр.

«Элекон» заводы» акционер җәмгыяте эшчәнлегенең төп юнәлеше – электр түбән ешлыклы һәм электр өзгеч тоташтыргычларын эшләү һәм җитештерү. Предприятиедә электромагнит киртәләрдән саклану, фильтр-контактлар белән дөньякүләм стандартларга туры килә торган импортны алыштыручы тоташтыргычларны җитештерү проектын тормышка ашыру буенча масштаблы программа планлаштырыла.

«Элекон» заводы» акционер җәмгыяте 2019 елда «Оборона-сәнәгать комплексын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы чараларын тәэмин итү буенча Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән төзелгән алты дәүләт контрактын үтәде.

***Агач эшкәртү сәнәгате***

2019 ел йомгаклары буенча урман эшкәртү сәнәгатендә сәнәгый җитештерү күләме 65,4 млрд сум тәшкил итте. Сәнәгать җитештерүе индексы – 105,1 процент.

«Агач эшкәртү һәм агачтан эшләнмәләр һәм бөкеләр җитештерү, җиһаздан тыш, соломкадан һәм үрү материалларыннан эшләнәләр җитештерү» икътисадый эшчәнлек төре буенча төяп җибәрелгән продукция күләме 27,4 млрд сум тәшкил итте, 2018 ел дәрәҗәсенә карата сәнәгать җитештерүе индексы – 100 процент .

Кәгазь һәм кәгазь эшләнмәләр җитештерүдә төяп җибәрелгән продукция күләме 32,4 млрд  сум тәшкил итте, бу 2018 елга карата 111,4 процент тәшкил итә, мебель җитештерүдә төяп җибәрелгән продукция күләме 5,68 млрд сум, сәнәгать җитештерүе индексы 97,4 процент тәшкил итте.

Татарстан Республикасында өч эре агач эшкәртү заводы эшли: «КАСТАМОНУ ИНТЕГРЕЙТЕД ВУД ИНДАСТРИ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Зеленодольск фанера заводы» гавами акционер җәмгыяте һәм «Идел буе фанера-җиһаз комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы территориясендә KASTAMONU компаниясенең МДФ плитәләре җитештерү заводы динамик рәвештә үсә. Завод продукциясенең 60 проценты Россиядә гамәлгә ашырыла, калган 40 проценты Азия һәм Европаның 20дән артык иленә экспортка җибәрелә. Ел саен Татарстан заводында җитештерелгән продукция халыкара күргәзмәләрдә һәм тармак чараларында чыгарыла.

Ел башыннан KASTAMONU компаниясе табигать саклау чараларына 23 млн сумнан артык акча юнәлдергән. Атмосфера һавасын, су ресурсларын,

туфракларны һәм җир ресурсларын саклау, әйләнә-тирә мохитне җитештерү һәм куллану калдыкларыннан саклау буенча берничә дистә чара тормышка ашырылды.

Шулай ук «Алабуга» махсус икътисадый зонасында KASTAMONU агач эшкәртү заводы PEFC урман сертификациясе системасы таләпләренә туры килү сертификациясен уңышлы узды.

Алабуга шәһәрендәге заводта KASTAMONU җитештерә торган Floorpan һәм Sunfloor сәүдә маркаларының ламинатлы идән япмалары «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре» конкурсының оештыру комитеты карары белән лауреатлар дип танылды һәм «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасының федераль этабында катнашу өчен тәкъдим ителде.

KASTAMONU компаниясе «Алабуга» махсус икътисадый зонасында агач эшкәртү заводында эшли торган интеграцияләнгән менеджмент системасының ISO 9001:2015, ISO 14001:2015, OHSAS 18001:2007 халыкара стандартларына туры килү-килмәве буенча инспекция аудитын уңышлы узды. Аудитны экспертлар TUV Austria системасында интеграцияләнгән менеджмент системаларын сертификацияләү буенча үткәрделәр.

KASTAMONU компаниясе 30 мм.га кадәр калынлык диапазонында МДФ плитәләренә CE Европа сертификатына (алга таба – CE сертификаты) ия булды, бу продукциянең Европа стандартларына (EN стандартларга) туры килүен раслый. Элегрәк Европа таләпләренә туры килү CE сертификаты компания тарафыннан идән япмаларын ламинатлауга алынган иде.

CE сертификаты «Алабуга» махсус икътисадый зонасында KASTAMONU җитештергән ламинат һәм МДФ плитәләре сыйфат һәм экология өлкәсендә Европа Берлегенең төп таләпләренә һәм стандартларына туры килүен раслый. Әлеге сертификат булу компания продукциясенең Европа Берлеге илләре базарларында булуын киңәйтү өчен техник һәм административ киртәләрне юкка чыгара.

Республиканың целлюлоза-кәгазь сәнәгатен түбәндәге эре предприятиеләр тәшкил итә: «С.П.Титов ис. Чаллы картон-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» хезмәткәрләрнең ябык акционер җәмгыяте, «Хәят Кимья» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «ПАЛП Инвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Драйлок Текнолоджиз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Агротехмашстройсервис» ябык акционер җәмгыяте.

«С.П.Титов ис. Чаллы картон-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» хезмәткәрләрнең ябык акционер җәмгыяте Россия Федерациясенең целлюлоза-кәгазь сәнәгатенең иң эре ун предприятиесенә, Татарстан Республикасының 50 төп салым түләүчеләре арасына керә, Чаллы шәһәренең иң эре бюджет төзүче предприятиесе булып тора.

Комбинат – инновацион технологияләр һәм заманча җиһазлар гамәлгә кертү буенча тармакның танылган лидеры. BHS Corrugated Maschinen-und Anlagenbau GmbH (Германия Федератив Республикасы), BOBST Mex S. A. (Швейцария Конфедерациясе), Bobst Lyon SAS Production (Франция Республикасы), Voith Paper (Германия Федератив Республикасы), Andritz AG (Австрия Республикасы), GL&V SWEDEN AB (Швеция Корольлеге), Valmet AB (Финляндия Республикасы), Fabio Perini S.p.A. (Финляндия Республикасы), Fabio Perini S. A. (Италия Республикасы),

Mitsubishi Heavy Industries Europe, Ltd. (Нидерланд Корольлеге) кебек дөньякүләм алдынгы җиһазлар җитештерүчеләр белән хезмәттәшлек итә.

Andritz (Австрия) фирмасы үткәргән чагыштырма тикшерү нәтиҗәләре буенча комбинат макулатурадан үз продукциясенең – гофрокартонның (тестлайнерның) яссы катламнары өчен катыргы һәм сырлау (флютинг) өчен кәгазь сыйфат характеристикалары буенча дөнья лидерлары исемлегенә керде.

Модернизацияләүнең өченче этабы тәмамланганнан соң катыргы ясау машинасының тизлеге минутына 800 метрга кадәр артты (продукция сортларында бер квадрат метрга 150 граммга кадәр).

«Хәят Кимья» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Алабуга» махсус икътисадый зонасының гамәлдәге резиденты, 2019 елда санитария-гигиена кәгазе (бәдрәф кәгазе, салфетка, кәгазь сөлгеләр) заводының икенче чиратын гамәлгә ашыру буенча эшне тәмамлады.

Икенче чиратка инвестицияләр күләме 4,2 млрд сум тәшкил итә. Инвестицияләрнең гомуми күләме 10,6 млрд сумга җитә. Җитештерүне киңәйтү җитештерелә торган продукция күләмен елына 65 мең тоннадан 140 мең тоннага кадәр арттырачак.

Заводның икенче чираты 2019 елның 27 августында файдалануга тапшырылды. Елына 70 мең тонна кәгазь җитештерүчәнлеге булган Valmet (Швеция) маркалы икенче кәгазь эшкәртү машинасы эшләтеп җибәрелде.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы территориясендә проект кәгазьдән югары сыйфатлы әйберләр: бәдрәф кәгазе, сөлгеләр, салфеткалар, борын яулыклары һәм косметик салфеткалар чыгарырга мөмкинлек бирә.

Drylock Technologies (Бельгия) компаниясе – гигиена продукциясен әйдәп баручы җитештерүче һәм тәэмин итүче – «Алабуга» махсус икътисадый зонасы территориясендә балалар, хатын-кызлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен шәхси гигиена чаралары җитештерү буенча «Драйлок Текнолоджиз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте проектын тормышка ашыра. Компания проекты нигезендә «Алабуга» махсус икътисадый зонасында елына 433 млн берәмлек күләмендә гигиена продукциясе җитештерү күздә тотыла. Инвестицияләр күләме 1,7 млрд сум тәшкил итә. Проект эзлекле рәвештә файдалануга тапшыру белән 14 линиягә исәпләнгән.

Предприятие үз сәүдә маркаларын да, контрактлы җитештерүне дә үстерә. Сыйфат менеджменты системасы ISO 9001 халыкара стандарты таләпләренә туры килә.

2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясендә кластерлы үсеш каралган, шул исәптән мебель тармагын да. Хәзерге вакытта җиһаз кластерын үстерү, кооперация элемтәләрен формалаштыру һәм яңа оешмаларны хезмәттәшлеккә җәлеп итү буенча эш алып барыла.

### *Җиңел сәнәгать*

Республиканың җиңел сәнәгать предприятиеләре тарафыннан 7,5 млрд сумнан артык продукция төяп озатылган. Шул ук вакытта тукыма җитештерүдә төяп җибәрелгән продукция күләме – 3,7 млрд сум, кием җитештерүдә – 2,6 млрд сум

тәшкил итә, сәнәгать җитештерүе индексы тиешенчә 104 процент һәм 92,4 процент булганда.

Тире, тире эшләнмәләре һәм аяк киемнәре җитештерү предприятиеләре тарафыннан 1,2 млрд сумлык продукция төяп озатылган, сәнәгать җитештерүе индексы 90,1 процент тәшкил иткән.

«Полиматиз» акционер җәмгыяте медицина, авыл хуҗалыгы, төзелеш билгеләнешендәге заманча тукыма булмаган материаллар җитештерә һәм сата. 2018 елдан башлап предприятие мәгълүматларны саклау һәм ИТ-инфраструктурага чыгымнарны киметү өчен DeNet яңа программа тәэминатын гамәлгә кертү буенча эш алып бара. Пилот проект сыйфатында предприятиедә DeNet.BOX сервисы гамәлгә ашырыла, ул мәгълүматларны исәпләү һәм саклау өчен ирекле компьютер егәрлекләрен кулланырга мөмкинлек бирә. Алдан бәяләү буенча, DeNet эшләү компьютер паркын тотуга «Полиматиз» акционер җәмгыяте чыгымнарын уртача 5 тапкыр киметергә мөмкинлек бирәчәк һәм мәгълүмат ресурсларын саклау дәрәҗәсен сизелерлек арттырачак.

«Эластик заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте яңа буын синтетик материаллар чыгара: «спанбонд» һәм «мельтблаун» технологияләре буенча заманча тукылмаган материаллар, төзелеш мембраналары, сәнәгатьнең төрле тармаклары, шул исәптән медицина, авыл хуҗалыгы, төзелеш, автомобиль төзелеше өчен тукылмаган полипропилен полотносы нигезендә төрле тыгызлыктагы пароизоляция пленкалары.

«Здравмедтех-Поволжье» ябык акционер җәмгыяте – бер тапкыр кулланыла торган медицина киеме һәм эчке киеменең киң ассортиментын, сыйфатлы заманча тукылмаган материаллардан югары технологияле медицина ярдәме күрсәткән вакытта кулланыла торган махсуслаштырылган операция комплектларын җитештерүче. 2018 елда Казан медицина инструментлары заводы базасында Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшләнмәләрен җитештерү һәм стерильләштерү комплексы ачылуга бәйле рәвештә, предприятие тарафыннан эшләнмәләрнең технологик документациясенә үзгәрешләр кертелде, һәм хәзерге вакытта чыгарыла торган эшләнмәләрне газ белән стерильләштерү республикада гамәлгә ашырыла, ә элек предприятиеләр үз продукцияләрен стерильләштерү өчен Мәскәүгә алып бара иделәр.

«Кама Аланы» индустриаль паркы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – төрү материаллары, текстиль сәнәгате өчен чимал чыгару буенча заманча, икътисадый нәтиҗәле югары технологияле производстволарның бердәм инфраструктурасы булган комплекс. Югары технологияле җайланмада иң заманча таләпләргә җавап бирә торган һәм тукыма сәнәгатендә, аерым алганда, техник тукымалар, махсус киемнәр өчен тукымалар, мебель һәм автомобиль тукымалары, жаккард, челтәр тукымалар, келәмнәр, ясалма мех өчен төпләмнәр,ленталар, канатлар, ятьмәләр, капчыклар, биг-беглар, сумкалар, чемоданнар һәм аяк киемнәре җитештерү өчен тукымалар җитештерүдә киң кулланыла торган югары ныклыклы полипропилен җеп җитештерәләр.

«Әлмәт оек фабрикасы «Алсу» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – Россиядә оек-оекбаш эшләнмәләре җитештерүчеләрнең иң эреләренең берсе. Фабрика эшләнмәләре «Носкофф» сәүдә маркасы белән чыгарыла. Фабриканың җитештерү

егәрлекләре елына 20 миллионнан артык пар оек-оекбаш эшләнмәләре чыгарырга мөмкинлек бирә. Продукция ГОСТР нигезендә җитештерелә, барлык кирәкле сертификатларга ия һәм югары сыйфат, заманча дизайн, төсләрнең киң гаммасы һәм тузуга каршы торуның югары проценты белән аерылып тора. 2019 елда фабрика тегү производствосын эшләтеп җибәрде һәм махсус кием һәм урын-җир кирәк-яраклары комплектларын чыгаруга кереште, шуның белән җитештерү эшчәнлеген киңәйтте һәм яңа эшләнмәләр чыгару белән җитештерү күләмнәрен арттырды.

«Кукмара киез комбинаты» акционер җәмгыяте – үз өлкәсендә декоратив элементлар белән киселгән тула һәм киез аяк киеменең заманча модельләрен, шулай ук өлкәннәр һәм балалар өчен 100 процент табигый йоннан төрле әйберләр җитештерүче лидер.

«Кукмара тегү фабрикасы» акционер җәмгыяте югары сыйфатлы тукымалар кулланып, уникаль җиһазларда турыдан-туры фабрикада җитештерелә торган җил һәм дымнан саклаучы махсус һәм экологик чиста полиэфир җепселләреннән торган югары җылылык саклау үзлегенә ия булган GRAFELITE тукымасын файдаланып балалар һәм өлкәннәр киеме чыгару белән шөгыльләнә.

Эшчеләр, инженер-техник хезмәткәрләр һәм көч структуралары өчен махсус кием чыгару белән шөгыльләнүче «Азнакай киемнәре» акционер җәмгыяте предприятиесе тарафыннан шулай ук Ерак Төньякта эшләүчеләр өчен «Төньяк» махсус киемен чыгару үзләштерелде. Эшче кием җитештерүдә махсус туендырылган тукыма кулланыла: юешләнми торган, су-май сеңдерми торган, утка каршы тора һәм җилдән саклый торган. Махсус киемнәрдән тыш, фабрика автомобиль һәм автобусларга чехоллар җитештерә, халыктан кабул ителә торган заказларны башкара.

«Бөгелмә тегү фабрикасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте икътисадның төрле тармаклары өчен махсус киемнәр җитештерә, Ерак Төньякта эшләүчеләр өчен «Арктика» костюмнарын, урман аударучылар өчен костюмнар, эре нефть компанияләре, төзелеш оешмалары, мәгариф һәм сәламәтлек саклау оешмалары өчен махсус киемнәр әзерли һәм чыгара.

«Мелита» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте эшкәртүдән, дизайнын эшләүдән, мех әйберләре булдырудан башлап һәм югары сыйфатлы кышкы киемнәр һәм мех аксессуарлар сатуга кадәр тулы технологик циклның иң өлкән предприятиесе булып тора. Соңгы елларда Россия өчен хас җылы кышлар башлану белән, «Мелита» уникаль технологияләр һәм купшы дизайн ярдәмендә җылы температурада да кию мөмкин булган җиңел туннар тудыра.

Мәктәп формасын эшләү – «ИРЭН» тегү остаханәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе. Кием-салым әйберләренә һәм иң төрле тукымаларга индивидуальлек һәм уникальлек бирү өчен компьютер чигүе кулланыла. Татарстан Республикасында мәктәп укучылары өчен форма киемнәрен башка тегү предприятиеләре дә чыгара: Казан шәһәрендә «Унисервис-Успех+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте; Чаллы шәһәрендә «Бросско» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Школьная Мода» фабрикасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте , «Триада» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте; Түбән Кама шәһәрендә «Түбән Кама тегү фабрикасы» ачык акционер җәмгыяте һ. б.

«Авалон продакшн» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «М-7» Индустриаль паркы резиденты, Peppy Woolton бренды астында 1 яшьтән алып 14 яшькә кадәрге балалар өчен оек-оекбаш эшләнмәләрен җитештерә, 2019 елда яңа туган балалар өчен җитештерелә торган продукция линейкасын киңәйтте. Предприятиенең җитештерү егәрлекләре бүген елына 1,2 млн кадәр оек-оекбаш эшләнмәләре чыгарырга мөмкинлек бирә. Предприятие «Метро кэш энд керри» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Впрок» СЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Табыш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Дочки-Сыночки», «Фамилия», «Монрео», «Верный», «ТД «Агат», «Silver Spoon», «Gulliver» һ.б. кибетләр челтәрләре белән эшләп чыгара торган продукция китерү буенча хезмәттәшлек итә.

«БАРС аяк киеме компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Чистай» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты, «Эшче аяк киеме җитештерүне оештыру» проектын гамәлгә ашыра (күн аяк киеме, поливинилхлоридтан аяк киеме, этиленвинилацетаттан аяк киеме). Аяк киеме җитештерүен булдыруга инвестицияләрнең гомуми күләме 134,5 млн сум тәшкил иткән, 58 яңа эш урыны булдырылган. Проектны гамәлгә ашыру срогы дәвамында заманча җитештерү җиһазларының куәте күннән, полимер материаллардан һәм күпертелгән каучуктан 1 млн пар аяк киеме чыгарырга мөмкинлек бирәчәк.

***Эчемлекләр җитештерү***

2019 елда алкоголь һәм сыра эчемлекләрен эре һәм урта җитештерүчеләр тарафыннан сәнәгать җитештерүе индексы 109,8 процент булганда 32,3 млрд сумлык продукция җитештерелгән.

Продукциянең төп төрләре буенча түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелгән: азык чималыннан ректификацияләнгән 5,9 млн дал спирт (2018 ел дәрәҗәсенә карата 104 процент), аракы – 9 млн дал (102 процент), сыра – 44,5 млн дал (116 процент) җитештерелгән.

«Татспиртпром» акционер җәмгыяте – Россия Федерациясендә иң эре алкоголь компанияләренең берсе. «Татспиртпром» акционер җәмгыяте продукциясен сатуның нәтиҗәле чарасы – «Алкоторг» дистрибьютор компаниясе һәм «Арыш мае» фирма республика ваклап сату алкомаркетлар челтәре.

2019 елда компания «Белый Кремль» сыра кайнату заводының (Чистай шәһәре) ассортимент портфелен киңәйтте, ул «Хмельные раки», «Чистай» һәм «Алтын кабан» сыраларын чыгарды. Завод шулай ук «Магнит» челтәре сәүдә маркасы «Danke» һәм «Кызыл & Ак» кибетләре өчен Schlosskeller һәм Bierstein эксклюзив сәүдә маркалары сыраларын җитештерә башлады. Хәзерге вакытта Чистай сыра кайнату заводы продукциясе илнең 60 тан артык төбәгендә тәкъдим ителгән.

2019 елның 19 октябрендә «Татспиртпром» акционер җәмгыяте һәм «CARÇIOĞLU GROUP» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте уртак предприятиесе – Әзербайҗан Республикасы территориясендә Гусар шәһәрендә «RUS-AZERI SPIRITS» ликер-аракы заводы рәсми рәвештә ачылды, аның кысаларында лицензияле килешү, шулай ук алкогольле продукция җитештерү буенча проектны гамәлгә ашыру ниятләре турында килешү имзаланды. Уртак проект алкогольле

продукция җитештерүне генә түгел, Әзербайҗан Республикасы территориясендә продукция сатуны да үз эченә ала.

«Татспиртпром» акционер җәмгыяте 24 илгә, шул исәптән Америка Кушма Штатлары, Кытай Халык Республикасы, Һиндстан Республикасы, Германия Федератив Республикасы, Италия Республикасы, Япония, Берләшкән Бөекбритания Корольлеге һәм Төньяк Ирландиягә алкоголь җибәреп, үз продукциясен сату географиясен киңәйтүне дәвам итә. «Татспиртпром» акционер җәмгыяте продукциясе сыйфатының югары стандартлары гадәттәгечә халыкара күргәзмәләрдә һәм конкурсларда билгеләп үтелә. Күп кенә брендларның төргәкләрендә «Россиянең иң яхшы 100 товары» һәм «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» дигән аеру билгеләре тора.

Уңышлы һәм конкурентлыкка сәләтле компания имиджын булдыруга «Татспиртпром» акционер җәмгыяте компаниясенең җәмгыять алдында социаль җаваплылык сәясәтен гамәлгә ашыру ярдәм итә, ул югары нәтиҗәле, ресурсларны саклау, экологик чиста җитештерү, кеше сәламәтлеге өчен куркынычсыз чимал һәм компонентлар кулланудан гыйбарәт.

«САН ИнБев» акционер җәмгыяте һәм «Пивоварня Москва-Эфес» акционер җәмгыяте, AB InBev дөньядагы иң эре сыра кайнату компаниясенең һәм Төркиянең Anadolu Efes иң эре сыра кайнату компаниясенең Россия бүлекчәләре үзгәртеп кору процессын төгәлләделәр һәм 2019 елның 1 мартыннан бердәм юридик зат – «АБ ИнБев Эфес» акционер җәмгыяте (AB InBev Efes) буларак эшли.

Завод заманча сыра кайнату җиһазлары, тизләтелгән агызу линияләре белән җиһазландырылган, барлык җитештерү процесслары алдынгы технологик карарлар кулланып гамәлгә ашырыла. Заводның җитештерү куәте – елына 32 млн дал чамасы сыра. Казан шәһәрендәге завод, турыдан-туры сыра җитештерүдән тыш, үз солодовнялары, шулай ук ПЭТ-преформалар һәм термоусадка ясау цехлары белән уникаль.

Әзер продуктны агызу төрле төр савытларга агызуның алты линиясендә башкарыла: ПЭТ-шешәләр, пыяла шешәләр, металл һәм пластик кеглар. Яңа заманча җиһазлар һәм программалар белән тәэмин итү заводка компаниянең танылган брендларын чыгарырга мөмкинлек бирә: «Старый Мельник», «Белый Медведь», Gold mine Beer, «Жигулевское Бочковое», «Сибирская корона» һәм башкалар.

2019 елның июлендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм AB InBev Efes сыра кайнату компаниясе төбәктә сыра кайнату арпасы үстерү буенча агросәнәгать программасын эшләтеп җибәрү һәм үстерү турында килешүгә кул куйдылар. Килешүнең төп максатлары – авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә фәнни һәм методологик ярдәм күрсәтү, алдынгы халыкара тәҗрибәгә, агросәнәгать секторында иң яхшы тәҗрибәләргә һәм инновацияләргә керү мөмкинлеге бирү, дөнья базарында үзебезнең авыл хуҗалыгы предприятиеләренең конкурентлылык дәрәҗәсен арттыру. Программаны тормышка ашыру 2023 елга халыкара сыйфат стандартлары буенча Татарстанда үстерелә торган сыра кайнату арпасы күләмен 40 тапкырга арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Килешү кысаларында AB InBev Efes Татарстан фермерларына SmartBarley («Акыллы арпа») технологик платформасына керү

мөмкинлеген бирәчәк, бу сыра кайнату арпасын үстерүнең уңыш күрсәткечләрен анализларга мөмкинлек бирә.

1981 елда нигез салынган «Болгарпиво» ачык акционер җәмгыятенең Чаллы заводы сыра, алкогольсез эчемлекләр, табигый әчетелгән кваслар, минераль һәм эчәргә яраклы су җитештерә. Компания продукциясе Россия Федерациясенең 30 төбәгендә һәм якын чит илләрдә сатыла.

Хәзерге вакытта компаниянең ассортимент портфеленә 45 төргә якын продукция, шул исәптән сыраның танылган брендлары: «Болгарпиво», «Бархатное», «Пшеничное», «Пятницкое», «Немецкое», «Английский Эль» һәм «Ирландский Эль» керә. 2019 елның августында компания «Казанкрафтфест-2019» фестивалендә беренче тапкыр тәкъдим ителгән «Шотландский Эль» һәм «Пшеничный бельгийский эль» яңа эль төрләрен чыгара башлады. 2019 ел ахырында сыраның ассортимент линейкасын яңа «Bulgarpivo Пенное» тулыландырды. Заводта шулай ук «Виват» лимонады, табигый әчетелгән «Хлебный», «Хлебный Челнинский», «Челнинский домашний» квaслары һәм «Яр Чаллы» «Эдельже» минераль һәм эчәргә яраклы су чыгаралар.

«Болгарпиво» ачык акционер җәмгыяте сыра кайнату продукциясе җитештергәндә Россия һәм Франциядә җитештерелгән салод һәм Германиядә сатып алына торган хмель куллана. Сыра нигезендә – предприятиенең артезиан скважиналарыннан махсус әзерләнгән су.

Компания Чаллы моношәһәре территориясендә эчемлекләр җитештерүне модернизацияләүгә һәм киңәйтүгә юнәлдерелгән инвестицион проектны гамәлгә ашыруны дәвам итә. Хәзерге вакытта предприятиедә бирелгән технология нигезендә һәр сортның өлгерешен тәэмин итүче 10 цилиндроконуслы танк урнаштырылган һәм монтажланган, шулай ук уңайлы, заманча логистика үзәге төзелгән. Цилиндроконуслы танкларда урнаштырылган барлык технологик процесслар автомат режимда уза. Бродиль-лагерь цехы куәтләрен арттыру төрле срокларда сыра ассортиментын җитештерергә мөмкинлек бирә. Проектны гамәлгә ашыру предприятиегә 2022 елга эчемлекләр җитештерү күләмен 20 процентка арттырырга һәм яңа эш урыннары булдырырга мөмкинлек бирәчәк. Хәзерге вакытта 80 яңа эш урыны булдырылган.

## Агросәнәгать комплексы

2019 елда барлык категорияләрдә авыл хуҗалыгы тулаем продукциясе күләме 250,9 млн. сум тәшкил итте, 2018 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә үсеш темпы – 103 процент. Үсемлекчелек продукциясен җитештерү – 3,5 процентка, терлекчелек – 2,4 процентка арткан.

Конкурентлыкка сәләтле, нәтиҗәле кластерлар булдыру тармак үсешенең нигезенә салынган.

Республиканың авыл хуҗалыгы тармагының төп программ документы – «2013 – 2022 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл

хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы.

Республикада түбәндәге субкластерлар уңышлы эшләп килә: бөртекле, шикәр чөгендере, үсемлек мае, яшелчә-бәрәңге һәм җиләк-җимеш. Һәр субкластер үсемлекчелек продукциясен җитештерүнең рентабельлеген арттыру буенча тәгаен чараларны күздә тота.

Үсемлекчелекне кластерлы үстерүне гамәлгә ашыру республика предприятиеләрендә товар чималының бөтен күләмен эшкәртү өчен шартлар булдыруны һәм агросәнәгать комплексының һәр субкластерында беренчел чималдан алып соңгы продукциягә кадәр өстәмә кыйммәтне арттыруны күздә тота.

Шикәр чөгендере, май алына торган һәм кукуруз бөртеге кебек маржиналь культураларга аерым басым ясала. Алар терлекчелек өчен өстәмә продукция алуны тәэмин итә.

2019 елда республиканың авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан башта алынган авырлыкта 4,52 млн тонна ашлык суктырылды (эшләп бетергәннән соң 4,17 млн тонна авырлыкта), бу 2018 елда алынганнан 15,4 процентка күбрәк. Әлеге күләм он тарту һәм икмәк пешерү предприятиеләрен икмәк пешерү өчен чимал, ә республиканың терлекчелек тармагын файдалы матдәләр белән баетылган азык белән тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Кыр эшләрен планлаштыруны җиңеләйтү өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм «Россельхозцентр» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы филиалы белән берлектә, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының геомәгълүмати системасы (алга таба – Татарстан Республикасы АСК ГМС) кертелде, ул вебсервис булып тора.

Татарстан Республикасы АСК ГМС авыл хуҗалыгы җитештерүе этапларын нәтиҗәле файдалану, планлаштыру һәм контрольдә тоту, шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне күзәтү һәм мониторинглау өчен билгеләнгән.

2019 елда шикәр чөгендеренең, төп техник культураның тулаем җыемы 33 процентка арткан һәм 2,8 млн тонна тәшкил иткән. Шикәр чөгендере субкластеры җирле чимал белән тулысынча тәэмин ителгән.

343,9 мең тоннадан артык яшелчә җыеп алынган, бу халыкның ихтыяҗын 79 процентка тәэмин итәргә мөмкинлек бирде. Бәрәңге җитештерү 1,2 млн тонна тәшкил итте.

Бүген авыл хуҗалыгы республика халыкын сыйфатлы һәм үзе җитештергән очсыз продукциянең төп төрләре белән тулысынча тәэмин итә.

Идел буе федераль округының миллион кеше яши торган шәһәрләре арасында Казан шәһәре азык-төлек продукциясенең күпчелек төрләре буенча бәяләрнең арзанлыгы буенча тотрыклы төстә 1 – 3 урыннарны били. Моңа, аерым алганда, үткәрелә торган авыл хуҗалыгы ярминкәләре ярдәм итә. 2019 елда 21 авыл хуҗалыгы ярминкәсе оештырылган (Казанда, шулай ук республиканың башка эре шәһәрләрендә). 1,3 млрд сумлык продукция китереп сатылган.

Республикада сөт һәм ит субкластерлары уңышлы эшли. Һәр субкластер терлекчелек продукциясен җитештерүнең рентабельлеген арттыру буенча тәгаен чараларны күздә тота.

2019 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы сөт җитештерү буенча Россиядә 1 нче урында, терлек һәм кош ите җитештерү буенча 8 нче урында тора.

Республиканың барлык категориядәге хуҗалыкларында 1 893 мең тонна сөт савып алынган (2018 ел белән чагыштырганда 102,4 процент). Җитештерелгән сөтнең тулаем күләме республика халкын әлеге продукция белән тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Республиканың нәсел хуҗалыклары сөт юнәлешенең гамәлдәге һәм яңа проектларын югары генетик потенциалы булган таналар белән тәэмин итә алалар.

Сөт җитештерү күләмнәрен арттыруга сөт терлекчелеге системасын җитештерүнең югары сыйфатлы рәвешләренә күчерү хисабына ирешү планлаштырыла: энергиягә бай һәм югары протеинлы терлек азыгын куллану, барлык технологик процессларны модернизацияләү, хайваннар авыруларын профилактикалау һәм аларга каршы көрәш өчен ветеринария препаратларын актив куллану, югары квалификацияле зооветеринария белгечләре әзерләү.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасының Дәүләт заказы агентлыгы» акционер җәмгыяте базасында авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча zakazrf.ru һәм tattis.ru ике электрон сәүдә мәйданчыгы эшли (zakazrf.ru сатуларда катнашу принцибы буенча, шартнамәләрне турыдан-туры төзү принцибы буенча электрон товар-мәгълүмат системасы).

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге (Татпотребсоюз) район кооперацияләре аша халык тарафыннан җитештерелә торган продукция сатып алуны, алга таба аны үз кибетләре челтәре аша, шулай ук авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә сату белән гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы республика продукциясен сәүдә челтәрләренә чыгару буенча даими эш алып бара. Бүгенге көндә барлык сәүдә челтәрләрендә дә республика товар җитештерүчеләре продукциясе бар.

***Хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү***

Хуҗалык итүнең кече формалары – ул 450 меңнән артык шәхси ярдәмче хуҗалык һәм 4,6 мең фермер хуҗалыгы. Күрсәтелгән хуҗалыкларны үстерүгә ярдәм күсәтү чаралары «Хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырыла, ул гаилә фермалары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар, крестьян фермер хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары форматында товар продукциясен җитештерүне оештыру һәм үстерү аша авыл территорияләрен тотрыклы үстерүне күздә тота. 2019 елда хуҗалык итүнең кече формаларына дәүләт ярдәме 2,5 млрд сумнан артык тәшкил итте. Аның нигезе булып фермерларга һәм кооперативларга грантлар – 1,3 млрд сум, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр – 528,3 млн сум тора.

2019 елда «Татарстан Республикасында яшь фермерларга ярдәм итү» һәм «Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» ыедомство программалары буенча конкурслар

уздырылды. Конкурс нигезендә сайлап алуда тиешенчә 250 һәм 360 млн сум бюджет белән 105 һәм 30 җиңүче билгеләнгән.

Республикада халыктан авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу күләмен арттыру өчен сату, әзерләү һәм эшкәртү буенча 270 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы төзелде. Авылда кече хуҗалыкларга кредит бирү мәсьәләләрен хәл итү өчен 10 авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативы теркәлгән.

2015 елдан республикада федераль катнашу белән «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасы гамәлгә ашырыла, ул кооперативның матди-техник базасын модернизацияләүгә, җитештерү биналары, төзелмәләре, бүлмәләре, цехларын сатып алуга һәм торгызуга, җитештерелә торган продукциянең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы буенча җитештерү контроле лабораторияләрен җиһазландыруга, ит һәм кош-корт әзерләү, саклау, эшкәртү, сортировкалау, сую, беренчел эшкәртү һәм суыту өчен җиһазлар сатып алуга, авыл хуҗалыгы продукциясен сату, төяү, бушату, ташуга әзерләүгә, махсуслаштырылган транспорт, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, модульләр, авыл хуҗалыгы продукциясе өчен контейнерлар сатып алуга йөз тоткан. 2019 елда әлеге программа буенча 10 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы гомуми суммасы 300 млн сумлык грант отты.

«Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән 2019 елда 528,3 млн сум күләмендә субсидияләр бүлеп бирелгән, шул исәптән:

кредитлар буенча процент ставкасын түләүгә – 33,3 млн сум;

сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзүгә – 89,97 млн сум;

товар һәм нәселле таналар һәм тана сыерлар сатып алуга – 12,9 млн сум;

яшь кош-корт (каз, үрдәк, күркә һәм бройлер) сатып алуга – 26,6 млн сум;

савым сыерларын, кәҗәләрне һәм бер елдан өлкән кәҗәләрне карап тотуга һәм сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария профилактика чаралары үткәрүгә – 365,5 млн сум.

Авылда кече хуҗалыкларга ярдәм күрсәтү мәсьәләсендә башкарыла торган эшне мәгълүмат белән тәэмин итү мөһим роль уйный – бу Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы сайтында мәгълүматны даими яңарту, консультация хезмәтләре күрсәтү һәм муниципаль районнарда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре белгечләренең актив эшләве.

Моннан тыш, белдерүләр электрон тактасы эшли, анда теләгән барлык фермерлар үз продукцияләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша тәкъдим итә һәм сата ала.

***«Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасы***

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 3 декабрендәге 858 номерлы карары белән расланган «2013 елга кадәр авылны социаль үстерү» федераль максатчан программасын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын

гамәлгә ашыру кысаларында 2006 – 2019 елларга авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларына 10 963,8 млн сум бүлеп бирелгән (шул исәптән федераль бюджеттан – 4 868,5 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 6 095,3 млн сум), шулардан яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә – 8 614,5 млн сум. Дәүләт ярдәме алучылар саны 14 280 гаилә тәшкил итте. 2020 елның 1 гыйнварына 1 250 мең кв.метр торак файдалануга тапшырылды (шул исәптән 2019 елда – 39,4 мең кв. метр).

2019 елда авылга һәм анда яшәүчеләргә социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү буенча ярдәм ярдәмче программа кысаларында түбәндәге юнәлешләр буенча башкарылды: авыл җирендә яшәүче гражданнарның, яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту; авыл җирлегендә локаль сүүткәргеч челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү; авыл җирлегендә газ бүлү челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү; гомуми белем бирү оешмалары төзү; яссы спорт корылмалары төзү; фельдшер-акушерлык пунктларын комплекслы төзекләндерү, компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыклар төзү; гражданнарның җирле инициативаларына ярдәм итү өчен грантлар.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән төзелгән килешүләр нигезендә 2019 елда «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру кысаларында 2 019,6 млн сум финансланган, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 1 014,1 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 1 005,5 млн сум.

Моннан тыш, 2019 елда «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасы буенча Росавтодор һәм Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы арасындагы килешү нигезендә гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының якындагы иҗтимагый әһәмиятле объектларына алып баручы каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын гамәлгә ашыру буенча 1 186,9 млн сум финансланган, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 531,2 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 655,7 млн сум), бу 41,3 км озынлыктагы 11 торак пунктны тоташтырырга мөмкинлек бирде.

**Сәүдә комплексы**

Кулланучылар базары төбәкнең икътисадый үсешенә һәм халыкның социаль иминлегенә актив йогынты ясый, икътисадый тотрыклылык нигезләрен формалаштыра һәм бюджетны тулыландыруның мөһим чыганагы булып тора.

2019 ел нәтиҗәләре буенча ваклап сату әйләнеше 952,7 млрд сум тәшкил итте, ягъни 2018 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 100 процент.

Җан башына ваклап сату әйләнеше 244,2 мең сум тәшкил итте (2018 елда – 235,3 мең сум).

2019 елда ваклап сату әйләнеше структурасында азык-төлек товарларының өлеше – 44,8 процент (2018 елда – 44,4 процент), азык-төлек булмаган товарлар өлеше – 55,2 процент (2018 елда – 55,6 процент) тәшкил итте.

2019 елда ваклап сату әйләнеше 92,7 процентка сәүдә оешмалары әйләнеше исәбенә формалашты; ваклап сату базарларында һәм ярминкәләрдә товарлар сату өлеше ваклап сату әйләнеше күләмендә 7,3 процент тәшкил итте.

2019 елда җәмәгать туклануы әйләнеше 47,7 млрд сум, яки 2018 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 101,8 процент тәшкил итте.

Татарстан Республикасы халкына 291,6 млрд сумлык түләүле хезмәт күрсәтелгән, яки 2018 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 100 процент. Түләүле хезмәтләр структурасында иң зур чагыштырма өлешне коммуналь (21,4 процент), транспорт (16,6 процент), көнкүреш (14,6 процент), телекоммуникацион (10,2 процент), шулай ук мәгариф системасы хезмәтләре (10,1 процент) алып тора.

Татарстан Республикасында 17 меңнән артык ваклап сату предприятиесе, 5 меңнән артык җәмәгать туклануы предприятиесе, 6 меңгә якын көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиесе, 27 ваклап сату базары эшли.

Хәзерге вакытта республика буенча бер мең кешегә исәпләгәндә сәүдә мәйданнары белән тәэмин ителеш уртача 841 кв.метр тәшкил итә, бу Татарстан халкының сәүдә объектлары белән минималь тәэмин ителеше нормативыннан артып китә (норматив – 603,1 кв. метр).

2019 елда республиканың ваклап сату челтәре үсеше эре сәүдә челтәрләренең инфраструктурасын формалаштыруның дәвамы булып тора. Бүгенге көндә республика территориясендә халыкара («Ашан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Метро кэш энд керри» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Зельгрос» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Леруа Мерлен» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Касторама РУС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һ. б.), федераль («Магнит» гавами акционер җәмгыяте, X5 Retail Group N.V. (Naamloze Vennootschap – ачык акционер компания), «Лента» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Красное и белое» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һ.б.) һәм төбәк («Бәхетле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Эдельвейс» ТК акционер җәмгыяте, «Эссен Продакшн АГ» акционер җәмгыяте, «Августина» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Тэмле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Челны-хлеб» акционер җәмгыяте, «Арыш Мае» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һ. б.) ваклап сату компанияләре эшчәнлек алып бара.

2019 елда челтәр сәүдәсе күләмнәрен арттыру тенденциясе дәвам итте, аның өлеше ел нәтиҗәләре буенча 29,7 процент тәшкил итте (2018 елда – 28,4 процент).

Республика товар бирүнең җитештерелә торган продукциянең сыйфатын күтәрү, аны эчке базарга гына түгел, ә россия һәм чит ил базарларына чыгару максатында да Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 елның 26 декабрендәге 1969-б номерлы боерыгы нигезендә, «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасы кысаларында ел саен «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре»конкурсы үткәрелә. 2019 елда конкурста 230 предприятиедән 453 төр товар һәм хезмәт күрсәтү

катнашты, шуларның 135е лауреат булды, 138е – I дәрәҗәдәге дипломант, 162 се – II дәрәҗәдәге дипломант булды.

«Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсының федераль этабына 160 төр продукция һәм хезмәт күрсәтелде, шуларның 54е лауреат булды. Бу Россия Федерациясе субъектлары арасында иң яхшы нәтиҗәләр. Республиканың өч предприятиесе югары бүләкләргә лаек булды. «Импортны алыштырудагы уңышлары өчен» призын «ТМС Групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ИК алды, ул, үз эшчәнлеген даими камилләштереп, нефть чыгару буенча бурычларны минималь югалтулар белән нәтиҗәле хәл итә, «Инновация» призын – «Инновацион технологияләр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «уттан саклаучы Re-Flame составы» өчен, «Сыйфат тәме» призын – Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты «Бифилайф» дәвалау һәм профилактик туклануының әче сөт продуктлары» өчен алды.

Биш төр продукция 2019 елда «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасының «Алтын йөзлек» исеменә лаек булды һәм Программаны оештыручылар советының махсус дипломнарына лаек булды.

# ИНСТИТУТЛАР. ЭШМӘКӘРЛЕК

## Стратегик планлаштыру

Татарстан Республикасында 2019 елда стратегик планлаштыру буенча эш дәвам итә.

Республиканың стратегик үсешенең төп юнәлешләре 2015 елда расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә (алга таба – Стратегия-2030) салынган. Стратегия-2030ның өч төп өстенлеге:

кеше капиталын формалаштыру һәм туплау;

аның үсеше өчен уңайлы тирәлек булдыру;

кеше капиталы икътисадка кирәкле һәм уңышлы эшли ала торган иҗтимагый институтлар булдыру.

2019 елда Стратегиягә-2030га, беренче чиратта, Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы кысаларында, ул 2024 елга кадәр илнең төп стратегик документы булып тора, илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга бәйле үзгәрешләр кертелде.

Стратегия-2030 проектын эшләгәндә дә, аны тулыландырганда да катнашучыларның максималь киң даирәсенең фикерләре исәпкә алынган. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, хакимият органнары, предприятиеләр, мәгариф һәм фән учреждениеләре, яшьләр һәм иҗтимагый оешмалар катнашында чаралар үткәрелде. Тиешле эш нәтиҗәләре буенча Стратегия-2030га үзгәрешләр «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 5 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланды.

Яңартылган Стратегия-2030 – ул барлык министрлыкларда да, барлык муниципаль берәмлекләрдә дә хакимият органнарының иҗтимагый советларында каралган беренче документ. Моннан тыш, Стратегик инициативалар сайты i.tatarstan2030.ru эшләнде һәм эшли башлады, бу Стратегия-2030га үзгәрешләр кертү процессына республика халкын җәлеп итәргә мөмкинлек бирде, аннан 3 500дән артык стратегик инициатива алынды.

Стратегия-2030га кертелгән үзгәрешләр нигезендә, 2019 елда аны гамәлгә ашыру чаралары Планына төзәтмәләр кертелгән, ул Стратегия-2030ның төп нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар комплексын үз эченә алган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында»). 2015 ел, 25 сентябрь, 707 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планына үзгәрешләр кертү турында» 2019 ел, 20 июнь, 503 нче карары).

Моннан тыш, Стратегия-2030га кертелгән үзгәрешләрдән чыгып, республиканың муниципаль стратегияләрен яңарту буенча эш төгәлләнеп килә.

Муниципальара хезмәттәшлек һәм агломерацияара элемтәләрне үстерү юнәлешендә стратегик планлаштыру буенча эшләр дәвам итә. Стратегия-2030да өч агломерация – Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләре бүлеп бирелгән, аларның һәрберсе үз үсеш приоритетларына ия.

Стратегия-2030ны гамәлгә ашыруның мөһим этабы булып 2019 елда Кама агломерациясе составына керүче Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында хезмәттәшлек турында килешү имзалау тора (2018 елда мондый килешүләргә Казан агломерациясе һәм Әлмәт зонасы башлыклары имза салды). Килешүләр муниципалитетлар тарафыннан уртак проектларны гамәлгә ашыру өчен норматив нигез булып тора.

Дүрт ел рәттән Татарстанның муниципаль стратегияләре, стратегияләр конкурсларында беренче урыннарны алып, федераль дәрәҗәдә танылa.

2019 елда «Россия төбәкләрендә һәм шәһәрләрендә стратегик планлаштыру» форумы кысаларында муниципаль стратегияләр конкурсы узды, анда Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге һәм Питрәч муниципаль районы «2019 елда авыл җирлегенең иң яхшы стратегиясе» һәм «2019 елда авыл муниципаль районының иң яхшы стратегиясе» номинацияләрендә беренче урыннарны алдылар.

Муниципаль стратегияләрне эшләү кысаларында муниципалитетларда республиканың барлык юнәлешләр буенча, шул исәптән комплекслы инфраструктура үсеше, генераль планнар әзерләү, иҗтимагый киңлекләрне формалаштыру һәм тулаем территорияләрне үстерү буенча, республиканың конкурентлы позицияләрен тәэмин итү өчен, территорияләрне үстерүне стратегияләү өлкәсендә кадрлар формалаштырырга кирәк дигән аңлау килде.

2019 елда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрен һөнәри әзерләү программасы буенча һөнәри стратеглар әзерләүгә юнәлдерелгән «Территорияләрне стратегик үстерү» белгечләренең беренче чыгарылышы булды.

**Илкүләм проектлар**

2018 елның 7 маенда Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» Указга кул куйды, ул илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга старт бирде, якындагы 6 елга ил үсешенең төп юнәлешләрен билгеләде.

2019 елда Татарстан 49 федераль проектта катнашты, аларны гамәлгә ашыру өчен республикада 27,4 млрд сум бүлеп бирелде, шул исәптән 20 млрд сум – федераль бюджеттан, 7,4 млрд сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан *(«Демография», «Сәламәтлек саклау», «Мәгариф», «Мәдәният» һәм «Цифрлы икътисад» илкүләм проектларының аерым чараларын гамәлгә ашыруга 2,2 млрд сум күләмендә республика бюджетыннан өстәмә акчаларны кертеп)*.

Ел нәтиҗәләре буенча (*01.01.2020 ел торышына*) 26,5 млрд сум үзләштерелгән, яки еллык лимитның 96,8 проценты.

2019 елда илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында социаль-мәдәни өлкәнең 341 объектын төзү һәм ремонтлау, 386 объектта җиһазлар сатып алу һәм матди-техник базаны яхшырту тәэмин ителде, адреслы ярдәм чаралары, социаль түләүләр бирелде, укулар һәм башка чаралар үткәрелде.

2020 елда Татарстан Республикасында илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга 25,7 млрд сум юнәлдерү планлаштырыла, шулардан федераль бюджет акчалары исәбеннән – 17,4 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 8,3 млрд сум (*республика бюджетыннан өстәмә акчалар – 4,9 млрд сумны да кертеп*).

Моннан тыш, республикада расланган 48 төбәк проектыннан тыш, 2020 елдан башлап «Уникаль су объектларын саклау» һәм «Чиста ил» дигән 2 яңа төбәк проекты гамәлгә ашырылачак.

### Эшкуарлыкка ярдәм итү

Татарстан Республикасында 157 783 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты (алга таба – КУЭ субъекты) эшчәнлек алып бара. Кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүчеләр саны 592,3 мең кеше тәшкил итә (шәхси эшмәкәрләрне һәм үзмәшгульләрне исәпкә алып), бу 2019 ел башына караганда 64,5 мең кешегә (8,5 процент) күбрәк. Әлеге күрсәткечләр буенча Татарстан Республикасы Идел буе федераль округында 1 нче урында һәм Россиядә 6 нчы урында тора.

| Күрсәткечләр | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2018 ел (9 ай) | 2019 ел (9 ай) | Үсеш/кимү темпы, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Икътисадый актив кече һәм урта микропредприятиеләр саны, берәмлек | 70 828 | 74 559 | 75 096 | 72 754 | 74 283 | 72 228 | 97,2 |
| Урта предприятиеләр саны, берәмлек | 567 | 501 | 441 | 433 | 435 | 395 | 90,8 |
| Шәхси эшмәкәрләр саны, кешек | 87 869 | 90 279 | 93 701 | 97 912 | 97 799 | 97 796 | 100 |
| Барлыгы | 159 264 | 165 339 | 169 238 | 171 099 | 172 517 | 170 419 | 98,8 |
| Предприятиеләр әйләнеше, млн сум | | | | | | | |
| Кече предприятиеләр | 987 574,7 | 957 874,4 | 964 528,7 | 1 275 057 | 770 086,4 | 791 146,2 | 102,7 |
| Урта предприятиеләр | 167 775,5 | 236 261,1 | 219 289,1 | 193 717,7 | 134 815,4 | 119 985,2 | 89 |
| Барлыгы | 1 155 350,2 | 1 194 135,5 | 1 183 817,8 | 1 468 774,7 | 904 901,8 | 911 131,4 | 100,7 |
| Товарлар, продукция, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатудан кергән табыш күләме, млн сум | | | | | | | |
| Шәхси эшмәкәрләр | 238 468,3 | 499 285,6 | 516 182,4 | 491 995,9 | x | x | x |

Кече һәм урта предприятиеләрнең әйләнеше 2019 елның 9 аенда 911,1 млрд сум тәшкил итә, бу 2018 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 0,7 процентка артыграк. Кече предприятиеләрнең әйләнеше 791,1 млрд сум (2018 елның гыйнвар – сентябрь дәрәҗәсенә 102,7 процент), урта предприятиеләр әйләнеше – 120 млрд сум (89 процент).

2019 елның 9 аенда кече һәм урта предприятиеләрнең исемлек составында эшләүчеләрнең уртача саны 374,8 мең кеше тәшкил итте, шул исәптән кече предприятиеләр – 337 мең кеше, урта предприятиеләр – 37,7 мең кеше.

| Күрсәткечләр | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2018 ел (9 ай) | 2019 ел (9 ай) | Үсеш/кимү темпы, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Исемлек составы хезмәткәрләренең уртача саны, кеше | | | | | | | |
| Кече предприятиеләр | 300 050 | 332 467 | 332 638 | 337 440 | 329 708 | 337 017 | 102,2 |
| Урта предприятиеләр | 60 765 | 54 642 | 46 262 | 40 326 | 40 538 | 37 744 | 93,1 |
| Барлыгы | 360 815 | 387 109 | 378 900 | 377 766 | 370 246 | 374 761 | 101,2 |
| Исемлек составы хезмәткәрләренең уртача исәпләнгән хезмәт хакы, сум | | | | | | | |
| Кече предприятиеләр | 24 492,3 | 20 621,9 | 23 032,4 | 23 329,2 | 22 585,6 | 23 749 | 105,2 |
| Урта предприятиеләр | 23 820,9 | 27 715 | 30 756 | 34 390 | 33 152,2 | 34 338 | 103,6 |

Бәяләүләр буенча 2019 елның гыйнвар-сентябрь нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының тулаем төбәк продуктында кече һәм урта эшмәкәрлек өлеше 26 процент тәшкил итте.

2019 елда кече һәм урта бизнес өлкәсендә түбәндәге мөһим чаралар үткәрелде:

1. «Синергия» университеты (Мәскәү шәһәре) белән берлектә 2019 елның 24 октябрендә өч мәйданчыкта: Казан шәһәрендә («Татнефть Арена» боз спорт сарае), Чаллы шәһәрендә (IT PARK) һәм Әлмәт шәһәрендә («Яшьләр үзәге») «Минем бизнес» киңкүләмле эшмәкәрлек форумы уздырылды. Республиканың яңа эш башлаучы һәм гамәлдәге эшмәкәрләре илнең алдынгы бизнес-консультантлары, бестселлер авторлары һәм уңышлы эшмәкәрләрдән бик күп файдалы мәгълүмат алдылар.

2. 2019 елда Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм һәм аны үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге тарафыннан Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процент ставкасын субсидияләү буенча яңа программаны гамәлгә ашыру башланды.

3. Татарстан Республикасында WorldSkills Бөтенроссия конкурсының «Эшмәкәрлек» компетенциясе буенча төбәк этабы узды. Татарстан Республикасы призлы урыннар яулады.

2019 елның 13 ноябреннән 7 декабренә кадәр Татарстан Республикасында этаплап 2019 – 2020 еллардагы чемпионат циклындагы «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) төбәк чемпионаты узды. 2019 елда төбәк чемпионаты 96 WorldSkills компетенциясе һәм 66 «WorldSkills юниорлар» компетенциясе буенча 43 мәйданчыкта оештырылды, аларда 2 300дән артык конкурсант һәм эксперт катнашты.

Чемпионатта 9 команда, һөнәри белем бирү оешмалары студентлары һәм «Эшмәкәрлек» компетенциясе буенча яшь профессионаллар катнашты.

4. Татарстан Республикасында контроль-күзәтчелек эшчәнлегенә һәм эшмәкәрләрне тикшерүгә кагылышлы КУЭ субъектлары өчен портал, «Тикшерелгән бизнес» интернет-ресурсы уңышлы эшләп килә.

5. 2019 елның 24 октябрендә «Фастрек» порталы – цифрлы платформа эшли башлады, аның ярдәмендә КУЭ субъектлары «бер тәрәзә» режимында ярдәм чараларына заявка бирү мөмкинлегенә ия булдылар.

Республикада финанс, мөлкәт һәм консультация инфраструктурасы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм һәм аны үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» КБО, «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБО, шәхси һәм дәүләт сәнәгать парклары, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары, төбәк инжиниринг үзәкләре һәм прототиплаштыру үзәкләре, «Татарстан Республикасының төбәк лизинг компаниясе» акционер җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Республикада турыдан-туры финанс ярдәме чараларыннан тыш эшмәкәрлеккә мәгълүмати ярдәм күрсәтү буенча чаралар: форумнар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, шул исәптән эшмәкәрлекне үстерүнең проблемалы мәсьәләләренә багышланган чаралар даими үткәрелеп тора.

*Татарстан Республикасы Гарантия фонды*

«Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешмасы (алга таба – Гарантия фонд) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 31 октябрь, 896 нчы карары нигезендә төзелде. Аның эшчәнлегенең төп максаты – Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының кредит һәм бүтән финанс ресурсларына үтемлелеген тәэмин итү, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның кредит шартнамәләренә, банк гарантиясе килешүләренә нигезләнгән йөкләмәләре буенча гарантияләр һәм җаваплылыкны үз өстенә алу системасын үстерү.

Гарантия фонды тарафыннан 42 банк, 4 лизинг компаниясе, 1 микрофинанс оешмасы, «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы, Сәнәгатьне үстерү фонды һәм Моношәһәрләрне үстерү фонды белән хезмәттәшлек турында килешүләр төзелгән (Фонд партнерларының тулы исемлеге www.garfodrt.u сайтында урнаштырылган.).

2019 елда Гарантия фонды КУЭ субъектларына 1 473,7 млн сумлык (2018 елда – 1 093,7 млн сум, үсеш – 34,7 процент) 274 йөкләмә биргән (2018 елда – 147 йөкләмә, үсеш – 1,9 тапкыр), бу эшмәкәрләргә 5 547,8 млн сумлык заем финанславын җәлеп итәргә мөмкинлек бирде (2018 елда – 4 172,7 млн сум, үсеш – 33 процент). 2019 елда Гарантия фонды беренче тапкыр интеллектуаль милекне нигез итеп йөкләмә бирде. Бу фәнни һәм техник эшләнмәләр белән шөгыльләнүче КУЭ субъектларын финанслау өчен зур потенциал.

2019 елдагы эш нәтиҗәләре буенча КУЭ субъектларына ярдәм итүнең максатчан моделе кысаларында Гарантия фонды төбәк гарантия оешмалары

арасында фонд җаваплылыгына бирелгән кредитлар күләме буенча лидерлык позициясен алды.

2019 елның июлендә кече бизнеска кредит бирү өчен яңа цифрлы сервис гамәлгә ашырылды. «Гарантия агымы» сервисы – Татарстан Республикасы Гарантия фонды җаваплылыгы белән кече бизнеска онлайн-кредит бирү буенча Россиядә беренче тәҗрибә. Заманча финанс технологияләре, банк инфраструктурасы һәм дәүләт ярдәме синергиясе аркасында финанслар мөмкин кадәр арзанайды. Дәүләт ярдәме белән илдә беренче краудлендинг инвесторларның хәвеф-хәтәрләрен киметә, бу эшмәкәрләргә онлайн-кредит бирү сегментында иң түбән процент белән займ алу мөмкинлеге бирә.

*«Бердәм кредит бирү үзәге» проектын тормышка ашыру*

Бердәм кредит бирү үзәге эшмәкәрләргә оптималь кредит продуктын сайлап алуда һәм кредит заявкасын формалаштыру этабыннан башлап һәм финанслау алу вакытына кадәр алыш-бирешләрне структуралаштыруда ярдәм итә. 2019 елда 899 гариза бирүчегә консультация бирелде, банкка 289 гариза җибәрелгән, 801,2 млн сум займ акчасы җәлеп ителгән.

*Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды*

Кече һәм урта эшмәкәрлеккә финанс ярдәме күрсәтү максатларында «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды» КБО (алга таба – Фонд) төзелде, аның төп бурычы – икътисадның өстенлекле тармакларында (авыл хуҗалыгы, төзелеш, җитештерү һәм эшкәртү, шул исәптән импортны алыштыруны, хезмәт күрсәтүне, инновацияләрне тәэмин итүче) эшләүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына займнар бирү.

2019 елда «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды» КБО микрофинанслау үзәге (алга таба – Микрофинанслау үзәге) тарафыннан КУЭ субъектларына 934,6 млн сумлык (2018 елда – 381,24 млн сум, үсеш – 2,5 тапкыр) 399 микрозайм бирелде (2018 елда – 235 микрозайм, үсеш – 1,7 тапкыр). Гамәлдәге микрозаймнар портфеле – 1 094 млн сум.

Фонд составында Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү үзәге, Татарстан Республикасында Экспорт юнәлешле кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүне координацияләү үзәге, Җитештерүче кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү үзәге, Татарстан Республикасы Социаль өлкә инновацияләре үзәге, Бизнес-инкубация һәм кластерлы үсеш үзәге, Бизнес өчен күпфункцияле үзәк үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

*Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү үзәге*

2013 елдан башлап «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды» КБО Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү үзәге (алга таба – Үзәк) эшли.

Үзәк эшчәнлегенең төп максаты – Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен уңай шартлар тудыру.

2019 елда Үзәк тарафыннан 18 меңнән артык консультация бирелгән, 34 чара оештырылган һәм үткәрелгән, шул исәптән Эшмәкәр көне, шулай ук «Минем бизнес» эшмәкәрлек форумы.

2019 ел дәвамында Үзәк тарафыннан шулай ук «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорация» акционер җәмгыяте тарафыннан эшләнгән 32 тренинг уздырылды, аларның 8 – «Эшмәкәр әлифбасы», «Әни-эшмәкәр» федераль проекты һәм 5 «Эшмәкәрлек мәктәбе» тренингы, 4 «Бизнес-эксперт: КУЭ Бизнес-навигаторы порталы» тренингы, 7 «Бизнес-идеяләрне генерацияләү» тренингы, 1 «КУЭ субъектларын тикшерү» тренингы, 2 «Проект идарәсе» тренингы, 1 «УНП Сакчыл җитештерү» тренингы, 3 «Финанс ярдәме» тренингы, аларда 400дән артык кеше катнашты.

Югарыда атап үтелгән белем бирү чараларыннан тыш, «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте һәм Google компаниясе белән берлектә «Бизнес-класс» программасы тормышка ашырыла, ул бизнес вәкилләре арасында зур популярлык казанды (гамәлгә ашырыла башлаганнан алып 2019 ел азагына кадәр республика территориясендә программада 48 692 катнашучы теркәлгән, 6 600 кеше укуын тәмамлаган).

*Татарстан Республикасында экспорт юнәлешле кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүне координацияләү үзәге*

Татарстан Республикасында экспорт юнәлешле кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүне координацияләү үзәге (алга таба – Экспорт үзәге) республиканың кече һәм урта экспортер-предприятиеләренең тышкы икътисадый эшчәнлегенә ярдәм итү максатларында эшли.

Экспорт үзәгенең төп максаты – Татарстан Республикасының экспорт юнәлешле кече һәм урта предприятиеләрен чит ил базарларына этәрүгә ярдәм итү.

2019 ел нәтиҗәләре буенча Экспорт үзәге тарафыннан 568 КУЭ субъектына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтелде. Шул ук вакытта КУЭның 94 субъекты Экспорт үзәге ярдәме белән чит ил базарларына чыкты һәм 24,19 млн долларлык экспорт контрактлары төзеде.

2019 елның 29 апрелендә Экспорт үзәге КУЭ субъектлары өчен MyExport халыкара конференциясен үткәрде. Конференциядә КУЭның 77 субъекты катнашты. Конференция кысаларында Россия Федерациясе һәм Германия Федератив Республикасыннан чакырылган спикерлар белән «РЭҮ төркеме продуктлары» һәм «Нәтиҗәле сату методлары һәм немец системасы буенча сөйләшүләр алып бару» темаларына ике түгәрәк өстәл үткәрелде. Конференция эшмәкәрләрне, федераль һәм төбәк дәүләт хезмәте органнары, шулай ук иҗтимагый оешмалар вәкилләрен Татарстан Республикасының экспорт юнәлешле предприятиеләрен үстерү һәм аларга ярдәм итү инструментлары турында фикер алышу өчен җыйды

2019 елда КУЭ 74 субъекты «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыятенең Экспорт мәктәбе» автоном коммерциячел булмаган өстәмә һөнәри белем бирү оешмасы тарафыннан үткәрелә торган «Экспорт проектының тормыш циклы» белем бирү программасында катнашты.

«Сколково» Мәскәү идарә мәктәбе белән берлектә партнерлык оешмаларын җәлеп итеп, акселерация программасы гамәлгә ашырылды, анда КУЭ 6 субъекты

катнашты (КУЭ 5 субъекты һөнәри яңадан әзерлек турында диплом алды, КУЭ 1 субъекты укуларын 2020 елның 6 мартында тәмамлаячак).

Моннан тыш, 2019 елда КУЭ субъектларын халыкара электрон мәйданнарда урнаштыру буенча яңа хезмәт эшли башлады, аның кысаларында КУЭ 10субъекты маркетплейсларда аккаунт алды (КУЭ 9 субъекты – Алибабада, КУЭ 1 субъекты – Эпиньдода).

*Татарстан Республикасы социаль өлкәсе инновацияләре үзәге*

Татарстан Республикасы территориясендә социаль эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү, социаль өлкәдә перспективалы һәм стратегик проектларны һәм инновацияләрне популярлаштыру һәм нәтиҗәле алга этәрү, шулай ук социаль проектларга һәм инициативаларга ярдәм итүнең сыйфатлы яңа дәрәҗәсен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы социаль өлкәсе инновацияләре үзәге эшли (алга таба – социаль өлкә инновацияләре үзәге).

2019 елда социаль өлкә инновацияләре үзәге традиция буенча Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем бирү учреждениесе белән берлектә берничә белем бирү программасы һәм чаралары үткәрде.

Төп чаралар арасында:

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләреннән эшсез халыкның үзмәшгульлегенә ярдәм итү программасы кысаларында «Эшмәкәрлек эшчәнлегендә бизнес-планлаштыру» гамәли семинары. Укыту кысаларында тыңлаучылар булачак эшмәкәрлек эшчәнлегенең бизнес-планын эшлиләр һәм аны яклау буенча тренинг үтәләр. 2019 елда 75 кеше белем алган, шуларның 33е бизнес-планнарын уңышлы яклап, шәхси эшмәкәр сыйфатында теркәлгән, шулай ук 145 100 сум күләмендә субсидия алган;

социаль эшмәкәрлек проектларын эшләүгә юнәлдерелгән «Эшмәкәрлек эшчәнлеге. Социаль эшмәкәрлек» һөнәри яңадан әзерләү программасы. 2019 елда 10 кеше белем алды, шул исәптән алга таба шәхси эшмәкәр яки коммерциячел булмаган оешма сыйфатында теркәлгән инициативалы гражданнар (нәтиҗәдә коммерциячел булмаган оешма Татарстан Республикасында Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына керде);

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен «Социаль проектлау һәм социаль проектлар белән идарә итү» һөнәри яңадан әзерләү программасы оешмаларның Татарстан Республикасында Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына керүе, халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүе һәм халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчаларын алуына «юл карталары»н эшләүгә юнәлдерелгән. Белем бирү программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре 2019 елда буенча 3 оешма Татарстан Республикасында Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына керде һәм тагын 1 оешма үзенең халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең санын арттырды;

«Коммерциячел булмаган оешмаларның эшлекле активлыгын арттыру механизмнары» квалификация күтәрү программасы, ул социаль-эшмәкәрлек проектларын үстерүгә һәм коммерциячел булмаган оешма эшенең социаль эшмәкәрләр белән охшаш бизнес-моделен булдыруга юнәлдерелгән

2019 елда социаль эшмәкәрлек, социаль-эшмәкәрлек проектларын үстерү һәм ярдәм чаралары буенча 600дән артык консультация үткәрелгән.

Социаль өлкә инновацияләре үзәге инициативасы буенча 2019 елның маеннан «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешмасында «Социаль эшмәкәр» дигән махсус кредит продукты (5 процентка ташламалы микрозайм) кертелде.

Гадәттәгечә, Социаль өлкә инновацияләре үзәге интернет-ресурсларда актуаль мәгълүмат урнаштыру юлы белән (сайт һәм социаль челтәрләр), шулай ук атна саен электрон адресларга дайджест-таратулар ясап, мәгълүмати ярдәм күрсәтә.

Ай саен социаль эшмәкәрлекне һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген популярлаштыру һәм социаль проектларга ярдәм итү чаралары турында бушлай семинарлар үткәрелә.

Өстәмә рәвештә Социаль өлкә инновацияләре үзәге Казан шәһәрендә һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарында социаль эшмәкәрлек һәм проектлау буенча 50дән артык белем бирү чарасын оештырды һәм үткәрде, шулай ук Идел буе федераль округының балалар йортларында тәрбияләнүчеләр һәм аны тәмамлаучылар өчен «Игелекле эшмәкәр» хәйрия проектында катнашты.

2019 елда Социаль өлкә инновацияләре үзәге катнашында барлыгы социаль эшмәкәрлекне һәм социаль проектлауны үстерүгә юнәлдерелгән 100дән артык белем бирү һәм башка чаралар узды.

*Бизнес өчен күпфункцияле үзәк*

2016 елда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат-консультация ярдәме күрсәтү максатларында Бизнес өчен күпфункцияле үзәк (алга таба – Бизнес өчен күпфункцияле үзәк) булдырылды.

Бизнес өчен күпфункцияле үзәк эшмәкәрләргә сервис югары дәрәҗәдә булган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итә. Әлеге проект мәгълүмат, хезмәт күрсәтүләр һәм ярдәмнән (дәүләт һәм муниципаль) файдаланганда эшмәкәрләрнең вакытын минимальләштерергә тиеш.

Бизнес өчен күпфункцияле үзәкнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

«бер тәрәзә» принцибын гамәлгә ашыру – бизнес өчен күпфункцияле үзәк базасында барлык дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарга һәм юридик затларга кирәкле документларны бердәм кабул итү, теркәү һәм бирү урынын булдыру, гражданнарга һәм юридик затларга бер үк вакытта үзара бәйләнгән берничә дәүләт һәм муниципаль хезмәт алу мөмкинлеген бирү;

федераль дәүләт хезмәтләре порталы, дәүләт хезмәтләре порталының төбәк сегменты белән мәгълүмат алмашуны оештыру;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының, «Кече һәм урта эшмәкәрлек корпорацияләре» акционер җәмгыятенең һәм «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды» КБОның ярдәм итү программалары буенча эшмәкәрләргә мәгълүмат бирү.

Казан шәһәрендә Эшмәкәр йортында бизнес өчен флагман күпфункцияле үзәк эшләп килә, анда 6 кабул итү тәрәзәсе эшли. Эшмәкәр «бер тәрәзә» режимында 60тан артык хезмәт алырга мөмкин.

2019 елда Бизнес өчен күпфункцияле үзәк хезмәтләреннән 1200 артык уникаль кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары файдаланган, аларга 10 меңнән артык хезмәт күрсәтелгән.

*Кече һәм урта эшмәкәрлек бизнес-навигаторы порталы*

Кече һәм урта эшмәкәрлек бизнес-навигаторы порталы – эшмәкәрләр өчен «Кече һәм урта эшмәкәрлек корпорацияләре» акционер җәмгыяте тарафыннан оештырылган бушлай онлайн-ресурс. Әлеге портал ярдәмендә эшмәкәр яки булачак эшмәкәр түбәндәгеләрне эшли ала:

якынча бизнес-план исәпли;

кече һәм урта бизнеска ярдәм итү чаралары турында белә;

бизнес өчен арендага бүлмә сайлый;

эре заказчыларның сатып алу планнары турында хәбәрдар була һәм башка бик күп нәрсәләр.

Татарстан Республикасында эшмәкәрләр әлеге порталдан актив файдалана. Онлайн-ресурсның дүрт ел эшләү дәверендә 120 меңнән артык кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары әлеге ресурстан файдаланган.

2019 елда республикада 10 меңнән артык уникаль субъект теркәлгән.

*Татарстан Республикасы Яшьләр инновацияле иҗаты үзәкләре*

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә 19 үзәктән торган яшьләр инновацияле иҗаты үзәкләре һәм кванториумнар челтәре булдырылды, алар*:*

булачак инженер-техник кадрлар өчен база формалаштыралар, аны булдыру Стратегия-2030 белән билгеләнгән;

инженер кадрларны әзерләргә генә түгел, ә тәрбияләнүчеләрнең эшмәкәрлек күнекмәләрен үстерергә дә ярдәм итәләр.

Бу Казан шәһәрендә 5 үзәк, Чаллы шәһәрендә 2 үзәк һәм Саба, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Мамадыш, Чистай, Чүпрәле, Лаеш, Биектау, Түбән Кама һәм Зеленодольск муниципаль районнарында 12 үзәк.

*Татарстан Республикасының индустриаль (сәнәгать) парклары һәм сәнәгать мәйданчыклары*

Инвестицион климатны яхшыртуның иң реаль юлы – төгәл бер бүленгән территориядә яңа производстволар булдыру һәм үстерү өчен максималь уңайлы шартлар тудыру. Сәнәгать парклары һәм сәнәгать мәйданчыклары булдыру бу мәсьәләне хәл итүнең нәтиҗәле ысулы булып тора. Мондый проектларны гамәлгә ашыру кече һәм урта эшмәкәрлек тармак структурасы белән бәйле мәсьәләләрне системалы хәл итәргә, эшлекле активлыкны арттырырга, шулай ук булдырыла торган эш урыннары рәвешендә социаль характердагы проблемаларны вакытында хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасын булдыру эше дәвам итә. Бүгенге көндә 100 объект эшли (шул исәптән муниципаль дәрәҗәдәге 80 сәнәгать мәйданчыгы һәм

20 сәнәгать паркы), аларда 1 484 резидент эшчәнлек алып бара, 31 меңнән артык эш урыны булдырылган. 2019 ел нәтиҗәләре буенча җитештерелгән продукция күләме 204,3 млрд сум тәшкил итте.

«Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм индивидуаль эшмәкәрлек инициативасына ярдәм итү» илкүләм проекты кысаларында «Җитештерү һәм инновация компанияләре төзү (үстерү) максатларында җитештерү мәйданнарына һәм биналарына кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының ташламалы үтемлелеген тәэмин итү» чарасын гамәлгә ашыру өчен 3 проектны («Саба» сәнәгать паркы, «Теләче» сәнәгать паркы һәм «Химград» технополисы территориясендә шәхси эшмәкәр) тормышка ашырырга 791,7 млн сум бүлеп бирелгән. Татарстан Республикасы бюджетын исәпкә алып, чарага 977,5 млн сум тотылган. Әлеге чара дәүләт-шәхси партнерлык механизмын кулланып тормышка ашырыла.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына (170 млн сум) өстәмә рәвештә «Урыссу», «Арча» һәм «Буа»сәнәгать парклары булдырылды.

Татарстан Республикасында 2019 елда КУЭ субъектларына ташламалы ставка буенча арендага бирү өчен мөлкәт исемлеген раслау буенча эш дәвам итә.

Муниципаль мөлкәт исемлеге Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында, шулай ук республиканың 32 шәһәр һәм 33 авыл җирлегендә расланган. Хәзерге вакытта әлеге исемлеккә 788 күчемле һәм күчемсез милек объекты кертелгән.

*Төбәк лизинг компаниясе*

Татарстан Республикасы «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорация» акционер җәмгыяте җиһазларына ташламалы лизинг программасы кысаларында төбәк лизинг компаниясен төзүгә Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче булды. «Татарстан Республикасының Төбәк лизинг компаниясе» акционер җәмгыяте (алга таба – РЛК) 2017 елның 3 августында теркәлгән. Аның программасы югары технологияле җиһазлар, сәнәгать җиһазлары һәм авыл хуҗалыгы эшкәртү өлкәсендә җайланмалар лизингын күздә тота. Лизинг компаниясе эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган иң эре заказчыларның сатып алуларына шәхси һәм кече эшмәкәрлек субъектларының үтеп керүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Лизинг компаниясен булдыру нәтиҗәсендә, шәхси һәм кече эшмәкәрлек субъектлары технологик яктан яңадан коралландыруны, җиһазландыруны яки яңа производство төзүне, шул исәптән турыдан-туры импортны алыштыру, инновацион продукция булдыру, шулай ук эре корпорацияләр ихтыяҗлары өчен беренче һәм икенче дәрәҗәдәге тәэмин итүчеләр сыйфатында катнашу мөмкинлегенә ия булдылар, сатып алу базары елына 2 трлн сумнан артык бәяләнә.

РЛК лизингка җиһазларны базар бәясеннән 3 тапкыр кимрәк алырга мөмкинлек бирә (*нәтиҗәле ставка: РЛК – 6 процент, базар ЛК – 18 процент*).

РЛК 2 млрд сумнан артык суммага 68 проект хуплады (2017 елдан башлап җыелма нәтиҗә). 2019 елда Россия Федерациясе буенча тулаем алганда 738,1 млн сумлык 26 проект финансланган, шул исәптән Татарстан Республикасы буенча 428,8 млн сумлык 10 проект.

*«Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе*

«Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе 2013 елдан башлап консультация һәм мәгълүмати ярдәм өлкәсендә хезмәт күрсәтү, шулай ук Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү программаларын гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек алып бара. Мәсәлән, газ-мотор ягулыгы үсешен стимуллаштыра торган программа. Әлеге программаны гамәлгә ашыру кысаларында техник хезмәт күрсәтүнең аккредитация узган күчмә пунктларга юридик һәм физик затларның транспорт чараларын метанга күчерү нәтиҗәсендә алынмаган керемне кайтаруга субсидия бирелә. Техника төренә карап чыгымнарның 30 процenttan артмаган өлеше субсидияләнә. Программа 2016 елдан бирле тормышка ашырыла. Бу вакыт эчендә компримацияләнгән газ – метанга күчерелгән транспорт чараларының гомуми сан 3 857 берәмлек тәшкил иткән, бирелгән субсидияләр күләме – 111,2 млн сум.

«Процент ставкасын субсидияләү» программасы чаралары кысаларында программада катнашучыларга Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле фактта җитештерелгән һәм документаль расланган барлык чыгымнар елына 10 млн сумнан артмаган күләмдә каплана. Субсидияне КУЭ субъектлары, идарәче компанияләр һәм аларның резидентлары, экспорт юнәлешле КУЭ субъектлары һәм режимлы объектның җитештерү мәйданчыгы территориясендә эшчәнлек алып баручы КУЭ субъектлары алырга мөмкин. 2019 елда 57 эшмәкәр 130,26 млн сумлык ярдәм алды. Кредит килешүләренең гомуми суммасы 3,4 млрд сум тәшкил итте.

Бизнес-инкубаторны үз эше өчен урын итеп сайлау эшмәкәрләргә аеруча уңай шартларда үз бизнесларын үстерергә мөмкинлек бирә. Бизнес-инкубаторлар шәһәрнең үзәк өлешләрендә урнашкан, алар офис бүлмәләре белән җиһазландырылган. Бизнес-инкубатор резидентлары офисларны ташламалы бәядән арендага ала. Бизнес-инкубатор командасы, индивидуаль эш планын төзү һәм алып баруны, инвестицион, финанс һәм маркетинг тәкъдир итүләре материалларын әзерләүдә ярдәм күрсәтүне, очрашуларда, чараларда катнашуга әзерлекне, потенциаль заказчыларны, партнерларны, һәр төгәл бер проект өчен инвесторларны җәлеп итүдә ярдәм итүне, белем бирү программаларында катнашуны кертеп, резидент эшчәнлегенә һәрьяклап бушлай ярдәм күрсәтә.

*Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме*

2019 елда КУЭ субъектларына дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасында 2,6 млрд сум (шул исәптән 1,6 млрд сум федераль бюджет акчалары исәбеннән) юнәлдерелгән, шулардан:

шәхси һәм дәүләт сәнәгать паркларын һәм мәйданчыкларын төзүгә һәм үстерүгә – 1,147 млрд сум;

кредитлар, микрозаймнар һәм субсидияләр буенча җаваплылык бирү рәвешендә финанс ярдәме күрсәтүгә – 750 млн сумнан артык;

авыл хуҗалыгында эшләүче КУЭ субъектларына ярдәм итүгә – 400 млн сум;

мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү чараларына, укытуга, эшмәкәрлекне популярлаштыру һәм товарларны базарга чыгаруга – 250 млн сумнан артык;

экспорт юнәлешле КУЭ субъектларына ярдәм итүгә (бизнес-миссия, күргәзмәләр, сертификация, мәгълүмати материаллар, тәрҗемәләр, укыту һ.б.) – 120 млн сумнан артык акча каралган.

*Кече һәм урта бизнесның сатып алуларда катнашу мөмкинлеге*

Республикада үткәрелә һәм планлаштырыла торган сатып алулар турында консолидацияләнгән мәгълүмат бирә торган (79дан артык ресурс) махсус электрон мәйданчыклар (bp.zakazrf.ru һәм smb.tattis.ru) булдырылды. Smb.tattis порталы ярдәмендә 2019 елда республиканың кече бизнес субъектлары 137,4 млрд сумнан артык суммага 44 620 артык контракт төзегән. Биржа мәйданчыгы ярдәмендә – 439,9 млн сумга 44,6 мең килешү.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан сатып алулар өлешен арттыру максатларында Татарстан Республикасының 14 эре заказчысының товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу планнары проектларының туры килүенә бәя бирелә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 19 апрель, 717-б номерлы боерыгы). Бу Идел буе федераль округында төбәк заказчыларының иң күп саны.

Татарстан Республикасының җайга салынулы заказчылары исемлегенә түбәндәгеләр керә:

1. «Казметрострой» акционер җәмгыяте.
2. «Казэнерго» акционер җәмгыяте.
3. «Сетевая компания» ачык акционер җәмгыяте.
4. «Татавтодор» акционер җәмгыяте.
5. «Татспиртпром» акционер җәмгыяте.
6. «Татхимфармпрепараты» акционер җәмгыяте.
7. «Таттелеком» гавами акционер җәмгыяте.
8. «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте.
9. «Татагролизинг» акционер җәмгыяте.
10. «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе.
11. «Энергопрогресс» инженер үзәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.
12. «Инженер челтәрләрен капиталь төзү һәм Татарстан Республикасының энергия саклау технологияләрен үстерү идарәсе» акционер җәмгыяте.
13. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчер үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе.
14. «Инвестицияләр һәм инновацияләр республика агросәнәгать үзәге» акционер җәмгыяте (РАЦИН).

Әйтик, 2019 елда КУЭ субъектларыннан сатып алулар планлаштырылган сатып алуларның еллык күләменнән кимендә 15 процентын тәшкил итәргә тиеш иде. Әлеге заказчыларның еллык сатып алу күләме 61,3 млрд сум тәшкил итте, шулардан КУЭ субъектларыннан – 22,1 млрд сум, ягъни 35,9 процент.

Моннан тыш, Республика маркетинг үзәге (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 5 мартындагы ПУ-157 номерлы Указы) республикада җитештерелә һәм республика территориясенә кертелә торган товарларның күләме

һәм бәясе турындагы мәгълүматны анализлау нигезендә КУЭ субъектлары өчен перспективалы инвестиция урыннары турында мәгълүмат формалаштырыла.

Маркетинг үзәге коммерциячел оешмаларга сатып алуларны урнаштырырга һәм конкурс аша тәэминатчыларны сайлап алырга мөмкинлек бирә. Маркетинг үзәге эшләгән чорда 4 300дән артык сәүдә уздырылган. Шул ук вакытта эре заказчылар – «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, «Татспиртпром» акционер җәмгыяте, «Сетевая компания» ААҖ, «АК БАРС Девелопмент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте. Бу бөтен илнең кече бизнесы өчен коммерциячел заказларның бик зур базары.

Шулай ук кайбер предприятиеләр өчен шәхси үсеш карталары формалаштырыла, аларны гамәлгә ашыру кысаларында яңа җитештерү корпусларын төзүгә, ташламалы шартларда сатып алынган җиһазлар урнаштыруга 340 млн сумнан артык акча җәлеп ителгән. Шулай ук гамәлдәге үсеш карталары чараларын гамәлгә ашыру кысаларында предприятиеләр өчен маркетинг тикшеренүләре үткәрелде, алар базарның сыешлыгын һәм республикада гына түгел, бөтен Россия буенча продукция чыгаруга потенциаль заказчыларны билгеләргә мөмкинлек бирде.

## Дәүләт идарәсе


*Программалы-максатчан идарә системасын камилләштерү*

Дәүләт программалары дәүләт бурычларын тормышка ашыруда һәм финанс ресурсларын бүлү һәм контрольдә тоту процессларын оптимальләштерүдә нәтиҗәле корал булып тора.

2019 елда Татарстан Республикасының 32 дәүләт программасы тормышка ашырылды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 декабрь, 991 нче карары белән расланган «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында товар аквакультурасын (товар балыкчылыгын) үстерү» дәүләт программасы гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр туктатылды, чөнки әлеге программа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән аерым норматив актлары исемлегенә кертелгән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2018 ел, 11 декабрь, 1113 нче карары).

2019 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанслауның факттагы күләме 317,5 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 38,3 млрд сум (12 процент), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 234,2 млрд сум (73,8 процент), җирле бюджетлар акчалары исәбеннән – 3,1 млрд сум (1 процент), бюджеттан тыш чыганаклардан – 41,9 млрд сум (13,2 процент).

**2009 – 2019 елларда Татарстан Республикасында дәүләт программаларын финанслау динамикасы, млрд сум**




2020 елда Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын гамәлгә ашыруга 300,8 млрд сум бүлеп бирү каралган, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 36,1 млрд сум (12 процент), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 214,6 млрд сум (71,3 процент), җирле чыганаклар акчалары исәбеннән – 2,1 млрд сум (0,7 процент), бюджеттан тыш чыганаклардан – 48 млрд сум (16 процент).

2019 елда һәм 2020 елга план чорына Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанслау турында мәгълүмат

| Т/б № | Дәүләт программасы исеме | Җаваплы үтәүче | Финанслау күләмнәре, млн сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2019 ел | 2020 ел (план) |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | 2014 – 2025 елларда Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 63 989,2 | 60 413,5 |
| 2 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | 46 441,6 | 30 346,1 |
| 3 | 2014 – 2025 елларда Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 22 706,8 | 30 648,3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4 | 2013 – 2022 елларда Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 17 891,6 | 16 180,2 |
| 5 | 2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауны үстерү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 70 482,9 | 77 990,6 |
| 6 | 2014 – 2024 елларда Татарстан Республикасы дәүләт финанслары белән идарә итү | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 14 678,4 | 10 895,4 |
| 7 | 2014 – 2019 елларда Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 18 121,0 | 20 496,6 |
| 8 | 2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | 4 819,4 | 7 937,2 |
| 9 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | 3 814,9 | 5 588,5 |
| 10 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 10 655,3 | 9 088,8 |
| 11 | 2014 – 2024 елларда Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 12 882,0 | 6 224,0 |
| 12 | 2014 – 2022 елларда «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 3 690,6 | 2 838,2 |
| 13 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасы дәүләт милкәте белән идарә итү | Татарстан Республикасы Җир һәм милкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 2 332,0 | 260,4 |
| 14 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм коррупциягә каршы көрәш | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы | 2 188,7 | 2 230,1 |
| 15 | 2014 – 2025 елларда Татарстан | Татарстан Республикасы | 1 891,1 | 1 794,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү | Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | |
| 16 | Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 5 253,2 | 8 388,0 |
| 17 | 2014 – 2024 елларда Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | 6 186,0 | 2 474,0 |
| 18 | 2014 – 2024 елларда Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | 1 089,9 | 950,3 |
| 19 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый ресурсларын яңадан торгызу һәм куллану | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | 1 258,6 | 1 453,9 |
| 20 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасында юстицияне үстерү | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 708,1 | 579,4 |
| 21 | 2013 – 2023 елларда Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | 1 148,0 | 1 490,0 |
| 22 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 122,9 | 123,4 |
| 23 | 2015 – 2020 елларда Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 119,1 | 119,1 |
| 24 | 2019 – 2021 елларда Татарстан Республикасы территориясендә автомобильгә газ тутыру | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 273,7 | 800,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | коммпрессор станцияләре төзү | | | |
| 25 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү | Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты | 120,1 | 394,3 |
| 26 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 64,5 | 67,1 |
| 27 | 2014 – 2022 елларда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 48,0 | 35,6 |
| 28 | Татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу (2014 – 2022 еллар) | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 33,5 | 44,7 |
| 29 | 2015 – 2022 елларда Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 9,4 | 8,8 |
| 30 | 2016 – 2022 елларда Татарстан Республикасында архив эшен үстерү | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты | 281,4 | 245,4 |
| 31 | 2019 – 2022 елларда чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ихтыярый күчеп килүенә ярдәм итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 1,5 | 2,4 |
| 32 | 2018 – 2022 елларга Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр тирәлеген формалаштыру | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 4 214,1 | 3 238,0 |
| Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруга барлыгы, шул исәптән: | | | 317 517,5 | 300 789,9 |
| Россия Федерациясе бюджеты | | | 38 259,5 | 36 127,3 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | | 234 225,4 | 214 545,4 |
| Җирле бюджетлар | | | 3 122,9 | 2 104,8 |
| Бюджеттан тыш чыганаклар | | | 41 909,7 | 48 012,4 |

*Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре системасын үстерү*

Бүген Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ) офисларының киң челтәре

булдырылды, алар Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында һәм шәһәр округында, шулай ук 1 меңнән артык халкы булган Татарстан Республикасы авыл җирлекләрендә эшли.

Республиканың КФҮ системасы үз эченә ала:

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – КФҮ ДБУ) республика буенча филиаллар челтәре белән;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча «Минем документлар» КФҮ ДБУ 59 үзәге һәр муниципаль районда һәм берничә офис – Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә;

Казан шәһәрендә Петербург ур., 28 йорт (Эшмәкәр йорты) адресы буенча 1 өстәмә офис (бизнес өчен КФҮ);

Саклык банкының Казан шәһәрендә (Җиңү проспекты, 62\4 йорт) һәм Чаллы шәһәрендә (Сөембикә проспекты, 16 йорт) бүлекчәләре базасында 2 хезмәт күрсәтү үзәкләре;

1 меңнән артык халкы булган авыл җирлекләрендә КФҮнең 281 территориаль-аерымланган структур бүлекчәсе (ТОСП – ерактан торып кабул итү тәрәзәсе) (аларда хезмәт җирлекләргә чыгып күрсәтелә).

Хезмәт күрсәтүләрнең якын булуын арттыру өчен даими нигездә КФҮ кабул итү офисларының санын арттыру буенча эш алып барыла.

2018 – 2019 елларда Казан шәһәрендә Дәрвишләр бистәсе, Юдино микрорайоннарында, Казан шәһәренең Совет районында (Җиңү Проспекты ур., 214йорт), «Салават Күпере» торак комплексында өстәмә дүрт үзәк, шулай ук Чаллы шәһәрендә зур яңа офис ачылды. 2019 елның декабрендә Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында яңа КФҮ һәм Түбән Кама шәһәрендә КФҮ мини-офисы эшли башлады.

Татарстан Республикасында КФҮ үзәкләре гариза бирүчеләргә (физик һәм юридик затларга) көн саен 200 дән артык дәүләт һәм муниципаль хезмәт түрен түбәндәге норматив хокукый актларда билгеләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә «бер тәрәзә» принцибы буенча бирә:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре белән федераль башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек турында» 2011 ел, 27 сентябрь, 797 нче карары:

17 мәҗбүри федераль хезмәт;

66 тәкъдим ителгән (федераль, төбәк, муниципаль) хезмәт;

14 федераль хезмәт, аларның нәтиҗәсе булып, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан булган мәгълүматны үз эченә алган документ тора;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары:

федераль хакимият органнары һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары (Росреестр, Салым хезмәте, Эчке эшләр министрлыгы (шул исәптән миграция линиясе буенча), ЮХИДИ), Росимущество, Роспотребнадзор, Суд приставларының федераль хезмәте, Пенсия фонды, Социаль иминият фонды, Россия Федерациясе Цифрлы үсеш министрлыгы, Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе хезмәтләре;

Татарстан Республикасы төбәк хакимият органнары һәм оешмалары хезмәт күрсәтүләре (ЗАГС, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы органнары, архив, социаль яклау, эш белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Кадастр бәяләве үзәге, БТИ өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр);

муниципаль хезмәт күрсәтүләр;

гражданнар өчен башка өстәмә хезмәтләр (Алданган кертемчеләр һәм акционерларның федераль фондына гаризалар бирү, машина йөртүче картасын алу, электрон цифрлы имза ясау, күчермәләү, килешүләр төзү, юридик консультацияләр күрсәтү буенча түләүле хезмәтләр күрсәтү).

2019 елда гына да КФҮ салым хезмәтенең, пенсия фондының, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, Техник инвентаризация бюросының, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының өстәмә 30га якын федераль һәм төбәк хезмәтләре өстәлә.

Гаризалар кабул итү һәм нәтиҗәләрен бирүдән тыш КФҮ гражданнарга «Скайп» видеосистемасы аша турыдан-туры хакимият органнары хезмәткәрләре белән, мәсәлән, Роспотребнадзор, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе, «Тикшерелгән бизнес» порталы консультантлары белән элемтәгә керү мөмкинлеген тәэмин итә. Республиканың һөнәри керемгә салым түләүчеләр («үзмәшгульләр») сыйфатында теркәү буенча пилот проектында катнашуы кысаларында һәр КФҮдә хезмәткәрләр теркәлү процедурасын узуда ярдәм итәчәкләр. 2019 елда КФҮ 2,4 мең үзмәшгуль кеше теркәлгән, шулай ук күрсәтелгән мәсьәлә буенча 40 меңнән артык граждан консультацияләр алган.

Барлык хакимият органнары һәм КФҮ ДБУ оешмалары белән үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешүләр төзелде.

Хезмәтләр исемлеге даими рәвештә киңәйтелә, күрсәтелгән хезмәтләр саны арта бара: 2016 елда – 2,7 млн хезмәт; 2017 елда – 3,4 млн хезмәт; 2018 елда – 3,7 млн хезмәт, 2019 елда – 4,9 млн хезмәт.

Гариза бирүчеләргә уңайлы булсын өчен Ярдәм белешмә хезмәте – КФҮ колл-үзәге (телефон: (843) 222-06-20) эшли, аның буенча атнага алты көн (шул исәптән татар телендә) сораулар белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, гариза бирүчеләргә документларның әзерлеге турында СМС-мәгълүмат бирү гамәлгә ашырыла.

2018 елдан башлап КФҮдә аерым хезмәтләргә карата комплекслы соратып алу кысаларында документлар бирү кертелде, ул чакта гариза бирүче берничә хезмәт күрсәтүгә бер гариза бирә, бу исә кабул итү вакытын шактый киметә.

*Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мониторингы*

Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мониторингы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм алар карамагындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген функциональ анализлау методикасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2011 ел, 5 март, 178 нче карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү мониторингы методикасын раслау турында» 2008 ел, 4 август, 560 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү кысаларында гамәлгә ашырыла. 2019 елда дәүләт хакимиятенең 11 башкарма органында анализ үткәрелгән.

2018 – 2019 елларда «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мониторингы кысаларында республика дәүләт хакимиятенең 29 башкарма органында, 6 муниципаль районда һәм КФҮ ДБУнең 6 филиалында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күчмә тикшерү уздырылды.

Күрсәтелгән чаралар нәтиҗәләре буенча хезмәт күрсәтү процедураларын оптимальләштерү һәм эшне камилләштерү, җитешсезлекләрне бетерү максатларында республика хакимият органнары һәм учреждениеләре адресына бәяләмәләр җибәрелде, күрсәтелгән рекомендацияләрнең үтәлешен даими рәвештә анализлыйлар.

Шулай ук 2019 ел дәвамында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан расланган КФҮ ДБУ бүлекләрен һәм филиалларын тикшерү планы-графигы нигезендә, КФҮ ДБУнең үзәк аппараты комиссиясе барлык филиалларын һәм бүлекләрен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы һәм 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы карарлары таләпләренә туры китереп тикшерү уздырды. Мондый тикшерүләр барышында КФҮ филиалларында һәм бүлекләрендә гариза бирүчеләрне кабул итү тәрәзәләре эше, хезмәт күрсәтү стандартын үтәү, документларны исәпкә алу журналларын алып бару, хезмәткәрләрнең тышкы кыяфәте бәяләнде. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча КФҮнең барлык филиаллары һәм бүлекләре билгеләнгән таләпләргә туры килә.

Күрсәтелгән федераль дәүләт хезмәтләренең сыйфатын бәяләү максатларында КФҮнең барлык филиалларында һәм бүлекләрендә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы заказы буенча оештырылган «Сезнең контроль» дәүләт хезмәтләре сыйфаты мониторингы мәгълүмати-аналитик системасы кулланыла.

Федераль хакимият органы хезмәтен алган гражданнар, шул исәптән аның артыннан республиканың КФҮ филиалларына һәм бүлекләренә мөрәҗәгать иткәндә, үзләре өчен иң уңайлы ысулны сайлап, хезмәт сыйфатын бәяләү мөмкинлегенә ия:

«0919» рәсми кыска номерыннан түләүсез СМС-сораштыруда катнашу;

«Сезнең контроль» мәгълүмати-аналитик системасы сайтында vashkontrol.ru хакимият органы яисә КФҮ ДБУ эше турында бәяләмәне калдырырга (шул исәптән сылтама буенча КФҮ рәсми сайты mfc16.tatarstan.ru аша);

КФҮ филиалларында һәм бүлекләрендә һәм республика хакимият органнарында урнаштырылган «Электрон хөкүмәт» инфоматлары аша бәяне калдырырга.

«Сезнең контроль» системасына КФҮ ДБУдән көн саен КФҮ филиалларында һәм бүлекләрендә урнаштырылган инфоматлардан файдаланып җыелган гражданнарның күрсәтелгән бәяләмәләре һәм түләүсез СМС-сораштыруларда катнашу өчен КФҮ ДБУга мөрәҗәгать иткән гражданнарның телефон номерлары җибәрелә.

Шулай итеп, «Сезнең контроль» системасының 2018 елдагы эш йомгаклары буенча аналитик мәгълүматына караганда, гражданнар һәм эшмәкәрлек субъектларының хезмәт күрсәтү сыйфаты белән канәгать булу дәрәҗәсе 97 процент, 2019 елда 98,2 процент тәшкил иткән, бу федераль нормативтан шактый артыграк (кимендә 90 процент).

Шулай ук ел саен Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы халкының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты белән канәгать булу дәрәҗәсен тикшерү буенча дәүләт хакимияте органнарында да, шулай ук КФҮ ДБУ аша да социологик сораштыру үткәрелә. 2019 елда үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләре буенча күрсәткеч 96 процент тәшкил итте, бу федераль нормативтан шактый артыграк (кимендә 90 процент).

*Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының эшен координацияләү*

2019 елда республикада контроль-күзәтчелек эшчәнлеген дәүләт хакимиятенең түбәндәге башкарма органнары (алга таба – контрольдә тотучы дәүләт хакимияте башкарма органнары нәтиҗәләре) гамәлгә ашырды:

контрольнең (күзәтчелекнең) 20 төбәк төрен гамәлгә ашыручы 15 контрольдә тотучы дәүләт хакимияте башкарма органы;

контрольнең (күзәтчелекнең) 8 федераль төрен гамәлгә ашыручы 4 контрольдә тотучы дәүләт хакимияте башкарма органы;

контрольнең (күзәтчелекнең) 36 контрольлек (күзәтчелек) төрен гамәлгә ашыручы 15 контрольдә тотучы федераль башкарма хакимият органы.

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында (алга таба – 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон) кысаларында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 31 гыйнварындагы 147-б номерлы боерыгы белән расланган «Россия Федерациясе субъектларында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделе нигезендә 2019 елда:

контрольдә тотучы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән методологик эш үткәрелде, мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча җитәкчелекнең 116 экспертизасы, профилактиканың ведомство программаларына 70 экспертиза, хокук куллану практикаларына гомумиләштерелгән 70 экспертиза үткәрелде;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында республика буенча гавами чаралар үткәрүнең җыелма план-графигы һәм барлык төбәк контроле (күзәтчелеге) төрләре буенча мәҗбүри таләпләрнең җыелма исемлеге урнаштырылды;

контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә мониторинг ясалды;

республика башкарма хакимиятенең 13 органы тарафыннан әзерләнгән дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында 16 докладка һәм 2018 елда уздырылган тикшерү-күзәтү чараларын гамәлгә ашыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасының 43 муниципаль районы һәм 2 шәһәр округы әзерләгән Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына гамәлгә ашыру өчен тапшырылган муниципаль контроль һәм дәүләт контролен гамәлгә ашыру турында 84 докладка экспертиза үткәрелде. Татарстан Республикасы буенча дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында тупланган җыелма докладлар «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында урнаштырылган;

муниципаль контроль органнары башкара торган контроль эшчәнлекне камилләштерү буенча чаралар планы («юл картасы») проекты һәм Татарстан Республикасында «Россия Федерациясе субъектларында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен кертү буенча чаралар планы («юл картасы») эшләнде;

республика хакимиятенең 9 контроль органы буенча А төркеменең контроль (күзәтчелек) гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре эшләнде һәм әлеге күрсәткечләргә паспортларга экспертиза үткәрелде. Тиешле күрсәткечләр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә кертелгән.

2019 елда контроль-күзәтчелек эшчәнлеген камилләштерү максатларында түбәндәгеләр оештырылды:

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Контроль-күзәтчелек һәм рөхсәт итү эшчәнлеге департаменты директоры урынбасары катнашында «түгәрәк өстәл» (29 гыйнвар);

инспекторлар составының квалификациясен күтәрү буенча ике укыту программасы (28 – 30 гыйнвар һәм 12 – 14 август);

республикада федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләре катнашында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру һәм Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» проектын тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем утырышлары. Утырышларда федераль башкарма хакимият органнарының федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле территориаль

органнары эшчәнлегенең Татарстан Республикасында инвестицион климат торышына йогынтысы мәсьәләсе каралды. Утырышлар нәтиҗәләре буенча 2019 елда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлегенә һәм (яки) алар тарафыннан кулланылучы җитештерү объектларына карата куркынычлылык классына уртача, сизелерлек, түбән риск категориясенә яисә 4, 5, 6 классына карата контроль чаралар санын киметүне тәэмин итү буенча тәкъдимнәр бирелде (5 апрель һәм 28 декабрь);

«Россия Федерациясе субъектларында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планын («юл картасын») гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем утырышы (18 октябрь);

«Югары икътисад мәктәбе» милли тикшеренү университеты белән берлектә дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен К(ИБ)ФУ дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе базасында «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, шул исәптән контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең гамәлгә ашырыла торган реформасы идеологиясен исәпкә алып» темасы буенча укыту программасы уздырылды (10 – 14 сентябрь). Укуларны 150 тыңлаучы үтте.

2019 елда контроль-күзәтчелек эшчәнлеген мәгълүматлаштыру кысаларында, бурычларны үтәүне тәэмин итү, хокукларны гамәлгә ашыру һәм хакимият органнарының электрон формасында үзара бәйләнешен тормышка ашыру максатларында, аларның контроль-күзәтчелек эшчәнлеге мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау юнәлеше буенча «Профилактика» электрон модуле» проекты эшләнде.

«Профилактика» электрон модуле – уникаль эшләнмә, аның төп бурычы – ярдәм күрсәткечләр һәм аларның алдагы рейтинглары булган профилактик чараларны бәяләү системасының контроль органнары эшенә кертү. «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча типлаштырылган болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасына өстәмә ресурс буларак эшләнде. Аның максаты – хокук бозуларны профилактикалау өчен Татарстан Республикасында дәүләт контроле (күзәтчелеге) өлкәсендә ярдәм мәгълүмати киңлек булдыру.

Ел саен үткәрелә торган «Контроль нокта – 2019» иң яхшы практикалар федераль конкурсында Татарстан Республикасы «Төбәкләрдә контроль-күзәтчелек эшчәнлеген автоматлаштыру» номинациясендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча типлаштырылган болытлы карарда «Профилактика» тышкы төбәк модуле» проекты өчен 1 дәрәҗә диплом белән билгеләп үтелде.

2019 елда Татарстан Республикасы дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне камилләштерү буенча нәтиҗәле эше өчен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан «Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге отличнигы» мактау билгесе белән бүләкләнде.

*Җайга салу йогынтысын бәяләү*

2019 елда җайга салу йогынтысын бәяләү эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының җиде проектына карата уздырылды. Ачык

консультацияләр йомгаклары буенча эшмәкәрләрнең иҗтимагый оешмалары фикерен исәпкә алып, ике проект буенча тискәре бәяләмәләр әзерләнде.

2019 елда «Тикшерелгән бизнес»порталында проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр юллау юлы белән җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү кысаларында ачык консультацияләрдә катнашу мөмкинлеге гамәлгә ашырылды.

Даими нигездә норматив хокукый актларга экспертиза һәм факттагы йогынтыны бәяләү үткәрелә. 2019 елда өч норматив-хокукый актка карата фактик йогынтыны бәяләү үткәрелде. Үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча җайга салуның сайлап алынган ысуллары нигезле дип танылды.

Казан шәһәрендә җайга салу йогынтысын бәяләүне процедурасы 2015 елның гыйнварыннан бирле үткәрелә. 2019 елда җайга салу йогынтысын бәяләү процедурасы норматив-хокукый актларның 79 проектына карата үткәрелде.

2019 елда җайга салу йогынтысын бәяләү институты 27 муниципаль берәмлектә һәм Чаллы шәһәр округында гамәлгә кертелде.

Моннан тыш, җайга салу йогынтысын бәяләү институтын камилләштерү кысаларында төбәк дәүләт хакимияте органнарының федераль дәрәҗәдә нормалар иҗат итү процессында катнашу дәрәҗәсен арттыру өчен 2018 елдан башлап, Россия Федерациясе субъектларының икътисадый үсешенә һәм чыгым йөкләмәләренә аларның йогынтысы предметына норматив хокукый актлар проектларын бәяләү кертелде. Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмәләрне әзерләгәндә, Россия Федерациясе субъектлары тәкъдимнәрен исәпкә алып, төбәкләрнең икътисадый үсешенә йогынты ясаучы нигезләмәләргә карата позицияне мәҗбүри рәвештә чагылдырыла.

Татарстан Республикасы күрсәтелгән эштә актив катнаша, 2019 елда 15 проект каралды, республика позициясен исәпкә алып, 3 проектка карата тискәре бәяләмәләр формалаштырылды.

2019 ел нәтиҗәләре буенча җайга салу йогынтысын бәяләүне гамәлгә ашыру сыйфаты буенча төбәкләр рейтингында Татарстан Республикасы «югары дәрәҗәгә» кертелгән Россия Федерациясе субъектлары төркемендә калды.

*«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы).*

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы төрле социаль әһәмияткә ия проблемалар, шулай ук бизнес проблемалары турындагы мәгълүматны үз эченә алган гражданнар һәм эшмәкәрлек субъектлары гаризаларын бастырып чыгару һәм карап тикшерү системасын тәшкил итә. Система 2012 елның апрелендә эшли башлады.

Хәбәрнамәләр категорияләр буенча кабул ителә, шул исәптән территорияләрне төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалык, юл хәрәкәтен оештыру, юлларны карап тоту, коррупциягә каршы тору, сәүдә, реклама, хезмәт мөнәсәбәтләре кагыйдәләрен бозу, һәм башка өлкәләрдә, шул исәптән эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеге һәм аларның хакимият органнары белән хезмәттәшлеге өлкәсендә.

2019 елда «Халык контроле» мобиль кушымтасы 18 меңнән артык тапкыр йөкләтелгән, 77,1 меңнән артык хәбәрнамә бастырылган, аларның 60 меңнән артыгы

уңай хәл ителгән, бу 77 процент тәшкил итә, 11,6 меңе (19 процент) планлаштырылган, 0,6 мең хәбәрнамә (0,01 процент) эшкәртүдә, 4,7 мең хәбәрнамә мотивлаштырылган рәвештә кире кагылган (0,07 процент).

*Дәүләт сатып алулары*

Дәүләт сатып алулары өлкәсенә контракт системасының ачыклыгын һәм үтә күренмәлелеген тәэмин итүче, шул ук вакытта бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелеген һәм дәүләт идарәсе өлкәсендәге чараларның нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итүче цифрлы технологияләр актив керә.

Аерым алганда, республикада сатып алу процессын автоматлаштыру Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә Төбәк мәгълүмат системасы ярдәмендә тәэмин ителә, аны модернизацияләү һәм эшләп бетерү даими нигездә башкарыла. Сатып алулар системасын камилләштерү максатларында 2020 елда планлаштырылган:

документлар һәм контрактлар конструкторын төзү;

өстәмә функционал тарафыннан контрактның башлангыч (максималь) бәясен нигезләү механизмын эшләп бетерү, ул элек төзелгән контрактлар буенча товарлар бәясен чагыштыру юлы белән контрольне көчәйтәчәк;

«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аерым юридик затлар тарафыннан сатып алуларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган функционалны камилләштерү.

Моннан тыш, 2016 елдан гамәлгә кертелгән Татарстан Республикасы Сатып алулар өлкәсендә электрон документ әйләнеше системасы илдә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр һәм заказчылар арасында беренчел документлар белән юридик яктан әһәмиятле алмашуны тәэмин итә торган беренче система булып тора.

Системада 6 500дән артык кулланучы теркәлгән. Россиянең барлык заказчылары, ә 2020 елның 1 гыйнварыннан, шул исәптән барлык коммерциячел оешмалар да, системаны бушлай куллана алалар.

2019 елда Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан башлангыч (максималь) бәясе 50 млн сумнан артык булган сатып алулар мониторингы нәтиҗәләре буенча 18 хокук бозу очрагы ачыкланды (2018 ел нәтиҗәләре буенча – 21 бозу очрагы).

Сатып алуларны мониторинглау барышында алынган мәгълүматларны анализлау һәм системалаштыру нигезендә республика заказчылары өчен методик тәкъдимнәр эшләнә, шулай ук күрсәтелгән мәгълүмат дәүләт сатып алулары өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда исәпкә алына, бу алга таба хокук бозулар санын киметергә ярдәм итә.

Сатып алулар өлкәсендә заказчылар белгечләренең белем дәрәҗәсен билгеләү һәм саклау өчен ел саен автоматлаштырылган тест үткәрелә. 2019 елда барлыгы тестлаштыруда сатып алулар өлкәсендә 3 меңнән артык белгеч катнашты.

2019 елда 33 белем бирү чарасы үткәрелде, аларда заказ бирүчеләрдән һәм сатып алуларда катнашучылардан 2 меңнән артык белгеч катнашты.

Дәүләт һәм муниципаль сатып алулар салым түләүчеләр акчалары хисабына гамәлгә ашырыла, шуңа күрә аларны тоту нәтиҗәлелеге һәр заказчының иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора. Заказчылар тарафыннан үткәрелә торган контрольне көчәйтү максатларында түбәндәгеләр эшләнгән:

товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр кабул итү регламенты;

оештыру техникасына чыгым материалларын кабул итү регламенты;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе һәм Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә азык-төлек продуктларын кабул итү регламенты актуаль хәлдә.

Моннан тыш, республиканың дәүләт һәм муниципаль заказчыларына контрактны үтәү, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр кабул итү белән бәйле мәсьәләләр буенча методологик һәм консультацион ярдәм күрсәтелә.

Бүген товарларны стандартлаштыру, сатып алуларны үзәкләштерү, азык-төлек продукциясенең төгәл исемлеген һәм товарларны һәм азык-төлек продуктларын кабул итү регламентын булдыру, һичшиксез, республикада җитештерелә торган сыйфатлы продукция санын арттырды. Әмма продукцияне кәгазьдә закон таләпләренә туры килә торган, ә чынлыкта сыйфатсыз продукция, фальсификат яки заказчы таләпләренә туры килмәгән товар белән тәэмин итү мәсьәләсе һаман да актуаль булып кала бирә.

2019 елда Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы мәгълүматлары буенча, контракт системасы турындагы законнар нигезендә республиканың дәүләт һәм муниципаль заказчылары тарафыннан 155,7 млрд сумлык сатып алулар бастырып чыгарылган, төзелгән контрактлар нәтиҗәләре буенча бюджет акчаларын экономияләү 3,1 процент тәшкил иткән. Шул исәптән муниципаль заказчылар тарафыннан 26 млрд сумнан артык суммага сатып алулар бастырып чыгарылган, төзелгән контрактлар нәтиҗәләре буенча бюджет акчаларын экономияләү 5,6 процент тәшкил иткән.

2019 елда кече эшмәкәрлек субъектларыннан сатып алулар күләме якынча 17 млрд сум тәшкил итте. 13 млрд сумнан артык суммага кече күләмле сатып алулар буенча контрактлар төзелде, бу төзелгән контрактларның гомуми бәясенең 8,5 процентын тәшкил итә.

2019 елда 1 047 үзәкләштерелгән сатып алулар гамәлгә ашырылды, гомуми суммасы 5,6 млрд сум, шуның 76,8 проценты – республика оешмалары белән контрактлар. Уздырылган сатып алу процедуралары нәтиҗәләре буенча бюджет акчаларын экономияләү 7,3 процент тәшкил итте.

Килешүләр кысаларында аерым юридик затлар өчен гомуми суммасы 22,8 млрд сумлык 1 700 сатып алу урнаштырылган, конкурент сатып алулар нәтиҗәләре буенча бюджет акчаларын экономияләү 14,5 процент тәшкил иткән.

2019 елда республикада Татарстан Республикасының 10 муниципаль районының мәктәпкәчә балалар учреждениеләре өчен туклануны оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм республиканың барлык социаль әһәмиятле учреждениеләре ихтыяҗлары өчен сөт продукциясе белән тәэмин итүгә сатып алуларны үзәкләштерү эше дәвам итә.

Ел саен «Сатып алуларның ачыклыгы милли рейтингы» проекты кысаларында Татарстан Республикасы төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт заказчылары классында «Гарантияле ачыклык» иң югары бәясенә лаек.

*Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү*

2007 елдан башлап, Россия Федерациясе Президенты указларын үтәү йөзеннән, ел саен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү үткәрелә.

Дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре буенча Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) докладлы төзелә. Әлеге докладларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте ел саен Россия Федерациясе субъектлары рейтингын формалаштыра.

Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү системасы даими рәвештә төзәтелә.

Хәзерге вакытта субъектлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2019 елның 25 апрелендәге 193 номерлы Указы белән расланган 15 күрсәткечне үтәү нәтиҗәләре буенча үткәрелә:

1. Хакимияткә (Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затларына (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләренә) ышаныч дәрәҗәсе.
2. Икътисадның бюджеттан тыш секторында югары җитештерүчәнлекле эш урыннары саны.
3. Шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгульләр саны.
4. Икътисадның чимал булмаган төп тармакларында хезмәт җитештерүчәнлеге.
5. Уртача айлык хезмәт хакы дәрәҗәсе.
6. Төп капиталга инвестицияләр күләме, инфраструктур монополияләр (федераль проектлар) инвестицияләре һәм федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләреннән тыш.
7. Хәерчелек дәрәҗәсе.
8. Туганда көтелгән гомер озынлыгы.
9. Халыкның табигый үсеше.
10. Торак шартларын яхшырткан гаиләләр саны.
11. Торак алу мөмкинлеге дәрәҗәсе.
12. Уңайлы шәһәр мохите булган шәһәрләр өлеше.
13. Әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты.
14. Белем дәрәҗәсе.

15. Төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары һәм шәһәр агломерацияләрендәге автомобиль юллары норматив таләпләренә туры килә торган өлеше (йөкләнешне исәпкә алып).

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, федераль һәм төбәк дәүләт хакимияте органнары алдына куелган бурычларны үтәү буенча индикатив идарә итү системасы, башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшен ачык планлаштыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы – Россия Федерациясенең алдынгы төбәкләренең берсе.

Министрлыкларның һәм ведомстволарның эшчәнлек максатларының, бурычларының һәм нәтиҗәләренең үзара бәйләнешен тәэмин итүнең төп инструменты – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе (алга таба – Идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе).

Идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен фаразлау нигезендә формалаштырыла һәм Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указында, Татарстан Республикасы Президенты Юлламасында, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән өстенлекле бурычларны үтәүне чагылдыра торган төп индикаторларны үз эченә ала.

Идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе кысаларында ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге бәяләнә. 2019 елга ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче карары белән расланган.

## ИННОВАЦИЯЛӘР

### Инновацияле үсеш

Хәзерге шартларда дөнья икътисадына интеграцияләнгән конкурентлыкка сәләтле инновацион икътисадны формалаштыруның мөһим өстенлекләре – технологик үсешне тизләтү, кластер сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт, фән һәм бизнес институтларының тыгыз хезмәттәшлеге юлы белән төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту.

Татарстан Республикасында 2012 елдан әлеге бурычлар, шул исәптән икътисадның ике эре секторын – автопром һәм нефть химиясен үстерү буенча махсуслашкан «ИННОКАМ» Кама инновацияле территориаль-җитештерү кластерын (алга таба – ИННОКАМ) үстерү нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла.

Бүген ИННОКАМда Россия синтетик каучукларының 45 проценты, стирол полимерларының 55 проценты, Россиянең һәр өченче йөк автомобиле һәм һәр икенче йөк шинасы җитештерелә. Кластерда ике белгечлек (нефть химиясе һәм автосәнәгать) арасында икътисадның инновацион өлкәләрендә яңа производстволар оештырыла: IT-технологияләр, робототехника, аддитив технологияләр, заманча материаллар, шулай ук инжиниринг, яшел технологияләр.

2016 елдан Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан ИНОКАМ «Инновацион кластерларны үстерү – дөнья дәрәҗәсендәге инвестицион җәлеп итүчәнлек лидерлары» өстенлекле федераль проектында катнашучы 12кластер исемлегенә кертелде.

Кама агломерациясендә инфраструктур чикләүләрне бетерү, ИННОКАМ предприятиеләренең конкурентлылык сәләтен арттыру максатларында (*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 июнендәге 1257-б номерлы боерыгы*) «ИнноКам» территориаль аерымланган инновацион-җитештерү үзәген булдыру концепциясе расланды, аңа энергия белән тәэмин итү, транспорт, инженерлык, социаль инфраструктураны үстерү, шулай ук импортны алмаштыру, модернизацияләү һәм яңа производстволарны ачу өлкәсендәге 79 өстенлекле инфраструктура һәм инвестицион проект керде.

«ИнноКам» концепциясе проектларын гамәлгә ашыру яңа инвесторларны җәлеп итү, эш урыннары булдыру, икътисадны диверсификацияләү һәм уңайлы шәһәр тирәлеген формалаштыру өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирәчәк.

Моннан тыш, 2017 елдан ИННОКАМ Россиянең барлык инновация кластерларыннан бердәнбер TCI Network оешмасы – инновацияләр, кластерлы үсеше һәм конкуренциягә сәләтле булу өлкәсендә юнәлешле оешмаларның һәм экспертларның глобаль халыкара челтәре әгъзасы булып тора.

2019 елда TCI Network 2020 елда Казанда ИННОКАМда  Россиядә һәм БДБ илләрендә әле үткәрелмәгән TCI Global Conference халыкара кластер конференциясен үткәрүгә заявка биргән.  2020 елда ел саен үткәрелә торган 23 нче TCI Global Conference конференциясен үткәрү кластерлы үсеш һәм инновацияләргә ярдәм итү буенча дөнья тәҗрибәләре белән танышырга, дөнья эксперт бергәлегендә Татарстан Республикасының һәм Россиянең имиджын үстерергә һәм фәнни һәм эшлекле даирәләрдә халыкара хезмәттәшлекне киңәйтергә мөмкинлек бирәчәк. Бу

ИННОКАМны һәм Россиянең башка кластерларын халыкара икътисадый киңлеккә интеграцияләү буенча мөһим чара булачак.

2018 елда ИННОКАМ Россиядә беренчеләрдән булып ECEI методологиясе буенча Көмеш сыйфат сертификатын алды, бу кластерны үстерү һәм алга җибәрү буенча халыкара стандартларга туры килүен тану булып тора.

Бүгенге көндә ИННОКАМ Россия кластерларында катнашучыларга ярдәм итүнең яңа инструментларын актив рәвештә гамәлгә кертүне дәвам итә:

субконтрактациянең милли порталы «Innokam.pro» кластерда катнашучылар арадашчылардан башка техник яктан катлаулы продукциягә заказлар урнаштыра һәм тикшерелгән тәэминатчыларны һәм партнерларны сайлый ала. 2020 елның 1 гыйнварына порталда 1 523 катнашучы теркәлгән, 1 364 заказ урнаштырылган, шул исәптән 12 илдән чит ил компанияләре;

«Россия ачык инновацияләр үзәге» «Инноскоп» интернет-порталы инновацион технологияләр һәм эшләнмәләрне гамәлгә кертү өлкәсендә фән һәм бизнес арасындагы хезмәттәшлекне үстерүгә, шулай ук югары белем бирү оешмалары һәм инжиниринг үзәкләре җиһазларын эшләтеп җибәрүгә юнәлдерелгән. 2020 елның 1 гыйнварына порталда Россиянең 82 төбәгеннән 1 600дән артык катнашучы тәкъдим ителгән, 11 меңгә якын эшләнмә, 43 950 берәмлек җиһаз һәм 3 823 инжиниринг өлкәсендә хезмәт күрсәтелгән.

2019 елда кластерда катнашучыларның продукциясен Россия һәм дөнья базарларына чыгару, автомобиль сәнәгате һәм нефть химиясе предприятиеләре белән кооперацияне үстерү максатларында ИННОКАМның 72 оешмасы 80 коммуникатив һәм күргәзмә-ярминкә чараларында, шул исәптән Россиядә һәм чит илләрдә 30 күргәзмәдә һәм Россиядә 2 бизнес-миссиядә катнашаты, Россия һәм чит ил партнерлары белән хезмәттәшлек, технологияләр трансферында һәм локальләштерүдә ярдәм итү турында 11 килешүгә кул куелды.

Татарстанның конкурентлылыкка сәләте күп очракта дөнья икътисадына интеграцияләнгән инновацион икътисадны формалаштыру белән билгеләнә, аның иң мөһим приоритетлары – технологик үсешне тизләтү, дәүләт, фән һәм бизнесның тыгыз хезмәттәшлеге юлы белән төбәкара кооперацияне ныгыту.

Республикада хуҗалык һәм фәнни эшчәнлекнең барлык инфраструктур элементлары да диярлек булдырылган, алар эшчәнлек төрләре, башкарыла торган функцияләр характеры һәм күләме, күрсәтелә торган хезмәтләр һәм инновацион эшчәнлеккә ярдәм итү ысуллары буенча аерылып тора.

Республика инновацион инфраструктурасы чылбырында технопарк структуралары элеккечә төп звено булып кала бирә, алар махсуслашкан мәйданчыкларны исәпкә алып, инновацион компанияләр үсешенә ярдәм итә. Мәсәлән, «Химград» технополисы мәйданчыгында кече тоннажлы химия, полимерлар эшкәртү, нанотехнологияләр, ресурсларны саклау һәм энергия нәтиҗәлелеге, медицина технологияләре өлкәсендә эшләүче 300 кече һәм урта компания үсеш ала, аларның табышы 2019 ел нәтиҗәләре буенча 39,2 млрд сум тәшкил итә.

Төбәк инновация системасының иң югары технологияле субъектларының берсе – «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» (алга таба – ИТ-парк) уңышлы үсә, үз илебезнең программа тәэминатын эшләү аның белгечлегенең

төп юнәлеше булып тора. ИТ-парк югары технологияләр өлкәсендәге компанияләрне тизләтеп үстерү өчен финанс һәм интеллектуаль ресурсларны туплау хисабына барлык шартлар тудыра. Бүген аның Казан һәм Чаллы шәһәрләрендәге мәйданчыкларында 140тан артык компания эшли, 2019 ел йомгаклары буенча аларның табышы 12,3 млрд сум тәшкил итте. ИТ-парк үз мәйданчыгында яшь ИТ-компанияләр үстерә, алар әлеге стадияне үткәннән соң һәм өлгерлек этабына күчкәннән соң «Иннополис» махсус икътисадый зонасы резидентлары рәтләрен тулыландыра ала.

Үз структурасында бизнес-инкубаторы, инновацион-технологик үзәге, бизнес-паркы булган «Идея» инновацион-җитештерү технопаркы үз мәйданчыгында эшләгән якынча 90 кече инновация компаниясен үстерү өчен барлык шартлар тудыра.

Татарстан Республикасында инновация эшчәнлегенең алга таба нәтиҗәле үсеше тиешле норматив хокукый базаны камилләштерүгә бәйле. 2019 елның 29 апрелендә «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, аның төп яңалыгы – фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыру тәртибен раслау. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасында фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне планлаштыруның һәм фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә дәүләт заказларын формалаштыруның үзәкләштерелгән инструментын булдыруга ярдәм итәчәк.

Татарстан Республикасы инновацияләргә ярдәм күрсәтү буенча югары үсеш алган сәясәтле төбәк үрнәге булып тора. Инновацион компанияләргә ярдәм күрсәтү чаралары арсеналында республика тарафыннан «Фәнни-техник өлкәдә предприятиеләрнең кече формаларын үстерүгә булышлык күрсәтү фонды» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең (алга таба – Фонд) ярдәм итү программалары актив кулланыла, әлеге программаларда катнашу Татарстан Республикасының технологик компанияләрен үстерүгә, инновацияләрне коммерцияләштерү мәсьәләләрен хәл итүгә, шулай ук республика товар җитештерүчеләренең үз илебез һәм чит ил базарларында көндәшлеккә сәләтлелеген арттыруга ярдәм итә. Татарстан Республикасы өчен 2019 ел игълан ителгән проектлар саны буенча да, ярдәм күрсәтелгән проектлар саны буенча да нәтиҗәле булды. Барлыгы гомуми суммасы 648,5 млн сум тәшкил иткән 119 проектка (2018 елга караганда 80 процентка күбрәк) ярдәм күрсәтелде.

2019 ел дәвамында югары белем бирүче мәгариф оешмалары, кече бизнес вәкилләре, яшь галимнәр һәм студентлар белән Фондның ярдәм итү программаларын алга этәрүгә һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән семинарлар һәм эшлекле очрашулар үткәрелде.

Безнең икътисад үсешенең җитди резервлары интеллектуаль өлешкә салынган. Уйлап табуларга бирелә торган заявкалар саны буенча Россия төбәкләре рейтингында Татарстан тотрыклы рәвештә лидерлар бишлегенә керә. 2019 ел йомгаклары буенча республика Россия төбәкләре арасында 4 нче урынны һәм Идел буе федераль округы субъектлары арасында 1 нче урынны саклап калды.

2019 ел йомгаклары буенча уйлап табуларга заявкалар саны – 4,7 процентка, сәнәгать үрнәкләренә – 21,4 процентка, ЭВМ программаларына 47 процентка арткан.

Бүген көндә матди булмаган активлар барлык дәрәҗәләрдәге икътисадны үстерүгә көчле йогынты ясый һәм дөньякүләм икътисадый үсешнең хәрәкәтләндерү көче булып бара. 2016 елдан Татарстан Республикасында «2014 – 2042 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2016 – 2021 елларга Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлгә ашырыла, ул түбәндәге 5 юнәлешне үз эченә ала:

предприятиеләрнең интеллектуаль милкенә хокуклар белән идарә итү системасын булдыру;

интеллектуаль милекне инвентаризацияләү, аңа экспертиза ясау, аның саклауга сәләтле нәтиҗәләрен ачыклау максаты белән предприятиеләргә тикшерү үткәрү;

«Татарстан Республикасының интеллектуаль потенциалы» мәгълүматлары банкы» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасын эшләү һәм алып бару;

интеллектуаль милек өлкәсендә белем бирү чараларын үткәрү;

интеллектуаль милек мәсьәләре буенча фәнни-техник, икътисадый һәм методик чаралар (форумнар, симпозиумнар, конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр, конкурслар) үткәрү.

Ярдәмче программа белән куелган бурычлар кысаларында 2019 елда сату базарларында предприятиеләр продукцияләрен һәм технологияләрне тарату өчен предприятиеләрнең интеллектуаль эшчәнлеге нәтиҗәләрен җәлеп итүгә шартлар тудыру максаты белән кече машиналар төзү предприятиеләренең – «ИННОКАМ» Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры резидентларының интеллектуаль милке белән идарә итү өлкәсе торышы тикшерелде һәм анализ ясалды.

2019 елда шулай ук Татарстан Республикасы инноваторлары һәм экспертлары арасында мәгълүмат алмашуның бердәм цифрлы мәйданчыгы эшләвен тәэмин итүгә, шулай ук проектның идеядән һәм саклана торган милек хокукы объекты буларак аны теркәүдән алып аны тормышка ашыруга һәм коммерцияләштерүгә кадәр тулы циклын үтү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән «Татарстан Республикасының интеллектуаль потенциалы» мәгълүмат банкы» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасын (алга таба – «ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасы) эшләп бетерү һәм модернизацияләү эшләре алып барылды.

«ТатПатент» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасына Татарстан Республикасы интеллектуаль милкенең бөтен базары буенча аналитика, шулай ук башлангыч стадиядән алып серияле чыгарылышка кадәр технологик һәм инновацион проектларны гамәлгә ашыру өчен барлык гамәлдәге ярдәм чаралары һәм гамәлдәге инфраструктура турында мәгълүмат кертелгән.

Ярдәмче программа чараларын үтәү һәм Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләре өчен югары

квалификацияле кадрлар әзерләү бурычларын хәл итү кысаларында, 2019 елда Казан илкүләм тикшеренү технология университетының Өстәмә һөнәри белем бирү институты базасында 158 академик сәгать (шул исәптән теоретик һәм практик өлешләрне дә кертеп) күләмендә «Интеллектуаль милек белән идарә итү» интеллектуаль милек өлкәсендә белгечләрнең квалификациясен күтәрү программасы буенча Татарстан Республикасы предприятиеләренең конкурентлы өстенлекләрен һәм инвестиция җәлеп итүчәнлеген арттыру максатларында, бөтендөнья һәм үз илебез тәҗрибәсен кулланып, оешмаларда интеллектуаль милек белән идарә итү өчен һөнәри компетенцияләрне формалаштыруга юнәлдерелгән белем бирү чаралары үткәрелде.

Тыңлаучылар кирәкле компетенцияләр буенча: интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны рәсмиләштерү, интеллектуаль милек белән идарә итү һәм аны коммерцияләштерү системасын эшләү һәм оешмада гамәлгә кертү буенча белемнәр, осталыклар, күнекмәләр алды. Квалификация күтәрү турындагы таныклыклар 102 кешегә бирелде.

Моннан тыш, Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында интеллектуаль милек белән эшләү өлкәсен популярлаштыруга һәм республика предприятиеләре белгечләренең күнекмәләрен һәм компетенцияләрен арттыруга юнәлдерелгән берничә чара үткәрелде.

Шулай итеп, 2019 елның августында «Товарларны чит ил базарларына чыгару: чит ил патентын алу. Россия базарында товарларны саклау» фәнни-гамәли семинары узды. Семинар барышында глобаль базарда компанияләрнең уйлап табуларын һәм товар билгеләрен саклау мәсьәләләре, чит ил патентын алу чыгымнарын субсидияләү механизмнары карап тикшерелде. Семинар эшендә Татарстан Республикасы предприятиеләре, югары уку йортлары, фәнни-тикшеренү институтларының 85 вәкиле катнашты.

2019 елның ноябрендә Чаллы шәһәрендә, Кама кластеры белән берлектә, интеллектуаль милек белән эшләүче предприятиеләр өчен базарда компаниянең уйлап табуларын һәм товар билгеләрен рәсмиләштерү, компаниянең үз патент хезмәтен булдыру һәм аның эшләве мәсьәләләренә (белгечләр укыту мәсьәләләрен кертеп) багышланган «Интеллектуаль милек объектларын ачыклау, аларны рәсмиләштерү үзенчәлекләре» темасына фәнни-гамәли семинар оештырылды һәм үткәрелде. Семинар эшендә Татарстан Республикасы предприятиеләренең 57 белгече катнашты.

2019 елның 12 ноябрендә Казан шәһәрендә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Федераль интеллектуаль милек хезмәте ярдәмендә «Кайнар ноктасы» күмәк эш киңлеге мәйданчыгында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан оештырылган «Интеллектуаль милек һәм Россия төбәкләре икътисады» III Халыкара форумы уздырылды.

Форум фәнни-техник эшчәнлек нәтиҗәләрен коммерцияләштерү, алар белән идарә итү, аларны саклау һәм яклау, Россия төбәкләре икътисадының стратегик үзгәрешләр динамикасын анализлау, шулай ук интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен булдыру һәм алар белән идарә итү өлкәсендә халыкара тәҗрибәне гомумиләштерү өчен 400дән артык бизнес, фәнни җәмәгатьчелек һәм хакимият органнары вәкилләрен җыйды.

Форум кысаларында шулай ук Халыкара лицензия җәмгыяте (LES International) һәм Кама кластеры арасында хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә тантаналы рәвештә кул куелды. Килешү озак вакытка исәпләнгән партнерлык мөнәсәбәтләрен урнаштыру һәм үстерү максаты белән, шул исәптән инновацион үсеш өлкәсендә партнерлык челтәрен үстерү һәм интеллектуаль милекне саклауга бәйле эшчәнлекне алга этәрү өчен хезмәттәшлек итүгә юнәлдерелә.

Мәктәп укучылары, югары уку йортлары яшьләре һәм предприятиеләр арасында уйлап табу һәм рационализаторлык эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү һәм стимуллаштыру, фәнни-техник потенциалны ачыклау максатларында «Россия төбәкләренең интеллектуаль милке һәм икътисады» III Халыкара форумы кысаларында Татарстан Республикасының фәнни-техник потенциалы күргәзмәсе оештырылды. Күргәзмәдә экология, энергия саклау, альтернатив энергетика һәм ИТ-технологияләр кебек актуаль юнәлешләр буенча предприятиеләрнең 15 иң уңышлы инновацион һәм перспективалы проекты һәм республика, Россия һәм халыкара фәнни иҗат конкурсларында җиңүчеләр тәкъдим ителде. Чара кунаклары уйлап табучыларның эксперименталь үрнәкләрен һәм әзер модельләрен сынап карый һәм эштә күрә алдылар.

Федераль башкарма хакимият органнары һәм үсеш институтлары белән, аерым алганда, Милли технологияләр трансферы ассоциациясе һәм «Федераль сәнәгать милке институты» федераль дәүләт бюджет учреждениесе белән үзара хезмәттәшлек итү кысаларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан интеллектуаль милеккә хокукларны залогка алып кредит бирүгә ярдәм итүнең комплекслы системасын популярлаштыру буенча эш үткәрелде.

Оешмалар, банк секторы һәм бәяләү оешмалары йөзендә экспертлар берләшмәсе катнашында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Интеллектуаль милеккә хокукларны залогка биреп кредитлар алуга бәйле чыгымнарны каплау өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 30 апрелендәге 533 номерлы карары нигезендә эшләнгән залогка алу максатлары өчен интеллектуаль милеккә хокукларның кыйммәтен бәяләү буенча методик тәкъдимнамәләр проекты буенча фикер алышулар үткәрелде.

Йомгаклау документында Татарстан Республикасының тәкъдимнәре исәпкә алынды, фикер алышу йомгаклары буенча залогка алу максатлары өчен интеллектуаль милеккә хокукларның кыйммәтен бәяләү буенча методик тәкъдимнамәләр проекты экспертлар тарафыннан бәя бирелү өчен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгына һәм Федераль интеллектуаль милек хезмәтенә җибәрелде.

Әлеге инструментны куллануның уңай тәҗрибәсен өйрәнү һәм Татарстан Республикасы кече һәм урта бизнесының мәгълүмати хәбәрдарлыгын арттыру максатларында 2019 елның 21 ноябрендә Казан шәһәрендә «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе» акционер җәмгыяте катнашында стратегик сессия кысаларында интеллектуаль милеккә хокукларны залогка биреп кредитлар алу темасына «түгәрәк өстәл» уздырылды. Түгәрәк өстәлдә 40тан артык бизнес, кредит оешмалары һәм ярдәм күрсәтү институтлары вәкилләре катнашты.

Интеллектуаль милек базарын алга таба үстерү һәм федераль дәүләт хакимияте органнары һәм үсеш институтлары белән үзара хезмәттәшлекне ныгыту максатларында Татарстан Республикасы 2019 елның июнендә Россия Федерациясе субъектларыннан беренче булып Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Федераль интеллектуаль милек хезмәте белән Татарстан Республикасында интеллектуаль милек өлкәсен үстерүгә ярдәм күрсәтү кысаларында үзара хезмәттәшлек итү турындагы өчьяклы килешүгә (2019 елның 10 июнендәге С-131-ОТ/Д01 номерлы) кул куйды.

Килешүдә төбәкнең Россия Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Федераль интеллектуаль милек хезмәте белән түбәндәгеләр өлешендә үзара хезмәттәшлек итү карала:

Татарстан Республикасында интеллектуаль милек өлкәсен үстерү буенча стратегик күзаллауларны формалаштыру;

Татарстан Республикасында интеллектуаль милек өлкәсендәге инфраструктураны үстерү;

Татарстан Республикасында интеллектуаль милек белән идарә итү өлкәсендә кадрлар әзерләү системасын төзүдә үзара хезмәттәшлек итү;

товарның килеп чыгу урыны, товар билгесе исеме сыйфатында теркәлгән төбәк брендларын формалаштыру.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Килешү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы итеп билгеләнде.

Шулай итеп, заманча инновацион инфраструктура, актуаль норматив хокукый база һәм актив дәүләт ярдәме булу республикада инновацион активлыкны үстерү өчен уңай шартлар булдыруны тәэмин итте. Татарстан Республикасының төрле рейтинглардагы позицияләре моңа дәлил булып тора. Шулай итеп, 2018 елда Россиянең инновацион төбәкләре ассоциациясен формалаштыра торган Россия төбәкләренең инновацион рейтингында Татарстан Республикасы 2 нче урын (2017 елда Мәскәү шәһәре – 2 нче урын, Татарстан Республикасы – 3 нче урын) яулады һәм Россиянең инновацион төбәкләре ассоциациясендә катнашучы төбәкләр арасында беренче урынны саклап калды.

***«Иннополис – югары технологияләр һәм инновацияләр шәһәре» флагман проекты***

*Шәһәрнең социаль инфраструктурасы.*

2019 елда Иннополис шәһәре үзенең 4 еллыгын билгеләп үтте. Шәһәрдә резидент компанияләр хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзалары өчен югары сыйфатлы социаль, мәгариф һәм спорт инфраструктурасы булган уникаль шәһәр мохите булдырылды. 1 572 фатирга исәпләнгән 22 күпфатирлы йорт төзелде, 88 мең кв.метрдан артык күчемсез мөлкәт арендага тапшырылды.

Уңайлы шәһәр мохитен булдыру буенча «Кече шәһәрләр һәм тарихый җирлекләр» бөтенроссия конкурсы кысаларында 8 996 кв.метр мәйданлы парк төзелде.

Шәһәрнең мәгариф инфраструктурасында «Иннополис мәктәбе» һәм «Иннополис лицее» дәүләт автоном мәгариф учреждениеләре аерым роль алып тора.

2019 елның 1 сентябреннән уку яңа бинада гамәлгә ашырыла. Анда 1 сыйныфтан алып 11 сыйныфка кадәр 316 укучы белем ала, 41 укытучы эшли.

Иннополис шәһәрендә медицина үзәге эшли, кизү бригадасы оештырылды, үз ашыгыч ярдәм машинасы сатып алынды. 2019 елда «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында педиатрия участогы булдырылды, шәһәрдә яшәүчеләргә киң комплекслы хезмәтләр күрсәтүче якынча 290 кече һәм урта бизнес компаниясе теркәлде һәм эшли. 2019 елда азык-төлек супермаркеты, көнкүреш химиясе һәм парфюмерия кибете, икмәк пешерү бинасы, киемнәр кибете, матурлык салоны ачылды. «OZON» компаниясенең торак йортларда постаматлар урнаштыру буенча проекты тормышка ашырылды.

«Яндекс Драйв» автомобильләрен арендалау сервисы эшли башлады. 2019 елда пилотсыз таксида Иннополис шәһәре кунаклары һәм анда яшәүчеләр 4 меңнән артык сәяхәт кылды. Парковка киңлекләрен тикшерүдә тоту буенча Smart Parking дигән пилот проекты эшли башлады.

Актуаль мәгълүматларны мессенджер аша тапшыра торган метеостанция куелды. Домофон панельләре мобиль кушымта аша дистанцион идарә ителә торган SIP-домофоннарга алыштырылды. 756 фатир «акыллы шәһәр» төзү өчен кирәкле «Әйберләр Интернеты» челтәренә тоташтырылды: LoRa WAN һәм NB-IoT технологияләре су, җылылык, электр энергиясе турында мәгълүматлар җыю өчен төрле датчикларны тоташтырырга мөмкинлек бирә.

Россиядә беренче булган SmartCityPole инновацион терәге урнаштырылды, ул 5G база станциясе, видеомониторлар, датчиклар, камералар һәм сенсорлар белән җиһазландырылырга мөмкин.

*Махсус икътисадый зона.*

Иннополис шәһәренең үзәге булып шул исемдәге техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зона (алга таба – «Иннополис» махсус икътисадый зонасы) тора. 2019 ел йомгаклары буенча аның территориясендә 89 резидент компания һәм 14 партнер компания эшчәнлек алып барды.

2019 елда «Иннополис» махсус икътисадый зонасы резиденты статусын 19 компания алды. 2019 елның 20 декабрендә «Иннополис» махсус икътисадый зонасының күзәтү советы утырышы уздырылды, анда 2020 ел башында резидентлар статусын алган 4 компания каралды. Резидентлар арасында «ДжиДиСи Сервисез» (ICL Services), «ИТ ИКС 5 Технологияләр» (IT X5 Retail Group), «Магнит ИТ Лаб», «МЭГИС Казан», «ННГ Казан» кебек эре компанияләр бар.

Якынча мәгълүматларга караганда, 2019 ел ахырына резидентлар һәм партнерлар тарафыннан гамәлгә ашырылган инвестицияләрнең гомуми күләме арта бара торган йомгак белән 16 996 млн сум тәшкил итте. Шул ук вакытта табыш күләме арта бара торган йомгак белән 14 499 млн сум тәшкил итте, 3 307 эш урыны булдырылды.

2019 елда А.С.Попов исемендәге технопаркта «Иннополис» махсус икътисадый зонасы тарафыннан берничә эре чара уздырылды. Әйтик, мәсәлән, 2019 елның 12 февралендә «Торак базарын үстерү һәм уңайлы шәһәр тирәлеген формалаштыру турында»гы мәсьәлә буенча Россия Федерациясе Президенты

В.В. Путин рәислегендә Россия Федерациясе Дәүләт Советы Президиумының киңәйтелгән утырышы үткәрелде.

2019 елның 22 маеннан 24 маена кадәр үтәли цифрлы технологияләргә һәм Россиядә аларны үстерү перспективаларына багышланган «Сәнәгый Россиянең цифрлы индустриясе» конференциясе узды. Чарага дөньяның 26 иленнән һәм Россия Федерациясенең 71 төбәгеннән 5 312 катнашучы килде. Конференциядә Россиядә цифрлы технологияләрне үстерү стратегиясе буенча фикер алышынды, ул «үтәли» технологияләрнең һәрберсе буенча юл карталары рәвешендә чагылыш тапты.

2019 елның 12 октябреннән 13 октябренә кадәр Иннополиста «СТАЧКА2019» дигән эре төбәкара IT-конференция узды, анда 3 меңнән артык кеше, 150 спикер катнашты, 150дән артык доклад тыңланды.

*Шәһәрнең мәгариф инфраструктурасы.*

Мәгълүмат технологияләре һәм робототехника өлкәсендә белем бирү, тикшеренүләр һәм эшләнмәләр белән шөгыльләнүче «Иннополис» университеты Иннополис шәһәренең интеллектуаль үзәге булып тора. Университет Россия өчен мәгариф, фән һәм бизнесны берләштерә торган уникаль модель буенча эшли.

2019 елда Иннополис университетына 162 илдән 16 210 заявка килде. 253 кеше – студент, 14 кеше – аспирант булды. 2019/2020 уку елында анда бакалавриат, магистратура һәм аспирантураның 181 курсы буенча 771 студент белем ала: компьютер фәннәре, компьютер фәннәренең теоретик нигезләре, программа тәэминатын эшләү белән идарә итү, куркынычсыз челтәрләр һәм системалар эшләү, зур мәгълүматлар белән идарә итү, робототехника һәм компьютер күзе. Инглиз телендә укытыла. Университетта 24 илдән дөнья ИТ-индустриясендә эшләү тәҗрибәсе булган 261 фәнни-педагогик хезмәткәр эшли.

2019 елда университетны 92 студент тәмамлады: 45 магистр һәм 47 бакалавр. «Иннополис» Университетында барлыгы 319 кеше укып чыкты. Чыгарылыш укучылар түбәндәге алдынгы ИТ-компанияләргә эшкә чакырылды: «МТС», «Дигинавис», «РТК СофтЛабс», «NNG», «БарсГруп», «Документлар әйләнеше системасы», «Портавита», «Маркетплейс Технологии» һ.б.

Университет Россиянең түбәндәге эре компанияләре белән 63 фәнни-тикшеренү проектын гамәлгә ашыра: «Газпром» гавами акционер җәмгыяте, «Аэрофлот» гавами акционер җәмгыяте, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, «Норникель» гавами акционер җәмгыяте, «Россети» гавами акционер җәмгыяте, «РусГидро» гавами акционер җәмгыяте, «Северсталь» гавами акционер җәмгыяте һ.б.

Иннополис университеты базасында «Робототехника һәм мехатроника компонентлары технологияләре» юнәлеше буенча Милли технологик инициативаның Компетенцияләр үзәге эшли. Үзәк структурасында 6 лаборатория бар, алар антропоморф һәм сәнәгать робототехникасы, пилотсыз транспортның барлык төрләре, нейрофән, ясалма интеллект һ.б. өлкәләрендә өйрәнү һәм эшләнмәләр ясау белән шөгыльләнә. Үзәк консорциумына дөньяның 56 алдынгы технологик компаниясе һәм университеты керде. Алар арасында «Сбербанк» гавами акционер җәмгыяте, «Аэрофлот» гавами акционер җәмгыяте, «РЖД» ачык акционер

җәмгыяте, «Газпромнефть» гавами акционер җәмгыяте, «РУСАЛ» акционер җәмгыяте, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, «KUKA Robotics» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, шулай ук Санкт-Петербург милли тикшеренү мәгълүмат технологияләре, механика һәм оптика университеты, Ерак Көнчыгыш федераль университеты, Волгоград дәүләт техник университеты, Ижевск дәүләт техник университеты һ.б. төп компанияләр һәм университетлар булып тора.

2019 елда Үзәк белгечләре, консорциум әгъзалары белән берлектә, 2024 елга кадәр Россиядә робототехника һәм сенсориканы үстерү буенча «Цифрлы технологияләр» федераль проекты кысаларында «Робототехника компонентлары и сенсорика» үтәли цифрлы технология юнәлеше буенча юл картасын эшләде һәм тәкъдир итте.

Шулай ук үзәк KIA Soul һәм Hyundai Santa Fe базасында җиңел транспорт өчен һәм КамАЗ автомобиле базасында йөк транспорты өчен үзенең очыш һәм җир өсте пилотсыз чишелешләрен эшли. Университет стадионнарда телевидениегә һәм кинога төшерү, зур габаритлы әйберләрне (корабльләр, самолетлар) җыю яки буяу, зур объектларның 3D-басмасын ясау өчен, хәрәкәт симуляторларында, тернәкләндерү өчен экзоскелетлар эшләүдә кулланып була торган кабель роботын эшләп чыгару өстендә эш алып бара.

«Газпром» гавами акционер җәмгыяте белән килешү кысаларында университет белгечләре комплекслы геомеханик модельләштерү өчен үз илебезнең платформасы прототибын булдырды. Бу чит илдән кертелә торган программа тәэминатына бәйлелекне киметәчәк. 2019 елда проектның барлык этаплары да тәмамланды.

Милли технологик инициативаның «Аэронет» юл картасы кысаларында «Иннополис» Университеты, сурәтләрне анализлау өчен компьютер күрүен һәм машина укуын кулланып, Татарстан Республикасының 4D-геомәгълүмат моделен булдыру проектын тормышка ашырды. 2019 елның июненнән «болыт» геомәгълүмат платформасы саклау зоналарын мониторинглау, капиталь төзелеш объектларын тану, урманнардагы үзгәрешләрне, авыл хуҗалыгын мониторинглау сервислары өчен файдаланыла башланды.

Шулай ук университет үзенең Мәгълүмат иминлеге үзәге базасында тикшеренүләр һәм проект эшчәнлеге алып бара. Үзәк белгечләре дәүләтне һәм җәмгыятьне киберһөҗүмнәрдән саклау өчен эчке һәм тышкы мәгълүмат куркыныч янаулары йогынтысы мәсьәләләрен хәл итә. 2019 елда «Иннополис» Университеты, ясалма интеллектны файдаланып, мәгълүмат иминлеге инцидентларын эшкәртү технологиясен булдыруга конкурс отты.

Иннополис университеты Institutions Active in Technical Games Research уеннарын тикшерүче 100 бөтендөнья югары уку йорты топына керде, ул бу исемлектә 87 урынны алды һәм Россиядә бердәнбер югары уку йорты булды. Югары уку йортында бу тикшеренүләр белән Ясалма интеллект лабораториясе шөгыльләнә.

2019 елда «Иннополис» университеты блокчейн өлкәсендә цифрлы икътисадның алдынгы тикшеренү үзәге статусын алды, ул Россия Федерациясе Цифрлы нигездә үстерү, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы конкурсында җиңеп чыкты. «Аэрофлот» һәм BitFury компанияләре белән берлектә,

университет, Россиядә беренче булып, 600 млн сумлык верификацияле блокчейн-платформа булдырачак.

2019 елда университетта 2 яңа уртак лаборатория ачылды:

интеллектуаль программа тәэминаты һәм робототехника лабораториясе, Көньяк-Көнбатыш университеты (Кытай) белән берлектә, программа тәэминатын эшләү өлкәсендә программа тәэминаты таләпләрен формалаштыру, киберфизика системаларын спецификацияләү һәм белем бирү белән шөгыльләнәчәк;

лаборатория, Тулуза университеты (Франция) белән берлектә, формаль ысулларны өйрәнү һәм программа тәэминатын верификацияләү белән шөгыльләнәчәк.

Барлыгы Иннополис университеты Россиянең 144 алдынгы ИТ-компанияләре һәм бөтен дөнья буенча 53 академик партнер белән хезмәттәшлек итә, алар арасында дөнья рейтингларында лидер булган югары уку йортлары бар. Университетта 15 лаборатория һәм 6 фәнни үзәк ачылды.

2014 елдан «Иннополис» университеты Бөтендөнья роботлар олимпиадасының илкүләм оештыручысы булып тора һәм үз мәйданчыгында ярышларның Россия этабын оештыра. 2019 елда Бөтенроссия робот техникасы олимпиадасы университет мәйданчыгында алтынчы тапкыр уздырылды. Иннополис университеты халыкара олимпиада финалында катнашу өчен илнең җыелма командасын формалаштыра һәм алар белән күнегүләр ясый. 2019 елда Венгриянең Дьер шәһәрендә уздырылган Бөтендөнья роботлар олимпиадасында Россия тарафыннан 11 шәһәрдән 16 командада 42 робот техникасы тәкъдим ителде. Россиялеләр гомумкоманда зачетында 1 нче урын яулады (2 алтын, 2 көмеш, 1 бронза медале).

Университетта мәктәп укучылары өчен «программалаштыру», «робототехника», «математика» һәм «проект эшчәнлеге» юнәлешләре буенча 29 белем бирү курсы эшләнде. 2019 елда «Иннополис» университеты 24 белем бирү сменасын һәм Олимпиада юнәлешләре буенча җыен үткәрде.

«Иннополис» университетының 5 олимпиадасы 2019/2020 уку елына мәктәп укучыларының Россия олимпиадалары берлеге исемлегенә кертелде. Университет мәктәп укучылары өчен информатика, математика, робототехника, финанс технологияләре, мәгълүмат иминлеге, проект инженер-фәнни бурычлары буенча 9 халыкара һәм бөтенроссия олимпиадаларына һәм конкурсларына методик ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыра. Ел саен югары уку йортына кадәрге юнәлештәге чараларга 30 меңгә якын мәктәп укучысы җәлеп ителә.

Университет «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» федераль проекты кысаларында 23,2 млн сумга 2 федераль субсидия алу хокукын конкурс нигезендә отты. Бер субсидия – өстәмә белем бирүне үстерүгә һәм математика, информатика һәм цифрлы технологияләр буенча сезонлы лагерьларда тематик сменалар үткәрүгә, икенчесе мәктәп укучыларын һәм рус мәктәпләрендә эшләүчеләрне чит илләрдә укытуга бирелде.

Моннан тыш, университетта түбәндәге өстәмә белем бирү үзәкләре эшли:

Карьераны үстерү үзәге; ул югары уку йорты студентларының һәм хезмәткәрләренең һөнәри үсеше; квалификация күтәрү һәм яңадан укыту; хезмәт

базары аналитикасы һәм ИТ-индустриядә трендлар мониторингы; магистрларны һәм бакалаврларны эшкә урнаштыру һәм аларның стажировкасы белән шөгыльләнә;

Махсуслаштырылган ИТ-әзерлек үзәге; аның тарафыннан 522 белгеч әзерләнде инде, максатчан кабул итү буенча укып бетерүчеләрнең 80 проценты «Иннополис» махсус икътисадый зонасына эшкә урнаштырылды;

Мәгълүмат технологияләре бизнес-модуле; 80 уку программасын гамәлгә ашырды һәм, 2016 елдан алып, 33 компаниядән 3 500 кеше укытты.

Университет мәйданчыгында, гадәттәгечә, төрле юнәлештәге бик күп чаралар уза. 2019 елда барлыгы «Иннополис» университеты 231 чара кабул итте һәм оештырды. Университет мәйданчыгында 153 делегация һәм 20 меңнән артык кунак булды.

***Фән һәм фәнни тикшеренүләр үсеше***

Татарстанның иң мөһим конкурентлы өстенлекләре исәбенә икътисадның шактый фәнни-техник потенциалы керә. Республиканың конкурентлы үсеше һәм үсеш резервлары – университетларның, фәнни оешмаларның, реаль сектор предприятиеләренең һәм яңа төзелгән фәнни һәм инновацион инфраструктура объектларының үзара тыгыз бәйләнешендә.

Татарстан Республикасының фәнни комплексы соңгы еллар дәвамында һәрвакыт үсеп килүче үсеш динамикасын күрсәтә. Республикада фәнни оешмалар һәм тикшеренүләр һәм эшләнмәләр белән шөгыльләнүче персонал саны югары дәрәҗәдә тотрыкланды, югары квалификацияле фәнни-педагогик кадрлар әзерләү һәм аларны аттестацияләү системасы эзлекле рәвештә эволюцияләнә, фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләрнең матди-техник һәм финанс-икътисадый нигезләрен өзлексез ныгыту дәвам итә.

Хәзерге вакытта республикада фәнни эзләнүләр белән 12700 штат хезмәткәре – тикшеренүчеләр, техниклар, ярдәмче хезмәткәрләр шөгыльләнә. 3 меңгә якын белгеч берьюлы ике эштә эшләү, граждан-хокукый характердагы шартнамәләр шартларында эшли.

Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре өлкәсенең институциональ структурасы 40 фәнни-тикшеренү учреждениесе, 8 проект-конструкторлык бюросы, 34 югары белем бирүче мәгариф оешмасы, 20 корпоратив фәнни-тикшеренү институты һәм конструкторлык бюросы, шулай ук 19 башка оешма тарафыннан тәкъдим ителә.

Фәнни үзәкләрнең гомуми саны (121 берәмлек) буенча Татарстан Россиянең Инновацион төбәкләр ассоциациясе әгъзалары составында лидер позицияләрен, калган субъектлар – әлеге оешма әгъзалары арасында алга китүче һәм шактый өстен булучы позицияләрен алып тора.

Басма һәм патент активлыгы күрсәткечләре, цитаталану индексы, интеллектуаль милек объектларын хуҗалык әйләнешенә кертүдән кергән керүләр күләме һ.б. белән күрсәтелә торган фундаменталь һәм гамәли эзләнүләрнең соңгы нәтиҗәләлегә фәнни проектларны финанслар белән ни дәрәҗәдә тулы күләмдә һәм үз вакытында тәэмин ителү белән бәйле.

Узган елларда Татарстанда тикшеренүләргә һәм эшләнмәләргә эчке чыгымнар якынча 15 тапкырга артты (2000 елда 1,2 млрд сумнан 2018 елда 17,8 млрд сумга кадәр).

Республикада фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренә акча салу чыганаклары структурасында бюджеттан тыш акча өстенлек итә, аларга фәнни-тикшеренү эшләренә чыгымнарның 72 проценттан артыгы туры килә, шул ук вакытта ил буенча тулаем бу күрсәткечнең зурлыгы 34 процент дәрәҗәсендә урнашты.

Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре өлкәсендә мондый нәтиҗәләргә ирешү тикшеренүләрне һәм эшләнмәләрне дәүләт тарафыннан җайга салуга карата программа-максатчан нигезендә якын килү нәтиҗәсендә мөмкин булды, аның концептуаль нигезләмәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары белән расланган, составында «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү» ярдәмче программасы гамәлдә булган «2014 – 2025 елларга Мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасына салынган.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру республика фәнни комплекс белән идарә итү системасын сыйфаты ягыннан яңа нәтиҗәлелек дәрәҗәсенә күчерү өчен уңай шартлар һәм алшартлар булдыруга ярдәм итәчәк.

Моннан тыш, хәзерге вакытта 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән 2017 – 2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы мәгарифен үстерүнең тармак стратегиясе кабул ителде.

2017 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан фән, технологияләр һәм техниканың актуальләштерелгән өстенлекле республика юнәлешләрен һәм критик технологияләр исемлеген кабул итү аның принципларын һәм механизмнарын гамәли тормышка ашыру юлында иң мөһим адым булды. Бу фәнни эзләнүләрне стимуллаштыруның төбәк моделенә төгәлрәк, акцентланган характер бирергә мөмкинлек бирә.

Тикшеренүләрнең һәм эшләнмәләрнең төбәк секторын үстерү процессларында фән һәм югары белем бирү оешмалары технологияләрен эшләү зур роль уйный, аларга фәнни программаларны һәм проектларны фондлаштыру өчен еллык чыгымнарның җыелма күләменең якынча 30 проценты туры килә, бу Татарстанда фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыруның аеруча алга киткән һәм базар чынбарлыгына туры килгән университет моделе формалашуның ышанычлы маркеры булып тора.

2020 елга кадәрге чорга Россиянең инновацион үсеш стратегиясе нигезендә фәнни-техник эшчәнлек нәтиҗәләрен коммерцияләштерү мәсьәләләрендә югары мәктәпнең роле өзлексез көчәю күзәтелә. Республиканың югары белем бирүче мәгариф оешмаларында 100дән артык кече инновацион предприятие төзелде, аларның күбесе федераль һәм ике илкүләм тикшеренү университетының инновацион поясларын булдыра.

*Дәүләт ярдәме чаралары*

Татарстан Республикасы Хөкүмәте традицион рәвештә югары белем бирүче мәгариф оешмаларына төрле фәнни проектларны гамәлгә ашыру мәсьәләләрендә, шул исәптән студентларны тикшеренү эшчәнлегенә җәлеп итү белән бәйле мәсьәләләрдә актив ярдәм күрсәтә.

Мәгариф һәм фән үсеше белән бәйле мәсьәләләрне караганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, белем бирү һәм фәнни оешмаларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында, шулай ук мәгариф һәм фәнни-техник үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтенең актуаль мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү максатларында Татарстан Республикасы Президенты каршында Мәгариф һәм фән советы эшли.

Әлеге киңәшмә органы Татарстанның дәүләт фәнни-техник сәясәтен гамәлгә ашыруга кагылышлы стратегик һәм оператив-тактик мәсьәләләр буенча гавами фикер алышу өчен иҗтимагый эксперт мәйданчыгы ролен башкара.

Яңа адреслы стимулларны һәм фәнни эзләнүләрне кызыксындыру механизмнарын арттыру максатларында соңгы берничә елда республикада А.Н.Туполев, В.Е.Алемасов һәм Н.И.Лобачевский исемендәге халыкара һәм дәүләт премияләре тапшырыла.

Моннан тыш, педагогик хезмәткәрләрнең фәнни һәм фәнни-методик эшчәнлеген бүләкләүнең яңа адреслы механизмнарын булдыру максатларында 2017 ел ахырында М.И.Мәхмүтов исемендәге Татарстан Республикасы дәүләт премиясе гамәлгә куелды.

2019 елда Татарстан Республикасы фәнни-белем бирү комплексының алдынгы оешмаларыннан 19 яшь галим Россия яшь галимнәренең фәнни тикшеренүләренә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Россия Федерациясе Президенты грантларын алу конкурсында җиңү яулады. Грантлар Россия Федерациясенең фән, технологияләр һәм техниканы үстерүнең өстенлекле юнәлешләре буенча фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләр уздыру чыгымнарын финанслау, шулай ук Россия яшь галимнәренә – фәннәр кандидатларына, фәннәр докторларына һәм Россия Федерациясенең алдынгы фәнни мәктәпләре коллективлары әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү өчен бирелә.

***«Фән» илкүләм проекты***

Татарстанның фәнни комплексын алга таба үстерү траекториясе, тулаем алганда, илнең дә, якын киләчәктә «Фән» илкүләм проекты, аның максатлары һәм бурычлары, өстенлекләре һәм гамәлгә ашыру динамикасы белән бәйле булачак.

Әйдәп баручы фәнни-белем бирү учреждениеләре аның кайбер чараларын гамәлгә ашыру, шул исәптән түбәндәгеләр буенча берничә инициатива белән чыкты:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе мультидисциплинар юнәлештәге дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-белем бирү үзәге төзүгә дәгъва итә;

«Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге агро- һәм биотехнологияләр өлкәсендә Россия Федерациясен фәнни-технологик

үстерү стратегиясенең өстенлекле юнәлеше буенча дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәк ачу инициативасы белән чыкты;

Республиканың югары белем бирүче кайбер төп мәгариф оешмалары үз структурасында махсуслаштырылган укыту-фәнни үзәкләр булдыруга исәп тота ала, аларның төп бурычы – талантлы мәктәп укучылары өчен югары дәрәҗәдәге белем алу мөмкинлеген тәэмин итү.

***«Татарстан технологик инициативасы» флагман проекты***

Төп технологияләрдә һәм инновацияләрдә булган эшләнмәләр һәм технологик трендлар нигезендә Татарстан Республикасының «акыллы» икътисады кластерларын булдыру «акыллы» икътисадның 10 инновация кластерын үз эченә алган «Татарстанның технологик инициативасы» комплекслы флагман проекты кысаларында гамәлгә ашыру күздә тотыла.

*«Акыллы» материаллар*

«Акыллы» материаллар» инновация кластеры кысаларында яңа инновация компанияләре булдыру һәм гамәлдә булганнарын үстерү өчен шартлар тудыру планлаштырыла, алар зур нефть-газ химиясе һәм энергетика бизнесы, тармак фәне һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә, яңа полимер һәм композиция, наноструктурлаштырылган материаллар эшләү, гамәлгә кертү, җитештерү һәм сату белән шөгыльләнә.

2019 елда 2020 – 2024 елларга һәм 2034 елга кадәр перспективага Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексын үстерү буенча бишенче программа проекты эшләнде. Аның төп максаты – функциональ материаллар (яңа һәм композицияле материаллар, суперконструкцияле пластмасса, функциональ өстәмәләр) һәм урта һәм кече тоннажлы химия продукциясенең башка төрләрен җитештерүне үстерү өчен чимал һәм фәнни база булдыру. Төп инициативаларның берсе – Татарстан Республикасында инновацион резин һәм пластмасса эшләнмәләрен, химия продукциясен апробацияләү (сәнәгый кулланышка кертү) өчен тәҗрибә полигоннары булдыру.

Татарстан Республикасы, Мәскәү һәм Саратов өлкәләре территориясендә UMATEX Group инициативасы буенча «Чикләре булмаган композитлар» төбәкара сәнәгать кластеры булдырылды һәм ул Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Сәнәгать кластерлары һәм махсуслаштырылган оешмалары реестрына кертелде.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы территориясендә 2019 елны 17 июлендә «Алабуга» махсус икътисадый зонасы күзәтү советының чираттагы утырышы уздырылды, аның барышында «Алабуга» базальт технологияләре үзәге» инвестицион проекты турында фикер алыштылар, ул елына 15 мең тонна базальтлы өзлексез җепселләр (ровинг) җитештерүне күздә тота. Проектның инициаторлары – «Промторг» һәм «Экопром» компанияләре җитештерүгә, өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, 3,3 млрд сум үз акчасын кертергә планлаштыра. Проект гамәлгә кергәннән соң, проект егәрлеге өчен 400дән артык эш урыны булдырылачак.

UMATEX (Росатом) һәм югары һөнәри белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль

дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе 2019 елның 25 октябрендә Казан шәһәрендә «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе базасында «Композитлар технологияләре» махсуслаштырылган компетенцияләр үзәге» фәнни-укыту лабораториясен ачты. Проект композитлар өлкәсендә югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә юнәлдерелгән.

*«Акыллы» машиналар»*

«Акыллы» машиналар» инновация кластерын формалаштыру кысаларында транспорт чаралары җитештерү өчен файдаланыла торган җиһазлар һәм транспорт чаралары җитештерү юнәлешләрен конвергенцияләү өлкәсендә яңа инновация компанияләре оештыру һәм гамәлдә булган компанияләрне үстерү өчен шартлар тудыру күздә тотыла.

2019 елның октябрендә «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте һәм «Вымпелком» гавами акционер җәмгыяте (Билайн бренды) арасында өч елга чыгарыла торган автомобильләр өчен M2M хезмәте күрсәтелә торган 90 мең SIM-карта белән тәэмин итүгә шартнамә төзелде. Ел саен 30 мең SIM-карта «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенә биреләчәк. Россия юлларында «тоташтырылган» КАМАЗ йөк машиналары барлыкка киләчәк, алар «Билайн» мультимедиа сервисларыннан файдалану мөмкинлеге булган борт мәгълүмат системасы (БМС) белән җиһазландырылачак һәм интеллектуаль транспорт-мәгълүмат системасы (ИТМС-КАМАЗ) белән интеграцияләнәчәк. «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең К5 яңа буын автотехникасы өчен дистанцион бәйләнешкә керү мөмкин булачак (җылыткычны «ерактан торып» эшләтеп җибәрү, автомобиль системалары торышы мониторингы һ.б.), бу «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте өчен үз клиентларына кыйммәтле тәкъдимнәр булдыру һәм автомобильләрне эксплуатацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыра торган яңа хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру буенча өстәмә мөмкинлекләр ачачак. Башка сүзләр белән әйткәндә, гамәлгә кертелә торган интеллектуаль системалар «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең өстәмә сервислары маркетплейсы булачак. Борт мәгълүмат системасы (БМС) машина йөртүчеләргә билгеләнгән курс буенча барырга, мультимедиа мөмкинлекләре (музыка, видео, радио) һәм Билайн контент-сервислары ярдәмендә юлда яки ял иткәндә кәефсезләнмәскә, шулай ук алар өйләреннән ни кадәр еракта булсалар да, хезмәттәшләре һәм гаиләсе белән һәрвакыт элемтәдә калырга мөмкинлек бирәчәк.

«Эйдос-Робототехника» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – Россия уйлап табучысы, сәнәгать роботлары һәм автоматлаштырылган чишелешләрне җитештерүче. Компания тарафыннан Россия заводларында пэт-тарага эчемлекләр салу өчен роботлаштырылган линияләр кулланышка кертелде; «ЕВРОПЛАСТ» заводында (Казан шәһәре) пластик эшләнмәләрне автоматлаштырылган җыю линиясе булдырылды; эзлекле кинематика белән сәнәгать робот-манипуляторының серия алды үрнәкләрен сынау тәмамланды.

Пилотсыз транспортны үстерү юнәлеше буенча 2019 елның декабрендә «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең җитештерү мәйданчыгында КАМАЗ-4308 пилотсыз автомобиленең беренче тест йөрүләре башланды. Автомобиль-роботлар

ярдәмендә комплектлау детальләрен ташу проекты «Одиссей» дип аталды. Әлегә сүз «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең сәнәгать мәйданчыгы периметрына кергән юлларда логистика операцияләре ясау турында бара. Мондый машиналар билгеләнгән маршрутлар буенча йөртүләр-ташуларны таләп итә торган теләсә кайсы җитештерүдә кулланылырга мөмкин.

2019 елның декабрендә – 2020 елның гыйнварында «Цифрлы тау предприятиесе» инновация проектын гамәлгә ашыру кысаларында Кузбассның «Листвяжная» шахтасында КАМАЗ-43118 пилотсыз автомобиле сынау үтте. Нәтиҗәдә 2020 елның декабренә Кузбасста күмерне пилотсыз ташу буенча тулы бер система булдырылырга тиеш.

*«Акыллы» җиһаз»*

«Акыллы» җиһаз» инновация кластеры кысаларында, нефть-газ химиясе, энергетика һәм машина төзү кластерларының төп предприятиеләре, тармак фәне һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән тыгыз элемтәдә булып, электроника һәм технология җиһазларының күп яңа төрләрен булдыру һәм җитештерү белән шөгыльләнүче яңа инновация компанияләре оештыру һәм гамәлдә булган компанияләрне үстерү өчен шартлар тудыру планлаштырыла.

«КАИ – Лазер» төбәк инжиниринг сәнәгать лазер технологияләре үзәгендә катламлы үстерү белән ике кәкрелектәге гиперболоидлы тешле көпчәкләр әзерләү технологиясе (3D-технологияләр) эшләнә. Технология фиништагы механик эшкәртүне 8 тапкырга киметергә мөмкинлек бирәчәк. Мөмкин булган кулланучылар – җитештерүнең авиация, суднолар төзелеше һәм башка тармаклары.

2019 елда «Цифрлы технологияләр үзәге» акционер җәмгыяте төгәл кою, өчүлчәмле бастырып чыгару һәм өчүлчәмле сканерлау өлкәсендә 40ка якын эре предприятиегә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына хезмәт күрсәтте.

Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техник институты – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фән учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе 0.06 Тл магнит кыры индукцияле «ТМР-0.06-КФТИ» дигән магнит-резонанс томограф эшләп чыгарды. Бу аппарат элек института эшләнгән 0.02 Тл «ТМР-0.02-КФТИ» томографының модернизацияләнгән варианты булып тора.

Бүгенге көндә Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техник институтында буыннар авыруларын һәм травмаларын диагностикалау өчен магнит кыры индукциясе 0.4 Тл булган яңа махсуслаштырылган томограф эшләнә. Белгечләр фикеренчә, әлеге томографлар Россия Федерациясе клиникалары өчен «бәя һәм сыйфат» нисбәте буенча оптималь булачак. Томограф «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге тарафыннан «Градиент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән берлектә эшләнә. Продуктны базарга 2020 елда чыгару планлаштырыла.

*«Акыллы» мәгълүмат технологияләре»*

Заманча мәгълүмати технологияләр Татарстан Республикасы икътисадының төрле өлкәләрендә кертелә һәм шәһәрләрнең һәм тулаем төбәкнең цифрлы үсеше дәрәҗәсен күтәрү, куркынычсызлык, көндәлек бурычларны автоматлаштыру,

энергияне һәм ресурсларны саклауны тәэмин итү, гражданнар белән хакимият арасындагы бәйләнешне гадиләштерү һ.б. өчен интеллектуаль чишелешләрне куллануга юнәлдерелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 13 ноябрендәге б-2882 номерлы боерыгы белән республиканың 7 шәһәрендә: Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Зеленодольск, Әлмәт, Алабуга һәм Иннополис шәһәрләрендә гамәлгә ашырылачак «Акыллы шәһәр» Татарстан Республикасы шәһәр хуҗалыгын цифрлаштыру буенча ведомство проекты паспорты расланды.

Хәзерге вакытта «Акыллы торак-коммуналь хуҗалык» юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы җавап бирә торган программалар белән түбәндәге чараларны синхронлаштыру эше алып барыла:

күпфатирлы йортларны күмәк (гомумйорт) исәпкә алу приборларында җылылык энергиясен, салкын һәм кайнар суны куллануны исәпкә алуның җылылык китерүче температурасы, басым, куллану күләме күрсәткечләрен алуны һәм дистанцион тапшыруны тәэмин итә торган автоматлаштырылган системалары белән җиһазландыру;

коммуналь ресурсларны куллануны исәпкә алуның автоматлаштырылган системаларындагы мәгълүматларны шәһәрнең бердәм диспетчерлык хезмәтенә (Шәһәр идарәсенең интеллектуаль үзәгенә) кабул итүне тәэмин итү, ә аларның күрсәткечләрендә критик тайпылышлар булган очракта – авария хәлләрендәге фактларның булуын һәм аларны бетерү вакытларын ачыклау, алга таба аларның үтәлешен контрольдә тоту; мәгълүматларны ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән синхронлаштыру;

төзелә торган күпфатирлы йортларда коммуналь ресурсларны исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборларында салкын һәм кайнар суны, җылылык энергиясен куллануны исәпкә алуның автоматлаштырылган системаларын урнаштыру.

Шәһәр идарәсе кысаларында гражданнарны шәһәр үсеше мәсьәләләрен хәл итүгә җәлеп итү буенча «Актив шәһәр кешесе» цифрлы платформасын булдыру күздә тотыла. Хәзерге вакытта түбәндәге чаралар башкарылды:

шәһәр хуҗалыгы өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру буенча, шул исәптән «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты буенча рейтинглы тавыш бирүдә катнашу буенча сервис булдырылды;

гражданнарның гариза белән дистанцион, шул исәптән телефон аша хәбәр итү юлы белән мөрәҗәгать итүе, кергән гаризаларның үтәлешен контрольдә тоту һәм аларга үз вакытында җаваплар җибәрү системасы булдырылды;

күпфатирлы йортларның техник торышы турындагы мәгълүматларның актуальлеге тәэмин ителде, ул күпфатирлы йортның барлык конструктив элементлары тасвирнамәсен һәм техник тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган тузу дәрәҗәсен үз эченә ала.

«2014 – 2021 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасы кысаларында гражданнар өчен «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының юл хәрәкәте кагыйдәләре үтәлешен контрольдә тоту буенча мобиль кушымта кулланышка кертелде.

*«Smart-белем бирү»*

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрүнең шәхсиләштерелгән системасы турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 6492/14 номерлы боерыгы нигезендә 2016 елдан республикада мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрүнең шәхсиләштерелгән моделе гамәлгә ашырыла.

Модель «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» бердәм мәгълүмат системасында эшли. Системада 1 миллионнан артык кулланучы – мәктәпләр һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре укучылары, ата-аналар һәм мәгариф оешмалары хезмәткәрләре теркәлгән.

2019 елда түбәндәге модульләр модернизацияләнде: «Квалификация күтәрү», «Электрон урта һөнәри белем бирү», «Бердәм хисаплылык системасы», «Акчалата бүләк алуга конкурс». 2019 елда, системаны кулланып, Татарстан Республикасының 17 108 педагогик хезмәткәре квалификация күтәрү курсларын узды.

Республиканың белем бирү оешмалары тарафыннан «Дәресне өйрән», «Фоксфорд» ресурсларында балалар өчен үстерү юнәлешендәге дистанцион мәйданчыклар кулланыла.

Укучылар контингенты өчен «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында укытучы һәм укучы арасында дистанцион бәйләнешне кулланырга мөмкинлек бирә торган төрле виртуаль факультативлар булдырылды.

Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрүнең шәхсиләштерелгән моделен гамәлгә ашыру кысаларында «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасының «Квалификация күтәрү» модуле аша курс үткәннән соң мониторинг системасын гамәлгә кертү (сыйфатны бәйсез бәяләү) нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрү турында электрон документ (таныклык) бирү апробацияләнде.

*Сәламәт яшәү рәвеше*

Татарстан Республикасы җәмәгать сәламәтлеге үзәкләренең яңа моделен, җәмәгать сәламәтлеген ныгытуның төбәк һәм муниципаль программаларын, шулай ук «Гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә (сәламәт туклану һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны кертеп) мотивацияләү системасын формалаштыру» төбәк проектында каралган эш урыннарында сәламәтлекне ныгыту буенча корпоратив программаларны гамәлгә кертү буенча 20 пилот проект арасына кертелде.

Гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә (сәламәт туклану һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны кертеп) мотивацияләү системасын формалаштыру, йогышлы авырулардан үлүчеләр санын киметү максаты белән 2019 елда «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасының «Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру. Беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүне үстерү» ярдәмче программасы кабул ителде.

Республика халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга волонтерлар-медиклар, шул исәптән тематик «ишегалды фестивальләре», акцияләр, конкурслар, массакүләм чаралар кысаларында актив җәлеп ителә.

2019 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Милли медицина тикшеренү терапия һәм профилактика медицинасы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә 18 яшьтән өлкәнрәк халык арасында сәламәтлек мәсьәләләре буенча грамоталылык дәрәҗәсен өйрәнү буенча пилот проектында Татарстан Республикасының 11 дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесенең катнашуы оештырылды. 2019 елда социологик сораштыруда 2 500 кеше катнашты.

Медицина профилактикасы хезмәтенең эше дәвам иттерелде, ул Казан, Түбән Кама, Әлмәт, Зеленодольск шәһәрләрендәге 4 медицина профилактикасы үзәгеннән, 19 медицина профилактикасы бүлегеннән, 67 медицина профилактикасы кабинетыннан, 66 сәламәт бала кабинетыннан, 799 «сәламәтлек мәктәпләре», 21 сәламәтлек үзәгеннән (өлкәннәр өчен 15 үзәк, балалар өчен 6 үзәк) тора. 2019 елда сәламәтлек үзәкләрендә 89 732 кеше, балалар өчен сәламәтлек үзәкләрендә – 26 706 бала (мәктәп яшендәге балаларның 85 проценты) тикшерелде.

Берничә ел дәвамында республикада «Бердәм Россия» партиясенең «Сәламәт киләчәк» проекты кысаларында профилактика максатларындагы «Сәламәт мәктәп» акциясе үткәрелә. 2019 елда проектка Казан шәһәренең 11 мәктәбе һәм муниципаль берәмлекләренең өч мәктәбе килеп кушылды, дәресләрдә 10,1 меңнән артык кеше катнашты.

2019 елда мәктәп яны һәм җәйге сәламәтләндерү лагерьларында 110нан артык тематик лекторий оештырылды, аларга якынча 100 мең кеше җәлеп ителде. «Тормыш пульсы. Балалар» проекты кысаларында Татарстанның 9 – 12 яшьлек 1000 мәктәп укучысы квест форматындагы сәламәтлеккә багышланган тематик дәресләрдә катнашты.

«Республика медицина профилактикасы үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең спорт медицинасы буенча табиблары ай саен методик ярдәм күрсәтү өчен республиканың балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләренә бара, шул исәптән тренерлар-укытучылар составы, укучылар һәм аларның ата-аналары өчен тренировка режимын, сәламәт яшәү режимын саклау темаларына лекцияләр үткәрә.

Балалар өчен сәламәтлек үзәкләрендә өстәмә тикшерүләр исемлегенә тәмәке тартучылар арасында токсик матдәләрне билгеләүгә тест керә. 2019 елда сулап чыгарыла торган һавада углерод окисе булу дәрәҗәсенә тест узган 21 356 яшүсмер арасында 2,6 процентында риск факторлары ачыкланган. Нәтиҗәләр нигезендә сәламәтлек үзәкләре табиблары тарафыннан тәмәке тартудан баш тарту буенча индивидуаль тәкъдимнәр бирелде.

Казан шәһәрендә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе һәм аның Әлмәт, Бөгелмә, Зеленодольск, Яр Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендәге филиалларында тәмәке тартудан баш тарту буенча медицина ярдәме кабинетлары эшли. Түләүсез нигездә табиблар-психиатрлар-наркологлар кабул итә. Ел саен тәмәке тартудан баш тарту буенча медицина ярдәме кабинетларында 500дән артык кеше дәвалана. Тәмәке кулланудан баш тартуда ярдәм күрсәтү буенча «кайнар линия» оештырылды. Аның турындагы мәгълүмат

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең рәсми сайтында (https://rnd-kazan.ru/) урнаштырылды.

Республика наркология хезмәте тарафыннан исереклекне һәм эчкечелекне беренчел профилактикалау чаралары, шул исәптән гомуми белем бирү мәктәпләренең өлкән сыйныфлары, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укучылары, Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары арасында әлеге чаралар үткәрелә, сәламәтлек саклау, эчке эшләр, мәгариф, яшьләр эшләре һәм спорт, социаль яклау органнары, иҗтимагый оешмалар белгечләре өчен наркология авыруларын профилактикалау буенча укыту-методик семинарлар уздырыла.

Тернәкләндерү программаларында коммерциячел булмаган оешмалар һәм традицион дини конфессияләр вәкилләре актив катнаша. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы мөселманнарының диния нәзарәте һәм Казан Епархиясе арасында өчьяклы килешү кысаларында нәрсәгә дә булса бәйле булган кешеләр белән уртак эш алып барыла.

Ел саен республиканың эре сәүдә үзәкләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба – «Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) катнашында «Яман шеш авыруына каршы белем бирү» эре масштаблы проекты кысаларында күкрәкнең яман шешен иртә диагностикалау буенча #минүттем социаль акциясе оештырыла. 2019 елда акция барышында онколог-маммологлар табиблары консультациясен һәм медицина күрсәткечләре буенча сөт бизләрен ультратавыш белән тикшерүне үткәрүне үз эченә алган медицина тикшерүен 1 097 хатын-кыз үтте.

Республикада яшәүче 50 – 69 яшьлек хатын-кызлар «Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә, телефоннан алдан язылып, бушлай маммографик скрининг узарга мөмкин.

Моннан тыш, Татарстан Республикасында түбәндәгеләрне үз эченә алган яшьләр сәясәте учреждениеләре системасы эшли: яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары, яшьләр үзәкләре, балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләре, җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәкләре, хәрби-патриотик эшләр һәм хәрби хезмәткә чакырганга кадәрге яшьләрне әзерләү үзәкләре һәм башкалар (барлыгы – 366 учреждение, шул исәптән 11 дәүләт бюджет учреждениесе); алар эшчәнлегенең бер юнәлеше булып балигъ булмаганнар һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвеше культурасын тәрбияләү тора.

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте органнары һәм учреждениеләре тарафыннан яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, тәмәке тартуны, алкоголизмны, ВИЧ/СПИДны профилактикалауга, наркоманияне беренчел профилактикалауга юнәлдерелгән, истәлекле даталарга багышланган республика тематик чаралар комплекслары уздырыла.

Эш Россия Федерациясе законнары кысаларында башкарыла.

2019 елда:

Россия Федерациясе Президентының «Наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында» 2007 елның 18 октябрендәге 1374 номерлы, «2020 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясен раслау турында» 2010 елның 9 июнендәге 690 номерлы, «Россия Федерациясендә кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруларның таралуын кисәтү турында» 1995 елның 30 мартындагы ФЗ-38 номерлы указларын үтәү йөзеннән, яшьләр эшләре органнары һәм яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан, 82 757 кеше җәлеп итеп, 354 профилактика чарасы үткәрелде, шул исәптән:

«Тукта ВИЧ/СПИД» бөтенроссия акциясе – 176 чара, 45 424 кеше җәлеп ителде;

«Үлем белән кайда сәүдә итүен хәбәр ит» гомумроссия акциясенең 1 нче этабы – 178 чара, 37 333 кеше җәлеп ителде;

«Йогышлы авыруларны иммунопрофилактикалау турында» 1998 елның 17 сентябрендәге 157-ФЗ номерлы, «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль законнарны, Россия Федерациясе Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең «Россия Федерациясендә профилактика прививкаларының һәм халыкны өстәмә иммунитетлаштыруның милли календарен гамәлгә ашыру чараларын камилләштерү турында» 2009 елның 7 апрелендәге 19 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Европа иммунитетлаштыру атнасы кысаларында балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең йогышлы авыруларны иммунитетлаштыру һәм кисәтү мөһимлеге турындагы белемнәрен арттыру максатларында 260 чара үткәрелде, 30 110 кеше җәлеп ителде;

«Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирә тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тартуның зыяннарыннан саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Бөтендөнья тәмәкесез көненә багышланган 198 чара үткәрелде, 20 446 кеше җәлеп ителде;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясе халкы арасында алкоголь продукциясен чамадан тыш куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру концепциясе турында» 2009 елның 30 декабрендәге б-2128 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Бөтенроссия аеклык көненә багышланган 213 чара үткәрелде, 29 730 кеше җәлеп ителде.

Чаралар үткәрү барышында балигъ булмаганнарга һәм яшьләргә тәрбия бирүнең социаль, педагогик, психологик һәм медицина аспектлары тормышка ашырыла:

профилактика чараларының социаль аспекты «#ВИЧкатесттапшыр», «#Росяшьләр», «#ТормышТехнологиясе», «#ТУКТАВИЧСПИД», «#яшьминистрлык» хэштеглары белән флешмоб онлайны ярдәмендә, социологик сораштырулар, профилактика акцияләре үткәрү, күрсәтмә агитация чаралары, кәгазьләр, буклетлар тарату аша; интернет-акцияләр, яшьләр өчен «Без сәламәт

яшәү рәвеше өчен», «Тәмәке тарту модада түгел», «Аеклык – көчлеләр сайлавы», «Үлем белән кайда сәүдә итүен хәбәр ит», «Без тормышны сайлыйбыз» темаларына семинарлар, медицина хезмәткәрләрен, кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар һ.б. белгечләрен чакырып «түгәрәк өстәлләр» утырышлары һ.б. ярдәмендә гамәлгә ашырыла;

тәрбия бирүнең педагогик аспекты сәламәт яшәү рәвешенә юнәлдерелә, ул «Сәламәтлек – минем сайлау», «Вакцинация – сәламәт милләт!», «Спорт – начар гадәтләргә альтернатива», «ВИЧ-инфекциянең таралуын профилактикалау», «Тормыш матур! Аны заяга үткәрмә!», «Мин сәламәт» һ.б. темаларга профилактик әңгәмәләр, аралашу сәгатьләре, мәгълүмати сәгатьләр, интеллектуаль уеннар, театрлаштыру, спорт чаралары, спорт төрләре буенча ярышлар, күңелле стартлар, флешмоблар, квестлар, рәсемнәр, плакатлар конкурслары, профилактик фильмнар карау һәм алар буенча фикер алышу ярдәмендә гамәлгә ашырыла;

психологик аспекты яшьләр өчен «Сәламәтлек әлифбасы», «Начар гадәтләрне профилактикалау» һ.б. темаларга тренинглар, интерактив семинарлар һәм башка программалар үткәрү аша тормышка ашырыла;

медицина аспекты балигъ булмаган балаларны һәм яшьләрне спорт-массакүләм чараларга, бию флешмобларына, саф һавада массакүләм ишегалды уеннарына һ.б. җәлеп итү аша аларның сәламәтлеген яхшырту ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

Моннан тыш, яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан даими нигездә балигъ булмаганнарны һәм яшьләрне мәнфәгатьләре буенча берләшмәләр дәресләренә, сәламәт яшәү рәвеше һәм социаль тискәре күренешләрне профилактикалау юнәлешләре буенча түгәрәк эшчәнлегенә җәлеп итү эше алып барыла.

Балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләре тарафыннан түбәндәге юнәлешләр буенча проект эшчәнлеге алып барыла:

яшьләр арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау – Чаллы шәһәрендә «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – «Диалог» үзәге) тарафыннан түбәндәге программалар тормышка ашырылды:

«Студент һәм укучы яшьләр арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау формасы буларак шәһәрнең югары һәм һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында психологик хезмәтләр эшләре». Максаты – укучы һәм студент яшьләре арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау буенча югары һәм һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларының психологик хезмәтләре эшчәнлеген оештыру-методик яктан тәэмин итү һәм координацияләү. Максатчан төркемнәр: беренчел – югары һәм һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларының психологлары, педагог-психологлары; икенчел – югары белем һәм урта һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары, укытучылар, ата-аналар. «Укучы яшьләр арасында радикализмны профилактикалау аспекты буларак булинг һәм моббингның психологик-педагогик превенциясе», «Кискен һәм җәрәхәт алганнан соңгы стресс киеренкелекләрен профилактикалауда стресслы халәтләрне коррекцияләү ысуллары», «Гаилә кыйммәтләрен формалаштыру буенча яшьләр белән эшләүдә ведомствоара хезмәттәшлек» дигән семинар-практикумнар

үткәрелде. «Социаль куркыныч авыруларны профилактикалау» дигән темага семинар, «Ресурслы нетворкинг» тренингы һ.б. уздырылды, 30дан күбрәк кеше җәлеп ителде;

«Яшүсмерләр мохитендә социаль тискәре күренешләрне профилактикалау һәм уңай күнекмәләр формалаштыру». Максаты – гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау буенча ведомствоара мәгълүмати-консультация механизмын үстерү. Максатчан төркем – шәһәрнең гомуми белем бирү оешмалары педагог-психологлары. Педагоглар өчен «риск төркеме»ндәге укучыларга психологик яктан булышлык күрсәтү мәсьәләсе буенча семинар-практикумнар, мастер-класслар, методик консультацияләр үткәрелә, әлеге эшкә 80нән артык кеше җәлеп ителде;

«Яшьләр сәясәте учреждениеләрендә яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә социаль тискәре күренешләрне профилактикалау һәм уңай тормыш күнекмәләрен формалаштыру буенча эш системасын оештыру». Максаты – яшьләр сәясәте учреждениеләре белгечләренең яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә социаль тискәре күренешләрне профилактикалау һәм уңай тормыш күнекмәләрен формалаштыру буенча эшчәнлеген оештыру-методик һәм психологик-педагогик яктан тәэмин итү һәм координацияләү. Максатчан төркемнәр: беренчел – шәһәрнең яшьләр эшләре буенча учреждениеләренең яшьләр белән эшләү буенча методистлары, психологлары, педагог-психологлары, белгечләре; икенчел – шәһәрнең яшьләр сәясәте учреждениеләренә йөрүче яшүсмерләр һәм яшьләр. Яшьләр сәясәте белгечләре өчен семинар-практикумнар, тренинглар, методик консультацияләр, ел саен үткәрелә торган «Яшь буынның кеше капиталын саклап калуга, формалаштыруга һәм туплауга юнәлдерелгән яшьләр белән эшләүнең перспектив стратегияләре» дигән шәһәр конференциясе үткәрелә, җәлеп итү – 400дән артык кеше;

«Төрле максатчан төркемнәр өчен яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә социаль тискәре күренешләрне һәм асоциаль үз тотышны профилактикалау программасы». Максатчан төркем – яшүсмерләр, яшьләр, ата-аналар, педагоглар, яшүсмерләр һәм яшьләр белән эшләү буенча белгечләр. «Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруның психологик аспектлары», «Хәзерге заман яшүсмере. Үсү авырлыклары», «Чаллы шәһәрендә халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» һ.б. дигән семинар-практикумнар һәм лекцияләр үткәрелде. Программа кысаларында психологик-педагогик белем бирү максатларында массакүләм мәгълүмат чараларында «Тормыш – уен түгел, яңадан башлап булмаячак», «Тукта-янау. Балалар куркынычсызлыкта», «Гади аралашу кагыйдәләре» һ.б. дигән мәгълүмат урнаштырылды, җәлеп итү – 1 300дән артык кеше;

«Яшьләр сәясәте учреждениеләрендә, гомуми белем бирү учреждениеләрендә, югары һәм һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында профилактика эшен оештыру мониторингы». Максаты – гомуми белем бирү учреждениеләрендә, югары һәм һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында профилактика эшчәнлеге торышын, аның психологик яктан тәэмин ителешен; яшьләр сәясәте учреждениеләрендә яшьләр белән эшләүче белгечләрнең эшчәнлеге торышын билгеләү һәм анализлау. Максатчан төркем – учреждениеләрдә профилактика эшләре өчен җаваплы белгечләр. Чаллы шәһәренең гомуми белем бирү оешмалары,

югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары, яшьләр сәясәте учреждениеләре мониторингы үткәрелде;

«Яшьләр мозаикасы». Максаты – 18 – 30 яшьләрдәге яшьләрнең социаль уңай күнекмәләрен формалаштыру. Программа кысаларында шәһәрнең югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары студентлары һәм эшләүче яшьләре өчен интерактив дәресләр һәм лекцияләр үткәрелде, анда 500дән артык кеше катнашты;

наркоманияне профилактикалау – Чаллы шәһәрендә һәм Чистай шәһәрендә.

Чаллы шәһәренең «Диалог» үзәге тарафыннан түбәндәге программалар гамәлгә ашырылды:

«Max Freedom». Максаты – яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең наркотик һәм психоактив матдәләрне кирәгеннән артык куллануга каршы тора торган һәм сәламәт үз тотышны формалаштыруга ярдәм итә торган шәхси ресурсларын активлаштыру һәм үстерү. Максатчан төркем – 14 – 22 яшьлек яшүсмерләр һәм яшьләр. Яшүсмерләр һәм яшьләр өчен «Яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә наркотиклаштыруны профилактикалау», «Сәламәт яшәү рәвеше», «Яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә ВИЧ-инфекцияне профилактикалау» һ.б. темаларга 9 интерактив мәгълүмати-агарту лекциясе үткәрелде; 1 200 дән артык кеше җәлеп ителде;

«Мәгълүмат киңлеге». Максаты – яшүсмерләргә, яшьләргә, белгечләргә, ата-аналарга сәламәтлекне профилактикалау һәм саклау мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү. Беренчел төркем – 14 – 30 яшьтәге яшүсмерләр һәм яшьләр, икенчел төркем – яшьләр сәясәте учреждениеләренең яшьләр белән эшләү буенча белгечләре, мәгариф оешмаларының педагог-психологлары һәм ата-аналар. Проект кысаларында яшьләр сәясәте учреждениеләренең тематик буклетлары әзерләнде, алга таба аларны яшьләр сәясәте учреждениеләренең яшьләр белән эшләү белгечләре, яшьләр һәм студентлар иҗтимагый берләшмәләре, волонтерлык оешмалары вәкилләре акцияләрдә, «түгәрәк өстәл»ләрдә, семинарларда, тренингларда, лекцияләрдә таратты.

«Диалог» үзәге тарафыннан түбәндәгеләр уздырылды:

«Яшьләр континенты» наркотикларга каршы марафоны. Максаты –яшьләрнең иҗади потенциалын үстерү һәм наркотикларга каршы пропаганда эшчәнлеге аша яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә наркотиклаштыруны профилактикалау; сәламәт яшәү рәвешен һәм уңай тормыш кыйммәтләрен формалаштыруга юнәлдерелгән яшьләр арасында наркотикларга каршы чаралар уздыру; наркотикларга каршы эшнең уңай тәҗрибәсе белән уртаклашу. Наркотикларга каршы профилактика чаралары үткәрелә. Катнашучылар саны – 1 300дән артык кеше;

яшьләр сәясәте учреждениеләре, югары һәм һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары белгечләре өчен яшьләр мохитендә асоциаль үз тотыш өлкәсендә һөнәри осталык конкурсы. Максаты – яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә асоциаль үз тотышны, наркоманияне һәм башка социаль тискәре күренешләрне профилактикалау өлкәсендә эшләүче иң яхшы белгечләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү. Конкурс йомгаклары буенча «Тормыш күнекмәләрен формалаштыру» һәм «Бәйлелекне профилактикалау» номинацияләрендә җиңүчеләр билгеләнде, алар дипломнар һәм бүләк сертификатлары белән бүләкләнде. Конкурс кысаларында үткәрелгән ачык дәресләр «Яшьләр мохитендә асоциаль үз тотышны профилактикалау өлкәсендә һөнәри осталык конкурсы йомгаклары» брошюрасында басылып чыкты. 77 кеше катнашты;

яшьләр сәясәте өлкәсе оешмаларының, һөнәри һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының, яшьләр иҗтимагый һәм ирекледәр берләшмәләренең, яшәү урыны буенча яшүсмерләр һәм яшьләр клубларының наркотикларга каршы профилактика чараларының шәһәр конкурсы. Максаты – наркотикларга каршы профилактик социаль әһәмиятле инициативаларны үстерү һәм аларга ярдәм итү. Максатчан төркем – яшьләр иҗтимагый һәм ирекледәр берләшмәләре, яшьләр сәясәте өлкәсе оешмалары, шәһәрнең яшүсмерләр һәм яшьләр клублары, һөнәри һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының психологик хезмәтләре вәкилләре. Конкурс йомгаклары буенча «Без сәламәтлекне сайлыйбыз», «Чынбарлыкта яшә», «Киләчәк безнең кулларда», «Тормыш ритмында», «Бәхет рецептлары» номинацияләрендә җиңүчеләр билгеләнде. 2000нән артык кеше җәлеп ителде.

Чистай шәһәренең «Статус» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениеләре белгечләре тарафыннан яшәү рәвешен пропагандалауга һәм химик бәйлелекне кисәтүгә юнәлдерелгән «Сәламәт киләчәк» программасы тормышка ашырылды. Мәктәп укучылары һәм студентлар белән спайслар, наркотиклар, алкоголь продукциясе куллану, тәмәке тарту мәсьәләре буенча интерактив дәресләр үткәрелде. 1 700дән артык кеше җәлеп ителде.

2019 елда Татарстан Республикасы «Сәламәт төбәк – сәламәт Россия» төбәкара проектында катнашты, аның кысаларында Халыкара наркотик чараларны явыз ният белән куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш көненә багышланган «Наркотикларсыз тормыш» республика наркотикларга каршы акциясе оештырылды. 18 746 кеше катнашында, 191 чара үткәрелде.

Акция барышында 2019 елның 26 июнендә Казан шәһәрендә «Россия – наркотикларсыз территория» бөтенроссия җиңел атлетика узышы уздырылды. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитеты тарафыннан концерт мәйданчыгы эше, шул исәптән Яшүсмер» яшәү урыны буенча яшүсмерләр клублары берләшмәсе» Казан шәһәре муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениеләренең иҗат коллективлары чыгышы, «Яшь Казан» проекты һәм «Волонтерлар медиклар» ирекледәр хәрәкәте волонтерлары эше – яшьләр арасында психоактив матдәләрне куллануны профилактикалау буенча мәгълүмати материаллар тарату оештырылды. Моннан тыш, «Республика яшьләр, инновацион һәм профилактика программалары үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең рәсми сайтында http://rcmipp.tatarstan.ru/rus/meropriyatiya.htm адресы буенча «Наркотикларсыз тормыш» республика наркотикларга каршы акциясен үткәрү буенча тәкъдимнамәләр» методик материаллары урнаштырылды.

Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте учреждениеләре эшчәнлеген норматив хокукый тәэмин итү буенча планлы эш башкарылды, аның барышында учреждениеләрнең һәр төре өчен бертип нигезләмәләр эшләнде һәм расланды. Учреждениеләрнең эшчәнлек үзенчәлекләренә туры китереп, бертип нигезләмәләр эшнең төп юнәлешләрен билгели, балалар һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора.

Шулай ук Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан 2019 елда Дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү эшләнде, ул Татарстан Республикасының яшьләр эшләре органнары һәм яшьләр

сәясәте учреждениеләре эшчәнлеген мониторинглауны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

Төп күрсәткечләр системасы «Даими нигездә оештырылган асоциаль тәртипне профилактикалау юнәлешләре буенча профилактика эше» бүлеген үз эченә ала, анда яшьләрнең муниципаль берәмлекнең ачык киңлекләрендә «Яшел Фитнес» даими мәдәни-спорт чараларында катнашуы, ХОӘ популярлаштыру чараларында һәм сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру буенча башка профилактика чараларында катнашуы бәяләнә. Бәяләү критерийлары булып Татарстан Республикасында яшьләрнең гомуми саныннан чараларга җәлеп ителгән яшьләр саны өлеше тора.

*«Экотуклану»*

Республика территориясендә органик авыл хуҗалыгын үстерү буенча максатчан эш алып барыла.

Органик авыл хуҗалыгы – «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән һәм аларны гамәлгә ашырганда әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итүгә, кеше сәламәтлеген ныгытуга, туфракның уңдырышлылыгын саклап калуга һәм торгызуга юнәлдерелгән ысуллар, методлар һәм технологияләр кулланыла торган икътисадый эшчәнлек төрләре җыелмасы. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршында Органик продукция (югарыда күрсәтелгән Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килә торган экологик чиста авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек) җитештерү буенча Иҗтимагый совет төзелде. Ул республиканың дәүләт хакимияте органнары вәкилләрен, галим-практикларын һәм фермерларны берләштерә, республика органик җитештерүнең хокукый базасын һәм органик авыл хуҗалыгын үстерү өчен уңай шартлар булдыруга ярдәм итә.

Татарстан Республикасында «Татарстанның органик продукты» органик продукция җитештерүне ирекле сертификацияләү системасы эшләнде, аның башкарма органы – «Тест-Татарстан» республика сертификатлаштыру методик үзәге» ябык акционер җәмгыяте. Хәзерге вакытта 2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасында органик авыл хуҗалыгын үстерү программасы эшләнә. Шулай ук җитештерүнең органик ысулына күчү турында ирекле рәвештә карар кабул иткән хуҗалыклар да билгеләнде.

*«Тотрыклы энергетика»*

Кластерны үстерү заманча зур энергетикада яңа технологияләр (акыллы генерация һәм акыллы челтәрләр, яңа аккумуляторлар һәм чыбыклар һ.б.) һәм тотрыклы энергия чыганаклары (кояш энергиясе, җил һәм су энергиясе, атом энергиясе, биомассадан һәм көнкүреш калдыкларыннан алына торган энергия) нигезендә инновацион тотрыклы энергетиканы үстерү өчен уңайлы шартлар булдыруны күздә тота.

Электр челтәре комплексын цифрлаштыру бүгенге көндә энергетика тармагының өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора.

2019 елның мартыннан «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте юридик һәм физик затларда (*шәхси сектор*) закон нигезендә электр энергиясен исәпкә алуның интеллектуаль приборларын урнаштыру буенча масштаблы эш

башлап җибәрде. Күпфатирлы йортларда исәпләгечләр «Татэнергосбыт» акционер җәмгыяте тарафыннан законнар нигезендә куелачак. «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте программасы 29 районны үз эченә алачак, аларда 130 меңнән артык «акыллы исәпләгеч» урнаштырылачак.

Моннан тыш, 2019 елда Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте филиалы Казан шәһәрендәге бүлгеч челтәрне реконструкцияләү һәм автоматлаштыру буенча биш еллык комплекслы программаны гамәлгә ашыруга кереште. Бу компания җиһазларын Smart grid элементлары белән җиһазландыру программасын тормышка ашыруның өченче этабы инде. Технология – кулланучыларны өзлексез электр белән, ә компания белгечләрен бүлү челтәрләренең эше белән дистанцион идарә итү мөмкинлеге белән тәэмин итә.

Республикада, яңартыла торган энергия чыганакларын кулланып, альтернатив энергетиканы, аерым алганда, җил энергиясе нигезендә үстерүгә зур игътибар бирелә.

2019 елда республиканың Кама Тамагы, Балык Бистәсе һәм Спас районнарында җилләрне үлчәү тәмамланды. Йомгаклар буенча кызыксынучы инвесторларга тәкъдим итү өчен җилләрне үлчәү турында һәм электр энергиясен эшләп чыгару турында хисаплар әзерләнде.

Транспорт логистикасы, электр челтәре инфраструктурасы өлешендә җил парклары өчен мөмкин булган мәйданчыкларны анализлауны исәпкә алып, потенциаль инвесторлар белән бергә Татарстан Республикасының башка районнарында да мәйданчыклар эшләнә.

*«Биосистемалар»*

Республика агросәнәгать комплексын фәнни яктан тәэмин итү өчен зур потенциалга ия. «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәген булдыру, молекуляр-генетик, биотехнологик һәм күзәнәк ысулларын кулланып, фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр алып барырга мөмкинлек бирә, бу исә авыл хуҗалыгы өчен алдан билгеләнгән үзлекләр булган үсемлекләрнең һәм препаратларның яңа сортларын булдыруны тизләтә. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең, «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең, югары белем бирүче «Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни проектлары авыл хуҗалыгы җитештерүенә һәм җитештерелгән продукцияне эшкәртүгә киңрәк җәлеп ителергә тиеш. Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең аерымланган структур бүлекчәсе коллективы тарафыннан 5 ел эчендә төрле культураларның 46 сорты булдырган, шуларның 24е Дәүләт реестрына кертелгән, 22се – дәүләт сорт сынавы уза. Соңгы 10 ел эчендә төрле культураларның булдырылган сортлары республикада чәчү мәйданнарының яртысыннан артыгын, шулай ук Россиянең башка төбәкләрендә 1,7 млн га чәчүлек мәйданнарын били.

Авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бәрәңгенең үз сортларын сыйфатлы орлык белән тәэмин итү һәм бәрәңгенең чит илдән орлык материалына бәйлелеген киметү

максатларында соңгы 10 елда институтта бәрәңгенең 6 вируска чыдам сорты булдырылды. Ел саен Россия селекциясенең 70 сортына экологик-географик сынау үткәрелә.

Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында сәламәтләндерелгән территория нигезендә бәрәңге орлыкчылыгы системасы эшләнде һәм гамәлгә кертелде. Институтның биотехнология комплексы халыкара сыйфат стандартларына туры килә торган сәламәтләндерелгән орлык бәрәңгесен (800 тонна) җитештерергә мөмкинлек бирә.

Моннан тыш, «Бәрәңгенең биоресурс коллекциясе» күмәк файдалану үзәге булдырылды, аның 523 сортын һәм гибридын үз эченә ала.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан, ведомство буйсынуындагы оешмалар белән берлектә, «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә игенчелекнең биологик системасын гамәлгә кертү»ведомство программасы эшләнде.

Программаның максаты – туфракның уңдырышлылыгын арттыру һәм тәэмин итү, туклану элементларының уңай балансына ирешү, үсемлекчелек продукциясен җитештерүне стабильләштерү.

Программаның максатчан күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

гектарына 4,5 тоннадан артык коры органик матдә (КОМ) кертүне тәэмин итү;

туфрак-климат зонасына карап, күпьеллык үләннәрнең тәкъдим ителә торган мәйданы – 15 проценттан 21 процентка кадәр (Татарстан Республикасы буенча – 17 процент);

бөртекле-кузаклы культураларның чәчү мәйданы – сөрүлек җирләренең 4 проценты;

табигый-климат зонасына карап, сидераль парларның һәм тамырда калган чәчүлекләрнең мәйданы – 20 процenttан 24 процентка кадәр (Татарстан Республикасы буенча – 22,3 процент);

майлы хаҗчәчәкле культураларның чәчү мәйданы – сөрүлек җирләреннән 5 проценты;

ел саен известьлау күләмнәре – 100 мең гектар;

кимендә 2 мең гектар мәйданда агроурманмелиорация эшләре башкару.

«2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә игенчелекнең биологик системасын кертү» программасын гамәлгә ашыру шактый икътисадый нәтиҗәгә ирешергә, республиканың агросәнәгать комплексын тотрыклы үстерүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк, әйләнә-тирә мохит торышын яхшыртуга һәм туфраклардан рациональ файдалануга китерәчәк. Моннан тыш, программаны гамәлгә ашыру үзкыйммәтне киметкәндә продукциянең продуктивлылыгы югары булган һәм сыйфатлы авыл хуҗалыгы культураларын үстерергә, туфракның уңдырышлылыгын яхшырту темпларын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасында 2019 елда авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан 472 тонна биологик препарат сатып алынды һәм файдаланылды. Республикада биопрепаратлар җитештерү белән «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы, «Биопрепаратлар» фәнни-җитештерү институты җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм BIONOVATIC шөгыльләнә.

**Электрон рәвештә хезмәт күрсәтү**

2019 елда Бердәм идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында теркәлгән һәм федераль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге булган кешеләр өлеше 2018 елга карата 21 процентка артты һәм 3,084 млн кеше тәшкил итте.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (алга таба – Портал) аша 272 электрон хезмәт күрсәтүдән һәм сервистан файдаланырга мөмкин. Порталда 2,4 миллионнан артык шәхси кабинет теркәлгән. 2019 елда Татарстан халкы электрон хезмәтләрдән 281,1 млн тапкырдан артык файдаланды, бу 2018 елга караганда 1,6 тапкырга күбрәк.

2019 ел йомгаклары буенча башкарылган түләүләрнең күзәтелә торган суммасы 20,1 млрд сум тәшкил итте.

2019 елда түбәндәге дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия хезмәтләр һәм сервислар гамәлгә ашырылды:

Порталда «Мәктәп картасы» информеры өстәлде;

мобиль кушымтада виртуаль карта балансын карау буенча сервис гамәлгә ашырылды;

газ өчен исәпләүләр буенча push-хәбәрнамәләр җибәрү гамәлгә ашырылды;

Порталда социаль түләүләр алу өчен банк счеты реквизитларын үзгәртү сервисы тормышка ашырылды;

мобиль кушымтада Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасыннан исәпләүләр өчен түләү сервисы гамәлгә ашырылды;

мобиль кушымтада электр энергиясе өчен абонент түләве кертү сервисы эше яхшыртылды;

«МИР» түләү системасының дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча виртуаль карта чыгару мөмкинлеге тормышка ашырылды;

Татарстан Республикасының пилот муниципаль берәмлегендә җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын алуга гариза бирү мөмкинлеге гамәлгә ашырылды;

төзелешкә электрон рәвештә рөхсәт алу буенча хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырылды.

*Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының яңа хезмәтләре:*

җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү;

начар табигать-климат шартлары барлыкка килгән чорда авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы белән Казан шәһәренең автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт бирү;

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең автомобиль юлларында хәрәкәт итүне вакытлыча чикләүгә яки туктатуга рөхсәтләр (күрсәтмәләр) бирү;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы карары белән төрләре билгеләнгән объектларны урнаштыру өчен дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан Казан шәһәренең милек реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда җир кишәрлеген сату юлы белән милеккә тапшыру;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль милекне рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

муниципаль милекне арендалау буенча гамәлдәге килешүне өзү;

муниципаль казна мөлкәтен арендага бирү;

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен, сатулар үткәрмичә, түләүсез файдаланугa тапшыру.

***«Цифрлы икътисад» милли проекты***

«Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» милли программасына 6 проект керә:

1. «Мәгълүмати инфраструктура».
2. «Цифрлы нигездә дәүләт идарәсе».
3. «Цифрлы икътисад өчен кадрлар».
4. «Мәгълүмат куркынычсызлыгы».
5. «Цифрлы технологияләр».
6. «Цифрлы мохитне норматив җайга салу» (инфографика).

Татарстан Республикасында «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» милли программасының 5 төбәк проекты гамәлгә ашырыла, алар кысаларында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә 3 меңгә якын социаль әһәмияткә ия объектны тоташтыру, халыкны цифрлы икътисадның төп компетенцияләренә түләүсез өйрәтү, гражданнарның хакимият органнары белән цифрлы нигездә үзара бәйләнешен арттыру, шулай ук Татарстан предприятиеләренә перспективалы «үтәли» цифрлы технологияләр кертү чыгымнарын каплау планлаштырыла.

*Цифрлы икътисад өчен кадрлар*

2019 елда югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның гомуми саны 29 742 мең кеше тәшкил итте, шулардан 12 югары белем бирүче мәгариф оешмаларында ИТ-белгечлек буенча белем алучылар – 1 637 кеше. Урта звено кадрларын әзерләүне 18 техникум һәм көллият тәэмин итә. 2019 елда урта һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның гомуми саны 18 041 кеше тәшкил итте, шулардан ИТ-юнәлешләр буенча – 931 кеше.

Өлкән яшьтәге гражданнар өчен квалификация күтәрү һәм һөнәри әзерлек программалары буенча «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында 143 кеше белем алды.

Цифрлы сертификатлар буенча укуга 1000гә якын татарстанлылар кабул ителде.

Дәүләт хезмәткәрләрен, муниципалитетлар һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар хезмәткәрләрен «CDO: мәгълүматларга нигезләнгән идарә» программасы буенча 2 150 кеше курс үтте, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясенең Казан филиалы программалары буенча 198 кеше курс узды.

2019 ел дәвамында «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе базасында «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе бизнес-инкубаторына 40лап сайлап алу, шулай ук Slush халыкара стартап-конференциясенә сайлап алу гамәлгә ашырылды. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм өлкәннәр өчен курслар оештырыла. ИТ-паркның ИТ-академиясендә өлкәннәр аудиториясе өчен төрле юнәлешләр буенча 40тан артык белем бирү курслары һәм мәктәп укучылары өчен 15тән артык курс, шул исәптән гомуми үстерә торган ILand курсы гамәлгә ашырыла. 2019 елда ИТ-академиядә Чаллы шәһәрендә 290дан артык бала һәм 70 олы кеше, Казан шәһәрендә 150дән артык бала һәм 235 олы кеше белем алды. Шулай ук ИТ-паркта мәктәп укучылары һәм студентлар өчен «Digital Start» цифрлы эшкуарлык компетенцияләрен үстерү программасының ике укыту курсы үткәрелде.

2019 елда белем бирү онлайн-платформасында барлыгы 1 300дән артык кеше теркәлде, алар арасында программада 700дән артык мәктәп укучысы һәм студент катнашты. Финалга 34 проект чыкты.

Чаллы шәһәренең «Кванториум» балалар технопаркында ел саен 460 тәрбияләнүчеләр белем ала, тагын 1 700гә якын бала мәгълүмат технологияләре өлкәсендә 12 юнәлеш буенча төрле чараларга җәлеп ителә. Түбән Кама шәһәренең «Кванториум» технопаркында ел саен 11 юнәлеш буенча 840тан артык бала белем ала, 3 500дән артык укучы төрле чараларга җәлеп ителә. 2019 елдан башлап, үзәк «Үсеш нокталары» проекты буенча информатика укытучыларын әзерләүнең төбәкара мәйданчыгы булып тора. Әлмәт шәһәренең «Кванториум» технопаркында ел саен 840тан артык бала белем ала. Балалар һәм яшүсмерләр белән укыту биш техник юнәлеш буенча оештырылды: робоквантум, IT-квантум, сәнәгать дизайны, нейроквантум, наноквантум.

Казан шәһәренең «IT-cube» балалар цифрлы белем бирү үзәгендә 5 – 18 яшьлек 878 бала һәм яшүсмер бушлай белем алды, шулай ук һөнәри юнәлеш бирүче чаралар үткәрелде, аларда бөтен республикадан 1 500дән артык мәктәп укучысы катнашты.

Бүгенге көндә «Яндекс.Лицей» (өстәмә белем бирү) проекты кысаларында 448 мәктәп укучысы Python телендә программалаштыруга өйрәнә. 2019 елда 42 мәктәп укучысы 2 еллык курсларны тәмамлады.

340 бала мәктәпләрдә шәхсиләштерелгән белем бирүнең цифрлы платформасын кертү кысаларында белем ала. 73 укытучы «Сбербанк» гавами акционер җәмгыятендә 4 белем бирү сессиясендә булды, цифрлы платформа белән эшләү кысаларында яңа компетенцияләр алды.

*Цифрлы технологияләр*

2019 елның 21 – 22 декабрендә «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесендә үтәли цифрлы технологияләр

өлкәсендә технологик проектлар өчен интенсив – «Цифрлы чемпионнар мәктәбе» уздырылды. Программаның максаты – икътисадның реаль секторы оешмалары белән хезмәттәшлек итүгә стартаплар яки венчур проектларын әзерләү. «Цифрлы чемпионнар мәктәбе»ндә 15 стартап-проект катнашты. «Цифрлы чемпионнар мәктәбе» эчтәлеге буенча преакселерация программасы булып тора, ул технологик стартапларның тизләтелгән үсешенә һәм аларның гамәлгә ашырылуына ярдәм итә.

Иң күп санда гаризалар: 118 гаризаның 21е Татарстан Республикасыннан тапшырылды. Россия мәгълүмат технологияләрен үстерү фонды 13 җиңүчене билгеләде, шулардан 4 Татарстан проекты.

# ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ

## Җир һәм су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану

2019 елда Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен сатудан Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр керү 8,1 млн сум тәшкил итте (әлеге статья буенча бюджет йөкләмәсе 105,9 процентка үтәлде).

2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы милкендә булган һәм арендага бирелгән җир кишәрлекләренең гомуми мәйданы якынча 3 400 гектар тәшкил итә. 2019 елда Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен арендага бирүдән Татарстан Республикасы бюджетына 85,6 млн сум акча керде (бюджет йөкләмәсе 105,8 процентка үтәлде).

Сервитутны билгеләү турындагы килешүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына 3,6 млн сум акча керде (бюджет йөкләмәсе 105,6 процентка үтәлде).

2019 елда җирле бюджетлар керемнәре структурасында иң зур чагыштырма авырлыкка җир кишәрлекләрен арендалаудан керемнәр (2 438,6 млн сум) һәм аларны сатудан керемнәр (1 044 млн сум) булды.

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары карамагындагы җирләрне һәм муниципаль мөлкәтне файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, 2019 елда өч еллык чор өчен салым булмаган керемнәрне һәр объект буенча аерым планлаштыру гамәлгә ашырылды, ай саен республика муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелгән шартнамәләр буенча җир кишәрлекләрен һәм мөлкәтне арендалау өчен түләү буенча бурычларга һәм керүләргә мониторинг үткәрелде.

2019 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары алдында мөлкәт һәм җир кишәрлекләре өчен аренда түләве буенча бурычларны киметү мәсьәләсе актуаль булды.

2020 елның 1 гыйнварына җирләрне арендалау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасының җирле бюджетлары алдында бурыч суммасы 345,7 млн сум тәшкил итте (2019 ел дәвамында бурыч 14,3 млн сумга артты).

Шул ук вакытта Татарстан Республикасының түбәндәге 23 муниципаль берәмлегендә бурычлар барлыкка килде: Әгерҗе, Арча, Аксубай, Алексеевск, Әлки, Апас, Әтнә, Балтач, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Кама Тамагы, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Яңа Чишмә, Нурлат, Балык Бистәсе, Теләче, Чирмешән, Чистай, Ютазы муниципаль районнарында, Чаллы шәһәрендә.

Ел дәвамында җирләрне арендалау буенча бурычлар суммасын республиканың 18 муниципаль берәмлеге кыскартуга йә бетерүгә иреште. Республиканың 2 муниципаль районында (Биектау һәм Саба) бурычлар юк. Республиканың Алабуга һәм Кайбыч муниципаль районнарында бурычлар 2018 ел башы дәрәҗәсендә сакланды.

*Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территориаль планлаштыру документлары*

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы буенча кадастр исәбенә 153 муниципаль берәмлек составына керүче торак пунктларның чикләре куелган

(республикада, шәһәр һәм авыл җирлекләрен исәпкә алып, барлыгы 913 муниципаль берәмлек).

Төрле башкаручыларда 348 җирлекнең генераль планнары эшләнә, аларны кабул итү 1 198 торак пунктның чикләрен исәпкә куюны тәэмин итәчәк.

2020 ел ахырына кадәр тагын 412 җирлекнең генераль планнарын эшләү һәм 1 326 торак пунктның чикләрен кадастр исәбенә кую планлаштырыла.

Татарстан Республикасы милкенә сатып алуның өстенлекле хокукын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләре сатып алынмады.

2019 елда муниципаль милеккә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән Татарстан Республикасының Чүпрәле муниципаль районы тарафыннан 9,4 гектар мәйданлы 3 җир кишәрлеге сатып алынды.

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне нәтиҗәсез файдалану иң кискен проблемаларның берсе булып калу дәвам итә. Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге 43 мең гектардан артык файдаланылмый торган җирләр булу ачыкланды, шуларның 7,9 мең гектары авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертелде.

*Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү*

2019 елда җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү буенча эш дәвам ителде. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан әзерләнгән документлар нигезендә 2019 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Казан шәһәре территориясендә 163,95 гектар гомуми мәйданлы 4 җир кишәрлеген Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү турында 3 боерыгы кабул ителде.

*Күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү һәм «ДОМ.РФ» акционер җәмгыяте белән хезмәттәшлек итү*

Татарстан Республикасында җир кишәрлекләрен булдыру һәм аларны күпбалалы гаиләләргә бирү эше дәвам итә.

Ана капиталы белән беррәттән, җир кишәрлеген бушлай алу мөмкинлеге бик күп гаиләләр өчен зур кызыксындыру чарасы булып тора һәм, һичшиксез, гаилә институтын үстерүгә һәм туучылар санын арттыруга этәргеч бирә.

Җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча, 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында 60,3 меңнән артык гаилә исәпләнә, шулардан 55,1 мең гаилә җир кишәрлекләре алу исемлегенә кертелде. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә, күпбалалы гражданнарга җир кишәрлекләре бирү процессын оештыру буенча эш алып барыла. Нәтиҗәдә, 35,17 мең күпбалалы гаилә җир кишәрлекләрен милеккә алды.

Республиканың «ДОМ.РФ» акционер җәмгыяте белән Россия Федерациясе милкендәге җир кишәрлекләренә карата хезмәттәшлек итүе дәвам ителә.

Үзара хезмәттәшлек нәтиҗәсендә Торак төзелешен үстерү һәм Россия Федерациясе милкендәге җир кишәрлекләрен файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү буенча хөкүмәт комиссиясенең (алга таба – Хөкүмәт комиссиясе) Казан шәһәренең күпбалалы гаиләләренә алга таба бирү өчен җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм алар белән эш итү буенча вәкаләтләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшыру турындагы түбәндәге карарлары кабул ителде:

2014 елның 30 сентябрендәге 8 номерлы – 190 гектар (Биектау муниципаль районы һәм Казан шәһәре янындагы) һәм 117,8 гектар (Константиновка поселогы);

2015 елның 31 мартындагы 3 номерлы – 331,5 гектар (Биектау муниципаль районы).

639,4 гектар гомуми мәйданлы җир кишәрлекләреннән (521,5 гектары – Биектау муниципаль районы һәм Казан шәһәре янындагы, 117,8 гектары – Константиновка поселогында) Казан шәһәренең күпбалалы гаиләләренә бирү өчен 2 500дән артык кишәрлек булдыру планлаштырылды, факта 2 360 җир кишәрлеге булдырылды, калган кишәрлекләр буенча кадастр исәбенә кую өчен кирәкле чаралар гамәлгә ашырыла. Булдырылган кишәрлекләрдән 803есе буенча аларны күпбалалы гаиләләргә бирү турында карарлар кабул ителде. Калган кишәрлекләр буенча чират нигезендә аларны күпбалалы гаиләләргә бирү эше дәвам итә.

Моннан тыш, 2019 ел ахырында Хөкүмәт комиссиясенең Казан шәһәренең күпбалалы гаиләләре өчен Биектау муниципаль районында 963,6 гектар мәйданлы өстәмә массив бүлеп бирү турындагы карары кабул итте.

Хәзерге вакытта массивны әйләнешкә кертү буенча чаралар үткәрелә.

*Идарә итү һәм эш итү буенча вәкаләтләре Татарстан Республикасына тапшырылган Россия Федерациясе милкендәге җир кишәрлекләрен әйләнешкә кертү*

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан әйләнешкә кертү өчен идарә итү һәм эш итү буенча вәкаләтләре Татарстан Республикасына тапшырылган федераль милектәге җир кишәрлекләре буенча «ДОМ.РФ» акционер җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек дәвам ителә.

2019 елда социаль инфраструктура объектларын (хоспис һәм балалар онкология үзәге) булдыру өчен Казан шәһәре, Оренбург тракты урамы адресы буенча урнашкан 3 гектар һәм 1,76 гектар мәйданлы җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләре Татарстан Республикасына тапшырылды.

2019 елда Татарстан Республикасына шулай ук территорияне комплекслы үзләштерү өчен Казан шәһәре, Аграр урамы адресы буенча урнашкан 1,21 гектар мәйданлы җир кишәрлеге белән идарә итү һәм эш итү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләре тапшырылды, аның кысаларында шул исәптән акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган өлешле төзелештә катнашучы – зыян күрүче гражданнарның (мондый гражданнар реестрына кертелгән) проблемаларын хәл итү максатларында торак төзелеше күздә тотыла.

*Җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге категориядән төзелеш өчен яраклы категориягә күчерү юлы белән аларны бирүдә, шул исәптән эшкуарлык субъектларына бирүдә ярдәм күрсәтү*

2019 елда республикада инвестицион климатны яхшырту максатларында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан сәнәгать һәм башка объектлар төзү өчен җир кишәрлекләре категориясен үзгәртү буенча эш дәвам ителде.

Хисап елында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1 602,6 гектар гомуми мәйданлы 855 җир кишәрлеген күчерү турында 147 карары кабул ителде.

*Татарстан Республикасы милкенең җир кишәрлекләренә хокукын дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итү*

2019 елда Татарстан Республикасы милкенә хокукларны дәүләт теркәве алу башкарылды һәм 212,3 гектар мәйданлы 136 җир кишәрлеге Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертелде.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы милкендә булган 652,8 гектардан артыграк гомуми мәйданлы 163 җир кишәрлеге даими (чикләнмәгән вакытта) файдалануга һәм түләүсез файдалануга бирелде. Муниципаль милеккә 45,5 гектардан артыграк гомуми мәйданлы 29 җир кишәрлеге тапшырылды.

*Җир ресурсларын саклау*

Татарстан Республикасы җир ресурсларын саклау өстенлекле бурычларның берсе булып тора. Деградацияләнгән җирләр барлыгын исәпкә алып, туфракларны җимерелүдән һәм ярлыланудан саклауга юнәлдерелгән чараларга аерым игътибар бирелә.

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең, җир өсте су объектларының туфракларын саклау, республика территориясенең экологик иминлеген тәэмин итү максатларында ел саен саклый торган урман утыртмаларын булдыру буенча эш алып барыла.

2019 елда саклый торган урман утыртмалары 2 415 гектар мәйданда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге эрозия куркынычы булган җирләрдә булдырылды.

Хәзерге дөньяда сәнәгать җитештерүе үсеше углеводород чималын чыгару һәм куллану артуга бәйле рәвештә алып барыла, бу туфрак катламы, җирлекнең гидрологик режимы бозылуга, техноген рельеф барлыкка килүгә һәм җир торышының сыйфаты ягыннан башка үзгәрешләренә китерә.

Шулай итеп, бозылган җирләрнең продуктлылыгын торгызуга юнәлдерелгән иң мөһим чараларның берсе – ул деградацияләнгән җирләрне рекультивацияләү.

Татарстан Республикасының җирле бюджетлары акчасы исәбеннән карьерларны түбәндәге күләмнәрдә рекультивацияләү чаралары финансланды:

2015 елда – 729,6 мең сумга 10 муниципаль берәмлеккә;

2016 елда – 11 395,6 мең сумга 17 муниципаль берәмлеккә;

2017 елда – 23 498 мең сумга 17 муниципаль берәмлеккә;

2018 елда – 5 078,6 мең сумга 8 муниципаль берәмлеккә;

2019 елда – 6 224,2 мең сумга 11 муниципаль берәмлектә.

*Су объектларын саклау*

Татарстан Республикасы Идел буе федераль округының иң күп сулы төбәкләренең берсе булып тора, республиканың барлык территориясенең якынча 6,4 проценты су белән капланган, 36 меңнән артык су объекты бар. Республикада 4 меңгә якын кече һәм урта елга исәпләнә, аларны саклауга һәм рациональ куллануга аеруча зур игътибар бирелә.

Су объектлары турында мәгълүматларны Дәүләт су реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү максатларында ел саен яр буе линияләре урнашу урынын билгеләү буенча эшләр башкарыла. Хәзерге вакытта яр буе линияләренең гомуми озынлыгы 11 840,16 км булган 137 су объектының чикләре билгеләнде. Шуның белән бергә, су саклау зоналарын урнаштыруны таләп итә торган яр буе линиясенең гомуми озынлыгы 42 914 км тәшкил итә.

2019 елда федераль бюджет субвенцияләре исәбеннән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан 12 су объектының яр буе линияләре (су объекты чикләре), су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклау полосалары чикләре урнашу урынын билгеләү буенча эшләр башкарылды.

2019 елда Федераль су ресурслары агентлыгында 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының су хуҗалыгы һәм су саклау чараларын федераль бюджет акчасыннан финанслауга, шул исәптән 2020 елда Татарстан Республикасының Казан шәһәрендә, Югары Ослан, Зеленодольск, Буа, Тәтеш, Кайбыч муниципаль районнарында урнашкан 48 су объектының яр буе линияләре, су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклау полосалары чикләре урнашу урыннарын билгеләү буенча чаралар үткәрүгә бюджет проектлары якланды.

2019 елда эш нәтиҗәләре буенча Дәүләт су реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан 6 су объектының (Әгерҗе елгасы, Урсалы елгасы, Бола елгасы, Дала Зәе елгасы, Шишма елгасы һәм Зур Чирмешән елгасы) су бастыру, су басу зоналары чикләре турындагы мәгълүматлар кертелде.

*Табигать-тыюлык фондын үстерү*

2019 елда табигать-тыюлык фондын үстерү максатларында түбәндәгеләр оештырылды:

Арча, Биектау һәм Зеленодольск муниципаль районнарында тайга табигать комплексын саклау һәм торгызу максатларында 10 715 гектар мәйданлы төбәк әһәмиятендәге «Шорский» дәүләт табигать зоология тыюлыгы;

Мамадыш муниципаль районында биологик төрлелекне саклап калу, шулай ук Нократ елгасы үзәннәрендә кыр үрдәкләре санын максатчан торгызу максатларында 1 380,72 гектар мәйданлы төбәк әһәмиятендәге «Нократ» дәүләт табигать зоология тыюлыгы;

Нурлат муниципаль районында биологик төрлелекне саклап калу, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау, уникаль ландшафт комплексларын саклап калу максатларында 2 344 гектар

мәйданлы төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле «Чирмешән» дәүләт табигать зоология тыюлыгы;

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә уникаль күл комплексын саклап калу, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су янындагы төрләрен саклау максатларында 2 гектар мәйданлы «Черек күл» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле;

Югары Ослан, Зеленодольск, Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территорияләрендә Идел елгасының уникаль ландшафтлы комплексларын саклап калу, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су янындагы төрләрен саклау максаты белән 29 076 гектар мәйданлы төбәк әһәмиятендәге «Волжские просторы» дәүләт табигать тыюлыгы.

Уникаль табигать ландшафтларын һәм үсемлекләрнең һәм хайваннарның кыйммәтле төрләрен саклап калу максатларында аеруча саклана торган табигать территорияләре мәйданын арттыру буенча эш дәвам итә. Хәзерге вакытта 3 аеруча саклана торган табигать территориясен (Сокольский утравы, Покш Пандо, Мәнәвез Үзәне), 2 аеруча саклана торган табигать территориясен (Кама-Ык тыюлыгы, Агыйдел елгасы Дельтасы) булдыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты эшләнде, алар Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгына килештерүгә җибәрелде.

**Әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметү**

***«Экология» илкүләм проекты***

2019 елда Татарстан Республикасына «Экология» милли проектының 3 федераль проекты чараларын тормышка ашыру өчен 1 797,7 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан 1 479,3 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән:

«Идел елгасына чыгарыла торган пычрак агызыла торган сулар өлешен киметү» юнәлеше буенча «Иделне савыктыру» – 1 647,6 млн сум, шулардан федераль бюджеттан – 1 334,6 млн сум (8 объект). Әлеге акча кысаларында республиканың 7 муниципаль районында 7 чистарту корылмасын һәм 1 яңгыр сулары канализациясен төзү һәм реконструкцияләү гамәлгә ашырыла. Объектларны файдалануга тапшыру 2020 елның 1 июненнән дә соңга калмыйча башкарылачак. 2019 елга 0,19 дәрәҗәсендә билгеләнгән «Идел елгасына чыгарыла торган пычрак агызыла торган сулар күләмен киметү, км$^3$» күрсәткече 100 процентка үтәлде;

«Чиста су» – 28,48 млн сум, шулардан федераль бюджеттан – 23,07 млн сум (1 объект). Әлеге акча кысаларында Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә су алу җайланмасы реконструкцияләнде, объект файдалануга тапшырылды.

«Урманнарны саклау» – 121,6 млн сум. Проектның максаты – 2024 елга карата 100 процент дәрәҗәсендә урманнарны чыгару һәм яңадан торгызу балансын тәэмин итү. Төбәк проекты кысаларында түбәндәге чаралар тормышка ашырылды: урман орлыклары запасын формалаштыру, урманнарны яңадан торгызу һәм урман үрчетүне тәэмин итү, учреждениеләрне урман янгыннарын сүндерү техникасы һәм

җайланмалары белән (117 берәмлек), шулай ук урман-культура техникасы һәм җиһазлары белән тәэмин итү (16 берәмлек).

Әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметү максатларында Татарстан Республикасы урман фонды территориясендә урманнарны торгызу чаралары түбәндәге күләмнәрдә үткәрелде: 2 514 гектарда урман торгызу, шул исәптән 1 768 гектарда урман культуралары утырту, 168 гектарда урман үрчетү, 542 гектарда табигый яңарышка ярдәм итү, 36 гектарда катнаш урман торгызу.

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә 2 490,1 гектар мәйданда саклый торган утыртмалар булдырылды (шул исәптән басу саклау утыртмалары – 34 гектарда, чокыр-балка утыртмалары – 1 772,1 гектарда, террасалау юлы белән чокыр-балка утыртмалары – 684 гектарда).

Урманнарның санитария торышын бәяләү максатыннан, 45 мең гектардан артыграк мәйданда урман утыртмаларына урман патологиясе буенча тикшерү үткәрелде. Зарарлы организмнар үзәкләре мәйданы, 2018 ел белән чагыштырганда, 49 процентка кимеде (бу урман патологиясе киеренкелегенең кимүен күрсәтә).

Үзенчәлеге ягыннан яхшы булган агачларны кисү, яңарту һәм үзгәртеп формалаштыру, ачыклау өлкәсендә, шулай ук урман кишәрлекләрен үзләштергәндә төп биотопларны билгеләү өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләре үткәрелде.

336 мең гектардан артык мәйданда (урман фонды мәйданының 27 процентында) кадастр исәбенә алу башкарылды.

Дистанцион зондлаштыру мәгълүматлары нигезендә Урман фонды торышын мониторинглау буенча геомәгълүмат системасын һәм сервисын кертү башланды.

«Каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасын формалаштыру» – 2019 елда Татарстан Республикасы өчен федераль бюджеттан акча бүлеп бирелмәде. Татарстан Республикасында калдыклар белән эш итү өлкәсендәге территориаль схема Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 13 мартындагы 149 номерлы карары белән расланды, 2019 елда аңа үзгәрешләр кертелде.

«Биологик төрлелекне саклау һәм экологик туризмны үстерү» – 2019 елда Татарстан Республикасы өчен федераль бюджеттан акча бүлеп бирелмәде.

*Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең территориаль системасын үстерү*

Хәзерге вакытта әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең территориаль системасы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә атмосфера һавасы пычрануны тикшерүдә тотуның 16 автомат станциясеннән торган атмосфера һавасы пычрануны күзәтү челтәре булдырылды: Казан шәһәрендә – 4, Чаллы шәһәрендә – 2, Түбән Кама шәһәрендә – 4, Алабуга шәһәрендә – 1, Азнакай шәһәрендә – 1, Менделеевск шәһәрендә – 1, Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогында һәм Кәләй авылында – 2, Түбән Кама муниципаль районының Олы Афанас авылында – 1.

Әйләнә-тирә мохитнең күбрәк пычрануы фактларына оператив чара күрү, атмосфера һавасы пычрануның ихтимал чыганагын билгеләү өчен приборлар комплексы белән (әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең автоматлаштырылган системасындагы приборлар комплексына охшаш) җиһазландырылган 6 күчмә

экологик лаборатория кулланыла: Казан шәһәрендә – 2, Чаллы шәһәрендә – 1, Түбән Кама шәһәрендә – 1, Әлмәт шәһәрендә – 1, Азнакай шәһәрендә – 1.

2019 елда экологик иминлекне тәэмин итү максатларында Кәләй авылында һәм Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогында урнашкан әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең автоматлаштырылган системасы, шулай ук Алабуга шәһәрендә урнашкан һәм «Алабуга» махсус икътисадый зонасында урнашкан әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең автоматлаштырылган системасы өстәмә җиһазландырылды. Күрсәтелгән чаралар кысаларында, әлеге районнарның сәнәгать предприятиеләре өчен хас булган атмосферага чыгаруларны исәпкә алып, автоматик режимда контрольдә тотыла торган пычраткыч матдәләр исемлеге арттырылды.

Су объектларын мониторинглауны оештыруда һәм тормышка ашыруда катнашу буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру максатларында, Федераль су ресурслары агентлыгының территориаль органы (Түбән Идел бассейны су идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге) белән килештерелгән Татарстан Республикасының җир өстендәге су объектлары дәүләт мониторингының территориаль күзәтчелек челтәре пунктларында күзәтүләр программасы нигезендә махсус аналитик контроль инспекцияләре тарафыннан республиканың 37 су объектының, шул исәптән 27 елның, 7 буаның, 1 карьерның, 2 күлнең гидрохимик торышына (пычрану дәрәҗәсенә) ай саен күзәтүләр (барлыгы 71 күзәтү пункты) алып барыла.

*Атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисаплар системасын үстерү*

Атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисапларын куллану билгеле бер территориядә эшли торган барлык стационар чыгарулар (сәнәгать предприятиеләре чыгарулар да, автотранспорт агымнары чыгарулар да) чыганакларының атмосфера һавасына җыелма йогынтысын объектив бәяләргә мөмкинлек бирә торган бердәнбер алым булып тора.

Республикада булдырылган атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисаплар системалары түбәндәгеләр өлешендә атмосфера һавасының сыйфаты белән идарә итүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирде:

1) Казан шәһәре 2013 елгы Универсиаданы үткәрүгә әзерләү өлешендә, атмосфера һавасына иң зур йогынты ясаучы предприятиеләр исемлеген эшләүне һәм алар өчен һава саклау чаралары комплексын эшләүне дә кертеп; бу шәһәрдә шактый санда сәнәгать җитештерүләре булганда да 2013 елгы Универсиада чараларын иң югары дәрәҗәдә үткәрергә мөмкинлек бирде.

Эшләнгән уңай тәҗрибә Казан шәһәрен 2015 елда спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатын, 2017 елда Футбол буенча конфедерацияләр кубогын һәм 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын уздыруга әзерләгәндә дә гамәлгә ашырылды;

2) атмосфераны пычрату чыганагы булган объектларны пычрану дәрәҗәсе билгеләнгән гигиена нормативларыннан артып киткән территорияләрдә проектлаштыруны һәм урнаштыруны тыюга кагылышлы мәсьәләләр буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләрен һәм Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 27 декабрендәге

1071 нче карары белән расланган территориаль планлаштыру документларын әзерләү өлешендә.

Казан шәһәренең генераль планын әзерләгәндә шәһәр атмосферасы пычрануның җыелма исәп-хисаплары нәтиҗәләре файдаланылды;

3) эше атмосфера һавасының сыйфаты начараюга китерә торган билгеле бер атмосфера пычрату чыганакларын билгеләү (идентификацияләү) һәм һава саклау законнарын бозучыларга карата кисәтү чаралары гамәлгә ашыру өлешендә. Мәсәлән, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан кулланыла торган административ йогынты чаралары билгеле бер чыгарулар чыганакларын билгеләүгә юнәлдерелгән атмосфера пычрануның җыелма исәп-хисаплары нәтиҗәләренә нигезләнә, аларның эше теркәлгән метеошартларда Казан һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге торак зоналары территориясендә атмосфера һавасының сыйфаты канәгатьсез булуына сәбәп булды;

4) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе өчен шәһәрләрдә атмосфера һавасының тиешле сыйфатын тәэмин итү өчен автотранспорт чаралары хәрәкәтен чикләү буенча тәкъдимнәр әзерләү өлешендә;

5) начар метеорологик шартлар булганда атмосфера һавасына чыгаруларны киметүне тәэмин итәргә тиешле предприятиеләрнең нигезле исемлеген әзерләү, шулай ук начар метеорологик шартлар булганда чыгаруларны киметүне тикшерүдә тоту режимнарын эшләү өлешендә. Үткәрелгән исәп-хисап нигезендә начар метеорологик шартлар булганда атмосфера һавасына чыгаруларны киметүне тәэмин итәргә тиешле предприятиеләр исемлеге арттырылды, шулай ук начар метеорологик шартлар булганда беренче чиратта контрольгә алынырга тиешле пычраткыч матдәләр исемлеге һәм шәһәр территорияләре билгеләнде;

6) Татарстан Республикасы Хөкүмәте – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түбән Кама шәһәрендә һәм Түбән Кама муниципаль районында атмосфера һавасына антропоген йөкләнешне киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2016 елның 9 ноябрендәге 828 номерлы тиешле карарын кабул итеп, Түбән Кама шәһәрендә һәм Түбән Кама муниципаль районында атмосфера һавасына тискәре йогынты ясый торган гамәлдәге җитештерүләрне арттыру яки яңа җитештерүләр булдыру мөмкинлеген анализлау өлешендә.

Хәзерге вакытта Түбән Кама сәнәгать узелының түбәндәге предприятиеләре буенча җитештерүләрне: «ТАИФ-НК» акционер җәмгыяте, «Нижнекамскнефтехим» гавами акционер җәмгыяте, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте, «Түбән Кама җылылык-электр централе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Саф-Пэт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Питон-Кама» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Сәнәгать паркы идарә итүче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, Индивидуаль эшкуар Зәйдуллин, Индивидуаль эшкуар Зиннәтова, «Симпл» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Промтранс-НК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте; шулай ук «Алабуга-2. Нефть химиясе» индустриаль паркын планлаштыру проекты белән төзелеше планлаштырылган объектларны арттыру һәм яңа җитештерүләр булдыру мөмкинлегенә бәя бирелде. «ТАИФ-НК» акционер җәмгыяте, «Түбән Кама нефть

химиясе» гавами акционер җәмгыяте тарафыннан башкарылган эшләр предприятиеләрнең атмосфера һавасына чыгаруларны киметү планын әзерләвен тәэмин итте;

7) предприятиеләрнең атмосфера һавасына йогынтысын минимальләштерү максатларында кулланыла торган материаллар, чимал, ягулыкның технологик процесслары үзгәрү мөмкинлегенә анализ үткәрү өлешендә. Атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисаплар системасы нигезендә Түбән Каманың ике җылылык-электр централендә мазутны төп ягулык сыйфатында кулланырга ярамаганлыгы нигезләнде, бу әлеге җылылык-электр центральләренең табигый газны ягулыкның аеруча экологик төре буларак кулланып кына эшләве кирәклеген якларга мөмкинлек бирде.

2019 елда «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын яңадан торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасының «2014–2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» ярдәмче программасы чараларын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 28 декабрендәге 1083 номерлы карары белән расланган) тормышка ашыру кысаларында Казан һәм Түбән Кама шәһәрләре өчен чыгаруларның стационар һәм күчмә чыганаклары буенча җыелма мәгълүматлар базасын актуальләштерү буенча эшләр башкарылды.

Хәзерге вакытта Алабуга шәһәре («Алабуга» махсус икътисадый зонасы территориясен кертеп) өчен атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисаплар системасын булдыру буенча эшләр оештырылды.

*Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохите компонентларының төбәк үзенчәлекләрен исәпкә ала торган әйләнә-тирә мохит сыйфатының төбәк нормативларын эшләү һәм Татарстан Республикасында файдалануга кертү*

Россия Федерациясе субъектларына әйләнә-тирә мохит сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү буенча вәкаләтләр бирүгә, «Вәкаләтләрне чикләүне камилләштерү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2005 елның 31 декабрендәге 199-ФЗ номерлы Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә, 2006 елдан Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохит сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү функциясе гамәлгә ашырыла.

Моннан тыш, Татарстан Республикасында нефть чыгару, транспортлау, саклау һәм эшкәртү белән бәйле рәвештә күп санда эшләр башкаруны исәпкә алып, 2006 елдан башлап, республикада рекультивация эшләренең сыйфатын объектив бәяләү, рекультивацияләү чыгымнарын оптимальләштерү, территорияләрнең экологик хәлен яхшырту өчен кирәкле рекультивацияләү һәм башка торгызу эшләре башкарылганнан соң туфракта нефть һәм аның трансформацияләү продуктларының рөхсәт ителгән калдык микъдарының төбәк нормативларын раслау буенча эшләрне оештыру тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы туфракларының түбәндәге типлары һәм астиплары өчен нефтьнең һәм продуктларның рөхсәт ителгән калдык микъдары нормативлары эшләнде һәм гамәлгә кертелде:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләренә караган көрән һәм аксыл көрән урман туфраклары өчен;

урман фонды җирләренә караган Татарстан Республикасының көлсуланган кара туфраклары, кәзле-көлсу, аксыл көрән урман, көрән урман һәм карасу көрән урман, кәзле-карбонатлы селтесезләнгән, кәзле-карбонатлы көлсуланган туфраклары өчен;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган Татарстан Республикасының көлсуланган кара туфраклары, типик кара туфраклары, кәзле-көлсу, карасу көрән урман, кәзле-карбонатлы селтесезләнгән, кәзле-карбонатлы көлсуланган туфраклары өчен;

аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләренә караган Татарстан Республикасының аксыл көрән урман һәм көрән урман туфраклары өчен;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, урман фонды, аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләре өчен аксыл көрән урман, көрән урман, карасу көрән урман җиңел һәм уртача балчыксыл туфраклар өчен;

урман фонды җирләренең типик авыр балчыксыл һәм үзле кара туфраклары өчен;

аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләренә караган көлсуланган кара туфраклар, типик кара туфраклар, карасу көрән урман туфраклары, кәзле-карбонатлы көлсуланган, кәзле-карбонатлы селтесезләнгән, кәзле-көлсу авыр балчыксыл һәм үзле туфраклар өчен.

Әлеге нормативларны гамәлгә кертү республиканың туфрак катламы структурасында, шул исәптән интенсив нефть чыгару, нефть һәм нефть продуктларын транспортировкалау районнарында зур мәйданнарны биләгән калдык нефть продуктлары микъдары булган туфракларны рекультивацияләү эшләрен башкарганда турыдан-туры һәм өстәмә барлыкка килә торган экологик зыянны киметергә мөмкинлек бирде.

Татарстан Республикасында расланган нефть һәм продуктларның рөхсәт ителгән калдык микъдары нормативларын исәпкә алу федераль дәрәҗәдәге һәм төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экологик күзәтчелеген үткәргәндә тәэмин ителә, шулай ук «Татнефть» гавами акционер җәмгыятендә бозылган җирләрне рекультивацияләү буенча эшләрнең үтәлешен җайга сала торган документлар белән каралды.

Республикада әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты буенча төбәк нормативларын кабул итү юнәлешендә үткәрелә торган эшләрне алып бару йөзеннән Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы туфракларының төп типларында авыр металлар (Cd, Pb, Co, Cu, Ni, Zn, Cr, Mn, Fe) фоны булуның төбәк нормативларын әзерләү оештырылды.

Гамәлгә кертелгән «Татарстан Республикасы туфракларында авыр металлар фоны булу» төбәк нормативлары антропоген йогынты ясау аркасында туфракларга салынган зыян күләмен исәпләгәндә кулланыла.

2019 елда «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру

кысаларында Татарстан Республикасы су объектларының су төбендәге утырмаларда нефть продуктлары фоны булуның төбәк нормативларын эшләү буенча эшләр башкарылды.

Шулай ук 2019 елда Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, урман фонды, аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләре өчен аксыл көрән урман, көрән урман, карасу көрән урман җиңел һәм уртача балчыксыл туфраклар өчен; урман фонды җирләренең типик авыр балчыксыл һәм үзле кара туфраклары өчен; аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләренә караган көлсуланган кара туфраклар, типик кара туфраклар, карасу көрән урман туфраклары, кәзле-карбонатлы көлсуланган, кәзле-карбонатлы селтесезләнгән, кәзле-көлсу авыр балчыксыл һәм үзле туфраклар өчен нефтьнең һәм продуктларның рөхсәт ителгән калдык микъдарының төбәк нормативлары эшләнде.


Әйләнә-тирә мохит сыйфатының әлеге төбәк нормативлары 2020 елның I кварталында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә кертеләчәк.

## ФИНАНС КАПИТАЛЫ ҺӘМ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР

### Финанс ресурсларын файдалануның нәтиҗәлелеге

2019 елда Татарстан Республикасы бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәр 249,5 млрд сумга, яки план күрсәткечләренең 103,1 проценты мобилизацияләнде, бу 2018 ел күрсәткечләреннән 14,3 млрд сумга артыграк тәшкил итте. Федераль бюджеттан һәм башка чыганаклардан республикага 39 млрд сум акча җәлеп ителде.

**2019 елда Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре структурасы**




Бюджет керемнәрен арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 апрелендәге 687-б номерлы боерыгы кысаларында республикада Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үз керемнәре артуны тәэмин итү буенча ведомствоара комиссия даими нигездә эшли. 2019 елда комиссиянең эше расланган эш планы кысаларында башкарылды. Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре арту буенча чаралар түбәндәге юнәлешләрдә үткәрелде:

табышка салым буенча – ай саен табышка салым керү мониторингы үткәрелде, аның нәтиҗәсендә узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда түләүләрне киметкән оешмалар ачыкланды. Мондый оешмалар исемлеге квартал саен баланс комиссияләре эше кысаларында кирәкле чаралар үткәрү өчен җаваплы тармак министрлыкларына җиткерелде, аларда 2018 ел белән чагыштырганда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына салымнар керүнең кимү сәбәпләре анализланды. Уртак эш нәтиҗәләре буенча тармак министрлыклары тарафыннан ведомство буйсынуындагы оешмалар җитештерүенең рентабельлегенә

ирешү һәм аларны табышлы дәрәҗәгә чыгару, шулай ук бюджетка түләүләр буенча үз вакытында түләнмәгән бурычларны киметү буенча тәкъдимнәр эшләнде;

физик затлар кеременә салым буенча – «күләгәдәге» эш хакын легальләштерү, «конвертлы» түләүләрне һәм физик затлар керемнәренә салым түләүдән читкә китүнең башка схемаларын ачыклау буенча чаралар үткәрелде, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр хезмәткәрләренә эш хакын федераль законнар белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән ким булмаган күләмнәрдә түләүне тикшерүдә тоту гамәлгә ашырылды, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда физик затлар керемнәренә салым керүне киметкән салым түләүчеләр мониторингы үткәрелде;

акцизлар буенча – төп акциз алынырга тиешле продукция җитештерүчеләр белән продукция җитештерү һәм сату күләмнәрен мониторинглау һәм план максатларына ирешү буенча даими эш алып барылды;

физик затлар мөлкәтенә салым – милек салымнары керүләренең тулылыгын тәэмин итү буенча чаралар үткәрелде. Алар кысаларында салымнарны закон нигезендә билгеләнгән вакытларда түләү, салым түләүчеләргә – физик затларга салым турындагы хәбәрнамәләрне вакытында тапшыру, кредит оешмалары һәм почта бүлекләре белән физик затлардан түләүләрне өзлексез кабул итү, эш һәм ял көннәрендә эш режимын озайту эшләрен алып бару буенча республиканың эре предприятиеләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль структуралары, муниципалитетлар белән үзара хезмәттәшлек гамәлгә ашырылды, шулай ук массакүләм мәгълүмати кампания, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында эш алып барылды,

салым булмаган керемнәр буенча – Татарстан Республикасы бюджетына һәм муниципаль район һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларына агымдагы керүләргә анализ ясалды һәм фаразлана торган керүләргә бәя бирелде, керемнәр базасын арттыру һәм түләүләр буенча бурычларны киметү максатларында салым булмаган керемнәрнең администраторлары белән уртак эш гамәлгә ашырылды;

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны киметү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 июлендәге б-1493 номерлы боерыгы белән төзелгән Ведомствоара комиссия (штаб) эше кысаларында түбәндәге төп юнәлешләр буенча чаралар гамәлгә ашырылды: атна саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы киңәшмәләрендә Федераль суд приставлары хезмәте идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре катнашында муниципаль берәмлекләрдәге ведомствоара комиссияләрнең эш нәтиҗәләре видеоконференция режимында карап тикшерелде; икътисадый эшчәнлек төрләре буенча оешмалар, шул исәптән эре салым түләүчеләр белән эшләр алып барылды; регламентлар кысаларында дәүләт сатып алуларында катнашуга дәгъва итүче оешмаларның бурычларын булдырмау буенча эш башкарылды.

Шулай итеп, 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетының баланслылыгын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү максатларында бюджетның керем базасын арттыру буенча системалы эш алып барылды.

Шулай ук табышка салым һәм оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым ташламалары бирү өлешендә дәүләт ярдәменә дәгъва итүче инвестиция эшчәнлеге субъектларының инвестиция проектларына; социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резидентлары составына керүгә дәгъва итүче оешмаларның инвестиция проектларына; инвестиция салым кредитын алуга гариза бирүче оешмаларның инвестиция проектларына; җир кишәрлеген, торглар үткәрмичә, арендага бирүгә дәгъва итүче оешмаларның инвестиция проектларына экспертиза үткәрү эше гамәлгә ашырылды.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның торышы турында хисаплар әзерләнде. Шулай ук инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында тиешле шартнамәләр гамәлдә булган чор дәвамында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнар һәм җыемнар түләүне ел саен тәэмин итү буенча йөкләмә үтәлешенә еллык бәя бирелде.

Татарстан Республикасы икътисады һәм берләштерелгән бюджеты өчен кабул ителә торган үзгәрешләрнең ихтимал булган нәтиҗәләрен тиз арада билгеләү максатларында федераль законнар проектлары белән эшләү даими нигездә алып барылды. Шулай итеп, 2019 елда салымнар һәм җыемнар турындагы законнарга үзгәрешләр кертү буенча закон чыгару инициативаларына 50дән артык бәяләмә әзерләнде.

Татарстан Республикасының салым законнарын камилләштерү буенча закон чыгару эше даими нигездә алып барылды. 2019 елда салымнар һәм җыемнар буенча, шул исәптән салым салуның гадиләштерелгән системасы, мөлкәткә салым һәм транспорт салымы буенча, этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә федераль законнарны камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү буенча 4 закон проекты әзерләнде.

2019 елда Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 274,8 млрд сум күләмендә гамәлгә ашырылды, шулардан иң зурлары: мәгарифкә – 68 млрд сум, социаль сәясәткә – 39,5 млрд сум, сәламәтлек саклауга – 25,2 млрд сум, юл хуҗалыгына – 33,9 млрд сум, авыл хуҗалыгына – 15,7 млрд сум, мәдәнияткә – 10,2 млрд сум.

2019 елда эчке дәүләт финанс контроле вәкаләтләрен үтәү кысаларында 369 тикшерү чарасы үткәрелде. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә 271,9 млн сумлык бюджет акчаларын нәтиҗәсез файдалану ачыкланды. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрү өчен учреждениеләр җитәкчеләренә күрсәтмәләр җибәрелде, аларның йомгаклары буенча 87 процент җитешсезлекләр бетерелде. Прокурорлык эш итү чараларын күрү өчен тикшерүләр актлары Татарстан Республикасы прокуратурасына җибәрелде.

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы, «2012 – 2017елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру буенча кайбер чаралар турында» 2012 елның 28 декабрендәге 1688 номерлы указларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасында 2013 –

2018 елларда Татарстан Республикасы учреждениеләре хезмәткәрләренең аерым категорияләренең уртача эш хакы һәм төбәктә уртача эш хакы чагыштырмасы мәгънәләре динамикасын билгели торган тармак «юл карталары» расланды.

«Юл картасы» чаралары 2018 елда үтәлүгә карамастан, 2019 елда бюджет өлкәсендә эшләүче аерым категория хезмәткәрләрнең эш хакы дәрәҗәсе һәм республикадагы уртача эш хакы дәрәҗәсе арасында ирешелгән мөнәсәбәтләрне саклап калу турында карар кабул ителде. Шуңа бәйле рәвештә, республикада бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең эш хакы дәрәҗәсен мониторинглау буенча эш дәвам итә. 2019 ел йомгаклары буенча, якынча мәгълүматларга караганда, Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 26 февралендәге Пр-294 номерлы күрсәтмәсе нигезендә аерым категориядәге хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү күрсәткечләренә ирешү көтелә.

2019 елда эш хакын түләү өчен акчаларга ихтыяҗ 133 млрд сум тәшкил итте һәм тулысынча финанслау чыганаклары белән тәэмин ителде, шул исәптән республика берләштерелгән бюджеты акчасы исәбеннән – 123,7 млрд сум, бюджеттан тыш акча исәбеннән – 9,3 млрд сум.

Бюджет законнары кысаларында 2019 ел дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисаплар һәм мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм Федераль казначылыкка даими рәвештә тапшырылды.

2019 елда 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетын һәм Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру эше 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзегәндә әзерләнә торган закон проектларын, документларны һәм материалларны әзерләү һәм карап тикшерү графигы нигезендә алып барылды.

«2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законы 2019 елның 27 ноябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителде һәм 2019 елның 30 ноябрендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан имзаланды (92-ТРЗ номерлы).

Әлеге закон белән 31 дәүләт программасы буенча чыгымнар каралды.

2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының социаль-мәдәни өлкә тармаклары буенча чыгым өлешен формалаштырганда норматив нигезендә финанслау механизмы кулланылды.

2020 елга Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетын социаль-мәдәни өлкә тармаклары буенча формалаштыру өчен 2020 елга учреждениеләрне финанслау нормативларын раслый торган тиешле норматив хокукый актлар һәм Татарстан Республикасы законнары кабул ителде.

2019 елда Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабрендәге 1194 номерлы карары), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 29 декабрендәге 6-3165 номерлы боерыгы

белән расланган 2017 – 2019 еллар чорына Татарстан Республикасы керемнәрен арттыру, чыгымнарын оптимизацияләү һәм бурыч сәясәтен камилләштерү буенча чаралар планы белән күздә тотылган чараларны гамәлгә ашыру дәвам ителде.

2019 ел дәвамында гамәлдәге кабул ителгән йөкләмәләрне үтәү графиклары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бурычын исәпкә алу, рәсмиләштерү, үз вакытында каплау һәм аңа хезмәт күрсәтү мәсьәләләре белән бәйле булган чараларның тулы комплексы уздырылды. Бу эш кысаларында Татарстан Республикасының Дәүләт бурычы китабын алып бару, Россия Федерациясе Финанс министрлыгына кертү өчен хисап мәгълүматларын әзерләү башкарылды.

2019 ел дәвамында Татарстан Республикасының дәүләт бурычын киметү буенча чаралар планын үтәү тәэмин ителде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 14 гыйнварындагы б-10 номерлы боерыгы). Әлеге юнәлеш кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау максатларында коммерциячел бурыч алуларны гамәлгә ашыру мораториясе үтәлде.

2019 елда бюджет кытлыгын каплау һәм гамәлдәге йөкләмәләрне түләү, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаны тулыландыру өчен Татарстан Республикасы федераль бюджеттан яңа кредитлар алмады. Элегрәк реструктурлаштырылган бурычларны (2012 елның декабрендә, 2017 елның октябрендә һәм декабрендә) исәпкә алып, хәзерге вакытта федераль бюджеттан җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрнең барлык күләме озак вакытка исәпләнгән нигездә реструклаштырылды.

2019 елда дәүләт бурычы өлешендә йөкләмәләрне үтәү эше кысаларында федераль бюджет кредитларыннан файдаланган өчен процентларны үз вакытында һәм тулы күләмдә түләү гамәлгә ашырылды һәм төп бурычның бер өлеше расланган түләүләр графиклары нигезендә 286,6 млн сум күләмендә кайтарылды. Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлар юк.

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт бурычының гомуми күләме (дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрне исәпкә алып) 93,7 млрд сум тәшкил итте. Шул ук вакытта 2019 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы бюджетының бурыч йөкләнеше дәрәҗәсе 37,5 процент тәшкил итте, 2018 ел йомгаклары буенча 40,4 проценттан төште. Бу Татарстан Республикасы бюджетының керем базасын эзлекле рәвештә арттыруны тәэмин итү кысаларында башкарылган эшләрнең һәм дәүләтнең читтән акча җәлеп итүен гамәлгә ашыруга карата кулланылган консерватив алымның нәтиҗәсе булып тора.

2019 елда Татарстан Республикасының кредит рейтингы мәсьәләләре буенча халыкара һәм үз илебез рейтинг агентлыклары белән хезмәттәшлек итү эше дәвам ителде. «Fitch Ratigs Ltd» линиясе буенча Татарстан Республикасының кредит рейтингы бер баскычка күтәрелде, инвестиция категориясенә каравын һәм тулаем алганда Россия Федерациясе рейтингы дәрәҗәсендә торуын дәвам итә. Moody's Investors Service линиясе буенча Татарстан Республикасының кредит рейтингы шулай ук бер баскычка күтәрелде.

Моннан тыш 2019 елда Татарстан Республикасы үз илебезнең «АКРА» рейтинг агентлыгы белән Татарстан Республикасының кредит рейтингы милли шкала буенча бер баскычка күтәрелде һәм рейтингның максималь дәрәҗәсенә

ирешелде. «Эксперт РА» агентлыгы линиясе буенча Татарстан Республикасының кредит рейтингы милли шкала буенча шулай ук рейтингның максималь дәрәҗәсендә тора.

*Төбәк сәнәгатьне үстерү фонды*

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 26 апрелендәге 248 номерлы карары белән «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасына Төбәк сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләре бирелде.

Хәзерге вакытта Федераль сәнәгатьне үстерү фонды, Төбәк сәнәгатьне үстерү фонды белән берлектә, «Үсеш проектлары» һәм «Комплектлау әйберләре» программалары буенча инвестиция проектларын финанслый.

Федераль сәнәгатьне үстерү фонды программалары, төбәк фондлар белән берлектә, «Эшкәртү җитештерүләре» секторында сәнәгатьнең өстенлекле юнәлешләре буенча гамәлдгә ашырыла торган һәм һәркем файдалана алырлык иң яхшы технологияләр (шул исәптән база тармак технологияләре) принципларына туры килә торган өстенлекле технологияләрне эшләүгә һәм Татарстан Республикасы предприятиеләрендә гамәлгә кертүгә, импортны алыштыру яки экспорт потенциалы белән граждан билгеләнешендәге конкуренциягә сәләтле һәм югары технологияле яңа продукция җитештерүгә юнәлдерелгән проектларны финанслауны күздә тота.

Бер проект өчен заемның гомуми суммасы 5 ел срок белән, елына 1 – 5 процент белән 20 млн сумнан 100 млн сумга кадәр тәшкил итә.

Барлыгы 2019 елда «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы Сәнәгатьне үстерү фонды программалары турында Татарстан Республикасының – сәнәгать эшчәнлеге субъектларының 339 потенциаль гариза бирүчесенә мәгълүмат бирде. «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы адресына 10 заявка керде. 2019 елда Сәнәгатьне үстерү фондының эксперт советы тарафыннан финанслау өчен гомуми суммасы 145 млн сум булган түбәндәге 2 проект хупланды (шул исәптән «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан 30 процент – 43,5 млн сум күләмендә финанслау):

«БАРС Аяк киеме компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Чистай шәһәре) – заем суммасы 45 млн сум, шул исәптән «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы өлеше (30 процент күләмендә) – 13,5 млн сум. 2019 елда Сәнәгатьне үстерү фонды һәм «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан финансланды;

«Ремдизель» акционер җәмгыяте (Чаллы шәһәре) – заем суммасы 100 млн сум, шул исәптән «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы өлеше (30 процент күләмендә) – 30 млн сум. 2019 елда Сәнәгатьне үстерү фонды, 2020 елның гыйнварында «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан финансланды.

**Инвестиция сәясәте**

Хәзерге вакытта инвестиция климатын яхшырту, инвесторларга бизнесны алып бару өчен уңайлы һәм алдан әйтеп була торган шартлар тудыру Татарстан Республикасы икътисадының өстенлекле бурычларыннан берсе булып тора.

2019 елның гыйнварында – декабрендә Татарстан Республикасында икътисадны һәм социаль өлкәне үстерү өчен төп капиталга инвестицияләр 640 837,1 млн сум күләмендә яки 2018 елның гыйнвары – декабре дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 96,3 процент файдаланылды. 2019 елның гыйнварында – декабрендә төп капиталга инвестицияләрнең шактый күләме эшкәртү җитештерүләрен үстерүгә 36 процент, шул исәптән 13,3 процент – кокс һәм нефть продуктлары җитештерүгә, 9,1 процент – химик матдәләр һәм химия продуктлары җитештерүгә, 5,2 процент – автотранспорт чаралары, прицеплар һәм ярымприцеплар җитештерүгә җибәрелде. Төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләменнән инвестицияләрнең 17,6 проценты – файдалы казылмалар чыгаруга, 9,7 проценты – транспортировкалау һәм саклауга, 7,9 проценты – күчемсез мөлкәт белән операцияләр буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга, 3,6 проценты – электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итүгә, 3,8 проценты авыл хуҗалыгы, аучылык һәм урман хуҗалыгына, 4,4 проценты мәгарифкә туры килә.

2019 елның гыйнварында – декабрендә төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләмендә предприятие һәм оешмаларның үз акчасы өлеше 64 процент (2018 елда – 63,3 процент), җәлеп ителгән акчаның чагыштырма күләме 36 процент (2018 елда – 36,7 процент) тәшкил итте. Җәлеп ителгән акчадан бюджет акчасына төп капиталга гомуми инвестицияләр күләменең 13,7 проценты, банклар кредитларына – 7,4 проценты, башка оешмаларның заем акчаларына – 2,7 проценты, чит илләрдән инвестицияләргә 0,3 проценты туры килә.

2019 елның гыйнварында – декабрендә Татарстан чит илләрдән җәлеп ителә торган инвестицияләре күләмнәрендә, 2018 елның шул ук чоры белән чагыштырганда, уңай динамиканы күрсәтте (2,9 тапкырга арту). Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан бизнесны уңайлы алып бару өчен шартлар тудыруга зур игътибар бирелә, бу инвестор өчен гаять мөһим конкурентлы өстенлек булып тора.

2019 елның гыйнварында – декабрендә чит илләрдән кергән инвестицияләр күләме 1 708,2 млн доллар тәшкил итте, аларның күп өлеше – туры инвестицияләр 1 297,5 млн доллар (кергән инвестицияләрнең гомуми күләменә карата 76 процент), башка инвестицияләр 410,7 млн доллар (24 процент) тәшкил итте.

Чит ил инвестицияләре керү республиканың 7 шәһәрендә һәм 5 муниципаль районында күзәтелде: Чаллы шәһәре – 1 242,1 млн доллар, Түбән Кама шәһәре – 341,1 млн доллар, Алабуга шәһәрендә – 112 млн доллар, Казан шәһәре – 12,4 млн доллар, Зеленодольск шәһәре – 276,7 мең доллар, Лениногорск шәһәре – 0,6 мең доллар, Югары Ослан муниципаль районы – 266 мең доллар, Лаеш муниципаль районы – 51,4 мең доллар, Теләче муниципаль районы – 32,1 мең доллар, Мамадыш муниципаль районы – 0,2 мең доллар, Саба муниципаль районы – 10,2 мең доллар. Чит ил инвестицияләренең шактый күләме Чаллы шәһәрендә (республикага кергән

чит ил инвестицияләренең 72,7 проценты) һәм Түбән Кама шәһәрендә (20 процент) тупланган.

2019 елның гыйнварында – декабрендә инвестицияләр 33 илдән керде. Иң актив инвесторлар: Нидерланды – 1 222,9 млн доллар (кергән чит ил инвестицияләренең гомуми күләмендә аларның өлеше 71,6 процент тәшкил итте), Германия Федератив Республикасы – 367,3 млн доллар (21,5 процент) һәм Сингапур Республикасы – 40,4 млн доллар (2,4 процент).

Инвестицияләрнең өстенлекле өлеше – 1 694,2 млн доллар (кергән чит ил инвестицияләренең гомуми күләменнән 99,2 процент) эшкәртү җитештерүләрен үстерүгә, шулай ук төзелешне үстерүгә – 7,03 млн доллар (0,4 процент) җибәрелде.

Төбәкнең икътисадый үсеше һәм инвестицион климатын яхшырту кысаларында төп бурычларның берсе – яңа җитештерүләр өчен югары технологияле компанияләрне һәм перспектив технологияләрне җәлеп итү. Моның белән бәйле рәвештә, республиканың инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру һәм аның территориясендә инвестицион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында «бер тәрәзә» режимында инвестиция проектларын алып бару системасы оештырылды. Анда төрле өлкәләрдәге инвестиция проектлары бар: авыл хуҗалыгы, сәнәгать, азык-төлек продуктлары җитештерү, телекоммуникацияләр, көнкүреш техникасы һ.б. Инвесторларның киң географиясен дә билгеләп үтәргә кирәк, алар арасында Франция Республикасы, Беларусь Республикасы, Кытай Халык Республикасы, Америка Кушма Штатлары, Германия Федератив Республикасы, Япония, Төркия Республикасы һәм башкалар бар.

Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының милли рейтингы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы 5 ел рәттән лидер-төбәкләр өчлегенә керә.

Үз илебез һәм чит ил инвесторлары өчен Татарстан Республикасының мәгълүмати ачыклыгын һәм җәлеп итүчәнлеген арттыру, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланучыларга Татарстан Республикасында инвестицияләү шартлары турында актуаль мәгълүмат бирү, аның инвестиция потенциалын тәкъдир итү, шулай ук инвесторларны җәлеп итү һәм аларга «бер тәрәзә» режимында булышлык күрсәтү системасын үстерү максатларында республикада Татарстан Республикасы Инвестиция порталы (www.invest.tatarstan.ru) эшли, портал дөньяның 11 телендә тәкъдим ителә.

2019 елда Инвестиция порталына «Ярдәм чаралары» бүлеге өстәлде:

Татарстан Республикасы территориясендә һәркем өчен файдалану мөмкинлеге булган мәйданчыкларны сайлап алу һәм ярдәм итү чараларын билгеләү системасы (http://invest.tatarstan.ru/ru/guide/mp/);

дәүләт-хосусый партнерлык өлкәсендәге проектлар турында мәгълүматлар урнаштырылган бит, анда дәүләт-хосусый партнерлык өлкәсен җайга сала торган норматив хокукый документлар, шулай ук республика территориясендә дәүләт-хосусый партнерлык проектларын тормышка ашыру өчен һәркем өчен файдалану мөмкинлеге булган концессион килешүләр һәм җир кишәрлекләре реестрлары урнаштырыла һәм даими рәвештә яңартылып тора (http://invest.tatarstan.ru/ru/guide/public-private-partnership/);

бизнеска ярдәм күрсәтүнең республика һәм федераль чаралары, мәйданчыклар һәм финанс инструментлары турында җыелма мәгълүмат алу максатларында инвесторлар запросларын эшкәртү өчен онлайн-система эшләтеп җибәрелде (http://invest.tatarstan.ru/ru/guide/online-service-for-investors/).

Татарстан Республикасының инвестицион мәйданчыкларына (махсус икътисадый зонасы, Социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр, сәнәгать парклары һәм сәнәгать мәйданчыклары) резидентларны җәлеп итү максатларында, алар турында мәгълүмат түбәндәге инструментлар аша актуальләштерелә:

Татарстан Республикасының Инвестиция порталы, аның мәгълүмати контенты даими рәвештә тулыландырыла һәм актуальләштерелә;

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан PriceWaterhouseCoopers компаниясе белән берлектә эшләнгән «Инвесторның бизнес-гиды»;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнгән «Фасттрек» бердәм порталы (Фасттрек.РФ), ул финанс һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү чараларын, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәр сәнәгать паркының һәм сәнәгать мәйданчыгының визуаль өлешен, һәр мөлкәти ярдәм объекты мөмкинлекләрен детальләштерүне кертеп, үз эченә ала.

Татарстан Республикасында административ киртәләрне киметүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру дәвам итә.

Татарстан Республикасында бизнес алып бару процедураларын гадиләштерүнең максатчан модельләрен гамәлгә ашыру йомгаклары буенча төбәк инвестицион стандарты нигезләмәләренә бәйле модельләр 100 процентка үтәлде:

инвесторлар һәм җитәкчелекнең турыдан-туры элемтә каналлары эшләвенең һәм кире элемтәгә керүнең нәтиҗәлелеге;

инвестицияләрне җәлеп итү һәм инвесторлар белән эшләү буенча махсуслаштырылган оешма эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге;

инвесторларны яклау һәм инвестицион эшчәнлеккә ярдәм итү механизмнары турында төбәк законнары булуы һәм аларның сыйфаты;

инвестицион порталның сыйфаты.

Электр белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өлкәсендә хезмәт күрсәтүне оптимальләштерү өлешендә түбәндәге эш башкарылды.

Административ киртәләрне киметү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 28 декабрендәге б-3529 номерлы боерыгы белән төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми торган очраклар исемлеге расланды.

Аерым алганда, төзелешкә рөхсәт территориаль челтәр оешмасының инвестиция программасын гамәлгә ашыруда һәм (яки) технологик тоташтыруда каралган, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган, көчәнеш классы 35 киловаттка кадәр (35 киловаттны кертеп) булган электр тапшыру линияләрен (һава линияләрен, кабель линияләрен) кертеп, электр челтәре хуҗалыгы объектларын, 0,4 – 35 киловатт көчәнешле трансформатор ярдәмче станцияләрен төзегән һәм (яки) реконструкцияләгән очракта таләп ителми.

Моннан тыш, электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник тоташтыру буенча хезмәт күрсәтүне максималь оптимальләштерү һәм үтә күренмәлелеген арттыру

максатларында «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте тарафыннан түбәндәге чаралар үткәрелә:

Заявкалар бирүне оптимальләштерү максаты белән «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте хезмәтләреннән файдаланучылар өчен мобиль кушымта эшләнде (гамәлгә кертү 2020 елда башкарылачак);

«Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте тарафыннан шәхси кабинетта онлайн-консультацияләр бирү өчен, шулай ук «on-line» хезмәтләр күрсәтүгә түләү сервисы өчен «Виртуаль әңгәмәдәш» чат-ботын булдыру буенча эш башланды;

«0-визитлар» функциясе аша электрон рәвештә энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру хезмәтен камилләштерү буенча эш башкарылды, анда хакимият органнарына бару таләп ителми, 2019 елда «электрон рәвештә күрсәтелгән хезмәтләр өлеше» максатчан күрсәткече – 6,3 процент (2018 ел белән чагыштырганда 3,3 процентка арту) тәшкил итте.

Гамәлдәге закон таләпләрен оптимальләштерү кысаларында 2019 ел дәвамында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче башкарма хакимият органнары белән берлектә, гамәлдәге административ регламентларга анализ ясалды, процедураларны оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр тикшерелде һәм гамәлгә кертелә. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең (2018 елдан башлап) һәм Түбән Кама муниципаль районының (2019 елдан башлап) башкарма комитетлары, «сакчыл җитештерү» принципларын кулланып һәм алга таба хезмәт күрсәтү процессын оптимальләштереп, муниципаль хезмәтләр күрсәтү процедураларын анализлау буенча эш үткәрелә.

Әлеге эш нәтиҗәсендә 2018 – 2019 елларда Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан якынча 180 административ регламент, җирле үзидарә органнары тарафыннан 2 200 дән артык административ регламент актуальләштерелде (үзгәрешләр кертү законнарга да, хезмәтләр күрсәтүнең аерым процедураларына да кагылды).

Моннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә федераль законнарны һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын даими нигездә инвентаризацияләүдә катнаша.

Төзелеш өчен рөхсәт алу белән бәйле хезмәт күрсәтү срокларын кыскарту өлешендә түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды:

Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләре өчен «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү» хезмәте күрсәтүгә гариза бирү мөмкинлеге гамәлгә ашырылды;

Татарстан Республикасында төзелешкә рөхсәт бирү буенча хезмәт күрсәтүнең факттагы вакыты 5 эш көнен тәшкил итә;

Татарстан Республикасының пилот муниципаль берәмлегендә җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын алуга гариза бирү мөмкинлеге тормышка ашырылды;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү һәм бирү буенча хезмәтләр күрсәтү вакыты 11 эш көненә кадәр кыскартылды (шул ук вакытта 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җир кишәрлегенең

шәһәр төзелеше планын бирү буенча хезмәт күрсәтү срогын 20 эш көненнән 14 эш көненә кадәр кыскарту каралды);

Проект документларына һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү срогы 21 эш көненнән артмый.

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе рәсми сайтта урнашкан шәхси кабинет ярдәмендә гариза бирүче белән аралашу юлы белән дәүләт хезмәтләренең 100 процентын электрон рәвештә күрсәтә (шәхси кабинетта эшләү турында видеоролик – http://gosekspertiza-rt.ru/instructions-docs/).

Эшкуарлар өчен электрон төрдәге дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлаштыру өлешендә:

Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында эшкуарлар өчен хезмәт күрсәтүне эзләүне гадиләштерү өчен «Бизнес өчен» вкладкасы булдырылды;

Татарстан Республикасы Инвестиция порталында мәйданчыкларны сайлап алу һәм ярдәм чараларын билгеләү буенча онлайн-система эшләнде.

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрне электрон төрдә күрсәтү дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия булган хезмәтләр күрсәтүнең электрон төрдәге тулы спектрыннан файдаланырга мөмкин булган үз-үзенә хезмәт күрсәтүнең мәгълүмати терминаллары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (алга таба – Портал), шулай ук iOS һәм Android платформаларындагы җайланмалар өчен «Татарстан Республикасы хезмәтләре» мобиль кушымтасы аша гамәлгә ашырыла. Мобиль кушымта смартфоннар ярдәмендә электрон счет-фактураларны карау һәм түләү, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар булуны тикшерү һәм түләү, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә чират статусын тикшерү һ.б. кебек хезмәтләрне тиз һәм уңайлы итеп алырга мөмкинлек бирә (кушымталарны AppStore һәм Play Market тан алырга мөмкин).

Инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 декабрендәге 1254 карары белән 2019 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы расланды, ул республикада инвестиция эшчәнлеге үсешенең төп өстенлекләрен билгели.

2019 елга дәүләт инвестиция сәясәтенең өстенлекләре булып түбәндәгеләр билгеләнде: Россия Федерациясе төбәкләре һәм чит ил партнерлары белән инвестицияләрне җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләренең продукциясен яңа базарларга чыгару өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү юнәлешләре, халыкара икътисадый кооперация киңлеген актив кулану; эшкуарлыкка, шул исәптән махсус икътисадый зоналарга, социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләргә, технопаркларга, индустриаль паркларга, сәнәгать мәйданчыкларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын үстерү; цифрлы икътисадны формалаштыру һәм үстерү һ.б.

2019 елга Татарстан Республикасы Инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә, Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумына туры килә торган өстенлекле инвестицион проектлар исемлегенә якынча 200 проект кертелде, шул исәптән түбәндәге инвестиция проектлары: «ЭП-600 яңа олефин һәм аннан

ясалган кушылмалар комплексын төзү» («Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционер җәмгыяте, Түбән Кама шәһәре), «ПОЗиС» акционер җәмгыятендә югары технологияле җиһазларны һәм прогрессив технологияләрне гамәлгә кертү нигезендә көнкүреш суыткыч техникасын һәм медицина суыткыч җиһазларын җитештерүне комплекслы үстерү» («Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте, Зеленодольск шәһәре), «КАМАЗ автомобильләренең модель рәтләрен үстерү һәм аның җитештерү өчен җитештерү егәрлекләрен модернизацияләү» («КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, Чаллы шәһәре), «ГАЗ турбинасы җайланмасы базасында Казанның 3 нче җылылык-ягулык централен модернизацияләү» («ТГК-16» ачык акционер җәмгыяте, Казан шәһәре), «Казан сөт комбинатында җитештерүне модернизацияләү, киңәйтү» («Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Казан шәһәре) һәм башкалар.

Татарстан Республикасында предприятиеләргә салым ташламалары бирү рәвешендә дәүләт ярдәме механизмы җентекләп эшләнде һәм актив кулланыла. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвесторларга Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган табышка салым ставкасын 13,5 процентка кадәр киметү һәм проектны гамәлгә ашыру өчен оешма тарафыннан яңа булдырылган яки сатып алынган мөлкәткә салым ставкасын 0,1 процентка ка кадәр киметү каралды. Әлеге ташламалар инвестиция эшчәнлеге субъектларына проектларның үз-үзен аклау срогына бирелә, әмма 7 елдан артмый, ә машина төзелеше тармагында салым ташламалары инвестицияләр башланган көннән 13 елга кадәр бирелергә мөмкин.

Якынча бәяләүләр буенча 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә якынча 15 млрд сум (шул исәптән 2019 елда – 1,5 млрд сум) гомуми суммага салым ташламалары бирелде. Әлеге инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында 743 млрд сум күләмендә инвестицияләр җәлеп ителде (шул исәптән 2019 елда – 20 млрд сум), Татарстан Республикасы бюджетына салым түләүләре якынча 25 млрд сум тәшкил итәчәк (шул исәптән 2019 елда – 2,9 млрд сум). Ярдәм күрсәтелә торган инвестиция проектлары кысаларында 17,7 мең берәмлек яңа эш урыннары булдырылды.

2019 елда инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында 3 яңа шартнамә төзелде:

«Берьюлы саклана торган 150 000 тоннага бөртекле һәм майлы культураларны саклау өчен элеватор төзү» («Зәй элеваторы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте);

«Җиңел нафта изомеризациясен һәм нафта сплиттеры секциясен катнаш урнаштыру» («ТАНЕКО» акционер җәмгыяте);

«Зеленодольск күпләп бүлү үзәге».

Татарстан Республикасында төбәккә инвесторларны җәлеп итүгә булышлык итә торган кирәкле инфраструктура ярдәме булдырылды, ул – «Алабуга» җитештерү-сәнәгать тибындагы һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы 2 махсус икътисадый зонаны, социаль-икътисадый үсеше алга киткән 5 территорияне («Яр Чаллы», «Түбән Кама», «Зеленодольск», «Чистай»,

«Менделеевск») үз эченә ала, 100 инфраструктура объекты (80 сәнәгать мәйданчыгы һәм 20 сәнәгать паркы), технопарклар, индустриаль парклар челтәре, бизнес-инкубаторлар, технополислар булдырылды.

*Социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр*

Социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләрне булдыру инвестицияләр җәлеп итүнең нәтиҗәле инструменты булып тора. Аларның төп максаты – моношәһәрләр икътисадын диверсификацияләү һәм аларның инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру.

2016 елдан Татарстан Республикасында Яр Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Зеленодольск һәм Менделеевск моношәһәрләре территорияләрендә социаль-икътисадый үсеше алга киткән 5 территория булдырылды.

Социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резедентларына салым ташламалары һәм табышка, җиргә, мөлкәткә һәм иминият кертемнәренә преференцияләр бирелә:

1) табышка салымның киметелгән ставкасы, шул исәптән:

федераль бюджетка күчерү өлешендә – эшчәнлектән беренче табышны алган вакыттан алып беренче 5 салым чоры дәвамында 0 процент; Татарстан Республикасы бюджетына күчерү өлешендә ставка беренче табышны алган вакыттан алып беренче 5 салым чоры дәвамында 5 процент һәм киләсе 5 салым чоры дәвамында 10 процент;

2) иминият кертемнәренең түбәнәйтелгән тарифлары гадәти тәртиптә түләнә торган 30 процент урынына 7,6 процент күләмендә (ташлама социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория резиденты статусын алган көннән 10 ел дәвамында бирелә һәм мондый статусны социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория оештырылган көннән 3 елдан да соңга калмыйча алган резидентларга карата кулланыла);

3) оешмалар мөлкәтенә салым түләүдән азат итү;

4) җир салымын түләүдән азат итү.

2020 елның 31 гыйнварына Татарстан Республикасының барлык социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләрдә 75 резидент теркәлде, социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резидентлары статусы бирелгән вакыттан якынча 10,7 млрд сумга капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымсыз) гамәлгә ашырылды һәм якынча 5 660 яңа эш урыны булдырылды.

2019 ел өчен хисап йомгаклары буенча:

социаль-икътисадый үсеше алга киткән «Чаллы» территориясендә 40 резидент теркәлгән, аларга социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория резидентлары статусы бирелгән вакыттан алып якынча 9,1 млрд сум капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымсыз) гамәлгә ашырылган һәм 4 900 яңа эш урыны булдырылган;

социаль-икътисадый үсеше алга киткән «Түбән Кама» территориясендә 10 резидент теркәлгән, аларга резидентлар статусы бирелгән вакыттан алып 980 млн сумнан артыграк капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымсыз) гамәлгә ашырылган һәм 330дан артыграк яңа эш урыны булдырылган;

социаль-икътисадый үсеше алга киткән «Чистай» территориясендә 11 резидент теркәлгән, аларга резидентлар статусы бирелгән вакыттан алып

460 млн сумнан артыграк капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымсыз) гамәлгә ашырылган һәм 330дан артыграк яңа эш урыны булдырылган;

социаль-икътисадый үсеше алга киткән «Зеленодольск» территориясендә 11 резидент теркәлгән, аларга резидентлар статусы бирелгән вакыттан алып якынча 150 млн сум капитал салулар гамәлгә ашырылган һәм якынча 100 яңа эш урыны булдырылган;

социаль-икътисадый үсеше алга киткән «Менделеевск» территориясендә 3 резидент теркәлгән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының һәм депутат берләшмәләренең Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшчәнлеге турында сораулар исемлеге буенча мәгълүмат**

**Граждан җәмгыяте**

***1. Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек кысаларында Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан башкарыла торган эш турында.***

Татарстан Республикасы Президентының «1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү турында» 2018 елның 8 маендагы ПУ-360 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасында 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелде.

Татарстан Республикасында бу эш оештыру комитетының 2009 елның 8 июлендәге Пр-169 номерлы утырыш беркетмәсе белән расланган чаралар планы нигезендә алып барыла.

2020 ел дәвамында төрле тематик концертлар, фестивальләр, музыкаль-театральләштерелгән тамашалар, хәтер кичәләре, шигырьләр уку, конкурслар, спорт ярышлары, эстафеталар, дан дәресләре, сыйныф сәгатьләре, сугыш турында документаль фильмнар карау, тематик күргәзмәләр, митинг, чәчәкләр салу тантаналары, Җиңү көнен бәйрәм итүгә багышланган «Үлемсез полк» һәм «Георгий тасмасы» акцияләре, «Җиңү хатлары» акцияләре һәм башка бик күп чаралар үткәрү планлаштырыла.

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек эшендә Республика яшьләр иҗтимагый оешмалары («Студентлар лигасы», «Иҗат яшьләре академиясе», «Җиңү волонтерлары», социаль волонтерлар, «Форпост» республика үзәге», «Балалар оешмалары советы» һәм студентлар хезмәт отрядлары) актив катнаша. Уздырылачак патриотик чараларның ведомство планы кысаларында 2020 ел дәвамында 50дән артык проект планлаштырылган, шул исәптән:

<u>хәрби-патриотик:</u>

спартакиадалар уздыру, шул исәптән Идел буе федераль округының иҗтимагый әһәмиятле проекты – «Идел буенда аҗаган уены» хәрби-спорт спартакиадасының муниципаль, районара этаплары кысаларында;

кадет сыйныфлары, район хәрби-патриотик клублары вәкилләренең «СОЮЗ-2020 – Җиңү варислары» бөтенроссия мәгърифәти җыенында катнашуы;

<u>гражданлык-патриотик:</u>

Бөтенроссия «Җиңү волонтерлары» иҗтимагый хәрәкәте активының сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре өйләренә баруы;

ветераннар катнашында паспортлар тапшыру;

«Геройлар белән әңгәмә» федераль проекты кысаларында муниципаль акцияләр үткәрү;

белем бирү оешмалары, яшьләр сәясәте учреждениеләре базасында ветераннарның яшьләр белән очрашуларын оештыру, шул исәптән хәрби-тарихи викториналар һәм конкурслар үткәрү;

«Хәтер вахтасы» Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарында эзләү хәрәкәте активы катнашында чаралар, эзләү экспедицияләре;

«Җиңү волонтерлары» корпусы чаралары, шул исәптән квестлар форматында да;

ветераннар оешмалары белән берлектә «Җиңүчеләр», «Җиңү хатлары», «Гаилә фотохроникасы» һәм «Минем гаиләм ядкәре» чараларын уздыру;

республика яшьләренең «Рус рифмалары», «Мин яратам сине, Россия!», «Кычкырыбрак!» иҗади конкурсларының гариза бирү этапларында катнашуы;

Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булганнар истәлегенә багышланган мемориаль комплексларда яшьләр катнашында тантаналы чаралар;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә патриотик проектларны гамәлгә ашыру – «Безнең Җиңү» республика конкурсы.

«Җиңү волонтерлары» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлегендә бөтен республикадан 8 меңнән артык актив гражданы катнаша. Республиканың 45 муниципаль берәмлегендә муниципаль штаблар булдырылды, студентларга гражданлык-патриотик тәрбия бирү буенча иҗтимагый үзәкләрдә һәм мәктәпләрдә «Җиңү волонтерлары» патриотик отрядлары оештырыла.

Төбәк бүлеге эшчәнлегенең бер юнәлеше – истәлекле урыннарны һәм сугышчылар каберлекләрен төзекләндерү. 2020 елның гыйнварыннан май аена кадәр «Җиңү волонтерлары» отрядлары ярдәме белән Бөек Ватан сугышы һәйкәлләрен һәм мемориалларын тәртипкә китерү планлаштырыла.

Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган солдатлар мәетләре калдыкларын эзләп табу һәм тиешенчә күмү буенча 1941 – 1945 елларда сугышлар барган урыннарда эзләү экспедицияләре үткәрү планлаштырыла.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә укучы яшьләр арасында түбәндәге конкурслар үткәреләчәк:

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорындагы туган як тарихына багышланган рус, татар, чуаш, удмурт, мари, мордва телләрендә иң яхшы инша;

якташларыбызның, шул исәптән урам, мәйдан, предприятие һәм оешмаларның атамаларында мәңгеләштерелгән исемнәрен һәм батырлыклары турында мәгълүматлы булуны ачыклауга багышланган.

Белем бирү оешмаларында 1 126 геройлык-патриотик, туган якны өйрәнү музее эшли, Бөек Ватан сугышы тарихына багышланган тематик почмаклар булдырылды. Музейларны, музей бүлмәләрен, хәрби һәм хезмәт даны почмакларын реконструкцияләү һәм яңарту планлаштырылган 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышына багышланган иң яхшы экспозициягә югары белем бирү оешмалары музейлары арасында иҗади конкурс узачак.

Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү мәсьәләләренә багышланган республика фәнни-гамәли конференциясен, югары уку йортлары арасында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгына багышланган хәрби җыр фестивален үткәрү планлаштырыла.

Белем бирү оешмаларында 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгына багышланган әдәби-патриотик әңгәмәләр, презентацияләр, хәтер сәгатьләре узачак. Җиңү көненә багышлап мәктәп китапханәләрендә китап-иллюстрация күргәзмәләре оештырылачак.

Instagram социаль челтәрендә «Җиңү турындагы тере хәтер 75» бердәм аккаунты эшли башлады, анда яшьләрнең иҗтимагый оешмалары һәм республиканың муниципаль берәмлекләре тарафыннан Җиңүнең 75 еллыгына багышлап үткәрелә торган чаралар турында мәгълүматлар бирелә.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә Бөек Ватан сугышы ветераннарына, гадәттәгечә, Татарстан Республикасы Президенты исеменнән котлау открыткалары һәм бүләкләр тапшырылачак.

2020 елның 1 мартына Татарстан Республикасында 32 936 Бөек Ватан сугышы ветераны яши, шул исәптән:

301 Бөек Ватан сугышы инвалиды;

инвалидлыгы булган 632 Бөек Ватан сугышы ветераны;

гамәлдәге армия составында сугышмаган, Бөек Ватан сугышында катнашкан, шул исәптән инвалидлыгы да булган 249 кеше;

«Камалыштагы Ленинградта яшәгән» билгесе белән бүләкләнгән, шул исәптән инвалидлыгы булган 150 Бөек Ватан сугышы ветераны;

сугыш вакытында балигъЛык чорына җиткәнче тоткынлыкта булган, шул исәптән инвалидлыгы булган155 кеше;

2 843 Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм сугышта катнашканнарның тол хатыннары;

Бер үк вакытта тол хатын һәм тыл хезмәтчәне дигән ике категориягә керүче 4 969 граждан;

23 637 тыл хезмәтчәне.

Россия Федерациясе Президентының «1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү турында» 2008 елның 7 маендагы 714 номерлы Указы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тиешле социаль ярдәм алу хокукына ия булган Бөек Ватан сугышы ветераннарын, һәлак (вафат) булган Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм анда катнашканнарның гаилә әгъзаларын торак белән тәэмин итү каралган.

Программаны тормышка ашыру чорында 20 млрд сумнан артык акча тотылган. 2020 елның 1 мартына торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган 19 106 сугыш ветеранының 19 103 се субсидия алган.

Гамәлдәге федераль законнар нигезендә Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм сугышта катнашканнарга, «Камалыштагы Ленинградта яшәгән» билгесе белән бүләкләнгән затларга, Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләрнең гаилә әгъзаларына, балигъЛык яшенә җиткәнче тоткынлыкта булганнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтелә.

Россия Федерациясе Президентының 2019 елның 24 апрелендәге 186 номерлы Указы нигезендә Бөек Ватан сугышы ветераннарына Җиңү көненә багышлап ел саен 10 мең сум күләмендә акча бирү каралган.

Бөек Ватан сугышы ветераннарына шулай ук түбәндәге ташламалар бирелә:

навигация чорында Татарстан Республикасында шәһәр яны су транспортында йөрү бәясенең 50 проценты күләмендә түләү;

торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары чикләрендә торак-коммуналь хезмәтләр бәясенең 50 проценты

күләмендә субсидия-ташлама.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә тыл хезмәтчәннәренә айлык акчалата түләү бирелә (2019 елда – 726 сум), түләүсез теш протезлары һәм колак протезлары эшләнә.

Россия Федерациясе Президентының «1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан Россия Федерациясенең кайбер категория гражданнарына бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2020 елның 7 февралендәге 100 номерлы Указы нигезендә Бөек Ватан сугышы инвалидларына, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан корылган концлагерьларның, гетто һәм башка ирексезләп ябып тоту урыннарының балигъ булмаган элеккеге тоткыннарына, Бөек Ватан сугышы, Финляндиягә, Япониягә каршы сугыш вакытында һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең тол хатыннарына (тол ирләренә), Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм анда катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә) 2020 елның апрель – май айларында – 75 мең сум, тыл хезмәтчәннәренә һәм нацист концлагерьларының, төрмәләрнең һәм геттоның балигъ булган элеккеге тоткыннарына 50 мең сум күләмендә бер тапкыр акча биреләчәк.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 февралендәге 244-р номерлы карары нигезендә бер тапкыр бирелә торган түләү түбәндәгеләргә билгеләнә:

«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктының 1 – 3 пунктчаларында күрсәтелгән Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан корылган концлагерьларның, гетто, башка төрле ирексезләп ябып тоту урыннарының балигъ булмаган элеккеге тоткыннарына – 25 мең сум күләмендә;

тыл хезмәтчәннәренә, шулай ук һәлак (вафат) булган Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләрнең тол хатыннарына 5 мең сум күләмендә акча бирү каралган.

Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм инвалидларына һәм гражданнарның аларга тиңләштерелгән категорияләренә (аларның социаль хезмәт күрсәтелүгә үзләренә аерым ихтыяҗларын исәпкә алып) «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442 -ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 26 ноябрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә социаль хезмәт күрсәтелә.

2020 елның 1 мартына 2 205 Бөек Ватан сугышы ветеранына, шул исәптән Бөек Ватан сугышында катнашкан 154 кешегә, 47 Бөек Ватан сугышы инвалидына, 1 979 тыл хезмәтчәненә, 8 граждан «Камалыштагы Ленинградта яшәгән» медале белән бүләкләнгән, балигълык яшенә җиткәнче тоткынлыкта булган 17 кешегә социаль хезмәт күрсәтелә.

Өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәләрендә 2 113 Бөек Ватан сугышы ветеранына, шул исәптән Бөек Ватан сугышында катнашкан 151 кешегә, 47 Бөек

Ватан сугышы инвалидына, 1 891 тыл хезмәтчәненә, «Камалыштагы Ленинградта яшәгән» медале белән бүләкләнгән 7 гражданга, балигълык яшенә җиткәнче тоткынлыкта булган 17 кешегә хезмәт күрсәтелә. Ялгыз һәм ялгыз яшәүче инвалидлар һәм сугышта катнашкан кешеләр, шулай ук авылдагы ялгыз һәм ялгыз яшәүче тыл хезмәтчәннәре социаль хезмәтләрдән өйдә бушлай файдалана.

***2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау (үтәү) нәтиҗәлелеге турында.***

Гражданнарның дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итүләре аларның дәүләт идарәсендә, дәүләт дәрәҗәсендәге һәм иҗтимагый мәсьәләләрне хәл итүдә катнашуы рәвешләреннән берсе, үтәлмәгән хокукларны торгызу ысулы булып тора.

Мөрәҗәгатьләрнең саны һәм аларның эчтәлеге дәүләт, хуҗалык һәм социаль-мәдәни үсешнең агымдагы һәм перспектив мәсьәләләрен хәл иткәндә кирәкле мөһим мәгълүмат чыганагы, шулай ук гражданнарның хакимият органнарына, республикада һәм илдә барган вакыйгаларга мөнәсәбәте күрсәткече булып тора.

Анализлау күрсәткәнчә, гражданнарның мөрәҗәгатьләре тотрыклы төстә арта бара. Әйтик, 2019 ел йомгаклары буенча республика министрлыкларында һәм ведомстволарында тикшерелгән гражданнар мөрәҗәгатьләре саны 2018 ел белән чагыштырганда 12 процентка артты һәм 84 751 данә (2018 елда – 75 937) тәшкил итте, шулардан 12 661 мөрәҗәгать шәхсән кабул итү вакытында каралды (2018 елда – 12 937), интернетта кабул итү аша 23 075 кеше мөрәҗәгать итте (2018 елда – 26 850).

Гражданнардан иң күп мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә керде.

2019 елда җирле үзидарә органнарына 101 574 мөрәҗәгать керде (2018 елда – 96 779), шул исәптән мәгълүмати системалар аша – 37 671 (2018 елда – 40 660), 22 902 кеше шәхсән кабул ителде (2018 елда – 20 892).

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне һәм аларны шәхсән кабул итүне оештыруны тикшереп торуны көчәйтү максатларында ел саен «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» 2010 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәү өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән чаралар уздырыла.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүнең нәтиҗәлелеген арттыру буенча

үткәрелә торган чаралар вакытында ачыкланган түбәндәге фактларны бетерүгә юнәлтелгән чаралар күрелә:

гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү, тиешле башкаручыларга юллау, мөрәҗәгатьләргә җавап бирү срокларын бозу;

шәхсән кабул итү карточкаларын тутыру һәм саклауның законнарга туры килмәве;

шәхсән кабул итү барышында гражданнарның телдән мөрәҗәгатьләрендә куелган сорауларның асылы буенча җаваплар бирелмәү;

шәхсән кабул итү барышында алынган язма мөрәҗәгатьләрне теркәмәү;

гражданнарга мөрәҗәгатьләрдә куелган сорауларның асылы буенча язма җаваплар җибәрү;

мөрәҗәгатьләрне карап тикшермәү;

гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясалмау;

гариза бирүченең татар телендәге мөрәҗәгатенә рус телендә язмача җавап бирү.

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» 2010 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның рәсми сайтларда һәм (яки) административ биналарның стендларында (кабул итү графигы, законнар) актуаль мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итү буенча эш алып барыла.

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Президентының «Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләрен мониторинглау һәм анализлау турында» 2017 елның 17 апрелендәге 171 номерлы Указы таләпләрен үтәүне тәэмин итү буенча ССТУ.РФ махсус интернет-порталында (гражданнарны гомумроссия күләмендә кабул итү) «Мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү» бүлеген тутыру буенча шактый эш алып барыла.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора. Гражданнарның язма рәвештә бирелгән һәм телдән мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү сыйфатын яхшырту максатларында йөкләмәләрне һәм алар буенча кабул ителгән карарларның үтәлү срокларын оператив тикшерүне көчәйтү буенча эш алып барыла.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне камилләштерүнең төп максаты – гариза бирүчеләрнең үз мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләреннән һәм алар буенча кабул ителгән чаралардан канәгатьлеге дәрәҗәсен күтәрү.

Хәзерге вакытта хакимият органнарына һәм вазыйфаи затларга гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү өлкәсендә түбәндәге төп бурычлар йөкләнде:

гражданнарны шәхсән кабул итү мәҗбүри;

гражданнарның телдән һәм язма рәвештә бирелгән мөрәҗәгатьләрен карап тикшергәндә, шул исәптән мөрәҗәгатьләрдәге мәсьәләләрне үз вакытында, һәрьяклап һәм объектив карап тикшерү өлешендә, законнарның бозылуына юл куймаска;

кабул ителгән мөрәҗәгатьләрнең саны һәм сыйфатлы составына анализ ясарга һәм алар буенча кирәкле чаралар күрергә;

башкару дисциплинасының дәрәҗәсен күтәрергә;

ССТУ.РФ махсус интернет-порталында «Мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү» бүлеген тутыру өлешендә Россия Федерациясе Президентының «Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләрен мониторинглау һәм анализлау турында» 2017 елның 17 апрелендәге 171 номерлы Указы таләпләре үтәлешен катгый контрольдә тотарга;

гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүгә эчке контрольне камилләштерергә;

гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче кадрларны әзерләү һәм яңадан әзерләү эшен үткәрергә.

***3. Гражданлык инициативаларын, шул исәптән «Экотектоника» экология архитектурасы һәм төзелеше бөтенроссия конкурсында икенче урынны алган «Савиново» табигать-ландшафт паркын төзү буенча иҗтимагый инициативаны гамәлгә кертү чаралары турында.***

Үткәрелгән анализ нигезендә, Казан шәһәренең Гаврилов урамындагы Казансу елгасы яры буенда табигать-рекреация билгеләнештәге функциональ зона булдыру каралган, аңа экологик коридорлар һәм ташу вакытында су баса торган Гаврилово территориясендәге төп кишәрлек керә.

Казан шәһәр округының генераль планы проектын (алга таба – Казан шәһәренең генплан проекты) эшләүче – «Мәскәүнең Генплан институты» дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан җирнең ландшафты өйрәнелде, Казан шәһәре экологлары белән берлектә аеруча кыйммәтле биологик үсемлекләрнең үсү һәм хайваннарның яшәү урыннары билгеләнде, шулай ук әлеге территориянең табигый байлыкларын саклауга карата куелган таләпләр исәпкә алынды.

Табигать-рекреация комплексы составында Казан шәһәренең Гаврилов урамы янында Казансу елгасы яры буена урнашкан яр буе биоценозларын һәм су-сазлык җирләрен саклау тәкъдим ителә. Табигатьне саклау билгеләнешендәге территорияләргә су баса торган болыннарны, су янындагы һәм сазлыкка әйләнгән табигый баткак урыннарны үз иткән сирәк төрдәге үсемлекләр үсә һәм хайваннар яши (шул исәптән дымсөяр орхидеяләр, тузбашлар, сакчы чикерткәләр, су янында оя коручы кайбер кошлар һәм кайбер су кошлары) торган урыннар белән бәйле аеруча кыйммәтле табигать берлекләре кишәрлекләре керә.

Казансу елгасының яр буендагы табигать территориясенең төп өлеше, җәяүлеләр өчен зоналар һәм халыкның ял итү зоналары, шулай ук җәмәгать һәм спорт чаралары үткәрелә торган территорияләр Казан шәһәр округының табигать-рекреация комплексына кертелгән һәм алар Казан шәһәренең территорияне фактта файдалану буенча генплан проектында саклана.

Иҗтимагый фикер алышулар барышында Казан шәһәренең генплан проекты буенча кергән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Мәскәүнең Генплан институты » дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан карап тикшерелде. Иҗтимагый фикер алышулар йомгаклары турындагы бәяләмәләр Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең 2019 елның 29 августындагы документлары һәм хокукый актлары җыентыгында басылып чыкты (Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштырылган: https://www.kzn.ru/naytidokument/-sbornik-dokumentov.

Хәзерге вакытта Казан мэриясе каршындагы иҗат төркеме тарафыннан җәмәгать урыннарын һәм рекреация территорияләрен үстерү стратегиясе эшләнә,

анда Гаврилов урамындагы Казансу елгасы ярын табигать-рекреация комплексының бер өлеше буларак саклап калу каралган.

Шулай ук «Orhestra» архитектура бюросы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Н.Л.Фишман җитәкчелегендә Казансу елгасы үсеше стратегиясе проекты эшләнә.

Казан шәһәрендә төзекләндерүне таләп итә торган территорияләр «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» өстенлекле проектын, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында һәм «Татарстан Республикасы хезмәтләре» мобиль кушымтасында җәмәгать пространстволарын үстерү буенча Татарстан Республикасы программасын гамәлгә ашыру кысаларында уздырыла торган онлайн-сораштыру йомгаклары буенча билгеләнә.

*Белешмә өчен: «Савиново» табигать-ландшафт паркын төзекләндерү концепциясе «Экотектоника» бөтенроссия экология архитектурасы һәм төзелеше конкурсында 2 урынны алган иде, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә карап тикшерүгә кермәде.*

***4. Татарстан Республикасында административ киртәләрне киметү буенча чаралар системасын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге турында.***

Татарстан Республикасында административ киртәләрне киметүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру дәвам итә.

Электр белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өлкәсендә хезмәт күрсәтүне оптимальләштерү өлешендә түбәндәге эшләр башкарылды.

Административ киртәләрне киметү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 28 декабрендәге 3529-р номерлы карары белән төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми торган очраклар исемлеге расланды. Аерым алганда, электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзегәндә һәм (яки) реконструкцияләгәндә, көчәнеш классы 35 кВ.га кадәр булган электр тапшыру линияләрен, технологик тоташтыру һәм (яки) территориаль челтәр оешмасының инвестицион программасын тормышка ашыруда каралган 0,4-35 кВ көчәнешле трансформатор подстанцияләрен, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчасына гамәлгә ашырыла торган трансформатор подстанцияләрен төзегәндә рөхсәт таләп ителми.

Моннан тыш, «Челтәр компаниясе» ААҖ электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник тоташтыру буенча хезмәт күрсәтүне максималь оптимальләштерү һәм ачыклыгын арттыру максатларында түбәндәге чаралар күрелә:

гаризалар бирүне җиңеләйтү максатыннан «Челтәр компаниясе» ААҖ хезмәтләрен кулланучылар өчен мобиль кушымта эшләнде (2020 елда кертеләчәк)

«Сетевая компания» ААҖ шәхси кабинетында онлайн-консультацияләр өчен «Виртуаль әңгәмәдәш» чат-ботын, шулай ук «on-line» хезмәтләре өчен түләү сервисын булдыру эше башланды;

«0 визит» функциясе аша энергия кабул итү җайланмаларын электрон рәвештә технологик тоташтыру хезмәтен камилләштерү буенча эш алып барылды, бу очракта хакимият органнарына килү таләп ителми; «Электрон рәвештә күрсәтелгән

хезмәтләр өлеше» 2019 елда 6,3 процент тәшкил итте (2018 ел белән чагыштырганда 3,3 процентка үсеш күзәтелә).

Гамәлдәге закон таләпләрен оптимальләштерү кысаларында 2019 ел дәвамында гамәлдәге административ регламентларга анализ ясалды, процедураларны җайлырак итү буенча тәкъдимнәр тикшерелде һәм гамәлгә кертелә башлады. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (2018 елдан башлап) һәм Түбән Кама муниципаль районы (2019 елдан башлап) башкарма комитетлары «Сакчыл җитештерү» принципларын кулланып муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын анализлау һәм алга таба хезмәт күрсәтү процессын җайлырак итү буенча эш алып бара.

Әлеге эш нәтиҗәсендә 2018 – 2019 елларда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан 180 административ регламент, җирле үзидарә органнары тарафыннан 2 200 дән артык административ регламент актуаль хәлгә китерелде (законнарга үзгәрешләр кертү, хезмәтләр күрсәтүнең аерым процедураларын оптимальләштерү).

Моннан тыш, Татарстан Республикасы федераль законнарны һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә даими рәвештә инвентаризацияләүдә катнаша.

Төзелешкә рөхсәт алу белән бәйле хезмәтләрнең срогын кыскарту өлешендә түбәндәге чаралар күрелде:

Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләре өчен «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү» хезмәтенә гариза бирү мөмкинлеге гамәлгә ашырылды;

Татарстан Республикасында төзелешкә рөхсәт бирү буенча хезмәт күрсәтү 5 эш эчендә башкарыла;

Татарстан Республикасының сынау муниципаль берәмлегендә җир кишәрлегендә шәһәр төзү планын алу өчен гариза бирү мөмкинлеге гамәлгә кертелде;

республика муниципаль берәмлекләре тарафыннан җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү һәм бирү буенча хезмәтләр күрсәтү вакыты 11 эш көненә кадәр кыскартылды (2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча хезмәт күрсәтү срогын 20дән 14 эш көненә кадәр кыскарту каралган);

Проект документларына һәм инженерлык эзләнүләре йомгакларына дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү срогы 21 эш көненнән артмый;

«Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе гариза бирүче белән рәсми сайтында урнаштырылган шәхси кабинет аша үзара бәйләнештә тору юлы белән дәүләт хезмәтләрен электрон рәвештә күрсәтә (шәхси кабинетта эшләү турында видеоролик: http://gosekspertiza-rt.ru/instructions-docs/);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында эшмәкәрләр өчен хезмәт күрсәтү төрен эзләүне гадиләштерү максатыннан чыгып «Бизнес өчен» вкладкасы эшләнгән;

Татарстан Республикасы Инвестицияләр порталында мәйданчыкларны сайлап алу һәм ярдәм чараларын билгеләү буенча онлайн-система эшләнде;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр электрон рәвештә үзлегеңнән хезмәт күрсәтү терминаллары (алга таба – инфоматлар), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (алга таба-Портал), «Услуги РТ» мобиль кушымтасы (iOS һәм Android платформаларында җайланмалар өчен) аша күрсәтелә. Болар смартфоннар аша счет-фактураны электрон рәвештә карау һәм түләү, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафларның булу-булмавын тикшерү һәм аларны түләү, мәктәпкәчә мәгариф учреждениесенә чират статусын тикшерү һәм башка шундый хезмәтләрдән уңайлы итеп һәм тиз файдаланырга мөмкинлек бирә.

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында һәм шәһәр округында (59 офис), шулай ук 1 меңнән артык халкы булган авыл җирлекләрендә (281 территориаль-аерымланган структур бүлекчә) эшләүче офислары челтәре (алга таба – КФҮ ДБУ, КФҮ) үсешен дәвам итә. КФҮнең төп бурычы – халыкка, хакимият органнарына мөрәҗәгать итмичә генә, «бер тәрәзә» принцибы буенча бер урында иң кирәкле хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү.

Республиканың күпфункцияле үзәкләре гариза бирүчеләргә (физик һәм юридик затларга) көн саен 200 дән артык дәүләт һәм муниципаль хезмәт төрен «бер тәрәзә»принцибы буенча тәкъдим итә. Гаризалар кабул итү һәм нәтиҗәләр бирүдән тыш, КФҮ гражданнарга «Скайп» видеосистемасы аша кайбер хакимият органнары (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роспотребнадзор), Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе, «Тикшерелгән бизнес» порталы) консультантлары белән элемтәгә керү мөмкинлеген тәэмин итә.

Хезмәтләр исемлеге даими рәвештә киңәйтелә, күрсәтелгән хезмәтләр саны арта. 2016 елда – 2,7 млн, 2017 елда – 3,4 млн, 2018 елда – 3,7 млн, 2019 елда 4,9 млн берәмлек хезмәт күрсәтелгән.

Гариза бирүчеләргә уңайлы булсын өчен бердәм белешмә хезмәте – КФҮ колл-үзәге (телефон – 222-06-20) эшли, аның аша барлык сораулар буенча (шул исәптән татар телендә) мөрәҗәгать итәргә мөмкин, гариза бирүчеләргә документларның әзерлеге турында смс-мәгълүмат җиткерелә.

Юридик һәм физик затларны индивидуаль эшкуарлар сыйфатында дәүләт теркәве процедурасын һәм срокларын оптимальләштерү максатларында КФҮ ДБУнең Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе белән бу органга документлар тапшыру буенча электрон хезмәттәшлеге гамәлгә ашырылды, бу исә КФҮ ДБУ аша хезмәт күрсәтү срогын 3 көнгә калдырырга (гариза бирүчегә документларны кире кайтару вакытын исәпкә алмыйча), шулай ук документларны курьер тарафыннан җиткерүгә тотылган чыгымнарны янга калдырырга мөмкинлек бирде.

КФҮ ДБУның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы район филиаллары биналарында «Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциячел булмаган оешмасының (алга таба – Фонд) вәкилләре урнашкан, бу исә муниципаль районнардагы эшкуарлык субъектларына Фондтан микрозайм, шулай ук эшкуарлыкка ярдәм итү мәсьәләләре буенча кирәкле консультацияләр алу хезмәтеннән файдаланырга мөмкинлек бирде.

Шулай ук КФҮ офисларында цифрлы нигездә 17 хезмәт күрсәтелә, алар Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә. Әлеге хезмәтләрнең күбесе бизнес эшчәнлегенә турыдан-туры кагыла, мәсәлән, тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү (паспорт), тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле җир эшләрен башкаруга рөхсәтләр (ордерлар) теркәү, рәсмиләштерү, бирү һәм озайту, авыр йөкләрне, зур габаритлы йөкләрне тулысынча яисә өлешчә Казан шәһәре чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар аша узучы маршрутлар буенча ташуга рөхсәт бирү һәм башкалар.

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (алга таба – Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе) хезмәтләре буенча электрон чират терминалларында гариза бирүчегә «Физик зат», «Шәхси эшкуар», «Юридик зат» категориясен сайлап алу мөмкинлеге бирелде. Әлеге инструмент Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсенә кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан килгән гаризаларны (мәгълүмат расланган очракта) кыскартылган срокта карау мөмкинлеге бирә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсендә күчемсез милекне инвестиция проектлары буенча дәүләт теркәве бүлеге оештырылды, аның төп бурычы булып кече һәм урта эшкуарлык субъектларының эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә һәм күчемсез мөлкәт объектларына хокукын дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) дәүләт теркәвен гамәлгә ашыру тора.

Кече һәм урта бизнес субъектлары өчен хокукларны дәүләт теркәве срокларын кыскарту буенча эш башкарылды: Татарстан Республикасы буенча Росреестр Идарәсенең 2009 елның 31 октябрендәге № П/0369 боерыгы нигезендә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының хокукларын һәм алыш-бирешләрен дәүләт теркәвенә алу (өлешләп төзүдә катнашу һәм аның белән бәйле алыш-бирешләрдән тыш) 5 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла (элек 9 эш көне дәвамында иде), бер үк вакытта кадастр исәбенә һәм хокукларны дәүләт теркәвенә алу – 9 эш көненнән дә артык булырга тиеш түгел (элек 12 эш көне иде).

2018 елның 9 гыйнварыннан республикада «Тикшерелгән бизнес» интернет-ресурсы гамәлдә. Портал тикшерүләр узу буенча гамәли тәкъдимнәр бирелгән белемнәр базасы рәвешендә эшләнгән. Порталның эксперт-консультантлары булган бэк-офислары бар, алар эшкуарларны кызыксындырган барлык мәсьәләләр буенча ярдәм күрсәтәләр. 2019 елда 4,5 меңнән артык кече һәм урта эшкуарлык субъектына консультацияләр бирелде.

Портал контрольнең төрле төрләре буенча үзеңне тикшерү өчен электрон чек-листлар белән тулыландырылып тора. Моннан тыш, портал норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү процедураларында катнашу мөмкинлеге бирә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, сайт һәм мобиль кушымталар базасында эшкуарларның хокук саклау һәм күзәтчелек органнары белән элемтәгә керү фактларына кагылышлы мөрәҗәгатьләрен җыю буенча цифрлы платформа эшли. «Тикшерүләрнең электрон журналы» функционалы аша ресурска шулай ук күзәтчелек, хокук саклау һәм башка дәүләт органнары белән үзара бәйләнешнең теләсә нинди очраклары (фотографияләр, видеофайллар, документлар)

материалларын урнаштырырга, экспертларның комментарийларын һәм киңәшләрен алырга мөмкин.

***5. Соңгы 10 елда Татарстан Республикасы икътисадының чималдан алынган керемнәргә бәйле булуын киметү динамикасы нинди?***

Татарстан– Россиянең икътисадый яктан иң алга киткән төбәкләренең берсе. Икътисад өлкәсендә уйланылган сәясәт, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, эшлекле активлыкны стимуллаштыру буенча чаралар күрү республикага үзенең социаль-икътисадый үсешен эзлекле дәвам итәргә мөмкинлек бирә.

Нефть чыгару сәнәгатьнең мөһим тармакларының берсе булып тора, бу исә республикада кирәкле ресурслар булуга бәйле. Шул ук вакытта хәзерге вакытта Татарстан икътисады диверсификацияләнгән. Бүген монда куәтле нефть эшкәртү, нефть, газ, химия производстволары, машина төзелеше, азык-төлек, агач эшкәртү сәнәгате, энергетика һәм башка тармаклар продукциясенең киң спектрын җитештерүче предприятиеләр тупланган.

Нәтиҗәле инвестиция инфраструктурасы формалаштырылган. Махсус икътисадый зоналар, алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре актив үсә, бу шулай ук инновация үсешкә һәм икътисадны алга таба диверсификацияләүгә этәргеч бирә.

Нәтиҗәдә Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты керемнәрендә республика икътисадының нефть чыгару, нефть эшкәртү, нефть химиясе кебек эре компанияләре түләүләренең чагыштырма күләме арта бара. Әйтик, 2010 елда әлеге компанияләрнең Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының салым керемнәре суммасындагы түләүләре 23 процент тәшкил иткән булса, 2018 – 2019 елларда ул 31,5 җитте.

***6. Татарстан Республикасы конкурентлыкка сәләте ягыннан Россия Федерациясендә һәм дөньяда нинди урын тота?***

Татарстан Республикасында Төбәкләрнең инновацион һәм инвестицион үсеше рейтингларында алдынгы урыннарга чыгарга мөмкинлек бирүче карарлар гамәлгә ашырыла.

Татарстан бишенче ел рәттән Россия Федерациясе субъектларында инвестиция климаты торышының илкүләм рейтингы лидерлары өчлегенә керә. 2018 ел йомгаклары буенча Татарстан беренче тапкыр Россиянең инновацион төбәкләре ассоциациясе рейтингында икенче позициягә күтәрелде һәм ассоциациядә катнашучы төбәкләр арасында 1нче урынны саклап калды. Татарстанда эшлеклелек климатын яхшырту, инновацион эшчәнлекне алып бару өчен социаль-икътисадый шартларны ныгыту һәм фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр санын арттыру эше дәвам итә.

AV Group AV RCI – 2019 консалтинг компаниясенең Россия регионнарының конкурентлылык индексы буенча Татарстан Республикасы Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән кала 3 урында тора һәм Россия үсешенә төп өлеш кертүче үсеш полюслары булган төбәкләр исемлегенә керә.

2019 ел йомгаклары буенча Татарстан халыкның тормыш дәрәҗәсе ягыннан РИА-Рейтинг Россия төбәкләре рейтингының лидерлары (Мәскәү шәһәре, Санкт-

Петербург шәһәре, Мәскәү өлкәсе, Татарстан Республикасы) арасына керә. Рейтингның беренче унлыктагы төбәкләренә икътисадый үсешнең югары дәрәҗәсе хас, Россия Федерациясе субъектлары буенча тулаем төбәк продуктының, ваклап сату әйләнеше, төп капиталга инвестицияләрнең 40 проценттан артыгы алар өлешенә туры килә.

Бүгенге көндә дөньяда Россия Федерациясе төбәкләренең конкурентлылык сәләтен бәяләү буенча рейтинглар эшләнмәгән. Шул ук вакытта дөнья рейтингларында Россия Федерациясенең конкуренциягә сәләтлелеге артуын да билгеләп үтәргә кирәк. Doing Business бөтендөнья банкы рейтингында Россия Федерациясе 28 урынны алып тора, ул 2019 елдагы позициясен 2018 ел белән чагыштырганда 3 пунктка яхшыртты (31нче урын).

Татарстан Республикасында үткәрелә торган социаль-икътисадый сәясәт республиканың һәм тулаем илнең, шул исәптән Россия Федерациясе Президентының 2024 елга кадәр ил үсешенең төп стратегик документы булып торган 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы кысаларында илкүләм проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә дә, конкуренциягә сәләтлелеген арттыруга юнәлдерелгән.

***7. «2014-2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновация икътисады» дәүләт программасы кысаларында хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү ничек бара? Югары квалификацияле эш урыннары санын күрсәтергә.***

Хезмәт җитештерүчәнлеге – икътисад үсеше һәм аның конкурентлык сәләтен арттыру резервларының берсе.

Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру бурычы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы (алга таба – ярдәмче программа), шулай ук предприятиеләргә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга этәргеч бирү, артык административ җайга салу киртәләреннән котылуга һәм экспорт потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» илкүләм проекты чаралары кысаларында хәл ителә.

2018 елда икътисадның чимал җитештерелми торган төп тармакларының урта һәм эре предприятиеләрендә (эшкәртү производстволары, транспорт, авыл хуҗалыгы, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык) хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеше республикада 2017 ел белән чагыштырганда 101,7 процент тәшкил итә. 2019 ел йомгаклары буенча күрсәткеч 2020 елның ноябрендә формалаштырылачак.

Куелган максатка ирешү өчен республика компанияләрен хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча чараларны гамәлгә ашыруга җәлеп итү буенча актив эш алып барылды. Бүгенге көндә 75 оешма илкүләм проектта катнаша (2019 елга план – 63 оешма).

Предприятиеләргә хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә федераль һәм төбәк компетенцияләре үзәкләре экспертлары, шулай ук конкурс нигезендә җәлеп ителгән консультантлар түләүсез ярдәм күрсәтә.

«Сакчыл җитештерү» инструментларын куллану нигезләрен өйрәтү өчен проектта катнашучы 884 предприятие хезмәткәрләре өчен уку уздырылды (2019 елга план – 632).

Шулай ук җитештерүчәнлекне үстерүгә юнәлтелгән «Җитештерүчәнлек лидерлары» һәм «Экспорт акселераторы» укыту программаларына җәлеп итү өчен предприятиеләр белән эш алып барылды.

2019 елда «Җитештерүчәнлек лидерлары» программасы буенча 23 предприятиенең 96 хезмәткәре укытылган, яңа уку сезонына 50 дән артык гариза бирелгән.

Республика предприятиеләренең һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең укуларын уңышлы тәмамлаган 11 хезмәткәре Германиягә стажировкага җибәрелде.

«Экспорт акселераторы» программасында 15 предприятие катнаша, аларның 3се экспорт контрактлары төзегән («ЭЙДОС-МЕДИЦИНА» ЖЧЖ, «ТАТПРОФ» АЖ, «Волма-Әбсәләм»ЖЧЖ).

2020 елда ярдәмче программа чараларында катнашу өчен предприятиеләр сайлап алу дәвам итә, ярдәмче программада катнашучы предприятиеләрдә агымнарны җайга салу буенча эш алып барыла.

Шулай ук быел җитештерү һәм офис процессларының тренажерлары, интерактив уку җиһазлары, белән җиһазландырылган укыту-методик сыйныф рәвешендәге процесслар фабрикасы ачу планлаштырыла. Анда проектта катнашучы предприятиеләрнең хезмәткәрләрен укыту эше алып барылачак.

2018 ел йомгаклары буенча республикада югары җитештерүчәнлекле эш урыннары саны 2017 ел белән чагыштырганда 85,8 меңгә арткан һәм 592,1 мең урын тәшкил иткән, шул исәптән бюджеттан тыш секторда – 487 мең. 2019 ел мәгълүматлары статистика органнары тарафыннан быелның апрелендә бастырып чыгарылачак.

***8. Инвестицияләр күләмен күрсәтергә һәм капитал кертүгә ярдәм итү турында закон проектлары пакетын кабул итү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру өчен күздә тотылган инвестиция проектларын санап чыгарга.***

Татарстан Республикасында гомуми суммасы 3,1 трлн сум булган перспектив инвестиция проектлар пулы формалаштырылды, бу исә 64 меңнән артык эш урыны булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Республика икътисадының үсеш локомотивы – гадәттәгечә, нефть, газ, химия комплексы предприятиеләре. Әлеге өлкәдә яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында инвестицияләр күләме 1,5 трлн сумнан артып китә, шул ук вакытта 37 меңнән артык эш урыны булдыру планлаштырыла. «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексын, яңа олефин комплексын һәм «Түбән Кама Нефтехим» ҖАҖнең җитештерү мәйданнарын төзү һәм башка шундыйлар иң мөһим проектлардан санала.

Шулай ук өлкәләрдә яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру планлаштырыла:

машина төзелеше һәм сәнәгатьнең башка эшкәртү тармаклары – гомуми суммасы 339 млрд сумнан артык;

энергетика (340 млрд сумнан артык);

авыл хуҗалыгы (48 млрд. сумнан артык);

транспорт-логистика эшчәнлеге өлкәсендә (731 млрд сумнан артык);

җитештерү һәм инновация инфраструктурасын үстерү («Алабуга» МИЗ, «Иннополис» МИЗ) (якынча 60 млрд сум);

башка тармакларда гомуми сумма 55 млрд сумнан артыграк .

***9. Татарстан Республикасы бюджетының керем базасын арттыру буенча күрелә торган чаралар турында.***

Татарстан Республикасының керем базасын арттыру максатларында түбәндәге чаралар күрелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 апрелендәге 687-р номерлы карары нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үз керемнәре үсешен тәэмин итү буенча ведомствоара комиссиясе эшчәнлеге кысаларында:

ай саен табышка салынган салымның керүен мониторинглау үткәрелә, аның нигезендә узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда түләүләрне киметкән оешмалар ачыклана. Мондый оешмалар исемлеге квартал саен баланс комиссияләре эшчәнлеге кысаларында тиешле эш алып бару, Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнарның кимү сәбәпләрен анализлау өчен, ведомство карамагындагы тармак министрлыкларына җиткерелә. Уртак эш нәтиҗәләре буенча тармак министрлыклары тарафыннан ведомствога караган оешмаларның җитештерү өлкәсендә рентабельлегенә ирешү һәм аларның табыш алу дәрәҗәсенә чыгуы, шулай ук бюджетка түләүләр буенча кичектерелгән бурычларны киметү турында тәкъдимнәр эшләнә;

физик затлар кеременә салым буенча «яшерен түләнә торган» хезмәт хакын легальләштерү, физик затлар кеременнән салым түләүдән «конвертлы» түләү һәм башка схемалар белән «качу» очракларын ачыклау чаралары үткәрелә, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт хакын федераль законда билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән ким булмаган күләмдә түләүне контрольдә тоту гамәлгә ашырыла, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда физик затлар кеременнән салым түләүне киметкән салым түләүчеләрне ачыклау мониторингы үткәрелә;

физик затлар кеременә салымның тулысынча алынуын тәэмин итү максатларында хезмәткә түләү фондына квартал саен мониторинг үткәрелә, шулай ук узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда физик затлар кеременнән салым түләүне киметкән салым түләүчеләр ай саен анализлана;

акцизлар буенча акциз продукциясен төп җитештерүчеләр белән даими рәвештә продукция җитештерү һәм сату күләмнәрен мониторинглау һәм пландагы күрсәткечләргә ирешү буенча эш алып барыла;

салым түләүчеләрдән – физик затлардан салымнарның вакытында керүен тәэмин итү максатыннан чыгып милек салымнарының тулысынча түләнүен тәэмин итү буенча чаралар күрелә. Аларны гамәлгә ашыру кысаларында республиканың эре предприятиеләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча

территориаль органнары, муниципаль берәмлекләр белән закон нигезендә билгеләнгән срокта салым түләү, салым түләүчеләргә – физик затларга салым түләү хәбәрнамәләрен вакытында җиткерү, кредит оешмалары һәм почта бүлекләре белән физик затлардан түләүләрне кабул итүнең өзлексезлеген тәэмин итү буенча эш алып барыла;

салым булмаган табышлар буенча Татарстан Республикасы бюджетына һәм муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларына агымдагы һәм фаразлана торган керемнәргә анализ ясала, керемнәр базасын арттыру һәм түләүләр буенча бурычларны киметү максатларында салым булмаган керемнәр администраторлары белән уртак эш алып барыла;

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны киметү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 июлендәге 1493-р номерлы карары нигезендә төзелгән ведомствоара комиссия эше кысаларында түбәндәге төп юнәлешләр буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

муниципаль берәмлекләр ведомствоара комиссияләренең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре катнашында видеоконференция режимында үткәрелгән киңәшмәләрендә даими рәвештә муниципаль берәмлекләр ведомствоара комиссияләренең эш нәтиҗәләре карала;

Татарстан Республикасының тармак министрлыкларына караган оешмалар белән эш алып барыла;

дәүләт сатып алуларында катнашырга теләүче оешмаларның бурычларын булдырмау буенча эш регламент кысаларында алып барыла;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге максатчан файдаланылмый торган (файдаланылмый торган) җирләрне ачыклау буенча эш алып барыла;

рәсмиләштерелмәгән һәм теркәлмәгән күчемсез милек объектларын, җир кишәрлекләрен дә кертеп, салым әйләнешенә кертү буенча чаралар күрелә.

Республиканың иң эре салым түләүчеләреннән керемнәрне арттыру максатыннан түбәндәге чаралар күрелә:

эре предприятиеләр һәм кече нефть компанияләре бюджетына агымдагы һәм фаразланучы түләүләрне анализлау һәм бәяләү;

республиканың эре салым түләүчеләре белән ведомствоара киңәшмәләр, аларда компанияләр эшчәнлегенең йомгаклары бәяләнә, түләүләр кимү сәбәпләре ачыклана, шулай ук бюджетка түләүләрне арттыру буенча чаралар күрелә;

эре предприятиеләрнең корпоратив идарә итү органнарының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы җитәкчеләре катнашында уздырылган корпоратив утырышларына материаллар әзерләнә;

кече нефть компанияләре җитәкчеләре белән хисап чорындагы эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов рәислегендәге киңәшмәләргә материаллар әзерләнә;

Дәүләт торак фондына түләүләр планын формалаштыру һәм аларның вакытында башкарылуын тәэмин итү буенча эш алып барыла.

Моннан тыш, оешмалар мөлкәтенә салым һәм табышка салым буенча салым ташламаларын бирү өлешендә дәүләт ярдәменә дәгъва итүче инвестиция проектларына, алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары составына кертүгә дәгъва итүче инвестиция эшчәнлеге субъектларының инвестиция проектларына, инвестицияле салым кредитын алуга гариза биргән оешмаларның инвестиция проектларына, сәүдә үткәрмичә арендага җир участогы алуга дәгъва итүче оешмаларның инвестиция проектларына экспертиза үткәрү буенча эш алып барыла.

Шулай ук инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында тиешле шартнамәләр гамәлдә булган чор дәвамында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнар һәм җыемнар түләүне ел саен тәэмин итү буенча йөкләмәләрнең үтәлешен ел саен бәяләү гамәлгә ашырыла.

Республика җитәкчелегенә кабул ителә торган үзгәрешләрнең Татарстан Республикасы икътисады һәм консолидацияләнгән бюджеты өчен ихтимал нәтиҗәләре турында оператив мәгълүмат бирү максатыннан федераль закон проектларын даими рәвештә карап бару эше алып барыла.

2019 елдан «Бизнес алып бару шартларын яхшырту» төбәк проекты кысаларында үзмәшгульләр сыйфатында теркәлү юлы белән гражданнарның үз бизнесларын легальләштерүенә этәргеч бирү каралган (республика «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын гамәлгә ашыру буенча Россиянең 4 пилот төбәге арасына керде).

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында үзмәшгульләр сыйфатында 62 меңнән артык кеше теркәлгән (башка төбәкләрдә теркәлгән, әмма республика территориясендә эшчәнлек алып баручы затларны исәпкә алып). Һөнәри керемгә салым буенча 123,3 млн сум күчерү каралган (шуларның 114 млн сумы түләнгән).

Шулай итеп, республика территориясендә Татарстан Республикасы бюджетының керем базасын арттыруга юнәлдерелгән системалы эш алып барыла.

***10. «Татфондбанк» гавами акционер җәмгыятенә акча салучыларга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында.***

«Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы» дәүләт корпорациясе (алга таба – КИА) 2016 елның 26 декабреннән «Татфондбанк» ГАҖнә акча салучыларга алар күргән зыянны каплау буенча акча түли, әлеге банкка карата 2016 елның 15 декабрендә Россия Банкы тарафыннан банк кредиторларының таләпләрен канәгатьләндерү өчен мораторий кертелгән иде.

2017 елның апрелендә «Татфондбанк» ГАҖ Татарстан Республикасы Арбитраж суды карары нигезендә банкрот дип танылды, конкурс идарәчесе функцияләре КИАга йөкләнде.

Кредит оешмасының кредиторлар алдында бурычы, банк операцияләрен башкаруга лицензияне алу датасына бухгалтерлык балансы мәгълүматлары буенча, 182 млрд сум, тәшкил итә, шул исәптән шуларның 73,2 млрд сумы – физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр кертемнәре буенча.

«Татфондбанк» ГАҖ конкурс производствосы барышы турындагы

белешмәләр нигезендә, 2020 елның 1 гыйнварына «Татфондбанк» ГАҖнең беренче чираттагы кредиторларның таләпләрен канәгатьләндерүгә 28 740,5 млн сум күчерелгән, бу исә беренче чираттагы кредиторлар таләпләренең гомуми суммасының 40,4 процентын тәшкил итә.

Әлеге банкның лицензиясе алыну сәбәпле, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан түбәндәге оешмалар мобильләштерелде: «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» КБО, «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБО һәм «Татарстан Республикасы кече бизнес лизинг компаниясе» ҖЧҖ.

2016 елның 26 декабреннән зыян күргән эшкуарларга ташламалы лизинг һәм махсус программа буенча микрозаймнар бирү механизмнары аша ярдәм итү чаралары гамәлгә ашырыла.

Шулай ук «Сбербанк» ГАҖ, «Ак Барс» Банк ГАҖ, «ВТБ 24» ГАҖ, «Энергобанк» АКБ ГАҖ катнашында кече һәм урта эшкуарлык субъектлары (алга таба – КУЭ) – «Татфондбанк» ГАҖ клиентлары өчен махсус программалар эшләнде.

2020 елның 1 февраленә 425 эшкуарга ярдәм күрсәтелгән, 1 070,3 млн сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелгән. Финанслау чыганаклары булып түбәндәгеләр тора:

ташламалы лизинг өчен – «Татарстан Республикасы кече бизнес лизинг компаниясе» ҖЧҖен 571 млн. сум күләмендә капиталлаштыру;

поручительлекләр өчен - «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБОның үз капиталлаштыруы.

| Күрсәткеч атамасы | Эшмәкәрләргә ярдәм, берәмлек | Күрсәтелгән ярдәм суммасы, - млн сум |
|---|---|---|
| Барлыгы | 425 | 1 070,3 |
| шул исәптән: | | |
| Ташламалы микрозаймнар,<br>шул исәптән:<br>«Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБО поручительлеге | 320<br><br>71 | 499,3<br><br>27,7 |
| Ташламалы лизинг | 105 | 571 |

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән кредит-финанс оешмаларының банкротлыгы нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 29 маендагы ПУ-447 номерлы Указы белән Республика ярдәм фонды (алга таба – РЯФ) төзелде.

Зыян күргән гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен РЯФка милек кертеме сыйфатында Аракчино торак массивы янындагы 759 га мәйдандагы җир кишәрлеге тапшырылды.

Фонд Советы карары нигезендә ярдәм, этапларның һәркайсында затлар категориясен төгәл билгеләп, финанс түләүләре рәвешендә этаплап күрсәтелә дип билгеләнде. Хәзерге вакытта, таләп суммасына карамастан, ярдәм физик һәм

юридик затларга күрсәтелә, түләүләрнең максималь күләме кертем күләменә тигез, әмма ул 500 мең сумнан да артмый.

Ташламалы категориягә кергән гражданнар өчен ярдәм күләме 1 млн. сумга кадәр җиткерелде, әмма ул кертемнәр күләменнән артып китмәскә тиеш.

Шулай ук РЯФ «ТФБ Финанс» ИК» ҖЧҖ эшчәнлегеннән зыян күргән кредиторларга акча түли. 2018 елның 16 ноябренә кадәр судка мөрәҗәгать иткән затлар инвестиция компаниясе реестрына һәм фонд реестрына кертелделәр, алар өчен максималь ярдәм күләме кертем күләменә тиң (ләкин 500 мең сумнан да артык түгел).

2020 елның 18 мартына РЯФка барлыгы 7 590 гариза керде, шул исәптән 4 205е – физик затлардан һәм 3 385е – юридик затлардан.

РЯФ мәгълүматларына караганда, 5 047 клиентка (физик һәм юридик затларга) 1,54 млрд сумлыктан артык, шул исәптән «ТФБ Финанс» ИК» ҖЧҖның 160 кредиторына – 79 млн сумлык ярдәм күрсәтелгән. Гомуми суммасы якынча 2 млрд сум тәшкил иткән 6 030 килешү төзелгән.

«Татфондбанк» ГАҖ, «ИнтехБанк» ГАҖ, «АНКОР БАНК» АҖ, «ТАТАГРОПРОМБАНК» ҖЧҖ һәм «Спурт» АКБ ГАҖ кертемчеләре булган Татарстан Республикасында яшәүчеләр «Сбербанк» ГАҖ, ВТБ банкы (ГАҖ), «Россельхозбанк» АҖ, «ФК Открытие» банкы ГАҖ, «Ак Барс» Банк ГАҖ агентлары аша зарарны каплау өчен 83,8 млрд.сумлык акча алды. Шулай итеп, түләнергә тиешле гомуми сумманың 99,45% ы түләнде. Зыян күргән вкладчыларга акча түләү дәвам итә.

***11. Цифрлы технологияләрне гамәлгә кертүдән Татарстан Республикасында гомуми икътисадый нәтиҗәлелек нинди дәрәҗәдә?***

Республиканың икътисадый үсешенә турыдан-туры йогынты ясый торган мәгълүмати технологияләр цифрлы нигезгә корылган икътисадның төп өлеше булып тора. 2019 елда тармак буенча, тулаем алганда, 73 млрд сумлык керем алынды дип бәяләнә, эш белән тәэмин ителгән кешеләр саны 44 меңнән артып китә.

2019 ел йомгаклары буенча «Россия Федерациясенең цифрлы нигезгә корылган икътисады» илкүләм программасын һәм «Ачык Татарстан» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында бүлеп бирелгән акча күләме 2,2 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 311,1 млн сум. 2020 елга 1,9 млрд сум күләмендә финанслау планлаштырылган, шул исәптән федераль бюджеттан – 357,2 млн сум күләмендә.

Республикада «Россия Федерациясенең цифрлы нигезгә корылган икътисады»илкүләм программасының түбәндәге төбәк проектлары гамәлгә ашырыла.

***«Мәгълүмати инфраструктура» төбәк проекты***

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә җепселле-оптик элемтә линияләре буенча 2019 елга планга кертелгән социаль әһәмияткә ия булган 498 объект тоташтырылды.

Татарстанның социаль әһәмияткә ия объектларын югары тизлекле интернетка тоташтыру буенча өч еллык проекты федераль бюджеттан финансланачак. Моның

өчен контрактны «Таттелеком» ГАҖ белән конкурс нигезендә Россия Федерациясенең Цифрлы нигездә үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы төзеде (1,1 млрд сум).

***«Цифрлы технологияләр» төбәк проекты***

«Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе базасында (алга таба – «ИТ-парк» ДАУ) «Россия Федерациясенең цифрлы нигезгә корылган икътисады» илкүләм программасының «Цифрлы технологияләр» федераль проекты кысаларында финанслау мәсьәләләре буенча координация төркеме төзелде. Финанс ярдәме күрсәтелүчеләргә мәгълүмат бирү алты юнәлеш буенча алып барыла (http://e-digital ктatar/).

Россия Федерациясе субъектларында «үтәли» цифрлы технологияләр базасында булдырылган, илдә җитештерелгән продуктларны, сервисларны һәм платформа чишелешләрен гамәлгә кертү проектларына дәүләт ярдәме күрсәтүгә грантлар бирүгә конкурс нигезендә сайлап алу өчен Татарстан Республикасыннан 21 гариза бирелде, конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча 4 мөрәҗәгать итүчегә грантлар бирү хупланды. Алар түбәндәгеләр:

«Алабуга» СҖТ МИЗ» – АҖ «LPWAN (NB-IoT) чыбыксыз элемтә технологиясе нигезендә су белән тәэмин итү челтәрен цифрлаштыру» проектына – 34,1 млн сум күләмендә;

«Татэнерго» АҖ – «Чыбыксыз элемтә үтәли технологиясе базасында җылылык белән тәэмин итү системасын оператив дистанцион контрольдә тоту системасы торышын мониторинглау системасы» проектына – 13,1 млн. сум күләмендә;

«Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» УК» ҖЧҖ – «Калдыклар җыелу урыннарын тикшереп тору һәм калдыкларны, шул исәптән коммуналь каты калдыкларны (ККК), ташу белән идарә итү өчен программа-аппарат платформасы» проектына – 97,4 млн сум күләмендә;

«КАМАЗ» ГАҖ – «КАМАЗ «ГАҖ җитештерү процесслары белән оператив идарә итү системасы» проектына – 224,1 млн сум күләмендә.

2019 елның 21 – 22 декабрендә «ИТ-парк» ДАУда цифрлы үтәли технологияләр өлкәсендә проектларны тормышка ашыручы технологик стартаплар – Цифрлы өлкәдә чемпионнар мәктәбе өчен интенсив узды https://leader-id.ru/event/38219/. Анда 15 старт-проект катнашты. Асылда әлеге проект преакселерация программасы булып тора, ул технологик стартапларның тизләтелгән үсешенә һәм аларны тормышка ашыруга финанслар җәлеп итүгә этәргеч бирә.

***«Цифрлы нигезгә корылган икътисад өчен кадрлар» төбәк проекты***

Республикада кадрлар әзерләү буенча чаралар уңышлы гамәлгә ашырыла:

хезмәткә сәләтле гражданнарны дәүләттән шәхси цифрлы сертификатлар нигезендә цифрлы нигезгә корылган икътисад компетенцияләренә өйрәтү;

дискрет математика, информатика, цифрлы технологияләрнең алдынгы юнәлешләре буенча мәктәп укучылары өчен сезонлы профильле лагерьларда тематик сменалар оештыру (ел саен);

мәгълүмати технологияләр өлкәсендә уку өчен грантлар бирү (ел саен);

дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең цифрлы технологияләр өлкәсендә грамоталылыгын арттыру (ел саен);

«Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында өлкән яшьтәге гражданнар өчен квалификация күтәрү һәм һөнәри әзерлек.

2019 елда югары белем бирү оешмаларын ИТ-белгечлекләр буенча 1 637 кеше, урта белем бирү оешмаларын 931 кеше тәмамлады.

Өлкән яшьтәге гражданнарның квалификациясен күтәрү һәм аларга һөнәри әзерлек бирү кысаларында «Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында 143 кеше белем алды.

Цифрлы сертификатлар буенча укуга 1000ләп татарстанлы алынган.

Дәүләт хезмәткәрләрен, муниципалитетлар хезмәткәрләрен һәм ведомство карамагындагы оешмалар хезмәткәрләрен «CDO: белешмәләргә нигезләнгән идарә» программасы буенча укыту кысаларында 2 150 кеше, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясенең Казан филиалы программалары буенча 198 кеше курслар узды.

2019 ел дәвамында «ИТ-парк» ДАУ базасында бизнес-инкубаторга һәм «Slush» халыкара стартап-конференциясенә сайлап алулар башкарылды. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм өлкәннәр өчен курслар оештырыла. Хәзерге вакытта «ИТ-парк» ДАУ ИТ-академиясендә өлкәннәр аудиториясе өчен 40 тан артык һәм мәктәп укучылары өчен 15тән белем бирү курсы, шул исәптән «ILand» курсы гамәлгә ашырыла. 2019 елда ИТ-академиядә Казан шәһәрендә 150дән артык бала һәм 235 олы кеше, Чаллы шәһәрендә 290нан артык бала һәм 70 олы кеше белем алды.

Шулай ук ИТ-паркта мәктәп укучылары һәм студентлар өчен «Digital Start» цифрлы нигездә эшкуарлык компетенцияләрен үстерү программасы буенча өйрәтмә ике курсы үткәрелде. 2019 елда белем бирү онлайн-платформасында барлыгы 1 300дән артык кеше теркәлгән, алар арасында 700дән артык мәктәп укучысы һәм студент катнашты. Финалга 34 проект чыкты.

Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә «Кванториум» балалар технопаркларында ел саен 2 140 бала белем ала. 2019 елдан башлап кванториумнар төбәк укытучыларын «Үсеш ноктасы» проекты буенча әзерләүне гамәлгә ашыру мәйданчыгы булып тора.

Казан шәһәренең «IT-cube» балалар үзәгендә 5 – 18 яшьлек 878 бала һәм яшүсмер бушлай белем алды, шулай ук һөнәри юнәлеш бирүче чаралар үткәрелде, аларда бөтен республикадан 1 500 дән артык укучы катнашты.

Бүген «Яндекс.Лицей»проекты (өстәмә белем бирү) кысаларында 448 укучы Python телендә программалаштыруга өйрәнә. 2019 елда 42 укучы 2 еллык курслар тәмамлады.

Мәктәпләрдә шәхси аерым укытуның цифрлы платформасын кертү кысаларында 340 балага әзерлек бирелә. 73 укытучы «Сбербанк» ГАҖ уздырган 4 белем бирү сессиясендә булды, аларга цифрлы платформа белән эшләү буенча яңа компетенцияләр бирелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 14 августындагы 598 номерлы карары нигезендә «Казан (Идел буе) федераль

университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Мәгълүмати технологияләр һәм интеллектуаль системалар югары мәктәбенең 1 – 4 курс студентларына мәгълүмати технологияләр өлкәсендә белем алуга ел саен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты бирелә. Барлыгы 180 млн сумлык 1 902 грант (2019 елда – 185) бирелде.

***12. 2019 елда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының табигый ресурслардан файдаланган өчен түләүләрне администрацияләү буенча бюджет вәкаләтләрен үтәве турында.***

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы Татарстан Республикасы керемнәренең баш администраторы («2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 6 нчы кушымтада каралган вәкаләтләр нигезендә) һәм Татарстан Республикасы җирле бюджетлары керемнәренең баш администраторы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре булган баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 елның 6 июнендәге 449 номерлы карары нигезендә) булып тора һәм Россия Федерациясе бюджет кодексының $160^{1}$ статьясы нигезендә түбәндәге бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

урта срокка каралган бюджет планын һәм (яисә) бюджет проектын төзү өчен кирәкле белешмәләр бирә;

касса планын төзү һәм алып бару өчен белешмәләр бирә;

бюджет керемнәре баш администраторының бюджет хисабын формалаштыра һәм тапшыра;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәренең чыганаклары исемлеге нигезендә аңа беркетелгән керемнәр чыганаклары буенча бюджет керемнәре чыганаклары реестрын алып бара;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән мондый методикага карата гомуми таләпләр нигезендә бюджетка керемнәрне фаразлау методикасын раслый;

исәп-хисапның дөреслегенә, бюджетка акча кертүгә, пеняларга һәм алар буенча штрафларның тулы һәм үз вакытында башкарылуына исәп-хисап ясау, исәпкә алу һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

бюджетка акча кертү, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүне гамәлгә ашыра;

бюджетка, артык түләнгән (түләттерелгән) акчаларны, пеняларны һәм штрафларны кире кайтару, шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентларны кире кайтару турында карар кабул итә һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кире кайтаруны башкару өчен Федераль казначылык органына йөкләмә бирә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына акча түләүне исәпләү (төгәллек кертү) турында карар кабул итә һәм Федераль казначылык органына хәбәрнамә юллый;

бюджетка бурычларны түләттерүне өметсез дип тану турында карар кабул итә һ.б.

2019 елда Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджетына Татарстан Республикасының табигый ресурсларыннан файдаланган өчен 104,1 млн сум (Татарстан Республикасы бюджетына – 46,8 млн сум, җирле бюджетларга – 52,3 млн сум) акча керде, шул исәптән:

Россия Федерациясе территориясендә җир асты байлыкларыннан файдаланганда, лицензиядә әйтелгән билгеле бер вакыйгалар килеп чыкканда, җирле әһәмияткә ия булган җир асты байлыклары кишәрлекләре буенча җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләтелә торган акча – 21,1 млн сум;

файдалы казылма запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияткә ия булган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик, экономик һәм экологик белешмәләргә өчен түләү – 1,7 млн сум;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына конкурста (аукционда) катнашу өчен җыемнар – 0,28 млн сум;

әйләнә -тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелергә тиешле сумма – 23,8 млн сум;

зыянны түләттерүдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан шәһәр округлары бюджетларына күчерелә торган башка төрле керемнәр – 14,02 млн сум;

зыянны түләттерүдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан муниципаль районнар бюджетларына күчерелә башка төрле керемнәр – 43,2 млн.сум.

### *13. Татарстанның туристлар җәлеп итүчәнлеген арттыру чаралары турында.*

Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21июлендәге 522 номерлы карары белән расланган «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстанның туристлар җәлеп итүчәнлеген арттыру буенча чаралар түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

***Туристлык инфраструктурасын һәм сервисларны үстерү***

Туристлык дестинациясе буларак Татарстан Республикасына карата кызыксыну, шул исәптән, биредә зур вакыйгалар уздырылу нәтиҗәсендә формалаша. Фестивальләр, бәйрәмнәр, спорт ярышлары – туристның мәдәни-күңел ачу программасының аерылгысыз өлеше булып тора. Бүген республиканың һәр туристлык үзәгенең үзен танытучы чаралары бар – «Тәмле Казан» һәм «Свияжск ухасы» гастрономия фестивальләре, «Бөек Болгар» урта гасыр көрәше фестивале, Алабуга шәһәрендәге Спас ярминкәсе, Лаеш муниципаль районындагы «Каравон»

халык бәйрәме, Мамадыш шәһәрендәге «Санни фест» креатив чаналар фестивале, Питрәч муниципаль районындагы «Скорлупино» фестивале һәм башкалар.

«Татарстан Республикасының туристлыкны үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы «АК БАРС» БАНКГАҖ белән берлектә «Tatarstan Tourist Pass» мобиль кушымтасы булдырды, биредә туристлар туристлык объектлары, туклану һәм ял итү урыннары турында мәгълүмат табарга, төрле юлкүрсәткечләр һәм маршрутлар белән танышырга була. Кушымтаны Google Play һәм AppStore аша күчереп алырга була. Шулай ук бушлай виртуаль банк картасы эшләп чыгарылды, аның ярдәмендә кулланучылар туристлык инфраструктурасы объектларында ташламалар яки бонуслар алырга мөмкин.

2019 елда республикада туристлык инфраструктураның яңа объектлары ачылды: тарихи һәм архитектура ягыннан әһәмияткә ия бинада «Kazan Palace by Tasigo» кунакханәсе; Болгар шәһәрендә «Вояж» мини-отеле; Раифа монастыреның 400 еллыгына багышланган музей; «Кыш Бабай һәм Кар Кызы резиденциясе» проекты кысаларында «Могҗизалар урманы» борынгы һәм яңа татар әкиятләре интерактив мәйданчыгы; Казан Богородица монастыре каршындагы Казан иконасы музее.

2019 елда Татарстан Республикасы икенче ел рәттән «Россиянең гастрономик туризмы» категориясендә National Geographic Traveler Awards – 2019 конкурсында җиңүче булды. Конкурста җиңүчеләр ачык онлайн-тавыш бирү нәтиҗәсендә билгеләнде.

***Татарстан Республикасының туристлык продукциясен таныту***

2019 елда республиканың туристлык өлкәсендәге мөмкинлекләре 8 зур халыкара туристлык күргәзмәсендә тәкъдим ителде: Matka Nordic Travel Fair (17 – 20 гыйнвар, Хельсинки шәһәре, Финляндия); Tehran International Tourism Exhibition (12 – 15 февраль, Тәһран шәһәре, Иран); «Интурмаркет» (9 – 11 март, Мәскәү шәһәре, Россия); «MITT/ Сәяхәтләр һәм туристлык» (12 – 14 март, Мәскәү шәһәре, Россия); «Җәй» (5 – 6 апрель, Екатеринбург шәһәре, Россия); BITE/ Beijing International Tourism Expo (18 – 20 июнь, Пекин, Кытай), «Ял» (10 – 12 сентябрь, Мәскәү, Россия); Saint Petersburg Travel Hub (11 – 12 сентябрь, Санкт-Петербург шәһәре, Россия). Күргәзмәләрдә республиканың туристлык өлкәсендәге мөмкинлекләре, шул исәптән Свияжск утрау-шәһәре һәм Бөек Болгар турында материал тәкъдим ителде, полиграфия материаллары таратылды, виртуаль чынбарлык форматындагы видеороликлар күрсәтелде, шулай ук презентацияләр күрсәтү ярдәмендә Татарстан Республикасының мәдәни-тарихи мирасы һәм туристлык инфраструктурасы турында доклад ясалды.

Ел дәвамында Россиядә һәм 11 чит илдә туроператорлар һәм журналистлар өчен 16 күчмә презентация һәм роуд-шоу оештырылды.

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм 11 чит илдән 222 туроператор һәм журналист өчен 16 реклама һәм мәгълүмат турлары үткәрелде.

2019 елда туристлык дестинациясе буларак Татарстанны популярлаштыру максаты белән Россия Федерациясендә, Иранда, Төркия һәм Казахстанда 6 реклама кампаниясе эшли башлады.

Ел дәвамында республика һәм Россия Федерациясенең басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында 2 меңгә якын мәкалә басылып чыкты, телеканалларда Татарстанның туристлык өлкәсендәге мөмкинлекләре һәм туристлар җәлеп итүчәнлеге турында 120 сюжет күрсәтелде.

***Туристлык өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек***

Идел буе федераль округының географик, тарихи һәм мәдәни яктан бергәлеге, милли үзенчәлекләре булган, төп сәүдә юлы – Идел елгасы буенда урнашкан төбәкләрен берләштерүче «Бөек Идел юлы» төбәкара проектын үстерү буенча алга таба да эш алып барыла.

Самара – Казан һәм Казан – Самара маршрутлары буенча тагын бер төбәкара «Белем вагоны» проектын тормышка ашыру уңышлы рәвештә дәвам иттерелде, ул поездда барганда мәктәп укучылары өчен белем бирү программалары нигезендә махсуслаштырылган турны һәм Татарстан Республикасы һәм Самара өлкәсе буйлап гаять кызыклы экскурсия программасын үз эченә ала.

***Туристлык өлкәсе өчен кадрлар әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү***

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә республиканың төп туристлык үзәкләрендәге туристлыкны үстерү өлкәсе белгечләре, кунакханәләр һәм рестораннар хезмәткәрләре һәм менеджерлары, экскурсоводлар һәм гид-тәрҗемәчеләр, музей-тыюлык хезмәткәрләре өчен квалификация күтәрү программалары үткәрелә.

***14. Татарстанның туристлык маршрутларына кертү һәм аларны торгызу максатларында Татарстан Республикасы территориясендәге барлык тарихи биналарга инвентаризация үткәрү турында.***

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге объектлар урнашкан:

1) 1 663 мәдәни мирас объекты Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестрына кертелгән, шулардан:

447 – федераль әһәмияткә ия, шул исәптән 281 – археологик мирас объекты;

876 – төбәк әһәмиятенә ия;

340 – җирле (муниципаль) әһәмияткә ия;

2) 3 522 элек билгеле булмаган мәдәни мирас объекты, шулардан:

795 архитектура һәм шәһәр төзелеше объекты, мемориаль һәм тарихи объектлар;

2 727 археологик мирас объекты;

3) 424 тарихи әһәмияткә ия шәһәр төзелеше объекты;

4) 13 тарихи җирлек, аларның:

2 – федераль әһәмияткә ия;

11 – төбәк әһәмиятенә ия;

5) ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектлары:

Казан Кремле тарих-архитектура комплексы;

Болгар тарих-археология комплексы;

Успение соборы һәм Свияжск утрау-шәһәрчеге монастыре.

2019 елда Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклап калу комитеты (алга таба – Комитет) тармакта инвентаризация уздыру буенча алып барылган киң колачлы эшне дәвам итте. Узган ел 372 объект тикшерелде, аларны карап тикшерү һәм техник торышы турында актлар төзелде, 68 саклауга алу йөкләмәсе әзерләнде һәм расланды.

28 объект төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары буларак дәүләт саклавына алынды. 47 объект буенча территорияләрне куллану чикләре һәм режимнары расланды, 344 объект буенча расланган чикләр турында мәгълүматлар, милек хуҗаларына объекттан файдалануга чикләүләр салып, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертелде.

Археология һәйкәлләрен саклау мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә. 2019 елда мәдәни мирас объектлары булып торучы 4 964 күчемсез милек объектына (җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары) анализ уздырылды.

Хуҗалык кулланылышына тапшырылырга тиешле җир мәдәни мирас объектларын саклау шартлары буенча кишәрлекләреннән файдалануга чикләүләр булу турында 1 386 бәяләмә әзерләнде.

Төзелеш эшләре алып барылырга тиешле җир кишәрлекләренә дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза уздырылып, аның йомгаклары буенча 117 акт карап тикшерелде.

2019 елда Болгар шәһәрендә казу эшләре башланып китте. Нәтиҗәдә, Болгар дәүләтенең төзелә башлаган чорына, монголлар яулап алганга кадәрге чор һәм Алтын Урда чорына караган объектлар табылды.

Җир кишәрлекләренә тарихи-мәдәни экспертизалар уздыру һәм фәнни археологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә элек билгеле булмаган 14 археологик мирас объекты ачыкланды һәм дәүләт саклавына алынды. Бу исемлеккә Идел (Бакалда) пристаньларына бара торган 700 метрга якын озынлыктагы таш түшәлгән юл керде, биредә Идел елгасының саегуы нәтиҗәсендә фәнни-архитектура тикшеренүләре алып бару мөмкинлеге туды.

Аксубай муниципаль районында нефтьүткәргеч уздыру планлаштырыла торган участокларны тикшерү барышында археологлар тарафыннан элек билгеле булмаган «X–XIV гасырлар Иске Кыязлы каберлеге» дип аталган объект табылды.

Тарихи мохиттә һәйкәлләрне саклауны тәэмин итүнең мөһим шарты булып, саклау зоналарын билгеләү һәм алар турында мәгълүматларны кадастр исәбенә алу органына кертү тора.

2019 елда Комитет тарафыннан түбәндәге эшләр оештырылды:

Казан шәһәрендә урнашкан объектларны саклау берләштерелгән зонасына төзәтмәләр кертү;

«Казан кремле ансамбле, XVI–XVIII гасырлар» федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектын саклау зоналарының яңа проектын эшләү;

Болгар шәһәре территориясендә объектларны саклау зоналарын эшләү.

Моннан тыш, «Казан Кремле тарих-архитектура комплексы» бөтендөнья мирасы объектының буфер зонасы картасын һәм чикләрен актуальләштерү эше башланды.

Шулай ук 2019 елда Комитет тарафыннан дистәләрчә мәдәни мирас объекты буенча төзекләндерү-реставрация эшләрен документаль һәм методик яктан тәэмин итү буенча эш дәвам иттерелде.

Казан Кремле территориясендә масштаблы эшләр дәвам итте. Аварияне кисәтү буенча эшләр комплексы, шулай ук «Административ биналар һәм консистория, XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башы» объектындагы фасадларны реставрацияләү эшләре башкарылды.

10 ел дәвамында барган реставрация эшләре тәмамланганнан соң быел Свияжск утрау-шәһәрчегендәге Успение соборы ачылды. 2019 елның августында Казан һәм Татарстан митрополиты Феофан катнашында Бөек изгеләндерү тантанасы узды.

2019 елда Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә булышлык итү фонды ярдәме белән Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авылында 1769 елда республикадагы беренче таш мәчеттә реставрация эшләре башланды.

Казан шәһәренең Юдино бистәсендәге Тимерьюлчылар мәдәният сараенда, Сәетгалиев исемендәге Мәдәният сараенда, Алафузов театры бинасында һәм Сандецкий утарында төзекләндерү-реставрация эшләре актив рәвештә дәвам итә. Петропавловск соборында һәм Әҗем мәчетендә реставрация эшләре дәвам итә.

Узган ел М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасы интерьерларын һәм инженерлык системаларын төзекләндерү-реставрация эшләре башкарылды. «Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе биналарында (1900–1904 елларда төзелгән) аварияне кисәтү эшләре башкарылды. күргәзмәсе, Казан укытучылар семинариясе бинасында (1873 елда төзелгән) авариягә каршы беренче чираттагы эшләр башкарылды.

2019 елда язучы Шәриф Камал музее-фатирында урнашкан Татар әдәбияты тарихы музеенда төзекләндерү-реставрация эшләре тәмамланды.

Татарстан Республикасында агач төзелеш сәнгате объектларына аерым игътибар бирелә.

Татарстан Республикасында агач архитектура сәнгате объектларына аерым игътибар бирелә.

2019 елның гыйнварында «Мәчет, XIX гасыр» (Балык Бистәсе муниципаль районы) һәм «Михаил-Архангельск чиркәве, 1757 ел» (Кама Тамагы муниципаль районы) кебек агач архитектурасы уникаль һәйкәлләрендә төзекләндерү-реставрация эшләре башланды. Эшләр Вологда шәһәреннән агач эшләре остасы, архитектор, югары категорияле реставратор Александр Попов җитәкчелегендә алып барыла, ул «Реставрация үзәге – архитектура, җитештерү, укыту» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте  җитәкли. Реставрация эшләре борынгы технологияләр буенча алып барыла, осталар максималь рәвештә барлык элементларның төп нөсхәсен саклап калырга тырыша.

Республикада агач архитектура сәнгатен үстерү темасы, шул исәптән Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан 2019 елның июнендә оештырылган агач архитектура һәйкәлләрен саклау буенча ведомство проектын исәпкә алып, комплекслы рәвештә карала.

2019 елда Комитет тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә «Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектлары» геомәгълүмат

системасын кулланышка кертү буенча эш дәвам иттерелде. 2019 елда Комитет һәм «Татарстан Республикасының мәдәни мирас үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләре тарафыннан «Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектлары» геомәгълүмат системасына 246 археология мирасы объекты, 798 мәдәни мирас объекты (тарихи һәм шәһәр төзелеше һәйкәлләре), 577 мәдәни мирас объекты территориясе һәм Казан шәһәренең тарихи җирлеге чикләре турында белешмәләр кертелде.

Мәдәни мирас объектларының торышына, аларны карап тотуга, саклауга һәм кулланылышына дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү барышында 148 объектка, шул исәптән 32 объектка прокуратура органнары белән бергә урынга барып тикшерү уздырылды.

Мәдәни мирас объектларының торышын контрольдә тоту буенча 59 чара һәм аларны системалы рәвештә күзәтеп тору буенча 81 чара үткәрелде.

Килешенгән һәм фәнни яктан нигезләнгән карарлар кабул итүдә җәмәгатьчелек, фәнни һәм эксперт оешмалары белән хезмәттәшлек мөһим урын алып тора. Шушы максатларда 2019 елның маенда Комитет каршында фәнни-методика советы төзелде, ул фәнни-проект документлары буенча фикер алышу, объектларны дәүләт саклавында булган һәйкәлләр исемлегенә кертү, тарихи җирлекләрне үстерү мәсьәләләрен карап тикшерү мәйданчыгына әверелде. Совет составына 35 абруйлы эксперт, реставраторлар, сәнгать белгечләре, әйдәүче галимнәр һәм белгечләр керә.

Тарихи фактларны һәм вакыйгаларны бергәләп тикшерү һәм бәяләү өчен Комитет тарафыннан Туган якны өйрәнүчеләр һәм тарихчылардан торган эксперт төркеме оештырылды. Уртак эшчәнлекнең төп юнәлешләре булып мәдәни мирас объектларына инвентаризация уздыру һәм аларның исемлеген актуальләштерү, элек билгеле булмаган мәдәни мирас объектларын табу тора.

Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү, аларга мәгълүмат бирү һәм хокукый белемнәрен арттыру, мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә хокукый практика үзенчәлекләрен аңлату максатында Комитет тарафыннан квартал саен мәдәни мирас объектлары милекчеләре һәм арендаторлары белән тармакның иң мөһим мәсьәләләре буенча ачык фикер алышулар үткәрелә.

2019 елның маенда Казан шәһәрендә «Архитектура мирасы – 2019» II Бөтенроссия фестивале узды. Фестивальнең эшлекле программасы 60 тан артык чараны үз эченә алды, аларда Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән 200ләп спикер катнашты.

«Архитектура мирасы – 2019» фестиваленең иң әһәмиятле чараларыннан берсе – Бөтенроссия мәдәни мирас объектларын саклап калу мәсьәләләре буенча фәнни-гамәли конференциясе һәм Бөтенроссия археология фәнни-гамәли семинары. Шулай ук фестиваль кысаларында Россия һәм Греция арасында гомуми мәдәни мирасны саклау, арттыру һәм үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек турында меморандумга кул куелды.

Узган елның шулай ук «Астрономия һәм дөнья мирасы» халыкара форумы да республика өчен әһәмиятле вакыйга булды, ул Германиядән, Грециядән, Болгариядән, Италиядән, Пакистаннан, Монголиядән, шулай ук Беларуссиядән,

Украинадан, Молдовадан, Үзбәкстаннан, Таҗикстаннан, Кыргызстаннан, Әрмәнстаннан һәм башка илләрдән күренекле галимнәр катнашты.

***15. Татарстан Республикасының газ һәм электр хуҗалыгына, киләчәктә хуҗасыз калган объектларны муниципалитетлар һәм махсуслаштырылган оешмалар милкенә тапшыру максатында уздырылган инвентаризациянең тәмамлануы турында.***

Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 20 июнендәге 24868-МР йөкләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан хуҗасыз калган газ белән тәэмин итү объектларын, аларны киләчәктә Татарстан Республикасы милкенә тапшыру һәм махсуслаштырылган оешмаларга беркетү максатында муниципаль берәмлекләр тарафыннан рәсмиләштерү механизмы килешенде.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан «Татарстан Республикасының техник инвентаризацияләү бюросы» АҖ белән берлектә 2014 елның 29 апрелендәге 80 номерлы дәүләт контракты кысаларында 2 741 бердәм җитештерү-технология комплексын дәүләт кадастр исәбенә куелды, эш барышында хуҗасыз калган объектлар да ачыкланды. Бүгенге көндә 2 639 газ белән тәэмин итү объекты хуҗасыз дип исәпкә куелды, шул исәптән 1 571 газ белән тәэмин итү объекты буенча 38 муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль милек хокукын тану буенча чаралар үткәрелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 2455-б номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт милке булып торучы электр челтәре хуҗалыгы объектларын билгеләү тәртибе расланды. 2012–2019 елларда махсуслаштырылган оешма – «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә хуҗалык алып бару хокукында 2 942 электр челтәре хуҗалыгы объекты (һава, кабельле электр тапшыру линияләре, трансформатор, электр бүлү ярдәмче станцияләре, комплект, блок – комплект трансформатор подстанцияләре) беркетелде. Объектларда инвентаризация уздыру һәм аларны дәүләт теркәвенә алу буенча эш дәвам итә.

***16. Европа – Көнбатыш Кытай халыкара транспорт коридорының (ХТК) автомобиль юллары өлешендә Шәле (М-7) – Баулы (М-5) участогында республика территориясе буенча узыны раслау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан башкарылган чаралар турында.***

Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 30 сентябрендәге 2101-р номерлы боерыгы белән 2024 елга кадәрге чорга магистраль инфраструктураны яңарту һәм киңәйтүнең комплекслы планы расланды. Планга 11 федераль проект, шул исәптән «Европа – Көнбатыш Кытай» федераль проекты кертелде.

«Европа – Көнбатыш Кытай» халыкара транспорт маршруты составында Татарстан Республикасы территориясендә М-12 «Мәскәү – Түбән Новгород –

Казан» югары тизлектәге автомобиль юлы төзү планлаштырыла. Әлеге проектны М-12 югары тизлектәге автомобиль юлы төзү хисабына гамәлгә ашыру аны «Европа – Көнбатыш Кытай» халыкара транспорт маршрутының мөстәкыйль юнәлеше буларак республикада төзелеп килүче «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)» автомагистрале участогы белән берләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

***17. Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондын формалаштыру перспективалары турында. Республиканың муниципаль берәмлекләрендә социаль найм буенча торак алуга чиратта торучылар санын күрсәтергә.***

Аның нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наемга алу институты кертелгән «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наемга алу буенча мөнәсәбәтләрне законнар нигезендә җайга салу өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 13-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде.

13-ТРЗ номерлы Закон нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарга түбәндәге очракларда бирелергә мөмкин:

гражданның һәм аның белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының кереме һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтенең бәясе 13-ТРЗ номерлы Законының 5 статьясы нигезендә гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасында күрсәтелгән иң чик күләменнән артмаганда;

граждан «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә аз керемле дип танылмаган һәм аз керемле дип танылу өчен нигезләре булмаганда.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 номерлы карары белән Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе (алга таба – тәртип) расланды. Әлеге Тәртип нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча бирүгә мохтаҗ гражданнар үзләренең яшәү урыннары буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпкә алына.

Барлык муниципаль берәмлекләрдә дә гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча бирүгә мохтаҗ дип тану максатларында гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм

салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасында күрсәтелгән иң чик күләме билгеләнгән.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча 2 812 граждан югарыда күрсәтелгән исәпкә куелды.

Татарстан Республикасы бюджетында социаль файдаланудагы торак фондын формалаштыруга акча каралмаган.

Җирле үзидарә органнарында наем шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ буларак 33 056 граждан исәптә тора (шул исәптән, 4 179 гаилә – күпбалалы, биш һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә өстәмә чаралар алу исемлегенә кертелгән).

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗлар буларак 18 596 гаилә, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча бирүгә мохтаҗ буларак – 5 гаилә исәптә тора. Казан шәһәрендә социаль файдалану фонды юк, муниципаль бюджет акчалары хисабына торак төзелеше алып барылмый. Бушатылган муниципаль торак урыннары гамәлдәге торак турында законнар нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданнарга бирелә, шулай ук суд карарларын үтәүгә җибәрелә.

***18. Тузган һәм авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарны күчерү мәсьәләләрен хәл итү перспективалары турында.***

«Яшәү өчен яраксыз булган торак фондын эзлекле рәвештә киметүне тәэмин итү» федераль проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 29 мартындагы 242 номерлы карары белән 2019–2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасы расланды.

Программа нигезендә Татарстан Республикасында «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды» дәүләт корпорациясе акчалары ярдәмендә 2019–2025 елларда күчерелергә тиешле авария хәлендәге торак фонды мәйданы 21 027,7 кв метр тәшкил итә, шулардан 85 авария хәлендәге йорттан 1 754 кешене күчерергә кирәк.

2019–2020 елларда программаның 2019 елга исәпләнгән этабы гамәлгә ашырыла (Әгерҗе, Актаныш, Арча, Балтач, Алабуга, Зеленодольск, Кукмара, Минзәлә, Саба, Чистай муниципаль районнары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге катнашында). План буенча 2 055,9 кв метр мәйдандагы 56 торак урыннан 200 кеше күчерелергә тиеш. 2020 елның 1 гыйнварына 1 087,2 кв метр мәйдандагы 29 фатирдан 90 кеше күчерелде, яисә 2019 елга исәпләнгән этабының 52,9 проценты.

***19. Бюджет өлкәсе, аеруча югары дәрәҗәдә кадрларга кытлык булган тармаклардагы торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ хезмәткәрләрне аренда торагы яки хезмәт иткән чорда бирелә торган торак белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында.***

Аренда йортлары төзү өлкәсендәге бурыч – югары квалификацияле белгечләрне җәлеп итү өчен шартлар тудыру юнәлешендә махсус икътисадый һәм сәнәгать зоналарын үстерүгә ярдәм итү.

Әлеге төр торак төзүнең төп өлеше «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы аша гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында 2010 елдан 2019 елга кадәр Татарстан Республикасында гомуми мәйданы 177,7 мең кв метр булган 3 124 фатирлы 297 аренда йорты файдалануга тапшырылды, шул исәптән 2019 елда – 23,5 мең кв метр булган 461 фатирлы 73 торак йорт.

2020 елда гомуми мәйданы 8,5 мең кв метр булган 138 фатирлы 71 торак йортны файдалануга тапшыру планлаштырыла. 2020 елның 20 февраленә 807 кв метр мәйдандагы торак йорт файдалануга тапшырылды.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы милкендәге махсуслаштырылган торак фонды составына ятим балалар, эчке эшләр органнары хезмәткәрләре өчен торак йортлар, шулай ук дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында беркетелгән торак йортлар кертелде.

***20. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак урыннары белән тәэмин итү максатларында күреләә торган чаралар турында.***

2007–2012 елларда 733 ятим бала торак сертификатлары алды, 2013–2019 елларда 2 127 ятим бала наем шартнамәләре буенча махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителде.

| Ел | Барлыгы, мең сумнарда | Шул исәптән | | Торак урын белән тәэмин ителгән ятим балалар саны, кеше |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан | федераль бюджеттан | |
| 2013 | 246 028,6 | 173 942,2 | 72 086,4 | 265 |
| 2014 | 317 134,6 | 233 728,2 | 83 406,4 | 309 |
| 2015 | 356 421,4 | 269 811,0 | 86 610,4 | 331 |
| 2016 | 339 182,8 | 288 697,8 | 50 485,0 | 311 |
| 2017 | 346 724,6 | 302 844,0 | 43 880,6 | 305 |
| 2018 | 355 286,2 | 314 957,8 | 40 328,4 | 297 |
| 2019 | 373 231,9 | 328 501,0 | 44 730,9 | 309 |

Ятим балаларның торактан файдалану һәм милек хокукы беркетелгән торак урыннарны саклап калуга; ятим балаларга бирелгән, әмма алар белән төзелгән шартнамә вакытыннан алда туктатылган һәм киләсе чиратта торучыларга тапшырылган торак урыннарны саклап калуга юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру аша бурыч йөкләмәләрен киметү планлаштырыла.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә торакларның сакланышын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга наем шартнамәләре шартларында бирелгән Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары сакланышын тикшерү турында» 2019 елның 18 гыйнварындагы карары бастырып чыгарылды.

Татарстан Республикасының норматив хокукый базасын «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 июлендәге 267-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 1 мартындагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Ятим балаларны торак белән тәэмин итүгә мохтаҗлар исемлегенә кертү (кертүдән баш тарту) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын арттыру максатларында 2018 елның 28 декабрендә «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән документлар кабул итү буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү төзелде. Социаль наем шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондыннан, социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан, социаль файдаланудагы торак фондыннан торак урыннары алуга мохтаҗ ятим балаларны җирле үзидарә органнары тарафыннан яшәү урыны буенча исәпкә алу тәртибе каралган.

2019 елда махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны исәпкә алу максатларында, гражданнарның әлеге категориясе турында белешмәләр Социаль хезмәт күрсәтүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына (3 меңнән артык кеше) кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 3 октябрендәге 888 карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак белән тәэмин итү һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү» дәүләт программасының «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча 2020 елда 600 ятим бала торак белән тәэмин ителәчәк. Бу максатларга 840,7 млн сум акча бүлеп биреләчәк, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан – 794,7 млн сум, федераль бюджеттан – 46 млн сум биреләчәк дип планлаштырыла.

***21. Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләрен инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән чаралар турында.***

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлекләрнең, шул исәптән җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, юынтык суларны агызуны оештыру; территорияне планлаштыру буенча муниципаль берәмлекләрнең генераль планнары

нигезендә әзерләнгән документларны раслау; җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту буенча юл эшчәнлеген алып бару вәкаләтләре билгеләнде.

2020 елның 20 мартына Татарстан Республикасында 35 972 җир кишәрлеге, шул исәптән Казан шәһәрендә – 5 745 җир кишәрлеге уртак өлешле милеккә бирелде. Татарстан Республикасында барлыгы 61 173 күпбалалы гаилә бушлай җир кишәрлеге алу хокукына ия, шулардан 56 165 гаиләе җир кишәрлекләре алу исемлегенә кертелде.

Муниципаль берәмлекләр мәгълүматлары буенча җир кишәрлекләре инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин ителгән (күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү буенча ярдәм чараларын тормышка ашыруның бар чорында арта бара), шул исәптән:

электр энергиясе тапшыру линияләре белән – 18 317 участок;

су белән тәэмин итү – 7 909 участок;

газ белән тәэмин итү – 5 611 участок;

асфальт юллар белән – 1 304 участок;

грунт юллары белән – 26 174 участок.

Җирле үзидарә органнары зур шәһәрләрдә җир кишәрлекләрен, аларны алга таба күпбалалы гаиләләргә тапшыру максатында торак пунктлар чикләренә кертү буенча эш алып бара.

Хәзерге вакытта күпбалалы гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләрен, инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итүгә аерым программа буенча акча бүлеп бирү каралмаганга күрә, аларны инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин итүнең бердәнбер мөмкинлеге – муниципаль берәмлекләрне кирәкле челтәрләр белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика программаларына кертү.

*Су белән тәэмин итү*

Ел саен, муниципаль берәмлекләр гаризалары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы торак пунктларында халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү объектлары исемлеге төзелә.

Чараларны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы кысаларында «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасы буенча гамәлгә ашырыла. Объектлар исемлеген формалаштыру белән Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы шөгыльләнә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы урамнардагы суүткәргеч челтәрләр төзүгә чыгымнарны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» яңа дәүләт программасы кысаларында федераль бюджеттан финанслау лимитларына кертү турында тәкъдимнәр әзерли.

*Электр энергиясе белән тәэмин итү*

Электр энергиясе белән тәэмин итүгә гариза бирүчеләрнең электр энергиясен белән кабул итү җайланмаларына технологик тоташтыру Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары белән расланган технологик тоташтыру кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла. Җир кишәрлекләре милекчеләре гаризалары һәм технологик тоташуны гамәлгә ашыру буенча төзелгән шартнамәләр нигезендә кирәкле чаралар комплексы тормышка ашырыла.

Чараларны үтәү вакыты һәр гариза бирүче өчен шәхсән билгеләнә һәм «Челтәр компаниясе» ААҖ тарафыннан тәэмин ителергә тиешле электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзүнең күләменә карап, шартнамә төзегәннән көннән 4 айдан алып 6 айга кадәр булырга мөмкин. Шул ук вакытта «Челтәр компаниясе» ААҖ тарафыннан шартнамәләрне үтәү максатларында барлык кирәкле чаралар комплексы гариза бирүченең җир кишәрлеге чикләренә кадәр җиткерелә.

Әлеге шартнамәләрне төзү өчен җир кишәрлекләре милекчеләренә теләсә нинди уңайлы ысул белән технологик тоташтыру өчен гаризалар белән «Челтәр компаниясе» ААҖ адресына мөрәҗәгать итәргә кирәк: компаниянең кулланучыларга хезмәт күрсәтү буенча теләсә-кайсы офисында, читтән торып почта аша яки компаниянең рәсми сайтында www.gridcom-rt.ru кулланучының шәхси кабинеты аша. Шәхси кабинетны куллану өстенлекле булып тора, чөнки ул гариза бирүчеләргә компания офисларына бармыйча гына хезмәт күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итә.

*Газ белән тәэмин итү*

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга махсус өстәмәләр кулланудан алынган акчалар хисабына финанслана торган Татарстан Республикасын газлаштыру чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру буенча җаваплы башкаручы итеп билгеләнде. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 693 номерлы карары белән Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибе (алга таба – Тәртип) расланды.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Тәртип нигезендә чираттагы елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планына кертү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тәкъдимнәре нигезендә объектларның җыелма исемлеге төзелде. «2020 елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 13 сентябрендәге 829 номерлы карары белән 2020 елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планы расланды.

2020 елга чаралар планы республиканың 19 муниципаль районында күпбалалы гаиләләргә бүлеп бирелгән җир кишәрлекләрен газ белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән 21 объект буенча проект-тикшеренү эшләрен башкаруны үз эченә ала. Аның нигезендә газлаштыру нәтиҗәләре буенча 8 000 җир кишәрлеген (яңа объектларның гомуми саныннан 90 проценты) газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) мөмкин булачак.

Әлеге эш 2021 елда һәм алдагы елларда «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ газ бүлү челтәренең техник мөмкинлеге булганда һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 22 августындагы 693 номерлы карары нигезендә тапшырылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тәкъдимнәре нигезендә дәвам итәчәк.

Шулай ук Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» яңа дәүләт программасы кысаларында федераль бюджеттан финанслау лимитларына урам газ челтәрләрен төзүгә чыгымнарны кертү буенча тәкъдимнәр әзерләнә.

*Юл хуҗалыгы*

Транспорт инфраструктурасы өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында республикада «2014–2024 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы гамәлдә, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 20 декабрендәге 1012 номерлы карары белән расланган, дәүләт заказчысы – координаторы булып Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тора.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күпбалалы гражданнарга бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренең транспорт инфраструктурасы белән тәэмин итүгә булган ихтыяҗына анализ ясалды.

Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга бүлеп бирелә торган участокларга килү юлларында гомуми суммасы 7 828,8 млн сумга 756,7 км юл төзү таләп ителә, шул исәптән асфальт-бетон өслекле юллар төзү таләп ителә торган юллар – 2 394,7 млн сумга 117,4 км һәм 5 434,1 млн сумга вак таш-ком катнашмасы җәю ярдәмендә юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү таләп ителә торган юллар – 639,3 км. Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә килү юлларын төзүне финанслау чыганагы билгеләнмәгән.

***22. Казан шәһәрендә балалар өчен күппрофильле хастаханәсе һәм «Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең икенче чиратын төзү перспективалары турында (балалар корпусын төзү).***

Казан шәһәренең «1 номерлы шәһәр балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе 1958 һәм 1983 елларда төзелгән биналарда урнашкан, гомуми мәйданы 5 616,1 кв метр. Биналар мәйданы һәм бүлмәләрнең торышы буенча заманча санитария-эпидемиология таләпләренә җавап бирми, шуңа да медицина ярдәме күрсәтүдә зур кыенлыклар килеп чыга, ә бу исә пациентлар тарафыннан канәгатьсезлек туугa сәбәпче була.

Әлеге проблеманың чишелеше булып хастаханәнең яңа бинасын төзү тора. Бу сабыйлар һәм балалар арасында үлүчеләр санын, авырулар санын киметергә, шулай ук балаларга медицина ярдәме күрсәтү мөмкинлеген арттырырга ярдәм бирәчәк. Яңа балалар хастаханәсе төзүнең проект идеясе Казан шәһәрендә яшәүче барлык балалар

өчен күппрофильле үзәк төзүдән гыйбарәт. Дәвалауның барлык кирәкле профильләрен, шул исәптән кичектергесез һәм ашыгыч медицина ярдәмен күрсәтүне, шулай ук балаларның сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга юнәлдерелгән яңа технологияләрне, дәвалауның реабилитацион алымнарын үстерү күздә тотыла.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан әлеге объект Казан шәһәренең Яңа Савиново районындагы Х.Ямашев проспектында урнашкан 3,5 гектар мәйдандагы буш җир кишәрлегендә төзү планлаштырыла, кадастр номеры – 16:50:000000:19081. Казан шәһәренең «1 номерлы шәһәр балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасын төзү объектының проект-смета документларын эшләү якынча 87 150 мең сум тәшкил итә. Финанслау чыганагы билгеләнмәгән.

«Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасы Казан шәһәренең Җиңү Проспекты урамы 83 йорт адресы буенча, проектның беренче чираты буларак, 2006 елда файдалануга тапшырылды. Әлеге учреждение территориясендә кирәкле барлык инженерлык коммуникацияләре, ярдәмче хезмәтләр бар, алар хастаханәнең икенче чиратын төзүне исәпкә алып проектланган һәм төзелгән. Проектның икенче чиратын тормышка ашыру кысаларында гомуми мәйданы 8 мең кв метр булган 150 урынга исәпләнгән балалар корпусы төзү планлаштырыла. Төзелеш өчен җир участогы хастаханәнең төп корпусы янында бүлеп бирелгән.

Татарстан Республикасы «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештерү фирмасы дәүләт унитар предприятиесе мәгълүматларына караганда, «Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 чиратын төзү» объекты буенча проект-тикшеренү эшләрен эшләү якынча 40 299 мең сум тәшкил итәчәк. Финанслау чыганагы билгеләнмәгән.

***23. Түбәндәге категория гражданнарны дарулар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирү чаралары турында:***

***- сирәк (орфан) авырулардан интегүче гражданнарны;***

***- төбәктәге дарулардан ташламалы кулланучыларны, онкологик авырулар, шикәрле диабеты, бронхиаль астма ачыклану белән бәйле рәвештә аларның саны арта.***

2012 елдан башлап Татарстан Республикасында орфан авырулары булган кешеләрнең федераль регистрының төбәк сегментын алып бару оештырылды. 2020 елның 1 февраленә 650 кешедә орфан авырулар ачыкланган (2009 елның 1 гыйнварыннан федераль дәрәҗәгә күчкән авыруларны, шул исәптән 292 баланы исәпкә алып). Югарыда күрсәтелгән авыруларны исәпкә алмыйча, регистрга 575 кеше кертелгән, шуларның 238е – балалар.

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сирәк (орфан) авырулары булган гражданнарны дару белән тәэмин итү вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарына беркетелгән.

Күрсәтелгән чыгымнар тиешле керем чыганаклары билгеләнмәгән хәлдә Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә тапшырылган.

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 299-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2009 елның 1 гыйнварында орфан авырулары булган кешеләрне (гемолитика-уремия синдромы, I, II, VI типтагы мукополисахаридоз, системалы төстә башланган яшүсмерләр артриты) дәвалауны оештыру чыгымнарын финанслау вәкаләтләре федераль дәрәҗәгә тапшырылды.

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 452-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеле булмаган апластик анемия, II (фибриноген) VII (лабиль), X (Стюарт-Прауэра) факторларының нәселдән күчә торган дефициты кебек орфан авырулары булган кешеләрне дәвалауны оештыру чыгымнарын финанслау вәкаләтләре шулай ук федераль дәрәҗәгә тапшырылды.

2020 елга орфан авырулары булган кешеләрне ташламалы рәвештә дарулар белән тәэмин итүне оештыруга якынча финанслау күләме 775,28 млн сум тәшкил итә (федераль дәрәҗәгә тапшырылган 5 авырудан башка). 2020 елда 199,68 млн сум күләмендә акча бүлеп бирү планлаштырыла, акча дефициты 575,6 млн сум тәшкил итә.

Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 23 июлендәге 1427-Пр номерлы йөкләмәләр исемлеге нигезендә Россия Федерациясе субъектларына ташламалы препаратларның төбәк исемлеген тормыш өчен өчен кирәкле һәм мөһим булган дарулар исемлеге дәрәҗәсенә җиткерү зарур.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча 2020 елга расланган тормыш өчен кирәкле һәм мөһим булган дарулар исемлеге дәрәҗәсенә җиткерү өчен, стационар шартларда кулланыла торган препаратлардан тыш, өстәмә 3,62 млрд сум акча таләп ителә.

***24. Перспективалар турында:***

***- офтальмология үзәген төзү (2018 елның октябренә 16911 кеше катарактаны дәвалау операциясенә чиратта тора, 2884 кешегә операция ясалды);***

***- начар ишетүче балалар өчен махсуслаштырылган тернәкләндерү үзәге ачу;***

***- сурдолог-белгечләрне һөнәри яңадан әзерләү һәм әзерләү факультетын ачу;***

***- балаларга югары технологияле операцияләр ясау, шул исәптән һәр биш ел саен алыштырылырга тиешле сөйләм процессорын алыштыру буенча түләүсез ярдәм күрсәтү;***

***- Татарстан Республикасыннан читтә һәм чит илләрдәге клиникаларда операция ясатуга мохтаҗ балаларга операция уздыру өчен финанслауны арттыру;***

***- онкологик авыруларны, алар дару белән тәэмин итүгә акча бүлеп бирүне килештерү процедураларын узган чорда, кыйбатлы, тормыш өчен кирәкле препаратлар белән тәэмин итүгә, шулай ук табиб билгеләгән, әмма тормыш***

***өчен кирәкле препаратлар исемлегенә кертелмәгән кыйбатлы препаратлар белән тәэмин итүне финанслауга акча бүлеп бирү.***

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясендә Казан шәһәренең Бутлеров урамы 14 нче йорт адресы буенча консультацияләр бирү поликлиникасының 4 катлы яңа корпусын төзү планлаштырыла. Поликлиниканы төзү халыкның амбулатория шартларында консультацияләр алу мөмкинлеген арттырырга, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне оештырырга, авыруларны амбулатор звенодан стационарга күчерү эшен гадиләштерергә, шулай ук өлкән яшьтәге авыруларны ерак арага (700 метр) йөртүне чикләү мөмкинлек бирәчәк. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең поликлиника бинасын төзү» объекты буенча проект-тикшеренү эшләренең якынча бәясе 10 760,5 мең сум тәшкил итә. Финанслау чыганагы билгеләнмәгән.

Татарстан Республикасында балаларга сурдология ярдәме күрсәтү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сурдология-оториноларингология профиле буенча халыкка медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 9 апрелендәге 178н номерлы карары, «Кохлеар имплантация системасының сөйләм процессорын алыштыруга мохтаҗ пациентларның кохлеар имплантациядән соң нейросенсор яктан икеъяклы ишетү сәләтен югалткан очракта махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү стандартын раслау турында» 2014 елның 17 сентябрендәге 526н номерлы карары, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сурдология – оториноларингология» юнәлеше буенча балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру» 2015 елның 14 октябрендәге 2136 номерлы карары нигезендә оештырыла.

«Сурдология-оториноларингология» юнәлеше буенча балаларга махсуслаштырылган медицина-санитария ярдәме «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы консультацияләр бирү поликлиникасының сурдология һәм колак протезлары бүлеге һәм Чаллы шәһәренең «Ишетү сәләтен торгызу үзәге» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе базасында күрсәтелә.

Икеъяклы сенсоневраль ишетү сәләтен югалткан һәм саңгырау (кохлеар имплантация) балаларга консультация һәм хирургия ярдәме түбәндәге федераль үзәкләр базасында күрсәтелә:

«Федераль медицина-биология агентлыгының Россия аудиология һәм колак протезлары фәнни-клиника үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе, Мәскәү шәһәре;

«Федераль медицина-биология агентлыгының Оторинолорингология милли медицина тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе, Мәскәү шәһәре;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Санкт-Петербург колак, тамак, борын һәм сөйләм авырулары фәнни-тикшеренү институты» федераль дәүләт бюджет учреждениесе;

«Федераль медицина-биология агентлыгының Л.Г. Соколов исемендәге 122 номерлы клиник хастаханәсе» федераль дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе, Санкт-Петербург шәһәре.

Имплантлар куелган балаларны реабилитацияләү эше Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының Троицк шәһәрендә урнашкан реабилитация үзәге (начар ишетүче балалар өчен) федераль дәүләт бюджет учреждениесендә гамәлгә ашырыла.

Республикада ел саен аудиологик скрининг нәтиҗәләре буенча 30га якын нейросенсор яктан ишетү сәләтен югалткан бала ачыклана, аларга федераль бюджет акчалары хисабыннан югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү кысаларында федераль үзәкләрдә кохлеар имплантация үткәрелә. Бер кохлеар имплантация системасының бәясе 1,5 – 1,6 млн сум тәшкил итә. 2019 елда 27 сөйләм процессоры алмаштырылды.

2015 елдан башлап федераль үзәкләрдә мәҗбүри медицина иминиятләштерүе федераль фонды акчалары хисабына, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары аша файдалану срогы тәмамлаганнан соң кохлеар имплантация системасының сөйләм процессорлары алыштырыла. Бер сөйләм процессорының бәясе 500 меңнән 700 мең сумга кадәр тәшкил итә.

2019 елда 27сөйләм процессоры алмаштырылды. 2020 елда 58 баланы федераль медицина учреждениеләренә сөйләм процессорларын алмаштыру өчен җибәрү планлаштырыла.

Татарстан Республикасында берьяклы ишетү сәләтен югалткан 320 бала, икеъяклы хроник ишетү сәләтен югалткан 1 424 бала диспансер исәбендә тора, шуларның 340 бала югары дәрәҗәдә ишетү сәләтен югалткан (III – IV дәрәҗә ишетү сәләтен югалткан һәм саңгырау) дип һәм инвалид балалар дип танылды. Начар ишетүче балаларның барысы да сурдопедагогик ярдәмгә, махсуслаштырылган белем бирү учреждениеләрендә укуга һәм даими рәвештә медицина ярдәменә мохтаҗ.

Хәзерге вакытта 297 бала кохлеар имплантация системаларыннан файдалана, шуларның 58енә бинаураль рәвештә имплантант куелган. Кохлеар имплантация уздыру өчен федераль медицина учреждениеләренә җибәрүгә 38 бала чиратта тора, шуларның 24 е – икенче колагына операция үткәрү өчен.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең сурдология һәм колак протезлары бүлеге булган күппрофильле клиникада авыруларны карау һәм диагностикалауга башка белгечләрне (невролог, эндокринолог, окулист, теш казнасы-бит хирургы һ.б.) җәлеп итәргә, функциональ, рентген, магнит-резонанс тикшеренүләре үткәрергә, тәүлек дәвамында эшли торган һәм көндезге стационарлар шартларында дәваланырга, медикаментлар ярдәмендә йоклатып, тикшеренүләр үткәрү мөмкинлеге бар.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика блалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре) һәм «Ишетү сәләтен торгызу үзәге» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау

учреждениесе (Чаллы шәһәре) базасында начар ишетүче балалар өчен реабилитация үзәге (алга таба – үзәк) оештыру начар ишетүче балаларга, шул исәптән кохлеар имплантация уздырылган балаларга медицина-психология-педагогика ягыннан реабилитация узу мөмкинлеге бирә.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы сурдология һәм колак протезлары бүлеге (Казан шәһәре) һәм «Ишетү сәләтен торгызу үзәге» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (Чаллы шәһәре) базасында үзәк оештыру өчен һәм өстәмә рәвештә җиһазлар белән (якынча 15 млн сумга) тәэмин итү, өстәмә 26 штат берәмлеге (табиблар, шәфкать туташлары, логопедлар, дефектологлар һәм башкалар) бүлеп бирү кирәк.

«Сурдология – оториноларингология» белгечлеге буенча һөнәри яктан яңадан әзерләү факультетын ачу мәсьәләсе буенча: Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры мәгълүматлары буенча белем бирү учреждениесе базасында бюджеттан тыш нигездә «Сурдология – оториноларингология» белгечлеге буенча һөнәри яктан яңадан әзерләү циклын оештыру мөмкин.

***25. Эшсез калган гражданнарны эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар турында. Вакытлыча эшсез калган гражданнарны социаль яклау чаралары турында.***

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча актив сәясәтне тормышка ашыру – эш белән тәэмин итү хезмәте органнары алдына куелган төп бурычларның берсе.

Татарстан Республикасында эшсез калган гражданнарны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү чаралары «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү»д әүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм  эш бирүчеләрнең эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына буш эш урыннары турында бирелгән мәгълүматы, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү буенча махсус программалар (җәмәгать эшләре, вакытлыча эшкә урнашу һ.б.) кысаларында гражданнарны эшкә урнаштыру ярдәмендә башкарыла.

2019 елда халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына үзләре өчен кулай булган эш эзләп 63,2 мең кеше мөрәҗәгать иткән, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары ярдәме белән 37,2 мең кеше (мөрәҗәгать итүчеләрнең 59 проценты) эшкә урнаштырылган.

Эшләмәүче һәм эшсез калган гражданнар өчен эш эзләү чорында республиканың халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан эшкә урнашу теләген саклап калу (эшкә урнашу теләге уяту), билгеле бер эшне башкару өчен күнекмәләр алу, билгеле бер очракларда эш урынын саклап калу мөмкинлеге бирүче халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү программалары тормышка ашырыла.

2019 елда актив программаларны гамәлгә ашыру халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнарга түбәндәге мөмкинлекләрне бирде:

түләүле җәмәгать эшләрендә катнашу (8 720 кеше);

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарны, урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эш эзләүче гражданнарны (1 295 кеше) вакытлыча эшкә урнаштыру программаларында катнашу;

эшкә җәлеп итү (укудан бушаган 14 яшьтән алып 18 яшькәчә 15 809 балигъ булмаган граждан вакытлыча эшкә урнаштырылды);

эшкуарлык өлкәсенә җәлеп итү (1 406 эшсез калган гражданга үзмәшгульлек мәсьәләләре буенча оештыру-консультация хезмәтләре күрсәтелде, шулардан 415 эшсез граждан эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү һәм тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләү турында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре белән төзелгән килешүләр нигезендә салым органнарында эшмәкәрлек эшчәнлеген теркәде).

Гражданнарның аерым категорияләрен (эшләмәүче инвалидларны, белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарны, күпбалалы ата-аналарны һәм инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарны) эшкә урнаштыру мөмкинлеген арттыру максатларында әлеге категория гражданнарны эшкә алу өчен эш бирүчеләрне стимуллаштыру механизмнары карала. Ел саен Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге юнәлешләргә 41 млн сумнан артык акча бүлеп бирелә.

Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте башкарма органнарының игътибар үзәгендә инвалидларның социаль һәм хезмәт реабилитациясенә һәм аларны җәмгыятькә интеграцияләүгә булган хокукларын тормышка ашыру мәсьәләләре тора.

«Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасында 2019 елның декабрендә эшкә яраклы инвалидларның саны 87,1 мең кеше тәшкил итте, шулардан 26,7 мең кеше (30,7%) эшли, 60,4 мең кеше (69,3%) эшләми.

Республикада инвалидларны хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итү буенча системалы эш алып барыла. Хәзерге вакытта барлык халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшкә урнаштыруга мохтаҗлар инвалидларны шәхси исәпкә алу формалаштырылган. Эшкә урнашырга теләк белдерүче сораштырылган һәр инвалидның «паспорт»ы булдырылган. Һәр инвалид белән эшкә урнаштыру буенча шәхсән эш алып барыла. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының боерыгы нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре җитәкчеләренә инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә максатчан күрсәткечләр җиткерелгән. Билгеләнгән күрсәткечләрнең үтәлешен даими контрольдә тоту гамәлгә ашырыла.

2019 елда халыкны эш белән тәэмин үзәкләренә эш эзләүдә ярдәм сорап 3 578 инвалид мөрәҗәгать иткән, 1 753 кеше эшкә урнаштырылган. Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарда каралган барлык механизмнар да файдаланылды (буш вакансияләргә эшкә урнашу, җәмәгать эшләре һәм вакытлы эшләр, үзмәшгульлек, һөнәри белем алу).

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять чагыштырмача тотрыклы дип бәяләнә.

2020 елның 1 февраленә халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә 11 466 кеше эшсез сыйфатында теркәлгән, шуларның 9 503е эшсезлек буенча пособие ала. Татарстан Республикасында эшсезлекнең гомуми дәрәҗәсе 3,3 процент тәшкил итте, республикадагы эшләүчеләр кешеләрнең гомуми санында теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе – 0,56 процент.

Эшсезлек буенча пособие билгеләү тәртибе, күләме һәм сроклары «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән билгеләнә.

Эшсезлек буенча пособиенең минималь һәм максималь күләме ел саен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елга эшсезлек буенча пособиенең минималь һәм максималь күләмнәре турында» 2020 елның 27 мартындагы 346 номерлы карары белән эшсезлек буенча пособиенең минималь күләме 1 500 сум, максималь күләме 12 130 сум күләмендә билгеләнде.

Эшсез калган гражданнарга социаль түләүләрне финанс ягыннан тәэмин итү Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

***26. Бала карау буенча пособиене Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталы аша рәсмиләштерү мөмкинлегенең перспективалары турында.***

Дәүләт хезмәтләрен алу механизмын кулланучы гражданнар өлеше 70 процент булырга тиеш дип билгеләнгән Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы кысаларында «Электрон хөкүмәт» ресурсы һәм шуның нәтиҗәсендә социаль өлкәдә хезмәт күрсәтүләр дә өзлексез үсештә.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең, өйдән чыкмыйча гына, социаль әһәмиятле хезмәтләр алу мөмкинлеге бар. Бу белгечләр эшенең нәтиҗәлелеген арттырырга, гражданнарның тагын бер кат кирәкле белешмәләр тапшыру өчен социаль яклау территориаль органнарына бару ихтыяҗын киметү һәм, нәтиҗә буларак, социаль яклау бүлекчәләрендә чиратны бетерү мөмкинлеген бирә.

«Тулысынча электрон рәвештә хезмәт күрсәтү» өчен гражданга Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (алга таба – ТР Дәүләт хезмәтләре порталы) гариза бирергә кирәк, социаль яклау хезмәткәрләре кирәкле мәгълүматларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша ала, карар турында мөрәҗәгать итүче шулай ук ТР Дәүләт хезмәтләре порталы аша белә, уңай хәл иткән очракта акчалата түләүләр рәвешендә социаль ярдәм чаралары гариза биргәндә күрсәтелгән счетка күчерелә.

Татарстан Республикасында уздырылган анализ нәтиҗәләре буенча 2015 елдан 2018 елга кадәр электрон рәвешкә күчерелгән иң кирәкле хезмәтләр билгеләнде.

Социаль яклау өлкәсендә 8 хезмәт тулысынча электрон рәвешкә күчерелде:

мәктәпкәчә белем бирү өчен төп компенсация билгеләү;

мәктәпкәчә белем бирү өчен өстәмә компенсация билгеләү;

балага айлык пособие билгеләү;

пенсионерларга транспортта йөрү өчен айлык акчалата түләү билгеләү;

күпбалалы гаиләләрдән укучыларга транспортта йөрү өчен айлык субсидия билгеләү;

18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләргә субсидияләр-ташламалар билгеләү;

күпбалалы гаиләләргә дарулар өчен субсидияләр билгеләү;

инвалидларга торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләргә субсидияләр-ташламалар билгеләү.

5 хезмәт буенча ТР Дәүләт хезмәтләре порталы ярдәмендә электрон рәвештә гаризалар бирү гамәлгә ашырылган, анда гариза бирүче сканер аша күчерелгән документларны теркәп бирергә һәм алга таба социаль яклау органнына шәхси мөрәҗәгать итәргә һәм документларның оригиналларын күрсәтергә тиеш була;

торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләргә субсидияләр билгеләү;

гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләргә субсидияләр-ташламалар билгеләү;

бала карау буенча 1,5 яшькә кадәр айлык пособие билгеләүгә гариза бирү;

бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү өчен гариза бирү;

оешмаларның бетерелүенә бәйле рәвештә эштән азат ителгән хатын-кызларга йөклелек һәм бала табу буенча пособиене билгеләү өчен гариза бирү.

Шулай ук ТР Дәүләт хезмәтләре порталында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә түбәндәге дәүләт хезмәтләрен алуга электрон рәвештә гариза белән мөрәҗәгать итү мөмкинлеге булдырылды:

хезмәт базарындагы вазгыять турында мәгълүмат;

гражданнарга үзләре өчен кулай эш табарга ярдәм итү;

эш бирүчеләргә үзләренә туры килә торган хезмәткәрләр сайлауда ярдәм итү;

Татарстан Республикасында эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлау, эшкә урнашу, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

вакытлыча эшкә урнашуны оештыру;

түләүле җәмәгать эшләрен оештыру;

эшсез гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү, шул исәптән башка җирдә белем бирүне дә кертеп;

эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә ярдәм итү.

2019 ел йомгаклары буенча социаль яклау органнарына бирелгән 1,7 млн гаризаның 1,5 млны электрон рәвештә, граждан шәхси катнашыннан башка бирелгән.

Шулай итеп, бүгенге көндә ТР Дәүләт хезмәтләре порталында баланы карау буенча айлык пособие билгеләү өчен гаризалар бирү мөмкинлеге гамәлгә ашырылган инде. 2019 елда әлеге хезмәт буенча 12 248 граждан мөрәҗәгать иткән, шуларның 24 проценты – электрон рәвештә.

***27. Инвалидлар, балалар коляскаларын йөртүче җәяүлеләр өчен уңайлы мохит булдыру турында. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле җәяүлеләрнең тоткарлыксыз хәрәкәт итүен тәэмин итү максатыннан юлларны һәм тротуарларны инвентаризацияләү турында.***

2015 елдан башлап Россия Федерациясенең «Уңайлы мохит» дәүләт программасы кысаларында җәяүлеләр өчен җир өсте һәм җир асты чыгу юлларын инвалидларга җайлаштыру буенча чаралар үткәрүгә финанслар каралмаган. Хәзерге вакытта Россия Федерациясенең «Уңайлы мохит» дәүләт программасы буенча чыгымнарны уртак финанслауга федераль бюджеттан субсидия Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы линиясе буенча гына бирелә, биредә мәгариф объектларын инвалидларга җайлаштыру эшләрен башкаруга җаваплы орган булып Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тора.

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (билгеләнгән вәкаләтләр өлкәсендә), оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмалар инвалидларга (кресло-коляскаларда һәм юл күрсәтүче этләр ярдәмендә хәрәкәт итүче) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларына (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналарына, корылмаларга, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмаларда урнашкан биналарны да кертеп), ил итү урыннарына тотрыксыз рәвештә керү алуын һәм алар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итә. Әлеге максатларда медицина-социаль экспертиза учреждениеләре һәм башка оешмалар хезмәткәрләрен инвалидларга хезмәт күрсәтү һәм хезмәт күрсәтү объектларыннан файдалана алуын тәэмин итү һәм тиешле ярдәмне оештыру мәсьәләләре буенча укыту өчен методик кулланма (инструкцияләр бирү) нигезендә оешмаларның җаваплы хезмәткәрләренә инструктаж уздырыла. Әлеге кулланма Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы сайтында урнаштырылган.

***28. Җәмәгать транспортында йөрү өчен айлык акчалата түләү алучы пенсионерлар санын арттыру максатларында пенсионерларның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләү параметрларына төзәтмәләр кертү перспективалары турында.***

***Мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, пенсионерларга аерым социаль ярдәм чаралары күрсәтү шартлары билгеләнгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турынд» 2019 елның 7 мартындагы 163 номерлы карары үз көченә кергәннән соң экономияләнгән акчалар нинди максатларга юнәлдерелде?***

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^{3-1}$ статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары

Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары хисабыннан гражданнарның аерым категорияләре өчен, шул исәптән законнарда һәм Россия Федерациясе субъектының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мохтаҗ булу критерийларыннан чыгып, федераль законнарда күрсәтелгән хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына карамастан, социаль ярдәмнең өстәмә чараларын билгеләргә хокуклы.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары нигезендә Россия Федерациясенең һәм (яисә) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга транспортта йөрү өчен айлык акчалата түләү (алга таба – транспортта йөрү өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) билгеләнде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге 1662-р номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең озак вакытка исәпләнгән социаль-икътисадый үсеш концепциясе нигезендә социаль ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән мохтаҗ гражданнарны тикшерү процедураларын камилләштерү юлы белән дә, каралган, юлда йөрү өчен бер тапкыр бирелә торган акчалар гариза бирү датасына уртача айлык кереме 25 мең сумнан артмаган пенсионерларга бирелә.

2019 елның 1 апреленнән юлда йөрү өчен айлык акчалата түләү билгеләгәндә пенсионерларның «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе исәпкә алына.

2019 елда кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, 101 921 кешенең юлда йөрү өчен бердәм айлык социаль билет алу хокукы бетерелгән, бу юлда йөрү өчен бердәм айлык социаль билет алучыларның 16,2 проценты (629 142 кеше), яисә Татарстан Республикасы пенсионерларының гомуми саныннан 9 проценты (1,13 млн кеше) тәшкил итә.

Шул ук вакытта транспортта йөрү өчен бердәм социаль билет (транспорт картасын) алу хокукын югалткан гражданнарның 505 сум торучы шәһәр транспортының барлык төрләрендә йөрү хокукы бирүче бердәм социаль билеты (транспорт картасы) алуга хокукы саклана, ул 2 500 сум торучы гадәти транспортта йөрү билеты бәясеннән шактый түбәнрәк бәядә.

2019 елда транспортта йөрү өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүгә каралган акчалардан экономияләнгән акчалар 306,3 млн сум тәшкил итте, шул исәптән мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпкә алуны кертү хисабыннан – 208,8 млн сум.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында 280,4 мең кеше яши, аларның 85 проценты – балалы гаиләләр.

2020 елда мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпкә алу кертелүгә бәйле рәвештә аз керемле гаиләләрнең керем дәрәҗәсен арттыруга түбәндәге чаралар юнәлдерелгән:

5 һәм аннан да күбрәк балалы, кереме яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләргә айлык пособие бирү – елына 223,5 млн сум;

3 һәм аннан да күбрәк балалы, кереме яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләрне балалар бакчасы өчен түләүдән азат итү – елына 44,7 млн сум;

кереме яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләрдәге 3 яшькә кадәрге балалар өчен даруларга электрон сертификат кертү;

даими рәвештә карауга мохтаҗ инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә пособие күләмен арттыру – елына 2,9 млн сум.

***29. Инвалид балалар, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм ВИЧ-инфекцияле балалар ялын оештыру чаралары турында.***

«2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019 – 2022 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру» ярдәмче программасы кысаларында үз-үзенә хезмәт күрсәтергә сәләтле инвалид балаларның ялын (махсус сменаларда да, индивидуаль рәвештә дә) оештыру өчен шартлар тудырылган.

«Дәүләтнең аерым кайгыртуына мохтаҗлар» категориясе буенча программа кысаларында инвалид балалар файдалана ала торган шифаханә һәм балалар сәламәтләндерү учреждениеләренә юлламаларның гомуми массивы якынча 14 мең тәшкил итә.

2019 елда, ихтыяҗны раслый торган заявкаларны исәпкә алып, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 1 009 бала (балалар церебраль параличы, сенсор (ишетү һәм күрү) җитешсезлекләре булган, интеллекты бозылган, шикәр диабеты белән авыручылар, аутист балалар, шикәр диабеты белән авыручылар) өчен махсус сменалар үткәрелде, шул исәптән:

Кара диңгез буенда – 225 кеше (шулардан 199 аутист бала);

шикәр диабеты белән авыручылар – 50 кеше;

«ана һәм бала» юлламалары буенча өлкәннәр озатып йөрүендә балалар церебраль параличы булган 50 бала;

сенсор (ишетү һәм күрү) җитешсезлекләре булган 188 бала;

интеллекты тоткарланган 170 бала;

үз-үзенә хезмәт күрсәтергә сәләтле 326 инвалид бала ял итте.

Тормышта авыр хәлдә калган балалар, инвалид балалар (үз-үзенә хезмәт күрсәтергә сәләтле) ялын оештыруның гамәлдәге механизмнары махсус сменаларны да, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы линиясе буенча шифаханә сменаларын да үткәрергә мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта ВИЧ-инфекцияле балалар өчен махсуслаштырылган сменалар оештырылмый, чөнки әлеге категориядәге балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерү өчен заявкалар юк.

***30. Татарстан Республикасында "сугыш чоры балалары"на социаль ярдәм күрсәтү чараларын оештыру перспективалары турында, шул исәптән:***

***– "сугыш чоры балалары" статусын билгеләү;***

***– "сугыш чоры балалары" дигән ташламалы категорияне сан ягыннан билгеләү;***

***– Россия Федерациясенең башка субъектлары тәҗрибәсен исәпкә алып, "сугыш чоры балалары"на ярдәм күрсәтүнең мөмкин булган чаралары;***

***– әлеге категориядәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслауның якынча күләме.***

Хәзерге вакытта федераль законнар белән дә, Татарстан Республикасы законнары белән дә «сугыш чоры балалары»на социаль ярдәм күрсәтү чаралары каралмаган. Шуның белән бергә, Бөек Ватан сугышы чорында балигъ булмаган өлкән буын гражданнарының күбесе федераль законнар яки Татарстан Республикасы законнары белән гражданнарның нинди дә булса ташламалы категориясенә (инвалидлар; тыл хезмәтчәннәре; «Блокадалы Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар; үлгән (һәлак булган) сугыш инвалидларының һәм анда катнашучыларның гаилә әгъзалары; акланган гражданнар һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнар; Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затлар; хезмәт ветераннары) кертелгән һәм законнарда каралган социаль ярдәм күрсәтү чараларыннан файдалана.

***31.* Мәктәп укучыларын һәм студентларны җәмәгать транспортында йөрү өчен ташламалы билетлар белән тәэмин итү мәсьәләсен уңай хәл итү перспективалары турында.**

Татарстан Республикасында студентлар өчен юл йөрү билетларын гамәлгә кертү турындагы тәкъдимнәрне эшләгәндә, республика бюджетының финанс мөмкинлекләреннән чыгып, мохтаҗ белем алучыларга ярдәм күрсәтү чаралары каралды.

2019 елның гыйнварында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан «Транспорт гранты» проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул ителде, анда бюджет субсидияләре күләмен елына 30 млн сумнан 60 млн сумга кадәр арттыру һәм белем алучыларга адреслы ярдәм күрсәтү өчен грант алучылар санын арттыру каралды. 2019 елда көндезге уку формасы буенча белем алучы һәм гаиләнең җан башына уртача кереме 20 мең сумнан кимрәк булган 5 792 кеше транспорт гранты алды. «Транспорт гранты» проектында Татарстан Республикасында 127 белем бирү оешмасы катнашты.

***32.* Ярдәмче персоналның хезмәт өчен түләвен республиканыкын яки муниципальнекен тәшкил иткән өлешкә күчерү өлешендә финанслау чыганаклары буенча (Татарстан Республикасы бюджеты – муниципаль бюджет – ата-аналар түләве) мәктәпкәчә балалар учреж-дениесендә баланы карап тоткан өчен түләү структурасын үзгәртү (бала җитди сәбәп аркасында балалар бакчасына йөрмәгән очракта, бу ата-ана түләвен гамәлдән чыгаруга мөмкинлек бирәчәк) перспективалары турында.**

**Баланы җитди сәбәп аркасында балалар бакчасына йөртмәгән очракта, ата-ана түләвен гамәлдән чыгаруның башка вариантлары турында.**

Республиканың мәктәпкәчә оешмаларында тәрбияләнүчеләрне караштырып тору һәм карау буенча хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү буенча, ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу буенча методик тәкъдимнамәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү

оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2009 елның 2 июлендәге 546 номерлы карары белән расланган.

Баланың белем бирү учреждениесенә йөрүе өчен ата-ана түләве, тәрбияләнүче балалар бакчасында булмаган очракта, туклану чыгымнары күләменә генә киметелергә мөмкин. Тәрбияләнүчеләрне караштырып тору һәм карау буенча хезмәт күрсәткәндә балалар бакчасы күтәрә торган башка чыгымнарның күләме (хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәте өчен түләү, тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш һәм санитария-гигиена хезмәте күрсәтүне оештыру, хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алу) фактта төркемдә булучы балалар санына бәйле түгел. Шуңа күрә күрсәтелгән чыгымнар даими күләмдә, ягъни абонент түләве сыйфатында ата-ана түләве күләменә кертелгән. Бу карар Татарстан Республикасы Югары судының 2014 елның 29 декабрендәге 3-110/2014 номерлы һәм Россия Федерациясе Югары судының 2015 елның 22 апрелендәге 11-АПГ15-4 номерлы карарлары белән килештерелә.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Россия Федерациясендә мәгариф турындагы закон) нигезендә инвалид балалар, туберкулез интоксикациясе булган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар ата-ана түләвеннән азат ителгән. Татарстан Республикасында өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләр өчен ата-ана түләвенең күләме билгеләнгән ата-ана түләвеннән 50 процент тәшкил итә.

Үз керемен бәйсез рәвештә, гражданнар Россия Федерациясендә мәгариф турындагы закон нигезендә беренче бала өчен ата-ана түләвенең бер өлешен – балалар бакчаларында ата-ана түләвенең уртача күләменнән 20 процент күләмендә; икенче бала өчен – 50 процент күләмендә; өченче һәм аннан соңгы балалар өчен – 70 процент күләмендә компенсацияләүгә хокуклы.

Татарстан Республикасында 2014 елның 1 гыйнварыннан муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә бер гаилә әгъзасына 20 мең сумнан кимрәк керемнәре булган гаиләләргә балалар бакчаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү билгеләнде.

Гаиләнең бер әгъзасына яшәү минимумыннан түбәнрәк керемнәре булган күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында 2020 елның 1 гыйнварыннан фактта кертелгән ата-ана түләвеннән чыгымнарны кире кайтару буенча 100 процент күләмендә компенсация билгеләнгән.

***33. Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклануга тәэмин итүгә айлык акчалата түләүләр күләмен арттыруга юнәлдерелгән чаралар турында.***

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итүгә 2020 елда бер укучыга көн саен 7 сум 70 тиен тәшкил иткән социаль ярдәм чарасы күрсәтелә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2009 елның 28 августындагы 724 номерлы карары).

***34. Физик культура һәм спортны үстерү һәм финанслау турында. Барлык яшь төркемнәре өчен бюджет (гражданнар өчен бушлай) спорт секцияләре санын арттыру мөмкинлеге турында.***

Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерүгә зур игътибар бирелә. Ел саен яңа спорт корылмалары файдалануга тапшырыла, яңа спорт мәктәпләре ачыла. Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының физик культура һәм спортны үстерүгә юнәлдерелгән чыгымнары ел саен төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт, яңа челтәр ачу хисабына гына түгел, ә массакүләм спортка һәм югары казанышлар спортына чыгымнарны арттыру хисабына да арта.

2012 – 2019 елларга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының физик культура һәм спортны үстерүгә чыгымнары

| Еллар | Чыгымнар суммасы, мең сум | Искәрмә |
|---|---|---|
| 2012 | 14 829 547,5 | Казан шәһәрендәге 2013 елгы Бөтендөнья җәйге универсиаданы оештыру һәм үткәрү чыгымнары исәпкә алынды |
| 2013 | 9 041 895,9 | |
| 2014 | 4 059 986,9 | |
| 2015 | 4 615 420,2 | |
| 2016 | 5 661 740,5 | |
| 2017 | 10 565 366,1 | 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын оештыру һәм уздыру чыгымнары исәпкә алынды |
| 2018 | 7 882 616,7 | |
| 2019 | 8 108 859,1 (оператив мәгълүматлар) | WorldSkillds оештыру һәм үткәрү чыгымнары исәпкә алынды |
| Барлыгы | 64 765 432,9 | |

Спорт буенча сәләтле балаларны ачыклауга һәм Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең җыелма командалары составына кирәргә сәләтле спортчыларны әзерләүгә юнәлдерелгән физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүнең массакүләм булуын арттыру буенча эш алып барыла.

Спорт мәктәпләре саны 2012 елда 162дән 2019 елда 170 кә кадәр артты, яңа спорт мәктәпләрен ачу һәм спортның кулланышта булган һәм яңа төрләрен популярлаштыру спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүчеләр санын арттыруга китерде, соңгы сигез ел эчендә бюджет нигезендә шөгыльләнүчеләр саны 7 422 тәрбияләнүчегә артты.

| | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Спорт мәктәпләре | 162 | 163 | 163 | 169 | 171 | 172 | 170 | 170 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| саны | | | | | | | | |
| Шөгыльләнүчеләр саны | 90 300 | 88 436 | 85 793 | 87 907 | 86 700 | 90 659 | 91 401 | 90 750 |
| шулардан бюджет нигезендә | 80 519 | 79 144 | 84 284 | 85 391 | 83 003 | 85 502 | 86 421 | 87 941 |

Бүгенге көндә барлык спорт корылмалары максималь дәрәҗәдә тулы күләмдә эшли һәм нәтиҗәле файдаланыла. Спорт мәктәпләрен яңа спорт объектларына күчерү процессы гамәлгә ашырыла.

Рентабельлек дәрәҗәсенә ирешү һәм спорт мәктәпләре һәм спорт объектлары персоналына эш хакын арттыру максатларында ел саен дәүләт һәм муниципаль спорт мәктәпләренең (объектларның) бюджеттан тыш керемнәре дәрәҗәсе билгеләнә.

Әлеге максатларны үтәү өчен, бюджет төркемнәренең дәресләре кысаларыннан тыш, гамәлгә куючыларның карары буенча ташламалы нигездә объектлар төрле категориядәге гражданнарга (студентларга, күпбалалыларга, азкеремле гражданнарга, пенсионерларга һ.б.) бирелә. Спорт объектларында өстәмә рәвештә даими нигездә төрле муниципаль, республика һәм бөтенроссия ярышлары уздырыла.

Шуның белән бергә, халыкның барлык яшь төркемнәре өчен бюджет (гражданнар өчен бушлай) спорт секцияләрен арттыру мәсьәләсе бүгенге көндә гамәлдәге региональ норматив актлар кысаларында кала. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары белән муниципаль районнар һәм шәһәр округлары өчен гомуми белем бирү оешмаларында белем алучылар санының 120 проценты күләмендә балаларга өстәмә белем бирү, спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итүнең норматив дәрәҗәсе (гомуми белем бирү оешмалары түгәрәкләрендә шөгыльләнүчеләрне исәпкә алып) билгеләнгән.

Яңа спорт төркемнәрен туплау фактта җәлеп итүнең норматив җәлеп итүдән артып китүгә китерәчәк. Моннан тыш, яңа спорт төркемнәрен һәм секцияләрне ачу өчен тренер ставкалары кирәк, аларны кертү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан өстәмә финанс чаралары кирәк булачак.

***35. Шәһәр мәктәпләрендә спорт залларына капиталь ремонт ясау чараларын финанслау максатларында аерым дәүләт максатчан программасын (яки ярдәмче программасын) эшләү перспективалары турында.***

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларының спорт залларын ремонтлау авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча «Һәр баланың уңышы» федераль

проектын гамәлгә ашыру кысаларында башкарыла. Объектлар исемлеге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре заявкалары буенча төзелә.

Шулай итеп, 2019 елда әлеге чаралар кысаларында авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 6 спорт залын ремонтлау гамәлгә ашырылды.

Моннан тыш, Татарстан Республикасында ел саен белем бирү оешмаларын капиталь ремонтлау программасы тормышка ашырыла. Программа объектлары исемлеге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре заявкалары буенча төзелә. Ихтыяҗ булган очракта, һәм муниципаль берәмлекнең карары буенча программаны тормышка ашыру кысаларында гомуми белем бирү оешмаларының спорт залларына расланган эш төрләре кысаларында ремонт ясалырга мөмкин.

***36. Гомуми белем бирү оешмаларында азык-төлек блокларын модернизацияләү (җиһазларны алыштыру яки яңалары белән җиһазландыру) һәм ашханәләрне реконструкцияләү (утырту урыннарын арттыру максатларында) өчен күрелә торган чаралар турында.***

Татарстан Республикасында 1 402 гомуми белем бирү оешмасы бар, аларда 1 763 азык-төлек блогы: 1 383 чимал азык-төлек блогы; 239 азык-төлекне әзерләп бетерү блогы; 141 буфет-тарату (әзер азыкны тарату) бүлмәсе.

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча бүгенге көндә 158 азык-төлек блогы, шуларның 88ендә – азык-төлек блогы урыннары җитәрлек булмау, 67сендә – технологик җиһазлар җитәрлек санда булмау, 3есендә – җиһазлар тузган булу буенча (80 проценттан артыграк) заман таләпләренә туры килми.

Шул ук вакытта, ихтыяҗ булган очракта, һәм муниципаль берәмлекнең карары буенча гомуми белем бирү оешмаларының азык-төлек блокларын ремонтлау белем бирү оешмаларын капиталь ремонтлау республика программасы кысаларында расланган эш төрләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Программа объектлары исемлеге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре заявкалары буенча төзелә.

***37. Татарстан Республикасының югары уку йортларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында гражданнарның түбәндәге аерым категорияләре өчен бюджет урыннары бирү программасын гамәлгә ашыру мөмкинлекләре һәм сроклары турында:***

***– 25 яшькә кадәрге ялгыз аналар;***

***– инвалид балалар тәрбияләүче аналар;***

***– авыл җирлегендә яшәүче күпбалалы аналар;***

***– авыл җирлегендә яшәүче һәм үз-үзен эш белән тәэмин итүче итеп теркәлгән аналар.***

Әгәр дә граждан урта һөнәри белем дәрәҗәсендәге белемне беренче тапкыр алса, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Россия Федерациясендә мәгариф турындагы закон) 5 статьясындагы 3 өлеше нигезендә урта һөнәри белем алу һәркем өчен мөмкин һәм түләүсез булуы гарантияләнә.

Урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укырга кабул итү һәркем өчен мөмкин булып тора (укырга керүчеләрдән билгеле бер иҗади сәләтләре, физик һәм (яки) психологик сыйфатлары булуын таләп итә торган һөнәрләр һәм белгечлекләр буенча укырга кабул итүдән тыш) (Россия Федерациясендә мәгариф турындагы законның 68 статьясындагы 4 өлеше).

Керүчеләр саны финанслар белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гамәлгә ашырыла торган урыннар санынннан артып киткән очракта, белем бирү оешмасы керүчеләр тарафыннан тапшырылган белем алу турындагы документларда һәм (яки) квалификация турындагы документларда күрсәтелгән төп гомуми яки урта гомуми белем бирү программасының мәгариф программаларын керүчеләр үзләштерү нәтиҗәләре, индивидуаль казанышлар нәтиҗәләре (алар турындагы мәгълүматларны керүче кабул иткәндә хокуклы тапшырырга), шулай ук оешмалар белән максатчан укыту турында шартнамәләр нигезендә урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча укырга кабул итүне гамәлгә ашыра.

Россия Федерациясендә мәгариф турындагы закон кабул ителгәндә махсус ташламалар каралмый, барлык категориядәге укучылар урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча гомуми тәртиптә укырга кабул ителә.

Хәзерге вакытта югары белем бирүче мәгариф программалары буенча укырга керү мәсьәләләре, бакалавриат программалары һәм специалитет программалары буенча укырга кабул итүне оештыруга карата гомуми таләпләр, шулай ук бакалавриат программалары һәм специалитет программалары буенча укырга кабул иткәндә махсус хокуклар Россия Федерациясендә мәгариф турындагы законның 70, 71 статьялары һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары, программалары, магистратура программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2015 елның 14 октябрендәге 1147 номерлы боерыгы белән җайга салына.

Федераль норматив хокукый җайга салу нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә (25 яшькә кадәрге ялгыз аналар; инвалид балалар тәрбияләүче аналар; авыл җирлегендә яшәүче күпбалалы аналар; авыл җирлегендә яшәүче һәм үз-үзен эш белән тәэмин итүче итеп теркәлгән аналар) югары белем бирү программалары буенча укырга кергәндә ташламалар каралмаган.

Шул ук вакытта әлеге категориядәге халыкны югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары һәм специалитет программалары буенча укырга кабул иткәндә махсус хокуклар бирелә алган гражданнар исемлегенә кертү максатларында федераль үзәккә тиешле законнар чыгару инициативасын җибәрү тәкъдим ителә.

***38. Россия Федерациясе Президентының 2020 елда сәнгать мәктәпләрен, музыка һәм рәсем сәнгате мәктәпләрен ремонтлау өлешендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасын гамәлгә ашыру һәм алдагы елларга планнар турында, шулай ук башка мәдәният учреждениеләрен һәм***

***гомуми белем бирү оешмаларын, шул исәптән "Үсеш нокталары" белем бирү үзәкләрен заманча җиһазлар белән җиһазландыру перспективалары турында.***

Балалар сәнгать мәктәпләрен капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 2020 елның 15 гыйнварындагы йөкләмәләр исемлеге (4 пунктның «з» пунктчасы) нигезендә балалар музыка сәнгать мәктәпләрен капиталь ремонтлауны, реконструкцияләнүне һәм җиһазландыруны Россия Федерациясе субъектлары белән финанслашу шартларында финанслар белән тәэмин итү буенча чаралар күрергә кирәк.

2020 елның гыйнварында Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2020 – 2022 елларга капиталь ремонт һәм реконструкция ясау чараларын тормышка ашыру өчен заявка документларын җыю турындагы соравы буенча 14 балалар сәнгать мәктәбенә капиталь ремонт ясау буенча тәкъдимнәр җибәрелде. 2020 – 2022 елларга 14 объект өчен кирәк булган финанслауның гомуми күләме 522 020,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджеттан – 303 466,6 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 218 553,5 мең сум (2020 елга – 10 учреждение; 2021 – 2022 елларга – 4 учреждение).

Хәзерге вакытта Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан 2020 елда капиталь ремонт чараларын гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан 250,7 млн сум (58 процент) күләмендә финанслашу хисабыннан 10 балалар сәнгать мәктәбенә ярдәм күрсәтелде (Татарстан Республикасы бюджетыннан ихтыяҗ 181,6 млн сум (42 процент) тәшкил итә).

Моннан тыш, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасындагы килешү (2009 елның 11 февралендәге 054-09-2019-135 номерлы килешү, 2019 елның 15 декабрендәге 054-09-2019-135/2 номерлы өстәмә килешү) нигезендә 2020 елда мәдәният өлкәсендә 14 мәгариф учреждениесен (сәнгать төрләре буенча балалар сәнгать мәктәпләрен һәм училищеларны) гомуми суммасы 106,38 млн сум тәшкил иткән музыка уен кораллары, җиһазлар һәм уку материаллары белән тәэмин итү каралган, шулардан 61,7 млн сумы – федераль бюджет акчасы исәбеннән, 44,68 млн сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән.

2022 елга шундый ук схема буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тагын 14 балалар сәнгать мәктәбен җиһазландыру каралган.

***39. Мәдәният өлкәсендә эш хакын арттыру перспективалары турында.***

Татарстан Республикасының мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 413 номерлы карары (алга таба – 413 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) белән расланган. Эш хакы окладтан, стимуллаштыручы һәм компенсация түләүләреннән тора.

Мәдәният хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча база окладлары Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген

раслау турында» 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы боерыгы («Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация тасвирнамәләре» бүлеге) нигезендә билгеләнде.

Татарстан Республикасында мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең эш хакы күләме тиешле стимуллаштыручы түләүләрне билгеләү юлы белән эшнең стажына, квалификациягә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына һәм сыйфатына бәйле.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Мәдәният хезмәткәрләре һөнәр берлекләренең Татарстан республика комитеты белән берлектә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 413 номерлы карарына түбәндәгеләр өлешендә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне хәл итә:

һөнәри стандартлары эшләнгән мәдәният хезмәткәрләре вазыйфалары өчен дифференциацияләнгән окладлар билгеләү (хәзерге вакытта «мәдәният һәм сәнгать» тармагы буенча һөнәри стандартлар 8 вазыйфа буенча гына эшләнгән);

дәүләт бүләкләре булган өчен компенсация түләүләре күләмен арттыру;

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә профиль буенча эш стажына өстәмә түләүләр билгеләү;

практик эштә чит телләрне кулланган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләү.

***40. Юлларда юл-транспорт һәлакәтләре һәм үлүчеләр санын киметү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.***

«2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасы, шулай ук «2013 – 2020 елларга юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы кысаларында «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы чаралары комплексын гамәлгә ашыру республика юлларында юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү һәм алар салган зыяннарны минимальләштерү буенча уңай динамиканы саклап калырга мөмкинлек бирде.

Соңгы 10 елда республика юлларындагы юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны 2 тапкырга диярлек кимеде (2009 елда – 689 кеше, 2019 елда – 369 кеше). Шул ук вакытта күрсәткечнең кимү динамикасы – ул Идел буе федераль округында һәм тулаем Россия буенча иң югары күрсәткечләрнең берсе булып тора.

2019 елда Татарстан Республикасы юлларында 4 525 юл-транспорт һәлакәте теркәлде, аларда 369 кеше һәлак булды һәм 5 600 кеше җәрәхәтләр алды (күрсәткечнең фаразлана торган мәгънәсе – 528 кеше).

Хисап чорында юл хәрәкәте өлкәсендә гамәлдә булган нормаларны һәм кагыйдәләрне бозуның 7,35 миллион очрагы ачыкланды, аларның күбесе (5,99 миллион, яки 85,1 проценты) фотога һәм видеога төшерүнең автомат комплекслары ярдәмендә теркәлде.

2020 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасының юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокук бозуларны автомат рәвештә теркәүгә алу системасы юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны фотога һәм видеога төшерә торган 1 102 датчикны (892 стационар, 177 күчмә, 33 мобиль) үз эченә ала.

2019 ел йомгаклары буенча төрле техник җитешсезлекләре булган транспорт чаралары белән идарә итүнең 33 539 очрагы бетерелде, транспорт чараларын эксплуатацияләүне башкаручы вазыйфаи һәм юридик затларга карата техник күзәтчелек линиясе буенча күзәтчелек эшчәнлеге барышында мәҗбүри куркынычсызлык таләпләрен бозуны бетерү турында 123 күрсәтмә бирелде, тикшерүләр һәм күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча 1 956 вазыйфаи һәм юридик зат административ җаваплылыкка тартылды.

Юл инспекциясе һәм хәрәкәтне оештыру линиясе буенча ЮХИДИ органнары тарафыннан юлларны файдалану торышындагы җитешсезлекләрне бетерүгә 3 521 күрсәтмә бирелде, күрсәтмәләрне үтәмәү фактлары буенча үткәрелгән контроль тикшерүләр нәтиҗәләре буенча 318 административ материал төзелде.

Прокуратура органнарына юл эшчәнлеген тормышка ашырганда җаваплы затларның юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендәге законнарны системалы рәвештә үтәмәве турында 82 хәбәр җибәрелде, юлларны ремонтлаганда һәм карап тотканда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү таләпләрен үтәмәү факты буенча вазыйфаи һәм юридик затларга карата административ хокук бозулар турында 840 эш кузгатылды.

Татарстан Республикасында «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты гамәлгә ашырыла. Проектның төп бурычлары – агломерациянең юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү һәм юл-транспорт һәлакәтләре күп булган урыннар санын киметү.

Хәзерге вакытта 2019 – 2024 елларга «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты кысаларында программа формалаштырылды, анда түбәндәгеләр карала:

норматив таләпләргә туры килә торган төбәк әһәмиятендәге юллар өлешен арттыру;

кирәгеннән артык күп эшләү режимында хезмәт күрсәтә торган федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары өлешен киметү;

юл-транспорт һәлакәтләре күп булган урыннар санын 2 тапкырга киметү;

юл-транспорт һәлакәтләре аркасында үлүчеләр санын 3,5 тапкырга киметү.

2019 елда илкүләм проекты кысаларында 205,8 км автомобиль юлларына ремонт ясалды, шул исәптән:

хәрәкәт интенсивлыгы югары булган 77 участокта (Казан – Малмыж, Казан – Шәмәрдән, Яр Чаллы – Зәй – Әлмәт һ. б.) 108,3 км төбәк әһәмиятендәге юлларга ремонт ясалды, бу исә норматив халәтнең 46,9 процентына ирешүне тәэмин итә;

Казан шәһәренең 88 урамындагы (Габишев, Фучик, Краснококшайская урамнары, Ершов, Чуйков, Адоратский урамнары буенча тротуарлар) 47,3 км юлларга ремонт ясалды, бу исә норматив халәтнең 83,3 процентына ирешүне тәэмин итә;

Яр Чаллы шәһәренең 5 үзәк урамындагы (Тынычлык, Яр Чаллы, Муса Җәлил проспектлары, Әлмәт тракты) 40,9 км юлга ремонт ясалды, бу норматив халәтнең 78,7 процентына ирешүне тәэмин итә;

Түбән Кама шәһәренең 5 төп урамындагы (Химиклар проспекты, Җиңүнең 30 еллыгы ур., Чистай ур., Октябрьнең 50 еллыгы ур.) 9,3 км юлга ремонт ясалды, бу норматив халәтнең 67,2 процентына ирешүне тәэмин итә.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 ноябрендәге 1064 номерлы карары белән 2019 елга юл эшләре программасы расланды.

Программаны үтәү кысаларында төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән берничә адреслы чаралар эшләнде, ягъни:

Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында халыкка хезмәт күрсәтү оешмалары һәм белем бирү оешмалары янында, төп юлга кушылып китә торган юлларга, торак пунктлар урамнарына тоташа торган юлларда ясалма тигезсезлекләр булдыру. 18 муниципаль район территориясендә 107 ясалма тигезсезлек урнаштырылды;

торак пунктлар аша уза торган юл участокларында ясалма яктырту җайланмалары урнаштыру. Республиканың 22 муниципаль районында гомуми озынлыгы 90,4 км булган 31 участокта ясалма яктырту җайланмалары урнаштырылды;

металлдан ясалган барьер киртәләр кую. Каршы як хәрәкәт полосасына чыгу аркасында һәлакәтләрне булдырмау өчен, шулай ук җәяүлеләрнең юл йөрү өлешенә чыгуны чикләү өчен 14 муниципаль районда 84 участокта 14,7 км барьер тибындагы металл киртә куелды;

27 тукталыш павильоны урнаштыру;

җәяүлеләр юла ша чыгу урыннарын төзекләндерү;

транспортлар йөри торган юллар өстенә 17 урында 5.19.1 нче «Җәяүлеләр юл аша чыгу урыны» юл билгесен урнаштыру;

24 534 сигнал баганаларын алыштыру.

Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләренең күп була торган урыннарын ачыклау һәм аларны бетерүгә юнәлдерелгән чараларны эшләү буенча планлы эш алып барыла. 2019 ел йомгаклары буенча республика территориясендә юл-транспорт һәлакәтләренең күп була торган 101 урыны ачыкланды.

Барлык ачыкланган һәлакәтләр һәм куркыныч урыннарда юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча чаралар үткәрелде, алар тизлек режимын киметүне, юл билгеләрен һәм тамгаларын урнаштыру схемаларын үзгәртүне, ясалма яктырту җайланмаларын урнаштыруны үз эченә ала.

Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен һәм алар салган зыяннарның авырлыгын киметү максатларында юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалау буенча шактый эш башкарыла.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының килештерелгән гамәлләрен оештыру өчен Татарстан Республикасының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе эшли.

Юл хәрәкәте иминлеген арттыру чараларын координацияләүдә һәм гамәлгә ашыруда Татарстан Республикасының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясенең ел саен киңәйтелгән утырышларын уздыру тәҗрибәсе

сизелерлек роль уйный. Әлеге утырышлар йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары чыгарыла, алар юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча оештыру эшчәнлегенең төп моментларын үз эченә ала.

Татарстан Республикасының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясенең 2009 елның 17 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф идарәләре (бүлекләре) башлыклары һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство буйсынуындагы оешмалары җитәкчеләре адресына балаларны йөрткәндә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча кирәкле чараларны гамәлгә ашыру, машина йөртүчеләргә инструктаж үткәрү, автобуслар салоннарында юл хәрәкәте иминлеге буенча тематик күрсәтмә мәгълүмат, шул исәптән Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе тарафыннан җибәрелгән белешмә-истәлекләр урнаштыру өлешендә транспорт белән пассажирлар йөртү өлкәсендә эшләүче оешмалар эшчәнлегенә контрольне көчәйтү турында 2009 елның 7 февралендәге 1172/19 номерлы хат җибәрелде.

Татарстан Республикасы буенча белем алучыларны имин йөртүләрне оештыру максатларында мәгариф идарәсе органнарының ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмаларында белем алучыларны Татарстан Республикасы буенча һәм аннан читтә чараларга алып баруын оештыру тәртибе расланды, балаларны чараларга муниципальара, шәһәрара тарнспортта йөртүне оештыру мәсьәләләре буенча «кайнар линия» телефонының эшләве тәэмин ителде.

Муниципаль мәгариф идарәсе органнары тарафыннан «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасында көн саен мәктәп автобусларын файдалану мөмкинлеге мониторингы оештырыла һәм юл хәрәкәте кагыйдәләре һәм балалар хәрәкәтенең имин маршруты схемалары нигезендә балаларның хәрәкәтен тикшерүдә тоту оештырыла.

Республиканың мәктәпкәчә оешмаларында махсус җиһазландырылган автосыйныфлар һәм юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәтү буенча кабинетлар эшли, алар юл билгеләре җыелмалары, балалар яши торган микрорайоннар макетлары, бик күп дидактик уеннар һәм үстерүче материал белән җиһазландырылган. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында барлыгы юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча 610 кабинет, 176 автосыйныф эшли.

Муниципаль мәгариф идарәсе органнары тарафыннан белем бирү оешмаларының Юл иминлеге паспортларын һәм балалар хәрәкәтенең имин маршруты схемаларын Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан җибәрелгән методик тәкъдимнамәләргә туры китерү буенча эш оештырылды. Белем бирү оешмаларының рәсми сайтларының төп битендә юл хәрәкәте иминлегенә багышланган «Юл куркынычсызлыгы» бүлеге бар, ул даими рәвештә актуаль мәгълүмат белән тулыландырылып тора.

Юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча профилактика эшенең инновацион тәҗрибәсе белән уртаклашу максаты белән педагоглар интернет-ресурсларны актив файдалана, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары сайтларында һәм төрле белем бирү сайтларында һәм порталларда үз эшләнмәләрен бастырып чыгара. Тематик

чараларны әзерләгәндә республиканың белем бирү оешмалары педагоглары www.sakla.ru порталында урнаштырылган мәгълүмати материалларны киң куллана.

Яктылык кайтаргыч элементлары булган өс киемнәре киюне һәм предметлар тагуны популярлаштыру буенча чаралар дәвам ителә. Әлеге мәсьәлә ата-аналар җыелышларында карап тикшерелә, бу темага яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары чыгыш ясый, белем бирү оешмаларында юл хәрәкәте иминлеге почмаклары ясала.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты тарафыннан 2020 елга юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны тикшерү үткәрү планы (алга таба – Тикшерүләр планы) эшләнде һәм Татарстан Республикасы Прокуратурасына килештерүгә җибәрелде. Тикшерүләр планына 46 автомәктәп түбәндәге критерийлар буенча сайлап алынды: планлы тикшерүләр үткәрү дәвамлылыгы (3 елга бер тапкырдан да ешрак түгел); машина йөртү стажы ике елдан кимрәк булган автосыйныфны тәмамлаучылар гаебе белән кылынган юл-транспорт һәлакәтләре саны; Татарстан Республикасы Дәүләт автомобиль инспекциясенең имтиханнар бүлекчәләрендә имтиханнар тапшыру күрсәткечләре түбән булган автосыйныфны тәмамлаучылар саны.

***41. Автомобиль юллары торышына җәмәгать контроле системасының («Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының) нәтиҗәлелеге турында.***

2012 елдан башлап, Татарстан Республикасында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы) эшли.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы эшенең нәтиҗәлелеге гражданнарның ышанычын арттыруга ярдәм итә, бу бирелгән хәбәрнамәләрнең саны артуда да чагылыш таба.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы эшли башлаганнан соң, барлыгы 256 179 хәбәрнамә басылып чыкты, шулардан: 224 158е – хәл ителде, 14 479ы – планлаштырылды, 16 838е буенча – нигезле рәвештә баш тартылды, 704е – эшкә алынды. Әлеге чор өчен гражданнардан кергән комментарийларның гомуми саны 1,5 миллионга, ярдәм күрсәтү саны 1,2 миллионга җитте.

2019 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында, барлык статуслардан килгән хәбәрнамәләрне исәпкә алып, 77 162 хәбәрнамә басылып чыкты, бу 2018 ел белән (61 378 заявка) чагыштырганда 26 процентка күбрәк, шуларның 60 052е – хәл ителде, 11 634е – планлаштырылды, 4 778е – нигезле рәвештә баш тартылды, 698е – эшкә алынды.

Системадан файдаланучылар күбрәк «Территорияне төзекләндерү», «Муниципаль юлларны карап тоту һәм ремонтлау», «Тышкы рекламаны бозу», «Юл хәрәкәтен оештыру», «Җәмәгать транспорты» һ.б. категорияләре буенча хәбәрнамәләрне активрак җибәрә.

Иң күп санда заявкалар Казан шәһәреннән, Яр Чаллы шәһәреннән, Әлмәт, Түбән Кама, Бөгелмә, Лениногорск, Зеленодольск муниципаль районнарыннан керә.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында хәбәрнамәләрне үз вакытында уңай карау системадан файдаланучыларның министрлыклар, ведомстволар һәм республика муниципаль районнары эше турындагы комментарийларында һәм бәяләрендә чагылыш таба.

Гражданнар, системада комментарийлар һәм хәтта өстәмә фотосурәтләр калдырып, аерым хәбәрнамәләрнең үтәлешен үзләре контрольдә тота, йә формаль карап тикшерелгәндә яки җавап җибәрелгәндә автор хәбәрнамәне үтәүчеләргә яңадан кире кайтара.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы гражданнарның авыр нокталарын һәм кискен проблемаларын ачыкларга мөмкинлек бирә һәм ул республика программаларын формалаштыру һәм муниципаль берәмлекләр бюджетын финанслау өчен чыганак булып тора.

Мәсәлән, 2014 елда ишегалды территорияләрен, поселоклар эчендәге юлларны төзекләндерү, авыл урамнарын яктырту буенча өстәмә республика программалары гамәлгә кертелде.

Әлеге программаларны ел саен гамәлгә ашыру, шулай ук «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына керә торган хәбәрнамәләрне үтәү буенча җаваплы үтәүчеләрнең актив эшләве нәтиҗәсендә 2019 елда республика һәм муниципаль юлларны ремонтлау буенча республика программалары кысаларында гражданнарның юлларны карап тоту һәм ремонтлау мәсьәләләре буенча 12 159 хәбәрнамәсен уңай хәл итеп булды, бу 2018 ел белән чагыштырганда 33 процентка күбрәк. 2019 елда йорт яны территорияләрен төзекләндерү һәм җәмәгать киңлекләрен карап тоту буенча системада басылган 30 147 мөрәҗәгатьнең 23 859ы хәл ителде, бу 2018 ел белән чагыштырганда 29 процентка күбрәк.

2019 елда республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары яктылыгында республика һәм муниципаль юлларны ремонтлау буенча гражданнарның тәкъдимнәре иң күп санда Казан шәһәре буенча – 9 624, Яр Чаллы шәһәре буенча – 2 388, Әлмәт муниципаль районы буенча – 1 211, Түбән Кама муниципаль районы буенча – 909, Бөгелмә муниципаль районы буенча – 563, Лениногорск муниципаль районы буенча – 483, Зеленодольск муниципаль районы буенча 366 тәкъдим керде.

Юлларны ремонтлау буенча республика программасы кысаларында 1 276 урамда һәм 716 ишегалды территориясе объектларында, шул исәптән 693е – системада контрольдә булган һәм аларны хәл итүгә системалы якын килүне таләп иткән хәбәрнамәләр буенча эшләр башкарылды.

2020 елда «Безнең ишегалды» программасын гамәлгә ашыру һәм гражданнарның фикерен исәпкә алу нәтиҗәсендә системада узган елларда системада «планлаштырылган» статусында булган юлларны ремонтлау һәм карап тоту буенча хәбәрнамәләрнең шактый өлешен үтәү планлаштырыла.

Юлларны капиталь ремонтлаганда гражданнарның халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренә тоткарлыксыз файдалана алу мөмкинлеге өчен җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын, тротуарларны җайлаштыру һәм җиһазландыру, пандуслар урнаштыру, бордюр ташларын түбәнәйтү буенча тәкъдимнәре һәм теләкләре исәпкә алына.

2019 елда Зеленодольск, Лениногорск, Алабуга муниципаль районнарында тимер юл аша юлүткәргечләрне, җәяүлеләр һәм автомобиль күперләрен ремонтлау буенча эш дәвам ителде, Саба муниципаль районында яңа күпер төзелде.

Гражданнарның хәбәрнамәләре мониторингын үткәргәндә юлларда гражданнарның иминлеге һәм «Юл хәрәкәтен оештыру» категориясе буенча светофор объектлары һәм юл билгеләре куюга кагылышлы хәбәрнамәләрне үтәү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә.

2019 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Юл хәрәкәтен оештыру» категориясе буенча 2018 ел белән чагыштырганда 21 процентка күбрәк заявка (5 725) килде, шулардан 3 911 хәбәрнамә хәл ителде.

2019 елда, системага кергән хәбәрнамәләрне исәпкә алып, бөтен республика буенча юл-урам челтәрләрендә 34 светофор объекты урнаштырылды: Казан шәһәре буенча – 21, Яр Чаллы шәһәре буенча – 7, Түбән Кама муниципаль районында – 3.

Бүгенге көндә «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында 61 мең даими файдаланучы исәпләнә.

***42. Татарстан Республикасында халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру буенча күрелә торган чаралар турында.***

Эшләүче халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү янгынга каршы инструктаж үткәрүне һәм янгын-техник минимум программасы буенча укытуны үз эченә ала. Оешмада инструктаж аның җитәкчесе яки янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат тарафыннан билгеләнгән дәвамлылык белән үткәрелә һәм барлык хезмәткәрләрне җәлеп итә. Янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы оешма җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре янгын-техник минимум программасы буенча янгын куркынычсызлыгын җайга сала торган норматив-хокукый актларның таләпләре күләмендә белем ала.

Уку Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү» янгын куркынычсызлыгы нормаларын раслау турында» 2007 елның 12 декабрендәге 645 номерлы боерыгы нигезендә үткәрелә. 2019 елда янгын-техник минимум программалары буенча республика предприятиеләренең 34 111 җитәкчесе һәм вазыйфаи заты, янгынга каршы инструктаж программалары буенча 5 510 оешмалар хезмәткәре белем алды.

Янгын куркынычсызлыгы күнекмәләрен үстерү максатларында балалар өчен мәгариф объектларында һәм җәйге ял итү урыннарында профилактика чаралары комплексы оештырылды. 2019 елда 174 меңнән артык бала катнашында янгын куркынычсызлыгы буенча 4 131 укыту-танып-белү дәресе үткәрелде. Җәйге чорда мондый чаралар мәктәп яны һәм балалар сәламәтләндерү лагерьларында үткәрелә. Балалар булган барлык объектларда, янгын чыккан очракта, объект персоналының гамәлләрен өйрәнеп, эвакуацияләү буенча күнегүләр үткәрелә.

Янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау максатларында, гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең Кризис хәлләрендә идарә итү үзәге» федераль казна учреждениесенә

караган Янгынга каршы пропаганда һәм иҗтимагый элемтәләр үзәгенә бару оештырылды. 2019 елда 15 158 кеше катнашында 586 экскурсия үткәрелде. Шулай ук балалар өчен янгын сүндерү һәм коткару частьләренә экскурсияләр үткәрелә.

Ел саен, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «Бөтенроссия ирекле янгын сүндерү җәмгыяте» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика бүлекчәсе белән берлектә, янгын куркынычсызлыгы буенча балалар конкурслары (әдәби профильле конкурслар, рәсемнәр һәм эшләнмәләр конкурслары, фестивальләр) үткәрелә. 2019 елда барлыгы 22 меңнән артык кеше катнашында конкурсларның 176 балалар район этабы һәм 1 800дән артык бала катнашында 4 республика этабы үткәрелде.

Эшләмәүче халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү яшәү урыны буенча янгыннан профилактика эше үткәрү юлы белән башкарыла. «Торак» операциясе кысаларында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен җиткерү һәм тиешле белешмә-истәлекләрне тапшыру максаты белән карт гражданнарның, күпбалалы гаиләләрнең, имин булмаган гражданнарның яшәү урыннарына барыла. 2019 елда профилактика төркемнәренең күпфатирлы торак йортларга 31 612 визиты һәм шәхси йортларга 478 707 визиты ясалды, шул исәптән 43 210 күпбалалы гаиләләр яши торган урынга бару, 33 958 ялгыз карт гражданнар яшәү урыннарына бару, 19 590 имин булмаган гражданнар яшәү урыннарына бару оештырылды. Шәхси йортларның ишегалдын карап чыгу барышында 671 567 кеше катнашында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструктажлар үткәрелде.

Халыкка янгыннарның торышы, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре турында хәбәр итү массакүләм мәгълүмат чаралары аша башкарыла. 2019 елда 2 101 мәкалә һәм янгынга каршы тематикага язмалар басылып чыкты, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 2 784 мәгълүмати материал урнаштырылды, телевидение һәм радиотапшырулар каналларында 4 731 материал (радиода – 3 051, телевидениедә – 1 680) эфирга чыкты.

Республика һәм шәһәр телеканалларында халыкка янгын чыгуның төп сәбәпләре турында хәбәр итә торган социаль аудио һәм видеороликлар, йөгерүче юл трансляцияләнә. 2019 елда 82 видеоролик һәм йөгерүче юл күрсәтелде (трансляцияләрнең гомуми саны – 15 853), 65 радиотекст яңгыратылды (трансляцияләрнең гомуми саны – 14 958).

Кешеләр күпләп була торган урыннарда тормыш эшчәнлеге иминлеге өлкәсендә мәгълүмат бирү һәм укыту максатларында Халыкка мәгълүмат һәм белем бирүнең гомумроссия комплекслы системасын, башка заманча техник чараларны куллану оештырылды. Бүгенге көндә Казан шәһәрендә 31 терминал комплексы һәм Халыкка мәгълүмат һәм белем бирүнең гомумроссия комплекслы системасының 1 мобиль комплексы эшли, алар көненә 200 меңнән артык кешене колачлый, Яр Чаллы шәһәрендә – 7 терминал комплексы һәм Халыкка мәгълүмат һәм белем бирүнең гомумроссия комплекслы системасының 1 мобиль комплексы эшли, алар көненә 80 меңнән артык кешене җәлеп итә. Барлыгы 138 ролик трансляцияләнә, шуларның 10ы – балаларның янгын куркынычсызлыгы буенча.

***43. Белем бирү учреждениеләрендә балаларның иминлеген тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны киметү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.***

Белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау эшен оештыру Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мөһим юнәлешләреннән берсе булып тора. Балаларны социаль әһәмиятле эшчәнлеккә җәлеп итү, аларның буш вакытын оештыру балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалауның нәтиҗәле инструменты булып тора.

Яшүсмерләр-яшьләр арасында хокук бозуларны һәм җинаятьләр кылуны профилактикалауны оештырганда мәгариф учреждениеләренә ярдәм итү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан берничә норматив-хокукый документлар эшләнде, шул исәптән:

Татарстан Республикасы мәгариф учреждениеләрендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау эшен оештыру стандартлары;

Җинаять җаваплылыгы яшенә җиткәнгә кадәр хокукка каршы гамәлләр кылган балигъ булмаганнар белән эшләү буенча методик тәкъдимнамәләр;

«Милләтләр һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсендә Россия законнары нигезләрен аңлату» методик кулланмасы.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында балигъ булмаганнарның хокук бозулары торышы, җинаятьләре турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җибәрелә, анализ йомгаклары буенча муниципаль берәмлекләр белән коррекцияләү чаралары үткәрелә.

Профилактика эшен оештырганда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы түбәндәгеләр белән тыгыз хезмәттәшлек итә: Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (алга таба – Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Экстремизмга каршы тору үзәге, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты (Татарстан Республикасы буенча филиалы), Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты, иҗтимагый оешмалар, башка кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар. Ведомстволар белән берлектә, муниципаль мәгариф органнары җитәкчеләре, педагоглар өчен дәресләр үткәрелә.

Мәгариф идарәсе органнарының һәм белем бирү оешмаларының тәрбия бирү планнары нигезендә һәр уку елында хокукый белемнәр атналыгы, иминлек айлыклары үткәрелә, аларның кысаларында профильле белгечләрне чакырып, белем бирү процессында катнашучыларның барысы белән дә тематик чаралар оештырыла.

Укучыларның хокукый аңын формалаштыруга хокук тәртибе буенча мәктәп отрядлары эшчәнлеге үз өлешен кертә. Үсеп килүче буынның хокукый культурасын күтәрү өстендә эш алып барыла, шул исәптән хокукка каршы гамәлләр кылган өчен җинаять һәм административ җаваплылык турында аңлату эшләре башкарыла. Бу

эшчәнлектә хокук бозуларны профилактикалау буенча мәктәп отрядларына зур роль бирелә.

Хокук бозуларны профилактикалау отрядларының үсеш динамикасы

| Уку елы | 2010/ 2011 | 2011/ 2012 | 2012/ 2013 | 2013/ 2014 | 2014/ 2015 | 2015/ 2016 | 2016/ 2017 | 2017/ 2018 | 2018/ 2019 | 2019/ 2020 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Отрядлар саны | 1 500 | 1 511 | 1 515 | 1 506 | 1 371 | 1 375 | 1 073 | 1 143 | 1 152 | 1 217 |
| Укучылар саны | 17 341 | 16 012 | 15 984 | 17 850 | 19 242 | 19 330 | 13 476 | 15 483 | 13 654 | 13 874 |

Мәктәп хокук саклау хәрәкәтен стимуллаштыру максатларында, 2009 елдан башлап, Белем бирү оешмаларының хокук бозуларын профилактикалау отрядларының республика конкурсы үткәрелә.

2019 елның 21 – 22 маенда өстәмә белем бирүче «Костер» республика балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе базасында белем бирү оешмаларының хокук бозуларны профилактикалау отрядлары арасында конкурс финалы узды. Конкурсның читтән торып үткәрелгән этабына 45 муниципаль берәмлектән 41 эш керде. Финал ярышларында 10 хокук бозуларны профилактикалау отряды – конкурсның читтән торып үткәрелгән республика этабында җиңүчеләр катнашты.

Укучыларны тәрбияләү системасын камилләштерү, югары әхлаклы, җаваплы, иҗади инициативалы, компетентлы шәхесне формалаштыру һәм үстерүгә социаль-педагогик ярдәм күрсәтү максатларында 2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләү үсеше стратегиясе эшләнде.

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең 2019 елның 10 июлендәге 14-16 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, хокук бозуларын һәм аларның тайпыла торган башка тотыш формаларын профилактикалау буенча ведомствоара эш төркеменең (алга таба – Ведомствоара эш төркеме) нигезләмәсе һәм составы расланды.

Ведомствоара эш төркеме мәгариф линиясе буенча яшүсмерләр-яшьләр арасында социаль-тискәре күренешләрне профилактикалауга юнәлдерелгән эшне оештыру белән җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра: балигъ булмаганнар арасында җинаятьләр һәм хокук бозулар, суицидаль тотыш, деструктив тотыш; мәгариф идарәсе органнарының, мәгариф оешмаларының балалар белән һәлакәт очраклары фактлары буенча мәгълүматын тыңлый. 2019/2020 уку елы башыннан Ведомствоара эш төркеменең 3 утырышы уздырылды.

Моннан тыш, балигъ булмаганнарның хокук бозулары саны кимү дәүләт учреждениеләре тарафыннан үткәрелә торган яшьләр сәясәте белән, шулай ук яшьләр үзәкләре һәм яшьләр (яшүсмерләр) клублары тарафыннан республикада үткәрелә торган профилактика чаралары белән турыдан-туры бәйле.

2019 елда яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан 986 110 кеше катнашында төрле юнәлештәге 20 963 чара үткәрелде, шуларның 5 929ы 97 083 кеше катнашында уздырылган профилактика чаралар (лекцияләр, әңгәмәләр,

интерактив дәресләр, юнәлешле сменалар, профилактик конкурслар, социологик тикшеренүләр һ.б.).

2019 елда Татарстан Республикасының 22 муниципаль берәмлегеннән профилактика исәбендә торучы 680 балигъ булмаган бала мәнфәгатьләре буенча 208 берләшмәдә, яшәү урыны буенча 88 яшьләр (үсмерләр) клубында шөгыльләнде. Әлеге категориядәге балалар белән яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубларының 111 белгече шөгыльләнде, шулардан 9 оештыручы педагог, 16 яшьләр белән эшләү буенча белгеч, 31 тренер-педагог, 32 җитәкче, 4 өстәмә белем бирүче педагог һәм 19 социаль педагог.

Моннан тыш, яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубларының штаттагы хезмәткәрләре арасыннан 16 җәмәгать тәрбиячесе балигъ булмаганнар эшләре органнарында профилактика исәбендә торучы 21 балигъ булмаган балага беркетелгән.

2019 елның җәйге чорында яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары тарафыннан Татарстан Республикасының 26 муниципаль берәмлегендә 144 яшьләр (яшүсмерләр) клубында 30 698 кеше катнашында 164 җәйге ишегалды ял итү мәйданчыклары эше оештырылды. Республиканың 28 муниципаль берәмлегендә җәйге чорда 64 159 кеше катнашында 1 981 чара (спорт бәйрәмнәре, «Күңелле стартлар», уеннар, эстафеталар, ярышлар һәм турнирлар, концерт-күңел ачу чаралары, фестивальләр, флешмоблар, балалар Сабантуйлары, театральләштерелгән тамашалар, «Исәнме, кызыл җәй!», «Бәхетле балачак!» темаларына ишегалды бәйрәмнәре, шигърият кичәләре һәм «Әкият – ялган, әмма анда ишарә бар», «Балачак һәрвакыт синең белән» темаларына әдәби конкурслар, «Балачак дөньясы», «Исәнме, җәй», «Җәй ясыйбыз!» темаларына плакатлар, коллажлар, рәсем конкурслары (шул исәптән асфальта), «Елмаю бүләк ит», «Без сәламәт яшәү рәвеше өчен», «Чиста яр», «Хәтер һәм кайгы көне» темаларына хәйрия, профилактик, экологик һәм патриотик акцияләр, профилактик әңгәмәләр, лекцияләр, «Юл әлифбасы», «Минем туган Татарстаным», «Синең дустың – велосипед», «Сәламәт бул!», «Зарарлы гадәтләр», «Экстремизмга ЮК!», «Яшьләр – тынычлык өчен һәм террорга каршы!» видеолекторияләр, музейларга, шәһәр паркларына экскурсияләр, кинотеатрларга һәм аттракционнарга бару һ.б.) үткәрелде.

Хисап чорында биш шәһәрдә – Казан, Яр Чаллы, Лениногорск, Түбән Кама һәм Чистайда «юридик зат» статусына ия булган балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү буенча 6 үзәк эшләде. 5 үзәк психологик-педагогик ярдәм күрсәтә һәм төркемнәрдә профилактика эшләре алып бара, берсе девиант тәртипле балалар өчен социаль-тернәкләндерү эшчәнлеген башкара.

Балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләренең төркемнәрдә эшләү формалары белән 60 330 кеше шөгыльләнде, 2 314 дәрес (семинарлар, тренинглар), 734 дәрес циклы, 292 массакүләм чара үткәрелде. Эш юнәлешләре берәр нәрсәгә бәйлелекне профилактикалауга (14 085 кеше), экстремизмны профилактикалауга (6 648 кеше), ВИЧ/СПИДны профилактикалауга (2 139 кеше), күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалауга (10 312 кеше) бәйле булды.

Төркемнәр белән эшләү һәм мәгълүмати-агарту эшчәнлеге кысаларында үзәкләр психологлары тарафыннан яшьләр арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалауга юнәлдерелгән проект эшчәнлеге алып барылды. Балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне, сукбайлыкны, хокук бозуларны профилактикалау Казан, Яр Чаллы, Лениногорск һәм Чистай шәһәрләрендә үткәрелә.

2019 елда 40 муниципаль берәмлектә җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләренең 40 үзәге эшләде. Үзәкләр яшьләрнең асоциаль һәм деструктив үз-үзләрен тотышын профилактикалау, хокукый, гражданлык һәм әхлакый кыйммәтләрне формалаштыру белән шөгыльләнә. 2019 елда үзәкләр тарафыннан 10 912 рейд үткәрелде, 49 831 яшь кеше – формированиеләр әгъзасы җәлеп ителде.

Студентлар хезмәт отрядлары үзәкләре тарафыннан 14 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге 10 933 яшүсмер эшкә урнаштырылды, 9 963 кеше катнашында төрле юнәлештәге 316 чара үткәрелде.

2019 елда Татарстан Республикасының 4 муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшүсмерләр ялы, аларны савыктыру, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча 4 үзәк эшләде. Үзәкләр тарафыннан 14 яшьтән 17 яшькә кадәрге 43 440 кеше катнашында төрле юнәлештәге 862 чара үткәрелде.

Сәламәтләндерү-ял итү учреждениеләре (лагерьлары) тарафыннан, 256 232 кеше җәлеп итеп, төрле юнәлештәге 4 516 чара үткәрелде.

«Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаган балаларны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасы базасында торучы балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре белән индивидуаль тернәкләндерү программалары нигезендә педагогик, тәрбия һәм коррекция эшләре алып барылды. Яшьләр эшләре органнары һәм яшьләр сәясәте учреждениеләре җитәкчеләре һәм белгечләре тарафыннан барлыгы 1 157 индивидуаль тернәкләндерү программалары кысаларында социаль ярдәм яки хезмәт күрсәтелде, шул исәптән 592 индивидуаль тернәкләндерү программалары буенча балигъ булмаганнар белән психологик консультацияләр, коррекцияләү эше үткәрелде, балаларны тренинг эшенә, түгәрәкләргә, кызыксыну буенча берләшмәләргә, җәйге ял мәйданчыкларына, мәдәни-массакүләм, спорт һәм башка чараларга җәлеп ителде; балалар социаль, хокукый, медицина, мәгариф, мәдәни-ял, спорт һәм башка оешмаларга җибәрелде.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә данлыклы һәм истәлекле даталарга багышланган яшьләр чараларын үткәрү турында» 2009 елның 16 апрелендәге 101 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан данлыклы һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар комплексы оештырылды. Эш түбәндәге юнәлешләр буенча алып барылды: традицион гаилә кыйммәтләренә ярдәм итү, патриотизмны үстерү, социаль тискәре күренешләрне профилактикалау. 2019 елда түбәндәгеләр үткәрелде: «Бөтендөнья тәмәкесез көне»; «Бөтенроссия аеклык көне»; Наркотик чараларны кирәгеннән артык куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш халыкара көненә багышланган «Наркотикларсыз тормыш» республика наркотикларга каршы акциясе; «Үлем белән

кайда сәүдә итүләрен хәбәр ит» гомумроссия акциясе; «Стоп ВИЧ/СПИДка» бөтенроссия акциясе; 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 74 еллыгы; Россия, Татарстан Республикасы һәм Россия яшьләре көннәре.

2019 елда Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләре тарафыннан эчке эшләр органнарында исәптә торучы 2 571 балигъ булмаган хокук бозучыга һәм 4 533 имин булмаган ата-анага карата профилактика эше гамәлгә ашырылды.

2019 елда балигъ булмаганнар тарафыннан яки алар катнашында кылынган 892 җинаять тикшерелде, тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми саныннан аларның чагыштырма авырлыгы 3,9 процент тәшкил итте.

Әлеге җинаятьчелек төре структурасында төп өлешне урлаулар – 504 (56,5 процент) һәм талаулар – 85 (9,5 процент) тәшкил итә. Яшүсмерләр катнашында 4 кеше үтерү, 8 аңлы рәвештә сәламәтлеккә зыян китерү, 46 яна янау, 51 караклык, 61 автотранспорт урлау һәм наркотикларның законсыз әйләнеше белән бәйле 19 җинаять кылынган.

Җинаять җәзасына тартылган яшькә җиткәнгә кадәр системалы рәвештә иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылучы 36 балигъ булмаган бала ябык типтагы махсус уку йортларына җибәрелде, аларның 20се – ябык типтагы махсус училищега, 16сы – Казан шәһәренең махсус мәктәбенә, 229 яшүсмер балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәгенә урнаштырылды.

Балигъ булмаганнарга һәм яшүсмерләргә карата хокук бозулар кылган зурлар яшендәге затларга карата 13 659 административ беркетмә төзелде.

Үз балаларын тәрбияләү буенча вазыйфаларын катгый рәвештә үтәмәгән өчен 7 596 ата-ана административ җаваплылыкка тартылды. Полиция хезмәткәрләре инициативасы буенча балигъ булмаган балаларны тәрбияләп тоту, укыту һәм тәрбияләү буенча вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен 204 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде, 14 кешегә карата 30 баланы тартып алу турында карар кабул ителде, 64 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде.

Территориаль эчке эшләр органнарына 304 күзәтүсез һәм сукбай бала китерелде, аларның 53е – социаль тернәкләндерү үзәкләренә һәм социаль приютларга, 1 бала – балалар йортына, 36 бала – сәламәтлек саклау учреждениеләренә урнаштырылды, 123 бала ата-аналарга тапшырылды. Балигъ булмаганнарның булуы тыела яки чикләнә торган җәмәгать һәм башка урыннарны карап эшкәртү буенча 3 554 рейд үткәрелде. Рейдлар барышында 2 829 яшүсмер ачыкланды, шулар арасыннан китерелгән 2 712есе төнге сәгатьләрдә җәмәгать урыннарында, 45е – торак йортларның гомуми кулланылыштагы урыннарында, 26сы – күңел ачуны һәм буш вакытны оештыру учреждениеләрендә, 41е – транспорт объектларында тоткарланды.

***44. Тәмәкесез никотинлы катнашмалар таралуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча күрелә торган чаралар турында.***

Татарстан Республикасында 664 гомуми белем бирү оешмасы базасында барлык муниципаль берәмлекләрдәге 10 522 укучы катнашында «Мөстәкыйль балалар» проекты гамәлгә ашырыла. Проект мәктәп яшендәге балаларның беренче

тапкыр психоактив матдәләрне куллануын кисәтүгә юнәлдерелгән. Масштаблы республика акцияләре һәм конкурслары үткәрелә.

2019 елның 26 июнендә Татарстан Республикасында «Сәламәт бул! Бие!» акциясе үткәрелде, анда 9 меңнән артык бала катнашты.

Наркотикларны медицинадан тыш куллануны профилактикалау өлкәсендәге чаралар «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы халкы арасында наркоманияне профилактикалау» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Белем бирү оешмаларының сәламәтлекне саклау эшчәнлеген тәшкил иткән иң мөһим өлешләренең берсе – сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауда гаилә тәрбиясе ресурсларын актив куллану. 2008 елдан башлап, наркоманияне һәм алкоголизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча «Уңышка юл» (авторы И.Г.Вахрушев) дигән ата-аналар өчен гомуми белем бирү программасы гамәлгә кертелә. Программаның төп максаты – ата-аналарга химик ысул белән аңны үзгәртүгә мохтаҗ булмаган уңышлы бала тәрбияләрдә ярдәм күрсәтү.

«Уңышка юл» программасын тормышка ашыру нәтиҗәләре

| Сан күрсәткечләре | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
|---|---|---|---|---|
| Гомуми белем бирү гамәлгә ашырыла торган белем бирү оешмалары саны | 1 372 | 1 378 | 1 378 | 1 379 |
| Проект гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлекләр саны | 45 | 45 | 45 | 45 |
| Барлыгы беренче һәм икенче дәрәҗәдәге программалар буенча дәресләрдә булган ата-аналар, кеше | 301 112 | 305 678 | 308 654 | 401 316 |

Гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларның тайпыла торган үз-үзләре тотышы формалары күрсәткечләрен киметү максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы педагог-психологларның (мәгариф өлкәсендәге психологларның) республика эксперт советы әгъзалары тарафыннан ата-аналар һәм педагогик хезмәткәрләр өчен «Белем бирү мохитенең мәгълүмати иминлеге» темасы буенча уку-укыту контенты эшләнде. Контент Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында һәм «Татарстан Республикасы Электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында «педагогларның шәхси кабинетлары»нда урнаштырылды.

2019 елда Психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү буенча «Росток» республика үзәге тарафыннан балалар һәм яшүсмерләрнең аддиктив тотышын профилактикалау буенча күрсәтмә агитацияләү чаралары һәм буклетлар сериясе эшләнде, ул «Психолог – ата-анага» методик тәкъдимнамәләр циклын (методик әдәбият) үз эченә ала.

2019 елның февраленнән мартына кадәр «Спорт – зарарлы гадәтләргә альтернатива» XV Бөтенроссия акциясенең республика этабы уздырылды.

2019 елда укучыларга социаль-психологик тест ясау Наркотикларга каршы дәүләт комитеты күрсәтмәсе (2017 елның 11 декабрендәге 35 номерлы беркетмә)

нигезендә эшләнгән Бердәм социаль-психологик тест үткәрү методикасы ярдәмендә башкарылды. Максаты – укучыларны социаль тискәре тотышка җәлеп итү куркынычын арттыру мөмкинлеге булган факторларны ачыклау.

Белем бирү оешмалары укучылары ел саен профилактика медицина тикшерүләренә җибәрелә. Мәгариф системасында бу юнәлеш өчен Укучыларга һәм студентларга профилактика наркологик тикшерүләре үткәрү буенча республика оператив штабы җавап бирә.

2019 елда 76 907 кеше, шулар арасыннан 69 823 укучы (шуларның 313е – яшьләрнең массакүләм ял итү урыннарында); Татарстан хәрби комиссариатының җыелу пунктында 7 084 хәрби хезмәткә чакырылучы тикшерелде. Гомуми белем бирү оешмаларында 2 укучы (Казан ш., Зеленодольск ш.), һөнәри белем бирү оешмаларында 7 студент (Казан ш. – 5 кеше, Зеленодольск ш. – 1 кеше, Тәтеш районы – 1 кеше), 7 кеше яшьләрнең күпләп ял итү урыннарында, 37 кулланучы Татарстан хәрби комиссариатының җыелма пунктында наркотик матдәләр куллану ачыкланды.

Республикада балигъ булмаганнарның «снюслар» һәм никотин катнашмалары куллануына бәйле хәл контрольдә тотыла. Барлык очракларга хокук саклау органнары һәм наркологлар белән берлектә анализ ясала. Педагог-психологларны һәм медицина хезмәткәрләрен җәлеп итеп, ата-аналар белән индивидуаль аңлату эшләре оештырыла. Аңлату эшләре барышында индивидуаль һәм төркемле очрашулар, ата-ана җыелышлары форматын куллану тәкъдим ителә.

Муниципаль мәгариф идарәсе органнарының мәгълүматлары буенча 2019/2020 уку елы башына 6 414 балигъ булмаган бала мәктәп эчендәге исәптә, 2095 балигъ булмаган бала балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә исәптә тора, шуларның 6 136 балигъ булмаган балага өстәмә белем бирелә. Хәзерге вакытта, балаларның үзенчәлекләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып, мәгариф оешмалары тарафыннан төрле дәрәҗәдәге программалар эшләнә.

Профилактика эшенең бер инструменты булып «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасы тора, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турындагы Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмат банкын формалаштыру хакында» 2010 елның 22 апрелендәге 294 номерлы карары белән җайга салына. Риск төркемендәге балалар турындагы мәгълүматлар базасын формалаштыруда барлык профилактика субъектлары катнаша. Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнар базасы барлык профилактика субъектларына бер-берсенең эшен күрергә мөмкинлек бирә.

2019 елда ведомствоара социаль патронатта 1 234 гаилә торды, аларда социаль куркыныч хәлдә булган 2 236 балигъ булмаганнар тәрбияләнде.

2019/2020 уку елы башында девиант тотышлы укучылар белән индивидуаль профилактика эшен оештыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнамәләр эшләнде һәм муниципалитетларга җибәрелде. Тәкъдимнамәләрдә Хокук бозуларны профилактикалау советы эшен оештыруга, мәктәп эчендәге исәпне һәм белем бирү оешмасының социаль паспортын алып баруга карата яңа алымнар тәкъдим ителде, тәрбия өлкәсендә эшләүче педагогик хезмәткәрләрнең, шул исәптән сыйныф

җитәкчесенең, социаль педагогның, педагог-психологның профилактика эшен оештыру буенча гамәлләре алгоритмы язылды.

Муниципаль һәм дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында 497 педагог-психолог, 142 социаль педагог эшли. Республиканың белем бирү оешмалары педагог-психологлары тарафыннан яшүсмерләр белән, «Барысы да синең кулыңда»... 

Кисәтү эшен оештыру максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән институты тарафыннан белем бирү оешмалары укучыларында «Колумбайн» идеологиясенең мөмкин булган чагылышларын эзләү алгоритмнары» методик кулланмасы эшләнде.

Балигъ булмаганнар һәм яшьләр арасында наркоманияне беренчел профилактикалауга юнәлдерелгән эшләр яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары, балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләре, яшьләр үзәкләре, «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәкләре һәм Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыручы башка учреждениеләрнең профилактика эшенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора. 2019 елда балигъ булмаганнар һәм яшьләр арасында наркоманияне профилактикалауга юнәлдерелгән эшкә 96 681 кеше җәлеп ителде.

Балалар һәм яшьләр өчен түбәндәгеләр оештырылды:

күрсәтмә агитация чаралары, листовкалар, буклетлар, флаерлар тарату белән наркотикларга каршы акцияләр; «Наркотикларсыз тормыш», «Яшьләр наркотикларга каршы!», «Наркотикларга стоп!» интернет-акциясе;

«Психоактив матдәләрне куллану, саклау һәм таратуның хокукый аспектлары», «Яшүсмерләр-яшьләр мохитендә наркотиклаштыруны профилактикалау», «Сәламәт яшәү рәвеше. Наркотикларсыз дөнья» һ.б.ш. темаларга интерактив дәресләр, профилактик әңгәмәләр, лекцияләр, «түгәрәк өстәлләр», интеллектуаль викториналар, квестлар һәм мастер-класслар;

2019 елның 26 июнендә Казан шәһәрендә «Россия – наркотикларсыз территория» бөтенроссия җиңел атлетика узышы уздырылды. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре комитеты тарафыннан концерт мәйданчыгы эше оештырылды, анда шулай ук яшьләр арасында психоактив матдәләрне куллануны профилактикалау буенча мәгълүмати материаллар таратылды.

Эшчәнлеге психоактив матдәләргә бәйле кеше белән нәтиҗәле хезмәттәшлекнең кирәкле күнекмәләрен үзләштерү һәм кирәкле белемнәр алуга юнәлдерелгән төркемнәр эшли. 395 чара үткәрелде, 2 720 кеше катнашты.

Тәмәке тартуны профилактикалауга юнәлдерелгән эшләр яшьләр эшләре органнары, яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары, яшьләр үзәкләре, балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләре, җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәкләре һәм башка яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган профилактика эшенең өстенлекле юнәлешләреннән икенчесе булып тора.

Ел дәвамында балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләре психологлары тарафыннан төркем тренинглары, интерактив дәресләр, яшьләр өчен лекторийлар, шәхси консультацияләр алып барыла, яшьләр арасында профилактика эшен оештыру буенча белгечләр белән методик эш үткәрелә.

2019 елда тәмәке тартуны профилактикалау эшенә 26 013 кеше җәлеп ителде.

2019 елда наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше белән бәйле 9 327 административ хокук бозу ачыкланды һәм бетерелде, 21 наркопритон эшчәнлеге туктатылды.

2019 елда наркоманиядән диагностика үтү һәм дәвалану бурычы йөкләнгән 1 167 кеше суд карарын үтәде, 1 327 кеше медицина оешмаларында дәваланды. Табиб билгеләвеннән башка наркотик чаралар яки психотроп матдәләр куллануга бәйле рәвештә, диагностика, профилактика чаралары узудан, наркоманиядән дәваланудан, медицина һәм социаль тернәкләндерүдән баш тарткан өчен 1 791 административ беркетмә (РФ Административ хокук бозулар кодексының 6.9.1 статьясы) төзелде.

Наркотик кулланып, исерек хәлдә транспорт чарасы белән идарә иткән 375 машина йөртүче, шулай ук ЮХИДИ бүлекчәләренә машина йөртү таныклыкларын алу өчен мөрәҗәгать иткән 38 наркотик кулланучы ачыкланды.

2019 ел дәвамында 360 меңнән артык кеше катнашында 11 меңнән артык наркотикларга каршы профилактика чаралары үткәрелде.

Белем бирү оешмаларында яшүсмерләр мохитендә наркоманияне профилактикалау буенча 8 меңнән артык чара үткәрелде, 33 038 мәктәп укучысы профилактика медицина тикшерүләре узды, алар барышында психоактив матдәләр куллануның 7 факты ачыкланды, 5 405 профилактик лекция укылды, шулардан 2 055е – наркотик чаралар, «снюслар» һәм башка матдәләрне куллануның зыяны турында.

«Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыю турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгәннән соң, полиция хезмәткәрләре тарафыннан Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәте хезмәткәрләре белән берлектә 181 сәүдә объекты тикшерелде, аларның нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы прокуратурасына 29 материал җибәрелде, 35 килограммнан артык тәмәкесез никотинлы продукция тартып алынды.

### *45. Криминаль җинаятьчел төркемнәргә, шул исәптән яшүсмерләр криминаль оешмаларына каршы көрәш турында.*

2019 елда Татарстан Республикасы хокук саклау органнары тарафыннан оешкан төркемнәр һәм җинаятьчел берләшмәләр составында кылынган 226 җинаять ачылган, 1 054е – оештырылган җинаятьчел төркемнәр (алга таба – оешкан җинаятьчел төркем) әгъзалары тарафыннан кылынган җинаятьләр. Җинаять җаваплылыгына 800 оешкан җинаятьчел төркем әгъзасы һәм оешкан төркем составында җинаять кылган зат тартылган.

Россия Федерациясе Җинаять кодексының (алга таба – РФ ҖК) 210 статьясы (җинаятьчел төркем оештыру) буенча квалификацияләнгән 10 җинаять буенча 6 җинаять эше, шулай ук РФ ҖК 210.1 статьясы (җинаять иерархиясендә югары урын алу) буенча квалификацияләнгән 1 җинаять буенча 1 җинаять эше кузгатылган.

Судларга РФ ҖК 210 статьясы буенча «Шәйморатов – Муницын», «Гудожников» һәм «Сазонов» (Казан ш.), «Семенов – Олейник» (Чаллы ш.) җинаятьчел берләшмәләре лидерлары һәм анда катнашучыларга карата 6 җинаять буенча 4 җинаять эше җибәрелгән.

Тулаем алганда, Татарстан Республикасында оешкан җинаятьчелеккә каршы тору линиясе буенча оператив вәзгыять тотрыклы һәм контрольдә тотыла. Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясендә иҗтимагый резонанс тудырган әлеге линия буенча оператив хәлнең җитди төркемле җинаять күренешләренә һәм катлаулануына юл куелмады.

Нинди дә булса низаглар, төркемле сугышулар, талау һәм травматик коралдан ату юлы белән хулиганлык юлы белән республикада оператив хәлгә тискәре криминаль йогынты ясарга омтылучы төркемнәр буенча, Эчке эшләр органнары тарафыннан низагларны һәм резонанс җинаятьләрне кылуны кисәтү буенча кичекмәстән адекват чаралар күрелә. Массакүләм мәгълүмат чараларында җәмәгатьчелек резонансын уяткан төркем әгъзалары катнашында төркемле хулиганлык кылуда гаеплеләр кыска вакыт эчендә билгеләнгән, тоткарланган һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

Соңгы вакытта әлеге линия буенча проблемалы мәсьәләләрнең берсе – яшьләрне һәм балигъ булмаганнарны җинаятьчелеккә тарту. Бу категориягә кергән затлар арасында «АУЕ» дип аталган криминаль идеология («арестантский уклад един») тарала. Әлеге төркемнәрдә катнашучыларның барысы да эчке эшләр органнары хезмәткәрләре тарафыннан билгеләнгән, исәпкә алынган, алар белән профилактик эш алып барылган, кайбер катнашучыларга карата янау һәм башка җинаятьләр фактлары буенча җинаять эшләре кузгатылган.

Әлеге проблема барлыкка килү белән бәйле рәвештә, балигъ булмаганнарны оешкан җинаятьчелеккә тартуны булдырмау буенча профилактик һәм оператив-эзләү чаралары комплексын үткәрү максатларында

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (алга таба – ТР буенча ЭЭМ) җитәкчелеге тарафыннан ТР буенча ЭЭМ аппаратында һәм Татарстан Республикасы эчке эшләрнең барлык территориаль органнарында «Лидер» махсус төркемнәрен булдыру турында карар кабул ителде, аларга җинаятьчеләрне эзләү хезмәткәрләре, шул исәптән экстремизм һәм төркемле җинаятьчелек линиясе буенча, полициянең участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча хезмәткәрләр кертелгән. Махсуслаштырылган эшче төркемнәр әгъзаларына балигъ булмаганнар арасында төркемле җинаятьләрне, янап акча алу фактларын кисәтү, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тыелган төркемнәрне кулланучыларны ачыклау, балигъ булмаганнарның җинаятьчелеген юл куймау бурычлары йөкләнде.

2019 елда җәмгыятькә каршы юнәлештәге балигъ булмаганнар арасында 123 төркем исәпкә куелган (2018 елда – 99), катнашучылар саны – 333 кеше (2018 елда –

263 кеше).

Хокукка каршы юнәлештәге билгеләнгән төркемнәргә яңа юнәлеш бирү максатыннан аларда катнашучыларның буш вакыты оештырылды. Бу – яшүсмерләне яшьләрнең хокук саклау хәрәкәтенә, мәктәп профилактика отрядларына, «Юнармия» балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенә җәлеп итү.

Республика территориясендә исәптә булган балигъ булмаганнарның буш вакытын үткәрергә мөмкинлек бирә торган күп кенә спорт объектлары эшләп килә. Шулай ук республикада төрле категория яшьләрнең социаль, иҗади һәм һөнәри үзенчәлекләрен тормышка ашыру өчен 29 яшьләр үзәге (20 муниципаль берәмлектә), яшәү урыны буенча 225 яшьләр (яшүсмерләр) клублары (29 муниципаль берәмлектә), җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) оешмаларының 40 үзәге (40 муниципаль берәмлектә), 2 студентлар хезмәт отрядлары үзәге (2 муниципаль берәмлектә), балалар һәм яшүсмерләрнең ялын, мәшгульлеген оештыру буенча 4 үзәк (4 муниципаль берәмлектә), 37 сәламәтләндерү-ял итү учреждениесе (21 муниципаль берәмлектә), 2 хәрби-патриотик эш һәм армиягә кадәр яшьләрне әзерләү үзәге (2 муниципаль берәмлектә), 1 яшьләргә ярдәм итү үзәге эшли.

Балалар һәм яшьләрнең үз-үзләрен асоциаль һәм деструктив тотышын профилактикалау, авыр тормыш хәлендә калган балаларга һәм яшьләргә, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) психологик ярдәм күрсәтү балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү республика үзәкләре эшчәнлеге кысаларында алып барыла.

2019 елда «юридик зат» статусына ия булган балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү буенча 6 үзәк эшләде (алга таба – ЮЗ үзәге), алардан:

5се психологик-педагогик ярдәм күрсәттеләр һәм профилактик эш алып бардылар: Казан шәһәре – «Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» ЯС МБУ (алга таба – «Ышаныч» үзәге), Чаллы шәһәре – «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ (алга таба – «Диалог» үзәге), Лениногорск шәһәре – «Логос» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ (алга таба – «Логос» үзәге), Түбән Кама шәһәре – «Эйдос» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ (алга таба – «Эйдос» үзәге), Чистай шәһәре – «Статус» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ (алга таба – «Статус» үзәге);

1 се социаль-тернәкләндерү эшчәнлеге алып барды – Казан шәһәре «Дуслык» девиант тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль-реабилитация үзәге» МБУ (алга таба – «Дуслык» СРҮ).

Моннан тыш, балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм психологлар тарафыннан күрсәтелде:

«Нур» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге (Әлмәт шәһәре «Яшьләргә ярдәм итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең структур бүлекчәсе);

яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы: «Миллениум» («Яшьләр сарае» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең структур бүлекчәсе, Бөгелмә шәһәре) (алга таба – «Миллениум» ЯЯК);

«Аҗаган» яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесе, Яңа Чишмә (алга таба – «Аҗаган» ЯК);

Чаллы шәһәрендә яшьләр үзәкләре («Заман» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – «Заман» яшьләр үзәге), Азнакай шәһәре («Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – ЯҮ), Баулы шәһәре («Яшьләр доньясы» күппрофильле яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – «Яшьләр доньясы» КЯҮ) һәм Минзәлә шәһәре («Веста» күппрофильле яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба –»Веста» КЯҮ).

Балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләренең төркемле эш формалары белән 60 330 кеше шөгыльләнә, 2 314 дәрес (семинарлар, тренинглар), 734 дәрес циклы, 292 массакүләм чара үткәрелгән.

Гамәлгә ашырылган:

бәйлелекне профилактикалау – 14 085 кешедә, шул исәптән: наркоманияне профилактикалау – 5 288 кешедә, эчкечелекне – 2 510 кешедә, тәмәке тартуны – 3 787 кешедә, бәйлелекне – 870 кешедә, интернет-бәйлелекне – 922 кешедә, башка төр бәйлелек – 708 кешедә;

экстремизмны профилактикалау – 6 648 кешедә;

ВИЧ/СПИД профилактикасы – 2 139 кешедә;

караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау – 10 312 кешедә, шул исәптән: КДН/ПДН, ВШУда профилактик исәптә торучы балалар белән эшләү – 1 611 бала белән, «Интернет» челтәрендә балаларның куркыныч тәртибен профилактикалау – 1 469 бала белән, имгәнүләрне/булингны/мәктәп моббингын профилактикалау – 3 217 бала белән, яшьләр субкультураларының тискәре йогынтысын профилактикалау – 659 бала белән, башкасы – 3 356 бала белән;

гаилә белән эшләү – 7 211 граждан белән, шул исәптән гаилә мөнәсәбәтләрен формалаштыруга һәм ныгытуга юнәлдерелгән интерактив дәресләр/тренинглар белән эшләүгә 3 650 кеше колачланган, ялгыз ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтү программалары белән – 29 кеше, яшь гаиләләр клубы эше белән – 1 312 кеше, гаилә клублары белән (балалар һәм аларның ата-аналары) – 134 кеше, гаилә фестивальләре, чыгулары, лагерьлар һ.б. белән – 127 кеше, яшьләрне гаилә тормышына әзерләү белән – 1 959 кеше колачланган;

сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча эш – 8 767 граждан белән;

ихтыярый инициативаларны үстерү буенча эш – 3 059 граждан белән, шул исәптән массакүләм чаралар (акцияләр, флешмоблар) белән 1 726 кеше, социаль әһәмиятле чаралар (өлкәннәр белән эшләү һ.б.) белән 272 кеше, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшьләр белән профилактик чаралар белән – 129 кеше, ихтыярыйлар клубы белән – 121 кеше, профилактик ихтыярыйлар белән – 135 кеше, социаль әһәмиятле башка чаралар белән 676 кеше белән алып барылган;

балигъ булмаганнар арасында үз-үзеңне суицидаль тоту профилактикасы 3 730 кешедә үткәрелгән;

башка чаралар, соратып алу буенча чараларны да кертеп, 4 379 граждан белән башкарылган.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясен һәм Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектларының ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2009 ел, 4 март, 149 нчы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 4 март, 151 нче карарларын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына (алга таба – Министрлык) халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын координацияләү, психологик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы төрле ведомстволарга караган учреждениеләр эшчәнлеген мониторинглау, психологлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү һ.б. функцияләр беркетелгән.

Халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең формалаштырыла торган системасында, нигездә, яшьләрдә үз-үзеңне тотуның норматан тайпылган рәвешләрен профилактикалауда һәм аларның психологик сәламәтлеген саклауда психологик хезмәтләргә зур роль бирелә.

Министрлыкта куелган бурычларны тормышка ашыру өчен психологик ярдәм күрсәтү бүлеге булдырылды, 2019 елның 20 маеннан 1 октябренә кадәр ул тулысынча комплектланды. 19 августтан Психологик хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү буенча ресурс үзәгенең кадрлар составының 15 ставкасын формалаштыру буенча эш оештырылды. 2019 елның 9 сентябреннән сайлап алуны узган белгечләрне эшкә урнаштыру башланды. 2020 елның 30 гыйнварында Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссиянең 15 нче беркетмәсе белән «Ориентир»ресурс үзәге турында нигезләмә расланды.

Хәзерге вакытта яңа юнәлеш буенча 22 профессионал (Министрлык бүлегенең 5 хезмәткәре һәм Ресурс үзәгенең 18 хезмәткәре) эше оештырылган, аларның җидесе галим дәрәҗәләренә ия.

Ярдәмнең оперативлыгы өстенлекле рәвештә дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә эшли торган ашыгыч психологик ярдәм «Ышаныч телефоны» белән тәэмин ителә. Быел Балалар өчен ышаныч телефонына 10 ел. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә 8-800-2000-122 бердәм гомумроссия линиясенә Чаллы, Әлмәт, Алабуга һәм Түбән Кама шәһәрләрендә биш учреждение тоташтырылган.

2019 елда Балалар өчен ышаныч телефонының 6 хезмәтенә 28 781 шалтырату килгән (2018 елда – 23 504 шалтырату, 2017 елда – 24 358 шалтырату), алардан проблемаларны хәл итү өчен 11 929 кеше (2018 елда – 1412 кеше, 2017 елда – 15 684 кеше) мөрәҗәгать иткән.

Иң күп шалтырату балалар һәм яшүсмерләрдән – 7 976 шалтырату (2018 елда – 8 053, 2017 елда – 9 920), ата-аналардан һәм аларны алмаштыручы затлардан 1 165 шалтырату (2018 елда – 2059, 2017 елда – 2015), башка гражданнардан – 2 788 шалтырату (2018 елда – 3 900, 2017 елда – 3 749) килде. Мөрәҗәгатьләрнең

гомуми саны арасында баланың яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләре һәм балалар – ата-аналар мөнәсәбәтләре мәсьәләләре буенча тематика өстенлек итте.

***46. Инвалидларны юлларда теләнчелек өчен куллану белән бәйле хокук бозуларга каршы көрәшкә юнәлдерелгән чаралар турында.***

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре тарафыннан 2019 елда Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.15 «Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү» статьясы буенча 93 административ беркетмә төзелде.

***47. М-7 трассасы буенда түбән социаль җаваплылыклы затларның җәгыятькә каршы тәртибе һәм территорияләрне чүпләвенә каршы көрәш өлешендә Татарстан Республикасының имиджын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар турында.***

2019 елда Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан РФ ҖК 240 статьясында (фахишәлек белән шөгыльләнүгә җәлеп итү) каралган 27 җинаять һәм РФ ҖК 241 статьясында (фахишәлек белән шөгыльләнүне оештыру) каралган 18 җинаять буенча эш тикшерелде.

Моннан тыш, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.11 статьясында каралган 290 административ хокук бозу очрагы ачыкланды (фахишәлек белән шөгыльләнү).

2019 елда җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт экология күзәтчелеген тормышка ашырганда, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының вазыйфаи затлары тарафыннан Биектау муниципаль районы территориясендә 72 бозу очрагы, шул исәптән М-7 трассасы янындагы территориядә 6 бозу очрагы ачыкланды. М-7 трассасы янындагы территориядә ачыкланган бозулар фактлары буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзелде, шулай ук кисәтү һәм штраф рәвешендә гаепле затларга карата административ җәза билгеләү турында карарлар кабул ителде. Кагыйдә бозучыларга 42 мең сумлык штраф салынды.

***48. Идел елгасында су кимүне минималь күрсәткечтән түбәнрәк төшүне булдырмау өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелә торган чаралар турында.***

Хәзерге вакытта Куйбышев сусаклагычының эш режимы РСФСР мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгының 1983 елның 11 ноябрендәге 596 номерлы боерыгы (алга таба – Кагыйдәләр) белән расланган Идел елгасында Куйбышев сусаклагычының су ресурсларын файдалануның гамәлдәге Төп кагыйдәләре нигезендә, Идел-Кама каскады сусаклагычларының эш режимнарын җайга салу буенча ведомствоара эшче төркем карары нигезендә, Су ресурслары федераль агентлыгы тарафыннан билгеләнә.

Кагыйдәләрдә язгы ташу чорында Волгоград һәм Әстерхан өлкәсе авыл хуҗалыгы мәнфәгатьләрендә Идел елгасы дельтасына язгы авыл хуҗалыгы һәм балык хуҗалыгы юллары гамәлгә ашырыла, аларны гамәлгә ашыру өчен Түбән Идел

сусаклагычларын язгы тутыруны туктатып торырга һәм аларда тупланган су запасларының бер өлешен хәтта эшкәртергә рөхсәт ителә. Шул ук вакытта язгы ташу чорындагы гидроузел буасының минималь су дәрәҗәсе минималь навигация дәрәҗәсеннән ким булмаска тиеш – Балтия системасының 49 метры (алга таба – мБС).

Федераль су ресурслары агентлыгының әлеге таләбенә нигезләнеп, 2019 елда авыл хуҗалыгы һәм балык хуҗалыгы юлларын гамәлгә ашыру өчен Куйбышев һәм Волгоград гидроузеллары аша югары ташлау чыгымнары билгеләнде, бу Куйбышев сусаклагычы дәрәҗәсе 49,86 м БС билгесенә кадәр (рөхсәт ителгән – 49 м БС) күтәрелүенә китерде.

2019 елның язгы чорында Куйбышев сусаклагычында су дәрәҗәсе зур иҗтимагый резонанс тудырган, су транспорты эшендә өзеклекләргә, төп балык төрләренең уылдык чәчүлеген соңрак вакытка күчерү (май азагы – июнь башы) һәм аның нәтиҗәлелеге түбән булуга китергән 49,86 м БС билгесенә кадәр кимүгә бәйле рәвештә Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының эш режимнары буенча тәкъдимнәр әзерләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) төзелде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 09 август, 664 нче карары).

Комиссия утырышында Куйбышев сусаклагычының су ресурсларыннан файдалану кагыйдәләренә авыл хуҗалыгы һәм балык хуҗалыгы юлларын Идел елгасының 51 м БС тамгасы белән түбәнгә Куйбышев сусаклагычының рөхсәт ителгән эшкәртүен чикләү өлешендә үзгәрешләр кертү кирәклеге турындагы мәсьәләләр каралды.

Бер үк вакытта, яңа кагыйдәләр расланганчы, 2020 елда Куйбышев сусаклагычының тирән эшләвенә юл куймас өчен, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы Татарстан Республикасы Президентының Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгына әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгате (су ташу чорында Куйбышев сусаклагычының кимәлен 51 м БС билгесеннән түбәнрәк булуын булдырмау) инициативасы белән чыкты. Бу тәкъдим Ульяновск өлкәсе, Чуашстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасының табигатьне саклау министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре тарафыннан Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының эш режимнары буенча тәкъдимнәр әзерләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия утырышы кысаларында 2020 елның 21 гыйнварында узган «түгәрәк өстәл» утырышында хупланды.

***49. Гомумтаралган файдалы казылмаларны, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә законсыз чыгару фактларын ачыклауга һәм булдырмауга юнәлтелгән чаралар турында.***

Экологик контроль буенча дәүләт инспекторлары 2019 ел башыннан бирле җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә табигать саклау законнарын бозуның 495 очрагын, лицензия шартларын бозуның 405 очрагын ачыклады. Ачыкланган бозулар нәтиҗәләре буенча 471 беркетмә төзелде, шуларның 154е – юридик затларга, 261е – вазыйфаи затларга, 33е – шәхси эшмәкәрләргә, 23е – физик затларга.

Табигать саклау законнарын бозучыларга 26,1 млн сумлык административ штраф салынган.

Карьерларны законсыз эшләү факты буенча хокук саклау органнары тарафыннан 7 җинаять эше кузгатылган.

2019 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан бирелгән вәкаләтләр кысаларында түбәндәгеләр ачыкланган:

категориясе туры килмәгән җирләрдә эш алып баруның 5 очрагы. Әлеге лицензияләр буенча җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы җирләрне тиешле категориягә күчерү вакытына кадәр туктатылды, кагыйдә бозулар 2 ел эчендә бетерелмәгән очракта лицензиянең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату каралган;

тау эшләрен үстерү планыннан башка гына эшләр алып баруның 9 очрагы. Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга ачыкланган бозулар турында хәбәрнамәләр җибәрелде, кабатланган фактны теркәгәндә – лицензиянең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату;

җир аст байлыкларын чыгаруның килештерелгән дәрәҗәсеннән тайпылуның 89 факты. Дәүләт күзәтчелеге органнарына административ чаралар күрү өчен мәгълүмат җибәрелде;

лицензия шартларын үтәү срокларын бозуның 55 очрагы. Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга ачыкланган хокук бозулар турында хәбәрнамәләр җибәрү, бозуларны бетерү вакытын билгеләп (3 ай), бетерелмәгән очракта – лицензияне вакытыннан алда туктату;

статистик хисап бирү тәртибен бозуның 45 очрагы. Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга ачыкланган хокук бозулар турында хәбәрнамәләр җибәрү, бозуларны бетерү вакытын билгеләп (3 ай), бетерелмәгән очракта – лицензияне вакытыннан алда туктату.

2019 ел башыннан ачыкланган бозулар буенча барлыгы 181 хәбәрнамә җибәрелгән, 79 лицензиянең гамәлдә булуы туктатылган, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан 60 бозу бетерелгән.

«Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 12 ноябрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителде, аның проекты Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан эшләнде.

шулай ук закон проектлары әзерләнгән:

«Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 7.3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» лицензия шартларын үтәмәгән өчен җаваплылыкны көчәйтү турында;

җинаять җаваплылыгын билгеләү өлешендә «Россия Федерациясе Җинаять кодексына, Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексына үзгәрешләр кертү турында».

***50. Атмосфера һавасы торышына автотранспортның тискәре йогынтысын киметү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.***

Автомобиль транспорты атмосфера һавасына зарарлы матдәләр чыгаруның төп чыганакларыннан берсе булып тора. Автомобиль транспортыннан һава чыккан пычраткыч матдәләрнең гомуми күләме Татарстан Республикасы буенча чыгарылган зарарлы матдәләрнең гомуми күләменең яртысыннан артыгын тәшкил итә.

2020 елның 1 гыйнварына республикада 1,6 млн берәмлектән артык автотранспорт чарасы исәптә тора.

Күчмә чыганакларның әйләнә-тирә мохит торышына тискәре йогынтысын минимальләштерү беренче чиратта әһәмияткә ия. Күчмә чыганаклардан ташлауларны киметү буенча эш юнәлешләренең берсе булып автомобильләрне экологик яктан чиста мотор ягулыгына, барыннан да элек – кысылган табигый газга күчерү тора.

«Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкурентлылык сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Автомобиль сәнәгате» ярдәмче программасы кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы расланды.

Программаның максаты – автомобиль транспортының матди-техник базасын модернизацияләү һәм автотранспорт чараларын тарафыннан мотор ягулыгы сыйфатында компримацияләнгән табигый газдан (алга таба – КТГ) өстенлекле файдалану өчен шартлар тудыру.

«2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» программасын тормышка ашыру бензин һәм дизель ягулыгын куллануны шактый киметергә һәм шуның белән 15 мең берәмлек автотранспорт чарасын компримацияләнгән табигый газга күчерү хисабына автотранспорттан атмосферага пычраткыч матдәләр чыгаруны 13 мең тоннадан артыкка киметергә мөмкинлек бирәчәк. 2013 елдан 2019 елга кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан программа чараларын гамәлгә ашыруга 1,2 млрд. сумнан артык акча бүлеп бирелгән, алар нигездә транспорт чараларын сатып алуны һәм яңадан җиһазлауны субсидияләүгә юнәлдерелгән.

Әлеге программаны тормышка ашыру кысаларында 2013 – 2019 елларда республикада 7 меңнән артык газ автомобиле файдаланыла, бу атмосферага чыгарылган зарарлы матдәләрне 10 мең тоннага киметергә мөмкинлек бирде.

Газ баллонлы автомобильләргә ягулык салу өчен автомобиль газ салу станцияләре челтәре (алга таба – АГССЧ) динамик үсүен дәвам итә.

Хәзерге вакытта 21 стационар АГССЧ файдаланыла, моннан тыш, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында 1 күчмә автомобиль газ салу (КАГС) файдаланыла. Республикада төзелгән АГССЧ челтәренең гомуми проект җитештерүчәнлеге елына 160 млн куб. метр компримацияләнгән табигый газны тәшкил итә.

2019 ел нәтиҗәләре буенча 50 млн куб. метрдан артык табигый газ сатылган (2018 елда – 35,75 млн куб. метр). Программаны тормышка ашыру башлану белән чагыштырганда (2013 ел) республикада метан куллану үсеше 11 тапкырдан артык тәшкил итте.

2019 ел нәтиҗәләре буенча республикада гамәлдә булган АГСС челтәренә уртача йөкләнеш 34% тәшкил итте, бу программаны гамәлгә ашыра башлаганнан 6 тапкыр югарырак.

2019 елда Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендә 2 АГССЧ файдалануга тапшырылды.

Автомобильләрне газ-мотор ягулыгына күчерү буенча иң актив эшләр «РариТЭК Холдинг» акционер җәмгыяте, «ШАНС», «АвтоЭкоСистемалар» ГК, «МТЗ-Татарстан» ТПК алып барыла.

Шулай ук «РариТЭК Холдинг» акционер җәмгыяте сыекландырылган табигый газда эшләү өчен җиһазлар җитештерү эшен башлап җибәрде. «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясе» акционер җәмгыяте «КАМАЗ» сәнәгать компонентлары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «РариТЭК Холдинг» акционер җәмгыяте белән берлектә сыекландырылган табигый газда эшләүче җирле «Чайка-СПГ» линияләре өчен йөреп кайту-экскурсия судносы төзи. Күрсәтелгән судно республика елга линияләрендә эшләячәк.

Дәүләт күзәтчелеген тормышка ашыру кысаларында һәм автотранспортның атмосфера һавасы торышына тискәре йогынтысын киметү максатыннан, Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы белгечләре, ЭЭМның Татарстан буенча ЮХИДИ идарәсе белән берлектә, ел саен «Саф һава» операциясе үткәрә, аның барышында автотранспорт чараларының төтен газларында пычраткыч матдәләр микъдарының инструменталь үлчәме гамәлгә ашырыла. Әлеге операцияне уздыру барышында 2019 елда Татарстан Республикасының 24 предприятиесе тикшерелде.

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе инспекторлары белән берлектә атмосфера һавасының пычрануы югары дәрәҗәдә булган кайбер шәһәрләрнең автомобиль юлларында һәм предприятиеләрдә автомобильләрнең төтен газларындагы пычраткыч матдәләр микъдарын сайлап алу инструменталь контроле үткәрелде.

Операция кысаларында республика предприятиеләрендә һәм автомобиль юлларында 2019 елда барлыгы 5 838 автомашина тикшерелде, аларның 303 автомашина (5,2 процент) төтен газларындагы пычраткыч матдәләр чыгаруның таләп ителгән нормативларына туры килми.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә, төтен газларында пычраткыч матдәләр микъдары югары булган транспорт чараларын линиягә чыгарган, шулай ук эксплуатацияләгән өчен, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы инспекторлары һаваны саклау законнарын бозу турында 222 беркетмә, шул исәптән вазыйфаи затларга карата 19 һәм физик затларга карата 203 беркетмә төзегән, алар буенча 35,5 мең сумлык штраф салу турында карарлар кабул иткән.

Берничә ел дәвамында республика территориясендә эшкәртелгән газларда зарарлы матдәләр микъдары арткан автомобильләр саны кимү тенденциясе күзәтелә,

бу автомобиль паркын акрынлап яңарту, физик һәм мораль искергән транспорт чараларын эксплуатацияләүдән этаплап чыгару, шулай ук АЯССларда яхшыртылган экологик характеристикалы, ЕВРО-4 һәм ЕВРО-5 таләпләренә туры килә торган мотор ягулыгын җитештерү һәм сату белән бәйле. Күрсәтелгән ягулыкны югары дәрәҗәдә чистарту хисабына ул янганда барлыкка килгән пычраткыч матдәләр саны кими.

***51. Каты коммуналь калдыклар күләмен киметүгә юнәлтелгән чаралар турында. Каты коммуналь калдыкларны аерым җыюны стимуллаштыру механизмын булдыру турында.***

Каты коммуналь калдыкларны (алга таба – ККК) җыю, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә аларны аерым туплану тәртибе (алга таба – туплау тәртибе) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 21 декабрь, 1202 нче карары белән расланган.

Күрсәтелгән тәртип нигезендә каты көнкүреш калдыкларын туплау фәкать каты көнкүреш калдыкларының утиль морфологик компонентларын икенчел матди ресурслар сыйфатында куллану мөмкинлеген тәэмин итүче ысуллар белән гамәлгә ашырыла.

Каты көнкүреш калдыкларын аерым туплау кулланучылар тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын морфологик компонентлар буенча бүленүне, морфологик компонентлар буенча бүленгән каты көнкүреш калдыкларын каты көнкүреш калдыкларын аерым туплау өчен билгеләнгән контейнер мәйданчыкларына күчерүне, тиешле контейнерларда һәм бункерларда каты көнкүреш калдыкларын морфологик компонентлар аерым җыеюны күздә тота. Каты көнкүреш калдыкларын аерым туплаганда утильләштерелергә тиешле морфологик компонентлар бүленә.

Каты көнкүреш калдыкларын аерым туплау нигездә дуаль схема буенча гамәлгә ашырыла, ул туплану тәртибе Татарстан Республикасы территориясендә каты көнкүреш калдыкларын аерым туплауның төп ысулы буларак билгеләнә.

ККК аерым туплау схемасын гамәлгә ашырганда, дуаль схемага караганда күбрәк контейнерлар, аерым туплана торган морфологик компонентлар өчен, туплану тәртибендә күрсәтелгән язма билгеләмәләр һәм төс индикациясе булган контейнерлар кулланыла ала.

2.1.7.3550-19 (2.5пункт) санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә каты көнкүреш калдыкларын аерым җыю аерым җыелган каты көнкүреш калдыкларында органик алдыкдар һәм тормыш эшчәнелеге калдыклары булырга тиеш.

Республиканың муниципаль берәмлекләреннән алынган мәгълүматларга караганда, контейнер мәйданчыкларының 20 процентында каты көнкүреш калдыкларын аерым туплау мөмкинлеге оештырылган.

Хәзерге вакытта республиканың күп кенә шәһәрләрендә контейнер мәйданчыкларында полиэтилен шешәләр, көнкүреш химиясеннән пластик савытлар, пластик канистрлар өчен челтәрсыман контейнерлар урнаштырылган.

Моннан тыш, халыктан утиль чимал кабул итү пунктлары эшли, анда халыкка катыргы, кәгазь, алюминий банкалар һәм каты көнкүреш калдыкларының башка утиль морфологик компонентларын утильләштерүгә тапшырган өчен акча түләнә (катыргы – килограммы 6 сум, макулатура – 5 сум, полиэтилен шешә – 5 сум, ПНД

(түбән басымлы полиэтилен) канистрлар – 5 сум, ПНД (көнкүреш химиясе) – 5 сум, буялмаган пленка – 5 сум, азык алюминие, банклар – 35 сум).

Казан шәһәрендә «Чиста мохит» проекты кысаларында халыктан икенчел чималны кабул итүнең махсуслаштырылган пунктлары эшли, анда каты көнкүреш калдыкларының 11 төре (шул исәптән полиэтилен шешәләр, ПНД канистрлары, көнкүреш химиясеннән ПНД савыты, пленка) утильләштерүгә кабул ителә.

Моннан тыш, Казан шәһәрендә «ТР – Инвест» фандоматларын урнаштыру буенча пилот проекты старт алды. Яңа үрнәктәге беренче кабул итүләр яшь кешеләрне аерым җыюга актив тоташтыру максатыннан уку йортларында барлыкка киләчәк. Тапшырылган һәр шешә өчен шәхси счетка бонус баллар исәпләнәчәк.

***52. Хуҗасыз хайваннар белән эш итү мәсьәләләрен җайга салу өлешендә Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.***

2020 елның 1 гыйнварыннан «Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 498-ФЗ номерлы Федераль закон) төп нигезләмәләре үз көченә керде, алар, аерым алганда, потенциаль куркыныч токым этләрне һава сулату, хайваннар өчен приютлар эшчәнлеге һәм хуҗаларсыз хайваннан белән эш итү белән бәйле мәсьәләләрне җайга сала.

498-ФЗ номерлы федераль закон хуҗаларсыз хайваннар белән мөрәҗәгать итү буенча төп чараларга түбәндәгеләр кертә: хайваннарны тоту, хайваннар өчен приютларда тоту, югалган хайваннарны аларның хуҗаларына кайтару, агрессив булмаган хайваннарны аларның элеккеге яшәү урыннарына кире кайтару, аларны яңа хуҗаларына тапшырганчы яки аларның табигый үлеме җиткәнчегә кадәр хайваннарны приютларда урнаштыру.

498-ФЗ номерлы Федераль законны төбәк дәрәҗәсендә гамәлгә ашыру максатларында «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) кабул ителде.

2014 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына хуҗаларсыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу буенча вәкаләтләр бирелде («Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

Җирле үзидарә органнарына хуҗаларсыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу буенча тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән күләмнәрдә субвенцияләр бүлеп бирелә. Җирле үзидарә органнарына 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан 27,5 млн сум бүлеп бирелгән.

2020 елда җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән субвенция күләме, Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле үзидарә органнары тарафыннан хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләүнең яңа методикасын раслау белән бәйле рәвештә, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә 56,5 млн. сумга кадәр арттырылды («Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль стандартларны һәм натураль нормаларны үстерү турында» 2000 ел, 5 июль, 470 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында ветеринария хезмәте учреждениеләрен тоту чыгымнарының социаль стандартларына һәм натураль нормаларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 1 ноябрь, 995 нче карары белән Махсуслаштырылган предприятиеләр тарафыннан хуҗаларсыз хайваннарны тоту, транспортлау, карап тоту, исәпкә алу һәм санын җайга салу чараларын тормышка ашыру өчен чыгымнар нормалары стандартлары актуальләштерелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән Татарстан Республикасы территориясендә хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе расланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 гыйнвар, 65 нче карары белән даими түбәндәге территорияләрдә яшәүче 1 мең кешегә хуҗаларсыз хайваннар саны нормативы билгеләнгән:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары территориясендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясеннән тыш – 2 баш;

Татарстан Республикасы «Казан шәһәре», «Чаллы шәһәре» шәһәр округлары һәм Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре территорияләрендә – 2,8 баш.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 11 февраль, 90 нчы карары белән Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе расланды.

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы

территориясендә хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 февраль, 150 нче карары чыгарылды.

Шулай итеп, югарыда әйтелгән кабул ителгән законнар һәм законлы норматив хокукый акт нормалары җирле үзидарә органнарына хуҗаларсыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм санын җайга салу буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешле дәрәҗәдә гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

***53. Шәхси милектә булган һәм озак вакыт билгеләнеше буенча файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне максатчан файдалануга юнәлдерелгән чаралар турында.***

Татарстан Республикасы буенча 2019 елда 43 мең гектар авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге файдаланылмый торган җир ачыкланды, шулардан 7,9 мең гектар җир авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертелгән. Бүгенге көндә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге файдаланылмый торган җирләр мәйданы 35,1 мең гектар тәшкил итә.

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – Росреестр) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына җирләрдән файдаланмау фактлары турында белешмәләр кертү өчен 117 материал, шулай ук Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына файдаланылмый торган җир кишәрлеген алу өчен 1 материал тапшырылды.

Файдаланылмый торган җирләр барлыкка килүнең төп сәбәпләре – аларны торак пунктлар чикләренә нигезсез кертү, авыл хуҗалыгы предприятиеләренең бөлгенлеккә төшүе һәм кредит оешмаларында җирләрне залогка салу.

Административ җаваплылыкка тартмас һәм киләчәктә җир кишәрлекләрен тартып алмас өчен милекчеләр бер тапкыр кулланыла торган агротехник чаралар (дисклау, сөрү, печән чабу) үткәрәләр, аларны алга таба чәчмиләр, бу тагын да күбрәк чүп үсүгә китерә. Файдаланылмый торган җирләрне «торак пунктлар» һәм «сәнәгать җирләре» җирләренә күчерү тенденциясе бар. Әмма аларда авыл хуҗалыгы җитештерүе дә, төзелеш тә алып барылмый.

Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә файдаланылмый торган җирләрне файдалануга тапшыру мәсьәләсе буенча зона семинарлары, шулай ук муниципаль контроль буенча укулар үткәрелә.

***54. Татарстан Республикасы территориясендә туфракның уңдырышлылыгын саклап калуга һәм арттыруга юнәлдерелгән чаралар турында.***

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан, ведомство буйсынуындагы оешмалар белән берлектә, «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә игенчелекнең биологик системасын гамәлгә кертү» ведомство программасы (алга таба – Программа) эшләнде.

Программаның максаты – туфракның уңдырышлылыгын арттыру һәм саклап калу, туклану элементларының уңай балансына ирешү, үсемлекчелек продукциясен җитештерүне стабильләштерү.

Программаның максатчан күрсәткечләре булып тора:

4,5 т/га артык коры органик матдә (КОМ) кертүне тәэмин итү;

туфрак-климат зонасына карап, күпьеллык үләннәрнең тәкъдим ителә торган мәйданы – 15-21 процент (Татарстан Республикасы буенча – 17 процент);

бөртекле-кузаклы культураларның чәчү мәйданы – сөрүлек җирләренең 4 проценты;

табигый-климат зонасына бәйле рәвештә сидераль парларның һәм пожнив чәчүлекләрнең мәйданы – сөрүлек җирләренең 20-24 проценты (Татарстан Республикасы буенча – 22,3 процент);

майлы әвернә чәчәклеләр культураларның чәчү мәйданы – сөрүлек җирләренең 5 проценты;

ел саен туфракны известьлау күләме – 100 мең гектар;

2 мең гектардан да ким булмаган мәйданда агролесомелиорация эшләре башкару.

«2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә игенчелек буенча биологик системаны гамәлгә кертү» программасын финанслау федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклардан, шул исәптән кредит ресурсларыннан файдалану хисабына гамәлгә ашырылачак. Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауның гомуми күләме 7 950 млн сум тәшкил итәчәк.

Программаны тормышка ашыру шактый икътисади нәтиҗәгә ирешергә, республиканың агросәнәгать комплексының тотрыклы үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк, әйләнә-тирәлекнең торышын яхшыртачак һәм туфраклардан рациональ файдалануга китерәчәк. Моннан тыш, үзкыйммәтен киметкәндә югары продуктивлылык һәм продукция сыйфаты булган авыл хуҗалыгы культураларын үстерергә, туфракның уңдырышлылыгын арттыру темпларын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

***55. Җир кишәрлекләрен комплекслы инвентаризацияләү һәм үзәкләштерелгән кадастр исәбенә алу сроклары турында, шул исәптән бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәтләренең территорияләре чикләрендә дә.***

2015 елның 28 маендагы 18 номерлы «Күчемсез милекне теркәү һәм кадастр исәбенә алуның бердәм дәүләт системасын үстерү (2014 – 2020 еллар)» федераль максатчан программасын тормышка ашыру буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте белән хезмәттәшлек итү турындагы килешү нигезендә комплекслы кадастр эшләрен үткәрү чараларын гамәлгә ашыру мөмкинлеге каралган.

Комплекслы кадастр эшләре шартлары буенча, чараны гамәлгә ашыру, финанслау шартларында, Россия Федерациясе субъектларының консолидацияләнгән бюджетлары хисабына, федераль бюджет чаралары хисабына тормышка ашырылырга тиеш. 2020 елга комплекслы кадастр эшләрен үткәрү өчен федераль

бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына 200 млн сум күләмендә субсидияләр бүлеп бирү каралган.

Татарстан Республикасыннан 2020 елда комплекслы кадастр эшләрен финанслауга федераль бюджеттан 82,3 млн сум субсидия алуга гариза җибәрелгән, шул исәптән федераль бюджеттан 72,3 млн сум күләмендә планлаштырылган субсидия һәм 10 млн сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау исәбенә, шулай ук Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә гаризаны тәэмин итү максатларында гарантия хаты (2009 елның 28 февраленнән чыгу номеры тиешенчә № 12-51/2342 һәм № 12-51/2341).

Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен гаризаларны карау комиссиясе тарафыннан комплекслы кадастр эшләрен үткәрүне финанслашу максатларында 2020 елда Татарстан Республикасының комплекслы кадастр эшләрен үткәрүгә субсидия бүлеп бирү мөмкин булмау турында карар кабул ителде. Шуңа бәйле рәвештә, билгеләнгән вакытта 2021 елга тиешле гариза формалаштырылачак.

Хәзерге вакытта 2020 һәм 2021 елларга Татарстан Республикасы бюджетында комплекслы кадастр эшләрен башкаруга максатчан акча каралмаган. Муниципаль районнар мәгълүматларына караганда, әлеге эшләрне, шул исәптән бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәтләре территорияләре чикләрендә дә үткәрү планлаштырылмый.

***56. Бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәтләрен хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү процедурасын гадиләштерү перспективалары турында.***

Эчәргә яраклы су чыгару өчен документлар җыю белән бәйле эшмәкәрләр һәм бакчачыларның мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча су җыю скважиналарын лицензияләү өчен кирәкле документларны җыю һәм рәсмиләштерүдә кайбер кыенлыклар ачыкланды.

Иң актуаль проблемалар булып тора:

эшмәкәрләр һәм бакчачылар өчен әлеге чараларны тормышка ашыруның югары бәясе белән бәйле лицензияне алу өчен суның сыйфатын санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китерү;

җир асты суларын чыгару буенча эшчәнлекне тормышка ашыруга лицензия алганчы эшмәкәрләр һәм бакчачылар тарафыннан су алу скважиналарыннан файдалану.

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы белән җир асты суларын чыгаруга җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү өчен кирәкле документлар исемлегенә конкрет таләпләр билгеләнмәгән. «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 3 пункты нигезендә су объектыннан конкрет күрсәтелгән максатларда файдалану су объектының санитар кагыйдәләргә һәм халык саулыгы өчен су объектыннан файдалану куркынычсызлыгы шартларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик нәтиҗә булганда рөхсәт ителә дип билгеләнә.

Әмма лицензияне рәсмиләштерүнең кайсы этабында күрсәтелгән санитар-эпидемиологик бәяләмә алынырга тиешлеге тәгаенләнмәгән.

Россия Федерациясенең кайбер субъектлары төбәк норматив актларында әлеге бәяләмәне җир асты суларын чыгаруга лицензия алу этабында түгел, ә лицензия алганнан соң лицензия шартларын үтәү этабында алу зарурлыгы турындагы нигезләмәне беркеттеләр.

Шуңа бәйле рәвештә, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проекты эшләнде һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына җибәрелде, ул башлангыч этапта эксплуатацияләүче оешмалар өчен рөхсәт документларын рәсмиләштерү процессын гадиләштерергә, су белән тәэмин итү чыганагын, шул исәптән коммерциячел нигездә дә, алга таба санитар-эпидемиологик экспертиза үткәрүгә киткән чыгымнарны өлешчә каплау өчен куллана башларга мөмкинлек бирәчәк.

2019 ел дәвамында коммерциячел булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен лицензияләүнең гадиләштерелгән тәртибе гамәлдә булды. Лицензиянең гадиләштерелгән тәртибе гамәлдә булган чорда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына тиешле лицензияләрне рәсмиләштерүгә 240 гариза керде, 90 лицензия рәсмиләштерелде. Калган 150 гариза керү чираты тәртибендә каралачак.

### *57. О мерах, направленных на беспрепятственную передачу земель общего пользования в общедолевую собственность членов садоводческих или огороднических некоммерческих товариществ. Бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәтләре әгъзаларының гомуми файдаланудагы җирләрен өлешләп милкенә тоткарлыксыз тапшыруга юнәлдерелгән чаралар турында*

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2.7 пункты нигезендә милеккә бушлай бирү өчен җир кишәрлеге бер үк вакытта түбәндәге шартларга да туры килергә тиеш:

коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте (алга таба – КББШ) яки ул төзелгән яисә оештырылган башка оешма тарафыннан бакчачылык алып бару өчен 2001 елның 10 ноябренә кадәр бирелгән җир кишәрлегеннән оештырылган;

гражданга СНТ әгъзаларының гомуми җыелышы карары яисә җир СНТ җир кишәрлекләрен бүлүне билгели торган башка документ нигезендә бүленде;

әйләнештән алынмаган, әйләнеше чикләнмәгән һәм аңа карата дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау турында карар кабул ителмәгән.

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 217-ФЗ номерлы Федераль Закон) нигезендә 2019 елның 1 гыйнварыннан

гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлекләрен бакча һәм яшелчә бакчасы җирләре кишәнлекләре милекчеләренең гомуми өлешле милкенә бирү каралган.

217-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен алу турында, күрсәтелгән җир кишәрлекләрен алу өчен кирәкле гамәлләр башкару турында карар кабул итү ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышының аерым компетенциясенә керә. Мондый карар кабул итү өчен ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышында катнашучыларның өчтән ике өлеше тавыш бирергә тиеш (217-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 2 өлеше).

217-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 15 өлеше нигезендә милек хокукында ширкәткә караган күчемсез мөлкәт булган бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциячел булсаган ширкәтенең гомуми файдаланудагы мөлкәтен үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләре булган затларның гомуми өлешле милкенә үләүсез тапшыру турында мәсьәлә 2024 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышына чыгарылырга тиеш.

### ***58. Алга таба Россия базарына чыгу белән селекция эшен (үсемлекчелек, нәсел терлекчелеге һәм кошчылык) торгызу буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын эшләү перспективалары турында.***

Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы культуралары селекциясе белән Татар авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты – «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең (алга таба – ТатНИИСХ) аерымланган структур бүлекчәсе шөгыльләнә, анда 15 культураның 160 сорт һәм гибридлары булдырылган. Тикшеренүләрнең яңалыгы Россия Федерациясенең селекция казанышлары һәм уйлап табуларына 194 патенты белән белән якланган, шуларның 45е – гамәлдә. Хәзерге вакытта Россия Федерациясенең селекция казанышлары дәүләт реестрына (алга таба – РФ Дәүләт реестры) 88 сорт һәм гибрид кертелгән, алар Россия Федерациясенең 32 төбәге җитештерүендә эшли.

Соңгы елларда сортларны булдыруның интенсивлыгы шактый артты. 5 ел эчендә авыл хуҗалыгы культураларының 46 сорты булдырылган, аларның 24е РФ Дәүләт реестрына кертелгән, 22се дәүләт сорт сынавы уза.

ТатНИИСХ 2017 – 2025 елларга авыл хуҗалыгын үстерүнең Федераль фәнни-техник программасын гамәлгә ашыруда катнаша. Максаты – авыл хуҗалыгы предприятиеләрен үзебезнең бәрәңге сортларының сыйфатлы орлык материалы белән тәэмин итү һәм бәрәңгенең чит илдән кертелгән орлык материалына бәйлелеген киметү.

Татарстан Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты базасында Россия Федерациясе Югары белем һәм фән министрлыгы инициативасы белән Селекция һәм бәрәңге орлыгы үзәге булдырылды, алар Россия Федерациясендә барлыгы 7.

Гомумән алганда, соңгы 10 елда институтта бәрәңгенең вируска чыдам 6 сорты булдырылган. Ел саен Россия селекциясенең 70 сорт авыл хуҗалыгы культураларын экологик-географик сынау үткәрелә.

Татарстан Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында сәламәтләндерелгән меристем нигезендә бәрәңге орлыкчылыгы системасы эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән. Институтның биотехнология комплексы 800 тоннадан артык савыктырылган орлык бәрәңгесен җитештерергә мөмкинлек бирә, ул Халыкара сыйфат стандартларына туры килә.

Моннан тыш, «Бәрәңгенең биоресурс коллекциясе» күмәк файдалану үзәге булдырылды, ул авыл хуҗалыгы культураларының 523 сортын һәм гибридын үз эченә ала.

Татарстан Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының авыл хуҗалыгы культуралары селекциясе өлкәсендәге планлы эшен исәпкә алып, үсемлекчелек буенча селекция эшен торгызу буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын эшләү максатка ярашлы түгел.

Татарстан Республикасында нәсел терлекчелеген үстерү буенча эш дәвам итә, аның максаты – ныклы нәсел базасын булдыру, аны саклап калу һәм арттыру.

Хәзерге вакытта республикада авыл хуҗалыгы хайваннарының нәсел базасы 75 хуҗалыкта бар, алардан:

сөт терлекчелегендә – 13 нәсел завод һәм 40 нәсел репродукторы;

ит терлекчелегендә – 3 нәсел репродукторы;

дуңгызчылыкта, сарыкчылыкта һәм җәнлек үрчетүдә – 2шәр нәсел репродукторы һәм 1 нәсел заводы;

кәҗәчелектә – 1 нәсел заводы;

атчылыкта – 4 нәсел репродукторы;

кошчылыкта – 2 нәсел репродукторы (шул исәптән 1әү «Линдовская» токымлы казлар үрчетү буенча);

умартачылыкта – 3 нәсел репродукторы.

Сөт терлекчелегендә 58,7 мең баш сыер нәселле санала, бу барлык санның 25,6 процентын тәшкил итә. Кара-чуар, Татарстан тибындагы холмогорск токымнары, симменталь һәм голштинская токымнары.

Нәсел хуҗалыкларында 2019 елда продуктивлылык 7 642 кг (+470 кг), яки 2018 елга карата 106 процент тәшкил итте.

Нәселле терлек башының генетик потенциалы шактый югары, барлык технологик таләпләрне үтәү хайваннарның мөмкинлекләрен ачуга ярдәм итә.

Ит терлекчелеге лимузин, абердин-ангус, герефорд токымнары белән тәкъдим ителгән (ит юнәлешендәге 1 мең баш нәселле сыер – ит юнәлешендәге барлык сыерларның 10,1 проценты).

Дуңгызчылыкта 4,3 мең баш нәселле ана дуңгыз исәпләнә (ана дуңгызларның гомуми баш санының 17,8 проценты). Дуңгызларны аталандыру өчен ландрас, дюрок, пьетрен һәм кроссов чит ил токымнары файдаланыла.

Республикада шулай ук сарыкчылык буенча нәсел базасы сакланып калган. Нәселле ана сарыкларның гомуми саны 3,5 мең баш тәшкил итә (аналарның гомуми баш санынннан 13%). Нәселле репродукторлар түбәндәге токымлы сарыклар үрчетәләр: романовский, эдильбаевск, татарстан.

2019 елда сәнәгать тибындагы ике сарыкчылык комплексы төзү буенча сынау проектлары эшли башлады: Әлмәт муниципаль районында С.Ю. Заикин крестьян

(фермер) хуҗалыгы – 5 000 башка һәм Алабуга муниципаль районында О.Ю. Фалалеев КФХда – 2 100 баш ана сарык үрчетелә.

Атчылыкта да селекция уңышлары бар. 2019 елның 6 февралендә сакланыла торган селекция казанышлары дәүләт реестрында татар токымлы атларга патент теркәлгән.

2019 елда Россия Федерациясе төбәкләрендә нәселле терлек сату турында мәгълүмат

| Россия Федерациясе төбәкләре | Баш саны | |
|---|---|---|
| | башмак тана | шешәк сары |
| Чуаш Республикасы | | 136 |
| Мәскәү өлкәсе | | 266 |
| Башкортстан Республикасы | 10 | |
| Ульяновск өлкәсе | 141 | |
| Марий Эл Республикасы | 19 | 355 |
| Пенза өлкәсе | 26 | |
| Киров өлкәсе | 47 | |
| Барысы | 243 | 757 |

***59. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен, шулай ук җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү турында.***

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон), шулай ук «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хакимиятнең һәр дәрәҗәсенә 19дан 44кә кадәр вәкаләт беркетелгән.

112 федераль законда өстәмә рәвештә җирле үзидарә органнарына 800дән артык төрле вазыйфа йөкләнгән, шуларның 250е 131-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларыннан чыга. Мисал итеп җирле үзидарә органнарының мәҗбүри күченүчеләргә шәхси торак төзелешендә ярдәм күрсәтү, шул исәптән җир кишәрлеге бирү һәм төзелеш материаллары сатып алу буенча, экологик экспертизалар оештыру буенча, бакчачылык ширкәтләренә ярдәм күрсәтү буенча һәм башка күп вәкаләтләрен атарга мөмкин.

2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары, тәкъдим ителгән федераль индексларны-дефляторларны исәпкә алып, республиканың берләштерелгән бюджетын формалаштыруның бердәм сценар шартларыннан чыгып формалаштырылды.

2020 елга бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда җирле бюджетлар закон белән беркетелгән керемнәр буенча 33,1 млрд сум күләмендә фаразланган, бу 2019 ел дәрәҗәсенә карата 1,4 млрд сумга, ягъни 4,4 процентка үкән. Җирле

бюджетларның үз вәкаләтләре буенча чыгымнары 2020 елга 55,5 млрд сум күләмендә билгеләнгән, ул 2019 елга карата 2,1 млрд сумга, ягъни 4 процентка арткан.

Шулай итеп, 2020 елга муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларының чыгым вәкаләтләрен беркетелгән керемнәр белән тәэмин итү уртача 59,7 процент тәшкил итте.

Җирле бюджетларның балансылыгы проблемасы ел саен бюджетара җайга салу аша хәл ителә.

2020 елга җирле бюджетларның балансылыгы максатларында Татарстан Республикасы бюджетында җирле бюджетларга 10,3 млрд сум күләмендә дотацияләр һәм субсидияләр каралган. Моннан тыш, җирле бюджетларга муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең бер өлешен алмаштыручы өстәмә нормативлар буенча физик затлар керемнәренә салым 12,3 млрд сум күләмендә күчерелергә тиеш.

Финанс ярдәмен исәпкә алып, 2020 елга республика җирле бюджетлары керемнәренең гомуми күләме 55,7 млрд сум, «тискәре трансфертлар»ны түләү буенча йөкләмәләрне исәпкә алып, үз вәкаләтләре буенча чыгымнар күләме 55,5 млрд сум күләмендә каралган.

Шулай итеп, 2020 елга җирле бюджетлар чыгымнарны формалаштыруның сценар шартларында дефицитсыз булып тора.

Ел саен Татарстан Республикасы бюджетын үтәү барышында Татарстан Республикасы бюджетыннан республика районнарына һәм шәһәрләренә өстәмә рәвештә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук муниципаль учреждениеләрне үстерүне һәм муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын күтәрүне тәэмин итә торган чараларны тормышка ашыруга акча юнәлдерелә.

Шулай итеп, 2019 ел дәвамында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга беренчел бүлеп бирелгән финанс ярдәме өчен өстәмә рәвештә 11,1 млрд сум күләмендә бюджетара трансфертлар бирелде.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, муниципаль берәмлекләр бюджетлары ел саен салым һәм салым булмаган керемнәр буенча беренчел расланган план билгеләнешләреннән шактый артып китә.

Муниципаль берәмлекләр бюджетларына 2019 елда үз керемнәре 49,6 млрд сум күләмендә кергән, бу расланган планга карата 114 процент тәшкил итә. 2019 ел нәтиҗәләре буенча беренчел расланган план нигезендә җирле бюджетларның салым һәм салым булмаган керемнәре 6,1 млрд сум тәшкил иткән.

Югарыда күрсәтелгән җирле бюджетларның план күрсәткечләреннән тыш ел дәвамында алынган үз керемнәре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү буенча чыгымнарны финанслауның өстәмә чыганагы булып тора.

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы законы белән 2020 елга җирле бюджетларга 28,9 млрд сум күләмендә субвенцияләр каралган.

***60. Халыкны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү чаралары турында.***

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны оештыру җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә керә. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү белән барлыкка килә торган финанс йөкләмәләре җирле бюджет акчалары хисабына үтәлә.

Моннан тыш, ел саен Татарстан Республикасы бюджетыннан республиканың торак пунктларында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларын төзү һәм ремонтлауга акча бүлеп бирелә.

2019 елда авылларны су белән тәэмин итү программасын гамәлгә ашыруга («Чиста су») Татарстан Республикасы бюджетыннан 654,2 млн сум бүлеп бирелгән, 2020 елга Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга 650 млн сум каралган.

2019 елда су бүлү системаларын модернизацияләү, канализация системаларын һәм корылмаларын төзү һәм капиталь ремонтлау буенча чараларны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 224,8 млн сум тотылган, 2020 елга Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга 317,1 млн сум каралган.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында 3 меңнән артык су алу җайланмасы файдаланыла, шул ук вакытта нибары 1 220 лицензиягә ия, шуларның 996 лицензиясе авыл җирендә яшәүчеләрне эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен бирелгән, калган лицензияләр предприятиеләрне хуҗалык-эчәргә яраклы яки техник су белән тәэмин итү өчен бирелгән. Судан файдалану килешүләре булмаган чишмәләр саны 306.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Экология министрлыгы), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә, Экология министрлыгы тәкъдим иткән «2020 – 2025 елларга авыл җирлекләрендә су белән тәэмин итү чыганакларын лицензияләүне геологик тәэмин итү» программасы проектын (алга таба – Программа) тормышка ашыруны финанслау күләмнәрен, төрләрен, бәясен һәм чыганаклары буенча фикер алышу буенча эш алып бара.

Программаның төп максаты – авыл халкын эчә торган су белән тәэмин итүче су алу җайланмаларын (скважиналарны һәм чишмәләрне) лицензияләүгә документлар әзерләүдә авыл җирлекләренең финанс йөкләнешен киметү.

Халыкны эчә торган су белән тәэмин итә торган су алу җайланмаларының санын төгәл билгеләү, шулай ук аларның перспективасын билгеләү өчен, җентекле ревизия үткәрү кирәк, аның нәтиҗәләре түбәндәгеләр булачак:

халыкны җир асты чыганакларыннан сыйфатлы су белән тәэмин итәргә сәләтле перспектив су алу җайланмаларын билгеләү;

һәр су алу җайланмасы өчен дә, һәр муниципаль район буенча гомуми су алу скважиналарына лицензияләү процедурасының шәхси исәп-хисабы.

Программаның чираттагы этабы булып авыл җирлекләрендә су белән тәэмин итү чыганакларын (скважиналарны һәм чишмәләрне) лицензияләүне геологик тәэмин итү буенча чаралар үткәрү тора.

***61. 2019 елда гражданнарның үзара салым программасын гамәлгә ашыру һәм 2020 елга фаразлар турында.***

Муниципаль берәмлекләрне социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсен һәм халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә стимуллаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның үзара салымы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары кабул ителгән (алга таба – Тәртип). Карар белән гражданнарның үзара салым салу кертелгән муниципаль берәмлекләр бюджетларына республикасы бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирү каралган.

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына кергән гражданнарның үзара салым акчасының 1 сумына 4 сум нисбәтендә билгеләнгән.

Гомумән алганда, 2014 – 2019 елларда Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның гомуми суммасы 4 189,2 млн сум тәшкил итте.

Еллар буенча бүлеп бирелгән акчалар динамикасы түбәндәгечә күренә:

2014 елда – 277,7 млн сум;

2015 елда – 449,5 млн сум;

2016 елда – 720,1 млн сум;

2017 елда – 835,6 млн сум;

2018 елда – 899,7 млн сум;

2019 елда – 1 006,6 млн сум.

Гражданнарның үзара салым акчаларын финанслашу программасы 2020 елда һәм 2021 – 2022 елларның план чорында дәвам итәчәк. 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларына ел саен 1 млрд сум күләмендә бюджетара трансфертлар каралган.

Гражданнырның үзара салым программасын тормышка ашыру чорында референдумнар үткәрү һәм үзара салым акчаларын финанслау механизмы буенча сораулар килеп чыкты. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 3 октябрь, 706 нчы карары белән чираттагы финанс елы башланганчы референдумнар үткәрү өлешендә үзгәрешләр кертелде, бу сезонлы эшләр башланганчы халыктан максималь акча җыюны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

2013 елда референдумнар 93 җирлектә, 2014 елда – 655, 2015 елда – 799, 2016 елда – 796, 2017 елда – 856, 2018 елда – 844, 2019 елда – 839 муниципалитетта узды.

2015 елда үзара салым буенча референдум нәтиҗәләре буенча гражданнарның акчалары җыю 87,9 процент тәшкил итте, 2016 елда – 86,6 процент, 2017 елда – 86,9 процент, 2018 елда – 82 процент, 2019 елда – 82,9 процент.

2019 елда гражданнардан үзара салым мәсьәләләре буенча җирле референдумнар 54 муниципалитетта узды: 47сендә узган, муниципаль районнарның 7 җирлегендә узмаган дип танылды.

2018 елдан башлап, федераль законнардагы үзгәрешләр нигезендә, үзара салым мәсьәләләре буенча референдумнар белән беррәттән, гражданнар җыеннары да үткәрелә.

2019 елга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыеннар Татарстан Республикасының 8 муниципаль районының 36 җирлеге составына керүче 93 торак пунктта үткәрелде.

Күпчелек торак пунктларда гражданнар 50 – 60 процент (уртача 54,2 процент) килгән. Үзара салым буенча түләүләр суммасы бер кешедән 100 сумнан алып 2000 сумга кадәр күләмдә билгеләнде.

2020 елга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыеннар барлык муниципаль районнарда 2 431 торак пунктта, шул исәптән этаплап 589 торак пунктта үткәрелде.

Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп үткәрелә торган чаралар структурасы 2019 елда түбәндәгечә күренә:

49,9 процент – юл эшләре (шул исәптән күперләрне карап тоту);

18 процент – җирлек территориясен төзекләндерү;

9,1 процент – су белән тәэмин итү эше;

7,5 процент – зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту;

4,2 процент – спорт һәм балалар мәйданчыкларын төзү, төзекләндерү;

2,7 процент – янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;

2,7 процент – массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү;

2,3 процент – башка чаралар;

2,1 процент – һәйкәлләр, стеллалар һ.б.ш. кую һәм төзекләндерү;

0,9 процент – транспорт чарасы;

0,4 процент – елга һәм күлләрне чистарту;

0,3 процент – юлларны карап тоту;

0,03 процент – буаларны ремонтлау һәм карап тоту.